ЖЮЛЬ ВЕРН

СЕРЛЕ УТРАУ

ЖЮЛЬ ВЕРН



СЕРЛЕ УТРАУ

РОМАН

ИКЕНЧЕ, ӨЧЕНЧЕ КИСӘКЛӘР

Фәния Гайнанова тәрҗемәсе

КАЗАН • ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ • 1984

ББК 84.3 Фр.
В31

Жюль Верн. Собрание сочинений в двенадцати томах, том 5. Таинственный остров. Издат. худ. лит. М., 1956.

Верн Жюль

В31 Серле утрау: Роман. Икенче, өченче кисәкләр. Ф. Гайнанова тәрҗемәсе.— Казан: Тат. кит. нәшр., 1984.— 368 бит.

Романның беренче кисәге 1981 елда басылып чыкты. Бу китап шуның дәвамы.

В $\frac{4703000000-245}{М132(03)-84}$ 171—84 ББК 84.3 Фр.

© Русчадан тәрҗемә. Татарстан китап нәшрияты, 1984.

ИКЕНЧЕ КИСӘК

ТОТКЫН

Беренче бүлек

Ядрә хакында бәхәс.— Көймә ясау.— Ауда.— Герберт агач башына менә.— Утрауда кеше яшәгәнлеге сизелми.— Чалкан әйләндерелгән ташбака.— Ташбака югалган.— Сайрес Смитның аңлатмасы

Качак әсирләрнең һава шары белән Линкольн утравына килеп төшүләренә төгәл җиде ай тулды. Шул вакыт эчендә ни тырышып эзләсәләр дә, утрауда алар бер генә кеше заты да очратмадылар. Әлек булсын, хәзер булсын, кайчандыр кеше яшәгәнлекне исбатларлык һичбер дәлил табылмады. Төтен-мазар чыкканы да күзгә чалынмады. Борын замандамы, хәзерме, кеше тарафыннан ясалган бер генә әйбергә дә юлыкмадылар. Утрау кеше яшәми торган җир булса кирәк; монда гомергә дә адәм аягы басмагандыр дигән нәтиҗәгә килгәннәр иде инде. Әмма мәхлук бер җәнлек тәненнән чыккан ядрә бөртеге аларның барлык фаразларын, уй-фикерләрен айкап ташлады.

Чыннан да, ул ядрә мылтыктан атылган бит инде, ә андый корал белән кем эш итә соң? Әлбәттә, кеше!

Пенкроф кургаш кисәген өстәлгә ташлагач, иптәшләре гаҗәпләнеп аңа бик озак текәлеп тордылар. Шушы юк кына нәрсәнең ахыры җәерлегә түгеллеге күз алларына килде булса кирәк. Алар күз күрмәгән, колак ишетмәгән берәр могҗизага тап булсалар да бу чаклы аптырап калмаслар иде!

Аяз көнне яшен суккандай тәэсир иткән әлеге табылдык хакында Сайрес Смит үзенең фикерен әйтергә ашыкты. Ул аны ике бармагы белән учына алып салды да, әле тегеләй, әле болай әйләндергәләп карагач:

— Пенкроф, сез бу ядрә белән җәрәхәтләнгән дуңгыз баласының өч айлык икәнен ышанып әйтәсезме? — дип сорады.

— Әйе, мистер Сайрес, шуннан артык булмас. Мин аны чокырдан тапканда ул әнисен имеп ята иде әле.

— Димәк, соңгы өч ай эчендә Линкольн утравында кемдер мылтыктан аткан...— дип йомгак ясады инженер.

— Әйе, ул аткан ядрә җәнлек баласын җәрәхәтләгән, тик үтерерлек булмаган,— дип аның сүзенә өстәп җибәрде журналист.

— Дөрес әйтәсез,— диде инженер.— Моннан без нинди нәтиҗәгә килергә тиеш инде? Димәк, утрауда безгә хәтле дә кешеләр яшәгән, яисә күп дигәндә өч айлап кына элек кемнәрдер утрауга тукталган булган. Тик үз ирекләре белән килеп утырганнар микән алар монда, әллә кораблары яки аэростатлары ватылып, ярга төшәргә мәҗбүр булганнармы,— әлегә анысын белмибез. Бу сорауларга җавапны без соңыннан табарга тырышырбыз. Шулай ук аларның Европа кешеләреме, әллә Малайяданмы, ягъни дошманнармы, әллә дуслармы икәне дә билгесез әлегә. Хәзер дә утрауда яшиләрме, әллә ташлап киткәннәрме инде? Бу мәсьәләләр безне бик кызыксындыра, шуларны ачыкламыйча без тынычлана алмаячакбыз.

Дингезче өстәл яныннан сикереп торды:

— Юк дим! Линкольн утравында бездән башка кеше яшәми. Әйттем бит инде, биредә беркем дә юк дип! Шул ук сүзләрне йөз тапкыр, мең тапкыр кабатларга ризамын! Утрау кеп-кечкенә, әгәр монда кешеләр яшәсә, моңарчы без аларны очратмый калмас идек инде! — дип кычкырды ул.

— Әгәр ул ядрә дуңгыз баласының тәнендә туганда ук булса, менә монысы могҗиза икән! — дип куйды журналист.

— Әллә ул ядрә Пенкрофның үз теше арасында кысылган иде микән? — дип сорады Наб җитди рәвештә.

Пенкроф кызып китте:

— Тагын ни диярсең! Ярты ел буе авызымда кургаш кисәге барлыгын искәрмәскә, мине кем дип белдең! Кайда кысылып торсын ул? Менә кара! — дип дингезче авызын ачып күрсәтте, аслы-өсле тезелеп киткән ап-ак таза тешләре ялтырап күренде.— Иплэп кара, Наб, анда берәр бозык теш табарсың микән? Әгәр тапсаң, менә тешләремнең яртысын суырып ал!

Уйга чумып утырган җиреннән Сайрес Смит ихтыярсыздан елмаеп куйды:

— Набның сүзе көлке, әлбәттә. Шикләнәсе юк, моннан өч ай чамасы элек утрауда кемнәрдер мылтыктан аткан. Минемчә, алар безнең утрау яныннан узып барганда бик азга гына тукталганнардыр. Югыйсә, Франклин тавы түбәсенә менеп утрау белән танышкан чакта, без аларны, алар безне күрми калмас идек. Иң дөресе, берничә атна элек узган давыл вакытында аларның кораблары ватылгандыр, шунда безнең утрауга тукталырга мәҗбүр булганнардыр. Һәрхәлдә, тиз көндә без бу хәлне ачыкларга тырышырбыз.

— Димәк, моннан соң безгә бик сак эш итәргә кирәк инде,— дип искәртте журналист.

— Мин исә бирегә Малайя пиратлары килеп чыкмады микән дип шикләнәм әле! — диде Сайрес Смит.

— Мистер Сайрес, аларны эзләп чыгып киткәнче, әллә башта көймә ясыйк микән? Көймәгә утырып елганың югары башына менәр идек, яки, кирәк дисәгез, диңгез буйларын әйләнеп кайтырга мөмкин! Искәрмәстән килеп чыкмагайлары дим.

— Киңәшең бик урынлы, Пенкроф, хуплыйм. Тик көймә ясарга ким дигәндә бер ай вакыт кирәк булачак... Алай озак көтә алмабыз шул.

— Диңгездә йөзәрлек зур көймә ясарга тотынсак, озак булыр, билгеле. Безгә андыйның кирәге юк. Үзебезнең елгада йөрерлек көймәне биш көн эчендә эшләргә мөмкин, мин анысын үз өстемә алам,— диде диңгезче.

Наб, аның сүзенә ышанмыйча:

— Биш көндә көймә ясамакчы буласыңмы? — дип гаҗәпләнеп кычкырып ук җибәрде.

— Әйе, Наб. Мин үзебезнең җирле халык каегы ишене генә ясарга әйтәм.

— Агачтанмы?

— Агачтан. Дөресрәге, кабык көймә. Мистер Сайрес, тагын бер тапкыр әйтәм, биш көн эчендә көймә әзер булачак.

— Әгәр биш көн дисез икән, мин көтәргә риза.

— Бүгеннән соң безгә бик уяу булырга кирәк,— дип кисәтте Герберт.

— Әйе, дусларым, саграк йөрегез. Киек ауларга Гранит сарайдан ерак китеп йөрмәгез,— диде Сайрес Смит.

Табын яны бик күңелле булыр дип хыялланган Пенкрофның өмете акланмады.

Димәк, утрауда кешеләр яши икән. Яки алар монда күптән түгел генә булып киткәннәр. Инде ядрә дә табылгач, моңа шик калмады. Утрау хуҗаларының күңеленә шом кереп урнашты.

Йокларга ятар алдыннан Сайрес Смит белән Гедеон Спилет ядрә хакында озак сөйләшеп утырдылар. Инженерның серле рәвештә исән калуы һәм тагын бүтән аңлаешсыз хәлләр белән ядрә вакыйгасе арасында берәр бәйләнеш юк микән? Озак гәпләшкәннән соң, Сайрес Смит иптәшенә әйтте:

— Кадерле Спилет, минем ни уйлаганны тәгаен беләсегез киләме?

— Килә, әлбәттә, Сайрес!

— Тыңлагыз алайса: бөтен утрауны актарып чыксак та, без берни дә таба алмаячакбыз.

Иртәгесен Пенкроф көймә ясау эшенә кереште. Ул калай белән тышланган, шәп җиһазланган шлюпка ясарга җыенмый иде, бәлки Рәхмәт елгасында йөзәрлек, бигрәк тә аның агым башында, сай төшләрендә дә йөри алырлык яссы төпле иң гади көймә генә әмәлләргә ниятли иде. Агач кайрысын бер-берсенә ялгап, җип-җиңел көймә ясап булачак, кирәк чагында аны күтәреп тә йөртә алсаң. Пенкроф агач кайрысы телемнәрен су үткәрмәслек итеп бер-берсенә агач чөйләр белән беркетергә уйлый.

Аның өчен үзе йомшак, үзе таза кабыклы агач табарга кирәк иде. Күптән түгел давыл вакытында каты җил байтак кына ылыслы агачларны җиргә аударган иде, шулар көймә ясау өчен яраклы булып чыктылар. Аларның кабыкларын гына каезлыйсы бар. Әмма утрау кешеләренең эш кораллары барлы-юклы гына иде, агачларны каезлау авырга туры килде.

Пенкроф бер минутны бушка әрәм итмичә, инженер җитәкчелегендә көймә ясаган арада, Гедеон Спилет белән Герберт та кул кушырып утырмадылар. Бар халыкны азык-төлек белән тәэмин итү вазифасы аларга йөкләнгән иде. Үсмер егет хәзер җәядән шәп ата, сөңгене дә оста ыргыта иде. Гедеон Спилет аның осталыгына сокланып туя алмый. Егет йөрәкле-гайрәтле һәм кирәк урында саклык белән эш итә белә иде. Аның батырлыгын «акыллы батырлык» дип атарга мөмкин иде. Аучылар, Сайрес Смит киңәшен истә тотып, Гранит сарай

янында ике мильдән дә ары китмиләр. Эчкәре кермәсәләр дә, урман авызында гына агутлар, көнгерәләр, пекариләр һәм башка төрле киек шактый күп очрый иде.

Дөрес, салкыннар кимегәч, җәнлекләр тозакка сирәгрәк төшә башлады. Ә Куян аланында капкыннар беркайчан да буш булмый; шул табыш Линкольн утравы качакларын туйдырырга җитә иде.

Ауда йөргәндә Герберт еш кына ядрә турында һәм шул вакыйга уңае белән инженерның әйткән фикерләре турында сүз кузгата. Бервакыт, 26 нчы октябрьдә, ул журналисттан болай дип сорады:

— Мистер Спилет, һәлакәткә очраган кешеләрнең безнең утрауда яшәп тә, бу көнгә хәтле Гранит сарай тирәсендә күренмәүләре гаҗәп түгелме?

— Әйе шул. Әгәр алар әле дә монда булсалар, очрашмавыбыз гаҗәп тоелыр иде. Инде китеп барганнар икән, бер дә гаҗәп түгел.

— Сез аларны киткән дип уйлыйсызмы?

— Шулайдыр дим шул, дустым. Әгәр утрауда яшәсәләр, без аларны күптән очратыр идек инде.

— Әгәр алар моннан китә алганнар икән, димәк, кораблары зарарланмаган булып чыга ич?

— Нигә, Герберт? Минемчә, алар вакытлыча гына тоткарланганнардыр, мөгаен давыл аларның корабын ватмагандыр, утрауның яр читенә генә чыгарып ташлагандыр, ә давыл басылгач, яңадан йөзеп киткәннәрдер.

— Сиздегезме сез, мистер Смит утравыбызга чит кешеләрнең килүен теләми, хәтта курка да бугай әле,— дип куйды Герберт.

— Шулай шул. Бу тирәләрдә ул бүтән беркем дә түгел, фәкать Малайя пиратлары гына йөрергә мөмкин дип уйлый. Ә ул явыз юлбасарларга юлыкмавың хәерле.

— Утрауда кешеләр барлыгын расларлык берәр эзгә төшәрбез әле, әйеме, мистер Спилет? Шул чакта ни булганын тәгаен белербез, шулай бит?

— Әйе, дустым! Кайчандыр алар яшәгән урынны яисә сүнгән учак көлен очратырбыз. Эзләсәк, табарбыз.

Алар шулай сөйләшә-сөйләшә Рәхмәт елгасы үзәнендәге урманга килеп керделәр. Әйләнә-тирәдә сокланып туя алмаслык матур агачлар үсеп утыра. Икешәр йөз футлы [1] биек мәһабәт агачлар күк йөзенә таба

[1] Фут — озынлыкны үлчәү берәмлеге, утыз сантиметр чамасы.

үрләгәннәр. Бу ылыслы агачларны Яңа Зеландиядә «каури» дип йөртәләр.

— Минем башыма бер фикер килде, мистер Спилет, әллә берәр каури очына менеп, тирә-якны карап төшимме? Аннан бик күп җирләр күренәдер.

— Әйбәт булыр иде, дустым. Тик андый биек агачның очына ук менеп җитә алырсыңмы соң?

— Тырышып карыйм.

Җиңел гәүдәле егет астагы ботакларга җитез генә менеп тә китте. Агач ботаклары менәр өчен җайлы урнашкан иде. Әллә ни арада Герберт тоташ яшеллек диңгезе өстенә үк чыгып торган агачның иң очына җиткән иде инде. Егетнең күз алдында утрауның көньяк өлеше җәелеп ята: көньяк-көнчыгыштагы Тырнак борыныннан алып көньяк-көнбатыштагы Елан борынына хәтле булган җирләр һәммәсе аермачык күренә. Ә төньяк-көнбатышта офыкны Франклин тавы каплап тора иде.

Герберт утрауның моңарчы үзенә таныш булмаган җирләренең дә бер өлешен күрде. Чит кешеләр, бәлки, шул якларда яшиләрдер, шуңа күрә моңарчы күзгә чалынмаганнардыр.

Егет бик җентекләп диңгез өстен күзәтте. Офыкта булсын, утрау тирәсендә булсын, ник бер җилкән күзгә чалынсын... Хәер, яр буйларын калын урман каплаган. Әгәр мачтасы җимерек корабны дулкын ярга чыгарып ташлаган булса да, моннан барыбер күренмәс иде. Ерак Көнбатыш урманнары эченә дә күз карашы үтеп керә алырлык түгел иде. Ничәмә-ничә квадрат мильгә җәелгән тоташ яшеллекнең ник бер аланы, ник бер ачыклыгы шәйләнсен. Елга да буеннан-буена күренеп ятмый, таудан агып төшә торган турылары агачлык эченә яшеренгән. Бәлкем әле көнбатышка таба агучы бүтән елгалар да бардыр. Хәер, күренмәгәч, бар дип әйтүе кыен.

Герберт кешеләр яшәгән берәр төбәк юкмы, һавага төтен-мазар күтәрелмиме дип никадәр эзләсә дә, берни күрмәде. Аның күзе үткен, булса, искәрми калмас иде. Күк йөзе дә чип-чиста, үтә күренмәле, аз гына төтен чыкса да, сизелер иде.

Кинәт Герберт көнбатыш якта сыек кына төтен чыкканын шәйләгәндәй булды. Әмма текәлебрәк карагач, үзенең алданганлыгын төшенде. Берни юк икән.

Герберт агач башыннан җиргә төште. Озакламый алар Гранит сарайга кайтып керделәр. Егетнең хикәясен тың-

лагач, Сайрес Смит уйчан гына башын чайкап торды. Хәер, ул да нәрсә әйтә алсын инде; утрауның һәр тарафын йөреп чыкмадылар бит, әлегә аны тулысынча белеп бетермиләр шул.

Ике көннән соң, 28 нче октябрьдә, тагын бер аңлашылмаган вакыйга булып алды.

Герберт белән Наб, Гранит сарайдан ике миль чамасы китеп, комлы яр буйлап баралар иде, кинәт ташбакага юлыктылар; каты кабыгы зәңгәрсу-яшькелт ялтырап торган менә дигән диңгез ташбакасы иде бу.

Ташлар арасыннан диңгезгә таба үрмәләп барган ташбаканы беренче булып Герберт күреп алды.

— Наб, тизрәк кил әле бирегә.

Наб йөгереп килеп җитте.

— Ух, шәп ташбака! — диде ул сокланып.— Ничек итеп алып кайтырбыз икән?

— Кайтырбыз, кыен түгел ул. Качып китмәсен өчен хәзергә чалкан әйләндереп калдырып торырбыз. Йә әле, таяк алып кил дә, миңа булыш...

Куркыныч барлыгын сизүгә, ташбака башын, аякларын кабыгы эченә яшерде дә таш шикелле катып калды. Шунда Герберт белән Наб, ташбака астына таяклар тыгып, бергәләп азаплана торгач, аны чалкан әйләндерделәр. Ташбаканың озынлыгы өч фут чамасы бардыр, ә авырлыгы дүрт йөз кадактан да ким булмас.

— Шәп! Пенкроф дустым куаныр инде! — диде Наб сөенеп.

Чынлап, Пенкрофның куанырлыгы бар иде шул: сусэмнәр белән туклануучы ташбаканың ите бик тәмле була.

Шул чакта ташбака чалкан яткан җирдән яссы кечкенә башын чыгарды, аның муенга таба юанаеп килгән башының ике ягында батынкы чокырларына хәтле аермачык күренде.

— Нишләтик соң бу табышны? Гранит сарайга хәтле болай гына алып кайта алмабыз бит? — дип сорады Наб.

— Чалкан яткан килеш шушында калдырып торырбыз, йөзтүбән әйләнә алмас әле. Аннары кул арбасы алып килербез дә шуңа салып кайтырбыз.

— Хәл иттек!

Наб кирәкмәс дисә дә, ышанычлырак булсын өчен, Герберт ташбаканы әйләнә-тирәдән зур-зур ташлар белән дә бастырып куйды. Һәм аучылар су чигенгәч киң

булып ачылып калган комлы яр буеннан кайтыр якка юнәлделәр. Герберт Пенкрофка ком өстендә ятып калган «шәп» диңгез ташбакасы турында әлегә әйтмәскә булды, сөенчене соңыннан, көтмәгәндә алырга ниятләде.

Ике сәгатьтән Наб белән Герберт ташбаканы калдырып киткән җиргә кечкенә арба тартып килеп җитсәләр, ни күрсеннәр: «шәп» ташбакадан җилләр искән!

Наб белән Герберт аптырашып башта бер-берсенә карашып тордылар, аннары әйләнә-тирәгә күз салдылар... Ташбака ятып калган җир шушы бит инде! Егет хәтта үзе бастырып калдырган ташларны да тапты, димәк, ялгышмаганнар.

— Менә тамаша! Димәк, ташбака йөзтүбән әйләнә ала икән! — диде Наб.

Герберт, үз күзенә үзе ышана алмыйча, әйләнә-тирәдә чәчелеп калган ташларга хәйран калып карап торды.

— Шулай, күрәсең!

— Их, Пенкрофның кәефе кырыла инде!

«Ә мистер Сайрес ташбаканың юкка чыгуын ничек итеп аңлата алыр икән, күрербез менә!» дип уйлады Герберт.

Набның бу күңелсез хәлне бүтәннәргә сиздерәсе килмәде:

— Берәүгә дә әйтмәбез инде, эчтән генә тынарбыз.

— Киресенчә, Наб, барысын да сөйләп бирергә кирәк,— дип каршы төште Герберт.

Алар, буш арбаны тартып, Гранит сарайга кире кайтып киттеләр.

Инженер белән диңгезче көймә ясап яткан җиргә җиткәч, Герберт әлеге вакыйгане аларга сөйләп бирде.

Пенкроф кызып китте:

— Их сез, ачык авызлар! Ташбаканы кулдан ычкындыргансыз бит! Ким дигәндә йөз илле тапкыр шулпа пешерерлек итне әрәм иткәнсез!

— Ташбака качканга без гаеплемени,— дип акланырга кереште Наб.— Без аны чалкан әйләндереп салган идек.

Диңгезче, үз-үзен тыя алмыйча, тегеләргә:

— Начар әйләндергәнсез! — дип төрттерде.

— Бер дә начар түгел! — диде Герберт һәм таш белән бастырып киткәннәренә хәтле сөйләп бирде.

— Могҗиза бит бу, билләһи! — дип аптыраштa калды Пенкроф.

— Мистер Сайрес, мин: ташбаканы чалкан салсаң, үзе йөзтүбән әйләнә алмый торгандыр, дип уйлый идем. Бигрәк зур ташбака иде ул.

— Әлбәттә, шулай, дустым Герберт,— диде Сайрес Смит.

— Ә ничек итеп аякка баскан соң ул?..

Инженер эшен ташлады, бу сәер хәл турында уйга калды.

— Сез ташбаканы диңгездән ерак калдырган идегезме?

— Биш метр чамасы бардыр,— диде Герберт.

— Су чигенгән чак идеме?

— Әйе, мистер Сайрес.

— Су күтәрелгәч, корсагына әйләнгәндер дә, иплэп кенә эчкә таба йөзеп кереп киткәндер. Комда ятканда әйләнә алмаганны, суда әйләнгән булып чыга,— диде инженер.

Наб үкенеченнән:

— Ах, ачык авыз икәнбез без! — дип кычкырып җибәрде.

— Шулай дип бая ук әйттем бит инде үзегезгә! — диде Пенкроф.

Сайрес Смитның бу вакыйгане шулай аңлатуы ышанырлык иде, әлбәттә. Әмма ул үзе аның дөреслегенә ышанды микән соң? Белмим шул, әйтүе кыен.

Икенче бүлек

Көймәне беренче тапкыр сынау.— Диңгез ярыннан табылган әйберләр.— Табылдык борыны.— Әрҗә эчендә нәрсәләр бар? — Эш кораллары, сугыш кораллары, приборлар, кием-салым, китаплар, йорт кирәк-ярагы.— Пенкрофка нәрсә җитми? — Инҗил.— Изге китапның бер аяте

Егерме тугызынчы октябрьгә көймә әзер диярлек иде инде.

Пенкроф сүзендә торды. Биш көн эчендә агач кайрысыннан көймә ясап бетерде. Кабыргаларын крехимба агачының пеше чыбыкларыннан корды. Ян-якларын тоттыру өчен уртага да, көймә борынына һәм койрыкка да утыргычлар әмәлләде; урталыкка ишкәк чөйләре өчен уентыклар уйды, ике ишкәк ясады, көймәне идарә итәр өчен артка койрык ишкәге беркетте. Бу уникe

футлы, авырлыгы ике йөз кадаклы көймәнең бар җиһазы шулардан гыйбарәт иде. Аны суга төшерүе кыен булмады. Җиңел көймәне күтәреп яр буена илттеләр һәм Гранит сарай каршысына комга куйдылар. Су арткач, көймә үзеннән-үзе су эчендә торып калды. Пенкроф көймәгә сикереп менде дә койрык ишкәге белән идарә итеп йөзеп карады һәм көймәнең үзләре ниятләгән максатка яраклы икәнлегенә ышанды.

Үз уңышы белән мактанырга җай чыгуына куанып, ул:

— Ура! — дип кычкырды.— Бу көймәдә сәяхәткә чыгарга була хәзер...

— Дөнья гизәргәме? — дип сорады Гедеон Спилет.

— Юк. Утрау тирәсен гизәргә. Тотрыклылык өчен төбенә авыр ташлар салырбыз. Әгәр дә Сайрес Смит көймә борынына мачта әмәлләргә, җилкән корырга ярдәм итсә, диңгез буйлап ерак сәяхәткә дә чыгарга була! Йәгез, мистер Сайрес, мистер Спилет, Герберт, Наб, әллә яңа көймәбезне сынап карыйсыгыз килмиме? Билләһи, бишебезне дә берьюлы күтәрә ала микән, белергә кирәк ләбаса!

Чыннан да, көймәне сынап карарга кирәк иде. Пенкроф ишкәген бер каерып ишүгә көймәне кыя ташлар арасыннан оста гына алып чыкты да комлы ярга якын китерде. Көймәне сынау өчен бүген үк Берләшү бухтасының көньягындагы борынга хәтле яр кырыйлап йөреп кайтырга карар иттеләр.

Көймә янына килгәч тә, Наб:

— Синең судноңа су тулган ич, Пенкроф! — дип кычкырып җибәрде.

— Зыян юк, агачның су сеңдереп күбенәсе бар әле. Менә күрерсең, ике көннән көймәбездә тавык эчәрлек кенә су калачак. Әйдә, утырышыгыз!

Дусларыбыз көймәгә кереп утырдылар, һәм Пенкроф аны ачык диңгезгә алып чыкты. Һава яхшы иде, диңгез өсте күл суы кебек тып-тын, көймә Рәхмәт елгасындагы кебек кыю рәвештә алга йөзә. Бер ишкәк белән Наб, икенчесе белән Герберт ишә, ә Пенкроф койрык ишкәге белән идарә итеп бара.

Бугаз суыннан йөзеп чыккач, Котылу утравының көньяк очыннан әйләнеп уздылар. Көньяктан йомшак җил исә. Бугаз өсте дә, диңгез өсте дә тыныч диярлек. Вак уйнак дулкыннар көймә кырыен сыйпап кына узалар. Франклин тавының бөтен матурлыгын күреп хозур-

лану өчен сәяхәтчеләр ярдан ярты миль чамасы эчкәрәк кереп бардылар.

Бераздан көймә елга тамагына таба борылды һәм яр буйлап очлы борын ягына таба йөзеп китте. Яр буеннан сузылган биек сырт Үрдәк сазлыгын сәяхәтчеләр күзеннән каплап тора иде.

Яр буйлап исәпләгәндә борын елга тамагыннан өч миль чамасы ераклыкта иде. Сәяхәтчеләр борынның очына хәтле үк барып җитәргә карар иттеләр, аннан аргы Тырнак борынына кадәр яр буйларын ерактан гына булса да күзәтергә ниятләделәр.

Көймә, ярдан ике кабельтов[1] чамасы эчкәре кереп, диңгездән алга таба йөзә, су арткач аста күмелеп калган кыяларны урап-урап уза. Елга тамагыннан алып очлы борынга хәтле сузылган сырт тәбәнәгәя төште. Күзәтү яссылыгын хасил иткән тоташ шома гранит стенага һич тә охшамаган, ул тәртипсез өелгән әкәмәт рәвешле зур-зур гранит ташлардан гыйбарәт иде. Шыксыз, кырыс манзара. Гүя бирегә бу таш өемнәрен гаять зур арбага төяп китереп аударганнар. Диңгез кырыйлап ике миль киңлектә сузылган бу таш хәрабәләрнең сыртында ник бер үсемлек заты күренсен. Ул яшел урман җиңе эченнән чыгып торган алыптай кулны хәтерләтә иде.

Пар ишкәк белән ишкәнгә, көймә җиңел генә йөзеп бара. Кулына карандаш тоткан Гедеон Спилет куен дәфтәренә киң штрихлар белән яр сызыгы рәсемен төшерә. Наб, Пенкроф һәм Герберт үз белмәмәләренең таныш булмаган бу якларын күзәтә-күзәтә үзара гәпләшеп баралар; көймә һаман көньякка карап йөзә; ерагайган саен Көньяк һәм Төньяк Казна борыннары урыныннан кузгалган шикелле тоелалар: гүя икесе бергә кушылып, Берләшү бухтасына керү юлын тарайталар иде.

Сайрес Смит сөйләшмичә генә, сагаеп, яр буйларын күзәтә, гүя анда могҗизалар белән тулган серле җирләр ята...

Алар шулай өч чирек сәгать йөзеп бардылар. Менә көймә очлы борын турысына җитте. Пенкроф борынны әйләнеп узарга ниятләп көймәне борырга керешкән иде, кинәт Герберт сикереп торды да:

— Карагыз әле, комда нәрсәдер ята,— дип яр буендагы ниндидер карамчыкка төртеп күрсәтте.

---

[1] Кабельтов — диңгездә араны үлчәү берәмлеге, ике йөз метрга тигез.

Һәммәсе ул күрсәткән якка карадылар.

— Нәрсәдер ята бугай анда,— диде журналист та,— яртылаш комга күмелгән, ниндидер ватык нәрсә ахрысы...

— Әһә! Нәрсә икәнен күрдем,— дип кычкырып җибәрде Пенкроф.

— Нәрсә соң? — дип сорады Наб.

— Мичкәләр бит алар, мичкәләр. Эчендә әйберсе дә бардыр әле! — диде диңгезче.

— Пенкроф, көймәне ярга таба бор! — дип боерды Сайрес Смит.

Ишкәк белән бер-ике тапкыр каерып ишүгә, көймә кечерәк кенә табигый култыкка килеп керде, яр читенә барып та төртелде. Сәяхәтчеләр комга сикереп төштеләр.

Пенкроф ялгышмаган икән: анда яртылаш комга күмелгән ике мичкә ята иде. Ике мичкә уртасына бау белән бер әрҗә бәйләнгән. Мичкәләрне әрҗә суга батмасын өчен такканнар булса кирәк.

— Безнең утраудан ерак түгел берәр кораб һәлакәткә очрады микәнни? — дип сорады Герберт.

— Шулай ахрысы,— диде Гедеон Спилет.

Пенкрофның җаны түзмәде:

— Әрҗәдә нәрсә бар икән? Нәрсә икән соң анда? Капкачын кадак белән какканнар, бәреп ватарга әйберсе дә юк ичмасам... Таш белән бәреп карасак инде...— дип сөйләнә-сөйләнә кулына авыр таш алып, шуның белән әрҗәнең бер ягын бәреп чыгарырга уйлаган иде, инженер аны кулыннан тотып калды.

— Пенкроф, бераз сабыр итә алмыйсызмы?

— Мистер Сайрес, ягез инде, аның эчендә, бәлки, безгә бик кирәкле әйберләр бардыр!

— Хәзер белербез, Пенкроф,— дип җавап бирде Сайрес Смит.— Карагыз әле, әрҗәсен ватмагыз дим бит, әрҗәсе дә кирәк булачак аның безгә. Гранит сарайга алып кайткач, иплəп ачарбыз. Әйбәт итеп ябылган; монда исән-сау йөзеп килеп җиткән икән, елга тамагына хәтле генә агып барыр инде.

— Сез хаклы, мистер Сайрес. Эшне чак бозып ташламадым. Кайвакыт үз-үзеңне җиңүе кыен була шул.

Инженер акыллы киңәш бирде. Суда батмасын өчен ике ягына ике буш мичкә тагылган булгач, әрҗә шактый авырдыр, күрәсең; аның эчендәге әйберләр көймәгә сыеп та бетмәс иде әле. Иң уңайлысы аны көймә артына тагып Гранит сарайга алып кайту иде.

Бу әрҗә кайдан агып килгән икән соң? Шуны белүе мөһим иде. Сайрес Смит һәм аның иптәшләре бөтен тирә-юньне бик дикъкатьләп тикшереп чыктылар. Яр буйлап берничә йөз адым алга таба барып карадылар, әмма бүтән нәрсә табылмады. Диңгез өстен дә озак күзәттеләр. Герберт белән Наб хәтта биек кыя башына менеп тә карадылар — океан сулары офык читенә хәтле буп-буш иде, ни давылда баткан кораб калдыклары, ни җилкәнен киереп йөзгән кораб күренмәде.

Хәлбуки, ничек кенә булмасын, кайдадыр берәр кораб һәлакәткә очраган икәнлегенә шик юк иде.

Бәлкем, бу табыш белән теге ядрә арасында берәр бәйләнеш тә бардыр? Бәлкем, бәлагә очраган корабның кешеләре утрауның икенче ягына барып чыкканнардыр? Бәлкем, алар әле дә шундадыр? Һәрхәлдә, баткан корабның кешеләре Малайя пиратлары булмаска тиеш. Диңгез ярыннан табылган әрҗә Америкадан яки Европадан чыккан булырга охшый иде.

Озынлыгы биш, киңлеге өч футлы әрҗәне барысы сырып алдылар. Ул таза имән такталардан нык итеп ясалган, калын күн белән тышланган, җиз кадаклар белән әйбәтләп кагылган. Як-ягына, эченә су кермәслек итеп, авызы ныгытып томаланган ике мичкә бәйләнгән. Шаңгырдап торуларына караганда, мичкәләрнең эче буш булырга тиеш. Ике мичкә дә әрҗәгә таза баулар ярдәмендә, Пенкрофның әйтүенчә, «диңгез төене» белән бәйләнгән. Әрҗә әйбәт сакланган, ватылмаган-кырылмаган, дулкын аны кыяга бәргәләмәгәндер ахрысы, комга гына кагып чыгаргандыр. Утрау хуҗалары, аны төрле ягыннан игътибарлап караганнан соң, суда озак тормаган, утрауның ярына да әле яңарак кына чыккан дигән нәтиҗәгә килделәр. Эченә дә су үтмәскә тиеш, шулай булгач әйберләре бозылмагандыр дип уйларга мөмкин иде.

Кораблары бәлагә очраган кешеләр әрҗәне мичкәләргә бәйләп диңгезгә ташлаганда үзебез утрауның ярына йөзеп чыккач табарбыз дип өметләнгәннәрдер инде.

— Әрҗәне көймә койрыгына тагып өйгә алып кайтыйк та, шунда ачарбыз, эчендәге әйберләрен барлап, исемлеген төзербез. Баткан корабның исән калган кешеләре утрауда табылса, әйберләрен үзләренә кайтарып бирербез,— диде инженер.— Әгәр берәүне дә тапмасак...

— Әйберләре үзебезгә калыр! — диде Пенкроф. — Эчендә нәрсә бар икән соң, беләсе килә бит!

Су арта башлады, дулкын әрҗәне ялап-ялап ала, озакламый ул аны урыннан кузгатып агызып китәчәк. Сәяхәтчеләр әрҗәне мичкәгә бәйләгән бауның беразын чишеп алдылар да шуның белән аны көймә койрыгына тактылар. Пенкроф белән Наб ишкәкләр белән әрҗә тирәсендәге комны казып урыныннан кузгаттылар; көймә әрҗәне тарттырып кузгалып китте һәм бу хөрмәткә *Табылдык* дип исем кушкан борынны әйләнеп уза башлады. Йөк авыр иде, мичкәләр аны су өстендә көчкә-көчкә тотып торалар. Диңгезче, әрҗәне бәйләгән бау чишелеп, әйберләр диңгез төбенә китмәгәе дип борчылып барды. Бәхетенә, Пенкроф юкка хафаланган булып чыкты, сәгать ярымнан көймә Гранит сарай турысына исән-сау килеп туктады. Барлы-юклы араны алар шактый озак кайттылар.

Көймә белән әрҗәне комга тартып чыгардылар; су чигенә башлаганлыктан, бирегә дулкын килеп җитәрлек түгел иде. Наб, өйгә йөгереп барып, корал-мазар алып килде, һәм алар саклык белән генә әрҗәне ачарга, әйберләрнең исемлеген төзергә әзерләнделәр. Пенкроф, әрҗәдә нәрсә бар икәнен тизрәк беләсе килеп, дулкынлана иде.

Ул башта мичкәләрне чишеп алды, алар төзек, киләчәктә дә эшкә яраклык иде. Аннары, кадакларын суырып, әрҗәнең капкачын күтәрде.

Эчтә, әйберләрне дымнан саклау өчен булса кирәк, цинк калайдан икенче тартма бар иде.

— Ах, әллә консервалар гынамы? — дип кычкырып ук җибәрде Наб.

— Юктыр, консерва түгелдер, — диде журналист.

Пенкроф үзалдына мыгырданды:

— Әгәр дә анда...

Наб, аның сүзләрен ишетеп:

— Нәрсә булыр дисең? — дип сорады.

— Юк ла, болай гына!

Цинк тартма капкачын уртадан ярып җибәрделәр, ике якка кайтарып куйдылар һәм тартма эчендәге әйберләрне берәм-берәм алып, комга тезә башладылар. Әрҗәдән яңа әйбер чыккан саен Пенкроф «ура» кычкыра, Герберт шатланып кул чаба, Наб очынып биеп җибәрә. Анда хәтта китаплар да бар иде, аларны күргәч,

Герберт куанычыннан шаша язды; ә савыт-сабалар чыккач, Наб аларны үбеп алырга җитеште.

Кыскасы, утрау хуҗаларының бәхете басты, әрҗәдән эш кораллары, сугыш кораллары, савыт-саба, кием-салым, китаплар һәм башка бик күп әйберләр чыкты. Менә Гедеон Спилет куен дәфтәренә теркәп куйган әйберләрнең төгәл исемлеге:

Эш кораллары

Күп җәпле 3 пәке,
утын яра торган 2 балта,
2 эш балтасы,
3 ышкы,
2 юнгыч,
1 ике йөзле балта,
6 өтерге,
2 игәү,
3 чүкеч,
3 борау,
2 тишкеч,
10 янчык кадак һәм шөрепләр,
төрле зурлыктагы 3 пычкы,
2 тартма инә.

Сугыш кораллары

Чакмалы 2 мылтык,
пистонлы 2 мылтык,
2 карабин,
5 сунарчы пычагы,
4 абордаж кылычы,
егерме бишәр кадаклы 2 мичкә дары,
12 тартма пистон.

Приборлар

1 секстан,
1 бинокль,
1 күзәтү трубасы,
1 готовальня,
1 кесә компасы,
1 Фаренгейт термометры,
1 барометр-анероид,
фотоаппарат, объектив, фоторәсем ясау өчен кирәкле пластинкалар, химик матдәләр һәм башка әйберләр салынган 1 тартма.

Кием-салым

Тукымасы карап торуга йонга охшаган, ләкин үсемлек сүсеннән булса кирәк, егермеләп күлмәк, шул ук тукымадан утызлап оекбаш.

Савыт-саба

1 чуен,
6 бакыр кәстрүл,
3 чуен таба,
алюминнән ясалган 10 тәлинкә-кашык,
2 чәйнек,
1 күчмә мич,
6 пычак.

Китаплар

1 Инҗил,
1 атлас,
2 Полинезия теле сүзлеге,
алты томлы табигать белеме энциклопедиясе,
3 төргәк язу кәгазе,
2 зур дәфтәр-кенәгә.

Исемлекне язып тәгәлләгәч, журналист:

— Әрҗәнең иясе бик хуҗалыклы кеше булган. Һич үпкәләрлек түгел. Барысын да салган: эш кораллары, сугыш кораллары, приборлар, кием-салым, савыт-саба, китаплар — берсен дә онытмаган. Корабларының батасын алдан ук белгән дә әзерләнеп үк куйган дип уйларлык,— диде.

Уйчан карашын төбәп карап торган Сайрес Смит:

— Әйе шул, бер генә нәрсә дә онытылып калмаган,— дип пышылдады.

— Давылда зарарланган корабка, бу әрҗәгә һәм аның хуҗасына Малайя пиратларының бер мөнәсәбәте дә юк, әлбәттә! — диде Герберт.

— Әгәр боларның хуҗасы пиратлар кулына әсир төшмәгән булса,— дип куйды Пенкроф.

— Юктыр, алай булмас: дөресрәге, Америкадан яки Европадан килүче берәр кораб давыл вакытында бәлагә очрагач, кешеләре иң кирәк дигән әйберләрне әрҗәгә тутырып суга ташлаганнардыр.

— Мистер Сайрес, ә сез ничек дип уйлыйсыз? — дип сорады Герберт.

— Мин дә шул фикердә,— диде инженер.— Корабларының батачагын сизгәч, андагылар иң кирәкле әй-

берләрне әрҗәгә тутырып суга ташлаганнардыр, үзләре ярга чыккач эзләп табарбыз дип өметләнгәннәрдер.

— Фотоаппаратны дамы? — диде Пенкроф, ничектер шигәеп.

— Фотоаппаратның нигә кирәге булгандыр, анысы минем үземә дә аңлашылып җитми әле,— диде Сайрес Смит.— Безгә дә, һәлакәткә очраган бүтәннәргә дә аның урынына кием-салымны яки корал-мазарны күбрәк салсалар яхшырак бит инде югыйсә!..

— Приборларда, инструментларда һәм китапларда фабрикасының тамгасы юкмы икән, яисә чыккан шәһәренең исеме язылмаганмы? Хуҗасының кайсы ил кешесе икәнен белер идек,— диде Гедеон Спилет.

Һәр әйберне, аеруча китапларны, приборларны һәм мылтыкларны аерым-аерым җентекләп карап чыктылар. Әмма, гаҗәпкә каршы, мылтыкларга һәм китапларга фабрика тамгасы сугылмаган иде. Фабрика тамгасы булып та, җуелырга тиеш түгелдер, чөнки әйберләрнең берсе дә тотылмаганга охшый, савыт-сабалар да, эш кораллары да һәммәсе өр-яңа. Кыскасы, әйберләр әрҗәгә тиз арада ашык-пошык тутырылмаган; киресенчә, бик уйланып, хәсиятләп салынган, анысы әллә каян күренеп тора. Әйберләрне су үтмәсен өчен цинк тартмага салулары да шуны раслый, аны ашыккан арада гына алай ябыштырып булмас иде.

Энциклопедия һәм Полинезия теле сүзлеге инглизчә басылган булса да, басылган елы да, нәширенең кемлеге дә күрсәтелмәгән.

Инҗил дә инглизчә, чирек табаклы форматта, әйбәт итеп басылган, кат-кат укылганы күренеп тора.

Атлас та шәп басма, дөнья ярымшарлары картасы Меркатор проекциясендә сызылган, географик исемнәр французча; тик, элеге дә баягы, басылган елы, нәшире күрсәтелмәгән.

Әйберләрне бик игътибар белән карап чыктылар. Тик күптән түгел шушы тирәдә йөзеп йөргән корабның кайсы илнеке икәнлеген, нихәтле тырышсалар да, белә алмадылар. Мәгәр әрҗә каян килсә килгәндер, ул Линкольн утравы кешеләрен баетты. Әлегә хәтле алар табигать хәзинәләрен генә файдаланалар иде, һәр кирәк-яракны үзләре ясап алалар иде, тормыш авырлыкларын үз тырышлыклары, үз белемнәре ярдәмендә җиңәләр иде. Әллә тәкъдир шуның өчен аларны фабрикада

эшләнгән әйберләр белән бүләкләргә уйлады микән? Алар аллаһе тәгаләгә рәхмәтләр укыдылар.

Хәер, арада берәүнең күңеле бигүк канәгатьләнеп җитмәвен әйтергә кирәк. Бу — Пенкроф иде. Ул бик зарыгып көткән әйбер әрҗәдән чыкмады, күрәсең. Чөнки әрҗә бушый барган саен аның «ура» кычкыруы сүлпәнәйде. Ә соңгы әйбер дә исемлеккә теркәлгәч, ул:

— Болар барысы да шәп, сүзем юк; әмма үзегез күреп торасыз, әрҗәдән миңа кирәклесе чыкмады,— дип сукранып куйды.

Наб, аптырап:

— Нәрсә көткән иден соң син, дускаем? — дип сорады.

— Ярты кадак тәмәке! — дип җавап бирде диңгезче.— Шул булса, миннән дә бәхетле кешене дөньяда тапмас идегез!

Пенкрофның сүзеннән барысы шаркылдап көлеп җибәрделәр. Әрҗә табылу вакыйгасеннән соң утрауны тулысынча йөреп чыгуны бүтән кичектерергә ярамаганлыгы тагын бер кат расланды. Дусларыбыз иртәгесен үк таң ату белән юлга чыгарга сүз куештылар. Рәхмәт елгасы буйлап агымга каршы югарыга таба менәргә, утрауның көнбатыштагы моңарчы күрелмәгән җирләрен карап йөреп чыгарга ниятләделәр. Кораблары һәлакәткә очраган бичаралар, бәлкем, шул ярга чыгарга мәҗбүр булганнардыр, хәлләре шәп түгелдер, аларга тизрәк ярдәм кулы сузарга кирәктер.

Әрҗәдән чыккан әйберләрне көне буе Гранит сарайга ташыдылар һәм зур бүлмәгә хәсиятләп урнаштырдылар.

Бу — 29 нчы октябрь, якшәмбе көн иде. Йокларга ятар алдыннан Герберт Сайрес Смиттан Инҗилнең берничә юлын укып күрсәтүен үтенде.

— Рәхәтләнеп укыйм,— дип җавап бирде Сайрес Смит.

Китапны кулына алып, битен ачарга җыенган иде, Пенкроф кинәт:

— Мистер Сайрес, мин хорафатка ышанам. Китапның битен карамыйча гына ачыгыз әле, күзегез төшкән беренче аятьне укыгыз. Күрик, нәрсә чыгар икән? — диде.

Сайрес Смит көлеп куйды, карамыйча гына Инҗилнең битен ачкан иде, кәгазь кыстырылган бит туры килде. Җиденче бүлекнең сигезенче аяте турысында кызыл

карандаш белән куелган билгегә күзе төште. Һәм ул шул аятьне кычкырып укыды:

«Ходайдан теләгез, теләгегез кабул булыр; эзләгез — табарсыз».

Өченче бүлек

Көймәдә сәяхәт.— Су күтәрелә.— Карама агачы, кычыткан агачы.— Төрле үсемлекләр.— Җакамар.— Урман күренеше.— Гигант эвкалиптлар.— Бизгәктән саклаучы агачлар.— Маймыллар көтүе.— Шарлавык.— Төн куну

Иртәгесен, 30 нчы октябрьдә, утрау хуҗалары сәяхәткә чыгарга җыендылар. Соңгы көннәрдәге вакыйгаләрдән соң утрауның моңарчы күрелмәгән якларын тикшереп кайтмыйча мөмкин түгел иде инде.

Чынлап та, хәлләр шулай булып китте ки, Линкольн утравы кешеләре хәзер үзләрен ярдәмгә мохтаҗ дип түгел, бәлки бүтәннәргә ярдәм кулы сузарга сәләтле дип исәплиләр иде. Алар Рәхмәт елгасының югары башына таба ни хәтле еррак менеп булса, шул хәтле менәргә карар иттеләр. Шул чагында юлның күп өлешен армыйча үтәргә, азык-төлек һәм коралларны көймә белән утрауның көнбатыш ярына хәтле үк алып менәргә мөмкин булачак иде.

Кире кайтканда Гранит сарайга алып кайтырдай әйберләр дә очраячак бит әле, шуларны төяр өчен үзләре белән нинди җайланма алырга дигән мәсьәләне хәл итәргә тырыштылар. Чыннан да, әгәр, фараз иткәнчә, утрау янында берәр кораб баткан булса, диңгез дулкыннары аның күп кенә ватык-сыныкларын ярга кагып чыгаргандыр, аларның берәр нәрсә ясарга ярап куюы ихтимал. Йөк төяр өчен арба җигеп бару көймәгә караганда әйбәтрәк булыр иде булуын, тик ул килбәтсез зур, авыр арбаны үзләренә тартырга туры киләчәк. Шуңа күрә хәзер Пенкрофка табылдык әрҗәдән «ярты кадак тәмәке» чыкмады дип үпкәләү өстенә, бер пар нәселле, көчле Нью-Джерси атлары да салган булсалар соң дип үкенергә калды. Ә атлар утрау кешеләренә бик зур ярдәмче булыр иде.

Сайрес Смит сәяхәтне иң күбе өч көнгә сузылыр дип чамалаганлыктан, Наб көймәгә өч көнлек азык төяде: тозлаган ит, сыра, драцена эчемлеге һ. б. ризыклар салды. Хәер, азыкны юлда да хәстәрләргә мөмкин иде.

Наб, шулар өстенә, күчмә мичне дә үзләреннән калдырмады.

Сугыш коралларыннан юлга пистонлы мылтыкларга караганда чакмалы мылтыклар алуны файдалырак күрделәр. Чөнки чакмалы мылтыкка чакма гына кирәк, аны алыштыру кыен түгел; ә пистонны еш куллансаң, тиз бетә; шулар өстенә патроннары белән карабин да алдылар.

Мичкәдә илле кадаклап дары бар иде, аны да бераз алырга туры килде, чөнки инженер киләчәктә дарыны алыштырырлык шартлагыч матдә ясарга ышандырды. Мылтыклар өстенә тагын, күн кыныларына тыгып, биш ау пычагы алдылар. Болай яхшы коралланган, кеше аягы басмаган теләсә нинди кара урман эченә курыкмыйча, кыю рәвештә аяк басарга мөмкин иде. Кирәге чыга-нитә калса, үзләрен якларга көч җитәчәк иде.

Әйтмичә дә аңлашылса кирәк, Пенкроф, Герберт һәм Набның баштан-аяк коралланып алгач, түбәләре күккә тиде, әмма алардан Сайрес Смит кирәккә-кирәкмәскә атып бер генә пуляны да әрәм итмәскә дип сүз бирдерде.

Иртәнге сәгать алтыда көймә суга төшерелде. Топны да алып, һәммәсе көймәгә кереп утырдылар, һәм көймә диңгездән Рәхмәт елгасы тамагына таба йөзеп китте.

Ярты сәгать элек кенә диңгездә су арта башлады. Димәк, әле тагын берничә сәгать буе су күтәреләчәк. Шуннан файдаланып күбрәк юл узып калырга кирәк иде, чөнки су кайтканда агымга каршы ишеп барырга туры киләчәк һәм хәл авыраячак. Өч көннән ай тула, шуңа күрә бу көннәрдә су аеруча күп арта. Әлегә ишкәк белән ишеп азапланууның кирәге юк, су үзеннән-үзе көймәне өскә таба куалый, көймә ике яр арасыннан шуып кына бара иде.

Берничә минуттан дусларыбыз елга тугаена барып та җиттеләр, ярты гына ел элек бу төштән Пенкроф беренче тапкыр сал агызган иде.

Бу турыда елга кырт борыла да ике яклап үсеп утырган биек-биек ылыслы агачлар ышыгыннан көньяк-көнбатышка таба юнәлеш ала.

Рәхмәт елгасының яр буйлары сокланып туя алмаслык матур иде. Сайрес Смит һәм аның иптәшләре табигатьнең урман белән елга күренешеннән туган гүзәл манзарасыннан хозурланып баралар. Алга таба йөзгән саен төрледән-төрле агачлар очрый. Уң як яр битендә өскә таба баскыч-баскыч булып мәһабәт карамалык үрли,

Карама агачы суда озак череми, шуңа күрә кораб төзүчеләр бу кыйммәтле чималны кулга төшерергә тырышалар. Монда башка төр агачлар да күп; кычыктан агачының җимешеннән кыйммәтле азык — май табыла. Арырак киткәч, Герберт лардибазала агачлары күрде, аның пеше чыбыкларын суда җебетеп, чыдамлы аркан ишәргә мөмкин икән. Арада берничә карагач күренеп калды, аның үзәге каралҗым төстә, гаҗәеп матур бизәкләр төшкән була.

Туктар өчен җайлырак урыннар очраса, көймәне туктатып ярга төшәләр. Җилкәләренә мылтык аскан Гедеон Спилет, Герберт һәм Пенкроф, Топны ияртеп, яр буйларында йөреп киләләр. Монда киек кошлар гына түгел, игътибарны җәлеп итәрлек файдалы үсемлекләр дә очрый. Яшь натуралист кыр шпинатының бер төрен һәм кәбестәгә охшаган эвернә чәчәкле үсемлекләр очраткач бик шатланды, чөнки аларны киләчәктә икенче җиргә күчереп утыртып, үзләре өчен игеп үстерергә мөмкин иде. Шулар өстенә кыргый кресс, керән, шалкан һәм, ниһаять, соры орлыклы, мамыксыман төкләр белән капланган сабаклы, вак тармаклы бер метр озынлыгындагы тагын нindидер үсемлек очраттылар.

Герберт диңгезчедән:

— Син моның нинди үсемлек икәнен беләсеңме соң? — дип сорады.

Пенкроф җандай кадерле тәмәкесенең төрепкәгә тутыра торган хәлендәгесен генә күргәне бардыр ахрысы:

— Тәмәке! — дип әсәренеп кычкырып җибәрде.

— Юк, Пенкроф, тәмәке түгел бу, горчица! — диде Герберт.

Диңгезче, үпкәләп:

— Ярар, горчица булса булыр инде,— диде.— Әгәр берәр җирдә күзеңә тәмәке чалынса, зинһар игътибарсыз үтмә, улым, яме.

— Анысын да табарбыз, тапмый калмабыз,— дип юатты аны Гедеон Спилет.

— Шәп булыр иде! Билләһи, тәмәке дә табылса, утравыбызда күгәрчен сөте генә җитмәячәк!

Алар һәр тапкан үсемлекне ипләп кенә казып алып көймәгә илтәләр. Сайрес Смит, уйга батып, көймәдән чыкмыйча утыра.

Журналист, Герберт һәм Пенкроф берничә тапкыр әле уң як ярга, әле сул як ярга төшеп менделәр инде. Уң яр сөзәгрәк, сул ярны куе урман каплаган. Инженер,

компаска карап, беренче тугайдан соң елганың өч миль чамасы арада көньяк-көнбатыштан төньяк-көнчыгышка таба туп-туры агуын чамалады. Бәлкем, алдарак елганың юлы үзгәрәдер, ул төньяк-көнбатышка, Франклин тавына таба борыладыр һәм Франклин тавы сыртыннан агып төшәдер.

Гедеон Спилет берсендә, ярга төшкәч, тавыксыманнар отрядына керә торган ике пар кош тотты. Болар озын нәзек томшыклы, озын муенлы, кыска канатлы, койрыксыз кошлар иде. Герберт аларны танып, яшерен койрыклылар икәнен әйтте. Сәяхәтчеләр утрауда кош кетәге төзергә карар иттеләр, болар исә кетәкнең беренче вәкилләре булыр.

Моңа кадәр мылтыклар тын килгән иде. Зәңгәр кошка охшаган матур кош күренгәч, Ерак Көнбатыш урманында беренче тапкыр мылтык шартлады.

Пенкроф ничек атканын сизмичә дә калды бугай.

— Танындым мин аны,— дип кычкырды ул әсәренеп.

— Кемне таныдың? — дип сорады журналист.

— Кошны. Беренче сәяхәт вакытында ул бездән качып киткән иде, аның хөрмәтенә урманга исемен дә кушкан идек әле!

— Бу — жакамар! — диде Герберт сокланып.

Яңа калай кебек ялтыравыклы, каты каурыйлы бу сөйкемле кош — чыннан да жакамар иде. Ике-өч ядрә аны җиргә бәреп төшерде. Топ кошны көймәгә табып китерде. Аннары эт күгәрчен зурлыгындагы бер дистә тутый кош алып килде. Ак бүрекле, кызыл канатлы, ямьяшел каурыйлы бу тутыйларны Герберт аткан, үзенең уңышлы авыннан бик тә күңеле горурланган иде, чөнки тутыйларның ите агач кебек каты жакамар итенә караганда тәмлерәк була. Әмма масаерга яраткан Пенкрофның мин-минлеге җиңә алмады ул. Пенкроф үзе аткан жакамардан да яхшырак киек дөньяда юк дип үз сүзен бирмәде.

Иртәнге сәгать уннар тирәсендә көймә елганың икенче тугаена килеп җитте, ул елга тамагыннан биш миль ераклыкта иде. Сәяхәтчеләр ярга тукталып, тамак туйдырып алдылар. Биек матур агачлар күләгәсендә ярты сәгатьләп ял иттеләр.

Монда елганың тирәнлеге алты фут чамасы булып, киңлеге алтмыш-җитмеш футлар бар иде. Елгага вак инешләр коя, әмма аларга көймә белән керерлек түгел иде. Елганың бер ягыннан Җакамар урманы, икенче

ягыннан Ерак Көнбатыш урманы сузылып бара. Урманның очы-кырые күренми. Әмма урман куелыгында да, елга ярында да кешеләр яшәгәнлекне исбатларлык эзләр очрамады. Бу агачларга үз гомерендә балта-пычкы тимәгән, агачтан-агачка чорналып чәбәләнеп беткән лианаларга сунарчы пычагы кагылмаган, ерып чыккысыз куаклар арасына, бил тиңентен үскән куе үләнгә гомергә кеше аягы басмаган. Әгәр дә һәлак булган корабның кешеләре утрауга чыга алган булсалар, кайдадыр диңгез яры тирәсенәрәк урнашканнардыр, ерып чыккысыз бу куелыкка керергә шикләнгәннәрдер.

Шуңа күрә инженер иптәшләрен Линкольн утравының көнбатыш ярына тизрәк барып җитәргә ашыктырды. Анынча, көнбатыш ярга тагын биш миль чамасы калган булырга тиеш.

Алар яңадан кузгалып киттеләр. Елга үзәне көнбатыш ярга таба түгел, Франклин тавына авышса да, бара алган хәтле агымга каршы күтәрелергә уйладылар. Вакыт та янга калыр, соңыннан үзләренә дә җиңелгә туры килер. Әгәр урман аша турыдан китсәләр, балта белән агачларны егып, юл арчып барырга туры киләчәк бит.

Озакламый елга агымы аларга ярдәм итми башлады, су күтәрелүдән туктады булса кирәк (чыннан да, суның кайтыр чагы җиткән иде); әллә болай ерак киткәч, су агымының көче кимедеме, һәрхәлдә, кулга ишкәк алырга туры килде аларга. Наб белән Герберт уртадагы утыргычка утырып ишә башладылар, Пенкроф койрык ишкәген тотты, һәм көймә агымга каршы йөзә башлады.

Ерак Көнбатыш урманы алга таба сирәкләнде, агачлар хәзер куе булып үсмиләр, иркенәеп утыралар. Яктылык һәм һава мул булганга, тагын да матураеп, мәһабәтрәк булып күтәрелгәннәр иде.

Бу урында үсемлекләрнең нинди генә очрамый! Аларга карагач та ботаник бу Линкольн утравының кайсы географик төбәккә урнашканлыгын шундук әйтеп бирер иде, әлбәттә.

— Эвкалиптлар! — диде сокланып Герберт.

Чыннан да, бу мәһабәт агачлар — субтропика зонасының соңгы вәкилләре — Линкольн утравы белән бер үк географик киңлектә урнашкан Австралия һәм Яңа Зеландиядә үсә торган эвкалиптларның бер төре иде. Кайбер агачлар икешәр йөз фут үскәннәр. Аларның юанлыгы егермешәр фут булып, хуш исле сумала агып төшкән кабыгының калынлыгы биш дюйм чамасыдыр.

Мирт токымына керә торган бу зур агачлардан да үзенчәлекле, алардан да кызыклы агач дөньяда тагын бар микән. Аларның яфраклары кояшка сырты белән борыла, һәм кояш нурлары аның ябалдашы аша тоткарлыксыз үтеп, агачның төбенә хәтле төшеп җитә!

Эвкалипт тирәли куе булып яшел үлән үскән, үлән араларыннан көтү-көтү нинди-дер вак кошлар пырылдап һавага күтәреләләр, алар кояш нурларында ахак кебек янып, уйнаклап очалар.

— Менә ичмасам болар агач дисәң дә агач! — диде Наб сокланып.— Тик берәр эшкә яраклы микән болар?

— Яраклы ди сиңа! Дөньяда гигант кешеләр кебек гигант агачлар да ярминкәдә күрсәтер өчен генә ярамаса! — диде Пенкроф.

— Ялгышасыз, Пенкроф,— диде Гедеон Спилет.— Эвкалиптларны хәзер куллана башладылар: алардан матур җиһазлар ясыйлар.

— Шуның өстенә эвкалиптлар төркеменә керә торган агачлар арасында бик файдалылары бар: мәсәлән, фейхоаның җимешен ашыйлар; канәфер агачының чәчәген аш-су тәмләткече итеп кулланалар; анар агачының җимешен ашыйлар; «eugenia cauliflora» агачының җимешеннән шәраб ясыйлар; «ugni»ның суы — үзе исерткеч эчемлек; «caryophyllus» дигәненең кабыгыннан дарчин алалар; «eugenia pimenta» дигәненең кузаклы борычы була; гади мирт агачының җиләге кара борычны алыштыра; «eucalyptus robusta» дигәненнән манный ярмасы ясыйлар; «eucalyptus Gunei» сыгынтысыннан сыра әчетәләр; ниһаять, «тормыш агачы» яки «тимер агач» дигәне дә мирт агачлары токымына керә; кыскасы, эвкалипт-мирт агачлары кырык алты төркемгә, меңдә өч йөзләп төргә бүленә.

Яшь егетнең рухланып-рухланып ботаникадан дәрес аңлатканын иптәшләре бүлдермичә игътибар биреп тыңлап тордылар. Сайрес Смит ул сөйләгәндә елмаеп утырды, ә Пенкрофның кәпрәюен әйтеп килештерерлек түгел иде.

— Бик шәп, Герберт,— диде ул.— Син санап чыккан файдалы агачларның берсе дә мондый ук гигант түгелдер, кулымны кисмәгә бирәм!

— Анысын дөрес әйтәсең, Пенкроф!

— Димәк, мин хаклы булып чыктым, менә бу гигантлар бернигә яраксыз.

— Ялгышасыз, Пенкроф,— диде инженер.— Безне үз

куенына сыендырган менә бу гигант агач бик күп яктан файдалы!

— Нәрсәсе файдалы соң аның?

— Алар үскән тирәлекнең һавасы сәламәтлеккә файдалы. Австралиядә һәм Яңа Зеландиядә бу агачны ничек итеп атап йөрткәннәрен беләсезме?

— Белмим, мистер Сайрес.

— «Бизгәк агачы».

— Ул бизгәкне дәвалыймы?

— Юк, бизгәктән саклый.

— Ярый, шулай дип язып куям,— диде журналист.

— Языгыз, яз, сөекле Спилет. Эвкалиптлар тирә-як табигатен сәламәтләндерергә ярдәм итәләр. Бу исбат ителде инде. Европаның көньягында, Төньяк Америкада табигатьнең бу шифалы агачын сазламык җирләргә утыртып карадылар. Нәтиҗәдә, вакытлар үтү белән, җирле халыкның сәламәтлеге әкренләп яхшырганлыгы мәгълүм булды. Эвкалипт урманы үскән якларда бизгәк кизүе юк. Эвкалиптның файдалы икәнлегенә хәзер беркем шикләнми. Линкольн утравында яшәргә мәҗбүр булган без бичаралар өчен дә монда эвкалиптлар үсүе куанычлы факт.

— Әйбәт утрау бу! Игелекле утрау! — диде Пенкроф.— Җаның ни тели шул бар безнең утравыбызда. Тик менә әлегә...

— Анысы да булыр, Пенкроф, эзләп табарбыз,— диде инженер,— әйдәгез, кузгалыйк, көймә су төбенә терәлгәнче барыйк әле.

Сәяхәтчеләр утрауны өйрәнүне дәвам иттеләр. Утрауның бу өлешендә башка барлык агачлар өстеннән калкып утырган эвкалиптлар ышыгыннан тагын ике миль алга йөзделәр. Рәхмәт елгасының ике як яры буйлап сузылган эвкалипт урманының очы-кырые күренми, яшеллеккә күмелгән биек яр эченнән тар гына елга борыла-сарыла ага да ага. Урыны-урыны белән елга үзәнен күрән баскан, урыны-урыны белән су астыннан ташлар тырпаеп чыгып тора, алар йөзүне кыенлаштыра иде. Ишкәк белән ишеп барырга мөмкин түгел хәзер. Пенкроф, су төбенә колга терәп, көймәне этеп кенә алып бара башлады. Елга суы тәмам саекты, озакламый көймә бөтенләй төпкә утырачак. Кояш офыкка авышты, агачларның күләгәләре озынайды. Сайрес Смит караңгы төшкәнче көнбатыш ярга барып җитә алмаячакларын аңлады һәм, елгада йөзеп булмый башлагач, көймә терәлгән

төштә төн кунарга карар итте. Диңгез ярына хәтле тагын биш-алты миль чамасы калгандыр. Шактый ерак әле. Төнлә белән ят урман эченнән йөрмәү хәерле дип уйлады ул.

Көймә әле һаман агымга каршы менә, урман куелана бара, җанварлар да күбәйде. Әгәр Пенкрофның күзе алдамаса, ул агачтан-агачка сикереп йөргән маймыл көтүен күрде. Маймылларның әле берсе, әле икенчесе көймә янына ук килеп чыга, курыкмыйча сәяхәтчеләргә карап тора иде. Кешеләрне беренче тапкыр күргәнлекләре әллә кайдан сизелә. Аларны атып алуы да кыен булмас иде. Комар аучы Пенкрофның кулы бик кыҗрыса да, Сайрес Смит мәгънәсезгә җәнлекләр җанын кыюга каршы булды. Аларга атсаң, үзеңә кыены төшүе мөмкин иде: яшен кебек елгыр, көчле маймыллар ярсыган чакта бик куркыныч булалар, аларга тимәвең хәерле.

Диңгезче исә маймылларга ит өчен генә кызыга иде, чыннан да маймыл үсемлек белән генә туклана һәм ите бик тә тәмле була. Хәер, сәяхәтчеләрнең азык-төлеге әлегә җитәрлек иде, юкка-барга патрон әрәм итәргә кирәкмәстер.

Сәгать көндезге дүртләр җитте. Елгадан баруы тагын да авырлашты, суүсемнәр, ташлар күбәйде, урыны белән алар суны бөтенләй бөягән иде. Ике яр да һаман биегәя бара, чөнки елга хәзер Франклин тавыннан ага инде. Күрәсең, су башына ерак калмагандыр. Ул тауның көньяк битеннән агып төшкән кар суларыннан башланса кирәк.

— Чирек сәгатьтән дә ары бара алмабыздыр, мистер Сайрес.

— Ярар, Пенкроф, нишләмәк кирәк, туктарбыз. Шул урында төн кунарбыз.

— Гранит сарайдан ерак киттекме инде? — дип сорады Герберт.

— Җиде миль чамасы булыр. Мин елганың барлык борылмаларын да кушып исәплим, шуның аркасында без бераз төньяк-көнбатышкарак авыштык,— диде инженер.

— Тагын да бара алабызмы әле? — дип сорады журналист.

— Бераз гына барырга була,— диде Сайрес Смит.— Ә иртәгә, таң аткач, көймәдән төшәрбез дә җәяүләп кенә китәрбез. Мөгаен, ике-өч сәгать дигәндә ярга барып җи-

тәрбез. Һәм кичкә чаклы диңгез яр буйларын йөреп-карап чыгарга өлгерербез.

— Алга! — диде Пенкроф.

Озакламый көймәнең асты су төбендәге ташларга ышкыла башлады. Бу тирәдә суның киңлеге егерме футтан артмас. Баш өстендә агач очлары бергә кушылып яшел чатыр хасил иткән, елгада ярым караңгылык хөкем сөрә. Кайдадыр югарыдан агып төшә торган суның шаулавы ишетелә, якында гына шарлавык бар ахрысы.

Чыннан да, бераз алдарак, елга борылышын узгач та, агачлар арасында шарлавык күренде. Көймә төпкә утырды, аны уң як ярдагы агачка бәйләп куйдылар.

Кичке сәгать бишләр тирәсе иде. Баеп барган кояшның сүрән нурлары агач яфраклары арасыннан үтеп шарлавык суын яктырта: читкә чәчрәгән су тамчылары кояш нурында салават күпере төсләренә манчылып жемелдиләр иде. Рәхмәт елгасының шарлавыктан аргы өлеше куе яшеллек эченә кереп күздән югала. Субашы бик якын булса кирәк. Елга суы бу турыда чишмә суыдай саф, салкын; сай төбендә ташлар ялтырап күренеп ята. Ә диңгезгә таба бару юлында ул тирәнәя, кушылдыклары белән баеп, мул сулы елгага әверелә.

Әкияттәгедәй матур шушы табигать почмагында төн кунарга әзерләнделәр. Әйберләрне көймәдән бушаткач та, учак ягып җибәрделәр, кичке аш әзерләргә керештеләр. Монда кычыткан агачлары үсә икән, аның ботакларына менеп йокларга да мөмкин иде.

Юлчылар бик ачыкканнар икән, ризыкка дәррәү ябырылып, ашап та бетерделәр. Һәм ятарга җыена башладылар. Караңгы төшүгә, әйләнә-тирәдә ниндидер җанварларның ырылдаганы, үкергәне ишетелә башлады. Сәяхәтчеләр ашыгып учакка күп итеп ботаклар өстәделәр,— әйдә, ялкыны биегрәк күтәрелсен, ерткычларны өркетсен, кешеләр тынычлап йокласын. Наб белән Пенкроф чиратлашып сакта тордылар, утынны кызганмыйча, төне буе учак ягып чыктылар. Ә тирә-якта һаман ниндидер җанварлар йөрде, агач арасыннан үтеп-сүтеп йөрүләре күренеп-күренеп калды. Ләкин төн хәвефсез узды, иртәгесен, 31 нче октябрьдә, иртән сәгать биштә, һәммәсе йокыдан торгач, юлны дәвам итәргә җыена башладылар.

Дүртенче бүлек

Диңгез ярына таба юл.— Маймыллар.— Яңа елга.— Нигә су күтәрелгәне сизелми? — Яр урынына — урман.— Елан борыны.— Герберт Гедеон Спилеттан көнләшә.— Бамбук ничек яна?

Иртән сәгать алтыда тамак ялгагач, сәяхәтчеләр юлга кузгалдылар,— алар көнбатыш ярга тизрәк барып җитәргә ашыгалар иде. Ничә сәгатьтән барып җитә алырлар соң? Сайрес Смит ике сәгатьтән диде диюен... Хәер, анысы юлның ничек булуына, алда нинди каршылыклар очрауга бәйле. Ерак Көнбатыш урманының бу тирәсе бик куе, биредә агачларның кайсы гына төрләре очрамый. Куе куаклыклар, чәбәләнеп беткән лианалар, кеше буе булып үскән үлән-чытырман эченнән балта белән чабып сукмак салып узарга туры килә иде. Ә икенче кулларында мылтык. Чөнки төнлә ерткычлар үкерүе аларны сагаерга мәҗбүр итте.

Төн кунган урынның кайдалыгын Франклин тавына карап чамаларга мөмкин иде. Тау төньякта, моннан өч миль чамасы ераклыкта,— димәк, диңгез ярына чыгу өчен көньяк-көнбатышка турылап барырга кирәк.

Сәяхәтчеләр көймәне агачка ныгытып бәйләп калдырдылар. Пенкроф белән Наб ким дигәндә ике көнгә чамалап азык-төлек алдылар, аны үзләре күтәреп бардылар. Юлда киек-фәлән аулап маташмаска карар иттеләр. Диңгез ярына ерак калмаганлыктан, инженер кирәккә-кирәкмәскә үзләрен сиздермәскә киңәш итте.

Шарлавыктан бераз өскәрәк менгәч, куе куакларны чабып сукмак салу өчен кулга беренче тапкыр балта тотарга туры килде. Кулындагы компасы белән Сайрес Смит алдан юл күрсәтеп барды.

Урманның бу тирәләрендә үсеп утырган агачлар барысы да таныш иде инде, алар күл буенда да, Күзәтү иссытаулыгында да очрыйлар: монда эрбет, деодар, дуглас, казуарин, эвкалипт, драцена, гибиск һәм башка агачлар бар иде. Агачлар бик куе үскән; нигәдер күбесе тәбәнәк. Сәяхәтчеләр юл сала-сала акрынлап алга баралар. Сайрес Смит, бу сукмакны киләчәктә Кызыл инеш буендагы юл белән тоташтырырбыз, диде.

Сукмак тау битеннән түбәнгә таба төшә. Аяк астында туфрак бик коры булуга карамастан, үлән куе булып күпереп үскән,— мөгаен, монда җир астындагы сулар якындыр яки янәшә-тирәдән генә елга агадыр. Хәер,

Франклин тавы башыннан күзәткәндә Сайрес Смит Кызыл инеш белән Рәхмәт елгасыннан башка елга күрмәде күрүен.

Юлчылар инде берәр сәгатьләп килгәннәрдер. Кинәт каршыга бер көтү маймыл килеп чыкты. Кешеләрне беренче тапкыр күргәнгәме, алар туктап калдылар да мавыгып карап тора башладылар.

Гедеон Спилет, әллә бу көчле, җитез дүрткуллылар безне үзләренең гарип нәселдәшләре дип таныдылар микән, дип шаяртып та куйды. Чынлап та инде, юлчылар адым саен очраган куе куаклык каршысында чарасыз булып туктап калалар, чәбәләнгән лианаларны аралап чыга алмыйча азапланалар, аяк астындагы корысарыга абынып егылалар, ә агачтан-агачка очып диярлек җиңел сикереп йөргән, теләсә кая асат кына үрмәли торган җитез маймыллар белән чагыштырганда алар мескен хәлдә шул. Маймыллар күп иде, бәхеткә, кешеләргә дошманлык кылырга ниятләре сизелмәде.

Әледән-әле аларга кабан дуңгызы, агут, көнгерә һәм төрле кимерүче җәнлекләр очрый, хәтта бер-ике тапкыр сумкалы аю да күренеп калды. Пенкроф боларның бер ишесенең маңгаена пуля җибәрергә кызыкса да, үзен тыеп калды:

— Әйдәгез, яшь биреғез инде! Ау башларга әлегә рөхсәт юк. Сикерегез, йөгерегез, оча торыгыз, дусларым. Кайтыр юлда гәпләшербез әле без сезнең белән,— диде.

Иртән сәгать унынчы яртыда бик тиз агышлы, тирән сулы билгесез тау елгасы аларның юлын бүлде. Аның киңлеге утыз-кырык футлар чамасы булыр, таштан-ташка сикерә-сикерә ярсып-котырынып аккан бу елгада көймә белән йөзү турында хыялланырлык та түгел иде.

— Юл киселде,— диде Наб.

— Юк, киселмәде,— диде Герберт.— Инеш кенә бит бу. Аны йөзеп тә чыга алабыз...

— Нигә кирәк ул,— диде Сайрес Смит.— Күрмисезмени, елга диңгезгә таба ага. Сул яр буйлап аңа нярсәк, тиздән без дә шунда барып чыгарбыз! Әйдәгез, кузгалдык!

— Туктагыз әле, дусларым! Елганы ничек дип атыйбыз? Картада ак тап калмасын инде,— диде журналист.

— Дөрес! — диде Пенкроф.

Инженер Гербертка мөрәҗәгать итте:

— Йәле, дустым, инешкә исемне син куш.

— Сабыр итсәк әйбәтрәк булмасмы: башта тамагына хәтле барып җитик әле, шунда карарбыз,— диде егет.

— Ярый соң,— дип ризалашты Сайрес Смит.— Әйдәгез, агымга ияреп, түбәнгә таба киттек, җитезрәк атлагыз!

— Туктагыз әле! — диде Пенкроф.

— Ни булды тагын? — дип сорады журналист.

— Ау тыелганын беләм, ләкин балык тотарга рөхсәттер бит.

— Вакытны әрәм итмик инде, зинһар,— диде инженер.

Ләкин Пенкроф үз сүзен тәкрарлады:

— Биш кенә минут сабыр итегез инде. Биш минутка гына тоткарланыйк. Аның каравы көндезгә тәмле ризыгыбыз булыр.

Пенкроф яр буена сузылып ятты да кулын агым суга тыкты. Таш арасында кайнашкан дистәләп кысланы күз ачып йомган арада ярга өеп тә куйды.

Наб аңа ярдәмгә ашыкты:

— Шәп бу!

Пенкроф авыр көрсенеп куйды:

— Әйттем бит инде мин сезгә, бу утрауда тәмәкедән кала, һәммә нәрсә бар дип.

Инештә кыслалар мыжлап тора иде, биш минут эчендә әллә нихәтле кысла тоттылар. Нәни кыскычлы, зәп-зәңгәр кабыклы эре-эре кыслаларны бер капчыкка тутырып, юлны дәвам иттеләр.

Елга буеннан баруы асат иде, юлчылар ашыга-ашыга алга атладылар. Ә кешеләр яшәгәнлеген күрсәтердәй билгеләр һаман да очрамады. Сирәк-мирәк кенә, эре җәнлекләрнең су эчәргә төшкән эзләренә тап булгаладылар. Шуннан башкасы күренмәде. Итеннән ядрә бөртеге чыгып, Пенкрофның тешен сындырган дуңгыз баласы бу урманда җәрәхәтләнмәгәндер, күрәсең.

Елганың диңгезгә таба кызу агуына карап, Сайрес Смит көнбатыш ярга хәтле әле үзләре чамалаганнан шактый ерак икәнлеген төшенде. Чыннан да, хәзер бит диңгездә су күтәрелә торган вакыт, әгәр дә елга тамагы якын булса, суы кирегә ага башларга тиеш иде. Ә елга, һаман да элеккечә, табигый агымы белән агып ята. Инженер бу хәлгә аптырады. Әллә елга, борылып, киредән Ерак Көнбатыш урманы эченә агып кереп китәме икән дип әледән-әле компасына карап алгалады.

Елга инде шактый киңәйде, агымы да әкренәйде. Уң ярда да сул ярдагы кебек ерып чыккысыз куе урман иде; монда кеше яшәмәгәнлеге күренеп тора. Топ та өрми. Әгәр бу тирәләрдә кеше-фәлән булганлыгын сизсә, акыллы эт күптән хәбәр бирер иде.

Иптәшләреннән алдарак барган Герберт сәгать унберенче яртыларда кинәт:

— Диңгез күренә! — дип кычкырып җибәрде.

Сайрес Смит моңа бик тә гаҗәпләнде. Юлчылар урман авызына килеп чыктылар, алда утрауның көнбатыш яры күренде.

Алар беренче тапкыр килеп төшкән көнчыгыш яр белән чагыштырганда бу ярның аермасы таң калырлык зур иде! Яр буйлап сузылган гранит стена да юк, су астыннан кыя ташлар да калкып тормый, комлык та күренми! Диңгез читендә үк ботакларын суга иеп агачлар үсеп утыра, диңгез дулкыннары агачларның төбенә үк килеп җитә. Гадәттә без күреп өйрәнгән, табигать үзе барлыкка китергән, ком түшәлгән, кыя ташлар өелгән гади яр буе түгел инде бу. Гаҗәеп матур мәһабәт агачлар үсеп утырган урман авызы бу. Елга тамагы биек яр өстендә, диңгез суы ничек кенә күтәрелмәсен,— барыбер аның агымына тәэсир итәрлек түгел. Яр буенда ук гранит нигез өстенә түшәлгән уңдырышлы туфракта җир йөзенең иң гүзәл агачлары күкрәп үсеп утыралар; утрауның башка җирләрендәге кебек үк, тамырларын тирәнгә җибәреп нык береккәннәр.

Сәяхәтчеләр елга тамагының кечерәк бухтага тоташуын күреп алдылар. Анда балык аулаучы ике-өч судно сыярлык иде. Елга суы диңгезгә сөзәк ярдан иркенләп акмый, бәлки кырык фут биеклектән шарлавык хасил итә. Шул сәбәпле диңгез суы аның агымын кирегә куалый алмый икән. Дулкын нихәтле югары күтәрелмәсен, Тын океан елганың ярына мәңге менеп җитәчәк түгел. Елга тамагында табигый шлюз барлыкка килгән. Аның төбен ашап, үзенә уңайлы юл салу өчен елгага әле миллион-миллион еллар агарга кирәк булачак. Елганы барысы бер авыздан *«Шарлавык елгасы»* дип атадылар.

Диңгез кырыйлап урман төньякка таба тагын әле ике миль чамасы сузыла, ә аннары сирәгәя башлый. Яр буена тезелеп үскән агачлардан соң калкулыклар китә. Шарлавык елгасы тамагыннан алып Елан борынына хәтле сузылган көньяк яр исә тоташ куе урман белән капланган, Күккә үрләгән мәһабәт агачлар яныннан

ук диңгез башлана. Кораблары баткан кешеләрне менә шушы ярдан, ягъни Борылмалы ярымутраудан эзләргә кирәк. Чөнки алар утрауга чыга алган тәкъдирдә, кыргый, шәрә төньяк ярга караганда, мондагы бай табигатьнең куенына сыенуны кулай күргәннәрдер.

Көн аяз, күктә кояш балкый. Наб белән Пенкроф ашарга әзерләп азапланган җирдән, биек яр башыннан, океан киңлекләре ерак-еракларга хәтле күренә. Офыкта ник бер җилкән шәйләнсен. Ярның буеннан-буена ник берәр көймә яисә ватык кораб калдыклары күренсен. Шулай да Сайрес Смит Борылмалы ярымутрауның очына хәтле барып җитәргә, яр буйларын тәмам йөреп чыгарга карар итте.

Төшке ашны тиз генә ашап алдылар. Уникенче яртыда Сайрес Смит юлга җыенырга әмер бирде. Алда комлы-ташлы яр түгел, суга тиеп үк үскән куе агачлар, куаклар арасыннан балта белән юл ярып барырга туры киләчәк иде.

Шарлавык елгасы тамагыннан алып Елан борынына хәтле ара унике миль чамасы булыр. Әйбәт юлдан барганда ул араны дүрт сәгать эчендә узарга мөмкин, әмма безнең сәяхәтчеләргә ауган зур-зур агачларны әйләнеп, чәбәләнеп беткән юан лианаларны, куаклыкларны кисеп, чабып узарга туры киләчәк; димәк, юллары ихтыярсыздан озынаячак, вакытлары икеләтә күбрәк китәчәк иде.

Алар баткан кораб калдыкларын очратмадылар. Диңгез дулкыннары ватык-сыныкларны еракка агызып алып киткәндер диюе белән, бәлки, Гедеон Спилет хаклыдыр. Соңгы чиктә, әгәр бер генә ватык-сынык очрамаса да, Линкольн утравының көнбатыш яры тирәсендә кораб һәлак булмаган дип әйтә алырга кыймас идең.

Ядрә табылу вакыйгасе моннан өч ай элек утрауда кемнеңдер мылтыктан атканлыгын раслый, шулай булгач журналистның сүзе хак булуы бик мөмкин иде.

Кичке сәгать биш җитте. Борылмалы ярымутрауның иң очына хәтле тагын ике миль чамасы калды. Анда барып җитсәләр дә, кичә төн кунган урынга, ягъни Рәхмәт елгасы ярына, яктыда әйләнеп кайтып җитәргә өлгермәячәкләр иде. Елан борынында төн кунарга туры килердер ахрысы. Ашарга-эчәргә ризык җитәрлек, анысы ярады. Югыйсә монда урманда да, диңгез яры буенда да атып алырдай киек җәнлек никтер очрамады. Кошлар күп иде күбен: җакамар, куруку, трагопан, көртлек,

зурысыннан-кечесеннән төрле тутый кошлар, какадулар, фазан, күгәрчен көтүе-көтүе белән очып йөри. Кошлар оя кормаган бер генә агач та юк! Оялардан чыр-чу килгән кош тавышлары яңгырап тора!

Арыган-йончыган юлчылар диңгез эченә сузылып кергән Елан борынына кичке сәгать җиделәргә килеп җиттеләр. Урман шунда бетте. Утрауның көньяк яры алар гадәтләнгән диңгез ярына охшаган иде: монда кыялар тезмәсе, урыны-урыны белән комлы сайлыклар очрый, су астыннан анда-санда ташлар калкып чыгып тора. Һәлак булган корабны диңгез дулкыннары, бәлкем, шушы ярга чыгарып ташлагандыр... Әмма, караңгы төшкәнлектән, аны эзләүне иртәгәгә калдырырга туры килде.

Пенкроф белән Герберт төн кунар өчен җайлы урын эзли киттеләр. Урман беткән җирдә бамбук ешлыгы күренде.

Герберт шунда шатланып:

— Менә кыйммәтле табышка юлыктык! — диде.

— Нәрсәсе кыйммәтле аның? — дип сорады Пенкроф.

— Бамбук сабагын юка итеп телсәң, кәрзин үрергә мөмкин. Әгәр шул ук сабакларны суда җебетеп, камыр итеп изсәң, аннан кытай кәгазе ясарга була. Бамбукның төрле юанлыктагы кәүсәсеннән таяклар, көпшәләр, су торбалары, тәмәке төрепкәләре ясыйлар. Зур бамбук агачы җиңел һәм нык төзү материалы булып хезмәт итә, аны агач корты зарарламый. Юан бамбук кәүсәсен бер буын төбен калдырып киссәң, менә дигән уңайлы савыт килеп чыгачак. Андый савыт-сабаны Кытайда кулланалар. Нигә боларны сөйләп азапланам, син барыбер күңел биреп тыңламыйсың. Ә аннары...

— Аннары нәрсә?

— Белмәсәң, бел! Һиндстанда бамбукны спаржа урынына ашыйлар.

— Утыз футлы спаржанымы! — дип кычкырып ук җибәрде Пенкроф. — Тәмлеме соң ул?

— Бик тәмле! Тик утыз футлы бамбукны түгел, яшь бәпчекләрен ашыйлар.

— Шәп икән, улым, бик шәп икән!

— Серкә сибеп әзерләгән яшь бәпчекләр ашап туймаслык тәмле була.

— Анысы тагын да шәбрәк икән!

Ниһаять, бамбукның суы татлы була, аннан эчемлек ясыйлар.

— Шуның белән беттеме?

— Бетте.

— Ә тәмәке итеп тартып булмыймы аны?

— Юк шул, булмый, дустым.

Герберт белән диңгезчегә төн куну өчен җайлы урынны озак эзләргә туры килмәде. Көньяк-көнбатыштан искән көчле җил кузгаткан ярсулы дулкыннар яр буендагы кыяларны ашап, куышлар хасил иткән. Куышлар начар көнне кереп ышыклану, төн куну өчен бик унайлы иде. Пенкроф белән Герберт шундый бер куыш каршысына килеп туктадылар һәм эченә керергә теләп бер-ике адым атлаганнар иде, кинәт куыш эченнән ярсулы ырылдаган тавыш ишетелде.

— Артка чиген! — дип кычкырды диңгезче.— Безнең мылтыклар ядрә белән генә корылган, мондый ярсып ырылдаган ерткычка ядрә белән ату тоз белән аткан кебек кенә.— Ул Гербертның кулыннан тотты да кыя артына йөгерде. Шул вакыт куыш эченнән таң калырлык матур ерткыч җанвар килеп чыкты. Бу — зур ягуар иде. Азиядә күп яши алар. Ягуарның озынлыгы биш футлар чамасы, җирән тиресе бөрчек-бөрчек кара таплар белән чуарланган, корсак асты тимгелле. Ак өстендә кара тимгелләр тагы да ачыграк күренә. Герберт аны шундук таныды: бу — юлбарысның көндәше ягуар; бүреләрнең көндәше исәпләнгән кагуарларга караганда да куркынычрак ерткыч җанвар.

Ягуар берничә адым атлады да сагаеп тирә-якка каранды, йоннары кабарды, күзләрен кан басты, гүя аның кеше белән очрашуы беренче тапкыр түгел иде.

Шул вакыт биек кыя артыннан Гедеон Спилет килеп чыкты. Ул ягуарны күрми ахрысы дип уйлады Герберт һәм бирегә килү куркыныч икәнен әйтер өчен аның каршысына ташланды, әмма Гедеон Спилет егеткә урыныннан кузгалмаска кушып ым какты, ә үзе туктамыйча бара бирде. Аның юлбарыс аулаганы бар иде,— ул ун адым каларак туктады да карабинын ерткычның маңгаена төзәде. Йөзендә ник бер шөбһәле төс булсын ичмасам! Юк!

Ягуар аңа ташланырга әзерләндеı гәүдәсен җыерды; нәкъ шул мәлдә аның ике күз арасына пуля килеп тиде һәм ул җиргә ауды.

Герберт белән Пенкроф ягуар янына йөгерделәр.

Наб белән Сайрес Смит та килеп җиттеләр һәм җирдә сузылып яткан ерткычны кызыксынып карарга керештеләр. Аның матур, затлы тиресе Гранит сарай залын бизәргә бик әйбәт булды, дип куандылар.

Герберт, соклануын яшерә алмыйча, канатланып:

— Ах, мистер Спилет! Сокланам мин сезгә! Кызыгам да, көнләшәм дә хәтта! — диде.

— Син үзең дә миннән ким атмас идең, дустым.

— Минме, сезнең кебек тыныч төзәпме?

— Андый чакта алдыңда юлбарыс түгел, куян тора дип уйларга кирәк. Шунда гына тыныч атып була.

— Менә күрдеңме, Герберт, ике тиен бер акча икән! — дип куйды Пенкроф.

— Хәзер ягуар өне бушады, нигә безгә шунда кереп йокламаска? — диде Гедеон Спилет.

Пенкроф шикләнә калды:

— Әгәр башкалары әйләнеп кайтса!

— Куыш авызына учак ягарбыз, керергә батырчылык итмәсләр,— диде журналист.

— Әйдәгез алайса, ягуарга кунакка рәхим итегез! — диде диңгезче. Һәм үле ерткыч гәүдәсен куышка таба өстерәп алып китте.

Башкалар да ягуар ташлап чыккан куышка юнәлделәр.

Наб ягуарның тиресен тунаган арада, иптәшләре урманнан күп итеп коры-сары җыеп чыктылар һәм куыш авызы алдына өеп куйдылар.

Сайрес Смит бамбук арасына кереп китте дә берничә бамбук агачы кисеп алып чыкты һәм аларны утын арасына салды.

Эш беткәч, куышның ком идәненә урнаштылар. Анда-санда кимерелгән сөякләр аунап ята иде. Көтмәгәндә берәрсе һөҗүм итә-нитә калса дип, мылтыкларны корып куйдылар. Кич ашап алгач, ятар алдыннан куыш авызындагы учакка ут төртеп җибәрделәр.

Кинәт берьюлы күпләгән мылтык аткан тавышлар чыгарып, күккә ут көлтәләре чөя-чөя бамбук агачлары яна башлады. Шарт-шорт иткән шушы тавышлар гына да иң явыз ерткычларның да котын алырлык иде.

Юк, инженер уйлап чыгарган хәйлә түгел иде бу. Марко Поло әйтүенчә, борын-борын заманнарда ук монголлар үзләре кунган җирдән Урта Азия далаларының усал ерткычларын шулай куркытып качыра торган булганнар.

Бишенче бүлек

Көньяк яр буйлап кайту.— Яр буе сызыгы.— Баткан кораб калдыкларын эзләү.— Һава шары калдыгы.— Табигый гавань.— Төн уртасында Рәхмәт елгасыннан көймә агып килә.

Сайрес Смит һәм аның иптәшләре «кунакчыл» ягуар куышында рәхәтләнеп тынычлап йокладылар. Кояш чыкканда алар Елан борынының иң очында басып торалар иде инде. Алларында җәелеп яткан очсыз-кырыйсыз диңгез өстен күзәтәләр иде. Инженер, күзәтү трубасы белән офык буйларын җентекләп карагач, диңгез өстендә ни баткан кораб калдыклары, ни җилкән күренмәвенә тагын бер тапкыр ышанды.

Яр буйлары буп-буш, һәрхәлдә, Елан борынының өч миль чамасы туп-туры булып сузылган көньяк ярында берни күренми, ә арырак киткәч, яр буе эчкә таба батып кергән, кечерәк кенә табигый култык хасил булган. Борылмалы ярымутрауның диңгезгә очлаеп кереп торган иң читенә барып баскач та моннан Тырнак борыны күренми әле, чөнки аны биек кыя каплый иде.

Димәк, утрауның көньяк яр буйларын йөреп, тикшереп чыгудан башка чара калмый. Хәзер үк кузгалып, әллә икенче ноябрь көнен шуңа багышларгамы?

Әмма бу кадәресе аларның элекке ниятләренә керми иде. Көймәне Рәхмәт елгасының башында бәйләп калдырган чакта, алар көнбатыш яр буйларын йөреп чыкканнан соң, кире шунда әйләнеп килербез дип уйлаганнар иде; аннары Гранит сарайга Рәхмәт елгасы белән йөзеп кайтырга исәпләгәннәр иде. Чөнки Сайрес Смит баткан судно калдыкларын яисә якорь салган корабны көнбатыш ярда очратырбыз дип өметләнгән иде. Хәзер инде монда табылмаганны көньяк ярдан эзләргә туры килә.

Бу тирәдә нинди дә булса кораб эзе бармы-юкмы икәнен тәгаен ачыклау өчен Гедеон Спилет утрауның калган өлешен карап бетерергә киңәш итте һәм ярымутрауның очыннан Тырнак борынына хәтле чама белән күпме ара калганын белергә теләде.

— Яр буйлап барсаң, утыз миль чамасы,— диде инженер.

— Утыз миль! — диде Гедеон Спилет.— Көне буе узарлык юл икән. Шулай да, минемчә, үзебезнең сарайга көньяк ярдан әйләнеп кайту хәерле.

— Гранит сарайга Тырнак борыныннан соң да тагын ун миль кала әле,— дип искәртте Герберт.

— Калса соң, барысы кырык мильгә җыелсын, ди. Зыян юк. Әйдәгез, вакытны әрәм итмик. Бу як яр буйлары белән танышырбыз да бүтән килеп тә йөрмәбез.

— Анысы дөрес дөресен, тик көймәне нишләтәбез соң? — диде Пенкроф.

— Көймәме, көймә шунда елга башында калып торыр. Ике көндә берни булмас! Утрауда каракларданзарланган юк бит әле,— диде Гедеон Спилет.

— Ташбака исемә төшсә, һәрнәрсәдән шикләнә башлыйм мин.

— Ташбака, ташбака! Әллә оныттыгызмы: дулкын аны корсагына әйләндергән бит,— диде журналист.

— Кем белә бит әле?..— дип куйды инженер үзалдына.

Наб:

— Әгәр...— дип нидер әйтмәкче булып авызын ачкан иде, нишләптер тыелып калды.

— Наб, син нидер әйтмәкче иден бугай? — дип сорады инженер.

— Әгәр яр буйлап Тырнак борыныннан әйләнеп кайтырга теләсәк, өйгә юл бикләнә димәкче идем.

— Дөрес әйтә! Рәхмәт елгасын аркылы чыгарга күпер юк бит. Көймәбез дә калды. Теге якка чыгып булмаячак,— диде Герберт.

— Юкка хафа чикмәгез әле, мистер Сайрес. Сал ясарбыз да, шуңа утырып чыгарбыз,— диде Пенкроф.

— Шулай да, ул Ерак Көнбатыш урманы белән бәйләнеш тоту өчен безгә барыбер елга аркылы күпер салырга туры киләчәк,— диде Гедеон Спилет.

— Исегез киткән икән! Мистер Смит инженер бит. Күпер кирәк дибез икән, төзеп бирер. Ә бүген кечкәсезне елга аркылы үзем чыгарам, бер тамчы су тимәс аягыгызга, сүз бирәм. Әле безнең бер көнгә җитәрлек азыгыбыз бар, юлда кош-корт кичәгедән ким очрамас дип өметләнергә мөмкин. Әйдәгез, кузгалдык!

Журналистның тәкъдимен Пенкроф та куәтләгәч, һәммәсе хуплады, чөнки Тырнак борынын урап узып, утрауны тулысынча күреп бетерәселәре һәм күңелләрендәге шик-шөбһәдән арынасылары килә иде. Юлга кичекмәстән чыгып китәргә кирәк иде, чөнки юл озын, кырык миль араны узасы бар. Юлчылар караңгы төш-

кәнче Гранит сарайга кайтып керәчәкләренә бик үк ышанып та бетмәделәр.

Иртәнге сәгать алтыда кечкенә бер төркем юлга кузгалып китте. Ике яки дүрт аяклы ерткычлар очраса дип, мылтыкларын корган килеш тоттылар. Алдан йөгергән Топка урман авызын күзәтә барырга әмер бирелде.

Елан койрыгына охшап бөгелгән борыннан башлап ярымутрауның яр буе монда дугасыман түгәрәкләнеп килә; юлчылар шул биш миль араны бик җентекләп карап узсалар да, берни тапмадылар: элек булсын, хәзер булсын баткан кораб калдыклары да, кайчандыр кешеләр яшәп, ташлап киткән урыннар да, учак көлләре дә, кеше эзләре дә очрамады.

Ниһаять, алар ярның төньяк-көнчыгышка таба борылган җиренә, Вашингтон бухтасы хасил итеп эчкә батып кергән турысына килеп җиттеләр. Аннан бөтен көньяк яр күренеп ята иде. Егерме биш миль ераклыкта иртәнге томанга төренгән Тырнак борыны шәйләнә — ул, әйтерсең, өскә күтәрелгән дә, җир белән күк арасында асылынып калгандай, күзне алдый. Бу төштән алып киң бухта беткәнчегә хәтле тип-тигез комлы яр сузылып бара, ярдан байтак эчкәре күгелҗемләнеп урман шәүләләнеп тора. Бухтадан соң яр буе телгәләнеп беткән, диңгез эченә таба комлыклар сузылып-сузылып кергән иде. Тырнак борынының иң очында исә киртләч-киртләч кыя таш каралып күренә.

Сәяхәтчеләр беренче тапкыр күргән бу яр күренеше әнә шундый иде, алар туктап байтак кына күзәтеп тордылар.

— Әгәр дулкын корабны бу ярга чыгарып ташлаган булса, мөгаен баткандыр инде ул. Диңгез эченә үк кереп торган сайлыклар, су астында кыя ташлар — ах, хәтәр дә соң! Әйе, бик хәвефле урыннар бу! — диде Пенкроф.

— Алай булган тәкъдирдә корабның берәр калдыгы табылыр иде! — диде журналист.

— Кыя ташлар тирәсендә булса, аның ватыклары сакланып калырга мөмкин әле, ә ком сайлыгына эләксә, йомычкасы да калмагандыр,— диде диңгезче.

— Нигә?

— Ком кыядан хәтәррәк, әкренләп аска суыра, аннары бөтенләй йота. Берничә йөз тонна сыешлы кораб комлыкта берничә көн эчендә юкка чыгарга мөмкин.

— Димәк, әгәр кораб комлыкка утырган булса, эз-

сез-нисез юкка чыгуы бер дә гаҗәп түгел? — диде инженер.

— Әйе, мистер Сайрес. Вакыт һәм давыл, мөгаен, аның эзен җуйгандыр. Шулай да ярда, диңгездән ерактарак, бер генә такта кисәге дә, мачта калдыгы да күренмәве бик гаҗәп.

— Барыбер, эзләүне дәвам итәбез! — диде инженер.

Төштән соң сәгать берләрдә сәяхәтчеләр Вашингтон бухтасының урталыгына җиттеләр, егерме миль юл артта калды.

Ашап алырга туктадылар.

Яр буйларының күренеше үзгәрде: алда әкәмәт рәвешле кыялар, су астыннан калкып торган ташлар тезелеп киткән; комлы сайлыклар инде юкка чыкты. Диңгез өсте әлегә тыныч, тик су чигенгәндә генә ташлар өскә калкадыр. Ак күбек белән өртелгән дулкыннар кыя ташларга салмак кына килеп бәреләләр дә чәчрәп кире чигенәләр. Тырнак борынына хәтле диңгез яры урман белән кыя-ташлар арасыннан тар гына булып кысылып бара.

Алга атлавы тагын кыенлашты: әледән-әле юлны бүлгән кыя җимерекләре очрый иде. Гранит кыялар тезмәсе биегәя башлады, урман һаман каядыр артка таба чигенде,— инде ямь-яшел агачларның очлары гына күренеп тора, алар тымызык һавада асылынып калгандай тоелалар иде.

Ярты сәгатьләп ял иткәч, юлчылар тагын алга киттеләр. Су кырыендагы кыя таш араларын, яр буеның һәр карышын җентекләп карый-карый бардылар. Шикле нәрсә күрсәләр, Пенкроф белән Наб, курыкмыйча, әллә кая хәтле барып аларны карыйлар иде. Ләкин кораб ватыклары дип алданган нәрсәләре һәрчак очлы кыя сыртлары булып чыга. Аның каравы яр буенда ашарга яраклы кабырчыклар тулып ятуын күрделәр. Аларны җыюдан әлегә мәгънә юк иде, Рәхмәт елгасы аша күпер салмыйча, йөк ташу өчен уңайлы җайланмалар эшләмичә, аларны алып кайтып булмаячак.

Димәк, монда да кораб батканлыгын расларлык эзләр табылмады. Әйтик, корабның каркасын яисә ватыксыныкларын дулкын ярга чыгарган булса, күрмичә калмаслар иде. Моннан әнә егерме миль алда табылган әрҗәне ерактан ук күреп алдылар бит әле.

Сайрес Смит һәм аның дуслары сәгать өчләргә кичерәк кенә бухтага килеп чыктылар. Аңа коючы бер

генә елга да күренми иде. Диңгез дулкыныннан ышыкланган тар гына табигый гавань иде бу, аңа су астыннан тырпаеп торган таш кыялар арасыннан кысылакысыла булса да керергә мөмкин иде. Бухта гүрендәге кыя җир тетрәгәндә ярылып киткән булса кирәк, аның сөзәк битләвеннән өстәге мәйданга менәргә унай икән ич. Тырнак борыныннан яр буйлап килгәндә ун миль ераклыктагы бу кыяны Күзәтү яссылыгыннан фәкать дүрт миль чамасы ара аерып тора иде.

Гедеон Спилет биредә тукталыш ясарга тәкъдим итте; ашау сәгате җитмәгән булса да, һәммәсенең карыны ачкан, берәр кисәк кош ите капкалап, хәл җыярга берсе дә каршы килмәде. Хәзер тамак ялгасалар, Гранит сарайга кайтып, кичкене ашаганчы түзәргә мөмкин.

Берничә минуттан сәяхәтчеләр искиткеч матур төз наратлар төбенә утырышып, Наб сумкадан чыгарган ризыкларны ашарга керештеләр.

Әлеге кыядагы мәйданчык, диңгез өсте тигезлегеннән илле-алтмыш фут биектә булып, моннан сәяхәтчеләргә Табылдык борынындагы кыялар артында зәңгәрләнеп яткан ерак Берләшү бухтасына хәтле барлык җирләр күренә, тик Котылу утравы белән Күзәтү яссылыгын гына утрауның төньяк өлешендә үскән биек агачлар каплыйлар иде.

Юлчылар хәзер дә иксез-чиксез ераклыкларга җәелгән океан суларында бер генә кораб та күрмәделәр; инженер зурайткыч трубадан офык буйларын нихәтле күзәтсә дә, ак җилкән күзенә чалынмады.

Башкалары да, ул озын трубаны алып, әле моңарчы тикшерелмәгән яр буйларына, тигез комлыкларга, су асты ташларына бик озаклап карап тордылар, әмма берәр баткан корабтан калган һични дә тапмадылар.

— Юк инде, берни тапмаячакбыз. Бездән башка Линкольн утравына хуҗа булуны дәгъва итәрлек беркем юк, моңа куанырга гына кирәк,— диде Гедеон Спилет.

— Теге ядрәне кая куясың? Ул хыялда тумаган бит, чын иде,— диде Герберт.

Пенкроф, сынган тешен хәтерләп:

— Валлаһи, чын иде ул! — дип куәтләде.

— Нинди нәтиҗәгә киләбез соң? — дип сорады журналист.

— Нәтиҗә менә болай: моннан өч ай чамасы элек билгесез кораб, үз ихтыяры беләнме яки ирексезләнме, монда тукталган булган,— диде инженер.

— Димәк, сез ул корабны эзсез-нисез юкка чыккан дип уйлыйсызмы? — дип сорады журналист.

— Юк, хөрмәтле Спилет, алай дип уйламыйм; әмма үзегез дә күреп торасыз: хәзергә без аны монда тапмадык...

— Алайса, әгәр мин сезне дөрес аңласам, кораб кире йөзеп киткән димәкче буласызмы? — диде Герберт.

— Әлбәттә!

— Һәм без илебезгә кайту мөмкинлегеннән бөтенләйгә колак какканбызмы?— диде Наб.

— Шулайдыр дип шикләнәм.

Гранит сарайны инде сагынып өлгергән Пенкроф:

— Мөмкинлек кулдан ычкынган икән; нихәл итмәк кирәк. Үкенүдән файда юк. Әйдәгез, кузгалыйк,— диде.

Ул урыныннан торырга да өлгермәде, кайдадыр Топның каты итеп өргәне ишетелде. Тиздән эт, авызына пычранып беткән чүпрәк кисәге кабып, урман эченнән чабып чыкты.

Наб эт авызыннан чүпрәкне тартып алды. Бу — калын киндер тукыма кисәге иде.

Топ сикерә-сикерә әсәренеп өрә, урманга таба чабып китә дә кире атылып килә, гүя ул хуҗасын үзе артыннан урманга барырга өнди иде.

— Ядрә серен ачарга ярдәм итәрдәй нәрсәдер бар ахрысы анда! — диде Пенкроф.

— Баткан корабтан котылып калган кеше мәллә? — дип кычкырып җибәрде Герберт.

— Бәлкем, ул яралыдыр? — диде Наб.

— Үлмәде микән? — дип сорады журналист.

Алар Топ артыннан стенадай куе булып үскән урман авызына таба киттеләр. Ул-бу була калса дип, алдан ук мылтыкларын кордылар.

Урман эченә бик ерак керсәләр дә, үкенечкә каршы, анда кеше эзләре очрамады. Куакларга, лианаларга кул тимәгән, кичәге Ерак Көнбатыш урманындагы кебек, ерып чыккысыз иде. Балта белән туктаусыз кизәнә-чаба сукмак салырга туры килде. Биредә кеше булгандыр дип уйга да китерерлек түгел иде. Хәлбуки, Топ бер алга чаба, бер кире килә, очраклы эзләрне иснәгән кебек түгел, ниндидер бер максатка омтылгандай кылана иде.

Җиде-сигез минут ашыгып килгәч тә, Топ туктады. Юлчылар биек агачлар уртасындагы бер аланга килеп чыкканнар икән. Ләкин куак араларын, агач төпләрен нихәтле караштырсалар да, берни күрмәделәр.

— Топ, нәрсә булды соң сиңа? — дип сорады аптыраган Сайрес Смит.

Топ гигант нарат төбендә сикергәли-сикергәли тагын да катырак өрергә тотынды.

Кинәт Пенкроф исе китеп кычкырып җибәрде:

— Менә сиңа кирәк булса! Менә әкәмәт!

— Нәрсә бар, нәрсә? —дип сорады Гедеон Спилет.

— Баткан корабның калдыкларын без диңгездән, яр буеннан эзлибез тагын!

— Эзләсәк соң?

— Ә ул һавада эленеп тора.

Диңгезче агач башында эленеп торган зур ак тукымага төртеп күрсәтте: Топ шуның җиргә өзелеп төшкән кисәген алып килгән булган күрәсең.

— Кораб ватыклары түгел бит бу,— диде Гедеон Спилет.

— Гафу ит...— диде Пенкроф.

— Бу безнең...

— Әйе шул, бу безнең һава шарының калдыгы, агач башына эләккән.

Пенкроф «ура» кычкырды:

— Вәт шәп тукымабыз булды! Ничәмә-ничә елларга күлмәк-ыштан тегәргә җитәчәк безгә! Кулъяулыклар да ясарбыз, күлмәкләр дә тегәрбез. Йә, мистер Сайрес, агач башында күлмәк үсә торган утрау турында ни диярсез икән?

Чынлап та, Линкольн утравы хуҗаларының бәхете басты: соңгы тапкыр талпынып очып киткән һава шары утрауга килеп төшкән һәм аны әнә үзләренә үк табу насыйп булды. Әгәр тагын һавага күтәрелеп сәяхәт кылырга уйласалар, һава шарын сакларга була яки берничә йөз аршын яхшы сыйфатлы киндер тукыманы юып, кер-маеннан арындырып, үз кирәкләренә кулланырга мөмкин бит. Шуңа күрә Пенкрофның шатлыгын һәммәсе дә уртаклаштылар.

Һава шарын агач башыннан алып төшәргә һәм ышанычлы җиргә яшереп куярга кирәк иде. Бик мәшәкатьле эш булып чыкты ул. Наб, Герберт һәм Пенкроф җитез генә нарат башына менеп киттеләр дә коточкыч зур аэростатны агач ботакларыннан ычкындырырга керештеләр.

Ике сәгать чамасы азаплана торгач, ниһаять, клапаны, пружиналары, җиз кисәкләре белән бергә шарның тышчасы гына түгел, бәлки җәтмәсе дә, ягъни баулары,

арканнары, кыршавы һәм якоре — барысы җиргә килеп төште.

Аскы клапан тирәсе ертылган булуын искә алмаганда, тышча әйбәт сакланган иде.

Чын мәгънәсендә күктән төшкән байлык булды бу.

— Мистер Сайрес, әгәр кайчан да булса без утрауны ташлап китәргә уйласак, һава шарына утырып китмәячәкбездер инде шәт, шулай бит? Һава кораблары син теләгән җиргә бармый икән ул, моны үз җилкәбездә татыдык инде! Карагыз әле, әйдәгез, егерме тонна сыешлы әйбәт судно төзибез. Сезнең рөхсәт белән, мин бу шәп киндердән фок һәм кливер җилкәннәре кисәм, калганыннан үзебезгә кием тегәрбез!

— Карарбыз әле, Пенкроф, карарбыз,— дип җавап бирде Сайрес Смит.

— Хәзер боларны ышанычлы урынга яшереп куярга кирәк,— диде Наб.

Чыннан да, бу хәтле авыр йөкне Гранит сарайга алып кайту турында уйлап та карыйсы түгел, киндер тышчаны, арканнарны, киергеләрне һ. б. төяп кайтыр өчен арба кирәк иде.

Ә хәзергә җил-яңгырдан сакларлык ышык урынга куеп калдыру хәерле булыр. Сәяхәтчеләр бердәм тотынып әйберләрне яр буена ташыдылар. Таш кыяда шактый тирән куыш, җил-яңгыр үтмәслек, диңгез дулкыннары килеп җитмәслек мәгарә табылды.

— Шкаф кирәк дидегезме, менә сезгә шкаф,— диде Пенкроф.— Бикләргә ишеге юк-югын, авызын томалап калдырсак, зыян итмәс. Ике аяклы караклар түгел, дүрт аяклылары шикләндерә!

Кичке сәгать алтыларга эшләрен бетергәч, бу тын бухтага *«Һава шары порты»* дип исем куштылар һәм Тырнак борынына таба юлларын дәвам иттеләр. Пенкроф белән инженер алдагы көннәрдә эшлисе эшләренең планын корып бардылар; иң беренче эш итеп, утрауның көньягы белән элемтә булдыру өчен, Рәхмәт елгасы аркылы күпер салырга кирәк булыр, аннары арба белән килеп аэростатны алып кайтырлар (көймә өчен ул авыр булачак). Һәм, әлбәттә инде, аларга палубалы судно төзиседер, аны Пенкроф үзе җиһазларга өметләнә; кораб әзер булгач, башта утрау әйләнә сәяхәткә чыгарга мөмкин, ә соңыннан...

Кич җитеп килә иде, кыйммәтле әрҗә табылган Табылдык борынына җиткәндә инде караңгы төшә башла-

ган иде. Баткан кораб калдыклары монда да очрамады; димәк, Сайрес Смитның фикере белән килешергә туры килә.

Табылдык борыныннан соң Гранит сарайга хәтле тагын дүрт миль араны узуы озак булмады. Сәяхәтчеләр диңгез яры буйлап кына Рәхмәт елгасы тамагына килеп җиттеләр. Елга яры белән агымга каршы менеп, беренче тугайга җиткәндә төн уртасы иде инде.

Елганың киңлеге бу төштә сиксән фут чамасы, аны йөзеп чыгуы кыен иде. Пенкроф аларны теге якка үзем чыгарам дип ышандырды ич, инде вәгъдәсен үтәргә тиеш.

Әйтергә кирәк, юлчыларыбыз тәмам йончыдылар, көне буе авыр юл узылды, һава шарын тапканнан бирле бөтенләй ял итәргә туры килмәде аларга. Һәрберсенең тизрәк Гранит сарайга кайтып җитәсе, ашап-эчеп, йокларга ятасы килә. Әгәр күпер салынган булса, чирек сәгатьтән инде өйдә булырлар иде.

Күзгә төртсәң күренмәслек караңгы төн. Пенкроф, вәгъдә иткәнчә, иптәшләрен Рәхмәт елгасы аша чыгарыр өчен сал ясарга тотынды. Наб белән икәүләп кулларына балта алып, сал өчен су кырыенда ук үскән ике агачны сайладылар да төбеннән чабарга керештеләр.

Сайрес Смит белән Гедеон Спилет кирәгебез чыкса-нитсә дип яр буенда көтеп утыралар, ә Герберт якынтирәдә йөренгәләп тора иде.

Агымга каршы барган җиреннән ул кинәт кире йөгереп килде дә елгага төртеп күрсәтә-күрсәтә:

— Карагыз әле, нәрсә ул тегендә? — диде.

Пенкроф, эшен ташлап, елга уртасыннан йөзеп килүче әйберне караңгыда чак шәйләп алды да:

— Көймә бит бу! — дип кычкырып та җибәрде.

Барысы да яр буена йөгереп килделәр һәм елганың югары ягыннан агым уңаена төшеп килүче көймәне күреп хәйран калдылар.

Пенкроф, диңгезчеләргә хас гадәтенчә:

— Әй, көймәдәгеләр! — дип кычкырды. Мондый чакта тыныңны чыгармау хәерле дигән уй башына да килмәде, күрәсең.

Җавап ишетелмәде. Көймә һаман якынлаша бирде. Унике адым чамасы каларак, диңгезче исе китеп кычкырып җибәрде:

— Безнең көймә ләбаса бу! Бәйләгән бавы өзелгәндер ахрысы, агым аны түбәнгә агызып алып төшкән. Кара син, иң кирәк чагында килеп җитүен әйт.

— Безнең көймәмени?..— дип үзалдына сөйләнде инженер.

Пенкрофның сүзе дөрес чыкты, аларның үз көймәсе иде бу. Бавы өзелгән дә елга буйлап түбәнгә агып төшкән! Елганың көчле агымы аны диңгезгә агызып китмәсен өчен, тизрәк тотып алырга кирәк иде. Наб белән Пенкроф озын колга белән оста гына тотып көймәне ярга таба китерделәр.

Көймә якын килгәч, инженер беренче булып аңа үзе сикереп менде дә бауны кулына алып капшап карады, чыннан да бау кыя ташка ышкылудан сусәреп өзелгән икән. Журналист аңа пышылдап кына әйтте:

— Бу очраклы хәл, минемчә...

— Үтә дә сәер хәл! — диде инженер.

Тегеләйме, болаймы, әмма аларның бәхете басты! Герберт, Наб һәм Пенкроф та үз чиратларында көймәгә утырдылар. Бауның ташка ышкылып үзеннән-үзе өзелгәненә алар шикләнмәделәр; әмма иң гаҗәбе шул: көймә нәкъ алар яр буенда чакта йөзеп килде бит, аны шундук тотып та алдылар, әгәр чирек сәгатькә генә соң килсә дә, ул диңгезгә үк агып киткән булыр иде.

Әгәр дә бу хәлләр җен-парияләргә ышанган элекке заманнарда булса, утрауда берәр изге рух яшидер, бәлагә тарыган бичараларга адым саен рәхим-шәфкатен шул күрсәтеп торадыр дип ышанырга мөмкин булыр иде.

Ишкәк белән бер-ике тапкыр колачлауга, елга тамагына килеп тә җиттеләр, Хәрабә турысында көймәне комга өстерәп чыгардылар. Һәм Гранит сарайның бау баскычына таба юнәлделәр.

Кинәт Топ ярсып-ярсып өрә башлады, ә баскычның түбәнге басмасын капмалап эзләп азапланган Наб аптырап кычкырып җибәрде...

Баскыч урынында юк иде.

Алтынчы бүлек

Пенкроф аваз сала.— Хәрабәдә төн куну.— Герберт ук ата.— Сайрес Смитның тәкъдиме.— Көтелмәгәндә чарасы табылды.— Гранит сарайданиләр булган? — Яңа хезмәтче

Сайрес Смит сүзсез калды. Иптәшләре исә баскычны җил очырмады микән дип як-яктан гранит стенаны куллары белән капшарга керештеләр. Тапмагач, әллә өзе-

леп төште микән дип, аяк астыннан эзләделәр. Әмма баскыч эзсез-нисез юкка чыккан иде. Бәлкем, көчле җил аны Гранит сарайның урталыктагы мәйданчыгына атып бәргәндер? Ләкин күзгә төртсәң күренмәслек караңгыда аны шәйләү мөмкин түгел иде.

— Берәрсе шаяртмады микән? — дип куйды Пенкроф.— Әгәр шаярткан булса, ахмаклык бу. Арып-талып юлдан кайткан кешеләр, баскыч тапмыйча, өйләренә керә алмасыннар имеш! Арган кешедә нинди көлү кайгысы булсын ди.

Наб, нишләргә белми, аһ та ух килде.

— Бүген җил булмады бит! — диде Герберт.

Пенкроф үзалдына сукрана бирде:

— Линкольн утравында гаҗәп сәер хәлләр була башлады бит әле!

— Гаҗәп сәер хәлләр дисеңме? Нигә гаҗәп булсын, бик табигый хәл бит, Пенкроф. Без өйдә югында кемдер берәү килгән дә, Гранит сарайга менеп, баскычны өскә тартып алган,— диде журналист.

— Кемдер берәү дисеңме! Ә кем булыр икән соң ул? — диде Пенкроф борчылып.

— Әйтик, дуңгыз баласын җәрәхәтләгән аучы,— диде журналист.— Әгәр ул булса, барысы өчен җавап тотарга мәҗбүр итәрбез әле без аны.

Пенкроф сабырын җуйды, сүгенеп җибәрде.

— Әгәр өстә берәрсе булса, хәзер тавышын ишетербез без аның.

Ул, югарыга карап, күк күкрәгән тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Әй, кем бар анда!

Җавап урынына катлы-катлы кайтаваз гына әйләнеп килде.

Сәяхәтчеләр сагаеп колак салдылар: югарыда кемдер хахылдап көлгән кебек тоелды, тик кем икәне аңлашылмады. Пенкроф янә бер тапкыр кычкырып карады.

Бу вакыйга утрау хуҗаларын гына түгел, хәтта чит кешеләрне дә аптырашка салырлык иде. Алар болай да һәр вак-төяктән мәгънә эзләргә генә торалар иде инде, әмма утрауда җиде ай яшәү дәверендә бу хәтле дә гаҗәп хәлнең булганы юк иде әле.

Кыскасы, утрау кешеләре, арганлыкларын да онытып, Гранит сарай төбендә ни уйларга да, ни кылырга да белмичә басып тора бирделәр. Бер-берсенә сорау яудырдылар, сораулары җавапсыз калды; берсеннән-берсе

ятышсызрак фаразлар уйлап таптылар. Өмете алданган Наб кухняга керә алмавына борчыла иде. Юлга дип алган ризыклары да бетте җитмәсә, ашатырга нәрсә табыйм инде дип пошына иде ул.

— Дусларым, безгә фәкать бер генә чара калды хәзер: иртәгә хәтле көтәргә туры килә, аннары, мондагы хәлләргә карап, нишләргә икәнен уйлашырбыз,— диде Сайрес Смит.— Ә хәзер, әйдәгез, Хәрабәгә киттек. Төнне шунда кунарбыз. Кичкене ашарга туры килмәсә дә, ичмасам тынычлап йокларбыз.

Пенкроф һич үзенә урын таба алмады.

— Нинди оятсыз бәндә шулай явыз рәвештә шаярта икән соң? — дип һаман сукранды.

Шаяртучы «оятсыз»ы кем генә булмасын,— сәяхәтчеләрнең, Сайрес Смит киңәшенә күнеп, Хәрабәгә барудан һәм иртән таң атуын көтүдән башка чарасы калмаган иде. Андый-мондый хәл булса дип, Топка Гранит сарай төбендә сакта торырга әмер бирелде, ә Топ исә әмерне җиренә җиткереп үтәргә һәрвакыт әзер иде. Шулай итеп, тугры эт гранит стена төбендә каравылда калды, ә хуҗалары исә якындагы таш кыя куышына кереп сыенырга мәҗбүр булдылар.

Әгәр дә без укучыларга әйтсәк: сәяхәтчеләр, арыган-талчыккан булуга карамастан, Хәрабәнең ком идәнендә рәхәтләнеп йокы туйдырдылар дисәк, хакыйкатьне тупас рәвештә бозган булыр идек. Аларның тормышында тагын ниндидер мөһим хәл булган, шуны төшенгәнгә күрә күңелләре тыныч түгел иде. Табигатьнең сукыр көче аркасында килеп чыккан очраклы хәл микән бу? Әллә кеше тарафыннан эшләнгән берәр әшәкелекме? Болар тик иртәгә генә билгеле булачак. Җитмәсә җир идәндә ятуы бик җайсыз иде. Тик тегеләйме-болаймы, аларның торагын кемдер үзләштергән, анда кереп ятып булмый иде хәзергә.

Өстәвенә Гранит сарай торак кына да түгел, барлык мал-мөлкәтләре саклана торган склад та иде бит. Мылтыклары, эш кораллары, приборлар, сугыш кирәк-яраклары, киләчәк өчен азык-төлекләре шунда саклана иде. Әгәр шуларның барысын урлаган булсалар, безнең бичараларга үз хуҗалыкларын тагын өр-яңадан торгызырга туры киләчәк, сугыш коралларын да, инструментларны да яңадан ясарга тиеш булачаклар. Әллә асат эшме бу? Бик борчылганга күрә, бу төндә аларга йокы кермәде; әле берсе, әле икенчесе куыштан тышка чыгып йөренде,

Топ Гранит сарайны әйбәт саклый микән дип тикшерделәр. Ни булганын төшенергә тырышып башын ватса да, фәкать Сайрес Смит кына тыштан тыныч күренә, үзенә хас салкын канлылык белән таң атуын көтә иде. Аларны әйләнә-тирәдә нindидер гайре табигый көчләр сагалый бугай дигән фикергә килде ул; тик аның ни икәнен әлегә төшенеп кенә җитми, шуңа күрә үз-үзенә ачуы килә иде. Гедеон Спилет та аның белән бер фикердә диярлек, алар бу сәер хәлләр каршында чарасызлыкларына аптырап аулакта бу турыда пышылдап кына сөйләшкәләп алалар иде. Шик юк ки, утрауда нindидер яшерен сер бар, тик ул сернең эзенә ничек төшәргә соң? Герберт та бу хәлне нәрсәгә юрарга белмичә аптырады, Сайрес Смиттан сорашасы килсә дә, якын барырга кыймады. Наб исә үзен тулысы белән хуҗасына тапшырган; мин үзем нишли алам, хуҗам берәр чарасын табар әле дип үзен юата иде. Әгәр дә әдәпсезлеге белән иптәшләренең хәтерен калдырудан шикләнмәсә, ул төнлә Гранит сарайдагы кебек рәхәтләнеп тынычлап йоклар да иде.

Ә Пенкроф тәмам чыгырыннан чыкты:

— Һе, тапканнар бит шаяртыр чак! Кем шулай бездән көлә икән соң? Яратмыйм мин аның эше көлкеләрне! Кулыма гына эләксен, күрсәтермен әле мин ул мәзәкчегә күрмәгәнен!

Таң сызылу белән утрау хуҗалары, кирәкле коралларын алып, гранит стена төбенә киттеләр. Гранит сарай алды көнчыгышка карый иде, кояш чыгуга, аның беренче нурлары Гранит сарайның стенасын яктырта.

Чыннан да, сәгать биш тулганчы ук кояшның беренче нурлары Гранит сарайның яшел үсемлекләргә төренгән тәрәзә капкачларына төште.

Анда үзгәреш сизелмәгән кебек иде, кинәт утрау хуҗалары ирексездән «аһ!» итеп кычкырып җибәрделәр: киткән чакта ныгытып ябып киткән ишек хәзер шыр ачык иде.

Шик юк ки, Гранит сарайга кемнәрдер кергән. Баскычның ишектән алып урталыктагы мәйданчыкка хәтле төшә торган өске өлеше үз урынында асылынып тора, ә түбәнге өлешен кемдер бусагага ук тартып менгезеп куйган. Өйгә басып кергән кешеләр көтелмәгән хәлләрдән саклану өчен шулай баскычны җыеп куйганнар булса кирәк.

Чакырылмаган кунаклар кемнәр икән, алар анда

ничәү — боларын әлегә белеп булмый, бусагада берәү дә күренми иде.

Пенкроф янәдән аларга кычкырып дәшеп карады. Ләкин җавап бирүче булмады.

— Кабахәтләр! Үз өйләрендәмени, шушы вакытка хәтле йоклап яткан булалар бит. Әй, әдәм актыклары, юлбасарлар, пиратлар, корсарлар, Джон Буль койрыклары! — дип кычкырды диңгезче.

Чын америкалы буларак, Пенкроф кемнедер «Джон Буль койрыгы» дип сүккән икән, димәк, бик яман ачуы чыккан һәм үтергеч итеп хурларга теләгән диган сүз.

Кояш чыгып җитүгә, Гранит сарайның алгы ягы ялт итеп яктырып күренә башлады. Тик ни эчтә, ни тышта шылт иткән тавыш та ишетелмәде, тирә-як тып-тын иде.

Утрау хуҗаларының күңеленә шик керә башлады, әллә Гранит сарайда берәү дә юк микән соң? Хәер, шикләнергә урын калмаган, әнә бит кемдер баскычны югарыга күтәреп куйган, димәк, кем булуына карамастан, чакырылмаган кунаклар әле һаман эчтә, алар беркая кача алма аннар. Ничек итеп менәргә соң анда? Гербертның башына бер фикер килде. ишек тупсасыннан асылынып торган баскычның аскы аратасына җәядән ук атарга кирәк, ә ук койрыгына нәзек бау тагарбыз дип киңәш итте ул. Аннары әкрен генә баудан тартып баскычны җиргә т шерергә мөмкин, диде.

Шуннан башка чара юк иде. Оста ата алсаң, максатыңа ирешергә мөмкин иде. Бәхетләреннән, ук җәяләр Хәрабәнең бер почмагында саклана иде, шунда ук үсемлек сүсеннән үргән берничә колач нәзек бау да табылды. Пенкроф бауны сүтеп, аны ук койрыгына такты. Герберт укны баскычның асылынып торган башына әйбәтләп төзәде дә җәя керешен тартып җибәрде.

Сайрес Смит, Гедеон Спилет, Пенкроф һәм Наб, арткарак чигенеп, күзләрен Гранит сарайның тәрәзәләренә юнәлттеләр. Журналист карабинын иңбашына терәп, көпшәсен ишеккә төбәде.

Ук, үз артыннан бауны ияртеп, сызгырып очып менеп китте дә, баскычның соңгы ике аратасы уртасыннан узып, аска килеп төште.

Эш уңды.

Герберт бауның җирдәге очын кулына алды, баскычны сөйрәп төшерергә теләп аска тартырга тотынган иде, шулчак ишек уемыннан ниндидер кул ялт кына сузылды да баскычны эчкә тартып алды.

— Ах, оятсыз хайван! Әле маңгаеңа пуля кирәкме, кәзер алырсың син аны,— дип ачынып кычкырды Пенкроф.

— Кем соң ул? — диде Наб.

— Нигә, күрми калдыңмыни?

— Юк.

— Маймыл иде бит, макака, сапажу, мартышка, орангутанг, бабуин, горилла, сагуин! Без югында баскычтан менеп безнең торакны маймыллар яулап алган.

Гүя диңгезченең сүзләрен раслар өчен, нәкъ шул мәлдә тәрәзә капкачлары ачылып китте дә, тәрәзәдә өч-дүрт маймыл күренде. Алар, өйнең чын хуҗаларын сәламләргә теләгәндәй, төрлечә кыландылар, йөзләрен чыттылар.

— Әйткән идем бит мин сезгә, кемдер шаяртткан дип. Менә мәзәкчеләрнең берсе һәммәсе өчен үз башы белән түләсен инде,— диде диңгезче. Мылтыгын иңсәсенә терәде дә, тиз генә төзәп атып җибәрде. Маймыллар качышып беттеләр, ә берсе, үлем җәрәхәте алып, комлы ярга егылып төште.

Шик юк ки, дүрткуллылар арасында беренче урында торучы зур маймыл иде бу. Тик анын кайсы төргә керүен: шимпанземы, орангутангмы, горилламы яки гиббонмы икәнен генә белмәделәр. Кешегә охшаганлыгын искә алып, кешесыман маймыллар төренә керүен генә әйтергә була иде. Герберт аны орангутанг диде, зоологиядән мәгълүматлы егет әйткәч, дөрестер инде.

— Нинди шәп маймыл! — диде Наб сокланып.

— Шәбен шәптер, ләкин өйгә керә алмыйбыз бит әле менә; берәр җай табабызмы-юкмы — белгән юк,— диде ризасызлык белән Пенкроф.

— Герберт төз ата,— диде журналист.— Җаясе бар!.. Тагын берәр тапкыр сынап караса...

— Ярый алайса, әйдә, сынасын! Әмма маймыллар бик хәйләкәр бит алар! Тәрәзә янына бүтән якын килмәсләр инде. Аларны атып бетерә алмабыз без. Бүлмәләрдә, чоланнарда ниләр кыланганын күз алдына китерсәм, уф...

— Сабыр итәргә кирәк, Пенкроф,— диде Сайрес Смит.— Маймыллар безне озак җәфалый алмас.

— Кайчан һәммәсе җиргә төшеп бетсә, шунда гына тынычлык табармын,— диде диңгезче.— Шулай да, мистер Сайрес, бу мәзәкчеләр анда ничәүләп бар икән, сез ничек уйлыйсыз?

Пенкрофның соравына җавап бирүе кыен иде. Герберт хәзер теләсә дә баскычның аскы аратасына угын тидерә алмый, чөнки баскычның очын ишектән эчкә күтәреп куйдылар; ул бауны тартып караган иде, өзелеп кенә чыкты, баскыч урынында торып калды.

Дусларыбызның хәле мөшкел иде. Пенкроф моны күреп тәмам чыгырдан чыкты. Вакыйганең үзенә күрә көлке ягы булса да, Пенкрофның хәле көлүдән узган иде шул. Алар иртәме-соңмы барыбер Гранит сарайга керәчәкләренә, маймылларны куып чыгарачакларына шикләнмиләр шикләнүен, тик кайчан, ничек итеп анда керергә икәнен әлегә берсе дә күз алдына китерә алмый иде.

Ике сәгатьләп вакыт үтте, ә маймыллар һаман качып утыралар, чыкмыйлар. Йә тәрәзәдән, йә ишектән берәрсенең кулы яки бите күренүгә, мылтык тавышы яңгырый һәм тегеләр шундук юк булалар.

— Әйдәгез, берәр җиргә ышыкланып торабыз,— дип киңәш итте инженер.— Безне китте дип белеп, чыкмаслар микән. Герберт белән Спилет кыя артына посарлар да, күренгән бер маймылны атып торырлар.

Инженерның тәкъдименә һәммәсе күнде. Оста мәргәннәр — журналист белән Герберт — маймылларга күренмәслек итеп кыя арасына җайлап урнаштылар, ул арада Наб, Пенкроф һәм Сайрес Смит, Күзәтү яссылыгына менеп, урманга кош-корт ауларга киттеләр: чөнки иртәнге аш вакыты җиткән, ә аларның ашарына берни юк иде.

Ярты сәгатьтән аучылар берничә кыя күгәрчене атып алып кайттылар. Учак ягып, аларны тиз генә кыздырып алдылар да тамак ялгадылар. Ә өйдән маймыллар һаман күренмәде.

Топны сакта калдырып, Спилет белән Герберт та ашап алырга дип киттеләр. Аннары элек поскан урыннарына кире әйләнеп килделәр.

Тагын ике сәгатьләп вакыт бертөрле үзгәрешсез үтте. Дүрткуллылар һичбер тереклек галәмәте күрсәтмәделәр, аларны качып киткән дип уйларга мөмкин иде. Дөресрәге, мылтык гөрселдәгән тавыштан, араларыннан берсенең һәлак булуыннан котлары очкан маймыллар Гранит сарайның берәр аулак почмагына, бәлки чоланга ук кереп качканнардыр.

Чоландагы азык-төлек, әйбер-сәйберләрне күз алдына китергәч, барысының да түземе төкәнде, инженерның

сабыр булыгыз дип үгетләве дә ярдәм итмәде; дөресен әйткәндә, аларның борчылуына нигез юк түгел иде.

Журналист сукранып алды:

— Бигрәк ахмак хәлгә төштек без! Моның очы да, кырые да күренми!

Пенкроф ачудан кычкырып ук җибәрде:

— Сыптырып чыгарырга вакыт бу кабахәтләрне! Әллә егерме маймылга көчебез җитмәсме! Сугышырга чыксыннар гына! Алар янына менәргә берәр чарасы юкмыни соң?

Инженер да шул турыда уйланган күрәсең:

— Бар бер чара,— диде.

— Бер чара? Бүтәне булмагач, анысы да ярый. Нинди чара соң ул?

— Гранит сарайга күлнең иске су юлыннан төшеп карарга кирәк,— диде инженер.

— Фу, иблис кавеме! Минем башыма ничек килмәде соң бу фикер! — дип кычкырып җибәрде диңгезче.

Чыннан да, Гранит сарайга шул юлдан кереп, маймыллар көтүен куып чыгарырга мөмкин бит. Дөрес, күл ярындагы элекке су аккан тишекне таш белән томалап, сылап катырганнар иде катыруын. Хәзер шуны җимерергә туры килә: җимерми хәл юк, соңыннан тагын томалап куярлар әле. Бәхеткә каршы, Сайрес Смит теге чактагы ниятен тормышка ашырып өлгермәгән иде әле, югыйсә, ул күл суын күтәреп, тишекне су астында калдырырга исәпләгән иде бит. Ул чагында байтак азапланырга туры килгән булыр иде.

Төш авышкан иде инде. Утрау хуҗалары, Хәрабәдән кирәк-китмәннәр алып, Топны Гранит сарай төбендә каравылга куйдылар да Рәхмәт елгасының сул яры буйлап Күзәтү яссылыгына таба юнәлделәр.

Илле адымлап та китеп өлгермәгәннәрдер, этнең абалап-абалап өргән тавышы ишетелде. Топ аларны ярдәмгә чакыра иде бугай.

Алар туктап калдылар.

— Әйдәгез, йөгердек,— диде Пенкроф.

Һәм барысы да киредән артка йөгерделәр. Гранит стенаның чатыннан борылуга, андагы хәлләрнең үзгәргән булуын күрделәр.

Чыннан да, нәрсәдәндер котлары очкан маймыллар күзләренә ак-кара күренмичә Гранит сарайдан чыгып качарга азапланалар иде. Ике-өч маймыл җитез клоуннарча әле бер тәрәзәгә, әле икенче тәрәзәгә атылалар: кур-

кудан баскычны төшерергә кирәген дә оныткаппар ахрысы, качарга асатрак булыр иде югыйсә. Утрау хуҗалары, мылтыкларын ашыкмыйча гына төзеп, маймылларга атып җибәрделәр. Җәрәхәтләнгән биш-алты маймыл ачыргаланып кычкырып эчкә авып төште. Калганнары тышкы якка сикереп, ташка егылып һәлак булдылар. Берничә минуттан Гранит сарай эчендә бер генә исән җанвар да калмады бугай.

— Ура! Ура! — дип кычкырды Пенкроф.

— Ура! кычкырырга иртәрәк әле! — диде Гедеон Спилет.

— Нигә? Һәммәсе кырылып бетте бит.

— Анысы хак. Тик өйгә ничек керәбез соң?

— Әйдәгез, иске су юлына! — диде Пенкроф.

— Шунда бармый да хәл юк болай булгач,— диде инженер.— Тик ин әйбәте...— Сайрес Смит сүзен төгәлләргә өлгермәде, аңа җавап иткәндәй, сарай ишегеннән баскыч шуып чыкты да сүтелеп аска очты.

— Төрепкәм белән ант итәм! Вәт шәп булды! — диде диңгезче Сайрес Смитка карап.

— Шәпнең дә аргы ягында түгел микән? — дип сөйләнде Сайрес Смит, баскычтан беренче булып үзе ашыгып менеп китте.

— Сак бул, мистер Сайрес! Маймыллар калмагае...— диде диңгезче.

Инженер тукталып тормады.

— Күрербез,— диде.

Иптәшләре дә аның артыннан баскычтан үрмәләделәр, берничә минуттан ишек төбенә менеп тә җиттеләр.

Бөтен өй эчен бетереп эзләсәләр дә, беркем табылмады. Бүлмәләр дә, чолан да буш иде. Дүрткуллылар өйнең эчен хәйран туздырганнар.

— Ә баскыч? Аны безгә кайсы әфәндесе ыргытты соң? — диде диңгезче аптырап.

Шул вакыт ниндидер тавыш ишетелде, коридорда посып калган олы гәүдәле бер маймыл залга атылып керде, аның артыннан Наб куа икән.

— Ах, юлбасар! — дип кычкырып җибәрде Пенкроф. Ул балтасы белән кизәнеп маймылнын башын ярмакчы иде, Сайрес Смит аның кулыннан тотып калды.

— Пенкроф, тимә, кызган маймылны! — диде.

— Ул кара йөзне җәлләп торыйммы тагын!

— Безгә баскычны ул ташлады бит,— диде инженер, ничектер сәеррәк тавыш белән, аның әллә чын, әллә юри әйтүен белүе кыен иде.

Барысы маймылга ябырылдылар, ярсып-ярсып карышуына карамастан, аны җиргә егып салдылар һәм бәйләп ташладылар.

— Уф,— дип авыр сулап куйды Пенкроф.— Нишләтәбез инде моны?

— Хезмәтчелеккә алабыз,— диде Герберт.

Егет шаяртмый иде, акыллы маймылларның кешегә зур ярдәмче икәнлеген ул белә иде.

Аның сүзеннән соң барысы да маймыл янына җыелдылар, аны җентекләп карарга керештеләр. Ул кешесыман маймыллар токымыннан иде, йөз авышлыгы австралиялеләрнекеннән һәм готтентотларныкыннан бик аз аерыла. Орангутанг иде ахрысы. Орангутанглар исә бабуиннар кебек явыз, макакалар кебек ахмак, сагуиннар кебек пычрак, маголар кебек кыбырсык, павианнар кебек бозык түгел. Кешесыман маймылларның бу төренә керүчеләрнең сыйфатлары аларда кеше акылы бар дигәнне раслый яза иде: кулга ияләштерелгән орангутанглар табын янында хезмәт күрсәтә алалар; өй җыештыралар, кием-салым, аяк киемнәрен чистарталар, пычак, кашык, чәнечке куллана беләләр, хәтта аракы да эчәләр... Ике аяклы хезмәтчеләрдән бер дә ким җирләре юк. Мәгълүм ки, Бюффонның шундый акыллы орангутангы булган, аңа тугрылыклы хезмәт иткән.

Аягы-кулы бәйләнгән килеш Гранит сарай идәнендә яткан бу орангутанг пәһлевандай зур гәүдәле иде; буе алты фут чамасы булып, килеш-килбәте дә ярыйсы, күкрәге киң, башы таманча, йөз авышлыгы алтмыш биш градуска тиң, баш сөяге түгәрәк, борыны шактый зур, тәнен елкылдап торган йомшак төк каплаган,— кыскасы, кешесыман маймылларның күркәм бер вәкиле иде бу. Күзе кешенекеннән аз гына кечерәк, күз карашы акыллы, тешләре ап-ак, мыегы һәм кечерәк кенә сакалы коңгырт төстә иде.

— Ай-һай чибәр егет бу! — диде Пенкроф.— Телен белсәң, гәпләшергә ярар иде моның белән!

— Ул безгә хезмәт итәр дисеңме? Чынмы бу сүз, хуҗам?

Инженер көлеп җибәрде:

— Әйе, Наб, чын. Тик син көнләшмә тагын!

— Әйбәт хезмәтче булырга тиеш бу,— диде Гер-

берт.— Әле яшь күренә, өйрәтүе кыен булмас. Гадәттә аларны кыйнап өйрәтәләр, казык тешен суыралар. Без алай итмәбез дип уйлыйм. Хуҗасы яхшы булса, ул тиз ияләшергә тиеш.

Пенкроф «мәзәкчедән» үч алырга җыенганын оныткан да инде.

— Без яхшылык белән генә өйрәтергә тырышырбыз,— дип орангутанг янына килде дә:

— Нихәл, дускай? — дип сүз кушты.

Орангутанг җавап итеп әкрен генә мырылдап куйды, тик тавышы ачулы түгел иде.

— Син безнең гаиләнең әгъзасы булмакчымыни инде, әйеме? Сайрес Смит әфәндегә хезмәт итмәкче буласыңмы, шулаймы?

Аның сүзен җөпләгәндәй, маймылның мырылдавы ишетелде.

— Хезмәт хакы — тамак ялы дисеңме?

Өченче тапкыр мырылдап гүя үзенең ризалыгын белдерде маймыл.

— Телгә бераз ярлырак икән ярлысын,— дигән булды Гедеон Спилет.

— Анысы яхшы да әле. Хезмәтченең аз сөйләгәне хәерле,— диде Пенкроф.— Аннары ул хезмәт хакы да сорамый! Әй, дускай, ишетәсеңме? Әлегә сиңа хезмәт хакы билгеләмибез, әгәр безне канәгатьләндерсәң, киләчәктә икеләтә алырсың! Ярыймы!

Шулай итеп утрауда тагын бер җан иясе артты һәм соңыннан ул утрау хуҗаларына бик күп хезмәт күрсәтте. Диңгезченең үтенечен искә алып, кайчандыр ул белгән Юпитер исемле маймыл хөрмәтенә орангутангка кыскартып Юп дип ат куштылар.

Һәм тантана-мазарларсыз гына Юп абзый Гранит сарайда урнашып калды.

Җиденче бүлек

Кичектергесез эшләр.— Рәхмәт елгасы аркылы күпер.— Күзәтү яссылыгы утрауга әвереләчәк.— Күтәрелмә күпер.— Уңышны урып-җыю.— Чишмә.— Кечкенә күперләр.— Кош-корт кетәге.— Күгәрчен оясы.— Онагрлар.— Ат җигү...— Һава шары портына бару

Линкольн утравы хуҗалары үз торакларын маймыллардан кире кайтарып алдылар. Моның өчен иске су юлын ачарга туры килмәде. Эшкә керешергә генә тор-

ганда, аларның бәхетеннән, маймыллар көтүе нәрсәдәндер өркеп, шашынып Гранит сарайны ташлап чыктылар. Бәлкем, алар икенче яктан үзләренә һөҗүм булачагын сизгәннәрдер? Күзләренә ак-кара күренмичә качулары шуңа булгандыр.

Кич җиткәнче кешеләр маймылларның мәетләрен урманга илтеп күмделәр. Торакларын җыештырып чыгардылар: чакырылмаган кунаклар өйнең астын-өскә китерсәләр дә, бер әйберне дә ватмаганнар иде. Наб плитәне кабызып җибәрде, чоланда булган азык-төлектән тәмле итеп ашарга әзерләде, аны һәммәсе мактый-мактый ашадылар.

Юпны да онытмадылар, эрбет чикләвеге һәм тамыразыклар белән туйганчы сыйладылар. Пенкроф аның кулларын чишеп җибәрде, ә аякларын тәмам ияләшкәнче чишми торырга булдылар.

Йоклар алдыннан Сайрес Смит һәм аның иптәшләре, өстәл әйләнәсенә утырышып, тиз арада эшләнәсе эшләр турында киңәшергә керештеләр.

Кичекмәстән эшләнергә тиешле иң мөһим эш — Гранит сарай белән утрауның көньягы арасында элемтә урнаштыру һәм моның өчен Рәхмәт елгасы аркылы күпер салу иде. Аннары киләчәктә кулга ияләштереләчәк муфлоннар һәм башка терлекләр өчен мал утары төзү иде.

Әгәр дә шушы ике бурычны тормышка ашырсалар, хәзерге көндә иң мөһим мәсьәлә булган кием-салым мәсьәләсе хәл ителәчәк. Чыннан да, күпер булса, һава шары тышчасын алып кайтырлар, аның тукымасыннан кием-салым тегәрләр иде; ә утарда муфлоннар асрап, аларның йонынннан кышкы кием әзерләргә мөмкин булыр иде.

Сайрес Смит мал утарын Кызыл инеш чыганагы гирәсенә корырга исәпли иде, чөнки анда тау битләре сусыл, мул үләнле көтүлекләргә бай. Күзәтү яссылыгыннан Кызыл инеш чыганагына таба юл салынган дисән дә була; әгәр җигәргә яраклы берәр терлек тота алсалар, уңайлы арба ясарлар һәм анда барып йөрүләре асатлашыр иде.

Мал утарын Гранит сарайдан еракка салу әле мөмкин булса да, кош-корт кетәген еракка куярга ярамый иде. Чөнки пешекчегә кош-кортның кул астында булуы уңай, диде Наб. Шуңа күрә кош кетәген күл буена, иске су юлы тирәсенә корырга кирәк дигән фикергә килделәр.

Су кошлары күлдә иректә генә дә үрчи ала. Соңгы сәяхәттән тотып алып кайткан яшерен койрыклы бер пар кошны, кулга ияләштереп, тәҗрибә ясап карарга булдылар.

3 нче ноябрьдә иртән яңа эшләрне башларга тиешләр иде. Күпер салу иң җаваплы эш булганга, аңа барысы да катнашырга тырышты. Иңбашларына балта-пычкы күтәргән, кулларына чүкеч-келәшчә тоткан балта осталары елга буена юнәлделәр.

Пенкроф шикләнеп әйтә куйды:

— Әгәр без югында Юп абзый кичә үзе ташлаган баскычны югары күтәреп куярга уйласа, нишләрбез?

Сайрес Смит җавабын тиз тапты:

— Баскычның түбәнге башын җиргә беркетеп калдырыйк,— дип киңәш итте.

Алар җиргә тирән итеп казык кактылар да баскычны шуңа ныгытып бәйләп куйдылар. Аннары Рәхмәт елгасының сул як яры буйлап беренче тугайга хәтле мендeләр.

Туктап, күпер кору өчен урын эзләп, яр буйларын карарга керештеләр. Күпер кору өчен бу урын уңайлы табылды.

Чыннан да, кичә утрауның төньяк ярында табылган һава шары порты моннан өч миль ярым гына ераклыкта иде: күпер белән порт арасына арба юлы салу кыен булмаячак, ул юл утрауның төньягын Гранит сарай белән тоташтырачак.

Сайрес Смит күптәннән күңелендә йөрткән бер уен иптәшләренә сөйләп бирде: ул Күзәтү яссылыгын ике аяклы һәм дүрт куллы дошманнар һөҗүменнән саклау өчен тирә-яктан су белән аерып алу кирәклеген исбатлады. Бу планны гамәлгә ашырсаң,— ә аны гамәлгә ашыру әллә ни кыен түгел иде,— аларга зур файда китерәчәк: Гранит сарай, Хәрабә, кош-корт кетәге һәм Күзәтү яссылыгының булачак иген-басулары ерткычлар һөҗүменнән азат ителәчәк.

Инженер бу ниятен түбәндәгечә тормышка ашырмакчы була:

Күзәтү яссылыгы хәзер өч яктан су эчендә утыра: күл һәм ике елга (берсе — табигый, икенчесе — ясалма елга) уртасында.

Төньяк-көнбатыштан аны Грант күле чикли, ул элекке су юлыннан алып көнчыгыш ярдагы артык суны агызу өчен уелган канауга хәтле җәелгән.

Яссылыкның төньягындагы әлеге канаудан диңгезгә шарлавык агып төшә; шарлавык суы Гранит стена битеннән түбәнгә омтылып, комлы ярны кисеп, диңгезгә барып җитә. Шушы ясалма тау елгасын буеннан-буена тирәнәйтсәң, ерткыч җанварлар кичеп чыга алмаячак.

Күзәтү яссылыгының көнчыгышын Шарлавык тамагы белән Рәхмәт елгасы тамагына хәтле арада диңгез саклый.

Ниһаять, яссылыкны көньяктан Рәхмәт елгасының түбәнге агымы, ягъни елга тамагыннан алып беренче тугайга кадәрге өлеше бүлеп тора.

Шулай итеп, яссылыкның фәкать көнбатыш ягы, ягъни Рәхмәт елгасының тугаеннан алып Грант күленә хәтле булган аралык кына ачык кала; аның озынлыгы бер миль чамасы булып, аннан теләсә нинди дошман һөҗүм итә ала иде. Әнә шул урынга киң итеп тирән канау казырга һәм күл суын кертергә туры киләчәк, нәтиҗәдә күл суыннан канал аша Рәхмәт елгасына таба икенче юл ачыла. Моннан соң күл бераз саегыр саегуын, әмма Сайрес Смитның исәбенчә, Кызыл инеш суы күлгә җитәрлек күләмдә өстәлеп торачак.

— Бу үзгәрешләрдән соң Күзәтү яссылыгы төрле яклап су уртасында калачак һәм чын утрауга әвереләчәк,— диде инженер.— Башка биләмәләребез белән элемтә өчен күперләр салырбыз: бер күперне Рәхмәт елгасына төзербез; ике кечкенә күперебез инде электән бар: берсе — шарлавыкның башланган җирендә, икенчесе аның диңгезгә койган турысында һәм, ниһаять, киләчәктә тагын ике кечкенә күпер салырга кирәк булыр: берсен — казылачак канауга, икенчесен — Рәхмәт елгасына. Әгәр күперләрнең зурысын да, кечкенәләрен дә күтәреп куела торган итеп тә төзесәк, ул чакта Күзәтү яссылыгына һич кем бәреп керә алмаячак.

Сайрес Смит үз планын иптәшләренә яхшырак аңлатыр өчен Күзәтү яссылыгының картасын сызып күрсәтте, һәм иптәшләре, аның ниятен аңлап, үзләренең дә аны бердәм хуплауларын әйттеләр, ә Пенкроф балтасын селкеп:

— Күпер салабыз! — диде.

Кичекмәстән эшкә тотындылар. Күпергә кирәкле агачларны сайлап, кисеп аудардылар, ботакларын ботадылар, баганалыклар, өрлекләр кистеләр, такта ярдылар. Күпернең бер башы Рәхмәт елгасының уң як ярына беркетелергә тиеш, ә икенче башы, фәнчә әйткәндә, каршы

авырлыклар үзлегенә нигезләнеп төзелгән шлюз капкалары кебек күтәрелә торган булырга тиеш иде.

Күпер салуы, әлбәттә, катлаулы иде, эшне бик белеп башкарсалар да, ул шактый озакка сузылды, чөнки елганың киңлеге бу турыда сиксән футка җитә иде. Күпернең кузгалмый торган өлешен беркетү өчен субай суктылар, моның өчен субай суккыч эшләргә туры килде. Күпернең бөтен нигезе субайлардан торганга, авыр йөк күтәрә алырлык чыдам иде.

Бәхетләренә, эш кораллары, кадаклар җитәрлек, уйлап табуга һәвәслекләре зур, инженер күпер төзү эшен яхшы белә, иптәшләре дә җиде ай эчендә төрле-төрле һөнәр үзләштерделәр һәм булышырга атлыгып торалар иде. Әйтергә кирәк, Гедеон Спилет та бүтәннәрдән калышмады, хәтта өлгерлектә диңгезче белән ярыша иде, ә тегесе «журналист кешедән андый җитезлекне көтмәгән идем»,— дип аның уңганлыгын мактап бетерә алмый иде.

Рәхмәт елгасы аша күпер салуга өч атна вакыт китте. Хәтта көндез ашарга да кайтып йөрмәделәр, шунда гына әзерләп тукландылар. Көннәр бик матур тора иде, алар торакка кич йокларга гына кайта иделәр.

Шул вакыт эчендә Юп абзый яна шартларга үзләште, хуҗаларына тиз ияләште. Аларны бик кызыксынып күзәтә иде ул. Шулай да Пенкроф әле һаман бераз шикләнә, шуна күрә аның барлык тышавын салдырмады; күперне төзеп бетерсеннәр. Күзәтү яссылыгы су уртасында калсын, аннан чыгып качарга җай бетсен, шул чагында иреккә җибәрербез дип уйладылар. Әйе шул, шулай акыллырак булыр. Топ белән Юп бик дуслашып киттеләр, бергәләп уйнарга, шаярырга яраталар иде. Хәер, Юп үзен гел җитди тота иде.

Егерменче ноябрьгә күперне салып бетерделәр. Кузгала торган башы каршы авырлыклар ярдәмендә асат күтәрелә, урталыкта егерме фут киңлеге ара ачылып кала һәм теләсә нинди ерткыч җәнлеккә юл бикләнә иде.

Алга хәзер һава шары тышчасын алып кайту бурычы килеп басты, һава шарын ышанычлы урынга җыеп куясылары килә иде аларның. Әмма аны алып кайту өчен һава шары портына арба җигеп барырга, димәк Ерак Көнбатыш урманнары аша юл салырга кирәк иде. Аны тиз арада гына эшләп булмый, шуна күрә Наб белән Пенкроф башта һава шары портына барып кына кайтырга булдылар. Мәгарәдәге «кием-салымлык» тукыма-

ның әйбәт саклангынлыгын белгәч, башланган эшне бүлеп тормаска, Күзәтү яссылыгын тизрәк утрауга әверелдерергә карар иттеләр.

— Әнә шул чакта әйбәтләп кош-корт кетәге корып җибәрербез: төлке ише явызерткычлар җәбер-золымыннан курыкмаска да булыр,— диде Пенкроф.

Наб та кушылып китте:

— Шуның өстенә, җир сөреп, кыргый үсемлекләрне күчереп утыртырбыз...

Диңгезче тантана белән үзенекен өстәде:

— Икенче кат иген чәчү өчен яңа басу сөрергә кирәк булыр!

Хикмәт шунда, бердәнбер орлыкны чәчкән беренче басуда Пенкрофның тырышлыгы нәтиҗәсендә ужым шәп шытты: бер төптән, инженер юраганча, ун башак үсте; һәр башакта сиксәнешәр бөртектән барлыгы сигез йөз орлык булды — әле бит бу ярты ел эчендә; ә ел ахырына хәтле тагын бер уңыш алырга өмет бар иде.

Сигез йөз орлыкның иллесен кара көнгә салып куярга, ә калганын яңа басуга, беренче тапкырындагы кебек үк бик пөхтәләп чәчәргә карар иттеләр. Иген басуын әйбәтләп сукаладылар, бер генә җәнлек-фәлән дә үрмәләп кермәслек итеп аны биек утыртма читән белән уратып алдылар. Кош-кортны куркыту өчен Пенкроф куркыныч кыяфәтле карачкылар ясап куйды, шакылдавыклар асты. Буразналар сызып, җиде йөз илле орлыкны утыртып чыктылар. Эшнең калган ягын табигатьнең мәрхәмәтенә тапшырдылар.

Егерме беренче ноябрьдә Сайрес Смит Күзәтү яссылыгын көнбатыштан саклау өчен Грант күленен көньяк очыннан алып Рәхмәт елгасының беренче тугаена хәтле казылачак канауның планын сызды. Бу урында туфрак катлавының калынлыгы ике-өч футтан артмый иде, ә асты тоташ граниттан тора. Тагын нитроглицерин әзерләргә кирәк иде. Нитроглицерин үз эшен эшләде: ике атна да үтмәгәндер, яссылыкның таш нигезен киңлеге унике, тирәнлеге алты футлы канау ярып узды. Күлнең гранит ярын шартлаткач та, суы яңа юлга бәреп керде һәм инеш Рәхмәт елгасына барып кушылды, аны «Глицерин инеше» дип атадылар. Инженер алдан уйлаганча, күлнең суы саекса да, әлләни күзгә ташланырлык түгел иде. Ниһаять, диңгезгә агып төшә торган шарлавыкның тамагын киңәйттеләр, комлы ярын ныгыту өчен ике рәт утыртма читән кактылар.

Декабрь урталарына утрау кешеләренең әлеге эшләре төгәлләнде. Периметры дүрт миль чамасындагы бишпочмакны хәтерләткән Күзәтү яссылыгын төрле яктан су уратып алды, хәзер аңа читтән бәреп керү мөмкинлеге калмады.

Декабрь аенда көннәр кызу торды. Әмма шуңа да карамастан, утрау кешеләре үз планнарын тормышка ашыруны вакытлыча туктатып торырга риза түгелләр иде. Алар озакка сузмыйча кош-корт өчен кетәк корырга керештеләр.

Яссылык хәзер тышкы дөньядан су белән аерып алынгач, Юп абзыйның иреккә җибәрелүен әйтеп тору кирәк булыр микән. Ләкин орангутанг качып китәргә теләк белдермәде, хуҗаларыннан бер адым да калмыйча ияреп йөрде. Ул бик көчле, елгыр һәм юаш холыклы иде. Гранит сарай баскычыннан аның кебек җитез менеп-төшеп йөрергә берәүнең дә хәленнән килми иде. Хәзер аңа тегебу йомышны куша башладылар: ул утын күтәреп кертә, Глицерин инеше үзәненнән чыккан ташларны ташый иде.

Ташчы осталар гадәттә үз кул астындагы булышчыларны «маймыл» дип йөртәләр, Герберт шуңа ишарәләп, аннан көлеп йөри:

— Чын ташчы ук булып җитмәсә дә, шәп маймыл булып чыкты бу,— ди. Әлеге кушамат бу очракта бик тә урынлы иде.

Күлнең көньяк-көнчыгыш яры буенда кош-корт кетәге кору өчен ике йөз квадрат ярд мәйданны утыртма читән белән әйләндереп алдылар. Анда кетәкләр салдылар, өчен бүлемнәргә бүлделәр.

Кош кетәгенә беренче башлап теге чакта тоткан яшерен койрыклыларны җибәрделәр. Тиздән кошлар мул үрчи башладылар. Озак та үтми алар янына күлгә иярләшкән ике-өч пар үрдәк килеп кушылды. Анда берничә кытай үрдәге дә бар иде. Аларның җилпәзәдәй җәелә торган ялтыравыклы койрыклары матурлык ягыннан алтынсыман фазаннардан һич калышмый иде. Берничә көннән Герберт тавыклар нәселеннән озын каурыйлы, түгәрәк койрыклы бер пар «бүрекле» кош тотып алып кайтты. «Бүрекле»ләр кулга тиз ияләштеләр. Яр буендагы кош кетәгенә озакламый үз ирекләре белән пеликаннар, зәңгәр кошлар, су тавыклары кереп тулды. Тирәяк чиаклашкан, бакылдашкан, кытаклаган авазлар белән тулды. Башта кошлар талашалар, чукышалар иде. Ә соңыннан татулашып яши башладылар. Кошлар ишәй-

гәннән-нишәйде. Утрау кешеләренең азык-төлектән кайгысы китте.

Сайрес Смит башлаган эшне төгәлләп куярга ярата иде: ул кош кетәгенә янәшә күгәрчен оясы да корып куйды. Аңа Күзәтү яссылыгының кыя кәрнизләренә оялаган дистәдән артык күгәрчен тотып китереп яптылар. Күгәрченнәр ояга тиз ияләштеләр, кичен яңа торакларына кайтып кунаклый торган булып киттеләр. Кыя күгәрченнәре ирексезлектә үрчеми торган әберченнәргә караганда кулга тиз ияләшәләр икән.

Ниһаять, һава шары тышчасын алып кайту, аннан кием-салым тегү турында уйлар вакыт җитте. Чыннан да шар тышчасын саклап торып, кайчан да булса эченә җылы һава тутырып очсыз-кырыйсыз океан өстеннән очып китәрбез дип өметләнү өчен акылдан язган кеше булу кирәк, ә Сайрес Смит аек акыллы кеше буларак, бу турыда башына да китерми иде.

Шар тышчасын Гранит сарайга алып кайту хәстәрен күрергә карар кылдылар. Моның өчен шыксыз авыр арбаны төзәтергә туры килде. Аны җайлы, җиңел итеп рәтләделәр. Инде арбаны тарту көчен кайдан юнәтү мәсьәләсе алга килеп басты. Утрауда ат, ишәк, сыер яки үгезне алыштырырдай берәр күшәүче хайван юк микән? Бу сорауга җавап бирүче табылмады.

— Сайрес Смит әле кайчан безгә пар двигателенә көйләнгән арба яки паровоз төзеп бирер, аңарчы һич югы арбага җигәрдәй берәр терлек тапсак шәп булыр иде,— диде Пенкроф.— Ышанам ки, бердән бер көнне утравыбызда Гранит сарайдан Һава шары портына таба тимер юл сузылачак, бер тармагы Франклин тавына алып менәчәк!

Әй изге күңелле диңгезче! Үз сүзенә ничек ышанып сөйли бит! Их син, хыял, ышаныч канатларына утырып очканда дөньяда синнән дә көчле нәрсә бар микән!..

Мәгәр, күктә йөзмик, бу мәлдә кыенлыктан чыгу өчен аларга арбага җигәрдәй гап-гади бер терлек кирәк бит. Хәер, язмыш Пенкрофка моңарчы адым саен мәрхәмәтен күрсәтә килде, инде хәзер дә озак көттереп зарыктырмады.

Бу хәл 23 нче декабрьдә булды. Бер көнне кинәт Наб кычкырып җибәрде, Топ ярсып-ярсып өрергә тотынган иде. Хәрабә тирәсендә эшләп йөргән иптәшләре моны ишеткәч, әллә берәр бәла-каза бар микән дип аның янына йөгерделәр.

Барып җитсәләр, ни күрсеннәр? Күзәтү яссылыгына сокландыргыч матур бер пар хайван килеп кергән, чөнки күпернең төшереп куелган чагы булган. Берсе ата, икенчесе ана бу хайваннар атка, аннан да бигрәк ишәккә охшаганнар: төсләре кола, койрык очы, бәкәлләре ак; баш, муен, арка тирәсендә зебраныкы кебек буй-буй кара сызыклар бар. Хайваннар болай таба өрекми-нитми тыныч кына якынлаштылар да акыллы күзләрен кешеләргә төбәп туктап калдылар. Алар бу кешеләрнең үзләренә хуҗа булачагын белмиләр иде әле.

— Болар онагрлар бит! — дип кычкырып җибәрде Герберт.— Зебра белән квагга арасындагы дүрт аяклы хайван.

— Ә нигә ишәк кенә димәскә? — диде Наб.

— Чөнки колаклары ишәкнеке кебек озын түгел, гәүдәләре дә сылу.

— Ишәк булсани, ат булсани — безнең өчен барыбер түгелме,— диде Пенкроф,— тегесе дә, монысы да җигү өчен ярый ла. Тотып алырга да, арбага җигәргә кирәк!

Дингезче, хайваннарны өркетмәс өчен, үлән арасыннан посып кына күпергә таба китте һәм Глицерин инеше күперен күтәртеп куйды. Онагрлар тоткынлыкка төштеләр.

Хәзер нишләтергә соң боларны? Тотып алып ирексезләп арбага җигәргәме? Алай ирексезләү ярамастыр дигән фикергә килделәр. Әйдә мул үләнле болында үз ирекләрендә берничә көн утлап йөрсеннәр; ә шул арада кош кетәге янына инженер җитәкчелегендә ат абзары салып өлгертерләр,— бәлкем онагрлар шунда барып керерләр дә җиргә түшәлгән йомшак үлән өстенә ятып йоклауны уңайрак күрерләр.

Утрау хуҗалары сылу хайваннарны иректә калдырдылар. Өркетмәс өчен, яннарына якын килмәскә тырыштылар. Иркен болыннарны, очсыз-кырыйсыз урманнарны гизеп йөргән онагрларга биредә кысан тоелды, ахрысы, берничә тапкыр качарга маташканнары сизелде. Су читенә килеп туктыйлар да теге якка чыгарга азапланалар иде. Әсир төшкәнлекләрен сизгәч, тирә-якны яңгыратып кешнәп җибәрәләр дә болын буйлап ярсып чабарга тотыналар. Бераз тынычлангач, туктап теге яктагы урманнарга, гомергә анда кайта алмаячакларын сизенгәндәй, моңсу гына карап торалар иде.

Утрау кешеләре шул арада аларга үсемлек сүсеннән дирбия әзерләделәр, берничә көннән онагрларны тотып

җигәр өчен арба юнәттеләр. Ул гына да түгел, Рәхмәт елгасы тугаеннан алып Һава шары портына хәтле Ерак Көнбатыш урманы аша, агач кисеп, арба белән йөрерлек юл салдылар. Ниһаять, декабрь ахырында беренче тапкыр онагрларны арбага җигәргә ниятләделәр.

Пенкроф моңарчы онагрларны үзенә ияләштергән иде инде: алар, аның янына килеп, кулыннан ризык ашыйлар, үзләрен сыйпарга-сыпырырга рөхсәт итәләр иде. Тик арбага җигәргә ниятләүләрен сизгәч, чыгымчыларга, тибенергә керештеләр, аларны көч-хәл белән генә тыя алдылар. Хәер, алар үз язмышларына тиз буйсындылар. Гомумән, онагрлар зебралар кебек үк кире беткән түгел, Көньяк Американың таулы төбәкләрендә аларны җигү өчен асрыйлар иде, Европаның шактый салкын өлкәләрендә дә онагрлар күп таралган иде.

Шул ук көнне безнең дуслар арбага төялеп Һава шары портына юнәлделәр. Пенкроф онагрларны җитәкләп алдан җәяүләп атлады. Әйтергә кирәк, чокыр-чакырлы, керделе-чыктылы юлдан селкенеп баруы бик йончытты. Шулай да арба кирәк урынына исән-сау барып җитә алды. Шул ук көнне алар, һава шары тышчасын һәм башка барлык әйберләрне төяп, кайтыр юлга кузгалдылар.

Кичке сәгать сигездә арба, Рәхмәт елгасы күперенпән чыгып, сул як яр буйлап диңгезгә таба төшеп китте һәм Гранит сарай каршысына килеп туктады. Онагрларны туарып, ат абзарына илтеп яптылар, һәм Пенкроф урынына килеп яткач, йокыга китәр алдыннан, бик канәгать булып, иркенләп бер сулап җибәрде, аның кайтавазы Гранит сарай гөмбәзләреннән, барлык почмаклардан озак яңгырап торды.

Сигезенче бүлек

Эчке кием-салым.— Тюлень тиресеннән тегелгән аяк киемнәре.— Пироксилин ясау.— Яшелчә утырту.— Балык тоту.— Ташбака йомыркалары.— Юп абзыйның уңышлары.— Мал утары.— Муфлоннар аулау.— Үсемлек һәм хайваннар дөньясының яңа байлыклары.— Еракта калган илләрен сагынып искә алу.

Январь аеның беренче атнасы эчке кием-салым тегүгә багышланды. Бигүк җитез булмасалар да, көчле бармакларда инә уйнап торды. Әйтергә кирәк, теккән киемнәре җиренә җиткереп эшләнгән иде.

Җеп җитәрлек иде: Сайрес Смит аэростат тышчасын теккән җепне сүтеп файдаланырга киңәш итте. Гедеон Спилет белән Герберт тышчаны түзем рәвештә бик пөхтәләп буй-буй итеп сүттеләр. Пенкроф исә сүтүдән баш тартты, аның түземе җитмәде. Аның каравы арада ул иң оста тегүче иде. Мәгълүм ки, диңгезчеләр тегү эшенә аеруча сәләтле булалар.

Аэростат тышчасының тукымасын агач көле селтесе һәм поташ ярдәмендә маеннан арындырдылар, тукыма йомшарып калды; аннары аны кояшка җәеп агарттылар.

Тукымадан берничә дистә күлмәк-штан, оекбашлар тектеләр. Киемнәре бераз тупасрак булды булуын; хәер, анысы вак мәсьәлә, аңа кем игътибар итсен. Яңа эчке күлмәк кигәч, тәннәре рәхәтләнеп китте; чиста җәймә җәеп яткач, чын урын-җирдә яткандай хис иттеләр үзләрен.

Алар тюлень тиресеннән аяк киеме дә тектеләр. Үз илләреннән киеп чыккан ботинкалары, итекләре тузып килә иде инде. Чын әгәр, тюлень тиресеннән тегелгән аяк киемнәре иркен дә, җайлы да булды.

1866 нчы яңа ел килде. Көннәр һаман кызу тора, шуңа карамастан урманга ауга йөриләр. Утрауда агутлар, пекариләр, су дуңгызлары, көнгерәләр, төрле кош-корт мыжлап тора. Гедеон Спилет белән Герберт хәзер оста мәргән булып киттеләр, алар аткан бер генә ук та җилгә очмады.

Сайрес Смит әрҗәдә табылган пуля һәм дарыны саклап тотарга киңәш итте, аларны алыштыру чарасын күрде. Чыннан да киләчәктә нинди көтелмәгән хәлләргә тарымаслар. Әгәр утрауны ташлап китәргә уйласалар, очраклы хәл кайларга илтеп чыгармас дисең...

Көтелмәгән хәлләргә тарый калсалар, чарасыз булмас өчен алдан хәстәрен күрергә, дары, пуляларны саклап тотарга, аларны алыштырырдай матдә табарга кирәк иде.

Утрауда кургаш табылмады, инженер аның урынына вакланган тимер кулланырга булды. Тимер ядрә — кургашка караганда җиңелрәк, шуңа күрә аны эрерәк итәргә туры килде; дөрес, мылтык корганда көпшәгә тимер ядрә азрак сыя сыюын, мәгәр оста аучылар өчен ул зур комачау түгел иде. Сайрес Смит дары да эшли алган булыр иде, чөнки аның кул астында, монда селитра да, күкерт һәм ташкүмер дә бар, әмма дары эшләве мәшә-

катьле, махсус җайланмалар таләп ителә, шунсыз яхшы сыйфатлы дары чыкмас иде.

Шуңа күрә Сайрес Смит пироксилин эшләргә булды. Пироксилин — мамыктан ясала торган шартлагыч матдә. Аның өчен мамык үзе булмаса да ярый, чөнки мамыктан алына торган клетчатка, ягъни үсемлекнең беренчел тукымасы башка үсемлекләрдә дә, әйтик, җитендә, киндердә, кәгазьдә, чүпрәк-чапракта, эт миләше үзәгендә һ. б. саф килеш дип әйтерлек бар. Кызыл инеш тамагында эт миләше агачы күпләп үсә, алар аның җиләген еш кына кофе урынына да кулланалар иде.

Димәк, клетчатканы эт миләше агачы үзәгеннән алырга мөмкин. Пироксилин ясау өчен тагын икенче матдә — төтенле торган нитрат кислотасы кирәк. Сайрес Смитның сульфат кислотасы бар; ә сульфат кислотасыннан нитрат кислотасын алуы кыен түгел. Сульфат кислотасын утрауда күп табыла торган селитра белән эшкәртсәң, төтенли торган нитрат кислотасы хасил була.

Инженер пироксилин ясарга һәм аны файдаланырга карар итте. Дөрес, ул пироксилинның зур кимчелекләре барлыгын да белә иде; пироксилин тиз ялкынлана (дары — ике йөз кырык градуста, ә пироксилин — йөз җитмеш градуста ялкынлана), ниһаять, кисәк кабыну аркасында мылтыкны бозуы мөмкин. Аның каравы, пироксилинның өстен яклары да бар: ул дым тартмый, мылтыкның көпшәсенә корым утырмый, шартлау көче дарыга караганда дүрт тапкыр артыграк.

Пироксилин ясау өчен клетчатканы төтенли торган нитрат кислотасына салып чирек сәгать тоту җитә, аннары алып, суда юарга һәм киптерергә кирәк. Укучы күрсә кирәк, пироксилин ясаудан да асат эш юк икән.

Сайрес Смитның гади нитрат кислотасы гына бар, ә аңа төтенли торган көчле кислота, ягъни дымлы һавада аксыл пар бөрки торган кислота кирәк. Төтенли торган кислотаны гади кислота белән дә алмаштырырга мөмкин: тик өч өлеш гади нитрат кислотасына биш өлеш куертылган сульфат кислотасы кушарга кирәк. Инженер шулай эшләде дә. Утрау аучыларының менә дигән шартлагыч матдәләре булды. Белеп файдалансаң, ул аларга күп игелек күрсәтәчәк.

Шул вакыт эчендә алар Күзәтү яссылыгында өч акр җир сөрделәр. Калган җирләр онагрларга көтүлек итеп билгеләнде. Берничә тапкыр Җакамар һәм Ерак Көнбатыш урманына барып, кыргый шпинат, салат, керән,

шалкан үсентеләре алып кайттылар. Белеп тәрбияләгәндә яшелчә яхшы уңыш бирәчәк һәм Линкольн утравы хуҗаларының гел иттән гыйбарәт ризыкларын төрләндерәчәк. Урманнан байтак утын, ташкүмер ташыдылар. Арба көпчәге таптаудан юл такырая, яхшыра барды.

Гранит сарай хуҗалары карамагында куяннар да көннән-көн күбәйде. Куян бакчасы Глицерин инешеннән өскәрәк урнашканлыктан, куяннар заповедникка әверелгән Күзәтү яссылыгына керә алмыйлар һәм утырткан яшелчә үсентеләренә зыян китерә алмыйлар иде.

Яр буендагы кабырчык сайлыгына барып, дусларыбыз әледән-әле кабырчык җыеп кайталар. Шуның өстенә күлдән, Рәхмәт елгасыннан балык тоталар; балык мул әлегә. Пенкроф тимер кармаклар тезгән кармак җебен елга төбенә салып калдыра, аңа еш кына тәмле ала балык эләгә һәм бик матур сары таплы ниндидер көмешсыман гаҗәп балык каба иде. Пешекче Набка колонистларның көндәлек ризыкларын төрләндерергә мөмкинлек артканнан-арта. Тик шунысы аянычлы: әлегә хәтле аларның ризык табыны иң хаҗәт нәрсәдән мәхрүм — ипиләре юк иде.

Утрау хуҗалары Казна борынына үрмәләп чыга торган диңгез ташбакаларын да аулыйлар. Комлы яр өсте түмгәкләр белән чуарланган, анда каты ак кабыклы түмтүгәрәк ташбака йомыркалары күмелгән. Ташбака йомыркасының агы кош йомыркасының агы кебек тиз оемый. Кояш кызуына җылынган йомыркалардан бер-бер артлы нәни ташбакалар борнап чыга. Йомырканың монда исәбе-саны юк, бер ташбака елына ике йөз иллеләп күкәй сала.

— Карагыз әле моны, йомырка басуы бит бу, уңышын гына җыясы бар,— диде Гедеон Спилет.

Утрау хуҗалары йомырка да җыйдылар, ташбака да ауладылар. Барган саен дистәдән дә ким ташбака алып кайтмый калмыйлар иде. Гранит сарай чоланында белгечләр арасында кыйммәт исәпләнә торган ташбака ите шактый күбәйде. Ташбака итеннән, хуш исле үлән, яшелчә салып, Наб бик оста итеп аш пешерә, аны мактыймактый ашап туймыйлар.

Кышка дигән азыкны арттырырга ярдәм иткән янә бер бәхетле очракны әйтеп китү урынлы булыр. Бер вакыт Рәхмәт елгасына көтүе белән сөләйман балыгы килеп керде, алар агымга каршы берничә миль өскә таба йөзеп менделәр. Бу — ана балыкларның уылдык чәчәргә

җайлы урын эзләп менүе икән; йөзләгән ана балык ага балыклар алдыннан елга суын шапы-шопы китереп агымга каршы йөзеп баралар. Утрау балыкчылары елга аркылы берничә тозак кордылар, байтак балык әсир төште. Берничә йөз сөләйман балыгын тозлап кышка салып куйдылар. Чөнки кыш көне елгада боз ката, балык тотып булмый иде.

Юп зирәк булып чыкты, аңа хәзер камердинер вазифасын йөкләделәр. Ак тукымадан штан, куртка тегеп киерттеләр, алдына кесәле алъяпкыч яптылар. Кесәне ул аеруча ошатты, кулын гел кесәгә тыгып йөри торган булды. Кесәдәге әйберләрен барларга берәүгә дә рөхсәт итми иде. Наб акыллы орангутангны төрле эшкә өйрәтте, аның белән сөйләшә иде, гүя тегесе дә ул әйткән сүзләрнең мәгънәсен төшенгәндәй кылана. Юп Набка бик ияләште. Наб та аны яратты. Утын ташыйсы, биек агач башына менәсе булмаганда, берәрсе бүтән йомыш кушмаганда, Юп кухнядан чыкмый, Наб нәрсә эшләсә, шуны кабатлый. Кыскасы, укытучысы гаять сабыр рәвештә бик теләп шәкертен эшкә өйрәтә, ә шәкерте гаҗәеп зирәклек белән укытучысы гыйлемен үзләштерә иде.

Шунысын да әйтик, Юп көтелмәгән булдыклылыгы белән хуҗаларын шаккатырды: көннәрдән бер көнне ул кулына тастымал алып табын янында хуҗаларына хезмәт күрсәтергә тотынды. Ризык салынган тәлинкәләрне алларына җитез генә китереп куя, бушаганнарын җәһәт кенә алып китә, чокырларга эчемлек сала. Һәр эшне бик тә эшлекле кыяфәт белән башкара, төгәл, пөхтә эшли. Бу хәл аның хуҗаларына хәтта гаҗәп мәзәк тоелып китте. Пенкроф шатлыгыннан нишләргә белмәде.

— Юп, тагын аш сал әле!

— Юп, бер кисәк агут өстә әле!

— Юп, тәлинкә китер!

— Юп, уңган Юп, булдыклы Юп!

Өстәл янында бер-бер артлы шундый боерыклар явып торды. Ә Юп исә бер дә югалып-каушап калмый, һәр боерыкны үти, кемгә нәрсә кирәген игътибар белән күзәтә иде.

Пенкроф кызык итеп:

— Валлаһи, Юп, хезмәт хакыңны моннан соң икеләтә арттырмыйча булмас инде,— дигәч, тегесе аңлагандай башын кагып куйды.

Үзегез күрәсез, орангутанг Гранит сарайда хәзер тәмам үзләште, хуҗалары белән еш кына урманга барып

йөри, тик анда да качу теләге исенә дә керен чыкмый иде. Аның мылтык урынына Пенкроф ясап биргән чукмарны иңенә салып аyга баруын карап тору үзе бер мәзәк иде. Биек агач очыннан җимеш җыярга кирәк булса, ул күз ачып йомганчы агачның иң очына менеп китә; арба тәгәрмәче былчыракка кереп батса, җилкәсен терәп этүгә, арба әйбәт юлга килеп чыга.

— Әй булдыклы да инде үзең! — ди Пенкроф сокланып.— Әле дә усал түгел, ярсыганда тотып тыя алмас идек!

Январь ахырларында алар утрауның түрендә дә зур эшләр башладылар. Франклин тавы итәгенә, Кызыл инешнең су башы тирәсенә күшәүче терлекләр өчен мал утары төзергә җыендылар. Терлек абзарын Гранит сарай тирәсенә салуны килештермәделәр. Анда башлыча муфлоннар асрарга уйлыйлар иде, муфлон йоны кышкы киемгә китәчәк.

Һәр көн иртән барысы бергәләп, ә күбесенчә Сайрес Смит, Герберт һәм Пенкроф үзләре генә, Кызыл инеш ягына таба китәләр. Аларны сәхрәгә сәйранга чыккан дип уйларлык иде: биш миль араны яшел агачлар чатыры астыннан онагрлар җигелгән арбада тирә-якны хозур кылып баралар. Бу юлны безнең дуслар *«Утар юлы»* дип атадылар.

Ике тау сырты арасында мул үләнле иркен генә болын бар иде, алар шуны ошаттылар. Анда-санда агачлар үсеп утырган бу урын бик уңайлы иде. Ике яктан да таулар ышыгында булу өстенә аның уртасыннан инеш ага, ул тау башыннан агып төшә дә, суын Кызыл инешкә илтеп коя. Болын үләне сусыл. Сирәк агачлар арасыннан үләннәрне сыйпап иркенләп җил йөри. Болынны тирә-ягыннан иң җитез терлекләр дә сикереп чыга алмаслык итеп биек утыртма койма белән уратып алырга кирәк иде. Мал утарын йөзләгән муфлоннар, кыр кәҗәләрен яңа туган бәтиләре белән бергә сыйдырырлык итеп корырга, койманы тау итәгенә үк илтеп җиткерергә исәплиләр иде.

Инженер аның чикләрен билгеләп чыкты. Утыртма коймага агач кисәсе генә калды. Хәер, бирегә юл салганда байтак агач екканнар иде, шуларны ташып, йөзләгән бүрәнә турадылар һәм аларны җиргә ныгытып кактылар. Койманың алгы ягына юан баганаларга калын такталардан ике якка ачылмалы капка торгызды лар.

Дусларыбыз тоташ өч атна ал-ял белми эшләделәр, шул вакыт эчендә койманы корып бетерделәр, терлек-туарга иркен абзарлар салдылар. Барысын да чыдам, нык итеп ясарга тырыштылар. Чөнки муфлоннар көчле, иректә йөреп өйрәнгән терлекләрнең, абзарга ябып куйгач, шашып дулаулары мөмкин иде.

Ныклык өчен утта ысланган очлы башлы бүрәнәләрне бер-берсенә таза араталар белән беркеттеләр. Тышкы яктан терәүләр дә тезеп чыккач, койма тагын да ныграк булды.

Абзарлар да әзер иде. Инде Франклин тавы итәгендә болыннарда утлап йөргән күшәүче терлекләрне тотып ябасы гына калды. 7 нче февральдә җәйге матур аяз көнне дусларыбыз ауга юнәлделәр. Җигәргә өйрәтелгән онагрларның да бу эштә ярдәме тиде: Гедеон Спилет белән Герберт онагрларга атланып бардылар.

Алар муфлоннарны, кыр кәҗәләрен камап алып, әкренләп кысрыклый-кысрыклый, утарга таба куарга уйлыйлар иде. Сайрес Смит, Пенкроф, Наб һәм Юп уйсулыкның төрле ягына таралыштылар, ә җайдаклар белән Топ терлек абзарлары тирәсендә ярты миль чамасы арада йөреп тордылар.

Утрауның бу тирәләрендә күпләгән муфлон көтүләре утлап йөри иде. Озын соры йонлы, зур мөгезле, сылу гәүдәле муфлоннар, болан зурлыгы булып, үзләре кыр кәҗәсенә охшаганнар иде.

Аучылар арлы-бирле чаба-чаба, кычкыра-кычкыра тәмам хәлдән тайдылар. Башта йөзләгән муфлон камалышта калган иде, әмма төрлесе-төрле якка чабышып, өчтән ике өлеше качып бетте. Калганнары ачык капканы күргәч, качарга юл эзләп, шунда атылып керделәр һәм тоткынлыкка эләккәннәрен сизмичә дә калдылар. Барысы утызлап муфлон, дистәләп кыр кәҗәсе әсир төште.

Кыскасы, ау уңышлы чыкты, утрау хуҗаларының хәле зарланырлык түгел иде. Муфлоннарның күбесе саулык, байтагы буаз, озакламый бәрәнли башларга тиешләр. Шик юк ки, тиздән көтү ишәячәк, утрау хуҗалары йонга да, тирегә дә мохтаҗ булмаячаклар.

Дусларыбыз арып-талчыгып кич белән Гранит сарайга кайтып керделәр. Иртәгесен тагын мал утарына юнәлделәр. Әсир терлекләр ирекә чыгарга омтылып, дулап, койманы җимерергә азапланганнар, соңыннан язмышла-

рына буйсынганнар булса кирәк, юаш кына көйшәп торалар иде.

Февраль ае тыныч узды, әлләни әһәмиятле вакыйгалар булмады. Көндәлек эшләр үз чираты белән әкренләп эшләнә торды, Утар юлын һәм Һава шары портына бара торган юлны һаман рәтләделәр, ул арада мал утарыннан көнбатыш ярга таба өченче юл салдылар. Линкольн утравының бер почмагы һаман өйрәнелмәгән килеш кала бирә әле, ул да булса, Борылмалы ярымутрау. Андагы куе урманнарда ерткыч җанварлар яши, Гедеон Спилет утрауны ерткычлардан тизрәк азат итеп бетерергә тели иде.

Дусларыбыз ерак урманнардан Күзәтү яссылыгына алып кайтып утырткан кыргый яшелчәләрне көннәр суытканчы тырышып үстерделәр. Герберт һәр көн диярлек яңадан-яңа файдалы үсемлекләр алып кайта тора. Орлыгыннан май сыгып алырга яраклы цикорий дисеңме, зәңгелә авыруыннан кузгалак дисеңме, Көньяк Америкада ел әйләнәсендә үсә торган, хәзерге көндә ике йөздән артык төре билгеле булган бәрәңге дисеңме һ. б. Яшелчә бакчасын әйбәт карыйлар, вакытында су сибәләр, кошкорттан саклыйлар. Түтәлләрдә салат, бәрәнге, кузгалак, шалкан, торма һ. б. яшелчәләр үсә. Күзәтү яссылыгында җир уңдырышлы, мул уңыш алырбыз дип өметләнәләр иде.

Төрле-төрле эчемлекләргә дә мохтаҗлык юк, иң бәйләнчек адәм дә шәраб булмаудан зарлана алмас иде. «Освег чәе», чыжлап торган драцена эчемлегеннән тыш Сайрес Смит чын сыра кайнатырга өйрәтте: «abies nigra»ның яшь бәпчекләрен башта суга салып кайнаталар, аннары әчетәләр, нәтиҗәдә бик тә файдалы, тәмле эчемлек хасил була. Аны инглизләр, америкалылар «springberr», ягъни чыршы сырасы дип йөртәләр икән.

Җәй ахырында кош кетәгенә шлапырсыман күпереп торган йонлы бер пар дүдәк, томшыклары ике якка чыгып торган үсентеле дистәләгән киң борыннар, кыргый күркәләр өстәлде. Мозамбик күркәләрен хәтерләтүче мәһабәт күркәләр җете кара кауырыйлары, саллы кикрикләре, кабарган бүксәләре белән бик һаваланып кул читендә салмак кына атлап йөриләр иде.

Зиһенле, булдыклы сәяхәтчеләребез үз тырышлыклары белән менә шулай әйбәт кенә көн итеп яталар. Дөресен әйткәндә, язмыш та аларга мәрхәмәтсез түгел; әмма алар яшәешнең төп канунына тугрылык саклап, күбрәк

үз көчләренә таяналар, ахыр чиктә генә тәңредән шәфкать өмет итәләр.

Наб Күзәтү яссылыгында чатыр корып, тирә-ягына үрмәле гөлләр утыртты. Көне буе эшләп арган эшчеләр кояш кызуы сүрелгәч, диңгез ягыннан искән йомшак җилгә иркәләнеп шунда ял итәргә яраталар иде. Белем-тәҗрибәләрен уртаклашып, киләчәккә хыяллар корып, алар җай гына гәпләшеп утыралар. Диңгезченең бераз дорфарак булса да, эчкерсез шаян сүзләре аларның тату дөньясына җанлылык өсти иде.

Кайвакытларны алар күңелдән бер минутка да китмәгән газиз ватаннары Американы да искә алып сөйләшәләр. Төньяк белән Көньяк штатлар арасындагы сугыш һаман дәвам итә микән? Юктыр, туктагандыр инде. Ричмонд һичшиксез генерал Грантка бирелгәндер! Кол биләүче штатларның башкаласы бирелү — канлы сугыш бетүгә сәбәп булгандыр. Хак эш өчен көрәштә җиңгән Төньяк штатлар тантана итәдер. Илләреннән сөрелгән, Линкольн утравында сыеныр почмак тапкан дусларыбыз унбер ай инде дөнья хәлләреннән бихәбәр булып, газета укырга зарыгып яшиләр. Озакламый 24 нче март җитә — кешесез ят утрауга һава шары белән килеп төшүләренә төгәл бер ел тула. Алар һәлакәткә очраганнан соң табигать көчләре белән көрәштә җиңеп чыгачакларына ышанмаганнар иде. Инде хәзер җитәкчеләренең аңбелеме һәм үзләренең акылы-булдыклылыгы аркасында утрауның чын хуҗаларына әверелделәр; аларның инде үз мылтыклары, эш кораллары, приборлары бар; алар утрауның хайваннар һәм үсемлекләр дөньясын, җир асты байлыкларын, ягъни табигатьнең төп өч хәзинәсен үзләренә хезмәткә җигә алдылар.

Әйе, алар бу турыда еш сөйләшәләр, киләчәккә яңадан-яңа планнар коралар!

Сайрес Смит иптәшләренең фикерен күп вакытта дәшмичә генә тыңлап тора. Гербертның кайбер сүзләреннән яки Пенкрофның мәзәк кыланышларыннан елмаеп куйгалый. Ә үзе утрауда әледән-әле туып торган аңлаешсыз хәлләрне, сәер табышмактай чишелешсез серләрне бер генә минутка да исеннән чыгармый, уйлана иде.

Тугызынчы бүлек

Көннәр бозылды.— Су көче ярдәм итә.— Тәрәзә пыяласы һәм пыяла савыт-саба ясау.— Саго пальмасы.— Мал утарына барып йөрүләр.— Терлекләр үрчи.— Журналистның соравы.— Линкольн утравының төгәл координатлары.— Пенкрофның тәкъдиме.

Март аеның беренче атнасында ук көннәр бозылды. Март башы ай тулган вакытка туры килгән иде, эсселеккә чыдар әмәл калмады. Һава электрга тәмам туенды, озак вакытка сузылачак яшенле яңгырлар чоры башланганлыгы сизелеп тора иде.

Чыннан да, 2 нче мартта көтмәгәндә колак тондыргыч көчле күк күкрәү ишетелде. Көнчыгыштан җил чыкты, Гранит сарайның алгы стенасына мылтыктан аткандай шарт-шорт итеп боз бәрә башлады. Ишекләрне, тәрәзә капкачларын ныгытып ябарга туры килде, югыйсә бүлмәләргә яңгыр суы тулган булыр иде.

Күгәрчен күкәе хәтле бозларның төшүен күргән Пенкроф иген басуын боз харап итә дип хафага калды. Шундук иген кырына йөгерде. Яшел башакларын чайкалдырып утырган бодай басуын ул өстән аэростат киндере белән каплап алды. Әмма үзенә шактый гына боз эләкте, тик ул эһ! дип тә зарланмады.

Яңгырлар атна буена китте, бертуктаусыз күк күкрәде. Бер яктан яшенле яңгыр килеп узып китәргә өлгерми, икенче яктан дөберди башлый. Яшен камчылары ялт та йолт күк йөзен телгәли. Байтак агачларны яшен сукты; шул җөмләдән күл буенда урман авызында күкрәп үсеп утырган биек наратны да яшен атты. Бер-ике тапкыр яшен камчысы яр комына сузылып төшеп, хәтта комны эретте һәм анда пыяла хасил булды. «Яшен пыяласын» күргән инженер яңгырдан, җилдән, кар-боздан саклар өчен тәрәзәләргә киләчәктә калын, нык пыяла куярга мөмкин икәнлеген хәтеренә салып куйды.

Утрауда әлегә ашыгыч эшләр юк иде. Һава начар булудан файдаланып, Гранит сарай эчендәге эшләрне башкардылар. Җиһазларны рәтләделәр, яңаларын ясап куйдылар. Инженер гади генә агач кыру станогы әмәлләде, кухняга савыт-саба, бизәнү нәрсәләре, хәтта бик кирәкле төймәгә хәтле кырып ясадылар.

Мылтыкларны куяр өчен махсус терәк эшләделәр, мылтыкларны аеруча саклап тоталар иде алар. Тагын шкафлар, шүрлекләр ясап куйдылар.

Тышта күк күкрәгән тавышка җавап итеп Гранит сарай эченнән станок зырылдаганы, ышкы чыжылдаганы ишетелеп торды: утрау хуҗалары агач кисәләр, юналар, ышкылыйлар, кыралар иде.

Юп абзыйны да онытып бетермәделәр: төп склад янында аңа аерым бүлмә ясап бирделәр, асылма ятак элеп куйдылар, астына көрпә түшәделәр; ятагы хәзер бик тә җайлы иде.

Пенкроф аны мактап туя алмый:

— Юп асыл егет ул безнең, зарлану дигәнне, тиргәшү дигәнне белми! Инде дә уңган хезмәтче булып чыкты ул, дөресме, Наб!

— Минем шәкертем шул ул, озакламый мине дә куып җитәр әле,— ди иде Наб.

— Узып китәчәк әле ул сине, чөнки син күп сөйлисең, ә ул дәшмичә генә эшләп тик йөри! — дип көлә иде Пенкроф.

Юп, чыннан да, үз вазифасын бик шәп белә иде. Кием-салымның тузанын кага, бүлмәләрне себереп чыгара, кирәксә чыгыр әйләндерә, табын янында хезмәт күрсәтә, утын ташып өя иде. Пенкрофны аеруча сокландырганы шул булды: йокларга яткан диңгезченең юрганын маймыл тирә-яктан кыстырып яба иде.

Кечкенә колониянең ике аяклы, ике куллы һәм дүрт аяклы, дүрт куллы вәкилләренең сәламәтлеге зарланырлык түгел иде. Алар саф һавалы, уртача климатлы әйбәт җирдә яшиләр, физик һәм акыл хезмәте белән шөгыльләнәләр; авыру-сырхауның ни икәнен дә белмиләр әлегә.

Чыннан да, һәркем үзен бик яхшы хис итә. Герберт бер ел эчендә буйга ике дюйм үсте. Йөз чалымына җитдилек инде, ирләр төсмере керде. Тәне таза, әхлагы саф кеше булып үсеп җитәчәге күренеп тора иде. Эштән бушаган араларда ул үзенең белемен арттыра, аз вакыт эчендә әрҗәдән табылган китапларның барысын да укып чыкты инде. Утрауда көн иткәндә кирәкле эшләргә өйрәнүдән тыш ул инженер һәм журналисттан белем ала: Сайрес Смит аны төрле фәннәргә, ә Гедеон Спилет исә телләргә өйрәтә иде.

Инженер үз белгәнен егеткә өйрәтеп калдырырга, эше белән дә, сүзе белән дә аңа остаз булырга тырыша иде, әйтергә кирәк, егет укытучысыннан намуслы рәвештә күп нәрсәләргә өйрәнеп, зур уңышларга иреште.

«Үзем үлгәч мине алыштырырлык кеше булсын»,— дип өмет итә иде Сайрес Смит.

Давыл 9 нчы мартта басыла төште, ләкин күк йөзе җәйнең бу соңгы ае беткәнче болыттан арынмады. Көчле электр тупланышы атмосфераның тынычлыгын тәмам бозды, туктаусыз яңгырлар койды, бөтен җир өстен томан сарды. Фәкать ике-өч көн генә аяз торудан файдаланып, утрау хуҗалары барасы җирләренә барып килделәр.

Шул көннәрдә ана онагр колынлады, гаҗәеп матур, таза колын дөньяга килде, ул да ана иде. Коральдә муфлоннар да бәрәнли башлады: абзарларда бәэлдәгән тавышлар яңгырап тора, Наб белән Гербертның куанычлары эченә сыймый; яңа туган бәтиләр арасында аларның аерып яраткан бәтиләре бар иде.

Алар пекариларны да кулга ияләштерергә булдылар һәм тәҗрибә уңышлы чыкты. Кош кетәге янына лапас ясадылар, тиздән анда дуңгыз балалары чинап йөри башлады. Набның тырышлыгы нәтиҗәсендә алар көнләп симерәләр иде. Юп абзый һәр бирмеш көнне дуңгызларга юынтык сулар, аш-су калдыклары илтергә тиеш булды һәм ул үз вазифасын намуслы рәвештә үти иде. Дөрес, ул кайвакыт нәниләр белән шаярырга керешеп китә; койрыкларыннан тарта, ләкин авырттырып түгел, яратып кына тарта иде. Үзеннән дә бала акылы чыкмаган маймылга нәни дуңгызларның өскә кәкрәеп торган койрыклары уенчыктай мәзәк тоела иде, күрәсең.

Март көннәренең берсендә Пенкроф инженерның кайчандыр вәгъдә итеп тә әлегә хәтле үтәп өлгермәгән эшен хәтеренә төшерде.

— Сез Гранит сарайга менә торган озын баскыч урынына ниндидер машина ясап куярга вәгъдә иткән идегез, мистер Сайрес. Шуны эшләмәссез микәнни?

— Сез лифт турында әйтәсезме? — дип сорады инженер.

— Лифт дисез икән, лифт булсын, анысы сезнең ихтыярда. Хикмәт исемендә түгел, торагыбызга мәшәкатьсез генә менеп-төшеп йөрерлек берәр җайланмада.

— Аны ясавы кыен түгел, Пенкроф, тик ул күтәрткеч бик кирәкмени соң?

— Нигә кирәк булмасын, мистер Сайрес. Көн итәр өчен кирәкле һәммә нәрсәбез булды бит инде, хәзер уңайлырак яшәү турында да кайгыртырга вакыттыр. Кешеләрне менгерү-төшерү өчен генә булса, күтәрткеч — артык зиннәт кебек тоелыр иде, ә авыр әйберләр ташы-

ганда ул кирәкмиме! Авыр йөк күтәргән килеш озын бау баскычтан үрмәләүләре әллә бик асатмы!

— Ярый, Пенкроф, сезнең өчен дигәндә ул уңайлыкны булдырырга тырышырбыз,— диде Сайрес Смит.

— Сезнең машинагыз юк бит.

— Ясыйбыз без аны.

— Пар машинасынмы?

— Юк, су машинасын.

Чыннан да, инженер Гранит сарайга менеп-төшеп йөрү өчен күтәрткеч җайланманы кул астындагы табигать көче — су ярдәмендә бер мәшәкатьсез-нисез генә хәрәкәткә китерә ала иде.

Моның өчен Гранит сарайны су белән тәэмин итә торган канал суын күбәйтергә кирәк иде. Алар элекке су юлында калдырылган кечкенә тишекне зурайттылар, һәм су шарлавык булып ага башлады, каналдагы су күбәйде, һәм аның артыгы сарай түрендәге коега агып төшә иде. Шарлавыкка инженер чарык ясап куйды, аны тышкы якта ишек турысына беркетелгән чыгыр белән тоташтырды, ә чыгырга уралган таза арканның бер башына күтәрткеч кәрзин бәйләнгән иде.

Җиргә хәтле салынып торган бау ярдәмендә бу су җайланмасын хәрәкәткә китерергә һәм, «кәрзин» Гранит сарай ишеге төбенә менеп җиткәч, аны туктатырга мөмкин иде.

Унҗиденче мартта, барысын куандырып, йөк күтәрткеч су җайланмасы беренче тапкыр эшләп күрсәтте. Шушы көннән алып бу гади корылма элекке бау баскычны алыштырды һәм өскә ташкүмер, азык-төлек ише йөкләрне һәм утрау хуҗаларының үзләрен ташый башлады. Бу җайланма Топның бик тә кәефенә килде, чөнки ул Юп абзый белән җитезлектә ярыша алмый иде, баскычтан көч-хәл белән үрмәләп менеп йөри иде; элек Гранит сарайга аны җилкәсенә атландырып еш кына Наб, хәтта Юп та алып менгәләделәр.

Шул көннәрдә Сайрес Смит пыяла коярга әзерлек эшләре башлады,— бу яңа эш өчен ул иске чүлмәк мичен файдаланырга булды. Күп кенә кыенлыкларны җиңеп, байтак уңышсызлыклардан соң, шулай да пыяла остаханәсен оештыра алды. Гедеон Спилет белән Герберт, инженерга булышып, берничә көн аннан чыкмыйча эшләделәр.

Пыяла ясау өчен чиста вак ком, акбур һәм сода (натрий карбонаты яки натрий сульфаты) кирәк иде.

Диңгез ярында ком исәпсез, известь катламыннан акбур, суүсемнәреннән — сода, күкерт колчеданыннан сульфат кислотасы табарга була. Ташкүмер ягып мичтә кирәкле температура булдырырга мөмкин. Димәк, Сайрес Смитның пыяла җитештерү өчен кирәкле һәммә нәрсәләре дә бар иде.

Ә иң кыены пыяла өрдерү өчен «пыялачы таягын», ягъни биш-алты футлы тимер көпшәне эшләве булды. Пенкроф озынча юка калай кисәге алды, аны мылтык көпшәсе кебек итеп түгәрәкләде, ярыктан һава чыкмаслык итте, шул көпшә пыяла өрдерергә ярады.

Егерменче мартта мичкә күп итеп яктылар. Йөз өлеш комга утыз биш өлеш акбур, кырык өлеш натрий сульфаты, ике-өч өлеш төелгән ташкүмер куштылар. Катнашманы утка чыдам балчык савытка салып, кызу мичтә тотып тәмам эреттеләр, нәтиҗәдә куе масса барлыкка килде. Сайрес Смит куе массаны озын көпшә очына элеп алды да алдан әзерләнгән тимер тактага салып әйләндергәли башлады һәм өрдерү өчен уңайлы бер рәвешкә кертте. Аннары көпшәне Гербертка сузды да буш очына өрергә кушты.

Егет аңардан:

— Сабын куыгы өргән кебек итеп өрергәме? — дип сорады.

— Әйе, шулай өр,— диде инженер.

Герберт тирән итеп сулыш алды да яңакларын кабартып көпшәгә тырышып өрә башлады, ә үзе көпшәне бертуктаусыз әйләндерә торды, пыяла әкренләп куык булып кабара башлады, аңа эрегән массаны тагын беразөстәделәр һәм өрә торгач диаметры бер футлы пыяла куык барлыкка килде. Сайрес Смит көпшәне егетнең кулыннан алды да сәгать теле кебек тирбәлдереп пыяла шарны озынчага сузды, куык цилиндр формасына кереп озынайды.

Баш-башлары түгәрәкләнеп килгән, эче куыш пыяла цилиндрның ике башын салкын суда чылаткан үткер пычак белән кисеп алдылар һәм шул ук пычак белән цилиндрны буйга ярып җибәрделәр. Аны яңадан җылытып йомшарттылар да тимер тактага салып агач уклау белән җәйделәр.

Нәтиҗәдә табаклы пыяла барлыкка килде. Шушы ук эшләрне илле тапкыр кабатлап, тәрәзәгә илле табак пыяла әзерләделәр. Менә Гранит сарай тәрәзәләренә пыяла

куеп җибәрделәр. Пыяла чак кына тоныук күрсәтсә дә, яктылыкны әйбәт үткәрә иде.

Пыяла савыт-саба, стаканнар, шешәләр ясау алар өчен күңелле шөгыльгә әверелде. Матур ук чыкмаса да, алар ясаган әйберләр һәммәсе эшкә яраклы була иде. Пенкроф та пыяла «өрергә» рөхсәт сорады. Рөхсәт иткәч, бик тә канәгать булды. Дөрес, ул өргәндә чамадан арттырып җибәрә, һәм пыяла әкәмәт рәвешләргә кереп сузыла иде, әмма ул үзе эшләгән әйберләргә үзе сокланып туя алмады.

Бер көнне экспедициягә барган җирдә утрау хуҗалары яңа төр агачка юлыктылар, ул аларның ашауэчүен тагын да баетып җибәрде.

Ул көнне Сайрес Смит белән Герберт Рәхмәт елгасының сул ярына Ерак Көнбатыш урманына ауга чыккан нар иде. Егет гадәтенчә инженерга сораулар яудырды, ә тегесе аңа куанып җаваплар бирә барды. Әмма сунар вакытында, һәр эштәге кебек, игътибарны таркату һич тә ярамый иде, югыйсә ауда ничек уңышка ирешмәк кирәк.

Сайрес Смитның гомумән сунарчылык сәләте юк, ә химия һәм физика белән мавыгып киткән Герберт исә асат кына атып алырлык байтак көнгерәләрне, су дуңгызларын, агутларны ычкындырды. Файдасыз узган көн бетеп килгәндә генә Герберт барган җиреннән кинәт туктап калды:

— Ах, мистер Сайрес, карагыз әле бу агачны! — дип кычкырып җибәрде.

Кәүсәсе тәңкәсыман кабыклы кечерәк кенә бер агачка төртеп күрсәтте ул. Куак биеклеге агачның яфраклары буй-буй сеңерчәләр белән чуарланган иде.

— Нинди агач соң бу, үзе кечкенә пальмага да охшаган? — диде Сайрес Смит.

— Бу «cycas revoluta», аның рәсеме безнең табигать белеме энциклопедиясендә дә бар.

— Нишләптер җимешләре күренми.

— Җимеше булмый аның, мистер Сайрес, аның каравы кәүсәсендә оны була — табигать безгә он бүләк итәргә уйлаган,— диде Герберт.

— Саго пальмасымыни бу?

— Әйе, саго пальмасы.

— Менә әйбәт булды, бодаебыз өлгергәнче, олы хәзинә бит бу безгә, балакаем! Ходай кушып, ялгышмаган булсаң ярар иде!

Герберт ялгышмаган иде. Ул пальманың кәүсәсен чабып карады. Көпшәк кабыгы эченнән сүсләр белән чорналган буынтыклы ончыл үзәге күренде. Аның тәмсез исле ябышкак сутыннан крахмалын аерып алуы кыен түгел иде. Яхшы сыйфатлы туклыклы бу онны кайчандыр Япониядән хәтта чит илгә чыгару закон белән тыелган булган.

Сайрес Смит һәм Герберт Ерак Көнбатыш урманының «cycas revoluta» агачы үскән тирәләрен йөреп чыктылар, агачларга тамга сала бардылар. Һәм шатлыклы хәбәрне иптәшләренә сөйләү өчен ашыгып Гранит сарайга кайттылар.

Дусларыбыз иртәгесен «он»га киттеләр. Утрауга көннән-көн ныграк соклана барган Пенкроф инженерга шундый сорау бирде:

— Һәлакәткә очраган кешеләр өчен җир йөзендә махсус утраулар бар икән дигән фикер килмиме сезнең күңелегезгә, мистер Сайрес?

— Ни димәкче буласыз сез, Пенкроф?

— Дөньяда шундый утраулар бар, алар янында кораб һәлакәткә очраса да үкенечле түгел — безнең кебек бәхетсезлеккә очраган бичаралар андый утрауда теләсә нинди бәла-казаны да җиңеп чыга алалар!

— Ихтимал,— диде Сайрес Смит елмаеп.

— Дөресе шулай, мистер Сайрес. Безнең Линкольн утравы да шулар рәтенә керә.

Гранит сарайга мул уңыш җыеп, күп итеп «он»лы пальма кәүсәләре күтәреп кайттылар. Инженер пресс ясап бирде, шуның белән пальманың ябышкак сутын сыгып, күп итеп он әзерләделәр. Оннан Наб печенье, пудинг пешерде. Пальма оныннан пешергән ипидән бодай күмәче тәме килә иде.

Бу көннәрдә онагрлар, кәҗәләр һәм муфлоннардан мул сөт савыла иде. Алар янына еш барып йөрергә туры килә. Мал утарына җиңел арба җигеп йөриләр. Пенкроф үзенең бару чиратында Юпны да ияртә, дилбегәне аңа тоттыра. Ә Юп тапшырылган эшне һәрвакыт җиренә җиткереп башкара, шарт та шорт чыбыркы шартлатып онагрларны куалый иде.

Кыскасы, Гранит сарайда һәм мал утарында эшләр шәп бара: туган илләреннән аерылган булуларын исәпләмәсәк, дусларыбызның хәле зарланырлык түгел иде. Алар утраудагы шартларга җайлаштылар инде, тәмам

иялəшеп җиттелəр, бу кунакчыл җир кисəген киләчәктә ташлап китүе дә кыен булачак.

Әмма үз туган илен ярату хисе кешенең йөрәгеннән мәңге китми торган хис ул. Шик юк ки, әгәр утрау янынннан берәр кораб узып барса, алар аңа сигнал биреп кораб командасыннан үзләрен алып китүен үтенерләр һәм утырып китәрләр иде.

Ә хәзергә алар кайгы-хәсрәтсез имин генә яши бирәләр, үзләренең тынычлыгын бозардай берәр вакыйга килеп чыгуын теләмиләр иде генә түгел, хәтта куркалар да иде.

Әмма бәхетле көннәр мәңгелек дип кайсыбыз мактана ала да, язмышның көтелмәгән хәлләреннән кайсыбыз азат соң!

Бер көнне алар әңгәмә корып утырган җирдән Линкольн утравы турында кызыклы гына фикерләр әйтеп ташладылар.

Бу хәл 1 нче апрельдә, якшәмбе көнне булды. Пасханың беренче көне иде бу. Сайрес Смит һәм аның иптәшләре бүген ял итәргә, гыйбадәт кылырга булдылар. Көн бик матур тора — мондый көннәр Төньяк ярымшарда октябрь аенда була.

Төштән соң алар Күзәтү яссылыгында яшел чатыр астына җыелдылар һәм күк читендә әкренләп сүнеп барган шәфәкъне күзәтергә керештеләр. Наб кофе урынына эт миләше җиләгеннән эчемлек бирде. Линкольн утравының Тын океан уртасында япа-ялгыз адашып калган булуы турында сүз чыккач, кинәт Гедеон Спилет инженердан сорап куйды:

— Кадерле Сайрес, әрҗәдән табылган секстан ярдәмендә утравыбызның торган урынын ачыклаганыгыз юкмы әле?

— Юк,— диде инженер.

— Кирәк иде. Секстан — әйбәт, камил прибор. Сезнең элекке ысулыгызга караганда, аның ярдәмендә утрауның координатларын төгәлрәк билгеләргә мөмкин.

— Нигә кирәге булыр икән аның. Аңа карап утрауның урыны барыбер үзгәрмәячәк бит.

— Әлбәттә үзгәрми,— диде Гедеон Спилет.— Әмма камил булмаган приборлар белән исәпләгәнлектән, теге чакта ялгыш нәтиҗәгә килмәдек микән, хәзер шуны ансат кына тикшерергә мөмкин дим.

— Дөрес әйтәсез, сөекле Спилет. Моны күптән эш-

ләргә кирәк иде. Хәер, теге чакта ялгышкан булсак та, ул ялгышлык биш градустан артмаска тиеш.

— Ничектер бит? — дип үзенекен тукыды журналист.— Халык яши торган җиргә без элек уйлаганнан якынрак тормыйбыз микән?

— Иртәгә белербез,— диде Сайрес Смит.— Әгәр вакыт тар булмаса, моны элегрәк тә тикшергән булыр идек.

Пенкроф та сүзгә кушылды.

— Сайрес Смит — ул безнең һәр эшнең чын остасы, аның ялгышуы мөмкин түгел. Әгәр утрау үзе урыныннан кузгалмаган булса, хәзер дә Сайрес Смит куйган урында торадыр!

— Карап карарбыз.

Иртәгесен секстан ярдәмендә утрауның теге чактагы инженер исәпләп чыгарган координатларын тикшерделәр.

Былтыр исәпләгәндә утрауның координатлары:

көнбатыш озынлыкның 150 белән 155 градусы арасында,

көньяк киңлекнең 30 белән 35 градусы арасында иде.

Икенче тапкыр төгәл исәпләүнең нәтиҗәсе:

көнбатыш озынлыкның 150 градусы 31 минуты, көньяк киңлекнең исә 34 градусы 57 минуты булды.

Димәк, гап-гади ысул белән исәпләвенә дә карамастан, Сайрес Смит беренче тапкырында ук координатларны шактый төгәл чыгарган, ялгышлык хәтта биш градустан да ким булган икән.

— Безнең хәзер секстан гына түгел, атласыбыз да бар бит,— дип искә төшерде Гедеон Спилет.— Хөрмәтле Сайрес, карыйк әле, Линкольн утравы Тын океанның кайсы төшенә урнашкан икән?

Герберт атлас алып килде,— ул Франциядә нәшер ителгән булса кирәк, географик атамалар французча иде.

Тын океан картасын ачып салдылар. Кулына җәзбә тоткан инженер утрауның урынын билгеләргә әзерләнгән иде, кинәт тынып калды:

— Тын океанның бу турысында утрау бар бит,— диде ул.

— Утрау бар? — дип сорады гаҗәпләнгән Пенкроф.

— Безнең утраудыр ул! — диде Гедеон Спилет.

— Юк. Бу утрау географик озынлыкның йөз дә илле өченче градусына, географик киңлекнең утыз җиденче градусы, унберенче минутына урнашкан, димәк Линкольн

утравыннан ул ике градус ярым көнбатыштарак, ике градус көньяктарак.

— Нинди утрау соң ул? — дип сорады Герберт.

— Табор утравы.

— Зурмы ул?

— Юк, кечкенә. Тын океан уртасында адашып калган бер кечкенә генә җир кисәге. Аңа үз гомерендә беркем аяк басмагандыр!

— Ә без аяк басарбыз,— диде Пенкроф.

— Без?

— Әйе, без, мистер Сайрес.

— Палубалы кораб ясарбыз да утырып юлга чыгарбыз. Корабны мин үзем идарә итәрмен. Табор утравы бездән еракмы?

— Якынча бездән йөз илле миль чамасы көньяк-көнбатышта урнашкан.

— Йөз илле миль генәме! Чүп кенә икән! — дип җибәрде Пенкроф.— Җил арттан исеп торганда ике тәүлектән анда булабыз.

— Нишләрбез соң без анда? — дип сорады журналист.

— Болай гына барабыз. Күреп кайтырга гына!

Бу җаваптан соң алар кораб ясарга һәм октябрьдә көннәр яхшы торганда утрауга барып килергә карар иттеләр.

Унынчы бүлек

Кораб ясау.— Икенче уңышны урып җыю.— Сумкалы аю аулау.— Файдасына караганда матурлыгы сокландырырлык үсемлек. — Диңгездә — кит. — Вайнъярдта ясалган гарпун.— Кит түшкәсен эшкәртү.— Кит мыегын файдалану.— Май азагы.— Пенкрофның дөньясы түгәрәкләнде.

Пенкрофның башына берәр уй керсә, аны гамәлгә ашырмыйча һич үзенә тынгылык тапмый торган кеше иде. Мәсәлән, хәзер аның күңеленә Табор утравына барып килергә кирәк дигән фикер кереп утырды, аның өчен шактый зур кораб кирәк иде,— һәм аны төзергә керештеләр.

Инженер корабның проектын төзеп бирергә мәҗбүр булды. Аның проекты диңгезчегә бик ошады.

Корабның озынлыгы утыз биш фут, киңлеге тугыз фут булырга тиеш. Суда утыру тирәнлеге һәм формасы уңыш-

лы килеп чыкса, ул тиз йөрешле булачак. Аның су асты өлеше алты футтан әлләни артмаска тиеш, шулай да кораб тотрыклы булсын өчен суда шактый тирән утырырга тиеш. Корабның борыныннан алып койрыгына хәтле палуба җәяргә, су үткәрми торган ике каютага төшү өчен ике капкач ясарга булдылар. Кораб зур шлюпка кебек җиһазландырылачак,— давыл вакытында маневр ясарга, көчле җилгә каршы текә барырга мөмкинлек бирүче, идарә итәргә асат җилкәннәр: кыекча грот, латин фокы, брифок, топсель, кливер җилкәннәре куелачак. Судноның яны биек булачак, тышлыгының такталары берсе өстенә берсе түгел, бәлки янәшә китереп тыгызлап кагылачак иде.

Корабны нинди агачтан ясарга соң? Утрауда күп үсә торган карама агачыннанмы, әллә нараттанмы? Наратка тукталдылар. Балта осталары телендә бу агач «тиз ярылучан» исәпләнсә дә, аның каравы наратны эшкәртергә җиңел, ул суда тиз череми иде.

Кораб ясауны, барлык вак-төякләренә хәтле уйлагач, Сайрес Смит белән Пенкрофның икесенә тапшырырга булдылар, чөнки язга хәтле ярты ел вакыт бар әле. Гедеон Спилет белән Герберт — элеккечә сунарчылык итәргә, ә Наб белән аның булышчысы Юп абзый — хуҗалыктагы үз вазифаларын башкарырга тиешләр иде.

Шулай итеп наратка тукталдылар. Тиз арада берничә агач кисеп аудардылар. Агачларның кабыгын каезлап, чын такта яручылар осталыгы белән такта ярдылар. Хәрабә белән Гранит стена арасындагы үзәнлек судно төзү урынына әверелде. Бер атнадан анда корабның утыз биш фут озынлыгындагы киле ята иде инде.

Сайрес Смит эшкә сукыр килеш тотынмады. Бүтән күп мәсьәләләр кебек, кораб төзү эше дә аңа таныш иде. Башта ук корабның сызымын кәгазьгә төшерде ул. Пенкроф бик яхшы ярдәмче булып чыкты, чөнки берничә ел Бруклин верфендә эшләгән, кораб төзү тәҗрибәсе бар иде. Байтак киңәшкәннән, җентекләп исәпләгәннән соң алар кораб корпусына өстәмә «кабыргалар» да куярга булдылар.

Пенкрофның кораб төзү эшенә нинди дәрт белән тотынуын күз алдына китерсәгез кирәк, ул ал-ялсыз эшләргә дә әзер иде.

Ул фәкать бер генә көнгә төзелештән китеп торды. Бу хәл 15 нче апрельдә бодайның икенче уңышын җыеп алган көнне булды. Икенче уңыш та беренчесе кебек

үк яхшы чыкты, алдан көтелгән кадәр ашлык җыеп алдылар.

Пенкроф үзләренең байлыгын үлчәп бетергәч:

— Мистер Сайрес, бодай биш буассо булды! — диде.

— Биш буассо,— дип кабатлады инженер.— Һәр буассода йөз утыз мең бөртек бар дип исәпләгәндә, барысы алты йөз илле мең чәчүлек орлык була.

— Саклау өчен беразын гына алып калырбыз да, калганын тагын чәчәрбез,— диде диңгезче.

— Ярый, Пенкроф, риза. Әгәр уңышны тагын да шул кадәр җыеп ала алсак, ул — дүрт мең буассо була дигән сүз.

— Аннары икмәк пешерербезме?

— Әйе, икмәк пешерербез.

— Тегермән салырга туры килә алай булгач?

— Тегермән дә салырбыз.

Өченче тапкыр чәчү өчен иген басуын шактый киңәйттеләр һәм, туфрагын бик яхшылап эшкәрткәч, бодайны иплән чәчтеләр. Иген игү эше төгәлләнгәч, Пенкроф тагын кораб төзүгә тотынды.

Гедеон Спилет белән Герберт ул арада һәр көн якынтирәгә ауга йөрделәр. Мылтыкларын корган килеш, атарга әзер тотып, еш кына Ерак Көнбатыш урманнарының тикшерелмәгән куе җирләренә дә кергәләделәр. Бернична тапкыр ерып чыккысыз ешлыкка тап булдылар, агачлар, гүя урын җитмәгәндәй, бер-берсенә кысылып диярлек үскәннәр. Мондый куе урманнарны тикшерү шактый кыен иде. Куе яфраклар арасыннан кояш нурлары чак үтеп керә, биредә адашуың да бик мөмкин, шуңа күрә Гедеон Спилет һәрвакыт үзе белән компас алып йөри иде. Куелыкта киек тә аз очрый, чөнки кошларга, җәнлекләргә иркенләп йөрер урын юк. Мәгәр безнең аучылар апрель ахырында үлән белән тукланучы өч зур җәнлек аттылар. Болар сумкалы аюлар иде (Грант күленең төньяк ярында алар бер тапкыр сумкалы аю күргәннәр иде инде); җәнлекләр агачның куе ябалдашларына яшеренеп калмакчылар иде, аучылар төз атып аларны җиргә егып төшерделәр. Аучылар аюларның тиресен тунап, Гранит сарайга алып кайттылар, сульфат кислотасы белән эшкәрткәч, иләгәч, тире йомшарып китте, үз кирәкләренә файдаланырлык булды.

Бервакыт алар ауда йөргәндә тагын бер кыйммәтле табышка юлыктылар. Аны табу бәхете Гедеон Спилет өлешенә тиде.

30 нчы апрель көне иде бу. Ул көнне аучылар Ерак Көнбатыш урманының көньяк-көнбатыш ягында йөриләр иде. Герберттан илле адымлап алда барган журналист бер аланга килеп чыкты,— андагы агачлар, гүя артка чигенеп, кояш нурларына үтеп керергә мөмкинлек биргәннәр диярсең.

Гедеон Спилет гаҗәеп хуш ис тоеп туктап калды, бу ис нәни генә орлык тартмачыклары һәм чәчәк чуклары белән бизәлгән озын төз кәүсәле бер үсемлектән килә иде. Журналист аның берничә ботагын сындырып алды да үсмер егет янына килеп, аңа күрсәтте:

— Герберт, кара әле, бу нәрсә?

— Бу чәчәкне кайдан өздегез сез, мистер Спилет?

— Әнә теге аланнан, анда күп үсә ул.

— Бу табыш өчен Пенкроф сезгә гомер буе рәхмәт укыячак, мистер Спилет.

— Әллә тәмәкеме бу?

— Әйе шул. Беренче сортлы булмаса да, чын тәмәке бу.

— Пенкроф бик куаныр инде! Барысын үзе генә тартып бетермәс әле! Безгә дә өлеш чыгарыр!

— Мистер Спилет, тәмәке тапканны Пенкрофка әлегә әйтми торабыз, яме. Башта тәмәкене әзерлик һәм бер дә бер көнне аңа тәмәке тутырылган төрепкә бүләк итәрбез.

— Һәйбәт тәкъдим бу, Герберт, ул чакта Пенкроф дустыбызның дөньясы түгәрәкләнәчәк, әйеме?

Журналист белән Герберт кыйммәтле яфракларны кочак тутырып җыйдылар да Гранит сарайга яшереп кенә алып кайттылар. Алар шул хәтле сакланып эшләделәр ки, әйтерсең лә Пенкроф чик күзәтчесе, ә болар контрабандистлар иде.

Серне фәкать Сайрес Смит белән Набка гына чиштеләр. Ә тәмәке яфракларын киптереп, турап, кайнар таш өстендә тоткан арада диңгезче берни сизмәде. Моңа бер айлап вакыт китте, кораб төзү белән мавыккан Пенкроф өйгә кичләрен бик соң кайтып йөри, әлеге хәллләрдән бихәбәр иде.

Беренче май көнне шулай да аңа яраткан эшен бүлеп торырга туры килде, иптәшләре белән бергә аңа сирәк очрый торган ауга катнашырга кирәк булды.

Инде ике-өч көннән бирле Линкольн утравы янында ярдан ике-өч миль эчкәре ачык диңгездә бик зур кит йөзеп йөри иде. Ул Капп яки көньяк киты булса кирәк.

Дингезче бер көнне иптәшләренә:

— Ничек итеп берәр хәйләсен табарга да китка гарпун кадарга соң? — диде.— Их, әгәр дә безнең рәтлерәк судныбыз һәм таза гарпуныбыз булса, мин үзем беренче булып китны ауларга чыгар идем: «Үлсәм үләм, барыбер китны җиңәм», дип ант итәр идем.

— Ә мин сезнең гарпун белән кит аулаганыгызны карап торыр идем,— диде Гедеон Спилет.— Ул бик кызыктыр.

— Кызыгын кызык та, тик хәтәр эш. Әмма безнең коралыбыз юк, кит аулау бәхетеннән мәхрүм шул без, шуңа күрә маташып торасы да юк,— диде инженер.

— Гаҗәп хәл, кит бу географик киңлеккә ничек килеп эләкте икән соң? — диде Гедеон Спилет.

— Нигә гаҗәпләнәсез, Гедеон, без бит Тын океанның Англия һәм Америка балыкчылары «кит басуы» дип йөрткән өлешендә яшибез. Китлар Көньяк ярымшарда нәкъ шушы тирәләрдә, Яңа Зеландия белән Көньяк Америка арасында күп очрый да инде,— диде Герберт.

Пенкроф та сүзгә кушылды:

— Дөрес сүзгә җавап юк. Аларның шушы вакытка хәтле биредә очрамаулары хәтта аңлашылмый да. Хәер, аннан ни мәгънә, барыбер яннарына якын бара алмыйбыз,— дип Пенкроф авыр көрсенде дә үз эшенә тотынды.

Мәгълүм ки, һәрбер дингезченең эчендә балыкчы җене утыра. Балык тотуның хозурлыгы турыдан-туры тоткан балыкның зурлыгына бәйләнгән икәнен искә төшерсәк, китны күргәч, гарпунчының күңелендә нинди давыл купканын күз алдына китерүе кыен булмастыр.

Хикмәт хозурлыкта гына булса бер хәер иде! Утрау хуҗалары нинди кыйммәтле табышның кулдан ычкынуын күреп торалар. Китның мыегы һәм мае аларга бик ярап куяр иде.

Ә кит гүя бу утрауны ташлап китәргә уйламый да иде. Утрау хуҗалары аны әле Күзәтү яссылыгыннан, әле Гранит сарай тәрәзәсеннән күреп калалар. Герберт белән Гедеон Спилет ауга китмәгән чакларында, Наб кухня эшеннән бушаган араларда чиратлашып күзәтү трубасыннан карыйлар.

Беркөнне кит Берләшү бухтасына килеп керде һәм Казна борыныннан алып Тырнак борынына хәтле бухта суын сөреп йөри башлады; искиткеч көчле койрык йөзгече ярдәмендә, аңа таянып, ул алга таба ыргыла-ыргыла йөзә, сәгатенә унике мильгә җитә язган тизлек белән

алга бара иде. Кайвакыт утрауга якын ук килә, аны гади күз белән дә әйбәт күрерлек була. Ул чыннан да көньяк киты икән: төсе кап-кара, башы Төньяк ярымшардагы китларныкына караганда җәлпәгрәк иде.

Борын тишекләреннән һавага бик биеккә әллә пар, әллә су фонтаны атканы күренә. Гаҗәп, табигать белгечләре һәм кит аулаучылар әле хәзергә хәтле аның пармы яки сумы икәнен белми үзара бәхәс алып баралар. Ул — пар, тик салкын һавада шундук тамчыга әйләнеп чәчелә дигән фараз яши.

Кыскасы, имезүчеләрнең бу иң зур вәкиле утрау хуҗаларының бөтен гамен биләде. Хәтта Пенкрофны эшеннән бүленергә мәҗбүр итте. Моның ахыры шуңа барып җитте ки, диңгезче көне-төне китны ничек итеп ауларга икән дип уйлый башлады,— бала-чаганы да тыелган эш шулай кызыктыра бит. Кит хәтта аның төшенә кереп йөдәтте. Әгәр дә кораб төзелеп беткән булса, гарпуннары да булса, ул, ике дә уйлап тормыйча, диңгезгә кит ауларга чыгып киткән булыр иде инде.

Боларның кулыннан килмәгән эшне башкарырга очраклы хәл ярдәм итте. 3 нче майда кухня тәрәзәсеннән диңгезне күзәтеп торган Наб кинәт: кит сайлыкка эләккән, дип кычкырып җибәрде.

Ауга барырга җыенган җирдән Герберт белән Гедеон Спилет мылтыкларын ташлап, ә Пенкроф балтасын атып бәреп, диңгез буена чаптылар. Сайрес Смит белән Наб та алар артыннан кит яткан сайлыкка таба йөгерделәр.

Гранит сарайдан өч миль ераклыктагы Табылдык борыны сайлыгына кит, мөгаен, су күтәрелгәндә кереп калгандыр да су чигенгәндә аннан чыгып өлгермәгәндер. Тегеләйме-болаймы, безнең дуслар, вакытны әрәм итмичә, аның чигенү юлын кисәргә ашыгалар иде.

Алар, кулларына сөңгеләр, очлы тимерләр тотып, Табылдык борынына таба йөгерделәр. Менә Рәхмәт елгасы күперен уздылар, менә елганың уң як ярына чыктылар, менә комлыкка җиттеләр, һәм егерме минут та үтмәгәндер, килбәтсез зур хайван түшкәсе янына килеп җиттеләр, баш өстендә кошлар көтүе әйләнә иде инде.

— Ай-яй, куркыныч нәрсә икән! — дип шаккатып кычкырып җибәрде Наб.

Бик дөрес бәя иде бу: көньяк китларының бу вәкиле чын гигант иде, озынлыгы сиксән фут, ә авырлыгы йөз илле мең кадактан да ким булмастыр.

Су әле кимүдән туктамаган. Кит нигәдер хәрәкәтсез ята, койрыгын да бәргәләми, йөзеп китәргә дә талпынмый.

Су чигенүдән туктагач, безнең дуслар кит тирәли әйләнеп чыктылар һәм аның нигә селкенмичә ятканын аңладылар.

Кит үле иде: аның сул янтавында гарпун тырпаеп тора иде.

Гедеон Спилет ашыгып:

— Димәк, безнең тирәгә дә кит аулаучы кораблар килеп чыга икән! — диде.

— Нигә алай әйтәсез? — диде диңгезче.

— Әнә бит гарпун...

— Юк, мистер Спилет, ул дәлил түгел. Кайбер китлар гарпун кадалган килеш меңәр миль ераклыкка йөзеп китәләр, бәлкем, безнең китны Атлантик океанның иң төньягында җәрәхәтләгәннәрдер, ә ул Тын океанның көньягына җан бирергә килгәндер.

Гедеон Спилет Пенкрофның сүзләренә ышанып җитмәде:

— Шулай да...

— Бу бик мөмкин хәл,— дип раслады Сайрес Смит,— Кая, гарпунын карыйк әле. Бәлкем, кит аулаучылар, гадәтләренчә, гарпунга кораб исемен язганнардыр!

Пенкроф китның янтавыннан гарпунны тартып алды да:

«Мария-Стелла. Вайнъярд» [1],— дип язылган сүзләрне укыды.

— Кораб Вайнъярдтан! Минем туган яктан! — дип кычкырып җибәрде Пенкроф.— «Мария-Стелла»! Кит аулаучы атаклы кораб ул! Мин аны яхшы беләм бит! Кит аулаучы кораб Вайнъярдныкы булып чыкты.

Диңгезче, гарпунны болгый-болгый, газиз туган җиренең исемен тәэсирләнеп кат-кат тәкрарлады!

«Мария-Стелла» бирегә йөзеп килеп чыгар да, матрослары китны үзләренә даулар дип өмет итәсе дә юк иде, шуңа күрә кит түшкәсен, бозылганчы, тиз-тиз кисәкләргә бүлгәләргә карар иттеләр. Ничә көннән бирле корбан артыннан сагалап очып килгән ерткыч кошлар шундук үле китка ябырылдылар; безнең дусларга аларны мылтыктан ата-ата куып җибәрергә туры килде.

---

[1] Нью-Йорк штатындагы порт. *(Автор искәрмәсе.)*

Бу ана кит булып чыкты — имчәкләреннән әле сөт килә иде. Табигать галиме Диффенбахның әйтүенчә, аның сөте сыер сөтеннән һич аерылмый, төсе дә, тәме дә, куелыгы да сыер сөтенеке кебек.

Пенкроф бер вакытларны кит аулаучы корабта йөзгән иде; шуңа күрә кит түшкәсен эшкәрткәндә ул җитәкчелек итте. Ярыйсы ук күңелсез бу эш өч көнгә сузылды, ләкин берсе дә аннан баш тартмады, хәтта Гедеон Спилет та, Пенкроф әйтүенчә, «сер сынатмады».

Кит маен ике фут калынлыгындагы телемнәргә бүлделәр, аннары авырлыгы меңәр кадак чамасы кисәкләргә турадылар һәм зур балчык чаннарга салып эреттеләр. Чаннарны яр буена ук китерделәр, чөнки Күзәтү яссылыгының һавасын май исе белән бозасылары килмәде. Эреткәч, майның өчтән ике өлеше кимеде. Әмма май шул хәтле күп иде ки, китның теленнән генә дә — алты мең кадак, ә аскы иреннән дүрт мең кадак эрегән май чыкты.

Шулай итеп утрау хуҗаларының бик озакка җитәрлек стеарины һәм глицерины да булды. Китның мае гына түгел, мыегы да эшкә ярады. Гәрчә Линкольн утравында зонтик тоту, корсет кию модада булмаса да, мыекны кулланыр әмәлен таптылар.

Мыек дигәне — кит авызының өске казнасында ике якка сыгылмалы яссы озын сөяк тырпаеп тора, аларның саны сигез йөзгә җитә. Һәр мыек алты фут чамасы озынлыкта булып, бер башы очлаеп килгән. Тезелеп киткән ул мыеклар рәте ике бихисап зур «таракны» хәтерләтә. Кит әнә шул мыекларга эләгеп кала торган вак җанварлар, балыклар, моллюскалар белән туклана.

Эшне тәгәлләп, калган кит түшкәсен ертлач кошлар ихтыярына тапшырдылар да, аларның комсыз томшыклары китның валчыгын да калдырмыйча талап бетерәчәгенә ышанып, утрау хуҗалары өйләренә кайтып киттеләр һәм үзләренең көндәлек мәшәкатьләренә чумдылар.

Ләкин Сайрес Смит судно төзү эшенә керешкәнче нәрсәдер әмәлләргә тотынды, тирәсенә җыелган иптәшләре нәрсә килеп чыгар икән дип түземсезләнеп аны күзәтергә керештеләр. Ул бер дистә кит мыегын алды, һәрберсен алтышар кисәккә бүлеп чыкты, баш-башларын юнып очлады.

Инженерның аларны очлап бетерүен күргәч, Герберт аңардан:

— Боларны нишләтәбез инде, мистер Сайрес? — дип сорады.

— Бүре, төлке, ягуар аулыйбыз,— диде Сайрес Смит.

— Хәзерме?

— Юк, кыш җиткәч, боз каткач.

— Аңлап җиткермәдем...

— Хәзер аңларсың, дустым. Мин уйлап тапкан хәйлә түгел бу. Аны Американың элек русларныкы исәпләнгән өлкәсендә [1] алеут аучылар куллана торган булган. Менә тыңлагыз, дусларым, көннәр салкынайткач, мин бу кит мыекларын бөҗра итеп бөгәм дә су сибеп бозга катырам, алар боз эчендә турая алмыйлар; аннары шуларны туң май эченә кыстырып, кар өстенә ташлыйм. Ач җәнлекләр аны кабып йоткач нишли дисезме? Җәнлекнең ашказанында җылыдан туң май эри, һәм кит мыегы турая, очлы башлары ашказанына кадала.

— Шәп хәйлә икән бу! — дип сокланды Пенкроф.

— Дары һәм пулялар янга кала,— диде Сайрес Смит.

— Тозакларга караганда да әйбәтрәк икән бу! — дип кушылды Наб.

— Түземсезләнеп кышны көтәбез болай булгач!

— Әйе, кышны көтик!

Кораб төзү эше көннән-көн алга барды, ай ахырына корпусны яртылаш тышлый алдылар. Инде хәзер үк корабның әйбәт булачагын, суда яхшы йөзәчәген чамаларга мөмкин иде.

Пенкроф бик дәртләнеп эшләде, тимердәй тазалыгы аркасында гына ару-талуны белми иде. Ә иптәшләре аның тырышлыгы өчен зур бүләк әзерләделәр. 31 нче май — аның гомерендә иң бәхетле көн булды.

Ул көнне Пенкроф ашап туйгач, өстәл яныннан торып китәргә дип кузгалган иде, кемдер аның җилкәсенә кулын салды.

Бу Гедеон Спилет иде.

— Туктагыз әле, кадерле Пенкроф, нигә кузгаласыз? Десертны оныттыгызмыни?

— Рәхмәт, мистер Спилет, вакытым юк.

— Ичмаса берәр чокыр кофе эчегез, дустым.

— Эчәсем килми.

— Ә тәмәке?

---

[1] Аляска 1741 елда руслар тарафыннан ачыла һәм Россиянеке була, әмма 1867 елда патша хөкүмәте аны (Алеут утраулары белән бергә) АКШка сата.

Пенкроф өстәл яныннан сикереп торды, журналистның аңа тәмәке тутырылган төрепкә, Гербертның утлы куз сузганын күргәч, мөлаем йөзе агарып китте.

Үзе нидер әйтмәкче булды, әмма авызыннан сүзе чыкмады; төрепкәне тартып алды да авызына капты, ут көйрәтеп, тирән итеп әчкә бер-бер артлы төтен суырды.

Өскә хуш исле соргылт төтен болыты күтәрелде, төтен эченнән аның куанып сөйләнгәне ишетелде:

— Тәмәке бит бу, валлаһи, чын тәмәке!

— Әйе шул, Пенкроф, менә дигән тәмәке! — диде Сайрес Смит.

— Йа тәңрем! Һәр нәрсәне юктан бар иткән шәфкать иясе! Хәзер утравыбызда җаның ни тели, шул бар! — дип шатланып кычкырып җибәрде Пенкроф.

Пенкроф комсызланып-комсызланып тәмәкесен тартты да тартты.

— Тәмәкене кем тапты, Герберт, синме? — дип сорады.

— Юк, Пенкроф, мистер Спилет тапты.

— Мистер Спилет! — Пенкроф журналист дустын каты итеп күкрәгенә кысты. Тегесенең үз гомерендә дә мондый эскәнҗәгә эләгергә туры килгәне булмагандыр. Тыны капланып:

— Уф, Пенкроф! — дип ыңгырашып куйды.— Рәхмәтегезне Гербертка да әйтегез: тәмәке икәнен ул таныды; тәмәкене киптереп әзерләгән Сайрес Смитны да, серне чишмәгән Набны да рәхмәттән мәхрүм итмәгез.

— Дусларым! Мин сезнең яхшылыгыгызны гомерем буе онытачак түгелмен! Бурычлы булып калмам, сезгә дә икеләтә кайтарырмын.

Унберенче бүлек

Кыш.— Йон әзерләү.— Тула басу.— Пенкрофның бәйләнчек фикере.— Кит мыегыннан алдавыч әзерләү.— Альбатросның ярдәме.— Киләчәк гасырлар ягулыгы.— Топ белән Юп.— Өермә.— Кош кетәгендә җимерекләр.— Сазлыкка сәяхәт.— Сайрес Смит өйдә кала.— Коены тикшерү.

Июнь аенда кыш керде, төньяк киңлектәге декабрь аена туры килә иде ул. Жылы кием хәстәрен күрергә вакыт җитте.

Утрау хуҗалары муфлоннарның йонын кыркыдылар. Яхшы сыйфатлы бу йонны эшкәртеп, кием тегү өчен

тукыма әзерләргә кирәк иде. Үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, аларның йонны язу, тетү, басу, эрләү, кату машиналары юк бит; йон эрләү, йон туку станогы да юк иде. Йонны эрләп, сугып тормыйча, иң гади ысул белән эшкәртергә туры килде. Сайрес Смит йонның агач бәләк белән әвәләгәндә басылу үзлеген белә, шуны файдаланырга уйлады, ягъни ул гап-гади тула басарга булды. Тула басуы әлләни кыен түгел икән, тула үзе тупас күренсә дә, бик җылы була икән. Муфлоннарның йоны кыска, тула басу өчен яраклы йон иде.

Инженер дуслары ярдәмендә (Пенкрофка да кораб төзүен ташлап торырга туры килде) әзерлек эшләре башлады: башта йонны майлы кердән арындырырга кирәк иде. Моның өчен йонны җитмеш градуска хәтле җылытылган сулы чанга салып, бер тәүлек буе тоттылар; аннары содалы суда әйбәтләп юдылар һәм пресс астына салып сыктылар. Тула басарга йон әзер иде. Тыгыз, тупас тула Европа һәм Американың промышленность үзәкләрендә арзан бәяләнсә дә, «Линкольн утравы базарында» аның бәясе «кыйммәт» йөри иде. Тула басу борын-борыннан килгән һөнәр, дөньяда иң беренче постауны да Сайрес Смит тәкъдим иткән әлеге ысул белән басканнар бит.

Инженерның техника өлкәсендәге зур белеме тула басу машинасын ясаганда да ярдәм итте. Тула басу эшенә ул шарлавыкның әлегә хәтле әрәм яткан көчен файдаланды.

Машинаның төзелеше бик борынгыча иде: таза агач рам, бәләкләрне менгерә-төшерә торган чөй беркетелгән чарык һәм йон салынган тагарак. Ничәмә-ничә гасырлар буе шундый гади ысул белән бастылар туланы, ә аннары уйлап табучылар бәләкләрне компресс белән алыштырдылар һәм йонны басмый, ә түши генә башладылар.

Сайрес Смит тула басу эшен дә үзе җитәкләде. Йон бөртекләре йомшак, шома булсын, бер-берсенә әйбәт керешсен һәм басканда өзелмәсен өчен йонны башта сабынлы су белән чылаттылар. Йон бөртегендә күзгә күренмәслек нәни сырлар — буразналар бар, шулар аркасында йон бөртекләре бер-берсенә керешә, тыгызлана һәм тула хасил була. Тула исә кышкы кием тегәргә дә, йоклаганда ябынып өчен юрган итеп кулланырга да яраклы иде. Аны меринос йонынннан тукылган нәфис йон тукыма, муслин, Шотландия кашемиры, штоф, репс, кытай атласы, Орлеан йоны, альпаг, юка постау, фла-

нель белән чагыштырырга да мөмкин түгел иде, әлбәттә. Әмма ул «Линкольн туласы» иде. Линкольн утравында һөнәрчелекнең тагын бер тармагы барлыкка килде.

Утрау хуҗаларының җылы, әйбәт киемнәре, җылы юрганнары булды, кышкы салкыннар хәзер куркыныч түгел иде инде аларга.

Июньнең егермеләренә көннәр тәмам суытты. Пенкроф та эшен ташларга мәҗбүр иде, шуңа кәефе кырылды. Хәер, корабны язга хәтле төзеп бетерәчәгенә ышана иде ул.

Тизрәк Табор утравын барып күрү теләге аның мазасын алды. Сайрес Смит бу сәяхәтне нигәдер хупламый, анда баруның мәгънәсен күрми, таш кыядан гына торган, үсемлексез утрауда безгә ярдәм кулы сузардай кешеләр табылмаячак дигән фикерне алга сөрә иде. Булыр-булмас корабка утырып йөз илле мильлек ерак юлга чыгу уен эш түгел ди. Әгәр алар Табор утравына да җитә алмый, Линкольнга да кире әйләнеп кайтмасалар, ачык диңгездә нишләрләр? Сайрес Смит еш кына Пенкроф алдына шундый сораулар куя, әмма Пенкроф һаман үз ниятеннән кайтмый иде, ни өчен җилкенгәнен ул үзе дә төшенеп җитми иде ахрысы...

Бер көнне инженер аңа:

— Бик гаҗәпләнәм мин сезгә, дустым, Линкольн утравын гел мактап туя алмый идегез, аны ташлап китүе кызганыч булыр инде дип сөйли идегез, хәзер үзегез шуны ташлап китәргә маташасыз.

— Берничә көнгә генә бит, мистер Сайрес,— диде Пенкроф.— Күрше утрау белән танышып кайтыр өчен генә. Барып җитәм дә шундук кире борылам, нинди утрау икәнен генә күрәсем килә!

— Ул Линкольн утравы белән чагыштырырлык та түгел бит.

— Анысына шикләнмим мин.

— Шулай икән, нигә хәвефле юлга чыгарга атлыгасыз соң?

— Табор утравынданиләр бар икәнен беләсем килә!

— Нәрсә бар дисең анда!

— Каян беләсең бит!

— Әгәр юлда өермәгә очрасаң?

— Язгы өермә куркыныч түгел ул,— диде Пенкроф.— Ул-бу булыр дип шикләнсәк, минем белән Герберт кына барсын.

Инженер аның иңенә кулын салды:

— Пенкроф, исеңдә тот, дустым, әгәр сез һәм язмыш ихтыяры белән безнең улыбыз булып киткән Герберт бәлагә тарысагыз, без ул хәсрәтне кичерә алырбызмы.

— Мистер Сайрес, без сезне андый хәсрәткә салмабыз,— диде үз уеның хаклыгына нык ышанган диңгезче.— Хәер, хәзер ул турыда сөйләшергә иртә. Вакыты җиткәч, бу әңгәмәгә кире кайтырбыз әле. Корабыбызның ныклыгын, ничек җиһазланганын үз күзегез белән күргәч, бергәләп утрау әйләнә сәяхәт иткән чакта ничек йөзүен сынап карагач, үзегез үк юлга чыгарга рөхсәт итәрсез. Чын әгәр, сезнең кораб әйбәт булачак! Менә күрерсез.

Диңгезченең сүзләреннән соң инженер җиңелдә.

— Әйбәт булсын, тик минеке генә түгел, *безнең* кораб диегез, Пенкроф.

Әңгәмә шунда өзелде, әмма бу турыда сүз әледәнәле кузгала торды, тик Сайрес Смит та, диңгезче дә үз фикерләрендә калдылар.

Июнь ахырында кар ятты. Утрау хуҗалары мал утарларында күп итеп печән әзерләгәннәр иде, шуңа күрә көн саен барып йөрүнең кирәген тапмадылар, атнага бер тапкыр бару җитә дип исәпләделәр.

Киек җәнлекләргә тозаклар яңадан куелды. Сайрес Смит уйлап тапкан алдавычны беренче тапкыр кулланып карарга булдылар. Бозга катырган, тышына калын итеп май сыланган кит мыегы бөҗраларын урман авызына гадәттә киекләр күлгә су эчәргә төшә торган сукмакларга ташлап-ташлап киттеләр.

Инженерның куанычыннан алеут балыкчылары куллана торган «җим» шәп нәрсә булып чыкты. Ул җимгә дистәдән артык төлке, берничә кабан, хәтта бер ягуар да капты: кит мыегы аларның ашказанын тишкән иде.

Шунысын да әйтергә кирәк, утрау хуҗалары тышкы дөнья белән элемтәгә керергә дә омтылып карадылар.

Гедеон Спилет үзләренең язмышы турында шешәгә язу салып, диңгезгә агызсак, яисә күгәрченгә тагып очырсак, кешеләр яшәгән җиргә барып ирешмәс микән дип инде күптәннән хыялланып йөри иде. Әмма күгәрчен яки шешәгә өмет баглау күрәләтә тилелек булыр иде, чөнки Линкольн утравы кешеләр яши торган җирләрдән мең ике йөз миль еракльтта урнашкан иде!

Утызынчы июньдә Герберт мылтыктан атып, бер альбатросның аягын җәрәхәтләде, һәм аны мең мәшә-

катьләр чигеп тотып ала алдылар. Канатларын җәйгән чагында озынлыгы ун футка җитә торган бииһая зур күркәм кош иде ул. Альбатрослар гадәттә бик еракка очалар, хәтта Тын океанны да кичеп чыга алалар.

Кошның җәрәхәте тиз төзәлде. Герберт аны кулга иялəштереп, утрауда калдырырга бик теләгән иде, тик Гедеон Спилет Тын океанның яр буйлары белән элемтәгә керү өчен кошны хәбәр илтүче итеп файдаланырга мөмкин дип ышандыргач, Герберт риза булды. Альбатрос бирегә кешеләр яши торган яклардан очып килгән, димәк ирекка җибәргәч, ул, һичшиксез, туган ягына кайтып китәчәк иде.

Кем белсен, күңелендә әледән-әле «гәзитче корты» кузгалып куйгалаган Гедеон Спилет, бәлкем, Линкольн утравы кешеләренең маҗаралы тормышы турында мавыктыргыч очерк язарга һәм аны язмыш ихтыярына тапшырырга хыялланадыр! «Нью-Йорк геральд» газетасы хәбәрчесенең даны дөньяга шауламас дисеңме! Әгәр дә аның хәбәре хөрмәтле баш редактор Джон Бенет кулына эләксәме, ул чагында хәбәр басылган газетаны укучылар бер-берсеннән тартып алып укыячак әле!

Гедеон Спилет кыска гына хәбәр язып, аны су үткәрми торган тукымадан тегелгән янчыкка салды һәм, әгәр бу хәбәр табыла калса, «Нью-Йорк геральд» газетасы редакциясенә тапшыруыгызны үтенәбез дигән язу да өстәде. Янчыкны албатросның аягына түгел, муенына бәйләделәр, чөнки кошның озын юлда су өстенә куныр ял итүе ихтимал. Ниһаять, җилдәй җитез канатлы хәбәрчене ирекка җибәрделәр һәм аның көнбатышка, томанлы ераклыкларга таба китеп югалуын моңаеп карап калдылар.

— Ул кая юл тотты икән? — дип сорап куйды Пенкроф.

— Яңа Зеландиягә,— дип җавап бирде Герберт.

Гәрчә ул почтальонга ышаныч чамалы булса да, Герберт кош артыннан хәерле юл теләп калды.

Кышкы көннәр өй эчендәге эшләр белән мәшәкатьләнеп узды: алар кием-салым ямадылар, төрле вактөяк әйберләр ясадылар; кораб өчен аэростат тышчасыннан җилкәннәр кисеп тектеләр. Тышчаның тукымасы бетмәс-төкәнмәс иде әле...

Июль аенда рәхимсез салкыннар китте, әмма Гранит сарай эче җылы иде, ягулыкны җәлләмәделәр. Сай-

рес Смит зур залга икенче камин чыгарды, кышкы озын кичләрдә дуслар камин каршысында җыелышып утыралар иде. Вакытларын бушка уздырмыйлар: эшләрен сөйләшә-сөйләшә эшлиләр, ял сәгатьләрендә китап укыйлар.

Шәмнәр белән яктыртылган зур залда балкып янган камин каршысында алар туклыклы аштан соң, тышта буран улавына колак салып, кофе эчәләр, хуш исле тәмәке тартып, чын мәгънәсендә хозурлык кичереп утыралар иде. Туганнарыннан читтә, хәбәр-хәтерсез яшәгән кешеләрне әгәр дә үз хәлләреннән канәгать була ала дияргә мөмкин икән, алар үз хәлләреннән бик канәгать иделәр. Дөрес, һәрвакыт алар туган яклары, дус-ишләре, куәтле Америка республикасы, аның үсеп килүче даны турында гәп куерталар.

Кушма Штатларның эчке эшләрен яхшы белгән Сайрес Смит иптәшләренә күп хәбәрләр сөйли, үзенең фикерләрен, үз фаразларын алар белән уртаклаша, ә иптәшләре аны бик кызыксынып тыңлыйлар иде

Көннәрдән бер көнне Гедеон Спилет инженердан сорады:

— Әйтегезче, кадерле Сайрес, көн-төн алга барган промышленность һәм техника киләчәктә иртәме-соңмы үсүдән туктап калмасмы соң? Ничек дип уйлыйсыз?

— Үсүдән туктар?! Ни өчен?

— Җир асты байлыкларының иң кыйммәтлесе — ташкүмер бетүдән!

— Дөрес, ташкүмер — иң кыйммәтле казылма байлык. Табигать гүя моны раслар өчен алмазны барлыкка китергән; ә алмаз — кристаллашкан углерод ул, ягъни шул ук ташкүмер токымы.

Пенкроф та сүзгә кушылды:

— Мистер Сайрес, әллә пар казаннары астына ташкүмер урынына алмаз яга башлаячаклар димәкче буласызмы?

Сайрес Смит көлеп җибәрде:

— Юк ла, дустым!

— Килер бер көн, ташкүмер катламнары бушап калыр, сез моңа каршы килә алмассыз,— диде Гедеон Спилет.

— Ташкүмер катламнары әле шул хәтле бай, йөзләгән мең эшче елына җир астыннан йөз миллион квинтал ташкүмер чыгарса да, ул бетмәячәк.

Гедеон Спилет аңа каршы төште:

— Ташкүмерне куллану артканнан арта бара. Озакламый йөз мең эшче урынына ике йөз мең эшче күмер казыячак, күмер чыгару икеләтә артачак.

— Анысын дөрес әйтәсең. Тик Европада күмер катламнары бушап калса да (хәер, яңа машиналар ярдәмендә киләчәктә бик тирән катламнарны да эшкәртә башлаячаклар), Америка һәм Австралиянең күмер катламнары промышленностьны күмер белән бик озак тәэмин итәчәк әле.

— Күпме соң?

— Ким дигәндә ике йөз илле, өч йөз ел.

— Безнең буын юана ала икән әле, ә безнең оныкларыбызның оныкларының хәле мөшкел,— дип куйды Пенкроф.

— Алар бүтән берәр нәрсә уйлап табарлар,— диде Герберт.

— Шулай дип өметләнергә туры килә, югыйсә ташкүмер булмаса, машиналар туктый, машиналар булмагач, тимер юллар, пароходлар, фабрикалар, кыскасы, хәзерге техника прогрессы тарафыннан барлыкка китерелгән нәрсәләр һәммәсе туктап калачак.

— Нәрсә уйлап табарлар икән, мистер Сайрес, сез күз алдына китерә аласызмы? — дип сорады Пенкроф.

— Азмы-күпме күз алдына китерәм, дустым.

— Ташкүмерне нинди ягулык алыштырыр соң?

— Су,— диде инженер.

— Су? — дип кайтарып сорады Пенкроф.— Пароход һәм паровоз учакларын су җылытачакмы, суны су кайнатачакмы?

— Әйе, тик әүвәл суны өлешләргә таркатырга туры киләчәк,— дип аңлатма бирде Сайрес Смит.— Бу эшне электр башкарачак. Электр кеше кулында куәтле көчкә әвереләчәк. Мәгълүм булганча, бөек ачышлар берсе артыннан берсе ясала, һәм бер-берсен тулыландыра килә, бу табигатьнең акыл ирешмәслек законы. Ышанам ки, килер бер заман, су ягулыкны алыштырачак; аның водород һәм кислород өлешләре аерым-аерым кулланылачак; алар бетмәс-төкәнмәс көчле яктылык һәм җылылык чыганагына әвереләчәк; ташкүмергә кая ул аларга җитү! Килер бер көн, дусларым, пароходларның трюмнарына, паровозларның тендерларына ташкүмер төямәсләр, куертылган газ тутырылган ике баллон гына куярлар. Ул газлар янганда көчле җылылык бүленеп чыгар. Димәк, куркыр урын юк. Дөньяда кешеләр яшәгәндә

җир байлыклары, яктысы, җылысы, үсемлекләр, минераль байлыклар һәм хайваннар кешеләр файдасына хезмәт итәчәк. Кыскасы, ышанам ки, ташкүмер ятмалары бушап калса, кешеләр суны ягулыкка әверелдерәчәк. Су — киләчәк гасырлар ташкүмере.

— Их, шуларны үз күзем белән күрер идем,— диде диңгезче.

Моңа чаклы бер сүз әйтми тыңлап торган Наб:

— Син дөньяга иртәрәк тугансың шул, Пенкроф,— дип куйды.

Набның сүзеннән соң әңгәмә өзелеп калды, чөнки Топның тәшвишле итеп өргәне ишетелде. Вакыт-вакыт эт үзен ничектер бик сәер тота иде: ул өй түрендәге кое янына чабып бара да гасабиланып өрә-өрә аның тирәли йөгереп йөри башлый. Шушы кыланышы белән Сайрес Смитны еш кына уйга сала иде.

— Нәрсә булды соң бу Топка, тагын өрә башлады,— дип аптырады Пенкроф.

— Юп та мырылдый,— дип өстәде Герберт.

Чыннан да, маймыл да эткә ияреп, тынычсызланып йөрепә иде. Тик шунысы гаҗәп, икесе дә гасабиланудан үзләренә урын таба алмасалар да, ярсыганнары тоелмый иде.

— Коеның төбе океан суына ук төшеп җитәдер ахрысы. Шунда берәр диңгез хайваны вакыт-вакыт кое авызына һава суларга йөзеп чыгадыр,— диде Гедеон Спилет.

— Шулай булса кирәк, югыйсә бу хәлне бүтәнчә ничек аңлатыр идең,— диде диңгезче һәм борылып этне тыйды: — Җитәр, Топ, тукта! Юп, бар син дә үз бүлмәнә кит!

Маймыл белән Топ тындылар. Юп үз бүлмәсенә йокларга кереп китте, ә Топ залда калса да, кич буе үзалдына ырылдап йөрде.

Бу вакыйга турында бүтән сүз куертмадылар, ә инженер тирән уйга калды.

Июль ахырына таба әле яңгыр, әле кар яуды. Көннәр былтыргы кыш белән чагыштырганда җылырак торды, температура Фаренгейт буенча сигез градустан (Цельсий буенча минус 13,33°) төшмәде. Әмма кыш салкын булмаса да, әледән-әле давыл котырды, каты җилләр чыкты. Зур-зур дулкыннар тыелгысыз көч белән Хәрабәгә бәреп керделәр. Гүя диңгез төбендә җир тетрәүдән су айкалып, ярларына сыеша алмыйча, Гранит

сарай стенасын җимерердәй дәһшәт белән тәгәрәп-тәгәрәп килә иде.

Утрау хуҗалары соклангыч кодрәткә ия бу тамашаны тәрәзәдән күзәтеп торалар. Тау биеклеге булып ишелеп килгән дулкын бөтен яр буен иңләп бәрә дә һавага су болыты атып кире чигенә. Океан, көчсезлегеннән ярсып, ак күбекләр кайнатып комлы ярны күмеп китә. Йөзәр фут биеклеккә чәчрәгән су тамчыларына күмелгән гранит стена айкалган диңгез упкынында япа-ялгызы торып калгандай тоела.

Давыл вакытында юлларда йөрүе дә хәтәр иде, көчле җил вакыт-вакыт төбе-тамыры белән агачларны аударды. Шулай да атнага бер тапкыр мал утарына барып кайтырга туры килә. Бәхеткә, мал утарын көньяк-көнбатыштан Франклин тавының бер сырты ышыклап тора, шунлыктан котырынган давыл вакытларында аңа әлләни зыян тимәде: агачлар, каралтылар, утыртма койма исән калды. Ә Күзәтү яссылыгында җилләр оясында урнашкан кош кетәге шактый зыян күрде: утыртма койма ауды, күгәрчен оясын ике тапкыр җил алып ыргытты. Аларны өр-яңадан ясарга һәм ныграк итеп корырга туры килде. Чөнки Линкольн утравы Тын океанның иң тынгысыз урынына урнашкан булып чыкты. Гүя ул көчле циклоннар оясында утыра иде. Өермә аны бөтерчекне сыдырткан чыбыркы шикелле сыдыртып торды. Тик биредә бөтерчек хәрәкәтсез, ә чыбыркы аның тирәсендә бөтерелә иде.

Август ае керде. Аның беренче атнасында ук давыллар басыла төште. Мәңге ачылмастай тоелган күк йөзе сафланды. Фаренгейт градуснигы минус сигез градус күрсәтә иде (Цельсий буенча $-22°$).

Өченче августта утрау хуҗалары утрауның көньяк-көнчыгышындагы Үрдәк сазлыгына күптән уйланылган, әмма моңарчы соңара килгән сәяхәткә барырга җыендылар. Анда кыш көне исәпсез-хисапсыз киек кошлар яши иде; чуллыклар, чүрәкәйләр, чумгалар, безкойрыкларны күп итеп ауларга мөмкин иде. Сәяхәткә Гедеон Спилет белән Герберт белән бергә Пенкроф та, Наб та барды. Тик Сайрес Смит кынаниндидер эшем бар дип өйдә калды.

Сәяхәтчеләр, кич кайтырга вәгъдә биреп, Һава шары порты юлыннан сазлыкка таба юнәлделәр. Юп белән Топ та аларга иярде. Юлчылар Рәхмәт елгасы күпереннән чыккач, инженер күперне күтәртеп куйды да, күп-

тән уйланылган ниятен тормышка ашырыр өчен, өйгә кайтып китте. Шуның өчен иптәшләреннән аерылып калды да ул.

Инженер Гранит сарай идәнендәге коены иркенләп тикшерергә тели иде. Кое, әлбәттә, диңгез белән тоташкан, чөнки күлнең артык суы шунда агып төшә иде. Нигә Топ еш кына аның янына чабып бара соң? Нигә гасабиланып кое тирәсендә әйләнеп йөри, нигә сәер итеп өрә? Нигә Юп та Топка кушылып гасабилана? Әллә, кое төбе диңгезгә генә чыгып калмыйча, анда утрауның башка якларына илтә торган тармаклар да释мы? Шуларны Сайрес Смит үзе генә тикшерергә булды. Шикле уйларын башкаларга белгертергә теләмичә, коены өйдә ялгыз калган чагында тикшерергә карар итте. Менә бүген шул форсат чыкты.

Күтәрткеч машина куелганнан бирле файдаланылмыйча яткан бау баскыч белән кое эченә төшәргә мөмкин иде, аның озынлыгы чама белән төпкә җитәрлек иде. Инженер бау баскычны диаметры алты фут чамасы кое авызы янына өстерәп китерде дә бер башын кое кырыена ныклап бәйләп куйды һәм икенче башын кое эченә төшереп җибәрде. Аннары билбавына пычак кыстырды да бер кулына фонарь, икенчесенә карабин тотып, баскыч арааларына басып кое эченә төшә башлады.

Коеның стенасы шоп-шома граниттан тора, ара-тирә киртләч-киртләч җирләре дә күренә иде, әлбәттә. Елгыррак җанвар шул киртләчтән өскә үк үрмәләп менә алыр иде.

Инженер, шуны уйлап, фонарь белән стенаның һәр киртләчен яктыртып карады, тик ташта бер генә сыдырылган, тырналган эз дә күренмәде. Аннан кемдер менеп йөргән дип исбатларлык дәлил табылмады.

Сайрес Смит һәр карыш җирне яктырта-яктырта түбәнгә төшүен дәвам итте.

Әмма шикләнердәй нәрсә тапмады. Инженер соңгы басмага да төшеп җитте, су өсте тып-тын иде. Стеналарында өстәрәк тә, иң түбәндә дә утрауның бүтән ягына илтә торган тармаклар күренмәде. Пычак сабы белән шакып карагач та стенаның куыш икәнлеге тоелмады. Тоташ стенадан бер генә җан иясе дә үзенә юл салып кое эченә үтеп керә алмагандыр. Коега су астындагы диңгез белән тоташкан каналдан гына үтәргә мөмкин, һәм аннан берәр диңгез хайваны гына керсә инде. Тик

ул канал нинди тирәнлектә икән һәм кай урында диңгезгә барып чыга,— монысын инженер белә алмады.

Кое эчен карап бетергәч, Сайрес Смит, өскә менеп, баскычны коедан тартып чыгарды да кое авызын ябып куйды һәм тирән уйга баткан килеш Гранит стенаның зур залына әйләнеп керде һәм:

— Берни таба алмадым. Ләкин анда барыбер ниндидер сер бар! — дип үз алдына сөйләнде.

Уникенче бүлек

Корабны җиһазлау.— Кыргый этләр һөҗүме.— Юп җәрәхәтләнде.— Юпны дәвалау.— Кораб ясалып бетте.— Пенкроф тантана итә.— «Хәерле юл».— Утрауның көньяк очына диңгез буйлап беренче сәяхәт.— Диңгездән табылган шешә.

Кич белән аучылар аудан кайтып керделәр. Юллары уңган: иңбашларына аллап-артлап бихисап күп киек кошлар элгәннәр, дүрт аучы дүртесе дә күпме күтәрә алса, шул хәтле киек алып кайтканнар! Хәтта Топның муенына да бер бәйләм безкойрык эленгән, ә Юп исә биленә шөлдиләр аскан иде.

— Менә, кара әле, мистер Сайрес, авыбыз ничек шәп булды! — диде шатланып Наб.— Берәрегез миңа булышса, күпме кошны какларга, күпмесеннән паштет ясап куярга була! Пенкроф, син булышырсың дип ышанам инде!

— Юк, Наб, корабны җиһазлап бетерәсем бар, мине эшемнән бүлдермә.

— Герберт, ә син?

— Миңа иртәгә мал утарына барырга кирәк.

— Мистер Спилет, сез ярдәм итмәссезме?

— Рәхәтләнеп булышам, Наб. Тик, кара аны, алдан кисәтәм, аш пешерү серләреңне белеп алсам, соңыннан газетага язып чыгачакмын!

— Ихтыярыгыз, мистер Спилет, каршылыгым юк,— диде Наб.

Кыскасы, иртән иртүк Гедеон Спилет кухняга кереп, Набка булышырга тотынды. Ә кичтән инженер аңа коены тикшерүен сөйләгән иде. Гәрчә коеда шикләнерлек нәрсә табылмаса да, анда ниндидер сер булырга тиеш дигән фикергә Гедеон Спилет та кушылды.

Суыклар тагын бер атнага сузылды, дусларыбыз күбрәк өйдә ябылып утырдылар, фәкать кош кетәгенә

барып килү өчен генә өйдән чыккаладылар. Наб белән журналистның оста итеп пешергән ризыкларыннан өй эченә тәмле исләр таралды. Сунардан алып кайткан киекнең һәммәсен ыслап, консерва ясап бетермәделәр, беразын суыкка чыгарып катырдылар. Хәзер көн саен үрдәк яки бүтән берәр кош итен кыздыралар һәм «дөньяда су кошы итеннән дә тәмле ризык юк» дип мактыймактый ашыйлар.

Пенкроф белән Герберт атна буе тырышып җилкән тектеләр. Егет кулына инә тотарга да оста икән. Шундый да бирелеп эшләделәр ки, атна ахырына җилкәннәр әзер иде инде. Һава шарының җәтмәсе юан арканнан үрелгән иде; юан, нык арканны диңгезче корабта файдаланырга булды; җилкән читенә тоту өчен ликтросны, фал, вант, шкот һәм башка кирәкле арканнарны шуннан ясадылар. Пенкрофның күрсәтеп торуы буенча, Сайрес Смит агач кыру станогында чыгырлар ясап бирде. Кораб төзелеп беткәнче үк, барлык җиһазлары әзер булды. Пенкроф хәтта флаг та әзерләде: утраудагы үсемлекләрне кайнатып ак тукыманы кызыл һәм зәңгәр төсләргә буяды. Америка судноларының флагындагы утыз җиде штатны аңлатучы утыз җиде йолдыз янына утыз сигезенче йолдызны — «Линкольн штаты» йолдызын да өстәде, чөнки утрауны Америка республикасына кушылган дип исәпли иде ул.

— Әле бу гамәлдә түгел түгелен, әмма күңелем сизенә, киләчәктә гамәлгә керәчәк,— дип сөйләнде.

Флаг әле судно өстендә җилферди башлаганчы ук аны өч тапкыр «ура» кычкырып Гранит сарай ишеге өстенә менгереп кададылар.

Ул арада кыш бетәргә якынлашты. Икенче кыш та имин генә үтеп китә дип өметләнеп торганда, 11 нче августка каршы төнне көтмәгәндә Күзәтү яссылыгын ерткыч җанварлар харап итә язды.

Көнозын эшләп арган дусларыбыз бик каты йоклап яталар иде. Иртәнге сәгать дүртләр тирәсендә кинәт аларны Топ өреп уятты.

Бу юлы эт кое тирәсендә өрми, ә ишеккә ташланып, аны ватып чыгарга теләгәндәй ыргыла иде. Юп та ачы итеп чиылдарга кереште.

Барысыннан алда уянган Наб:

— Шаулама, Топ, тукта,— дип аны тыеп та карады. Эт тагын да катырак өрергә тотынды.

— Нәрсә булган соң аңа? — дип сорады Сайрес Смит.

Ашык-пошык киенеп, барысы да тәрәзә янына ташландылар һәм аска карадылар.

Аларның күз алларында караңгы төндә беленер-беленмәс ак кар катлавы җәелеп ята иде. Анда бер нәрсә күренми иде, әмма караңгыда ниндидер җәнлекләрнең өргәне ишетелде. Шик юк ки, ниндидер җәнлекләр яр буена килеп кергәннәр, тик үзләре моннан әлегә күренмиләр иде.

— Нинди җәнлекләр булыр бу? — дип сорады Пенкроф.

— Бүреләр, ягуарлар яки маймыллардыр,— дип җавап бирде Наб.

— Ах шайтан! Күзәтү яссылыгына бәреп кермәгәйләре,— диде Гедеон Спилет.

— Кош кетәген, иген басуларын харап итмәгәйләре болар!..— дип борчылып кычкырып җибәрде Герберт.

— Ничек керә алганнар соң алар бирегә? — дип сорады Пенкроф.

— Күпердән кергәннәрдер, мөгаен, берәрегез күперне күтәртеп куярга онытканcыздыр,— диде инженер.

— Ах, исемә төште, мин онытканмын бит аны...— диде Гедеон Спилет.

Пенкроф кызып китте:

— Рәхмәт инде, дустым, булдыргансың икән!

— Булган эш булган инде, кире кайтара алмассың,— диде Сайрес Смит.— Хәзер нишләргә икәнен уйлашырга кирәк.

Сайрес Смит һәм иптәшләре ашыгыч кына шулай сөйләшеп алдылар. Мәсьәлә ачыкланды: ниндидер ерткычлар күпер аша чыгып, яр буена узганнар. Хәзер алар Рәхмәт елгасының сул яры буйлап өскә таба менәрләр, Күзәтү яссылыгына һөҗүм итәрләр. Аларны тизрәк куып җибәрергә кирәк, әгәр каршы торсалар, сугышырга да туры килер.

Аста өргән тавыш көчәя барды.

— Нинди ерткычлар икән соң болар? — дип аптыраштылар алар.

Герберт, астагы тавышка колак салгач, сискәнеп китте. Кызыл инеш чыганагына беренче тапкыр барган чакта шундый өргән тавыш ишеткәне хәтеренә төште.

— Кыргый эт көтүе бит бу! — дип кычкырып җибәрде ул.

— Алга! — дип ашыктырды Пенкроф.

Утрау хуҗалары балталар, карабиннар һәм мылтыклар белән коралландылар да тиз генә кәрзингә төялеп, аска төшеп киттеләр.

Ач ыргый этләр бик куркынычлы җанварлар алар. Ләкин аучылар икеләнеп тормастан ул эт өеренең иң уртасына ташландылар. Караңгылыкны ялт та елт мылтык утлары телгәләде, дошманнар чигенергә мәҗбүр булдылар.

Аларны Күзәтү яссылыгына таба үткәрмәскә кирәк иде, чөнки алар анда узсалар, кош кетәген пыран-заран китерәчәкләр, яшелчәләрне таптап бетерәчәкләр, иген басуын харап итәчәкләр. Яссылыкка бары бер генә юлдан, Рәхмәт елгасының сул як яры буйлап кына барырга мөмкин иде. Шуңа күрә гранит стена белән елга яры арасындагы тар гына урынны сакларга, этләрне шуннан уздырмаска кирәк иде.

Утрау хуҗалары, Сайрес Смит боерыгына буйсынып, шунда ашыктылар, этләр өере алар артыннан ташланды.

Сайрес Смит, Гедеон Спилет, Герберт, Пенкроф һәм Наб бер рәткә тезелделәр. Авызын ыржайткан Топ алга чыкты, Юп, чукмарын селтәп, аның янәшәсенә басты.

Төн бик караңгы. Мылтык уты яктысында гына этләрнең нишләвен күреп өлгереп була. Күзләре утлы күмер кебек янган йөзәрләгән ерткыч аларга ташланырга әзер иде.

— Ерып үтәрләр микәнни? — дип кычкырды Пенкроф.

— Юк, үтә алмаслар, — диде инженер.

Ерткычлар тере киртәне кысрыклап килсәләр дә, өзә алмадылар. Этләрнең арттагы рәте алдагыларын тыгызлап килә, утрау хуҗалары аларны берәм-берәм атып үтерә торалар, балта белән чабалар. Инде җирдә ничәмә-ничә эт үләксәсе ауный, әмма өер һаман әле чигенми дә, кимеми дә, күпәр аша чыгып өстәлә бара ахрысы. Менә алар ерткычларча кешеләргә ташландылар, кемнәрнедер җиңелчә җәрәхәтләделәр дә. Герберт Набның җилкәсенә мәче кебек менеп атланган бер этне төз атып егып төшерде. Топ ярсып сугыша, тешләре белән кыргый этләрнең бугазына барып ябыша да буып ыргыта, аннары икенчесенә, өченчесенә ябыша... Юп, чукмарын уңлы-суллы селтәп, дошманнарын бер-бер артлы кырып тора. Аны артка чигендерерлек түгел. Ул

карангыда да күрә аладыр ахрысы: сугышның иң кайнаган җиренә ташлана; ярсудан әче итеп сызгырып алгалый. Сугыша торгач, кызып китеп, ул алга ук узып кергән. Мылтык уты яктысында аучылар аны биш-алты зур эт абалап алганлыгын күрделәр. Маймыл исә кабаланмый гына аларның һөҗүмен кире кайтара тора иде.

Ике сәгатьләп каты көрәштән соң утрау хуҗалары җиңеп чыктылар! Таң нуры беленгәндә, ерткыч этләр күпергә чигенделәр һәм төньякка таба китеп югалдылар. Алар артыннан Наб күперне күтәртеп куярга ашыкты. Кояш чыгып, сугыш кырын яктырткач, аучылар җирдә аунап яткан иллеләп үле эт гәүдәсе санадылар.

Пенкроф кинәт:

— Юп кайда соң безнең? Юп кайда? — дип борчылып кычкырып җибәрде.

Юп югалган иде. Наб аңа дәшеп караса да, дустының чакыруына маймыл беренче тапкыр җавап бирмәде.

Дуслар аны эзләргә керештеләр. Юп та үлгәннәр арасындадыр инде дип курыктылар. Кызыл кан белән аралашкан кар өстендә өелеп яткан эт үләксәләрен актарып, Юпны иң астан казып чыгардылар. Этләрнең кайсының баш сөяге чәрдәкләнгән, кайсының сырты сынган,— болар бар да курку белмәс Юпның чукмары эзе иде. Бичара Юп чәрдәкләнгән чукмарын әле һаман да кулыннан ычкындырмаган килеш ята.

Ерткыч этләр, Юпның чукмары ватылгач, коралсыз калуын күрег өстенә ташланганнардыр, аяктан егып талаганнардыр, күрәсең.

Наб аның өстенә иелеп карагач:

— Ул тере! — диде.

— Без аны дәвалап савыктырырбыз, балабыз кебек итеп карарбыз!..— диде Пенкроф.

Маймыл, аның сүзен төшенгәндәй, башын диңгезченең җилкәсенә салды, диңгезче үзе дә яраланган, әмма аның һәм башкаларның җәрәхәте ул кадәр куркыныч түгел иде. Мылтык уты ерткыч этләрне алай да бигүк якын җибәрмәде. Маймылның гына ярасы каты иде.

Пенкроф белән Наб Юпны Гранит сарай янына күтәреп алып килделәр, шунда ул бер генә тапкыр ыңгырашып куйды. Аны әкрен генә Гранит сарайга менгерделәр, бер караватның матрасын алып, маймылны шун

да иплэп кенэ китереп салдылар һәм әйбәтләп җәрәхәтләрен тазарттылар. Аның эчке әгъзалары зарарланмаган булса кирәк, ләкин Юп каны күп агудан хәлсезләнгән һәм тәне бик кызыша иде.

Җәрәхәтләрен бәйләгәч, үз урынына илтеп яткыздылар да, Наб әйтмешли, «чын кеше» исеменә лаеклы маймылга бик каты диета билгеләделәр. Гранит сарай аптечкасындагы дару үләннәрен кайнатып, тәненең кызуын баса торган берничә чокыр эчемлек эчерделәр.

Юп башта саташып бик тынычсыз йоклады, аннары сулыш алуы тигезләнә төште, һәм дусларыбыз аны тынычта калдырып чыгып киттеләр. Топ кына әледәнәле йомшак кына басып аның янына гүя хәл белергә кереп чыга иде. Юпның ятагыннан салынып торган аяккулларын ялап-ялап ала иде ул.

Утрау хуҗалары шул ук көнне иртән эт үләксәләрен Ерак Көнбатыш урманына илтеп күмделәр.

Ерткыч этләр һөҗүме бик күңелсез хәлләр китереп чыгаруы мөмкин иде, һәм бу аларга зур сабак булды. Шул көннән башлап алар күперләр күтәрелгәнме, читтән һөҗүм итү куркынычы юкмы икәнен барламыйча йокларга ятмас булдылар.

Утрау хуҗалары Юп өчен бик борчылганнар иде, берничә көннән ул савыга башлады. Тәненең кызуы әкренләп сүрелде. Медицина өлкәсендә акны карадан аера белгән Гедеон Спилет авыруның хәле уңайлануын әйтте. 16 нчы августта Юп үзе теләп тамагына ашады. Наб аңа тәмле ризыклар пешерә, авыру исә аны комсызланып сыпыра гына. Маймылның бердәнбер йомшак ягы бар — ул тәмле тамак иде. Ә Наб аның бу гаебенә күз йома килде.

Гедеон Спилет маймылны узындырасың дип шелтәләгән чакларда Наб:

— Нишлим инде, бичара Юпның бердәнбер куанычы — тәмле ашау. Тугрылыклы хезмәт иткән өчен аңа рәхмәтем шул булыр, мин аны сыйларга бик риза, — ди иде.

Ун көннән соң, 21 нче августта, Юп абзыйга урыныннан торып йөрергә рөхсәт иттеләр. Аның барлык җәрәхәтләре төзәлде, элеккеге көче, җитезлеге тиздән кире кайтырга тиеш иде. Авырудан әле генә терелеп килүче кешеләр шикелле, ул ашап туя алмады. Журналист аңа җаны теләгәнчә ашарга рөхсәт итте, чөнки

ул аның кирәкмәсне ашамаячагын белә иде. Маймылларда кешедә булмаган, артык ашаудан тыя торган сизем бар. Ә Наб исә шәкертенең әүвәлгечә яратып ашый башлавын күреп куанды.

— Аша-аша, дустым. Җаның ни тели, шуны аша. Безнең өчен кан койдың, сиңа савыгырга кирәк. Сиңа ярдәм итә алуыма мин бик шат.

25 нче августта көтмәгәндә Наб зур залда утырган иптәшләрен үз янына чакырды:

— Мистер Сайрес, мистер Гедеон, Герберт, Пенкроф, тизрәк килегез әле! — дип кычкырды.

Иптәшләре сикерешеп торып Юпның бүлмәсенә йөгерделәр.

— Нәрсә булды? — дип сорады журналист.

— Менә карагыз әле моны! — дип Наб шаркылдап көлеп җибәрде.

Ни күрсеннәр! Юп абзыкай Гранит сарай ишеге бусагасына чүгәләгән дә төрепкә төтәтеп утыра, оста тәмәкече диярсең.

— Минем төрепкә бит ул! Кара әле, минем төрепкәне алган! — дип шаккатты Пенкроф.— Ярар инде, әйдә, үзеңә бүләк булсын! Тарт, әйдә, тарт, картлач! Җаның теләгәч, рәхәтләнеп тарт, дускай!

Юп бик канәгать төс белән төтен бөҗралары чыгарып утыра, шуннан тәм таба иде, күрәсең.

Сайрес Смит моңа бер дә шаккатмады; кулга ияләштерелгән күп маймылларның тәмәке тартырга өйрәнүләрен сөйләргә кереште, мисаллар китерде.

Шул көннән алып Пенкрофның төрепкәсе Юпка күчте, ул аның бүлмәсендә тәмәке янчыгы белән янәшә, кадакта эленеп тора башлады. Юп төрепкәгә тәмәкене үзе тутыра, утлы куз алып үзе көйрәтә һәм үзен дөньяда иң бәхетле маймыл кебек тота иде. Юп белән диңгезче арасындагы дуслык уртак зәвык җирлегендә тагын да ныгыды.

Пенкроф Набка кайвакыт:

— Әллә кеше микән ул? Көннәрдән бер көнне ул безнең белән сөйләшә башласа гаҗәпләнер идеңме? — диде.

— Валлаһи, бер дә шаккатмас идем. Аның сөйләшмәве мине ныграк гаҗәпләндерә әле!

— Әгәр көннәрдән бер көнне ул минем янга килеп әйтсә: «Әйдә, Пенкроф, төрепкәләребезне алмашабыз!» дисә, нинди кызык булыр иде.

— Әйе шул, дустым, аның тумыштан телсез булуы бик үкенечле! — дип куйды Наб.

Сентябрь ае керде, кыш та узып китте, һәм дусларыбыз кызып эшкә тотындылар.

Корабт төзү тизләп алга барды. Аны тышкы яктан такта белән тышлап бетерделәр, хәзер эчке ягына такта кагалар. Парда йомшартылган такталарны кабыргаларга җайлаштырып кагу кыен түгел иде. Такталары җитәрлек иде, Пенкроф инженерга тактаны эчке яктан да су үткәрмәслек итеп тыгызлап кагарга тәкъдим итте, кораб ныграк булыр диде.

Киләчәк аларга нинди көтелмәгән хәлләр әзерләгәнлер бит әле, белгән юк, шуңа күрә Сайрес Смит диңгезченең әйбәт кораб ясарга теләвен хуплады гына.

Корабның эченә такта кагу һәм палубасын ясау 15 нче сентябрьгә төгәлләнде. Палуба кырыйларын, тышкы һәм эчке тышлыкның җөйләрен агач чөй белән мүкләп чыктылар, мүк урынына кипкән сүүсемнәрен кулландылар. Мүк өстеннән нарат сумаласы белән сумалаладылар.

Корабның җиһазлары да бик гади иде. Балласт урынына трюмга авырлыгы унике мең кадак чамасы гранит таш төяделәр, аларны кузгалмаслык итеп урнаштырдылар. Балласт өстенә палуба җәйделәр. Корабның урта өлеше ике каютага бүленде, һәр каютада бүлемгә терәп икешәр тар сәке ясалды, алар сандык хезмәтен дә үтәргә тиеш иде. Мачтаның нигезе бүлем турысына беркетелде. Һәр каютадан палубага тар баскыч күтәрелә, аның капкачы су кермәслек итеп ябыла иде.

Пенкроф мачталык озын агачны бик тиз эзләп тапты. Төз кәүсәле ботаксыз яшь чыршыны төбеннән кисеп, кабыгын каезлады да очын түгәрәкләде. Мачта, рульнең һәм корабның башка тимер өлешләре Хәрабәдәге тимерчелектә эшләнде, тупасрак булса да, нык иде. Ниһаять, октябрьнең беренче атнасында рей, гик, флагшток, кыскасы, барлык рангоутлар һәм ишкәкләр эшләнеп бетте. Корабның диңгездә йөзү сәләтен һәм ерак юл йөрергә яраклылыгын белү өчен утрау тирәли йөреп сынап карарга булдылар.

Ә ул арада көндәлек мәшәкатьләр дә чыга торды, алар үз чиратында эшләнә барды. Мал утарында яңа абзарлар салдылар, чөнки муфлон һәм кәҗә бәтиләре

ишәйгәч, аларга торырга урын иркенрәк, печән күбрәк кирәк булды.

Утрау хуҗалары әледән-әле устрица сайлыгына барып киләләр, куян бакчасына йөриләр, ташкүмер һәм тимер чыккан җиргә баргалыйлар, Ерак Көнбатыш урманының моңарчы тикшерелмәгән якларына киек ауларга йөриләр иде.

Утрауда үсә торган тагын яңа төр үсемлекләр дә таптылар алар, бу яңа үсемлекләр аш төрләндерергә ярап куйды. Кайбер үсемлекләрнең итләч яфрагын ашарга мөмкин иде, икенче берләренең орлыгын төеп, он ясадылар.

Унынчы октябрьдә кораб суга төшерелде. Төзелеп беткән корабны, астына бүрәнәләр кыстырып, яр буена ук тәгәрәтеп китерделәр дә, су күтәрелгәч, ул су эчендә торып калды. Кораб горур йөзеп киткәч, яр буенда төзүчеләрнең көчле алкыш тавышлары яңгырады. Пенкрофның куанычы эченә сыймады; ул тыйнаклык саклап та тормыйча, котырынып кул чапты. Корабны төзүче генә түгел, йөртүчесе дә булганлыктан, аның шөһрәте тагын да артып китте. Барысы бертавыштан капитанлыкка аны билгеләделәр бит.

Капитанның күңелен күрергә тырышып, иптәшләре корабка исем эзләшергә керештеләр. Озак бәхәстән соң корабны «Хәерле юл» дип атадылар, чөнки бу исем диңгезченең үз исеменең мәгънәсенә туры килә иде.

«Хәерле юл» йөзеп киткәч, аның суда әйбәт утыруын, теләсә нинди тизлек белән бара алачагын күрделәр.

Утрау әйләнә сәяхәткә чыгарга, корабны шул ук көнне сынарга карар иттеләр. Көн әйбәт иде, талгын җил исә, су өстендә дулкын зур түгел, көньяк яр тирәләре бигрәк тә тыныч; бер сәгатьтән бирле норд-вест җиле иссә дә, зыянлы түгел иде. Капитан тизрәк кузгалып китәргә ашыга:

— Юлга чыгарга вакыт! — ди.

Кузгалып киткәнче ашап алырга кирәк иде, сәяхәт кичкә хәтле сузылса дип, юлга да ризык алырга булдылар.

Диңгезче киңәше белән гәрчә кайбер вак-төяген үзгәртергә мәҗбүр булса да, үз сызымы буенча ясалган корабны Сайрес Смитның да тизрәк сынап карыйсы килде. Ул судноның ныклыгына Пенкроф кебек сукыр рәвештә ышанмый, аннары ул инде Пенкрофны Табор

утравына бару ниятеннән баш тарткан дип өметләнә иде, чөнки диңгезченең соңгы вакытта бу турыда сүз кузгатканы ишетелмәде. Күп дигәндә унбиш тонна су сыйдырышлы шушы кечкенә корабка утырып, ике-өч иптәше ерак юлга сәфәр чыгарга тәвәккәлләр дип уйлыйсы да килми иде.

Сәгать унберенче яртыларда утрау хуҗалары һәммәсе корабта иделәр инде, хәтта Топ белән Юпны да алдылар. Наб белән Герберт Рәхмәт елгасы тамагында комга батырылган якорьне күтәрүгә, «Хәерле юл» кыек грот җилкәнен җәеп җибәрде һәм, Линкольн утравы флагын җилфердәтә-җилфердәтә, капитан Пенкроф командасына буйсынып, ачык диңгезгә чыкты.

Берләшү бухтасыннан чыгып китү өчен җилнең уңай исүе кирәк иде. Һәм фордевинд[1] вакытында кораб шактый кызу йөзә алуын күрсәтте. Табылдык һәм Тырнак борыннарын урап узгач, корабны җилгә каршы борырга туры килде, һәм кораб утрауның көньяк яры буйлап бара башлады. Корабны әле бер яны, әле икенче яны белән борып, җилгә каршы барып карагач, Пенкроф аның биш румбка хәтле дрейф ясамыйча бара алуын белде. Диңгезчеләр теле белән әйткәндә, оверштаг[2] белән борылганда кораб икенче галска да әйбәт ята һәм шактый вакытны ота да икән.

Сәяхәтчеләр «Хәерле юл»ның шәп судно икәненә ышандылар, ихтыяж төшкәндә ул аларга яхшы хезмәт күрсәтә алачак. Ә бүген, шундый матур аяз көнне, җил уңаена баруы үзе бер хозурлык иде.

«Хәерле юл», ярдан өч-дүрт миль эчкәре кереп, диңгездән Һава шары портына таба йөзә. Утрау биредән бөтенләй яңача күренә: Тырнак борыныннан алып Елан борынына хәтле яр буе бөтен күркәмлеге белән күз алдында җәелеп ята: алгы рәттә каракучкылланып чыршы-нарат урманы күренә, өскә таба ямь-яшел яфраклы агачлар урманы үрли, ә иң артта башына кар бүреге кигән Франклин тавы күккә ашып утыра.

— Нинди матурлык! — дип сокланып куйды Герберт.

— Утравыбыз гаҗәеп матур шул безнең, мәрхәмәтле. Ул миңа үз әнием кебек якын! — диде Пенкроф.— Авыр хәлгә төшкән чакта ул без бичараларны үз куе-

---

[1] Җил уңай искәндә, ягъни арттан искәндә.
[2] Җилгә каршы борылу.

нына сыендырды. Әле кайчан гына очып, бернисез килеп төшкән идек, хәзер безнең барлык нәрсәбез дә житеш!

— Дөрес әйтәсез, капитан, безнең һәммә нәрсәбез бар, хәзер бер мохтаҗлыгыбыз да калмады,— дип җавап бирде Наб.

Утрауның игелекле ике улы утрау хөрмәтенә өч тапкыр «ура» кычкырдылар.

Ә Гедеон Спилет, мачтага сөялгән килеш, куен дәфтәренә күз алдында җәелеп яткан табигать манзарасын рәсемгә төшереп алды.

Сайрес Смит та сөйләшмичә генә яр буйларын карап бара иде.

— Я, мистер Сайрес, безнең кораб турында ни әйтерсез? — дип сорады Пенкроф.

— Әйбәт күренә! — дип җавап бирде инженер.

— Шәп! — дип раслады Пенкроф.— Ерак сәфәргә чыгу өчен яраклы булыр микән, ничек дип уйлыйсыз?

— Нинди сәфәргә, Пенкроф?

— Әйтик, Табор утравына.

— Дустым, әгәр ихтыяҗ төшсә, аннан да ераграк юлга чыгарга мөмкин дип уйлыйм; «Хәерле юл»га һич шикләнмичә ышанырга була. Әмма минем сезне Табор утравына бер дә җибәрәсем килми, дустым. Анда баруның бер хаҗәте юк.

Пенкроф үз сүзендә нык торды:

— Табор утравы безнең бердәнбер күршебез! Күршеләр белән танышырга кирәк бит инде! Әдәп йөзеннән булса да, барып кайтырга кирәк!

— Шайтан алгырысы! Пенкроф дустыбыз да итагать саклап маташа икән безнең!

Диңгезче мыгырданып куйды:

— Уйлаганым да юк.— Инженерның рөхсәт итмәвенә ачуы чыкты аның, әмма шул ук вакытта аның хәтерен дә калдырасы килмәде.

— Кара әле, Пенкроф, сәяхәткә юлдашларсыз чыгып булмый бит!

— Бер юлдаш җитә миңа.

— Ярый, шулай да булсын, ди. Димәк, сезнең аркада Линкольн утравы ике кешесен югалта, ә без барыбыз биш кеше!

— Алты,— диде Пенкроф.— Юпны санарга оныттыгыз.

— Җиде! — дип өстәде Наб.— Топ безнең беребездән дә ким түгел!

— Нигә куркасыз, мистер Сайрес, хәтәр сәфәр түгел бит бу,— дип һаман карулашты Пенкроф.

— Шулайдыр, Пенкроф, ышанам. Әмма кирәкмәгәнгә нигә әле язмыш ихтыярына ташланырга торасыз?

Үзсүзле диңгезче җавап кайтармады, ләкин кайчан да булса бу әңгәмәне яңартырбыз әле дип күңеленнән генә уйлап куйды. Әмма тиз көндә бер очраклы хәлнең үзенә ярдәмгә киләсен уйламаган иде ул. Табор утравына сәяхәт моңа кадәр бер максатсыз омтылыш дип кенә исәпләнсә, хәзер ул бәлагә тарыган бер бичарага ярдәм кулы сузу өчен кирәк булып чыкты.

Диңгездән йөзеп килгән «Хәерле юл», Һава шары портына якынлашкач, ярга таба борылды. Сәяхәтчеләрнең кыя ташлар белән сайлык арасында калган тар тына җирдән узып булу-булмавын беләселәре килә иде, чөнки алар киләчәктә корабны шушы кечкенә бухтада тотарга исәплиләр иде.

Ярга ярты миль чамасы калды, тик җилгә каршы бару өчен әле уң ян белән, әле сул ян белән борылып йөзәргә туры килде. Биек яр ышыгында җилнең көче кимеде, җилкән әйбәт кабармый, корабның тизлеге әкренәйде. Җил көзге кебек ялтырап яткан диңгез өстен шадралап кына исә иде.

Кораб борынында басып торган килеш фарватерны күрсәтеп барган Герберт кинәт:

— Пенкроф, җил уңаена бор әле, җил уңаенарак бор! — дип кычкырып җибәрде.

— Нәрсә бар тагын? Кыямы әллә? — дип сорады диңгезче аягүрә басып.

— Юк... сабыр ит әле, ни икәнен күреп бетермим... тагын да ыграк бор... менә шулай, әйбәт булды... аз гына алга бар...— дип сөйләнә-сөйләнә Герберт борт аркылы сузылып кулын суга тыкты һәм:

— Шешә! — дип кычкырып җибәрде.

Ул ярга берничә кабельтов каларак судан авызы бөкеләнгән шешә тапты.

Сайрес Смит шешәне кулына алып, бөкесен бәреп төшерде дә эченнән кәгазь тартып чыгарды. Суда җибегән кәгазьдән түбәндәге сүзләрне танып була иде:

«Һәлакәткә очрады... Табор утравы... Көнбатыш озынлыкның 153°, көньяк киңлекнең 37°11′»

Уникенче бүлек

Утрауга бару хәл ителде.— Төрле фаразлар.— Юлга җыену.— Өч сәяхәтче.— Беренче төн.— Икенче төн.— Табор утравы.— Комлы яр буеннан эзләнүләр.— Урманда эзләнүләр.— Утрауда беркем юк.— Хайваннар.— Үсемлекләр.— Йорт.— Өй эче буш.

— Кемдер һәлакәткә очраган! Бездән күп булса йөз миль генә ераклыкта, Табор утравында япа-ялгызы яши! Мистер Сайрес, инде хәзер утрауга баруга каршы төшмәссездер дип уйлыйм,— диде Пенкроф.

— Юк, каршы түгел, Пенкроф,— дип җавап бирде Сайрес Смит.— Тизрәк юлга чыгарга кирәк.

— Иртәгә үкме?

— Иртәгә үк.

Инженер шешәдән чыккан язуга байтак текәлеп карап торгач, бер фикергә тукталды булса кирәк. Болай диде:

— Бу язуга карап шундый нәтиҗәгә килергә мөмкин: беренчедән, Табор утравындагы кеше — диңгез эшендә мәгълүматлы булса кирәк, чөнки ул Табор утравының географик киңлеген һәм озынлыгын дөрес күрсәткән, без исәпләп чыгарган белән минуты минутка туры килә; икенчедән, ул инглиз яки америкалы булырга тиеш, чөнки язуы инглизчә.

— Логик яктан бу фикер дөрескә охшый,— диде Гедеон Спилет.— Яр буеннан табылган әрҗәнең дә сере чишелде: менә кайдан килгән икән ул. Кешесе табылгач, димәк кайдадыр чыннан да кораб һәлакәткә очраган булып чыга. Кем генә булуына карамастан, ул кешенең бәхете бар икән: кораб төзергә кирәк дигән фикер Пенкрофның башына ярый әле бик вакытында килгән һәм аны бүген сынавыбыз да хәерлегә булган. Бер генә көнгә соңга калсак та, шешә су асты ташларына бәрелеп, челпәрәмә киләсе икән.

— Дөрестән дә, шешә суда йөзеп барганда «Хәерле юл»ның биредә туры килүе әйбәт булды,— дип килеште Герберт.

Сайрес Смит Пенкрофка карады:

— Бу хәл сәер тоелмыймы сезгә?

— Безнең бәхет басты дип кенә уйлыйм мин,— дип җавап бирде диңгезче.— Нигә сәер тоелды соң ул сезгә, мистер Сайрес? Шешә нигә бире килеп чыкмасын икән?

Барыбер кая да булса йөзеп барып чыгарга тиеш иде бит инде ул?

— Әйе шул, бәлкем, сез хаклыдыр, Пенкроф. Шулай да...

— Шешә диңгездә озак йөзмәгән,— диде Герберт.

— Әйе шул, эчендәге язуы да яңарак кына язылганга охшый. Сезгә дә шулай тоеламы, мистер Сайрес?

— Нәрсә дип әйтсәм дә кыен. Хәер, боларны без тиздән белербез! — диде Сайрес Смит.

Бу сөйләшү вакытында Пенкроф кул кушырып утырмады. Ул корабны икенче ягына борды, һәм «Хәерле юл», барлык җилкәннәрен киереп, Тырнак борынына таба кызу йөзеп китте. Аларның һәрберсе Табор утравына аяусыз язмыш китереп ташлаган бәхетсез кеше турында уйлый иде. Ул бичараны коткарырга соңга калмадылар микән инде, коткара алырлар микән? Утрау хуҗалары тормышында моңарчы күрелмәгән зур вакыйга иде бу. Алар үзләре дә шундый язмышны башларыннан кичерделәр бит. Әмма алар аның хәлен үзләренекеннән кыенрак дип исәплиләр һәм аңа тизрәк ярдәм кулы сузуны үз бурычлары саныйлар иде.

Тырнак борынын әйләнеп узып, «Хәерле юл» сәгать дүртләрдә Рәхмәт елгасы тамагына кайтып җитте һәм якорь салды.

Шул ук кичтә бик җентекләп сәяхәт планын төзеделәр. Утрауга Пенкроф белән Герберт барса, әйбәтрәк булыр, чөнки икесе дә корабны йөртә беләләр. Иртәгәсен, 11 нче октябрьдә, кузгалып китсәләр, унөчендә көндез утрауга барып җитәчәкләр, чөнки җил уңай исеп торганда йөз илле миль араны ике тәүлектә узарга мөмкин; бер көн утрауда торып, өч-дүрт көн юлда кайтсалар, 17 нче октябрьдә Линкольн утравында булачаклар. Көннәр эле матур тора, барометр әкрен генә өскә күтәрелә, җил дә гел бер юнәлештән исә, кыскасы, бәлагә тарыган кешегә ярдәм кулы сузу өчен газиз утрауларын ташлап китүче батыр сәяхәтчеләргә һәр яктан уңай килеп тора иде.

Димәк, Сайрес Смит, Наб белән Гедеон Спилет өйдә кала; әмма үзенең «Нью-Йорк геральд» газетасы хәбәрчесе икәнлеген бер генә минутка да истән чыгармаган Гедеон Спилет мондый форсатны кулдан ычкындырырга риза түгеллеген, судан йөзеп булса да барырга әзер икәнлеген әйткәч, ул да сәяхәтчеләр арасына эләкте.

Кич белән алар «Хәерле юл»га урын-җир, савыт-саба, сугыш кораллары, ядрә һәм дары, компас, бер атналык азык-төлек ише әйберләрне илттеләр, барысын тиз генә төяп, Гранит сарайга әйләнеп тә кайттылар. Иртәгәсен иртән сәгать биштә өч сәфәрче утрауда калучы дуслары белән хушлашып аерылыштылар. Пенкроф җилкәннәрне күтәрде, һәм кораб Тырнак борынына таба кузгалып китте. Борынны урап узгач, алар көньяк-көнбатышка таба юл тотарга тиешләр иде.

«Хәерле юл» ярдан чирек миль киткәч, сәяхәтчеләр Гранит сарай мәйданчыгында ике кешенең кул болгап басып торганын күрделәр, болар Сайрес Смит белән Наб иде.

— Әнә безнең дусларыбыз! Ел ярым бергә яшәү дәверендә беренче тапкыр бер-беребездән аерылырга туры килде,— диде Гедеон Спилет.

Пенкроф, журналист һәм Герберт дусларына соңгы тапкыр кул болгадылар, һәм тиздән Гранит сарай Тырнак борынының биек кыя яры артына күмелеп күздән югалды.

Иртәнге якта «Хәерле юл» утрауның көньяк өлешен күздән җуймыйча йөзеп барды. Утрау суднога яшел кәрзин кебек булып күренә, гүя кәрзин уртасыннан Франклин тавы калкып чыгып тора. Утрауның таулы-кыялы өсте еракка киткән саен томанга төренә бара, бу якларга очраклы рәвештә берәр кораб килеп чыкса да, аңа игътибар итүе икеле иде.

Көндез сәгать икеләрдә яр буеннан ун миль ераклыктагы Елан борыны турысыннан узып киттеләр. Бирелән Франклин тавы итәгенә кадәр сузылган көнбатыш яр күренми иде инде. Ә тагын өч сәгатьтән Линкольн утравы дигән нәни генә җир офык артына күмелде.

«Хәерле юл» кызу бара. Дулкыннарны уйнап кына диярлек кичә, тизлеге дә әйбәт. Пенкроф топсель җилкәнен дә күтәрде. Кораб, барлык җилкәннәрен киереп, компас күрсәткән юнәлештә туп-туры Табор утравына таба йөзде.

Герберт билгеле бер вакыттан соң рульдәге Пенкрофны алыштыра; ул корабны ышанычлы алып бара, курстан читкә чыкмый. Капитан яшь ярдәмчесенә бер генә шелтә дә әйтә алмады.

Гедеон Спилет әле капитан белән, әле Герберт белән сөйләшеп бара, җилкәннәрне күтәрешергә, төшере-

шергә булыша. Капитан үз экипажыннан канәгать иде, мактап кына тора, «вахтадан соң берәр стакан шәраб белән сыйлыйм әле сезне», дип ымсындырган булды.

Кичке эңгер-меңгердә тар гына ай урагы калыкты; уналтынчы числода айның чиреге була. Бераздан ай төныкланып батты да. Төн караңгы һәм йолдызлы иде, иртәгә көннең аяз буласын вәгъдә итә иде. Кинәт көчле җил чыкса дип Пенкроф топсельне җыя төште. Бәлкем бу саклану чарасы артык та булгандыр, чөнки төн бик тыныч күренә. Әмма уяулык күрсәткән өчен аны гаеп итү кирәкмәстер.

Журналист төнлә тынычлап йоклады. Пенкроф белән Герберт ике сәгатьтән ике сәгатькә алмашынып руль янында вахтада тордылар. Диңгезче Гербертка үзенә ышангандай ышана иде. Уйлап эш итүчән акыллы егет аның йөзенә кызыллык китерми, капитанның боерыкларын җиренә җиткереп үтәп, корабны төгәл курстан алга алып бара иде.

Төн тыныч үтте. 12 нче октябрьдә көндез дә әллә ни яңалык булмады. «Хәерле юл» көне буе көньяк-көнбатышка таба йөзә бирде. Әгәр берәр билгесез су агымы читкә авыштырмаса, кораб Табор утравына туры чыгарга тиеш.

Океан өсте буп-буш. Фәкать кайчак аларның баш очыннан берәр зур кош — альбатрос яки фрегат очып уза. Гедеон Спилет «Нью-Йорк геральд» газетасына язган мәкаләсен тагып җибәргән кош шулар арасында юк микән дип уйлап куя. Тын океанның Табор утравы белән Линкольн утравы урнашкан бу тирәләренә әлеге көчле канатлы кошлар гына килеп-китеп йөриләрдер, күрәсең.

— Елның бу вакытларында кит аулаучы суднолар Тын океанның көньягына килеп чыгарга тиешләр иде бит югыйсә. Моннан да буш диңгез дөньяда да юктыр,— дип куйды Герберт.

— Алай ук буш түгел лә инде! — дип каршы төште Пенкроф.

— Нигә буш булмасын? — дип сорады журналист.

— Менә без бар бит. Безнең судноны баткан кораб ватыгы димәкче буласың мәллә, әллә без үзебез дельфиннармы? — дип үз сүзеннән үзе шаркылдап көлде Пенкроф.

Сәяхәтчеләрнең исәпләвенчә, сәгатенә өч миль тирәсе тизлек белән баручы «Хәерле юл» Линкольн ут-

равыннан кузгалып киткәннән бирле инде йөз егерме миль юл узгандыр. Җил әкрен исә, бөтенләй туктарга җыена ахрысы. Әгәр алдан дөрес исәпләгән булсалар һәм кораб курстан чыкмаган булса, иртәгә иртән Табор утравы күренер дип өмет итәләр иде.

12 нче октябрьдән 13 нче октябрьгә каршы төнне берсе-бер керфек тә какмады.

Борчылып таң атуын көттеләр. Күңелләренә төрле-төрле шикле уйлар килеп, йокыны качырды. Алар Табор утравына якынайдылар микән инде? Бәлагә тарыган кеше әле дә исән микән? Ул бичара кем икән соң? Аларның тату гаиләсенә килгәч тынычлыкны бозмасмы? Бер ябылу урынын икенчесенә алыштырырга риза булырмы? Бу сорауларга җавап фәкать иртәгә генә табылачак.

Таң нуры сызылуга алар көнбатыш офыкны текәлеп күзәтә башладылар.

Сәгать иртәнге алтылар тирәсе иде микән, Пенкроф кинәт:

— Җир! — дип кычкырып җибәрде.

Пенкрофның күзе алдамаган икән, чыннан да алда җир күренде.

Кечкенә экипажның шатлануын күз алдына китерсәгез икән! Берәр сәгатьтән алар җиргә барып җитеп, ярына аяк басачаклар бит!

Унбиш мильдән дә ары булмастыр, дулкыннар арасыннан утрауның сөзәк яры чак күренеп тора. «Хәерле юл» курстан аз гына көньякка авышкан икән, аны чак кына бора төштеләр, һәм ул туп-туры утрауга таба юнәлде. Чыгып килгән кояшның алсу нурлары утрауның тәбәнәк тау башларын яктыртты.

— Кая инде монда безнең Линкольн белән ярышу! — диде Герберт — Тик бер уртаклык бар: бу утрау да вулкан атканнан соң барлыкка килгәндер, күрәсең.

Сәгать унберләрдә утрауга барып җитәргә ике миль чамасы калды. Таныш булмаган су юлыннан Пенкроф «Хәерле юл»ны бик сакланып алып барды.

Утрау хәзер бөтен буена күренә, анда да Линкольн утравындагы кебек биек-биек чәер агачлары үсеп утыра иде. Ләкин, ни гаҗәп, кеше яшәгәнлеге сизелми: төтен-мазар да чыкмый, бәлагә очраучылар барлыгын белгертердәй берәр билге-фәлән дә күренми.

Һәлакәткә очраган кеше шушы утрауда яши диелгән иде бит инде язуда. Ул ярдәм көтәдер бит!

Ә «Хәерле юл» су асты ташлары арасыннан борыла-сарыла кыю гына алга йөзә. Пенкроф су юлын бик җентекләп карап бара. Ул рульне Гербертка тоттырды, ә үзе борынга барып басты да кулына җилкән бавын алды, җилкәннәрне җыярга әзерләнде. Гедеон Спилет, бинокль белән яр буйларын күзәтсә дә, берни күрмәде.

Ниһаять, көн үзәгендә «Хәерле юл» түше белән яр комына барып терәлде. Сәяхәтчеләр якорь төшереп, җилкәннәрне җыйдылар һәм ярга аяк бастылар.

Шик юк, Табор утравы шушы булырга тиеш. Соңгы карталарда да Тын океанның Яңа Зеландия белән Америка яры арасында аннан бүтән утрау юк иде.

Су чигенгәндә дулкыннар диңгез эченә алып кереп китмәсен дип корабны әйбәтләп бәйләделәр. Яхшы коралланган өч сәяхәтче яр буеннан ярты миль ераклыкта күренеп торган, диңгез өсте тигезлегеннән ике йөз илле, өч йөз футлар чамасы биеклектәге тауга таба юнәлделәр.

— Тау башына менеп, утрауны өстән карап төшик, аннары эзләве җиңелрәк булыр,— диде Гедеон Спилет.

— Мистер Смит та бит Линкольн утравын башта Франклин тавына менеп күзәтеп төште! — диде Герберт.

— Әйе шул, сәяхәтне шуннан башларга кирәк! — дип җөпләде журналист.

Дуслар гәпләшә-гәпләшә тау итәгенә хәтле сузылган болын буйлап киттеләр. Баш өстендә, нәкъ Линкольн утравындагы кебек үк, кыя күгәрченнәре, диңгез карлыгачлары очып әйләнә. Сул яклап урман сузыла, аннан шыртлап сынган ботак тавышлары ишетелгәли, биек үлән селкенгәне күренеп-күренеп кала: ниндидер куркак җәнлекләр болардан өркешеп чабышып китәләрдер, күрәсең. Тик бер җирдә дә кеше барлыгы сизелми әлегә.

Сәяхәтчеләр тау янына килеп җиттеләр. Тиз генә башына менеп, әйләнә-тирәне карарга керештеләр.

Утрау озынча түгәрәк, әйләнәсе алты миль чамасы булыр, яр сызыгы тигез, эчкә иңеп кергән култыклары, очлаеп чыккан борыннары күренми. Ә әйләнә-тирәдә офыкка хәтле буп-буш су өсте ялтырый, ник берәр коры җир кисәге яки берәр җилкәнле кораб күренсен!

Бер ягы гына үсемлекләргә бай һәм уңдырышлы, ә икенче өлеше сусыз кыргый дала белән капланган Линкольн утравыннан аермалы буларак, бу утрауның өс-

тен тоташ урман каплаган иде. Тигез яшеллек эченнән тәбәнәк кенә ике-өч тау калкып тора. Иркен болын уртасыннан аккан елга утрауны кыеклап кисеп уза, диңгезгә койган тамагы киңәеп күренә.

— Утрауның җире аз,— дип куйды Герберт.

— Аз шул, безгә монда яшәргә кысан булыр иде,— диде Пенкроф.

Журналист та сүзгә кушылды:

— Өстәвенә монда кеше дә яшәми бугай.

— Әйе шул, кеше барлыгы сизелми,— диде Герберт.

— Әйдәгез, таудан түбән төшеп, эзләргә керешик,— дип тәкъдим итте Пенкроф.

Диңгезче һәм аның иптәшләре кораб торган җиргә әйләнеп кайттылар. Башта җәяүләп яр буйларын әйләнеп чыгарга, аннары урман эченә кереп эзләргә карар иттеләр. Утрауның һәммә җирен карап чыгарга иде.

Яр буйлап баруы җиңел иде, кайбер урыннарда кыялар очраса да, аларны урап узуы читен булмады. Сәяхәтчеләр көньякка юл тоттылар, су кошлары һәм тюленьнәр, кешеләрне ерактан күрүгә, куркып диңгезгә сикереп төшәләр иде.

— Җәнлекләрнең кешене беренче тапкыр гына күрүе түгел,— диде журналист.— Алар бездән куркалар, димәк, кешене таныйлар.

Бер сәгатьтән дуслар көньяк яр чигенә килеп життеләр һәм төньякка борылдылар, буйдан-буйга урман, ком һәм таш кыялар белән капланган көнбатыш яр өсләп киттеләр.

Алар бөтен яр буйларын дүрт сәгать эчендә йөреп чыктылар, ләкин бер кайда да кеше эзен очратмадылар.

Гаҗәп хәл иде бу. Гүя Табор утравында гомумән бер кайчан кеше яшәмәгән, һәрхәлдә, күптән инде монда кеше яшәмәгән диярсең. Бәлкем, теге язу бик күп айлар элек, яисә күп еллар элек язылган булгандыр; бәлкем, һәлакәткә очраган кеше инде иленә кайтып киткәндер яки мондагы авыр тормышка түзә алмыйча үлеп калгандыр.

Пенкроф, Гедеон Спилет һәм Герберт бу хәлне төрлечә юрап, төрле фараз корып ашык-пошык кына каютага кайтып ашап алдылар,— караңгы төшкәнче утрауны карап бетерү өчен, тагын юлга чыгарга кирәк иде.

Кичке сәгать бишләр тирәсендә алар яшел урман эченә кереп киттеләр.

Аларны күргә ниндидер хайваннар төрлесе төрле якка чабышып качалар иде; болар Европада үрчетелә торган кәҗәләр һәм дуңгызлар булып чыкты. Мөгаен, йорт терлекләрен кит аулаучы берәр судно бирегә алып килгәндер дә, мондагы уңай шартларда алар тиз үрчеп киткәннәрдер. Герберт Линкольн утравына алып кайту өчен аларның берәр парын ничек тә тотарга булды.

Шик калмады хәзер, кайчандыр утрауда кешеләр яшәгән. Урман эченә кергәч, юлчыларның бу фикере тәмам ныгыды, чөнки анда балта белән чабып аударылган агачлар очрый башлады, һәр җирдә кешенең табигатькә каршы көрәшкән эзләре күренеп тора иде. Дөрес, агачлар моннан күп еллар элек чабылган, инде череп-таркалып баралар, балта эзләренә мүк үскән, кеше йөргән сукмакларны биек куе үлән басып киткән, алар хәзер хәтта беленми дә диярлек.

— Кешеләр монда азга гына тукталмаганнар, бәлки күпмедер яшәгәннәр булса кирәк. Кемнәр булды икән алар? Ничәү булганнар? Күпмесе исән калды икән? — диде Гедеон Спилет.

— Язуда фәкать бер кеше турында әйтелә,— диде Герберт.

— Без аны тапмый калмабыз! — диде Пенкроф.

Эзләүне дәвам иттерделәр. Утрауны кыеклап кисеп үтә торган сукмак буйлап атладылар, һәм ул аларны диңгезгә коючы инешкә алып чыкты.

Европадан китерелгән йорт терлекләре, агачлардагы балта эзләре генә түгел, утрауда очраган кайбер үсемлекләр дә монда кеше яшәгәнлеген раслый иде. Аланнарда кайчандыр бик күптән түтәл-түтәл яшелчә утыртылган булган.

Бәрәңге, кишер, кәбестә, шалкан очраткач, Герберт бик куанды, аларны алып кайтып, Линкольн утравында да игеп үстерергә уйлады.

— Менә шәп булды! Набка кирәк иде болар! — дип куанды Пенкроф.— Әгәр һәлакәткә очраган кешене тапмасак та, сәяхәтебез файдасызга китмәде, алла мәрхәмәтен салды.

— Анысы ярады яравын, тик яшелчә түтәлләре бик ташландык бит, утрауда күптәннән кеше яшәмидер, күрәсең,— диде Гедеон Спилет.

— Әлбәттә, әгәр монда берәрсе булса, бу яшелчәләргә кул селтәр идемени! — диде Герберт.

— Тегеләй-болай юрап торасы калмаган инде, һәлакәткә очраган кешенең утраудан киткәнлеге бер карауда күренеп тора! — дип нәтиҗә чыгарды Пенкроф.

— Язу күптән язылган дисезмени?

— Әлбәттә!

— Шешә бик озак диңгездә йөзеп йөргәннән соң гына Линкольн утравына килеп чыккан микәнни?

— Нигә шулай булмасын икән? — диде Пенкроф һәм: — Караңгы төшеп килә, эзләүне туктатырга вакыт, — дип өстәде.

— Каютага кайтыйк инде, иртәгә өр-яңадан эзли башларбыз, — дип тәкъдим итте журналист.

Аның киңәшен тотып сәяхәтчеләр кузгалырга дип җыенганнар иде, кинәт Герберт агач арасыннан бер каралты күреп алды да аңа төртеп күрсәтеп:

— Карагыз әле, алачык! — дип кычкырып җибәрде.

Дуслар дәррәү алачыкка таба йөгерделәр. Эңгер-меңгердә аның стеналары тактадан корылган булуы, ә өсте сумалаланган киндер белән ябылган икәнлеген шәйләргә мөмкин иде.

Пенкроф ябылмый калган ишекне төбенә хәтле ачып, эчкә керде.

Алачык эче буш иде!

Ундүртенче бүлек

Әйбер-сәйберләрнең исәбен алу. — Төн. — Берничә хәреф. — Эзләнүләрне дәвам иттерү. — Үсемлекләр һәм хайваннар. — Герберт чак исән калды. — Корабта. — Утраудан китү. — Көн бозыла. — Гадәт онытылмаган. — Диңгездә адашу. — Коткаручы ут.

Пенкроф, Герберт һәм Гедеон Спилет, сүзсез калып, караңгы алачыкта басып тора бирделәр.

Пенкроф каты кычкырып хуҗага дәшеп карады.

Җавап булмады.

Шуннан соң ул чакма чагып коры агач ботагына ут кабызды да алачык эчен яктыртып җибәрде, һәм юлчылар монда кеше тормаганын искәрделәр. Таштан өеп ясалган учакта суынган көл калган, аның өстендә яныл бетмәгән коры-сары күренә. Пенкроф кулындагы утлы кисәүне учакка ташлады, ботакларга ут кабынып китте һәм алар чарт-чорт яна башладылар, алачык эчен ялкын яктыртып җибәрде.

Дуслар түрдә дым тартып саргайган юрган җәелгән ятак күреп алдылар,— аңа күптәннән бирле берәү дә ятмаган ахрысы; учак янында тутыгып беткән ике нәни чиләк, йөзтүбән капланган җамаяк ята, шкафта күгәрә башлаган диңгезче киеме эленеп тора, өстәл өстендә тутыккан кургаш тәлинкәләр, яшел күгәрек каплаган Инҗил ята; почмакта көрәк, китмән, кәйлә, берсе ватык, берсе төзек ике ау мылтыгы ауный; шүрлектә бер мичкәдә дары, икенчесендә ядрә, ике-өч вак тартмада капсульләр тора; барысының өстенә күп еллардан бирле җыелган калын тузан утырган.

— Беркем юк,— диде, ниһаять, журналист.

— Берәү дә юк! — дип җөпләде Пенкроф.

— Монда күптән кеше яшәми бугай,— дип өстәде Герберт

— Әйе шул, бик күптәннән яшәми,— диде журналист.

— Мистер Спилет, әллә алачыкта гына төн кунабызмы? — дип тәкъдим итте Пенкроф.

— Мин риза,— дип җавап бирде Гедеон Спилет,— өйнең хуҗасы кайтса да, чакырылмаган кунакларга ачуланмас әле.

Диңгезче башын чайкады:

— Юктыр, хуҗасы кайтмас! — дип куйды.

— Утраудан киткәндер дип уйлыйсызмы? — дип сорады журналист.

— Юк. Киткән булса, мылтыкларын, инструментларын үзе белән алган булыр иде,— диде Пенкроф.— Һәлакәт кичергән кеше исән калган әйберләрнең кадерен белә, анысын үзегез дә аңлыйсыз. Ай-һай, юктыр, юк; ул утраудан китмәгән,— дип кабатлады Пенкроф ышанып.— Әгәр ул көймә ясап, аңа утырып киткән булса, бу иң кирәкле әйберләрнең берсен дә калдырмас иде! Юк, ул хәзер дә утраудадырсыман миңа!

— Әллә тередер дисеңме? — дип сорады Герберт.

— Йә тере, йә үлгән. Әгәр үлгән булса, үзен-үзе күммәгәндер әле, сөякләрен табарбыз,— диде Пенкроф.

Дуслар ташландык алачыкта төн уздырырга булдылар; утын җитәрлек иде, мичкә кызу итеп яктылар. Ишекне ябып, Пенкроф, Герберт һәм Гедеон Спилет эскәмиягә килеп утырдылар, һәм һәрберсе үзалдына уйга батты. Алар сирәк-мирәк кенә сүз алышкаладылар. Кеше шундый икеле-микеле халәттә чакта төрлечә фараз кора, көтелмәгән нәрсәләргә әзер була; алар да

урманнан ишетелгән һәр авазга колак салалар иде. Әгәр шунда кинәт ишек ачып берәү килеп керсә, алар һич тә шаккатмаслар иде; һәлакәткә очраган ялгыз кешенең кулын дусларча ихластан кысарлар иде. Кем икәнен белмәсәләр дә, алар аны бик көтәләр иде.

Сәгать артыннан сәгать узды, ә ишек ачылмады, аяк тавышы да ишетелмәде...

Төн бик озын тоелды! Герберт кына ике сәгать йоклап алды, чөнки аның яшендә йокысыз түзүе авыр хәл. Өчесенең дә тизрәк тегене эзләргә чыгасылары килә, утрауның барлык аулак почмакларын күрәселәре килә. Пенкрофның сүзе дөрескә чыкса кирәк, ташландык өйгә, әйберләргә, коралларга карагач, монда яшәгән кеше вафат булган дигән уй туа. Шуңа күрә алар аның сөякләрен табып, христиан йоласы кушканча күмүне үз бурычлары саныйлар иде.

Таң атты. Пенкроф һәм аның иптәшләре алачык эчен тагын бер әйбәтләп карап чыктылар. Ул уңайлы урынга, кечерәк кенә тау итәгенә, матур чәер агачлары ышыгына салынган. Алгы яктан агачларны кисеп, киң ачыклык ясалган, аннан диңгез күренеп тора. Диңгез ярына хәтле болын сузылып төшә, әйләндереп алган киртәсе инде җимерелеп бетә язган, болынның сул ягыннан инеш ага, ул диңгезгә коя.

Алачык такталардан корыштырылган, такталар берәр корабның тышлыгы, яисә палубасыннан сүтеп алынган булса кирәк. Һәлак булган судноны диңгез дулкыннары утрау ярына чыгарып ташлагандыр, арадан исән калган берәү, инструментларны табып, кораб ватыкларыннан шушы алачыкны әмәлләп куйгандыр, мөгаен.

Гедеон Спилет алачыкны әйләнеп чыккач, бер тактада җуелып бетә язган: «Б...тан...я» дигән хәрефләрне күргәч, моңа шик калмады.

Журналист Пенкрофны чакырып китерде, тегесе язуны:

— Британия! — дип кычкырып укыды.— Күп судноларга «Британия» дигән исем кушылган. Тик Америка судносымы яки Англиянекеме икәнен әйтә алмыйм,— диде.

— Кемнеке булса да барыбер бит, Пенкроф!

— Әйе шул, кайсы илнеке булса да булсын, әгәр исән икән, без аны коткарачакбыз. Тик эзләргә чыгып киткәнче, «Хәерле юл»ны карап килергә кирәк.

Пенкроф үз корабы өчен борчыла иде. Әгәр утраудa кешеләр яшәсә, берәрсе аны кулга төшерергә теләмәсме дигән шикле уй керде аның күңеленә. Әмма ул үз уеннан үзе уңайсызланып җилкәсен җыерып куйды.

Һәрхәлдә, ул «Хәерле юл»да иртәнге ашны ашап алуга шат иде. Яр буена таба илтүче сукмак озын түгел, күп дигәндә ярты миль чамасыдыр. Сәяхәтчеләр корабларына таба юнәлделәр. Барган уңайда урман эчләрен, һәр куак төбен карый-карый бардылар. Юлда алардан куркып көтү-көтү кәҗәләр, дуңгызлар як-якка чабышып китәләр иде.

Егерме минутлап барганнан соң сәяхәтчеләр көнчыгыш ярга килеп чыктылар, якорьга бәйләнгән килеш комда тирән батып утырган корабларын күрделәр.

Пенкроф тирән сулап куйды. Кораб аның баласы бит, ә ата кешенең акылга буйсынмыйча, хискә бирелергә, балалары өчен борчылырга хакы юкмы. Юлчылар үз каюталарына менделәр һәм төшкә хәтле, дөресе — кичкә хәтле түзәрлек булсын дип нығытып ашадылар. Аннары әйбәтләп эзләргә дип утрауның эченәрәк кереп киттеләр. Утраудагы кеше күптән үлгәндер инде, мөгаен. Сәяхәтчеләр аны тере килеш табудан өмет өзеп, сөякләрен булса да очратмабызмы дип уйлыйлар иде. Ләкин төшкә хәтле бөтен урманны бетереп йөрсәләр дә, берни тапмадылар. Һәлакәткә очраган кешенең сөяге дә калмаган, ерткыч җанварлар аның үләксәсен дә ашап бетергәндер, күрәсең.

Көндезге сәгать икеләр тирәсендә эзләүчеләр тәмам арып, биек нарат агачы күләгәсенә ял итәргә утырдылар.

Пенкроф иптәшләренә:

— Иртәгә таң белән кайтыр юлга кузгалырбыз,— диде.

— Өйдәге әйберләрне, коралларны, инструментларны алып китсәк, намуссыз дип гаепләмәсләр бит безне,— диде Герберт.

— Мин дә андагы әйберләрне алып кайту ягында. Эшкә ярарлар. Ялгышмасам, алачыкта ядрә белән дары да шактый бар бугай,— диде Гедеон Спилет.

— Берәр пар дуңгыз тотып кайтырга да кирәк булыр, безнең Линкольн утравында йорт дуңгызлары юк бит...— дип искә төшерде Пенкроф.

— Яшелчә орлыкларын да җыярбыз,— дип өстәде

Герберт.— Ул чагында бездә Иске һәм Яңа дөньяда үсә торган һәммә яшелчә булачак.

— Әллә Табор утравында тагын берәр тәүлек торабызмы, үзебезгә ярардай нәрсәләрне судпога ташыр идек.

— Юк, мистер Спилет,— дип кырт кисте Пенкроф.— Иртәгә иртүк кузгалып китәбез. Җилнең юнәлеше үзгәрә, ул көнчыгыштан исә башлады; монда килгәндә җил уңай исә иде, кайтканда да арттан искән җил уңаена кайтып калыйк.

Герберт сикереп торды:

— Әйдәгез алайса, көнне бушка уздырмыйк!

— Әйе шул, вакытны әрәм итмик,— диде Пенкроф та.— Син орлыклар җый, аларны яхшырак таныйсың; ә без мистер Спилет белән дуңгыз аулыйк; ярдәм итәргә Топ булмаса да, берәр пар дуңгызны тота алырбыз бәлкем.

Герберт сукмактан яшелчәлеккә юнәлде, ә дингезче белән журналист урманга кереп киттеләр.

Утрауда төрле нәселле дуңгызлар очрый; алар шул хәтле елгыр, кешеләрне күрүгә як-якка качып бетәләр, беркемне якын китермиләр иде. Ярты сәгатьләп эзәрлекләп йөргәч, аучылар шулай да ешлык арасына кереп поскан бер пар дуңгызны тотып ала алдылар. Шул чак кинәт каяндыр төньяктан берничә йөз метр гына читтән ачыргаланып кычкырган тавыш ишетелде. Аңа ниндидер ерткыч ырылдавы кушылды.

Пенкроф белән Гедеон Спилет, дуңгызларны бәйләп азапланган җирдән тураеп, тавышка колак салдылар, дуңгызлар исә шуннан файдаланып качып киттеләр.

— Герберт тавышы бит бу! — диде журналист.

— Йөгердек! — диде Пенкроф.

Икесе дә тавыш килгән якка чаптылар.

Ашыгып дөрес иткәннәр: сукмак борылган төштә алар аланга килеп чыктылар, алан уртасында бик зур маймылга охшаган ниндидер ерткыч җанвар Гербертны җиргә бәреп еккан да бугазыннан буып азаплана иде.

Пенкроф белән Гедеон Спилет яшен тизлеге белән ерткычка ташланып, аны җиргә бәреп төшерделәр һәм Гербертны коткардылар. Геркулестай ярау Пенкроф һәм аның кебек үк көчле журналист ерткычны, ярсып көрәшүенә карамастан, селкенмәслек тә итеп бәйләп тә куйдылар.

— Сине җәрәхәтләмәдеме ул, Герберт? — дип сорады Гедеон Спилет.

— Юк, юк.

Пенкроф ярсып ерткычка янады:

— Ботарлап кына карасын, мин ул маймыл актыгын!..

— Маймыл түгел ул! — диде Герберт.

Гербертның сүзен ишеткәч, Пенкроф белән Гедеон Спилет аптырап җирдә яткан сәер җанварга төбәлделәр.

Кара син, чынлап та, маймыл түгел икән ул. Кеше затыннан икән, валлаһи кеше икән! Нинди диген син! Кыргыйланып беткән, вәхшигә әйләнгән куркыныч зат! Аның килеш-килбәте имәнгеч иде: кием урынына биленә сәләмә чүпрәк кисәге бәйләгән, чәчләре чәбәләнеп беткән, пычрак сакалы күкрәгенә хәтле салынып төшкән, күз карашы алмашынган, көрәктәй кулының тырнаклары кош тырнагыдай озын булып үскән, бите чуен китеге кебек кап-кара, аяк табаннары каешланып катып тояккa әйләнгән,— кеше затыннан булса да, әнә шундый хәшәраткә әйләнгән мәхлук иде ул. Аңа карагач, ирексездән күңелдә: акыл дигәне сау калды микән соң моның, әллә хайвани теләкләре генә сакланды микән дигән сорау туа иде.

Пенкроф журналисттан:

— Сез моны кеше дисезме, яки кайчандыр кеше булган дип уйлыйсызмы? — дип сорады.

— Кызганычка каршы, кеше шул, шик булуы мөмкин түгел,— дип җавап бирде журналист.

— Бу теге һәлакәткә очраган кешемени? — дип кычкырып ук җибәрде Герберт.

— Әйе,— диде Гедеон Спилет,— ләкин ул бичараның кеше диярлеге калмаган инде.

Хаклыкка туры килә иде бу: әнә бит, күз алдында, бу тоткын утрауда ялгыз яшәүдән кыргыйланып кына калмаган, бәлки, чын ерткычка әверелгән. Ерткыч хайван тешедәй үткер тешләрен ыржайтып ырылдый үзе. Ә тешләре чи ит ашарга җайлашкандыр, күрәсең. Үзенең кеше икәнлеген ул инде күптән оныткан булса кирәк; инструментлар, мылтык белән эш итә белми, уттан да файдалана алмый ахрысы. Үзе бик көчле, елгыр булса да, бу сыйфатлары акыл сыйфатлары кимү исәбенә генә алга киткәндер, күрәсең.

Гедеон Спилет аңа сүз кушып караган иде, тик ул үзенә мөрәҗәгать иткәнне аңламады да бугай, хәтта

ишетмәде дә ахрысы... Әмма күзенә текәлебрәк карагач, журналист аның акылы бөтенләй үк сүнмәгән икәнлеген төшенде.

Тоткын исә тыныч кына ята бирде, дуларга, бәеннән ычкынырга маташмады да. Бәлкем, ул кешеләрнең үзенә охшаган зат икәнлеген күреп, буйсынырга исәпләгәндер? Бәлкем, зиһененең берәр почмагында ялтырап киткән ниндидер хатирә аның кеше икәнлеген исенә төшергәндер? Әгәр аяк-кулларын чишсәң, ул качып китәр иде микән, әллә калыр идеме? Әмма сәяхәтчеләр аны ирекка җибәрергә ашыкмадылар. Гедеон Спилет бу бичарага игътибар белән карап торды да:

— Кем генә булмасын, үткәндә ни белән генә шөгыльләнмәсен, киләчәктә нинди хәлгә генә төшмәсен, аны Линкольн утравына алып кайту — безнең бурычыбыз! — диде.

— Әлбәттә шулай,— дип әләктереп алды Герберт.— Әгәр дә әйбәт мөгамәлә күрсәтсәк, бәлкем, мескеннең зиһене кайтыр әле!

Пенкроф, ай-һай, булыр микән дигәндәй, башын чайкап торды.

— Алай да тырышып карыйк әле, кеше бит! — диде журналист.

Чыннан да, кешелек бурычы аларны шуңа мәҗбүр итә иде. Өчесе дә аны алып кайтырга кирәклеген төшенделәр һәм Сайрес Смитның аларны хуплаячагын беләләр иде.

— Аны бәйләнгән килеш калдырыйкмы? — дип сорады диңгезче.

— Әгәр аякларын чишсәк, безнең арттан үзе бармас микән? — дип тәкъдим итте Герберт.

— Сынап карыйк! — диде диңгезче.

Кулларын бәйләүле килеш калдырып, тоткынның аягын чорнаган бауны кисеп җибәрделәр. Ул аягүрә басты, әмма качарга исәбе күренмәде. Янәшәсеннән атлап барган өч кешедән күзләрен алмады. Әмма үзенең дә алар шикелле үк кеше икәнлеген, һич югы элек кеше булганлыгын ул күптән оныткан иде, күрәсең. Йөзе сүрән, үзе гыж-гыж сулый, әмма каршылык күрсәтер исәбе чамалы иде.

Журналист аны алачыгына алып барыйк әле, үз әйберләрен күргәч, зиһене ачылмас микән дип киңәш итте. Бу бичараның томаланган зиһенен, сүнгән җанын тергезеп җибәрү өчен, бәлкем, бер очкын җитәдер...

Алачык ерак түгел иде. Берничә минуттан юлчылар анда барып та җиттеләр. Әмма тоткын үз өенә кайтканын танымады бугай, гүя бу җирләр аңа ят иде!

Кыргый кыяфәтенә карагач, ул бәхетсезнең утрауда инде бик күптәннән бирле тоткынлыкта яшәгәнен, бирегә үз акылында чагында килеп тә, ялгызлыктан әкренләп зиһенен җуйганын чамаларга мөмкин иде.

Журналист учак яксак, тоткынга ничек тәэсир итәр икән дип сынап карамакчы булды. Учак ялкыны хәтта хайваннарны да үзенә тарта бит.

Учакта ут дөрләп китте. Башта теге бичара утка игътибар иткән кебек тоелган иде, әмма бераздан учак яныннан китеп барды, күзендә нур сүнде, мәгънә әсәре тагын юкка чыкты.

Нишләмәк кирәк, әсирне «Хәерле юл»га илтүдән башка чара калмады; сәяхәтчеләр шулай эшләделәр дә, Пенкроф аны каравылларга калды.

Гедеон Спилет белән Герберт башлаган эшләрен төгәлләү өчен яңадан ярга төштеләр, берничә сәгатьтән алачыктагы барлык әйберләрне, коралларны, яшелчә орлыкларын, берничә йорт кошы, бер пар дуңгыз алып, корабка әйләнеп кайттылар. Барысын корабка төяделәр. Иртән су күтәрелә башлауга, «Хәерле юл» юлга кузгалырга әзерләнде.

Әсирне судноның алгы каютасына урнаштырдылар, ул телсез кешедәй тавыш-тынсыз, тыныч кына утыра бирде.

Пенкроф аңа ашарга китергән иде, тоткын пешкән итне этеп кенә җибәрде, ул пешкән иттән күптән бизгән, әлбәттә. Чыннан да, Герберт атып кайткан үрдәкләрнең берсен тәкъдим иткәч, ул ерткыч хайваннарча комсызланып аңа ташланды, кабалана-кабалана ашап та бетерде.

Пенкроф шикләнеп башын чайкап торды да:

— Бу бичараның акылы кире кайтыр дип уйлыйсызмы? — дип сорады.

— Кайтырга тиеш дип уйлыйм, анысы бездән генә тора. Ул ялгызлык аркасында гына шушы хәлгә төшкән бит, бүгеннән соң ул ялгыз булмаячак,— диде Гедеон Спилет.

— Мескен, ул күптән акылын җуйган булса кирәк,— диде Герберт.

— Әйе, күптәндер,— диде журналист.

— Ничә яшьтә икән ул? — дип сорады үсмер.

— Әйтүе кыен,— диде журналист.— Ул сакал-мыекка баткан, әмма яшь түгелдер дип уйлыйм. Ким дигәндә илле яшьтә бардыр.

— Сез игътибар иттегез микән, мистер Спилет, аның күзләре бик эчкә баткан? — дип сорады егет.

— Әйе шул, килеш-килбәтенә караганда акыллы зат дип әйтеп булмаса да, аның күзләрендә акыл чаткысы бар әле.

— Анысын алда күрербез,— диде Пенкроф.— Бу вәхшине алып кайткач, Сайрес Смит нәрсә дияр икән? Әкәмәт! Кеше коткарырга дип килгән идек, вәхши алып кайтабыз. Берни эшләр хәл юк.

Төн имин генә узып китте; тоткын йоклагандырмы-юктырмы, анысын белгән юк; аяк-куллары чишүле булса да, селкенми дә. Ул читлеккә эләккән ерткыч җанварны хәтерләтә иде: ерткыч җанвар да, әсир төшкәч, башта хәрәкәтсез-өнсез катып кала да, аннары ярсып дуларга тотына.

Иртәгесен, 15 нче октябрьдә таң белән, Пенкроф алдан юраганча, һава алмашынды: җил төньяк-көнбатыштан исә башлады, ул «Хәерле юл» өчен уңай иде; әмма диңгездә дулкын купты, күренеп тора: кайтуы җиңел булмаячак.

Иртән сәгать биштә якорьны күтәрделәр. Пенкроф грот җилкәнен корып җибәрде һәм корабны көнчыгыш-төньяк-көнчыгыш юнәлештә — Линкольн утравына таба туры алып китте.

Юлның беренче көне тыныч узды, әллә ни әһәмиятле вакыйга булмады. Тоткын каютасында тын гына утырды,— ни әйтсәң дә, диңгезче бит, диңгез дулкыны аңа уңай тәэсир иткәндер ахрысы. Бәлкем, аның корабта хезмәт иткән чаклары хәтеренә төшкәндер? Һәрхәлдә, ул үзен әйбәт хис итә; мескен хәлгә төшкән кеше кебек түгел, гаҗәпләнгән кешедәй тоела иде.

Иртәгесен, 16 нчы октябрьдә, җил тагын да көчәя төште, төньякка авышты. Бу — «Хәерле юл» өчен уңай түгел иде инде. Кораб дулкыннар өстендә чайкала башлады. Пенкрофка корабны җилгә каршы текә тотарга туры килде; ярсулы дулкыннар бер-бер артлы корабның борынына китереп бәрә. Гәрчә иптәшләренә сиздермәсә дә, диңгезченең күңеленә пошаман керде. Әгәр җил юнәлеше үзгәрмәсә, Линкольн утравына кайту Табор утравына килгәнгә караганда озагракка сузылачак.

Чыннан да, 17 нче октябрьдә иртән, «Хәерле юл»-ның диңгезгә чыгып китүенә ике тәүлектән артса да, утрауга якынаерга исәпләрендә дә юк иде әле. Хәтта ничә миль узганлыкны да исәпләрлек түгел иде, чөнки корабның бару юнәлеше һәм тизлеге туктаусыз үзгәреп тора иде.

Тагын бер тәүлек үтеп китте, ләкин җир күренмәде. Җил хәзер көнчыгыштан исә, диңгез каты давыллый, дулкыннар палубага хәтле күтәрелә. Шуңа күрә әледән-әле җилкәннәрнең торышын үзгәртергә, рифларны алырга, курсны еш алмаштырырга, кыска-кыска галслар белән барырга туры килә. 18 нче октябрьдә бер тапкыр «Хәерле юл»ны дулкын бөтенләй күмеп китте, әгәр сәяхәтчеләр саклык йөзеннән алдан ук үзләрен палубага бәйләп куймаган булсалар, барысын диңгезгә юып төшергән булыр иде.

Пенкроф һәм аның иптәшләре дулкын эчендә чарасыз калдылар, шул чак кинәт әсир аларга ярдәмгә ташланды. Аның диңгезче сиземе уянды ахрысы: ул каютадан өскә сикереп чыкты да колга белән фальшбортны бәреп тиште, палубага җыелган су шуннан агып чыгып бетте; палуба судан арынгач, әсир берсүзсез тагын каютасына төшеп китте.

Пенкроф, Герберт һәм Гедеон Спилет гаҗәпләнүдән тынсыз калдылар һәм моннан соң аның ирегенә тимәскә булдылар.

Әмма аларның хәле мөшкелләнде; диңгезче үзләренең океан уртасында адашып калганлыкларын аңлады, утрауга кайтып җитә алырлармы-юкмы...

18 нче октябрьдән 19 нчы октябрьгә каршы төн бигрәк караңгы һәм салкын булды. Әмма сәгать унберләр тирәсендә җил басыла төште, дулкын кимеде, «Хәерле юл» артык чайкалмый иде инде, ул кызурак бара башлады. Кыскасы, кораб давыл сынавын җиңеп чыга алды.

Пенкроф, Гедеон Спилет һәм Герберт бу төнне керфек тә какмадылар. Бер генә секундка да күзләрен диңгездән алмадылар: әгәр Линкольн утравына ерак калмаган булса, ул таң атканда күренә башларга тиеш иде; әгәр су агымы, яки җил «Хәерле юл»ны читкә авыштырган булса, ул чагында дөрес курсны табуы кыен булачак.

Пенкрофның күңеленә шом төшсә дә, өметен өзмәде; батыр йөрәкле, чыныккан диңгезче, рульне кулыннан

ычкындырмастан, күзгә төртсәң күренмәслек караңгылыкка төбәлеп, һаман утрауны эзләп барды.

Төнге сәгать икеләр тирәсендә ул кинәт урыныннан сикереп торды да:

— Ут күренә! Ут! — дип кычкырып җибәрде.

Егерме миль чамасы ераклыкта төньяк-көнчыгыштарак ут елтырап күренде. Линкольн утравында Сайрес Смит аларга юл күрсәтү өчен яр башына утын өеп учак ягып җибәргән, күрәсең.

Корабның юнәлеше бик купкә төньякка авышкан булган; Пенкроф, курсны үзгәртеп, аны офык читендә якты йолдыз кебек ялкынланып янган утка таба туры алып китте.

Унбишенче бүлек

Утрауга кайту.— Бәхәс.— Сайрес Смит һәм билгесез кеше.— Һава шары порты.— Өченче уңыш.— Җил тегермәне.— Он тарту, икмәк пешерү.— Инженерның фидакярлеге.— Сынау.—Күз яшьләре.

Икенче көнне, 20 нче октябрьдә, иртәнге сәгать җиделәр тирәсендә, дүрт көнлек сәяхәттән соң «Хәерле юл» Рәхмәт елгасы тамагына әкрен генә килеп туктады.

Көннәрнең бозылуыннан һәм иптәшләренең озак кайтмый торуыннан бик борчылган Сайрес Смит белән Наб иртә таңнан бирле Күзәтү яссылыгында аларны көтеп торалар иде. Ниһаять, озак көткән «Хәерле юл» күренде.

— Аллага шөкер, кайттылар! — дип җиңел сулап куйды Сайрес Смит.

Наб сөенеченнән биергә кереште, кулларын чәбәкли-чәбәкли бер урында бөтерелде:

— Ах, хуҗам, хуҗам! — дип такмаклады ул.

Бу тамаша — һәртөрле тантаналы котлау сүзләреннән дә тәэсирлерәк иде!

«Хәерле юл» палубасында басып торган кешеләрне санагач, инженер, сәяхәтчеләр һәлакәткә очраган кешене таба алмаганнардыр яисә теге бичара үз утравын ташлап китәсе килмәгәндер, бер төрмәне икенчесенә алмаштырырга теләмәгәндер, дип уйлады.

Чыннан да, палубада Пенкроф, Герберт һәм Гедеон Спилет өчәү генә басып торалар иде.

Кораб килеп туктаганда, инженер белән Наб инде

яр буенда көтеп торалар иде. Сәяхәтчеләр җиргә аяк басарга да өлгермәделәр, Сайрес Смит:

— Сезнең өчен борчылып беттек, дусларым: бик озакладыгыз! Әллә берәр бәлагә тарыдыгызмы? — диде.

— Юк,— дип җавап бирде Гедеон Спилет,— киресенчә, юлыбыз унды. Хәзер барысын да сөйләп бирербез.

— Беркемне дә тапмагансыз бит, өчәүләп киткән идегез, өчәүләп кайтып кердегез.

— Гафу итегез, мистер Сайрес, без дүртәү,— диде диңгезче.

— Сез һәлакәткә очраган кешене таптыгызмыни?

— Таптык.

— Алып та кайттыгызмы?

— Әйе.

— Тереме ул?

— Тере.

— Кайда соң ул? Кем ул?

— Ул — кеше, дөресрәге, кайчандыр кеше булган! Без әлегә сезгә шунысын гына әйтә алабыз, Сайрес,— диде Гедеон Спилет.

Һәм дусларыбыз инженерга сәяхәт вакытында күргән хәлләрне сөйләп бирделәр. Бәлагә тарыган кешене ничек-ничек эзләүләрен, утраудагы бердәнбер алачыкны ничек табуларын, аның күптән ташландык хәлдә булуын, ниһаять, һәлакәткә очраган кешенең ничек әсир төшкәнлеген, ләкин аңарда кешелек сыйфатлары калмаганлыгын хикәя иттеләр.

— Аны монда алып кайтуын кайттык, ләкин дөрес эшләдек микән? — диде Пенкроф.

— Әлбәттә, дөрес булган, Пенкроф! — диде инженер шундук.

— Акылын җуйган бит ул!

— Җуйгандыр да, ләкин моннан берничә ай гына элек ул да сезнең белән минем шикелле үк кеше булган. Кем белә, безнең арадан исән калган соңгы кеше утрауда ялгызлыктан нинди хәлгә төшәр бит әле. Ялгызлык — бәхетсезлек ул, дусларым. Гаҗәп түгел, ялгызлыктан кеше акылын җуядыр.

— Мистер Сайрес, ул бәхетсезне моннан берничә ай гына элек кыргыйланган дип уйлыйсызмыни?

— Әйе, без тапкан язу күптән түгел генә язылган, аны бары ул гына язган,— дип җавап бирде Сайрес Смит.

— Яисә берәр үлгән иптәше язгандыр,— дип өстәде Гедеон Спилет.

— Юк, иптәше түгелдер, кадерле Спилет.

— Нигә?

— Чөнки ул чакта язуда ике кеше дип күрсәтелер иде, ә анда сүз бер генә кеше хакында бара.

Герберт кайтыр юлда корабны дулкын күмеп киткәч, әсирнең акылына килүен, гүя диңгезче сизгерлеге уянуын сөйләп бирде. Бу хәлгә Сайрес Смитның игътибар итүен үтенде.

— Бу фактны дөрес искәргәнсез, Герберт. Ул бичараны терелтергә мөмкин. Өметсезлеккә бирелү аркасында гына шушы хәлгә төшкән ул. Моннан соң ул кешеләр арасында яшәячәк бит. Аның җаны исән, без аны терелтербез.

Табор утравыннан алып кайткан әсиргә инженер кызганып, ә Наб гаҗәпләнеп озак карап тордылар, аннары аны каютасыннан алып чыктылар; җиргә аяк баскач, әсир качарга омтылып карады.

Әмма Сайрес Смит аның янына килеп буйсындыручан хәрәкәт белән кулын җилкәсенә салды һәм бик тә ягымлы итеп күзенә карады. Әсир, аның ихтыяр көченә буйсынгандай, тынып калды, күзен җиргә төшерде, башын иде, карышмады.

— Бичаракай, ташландык мескен! — дип җәлләп пышылдады инженер һәм аңарга бик игътибар белән карап торды. Килеш-килбәтенә карап хөкем йөрткәндә, бу мескендә кешелек сыйфатларының заты да калмаган, әмма Гедеон Спилет кебек үк, Сайрес Смит та әсирнең күзләрендә сизелер-сизелмәс уй чаткылары барлыгын искәреп шаккатты.

Әсирне, ягъни билгесез кешене, Гранит сарайның бер бүлмәсенә урнаштырырга булдылар, ул аннан качып китә алмас. Утрау кешеләре әсирне моннан соң *билгесез кеше* дип йөртә башладылар. Әсир яңа торагына карышмыйча килеп керде. Иптәшләре киләчәктә Линкольн утравында тагын бер вәкил артачагына шикләнмәделәр.

Журналист, Герберт һәм Пенкроф ачыгуның чигенә җиткәннәр иде, Наб ашыгып кына иртәнге аш әзерләп алды. Ашарга утыргач, Сайрес Смит алардан сәяхәт вакытында күргәннәрен иркенләп сөйләүләрен үтенде.

Билгесез кеше инглиз яки американ булырга тиеш дигән фикергә ул да кушылды: баткан корабның исе-

ме «Британия» булу шуңа ишарәли иде; билгесез кешенең чәчләре тузгыган, бөтен битен сакал-мыек баскан булуга карамастан, Сайрес Смит аның йөз чалымнары англосаксларга охшаганлыгын таныды.

Гедеон Спилет Гербертның хәтеренә төшерде:

— Герберт, син бу кыргый белән ничек очрашуыңны безгә сөйләмәдең бит әле. Әгәр без килеп өлгермәгән булсак, ул сине буып үтерәсе икән — безгә шунысы гына мәгълүм бит.

— Нәрсә сөйлим икән соң, мин белмим дә инде,— дип җавап бирде Герберт.— Тик шунысы хәтеремдә; үсемлек орлыгы җыеп йөри идем, артымда нәрсәдер агач башыннан шапылдап килеп төшкән кебек тоелды... Борылып карарга өлгермәдем, шушы кыргый яшен тизлеге белән миңа ташланды, ул бичара агач башында качып торган булса кирәк; әгәр мистер Гедеон һәм Пенкроф килеп җитмәгән булса, мине...

— Дустым, син үлемнән котылып калгансың,— диде Сайрес Смит,— әмма ул хәл чыкмаса, бу бәхетсезне тапмаган булыр идегез, без яңа иптәшсез калыр идек.

— Сез аннан кеше чыгар дип өмет итәсезмени, Сайрес Смит? — дип сорады журналист.

— Әйе, өмет итәм,— диде инженер.

Ашаганнан соң Сайрес Смит һәм аның иптәшләре өйдән чыгып киттеләр. Яр буена барып, «Хәерле юл»ның йөген бушаттылар. Инженер сугыш коралларын һәм инструментларны җентекләп карап чыкса да, билгесез кешенең кем икәнлеген расларлык дәлил табылмады.

Күрше утраудан йорт дуңгызлары алып кайтулары өчен ул хуплады. Дуңгызларны абзарга илтеп яптылар. Алар яңа җиргә тиз ияләшер дип өметләнәләр иде.

Инженер дарылы, ядрәле мичкәләрне, капсульле тартмаларны алып кайткан өчен дә иптәшләрен мактады. Шартлау хәвефеннән сакланыр өчен, Гранит сарайдан читтә, яки өске мәгарәдә дары базы казып, аларны шунда тотарга карар иттеләр. Әйбәт шартлый торган пироксилинны һаман файдалана торырга булдылар, чөнки аны әлегә дары белән алыштыруның хаҗәте юк иде.

Корабтан йөкне бушатып бетергеч, Пенкроф инженерга:

— Мистер Сайрес, корабыбызны ышанычлырак җиргә куясы иде,— диде.

— Рәхмәт елгасы тамагы янында торса, начармыни? — дип сорады Сайрес Смит.

— Начар, мистер Сайрес. Су чигенгәндә кораб ком өстендә утырып кала, бу бик зыянлы. Үзегез күрдегез, корабыбыз бер дигән шәп булып чыкты. Давыл вакытында да сынатмады, кайтканда аяусыз дулкыннар айкаса-чайкаса да бирешмәде.

— Әгәр елга тамагына кертеп куйсак?

— Куярга була булуын. Тик анда көнчыгыштан искән җилләрдән ышык түгел бит, дулкын харап итмәгәе.

— Алайса кая куярга соң, Пенкроф?

— Һава шары портына. Андагы култыкны тирә-яктан кыялар ышыклап тора, корабка иң кулай урын шул булыр.

— Ерак булмасмы соң ул?

— Булмас! Гранит сарайдан өч кенә миль ераклыкта ул, юлы да әйбәт, туп-туры!

— Алайса «Хәерле юл»ны үзегез генә илтерсез инде, Пенкроф. Дөресен әйткәндә, якынгарак куйсак, уңайрак булыр иде. Вакыт булгач, махсус порт төзербез әле.

— Менә анысы шәп! — дип куанды Пенкроф.— Маяклы, коры доклы порт та булса! Валлаһи, мистер Сайрес, сез исән чагында без мохтаҗлык күрмәбез!

— Һәй, дустым, сезнең ярдәм булса гына эш алга бара ул, бар эшнең дә дүрттән өч өлешен үзегез башкарасыз бит!

Һәм Герберт белән диңгезче яңадан корабка киттеләр. Якорен күтәреп, җилкәннәрен кордылар да җил уңаена кызу гына йөзеп Тырнак борынына таба юнәлделәр. Ике сәгатьтән «Хәерле юл» Һава шары портының аулак почмагында тыныч кына тора иде инде.

Гранит сарайда бергә яши башлаган көннән үк билгесез кешене гел күзәтеп тордылар. Аның кыргый гадәтләре бетә башладымы, зиһене ачылмыймы, рухы күтәреләме дигән сорауларга хәзер уңай җавап бирергә мөмкин иде; Сайрес Смит белән журналист хәтта бу мескеннең акылы томаланып ук бетмәгәндер дигән нәтиҗәгә килделәр.

Табор утравының ирекле һавасында, чиксез хөрлектә яшәргә күнеккән бу бичараның башта ярсу өянәге кузгалып-кузгалып куя иде, утрау хуҗалары хәтта аны Гранит сарай тәрәзәсеннән ташланмагае дип тә шик-

ләнделәр. Әмма әкренләп ул тынычланды, аны үз ирегенә куйдылар.

Хәзер аны сәламәтләнер дип өмет итәргә мөмкин иде инде. Вәхши гадәтләреннән арына барды: хәзер чи ит ашамый, «Хәерле юл»дагы кебек пешкән иттән йөз чөерми башлады.

Бер көнне Сайрес Смит йоклап яткан вакытында билгесез кешенең тузгыган куркыныч чәчләрен, киезләнгән сакал-мыекларын кыркып ташлады. Биленә бәйләгән сәләмә чүпрәк урынына ярыйсы гына кием киертеп куйды. Шундый игътибарлы мөгамәлә нәтиҗәсендә, ниһаять, әсир — кеше кыяфәтенә керде, күз карашы да үзгәрде, төкселеге кимеде. Элек, акылын җуйганчы, матур кеше булгандыр ахрысы ул.

Сайрес Смит көн саен берничә сәгать әсир янында утыра башлады. Аның бүлмәсенә эшләрен алып керә, игътибарын үзенә тартырга тырыша иде. Күңелендә берәр хатирә уянып, томаланган аңы ачылып китмәсме дип өметләнә иде. «Хәерле юл» давылга эләккәч, шундый хәл булган бит әнә.

Билгесез кешенең йоклаган аңын уятырга теләп, ул аңа төрле хәл-әхвәлләрне сөйли; уйланырга, колак салырга мәҗбүр итә. Бүлмәгә бүтәннәр дә кергәләп йөри, ә кайвакыт алар барысы бергә җыелалар. Гадәттә андый вакытта алар диңгез турында, кораблар турында, кыскасы, һәр диңгезчене кызыксындырырдай нәрсәләр хакында сөйләшәләр. Кайчагында билгесез кеше аларның сүзенә колак та салгандай тоела. Озакламый дуслар аның үзләре сөйләгән нәрсәне аңлаганын төшенделәр. Кайчагында аның йөзенә сагыш төсмере чыга, димәк, күңелен ниндидер газаплы уйлар борчый ахрысы. Юри кылануга охшамаган. Кайчак теленнән ниндидер сүз ычкынырга торган кебек тоела, тик нигәдер үзе һаман сөйләшми әле.

Ул тынычланды хәзер, ләкин басынкы, сагышлы бер халәт иде бу. Тыныч булып күренергә генә тырышмый микән ул? Әллә аны ирексезлек изә микән? Әкренләп яхшы якка үзгәрә барса да, гаҗәп түгел бит инде, бик табигый хәл югыйсә. Янында дуслары бар, тыныч яши, һәрнәрсә җитеш: тамагы тук, өсте бөтен, утрау хуҗаларына да ияләште инде. Шушы яңа тормыш аны рухи баетмады микәнни; әллә кыргый хайван кулга ияләшкәндәй, ияләште генә микән? Сайрес Смитны әнә шул сораулар борчый иде. Әмма ул билгесез кешене авыруга

саный, авыруны өркетүдән курка иде. Кыскасы, кайчан да булса терелерме бу бәхетсез, юкмы? Беләсе иде!

Инженер аны бер генә минутка да күз уңыннан җибәрмәскә тырышты. Аның һәр күңел хәрәкәтен күзәтте. (Әгәр бу сүзне билгесез кешегә карата кулланырга яраса.) Аның күңелендә нинди серләр барын төшенергә тели иде ул.

Иптәшләре дә Сайрес Смитның билгесез кешене ничек итеп дәвалавын кызыксынып күзәттеләр. Кулларыннан килгәнчә аңа ярдәм итүне үзләренең кешелек бурычы саныйлар иде. Билгесез кешенең тереләчәгенә Пенкрофтан кала һәммәсе ышана иде.

Алда әйтелгәнчә, билгесез кеше битарафлык сакласа да, һәркайсы күреп тора: ул көннән-көн инженерга ияләшә бара. Инженер аңа бер кечкенә генә сынау үткәрергә теләде: ничә еллар буе тоткынның күз алдында җәелеп яткан океан ярына һәм урман авызына җибәреп карарга булды!

— Иреккә чыккач, ул качып китәр! — диде Гедеон Спилет.

— Шулай да аны сынап карарга кирәк,— дип үз сүзеннән кайтмады Сайрес Смит.

— Менә әйтте диярсез, ирекле һавага чыгу белән чибәр егетебез үкчәсен ялтыратыр! — дип куйды Пенкроф.

— Мин алай дип уйламыйм,— диде Сайрес Смит.

— Сынап карыйк алайса,— диде Гедеон Спилет.

— Әйдәгез!

Бу хәл 30 нчы октябрьдә булды. Табор утравыннан алып кайткан билгесез кешенең Гранит сарайда тора башлавына тугызынчы көн иде. Көн эссе, кызу кояш нурлары бөтен утрауны коендыра.

Сайрес Смит белән Пенкроф килеп кергәндә әсир тәрәзә буенда күк йөзенә карап ятып тора иде.

— Әйдәгез, дускай, һавага чыгабыз! — диде инженер аңа.

Билгесез кеше шундук сикереп торды. Сайрес Смитка текәлеп карап алды да артыннан иярде. Ә дингезче бу тәҗрибәнең уңышлы чыгачагына ышанмаган кыяфәттә арттан кузгалды.

Сайрес Смит һәм Пенкроф билгесез кешене ишек төбендә күтәрткеч кәрзингә утырттылар, ә Наб, Герберт һәм Гедеон Спилет түбәндә көтеп торалар иде. Кәрзин

аска шуып төшеп китте. Берничә минуттан алар яр буена барып җиттеләр.

Билгесез кешене үз иркендә калдырыр өчен, барысы бераз читкәрәк киттеләр.

Менә ул диңгезгә таба берничә адым атлады, күзләре әсәренеп ялтырарга тотынды, ләкин качарга исәбе күренмәде. Ярга бәрелеп салмак кына кире тәгәрәгән дулкыннарга карап тора бирде.

— Ул әле диңгезне генә күрде. Диңгез аның качу теләген уятмыйдыр,— диде Гедеон Спилет.

— Дөрес әйтәсез, Күзәтү яссылыгына алып менеп, аны урман авызына җибәрергә кирәк. Тәҗрибә шунда гына ышанычлы булачак,— диде Сайрес Смит.

— Барыбер кача алмаячак, күперләр күтәртеп куелган бит,— дип искәртте Наб.

— Әйттең сүз! Синең Глицерин инешеңнән куркып калды ди ул! Сикерде чыкты булыр! — диде Пенкроф.

— Күрербез! — дип кенә куйды Сайрес Смит, авыруның күзенә карап.

Утрау хуҗалары аны Рәхмәт елгасы тамагына таба алып киттеләр, елганың сул як яры буйлап барып, Күзәтү яссылыгына менделәр.

Урман авызына килеп җитеп, яфраклары җилдә җилфердәп утырган мәһабәт агачларны күргәч, билгесез кеше урманның хуш исле һавасын күкрәгән тутырып суларга кереште һәм көтмәгәндә тирән ыңгырашып куйды.

Утрау хуҗалары аны, аз гына качарга маташса да тотарга әзер хәлдә, читтән күзәтеп торалар иде.

Чынлап та бер мизгелдә ул урман кырыеннан аккан инешкә ташланырга талпынып аяк мускулларын киерде... әмма шундук артка чигенде дә җиргә сыгылып төште, күзеннән эре бөртек күз яше тәгәрәп чыкты.

— Син елыйсың түгелме? Димәк, син яңадан кешегә әвереләдең!

Уналтынчы бүлек

Әйтелмәгән сер.— Билгесез кешенең беренче сүзләре.— Утрауда унике ел.— Гаебен тану.— Югалып тору.— Сайрес Смит өметен өзми.— Җил тегермәне салу.— Икмәк пешерү.— Тугрылык.— Гадел кешеләрнең сәламләве.

Күңелендә ниндидер хатирәләр кузгалудан, билгесез кеше туйганчы елады. Сайрес Смит әйткәнчә, күз яшьләре аның кешелеген яңадан кайтарды.

Үзен ирекле сизсен дип утрау хуҗалары аны бу иркенлектә ялгызын калдырып киттеләр. Әмма ул ирегеннән файдаланып качарга уйламады. Бераздан Сайрес Смит аны Гранит сарайга алып кайтты.

Шушы вакыйгадан соң ике көн үткәч, билгесез кеше аларның көндәлек тормышына катнаша башлады. Аның һәммә сүзне ишеткәнен, һәммәсен аңлаганын белделәр, тик нигәдер ул сөйләшергә теләми иде. Беркөнне кич белән билгесез кешенең ишегенә колак куеп тыңлап торган Пенкроф эчтән аның:

— Юк, юк, боларга түгел! — дип мыгырданганын ишетте.

Диңгезче моны иптәшләренә сөйләп бирде.

— Монда ниндидер сер бар! — диде Сайрес Смит.

Ниһаять, билгесез кеше эшкә тотынды. Яшелчә түтәлләрен казырга кереште. Тик ул еш кына көрәген ташлый да озак кына уйга чумып тора иде; инженерның киңәшен тотып, иптәшләре аның янына бармаска, ялгызын калдырырга тырыштылар. Берәрсе якын килә башласа, ул үксеп елый-елый читкә китеп бара иде.

Бәлкем, аны вөҗдан газабы борчыйдыр? Дөресе дә шулайдыр әле. Бер көн Гедеон Спилет түзмәде, үз фикерен әйтә салды:

— Аның зур гаебе бардыр, гаебен тануы авыр булганга дәшми торгандыр,— диде.

Ничек кенә булмасын сабыр итәргә туры килә иде.

Берничә көннән соң, 3 нче ноябрьдә, Күзәтү яссылыгында эшләгән җиреннән, билгесез бәндә тагын көрәген җиргә ташлады да еларга кереште. Сайрес Смит аны ерактан күзәтеп тора иде. Кызгануына түзә алмыйча, инженер аның янына килде дә кулы белән сак кына җилкәсенә кагылды:

— Миңа карагыз әле, дустым! — диде.

Билгесез кеше күзен читкә алды. Сайрес Смит аның кулын тотарга теләгәч, артка тайчанды.

Сайрес Смит буйсындыручан ихтыярлы тавыш белән:

— Дустым, минем күземә карагыз әле,— дип кабатлады.

Гипнозланган кеше кебек, ул инженерның ихтыярына буйсынып күзенә карады. Кинәт йөзендә ниндидер үзгәреш чагылды. Күзләре очкынланып китте. Ниндидер сүз әйтергә теләп, ирене кыймылдады. Бүтән түзәрлек чамасы калмаганлыгы сизелә иде!.. Ниһаять, кулын күкрәгенә куеп, тоныкланган тавыш белән:

— Сез кем буласыз? — дип сорады.

— Сезнең кебек үк һәлакәткә очраган кешеләр без,— дип җавап бирде инженер. Ул гаять каушаган иде.— Сез кешеләр арасында, үз кешеләрегез арасында...

— Кешеләр арасында дисезме?.. Юк, мин кеше түгел инде!

— Сез — дусларыгыз арасында.

— Дуслар арасында! Минем дусларым юк!..— дип кычкырды билгесез кеше, битен кулы белән каплады.— Юк... беркайчан булмас та... Китегез, калдырыгыз мине...

Ул Күзәтү яссылыгының иң читенә, диңгез өстенә үк чыгып торган маңгае турысына йөгереп барды да шунда озак басып торды. Сайрес Смит иптәшләре янына китеп, әле генә ишеткән сүзләрен аларга сөйләп бирде.

— Бу кешенең тормышында ниндидер сер бар икән шул,— дип куйды Гедеон Спилет.— Вөҗданы газаплаганга күрә түзә алмыйча кешелеге уянган булса кирәк.

— Валлаһи чын кыргый бер дивана алып кайткан быз икән без. Бигрәк йомыкый инде...— диде диңгезче.

Сайрес Смит аңа каршы төште:

— Алай димә. Аның тормышында ниндидер сер бар, без аны ихтирам итәргә тиешбез! Әгәр үткәндә берәр гаебе булса да, ул җәзасын җитәрлек татыган инде. Ходай гөнаһларын ярлыкасын!

Билгесез кеше яр буенда ике сәгатьләп ялгыз утырды; үткәннәре, үкенечле үткәннәре хәтеренә төшеп, күңелен газаплый иде булса кирәк; юлдашлары аны күздән җуймастан, ялгызын калдырдылар.

Ниһаять, озак уйлаганнан соң, ул бер карарга килде бугай, Сайрес Смит янына юнәлде.

— Сэр, сез инглизләрме? — дип сорады.
— Юк, без — американнар,— диде инженер.
— Алай икән,— дип куйды ул һәм әкрен генә: — Анысы яхшырак та әле,— дип өстәде.
— Ә сез, дустым, кем? — дип сорады инженер.
— Инглиз.
Аңа шушы берничә сүзне әйтүе дә авыр булды, күрәсең; чөнки шундук ул яр буеннан йөгереп китеп барды; гүя йөрәге кузгалганга түзә алмыйча, шарлавык яныннан елга тамагына хәтле йөгерде.
Герберт яныннан үтеп барышлый туктады да, йөгерүдән сулышы кабып, тыны кысылган килеш:
— Бу кайсы ай? — дип сорады.
— Ноябрь,— диде Герберт.
— Кайсы ел?
— Бер мең сигез йөз алтмыш алтынчы ел.
— Унике ел! Унике ел! — дип кабатлый-кабатлый тагын йөгереп китте теге.
Герберт бу сөйләшүне иптәшләренә җиткерергә ашыкты.
— Мескен, инде айларның, елларның исәбен дә оныткан! — дип куйды Гедеон Спилет.
— Ул Табор утравында унике ел торган! — дип өстәде Герберт.
— Унике ел! — дип кабатлады Сайрес Смит.— Унике ел буе таплы вөҗданың белән япа-ялгызың яшәп кара әле, акылыңнан язмассыңмы!
— Мин уйлыйм, ул һәлакәткә очраган корабтан котылып калган кеше түгелдер. Нindидер җинаяте өчен аны Табор утравында ташлап калдырганнардыр,— диде Пенкроф.
Журналист та аның сүзен җөпләде:
— Дөрес әйтәсез, Пенкроф. Ул утрауда калдырылган тоткындыр. Әгәр бу чын булса, аны утрауга ташлап киткән кешеләр кире килеп алырга тиешләр!
— Килсәләр, алар анда аны таба алмаячаклар,— дип куйды Герберт.
— Утрауга яңадан барып килергә кирәк алайса...— диде Пенкроф.
— Дусларым! Дөресен тәгаен белмичә, бу мәсьәләдә баш ватмыйк әле. Гаебе никадәр зур булса да, ул җәзасын артыгы белән татыган инде, безнең алда ничек ачылырга белмичә үзе дә җәфалана. Әлегә аңа басым ясамыйк. Бүген булмаса, иртәгә ул үзе үк барысын да

сөйләп бирәчәк, шул чакта нишләргә икәнен күрербез. Кайчан да булса Ватанына кайтырына өметләнәме ул, юкмы — моны ул фәкать үзе генә әйтә ала. Хәер, мин үзем аңа кайтырга рөхсәт итүләренә шикләнәм.

— Нигә? — дип сорады журналист.

— Әгәр аны фәлән вакытка хәтле дип хөкем иткән булсалар, ул котылу көнен көтеп торыр иде, диңгезгә язу язып ташламас иде. Аны гомерлек тоткынлыкка, мәңге ялгыз яшәргә хөкем иткәннәрдер.

Диңгезче:

— Алайса һич аңлашылмый...— дип башлаган иде, инженер:

— Нәрсәсе аңлашылмый? — дип сорады.

— Әгәр аны унике ел элек Табор утравына ташлап киткәннәр икән, ул вакытта бу кеше күптән кыргыйланган булырга тиеш!

— Бик мөмкин,— диде Сайрес Смит.

— Шулай булгач, язуны ул моннан күп еллар элек язып салган була ич!

— Әлбәттә... Әмма язу яңарак кына язылган кебек иде.

— Шешәдәге язу Табор утравыннан Линкольн утравына берничә ел буе агып килмәс инде!

— Бер дә гаҗәп түгел,— дип каршы төште журналист.— Бәлкем ул безнең утрауга күптән килеп җиткән булгандыр.

Ярга бер тапкыр чыгарып ташлангач, дулкын янәдән эчкә алып кереп киткәндер димәкче буласызмы? Юк инде! Көньяк ярда гел таш та кыя, шундук кыяга бәрелеп челпәрәмә килгән булыр иде ул.

— Дөрес әйтәсез,— диде Сайрес Смит уйга калып.

— Шуның өстенә,— дип дәвам иттерде сүзен диңгезче,— язу шешә эчендә берничә ел ятса, дымнан бозылып беткән булыр иде. Ә без тапканда ул танырлык иде.

Диңгезченең шикләнүе юкка түгел иде: гаҗәпләнми дә хәл юк, чөнки язу яңарак кына язылган кебек иде. Әле алай гынамы, Табор утравының географик киңлеге белән озынлыгы язуда дөрес күрсәтелгән, ә бу нәрсә гади матросның кулыннан килә торган эш түгел, гидрографиядән зур мәгълүматы булган кеше генә аларны төгәл белүе мөмкин иде.

— Бередә әле тагын аңлашылмый торган нәрсәләр бар,— диде, ниһаять, инженер.— Ләкин шуңа да карамастан без яңа иптәшебезне сөйләшергә мәҗбүр итәргә тиеш түгелбез. Ул барысын үзе сөйләячәк.

Тагын берничә көн узды; шул вакыт эчендә билгесез кеше бер авыз сүз дә сөйләшмәде, яссылык киртәсенең аргы ягына бер тапкыр да чыгып карамады. Таңнан алып төнгәчә, алсыз-ялсыз яшелчәлектә һәммәсеннән аерым, бер читтә эшләде. Ял итәр өчен Гранит сарайга кайтып йөрмәде, иптәшләре ни хәтле кыстаса да, табынга якын да бармады, чи яшелчәләр белән генә тукланды. Үз бүлмәсенә кайтып йокламады, шунда яссылыктагы агачлар ышыгында төн куна, көн бозылганда кыя куышларына кереп поса иде,— кыскасы, Табор утравында бердәнбер сыеныр почмагы урман булганда ничек яшәсә, монда да шулай яши бирде; иптәшләре аның бу гадәтеннән биздерергә тырышып карасалар да, булмады — сабыр рәвештә күтәргә генә калды. Ниһаять, аның вөҗданы баш күтәрде, гүя ниндидер көчкә буйсынып, ул ихтыярсыздан үзенең коточкыч гаебен танырга мәҗбүр булды.

Унынчы ноябрьдә, кичке сәгать сигезләр тирәсендә, утрау хуҗалары яшел чатыр эчендә ял итеп утыралар иде, кинәт алар каршысына билгесез кеше килеп басты. Күзләре иләсләнгән, йөзе кыргыйланган, тешләре шыкырдый.

Сайрес Смит һәм иптәшләре аның бу кыяфәтен күреп куркып киттеләр. Нәрсә булган моңа? Кешеләргә нәфрәт саклыймы әллә? Намуслы хезмәт белән көн күрүчеләр арасында яшәүдән туйганмы? Әллә вәхши теләкләре яңадан уянганмы? Аның бәйләнешсез сүзләр кычкыруын ишетеп иптәшләре аптырап тордылар.

— Нишләп мине монда алып килдегез? Мине үз утравымнан алып китәргә сезнең ни хакыгыз бар?.. Сезнең белән минем нинди уртаклыгым булсын... Минем кем икәнне сез беләсезме?.. Гаебем бардыр, бәлки?.. Ни өчен анда япа-ялгызым яттым? Шуны беләсезме? Бәлкем, мин иленнән сөрелгән кешедер?.. Шунда утрауда үлемгә хөкем ителгәнмендер?.. Минем үткән тормышымны сез бер тамчы да белмисез бит... Бәлкем, мин карактыр, кеше үтерүчедер... бәлкем, миңа ләгънәт тамгасы сугылгандыр... кешеләр белән яшәргә хокукым юктыр... бәлкем, минем урын ерткыч җанварлар арасындадыр?.. Шуларны беләсезме сез? Йә, әйтегез....

Билгесез кешенең авызыннан үз ихтыярыннан тыш агылып торган ярым тәүбә сүзләрен утрау хуҗалары тын да алмыйча тыңлап тордылар. Сайрес Смит бу

бәхетсез башны тынычландырмакчы булып янына килгән иде, тегесе читкә тайчанды:

— Китегез! — дип кычкырды ул.— Мин ирекләме — шуны гына әйтегез...

— Әйе, сез ирекле,— диде инженер.

— Ул вакытта сау булыгыз! — дип кычкырды да шашкан кешедәй йөгереп китте теге.

Наб, Пенкроф, Герберт аның артыннан куа киткәннәр иде, буш кул белән әйләнеп кайттылар.

— Әйдә, үзенчә йөрсен,— диде Сайрес Смит.

— Ул бүтән әйләнеп кайтмас инде,— диде Пенкроф.

— Кайтыр,— диде инженер.

Шуннан бирле күп көннәр үтте, әмма Сайрес Смитның ышанычы какшамады, иртәме-соңмы билгесез кеше кире әйләнеп кайтыр дип уйлый иде ул.

— Бу аның йөгәнсез кыргый холкының соңгы дулавы иде, аңарда вөждан газабы уянган, хәзер ул ялгызлыкка түзә алмаячак,— дип сүзендә нык торды инженер.

Ул арада Күзәтү яссылыгында да, мал утарында да эшләр тукталып тормады.

Табор утравыннан Герберт җыеп кайткан яшелчә орлыкларын чәчәр өчен яссытаулыкта җиренә җиткереп эшкәртелгән пөхтә түтәлләр тезелеп китте. Көне-төне тырышып эшли торгач, зур гына яшелчә бакчасы барлыкка килде. Анда эш бер дә бетеп тормады. Яшелчә түтәлләренең саны артканнан-артты, хәтта болынның бер өлешен сөрергә туры килде. Утраудагы көтүлекләр җитәрлек иде, онагрлар печәнсез калыр дип куркасы юк. Төрле яктан су киртәсе белән әйләндереп алынган Күзәтү яссылыгының бөтен җирен яшелчә бакчасына әйләндерсәң дә начар булмас иде; терлекләрне утрауның бүтән якларындагы ачык болыннарда да утлатырга мөмкин бит.

Унбишенче ноябрьдә бодайның өченче уңышын җыеп алдылар. Җиргә бердәнбер орлыкны утыртканнан бирле ел ярым эчендә иген басуы танымаслык булып үзгәрде. Икенче елында алты йөз мең бөртек орлык чәчеп, дүрт мең буассо уңыш җыеп алынды, бу — биш йөз миллион бөртектән артык дигән сүз иде. Хәзер утрау хуҗалары бодайга баедылар. Үзләрен һәм терлекләрне икмәк белән тәэмин итү өчен аларга ел саен ун буассо бодай чәчү җитә иде.

Уңышны җыеп алгач алар ноябрьнең соңгы көннәрендә он тарту хәстәренә керештеләр.

Хәзер аларның ашлыклары бар, ә оннары юк иде. Кичекмәстән тегермән салырга кирәк булды. Сайрес Смит башта Рәхмәт елгасындагы икенче шарлавыкны файдаланырга, шунда су тегермәне салырга уйлаган иде; беренче шарлавык куәте исә тула басуга көйләнгән иде. Үзара киңәшкәч, Күзәтү яссылыгына җил тегермәне салырга кирәк дигән фикергә килделәр. Аны салуы да ансатрак, яссытаулык диңгез ягыннан исә торган җилләр оясында булганга, җил тегермәне әйбәт тартачак.

— Өстәвенә җил тегермәне утравыбызны матурайтып җибәрер, кешеләр яшәгәнен күрсәтеп торыр,— диде Пенкроф.

Алар эшне башладылар. Башта төзүлек агач әзерләделәр, күлнең төньяк ярында аунап яткан комташ кантарларын тегермән ташы итеп файдаланырга булдылар. Канатларына әлеге бер бетмәс һава шары тышчасы тукымасын кагып куярга исәпләделәр.

Сайрес Смит сызымын сызып бирде. Тегермәнгә күл буендагы кош кетәгенең уң ягында урын сайладылар. Бүрәнә нигез өстенә стенасын өеп менәргә һәм түбәсен канатлары белән бергә борып йөрешле итеп эшләргә ниятләделәр.

Тегермән салу эше тиз алга барды. Булдыклы балта осталары Наб белән Пенкроф, инженерның сызымы буенча, күл буена тиздән очлы башлы озынча борыч савытына охшаган тегермән кысасын бастырып та куйдылар. Канатларын тимер ыргаклар белән чарыкка беркеттеләр. Тегермән эчендәге җиһазларны да ясавы кыен булмады. Берсе әйләнә, берсе кузгалмый торган ике тегермән ташына агачтан кыса әмәлләделәр, ашлык салу өчен киң авызлы өсәк асып куйдылар, орлыкны тегермән ташына тигезләп сибеп торучы селкенмә мөшкә, онны кибәгеннән аеру өчен иләк ясап куйдылар. Эш кораллары бер дигән үткен, тегермән салуның әллә ни серләре юк, эш тиз алга барды.

Барысы бергә тотынып 1 нче декабрьгә тегермәнне салып өлгерттеләр.

Гадәтенчә, Пенкроф эш беткәч масаерга кереште:

— Көчле җиле генә чыксын, тегермәнебез күз ачып йомганчы бөтен ашлыкны тартып бетерәчәк,— диде.

— Җил чыкса, чыксын, тик көчле булмасын,— диде инженер.

— Ник, тегермән канаты кызурак әйләнер!

— Тегермән канатының кызу әйләнүе кирәкми безгә,— диде Сайрес Смит.— Тегермән канатларының әйләнеш саны җилнең исү тизлегенә бәйләнгән. Тәҗрибә күрсәткәнчә, бер секундка дүрт фут тизлек белән исә торган уртача җилле көнне тегермән канаты минутына уналты әйләнеш ясый, шуннан артыгының кирәге юк.

— Бүген җил төньяк-көнчыгыштан исә, ул безгә ярдәм итәр! — диде Герберт.

Аларның үзләре пешергән икмәкне тизрәк авыз итәселәре килә иде. Озакка сузмыйча он тартып карарга булдылар. Шул ук көнне иртән ике-өч буассо бодайдан он тартып өлгерттеләр, ә иртәгесен Гранит сарайның аш өстәле уртасында күпереп пешкән күмәч утыра иде. Утрау хуҗалары туйганчы тәмле күмәч ашадылар, аларның шатлыгын сөйләп аңлатырлык түгел иде.

Ә билгесез кеше һаман кайтмады. Гедеон Спилет белән Герберт Гранит сарай тирәсендә урманнарга еш барып йөрсәләр дә, аны очратмадылар, хәтта аның анда яшәү-яшәмәвен дә белерлек түгел иде, бер төрле эз күренмәде. Алар аның өчен чынлап борчыла башладылар. Табор утравында кыргыйларча яшәгән кеше киеккә бай Ерак Көнбатыш урманнарында ачыгуын-ачыкмас. Әмма вәхши гадәтләре киредән кузгалмас микән? Шулай да Сайрес Смит аның кайтырына ышана, күңеле шулай сизенә иде.

— Менә күрерсез, кайтачак ул,— дип үз фикерендә нык торды инженер. Әмма иптәшләре моңа инде шикләнә башлаган иде.— Табор утравында ул ялгыз иде, ә монда без көткәнне белә. Ул элекке тормышын бераз сөйләде инде, бер көнне кайтыр да барысын сөйләп бирер; гөнаһларыннан тәүбә итәр һәм безнең гаиләдә калыр.

Алдагы вакыйгалар Сайрес Смитның фикере дөрес икәнлеген исбат иттеләр.

Өченче декабрьдә Герберт, Күзәтү яссылыгыннан төшеп, күлнең көньяк ярына кармак салырга барган иде. Ул коралсыз иде, чөнки утрауның бу өлешендә монарчы ерткыч җанварлар күренгәне юк иде.

Пенкроф белән Наб кош кетәгендә нәрсәдер әмәллиләр, ә Сайрес Смит белән журналист сода ясап азапланалар, чөнки тотарга сабыннары беткән иде.

Кинәт:

— Ярдәм итегез! Коткарыгыз! — дип ярдәмгә чакырган тавыш ишетелде.

Сайрес Смит белән журналист, ара ерак булганлыктан, тавышны ишетмәделәр. Ә Пенкроф белән Наб, кетәктән атылып чыгып, күл буена йөгерделәр.

Әмма алардан алда билгесез кеше дә йөгерә иде, аның бу тирәдә икәнлеге беркемнең башына килмәгән иде. Ул Глицерин инешен аркылы чыкты да каршы ярга менеп тә китте.

Карасалар, теге чакта Елан борынында үтерелгән ягуарга охшаган гаять зур ягуар Гербертка һөҗүм итәргә әзерләнә. Бу хәлне көтмәгән Герберт аркасы белән агачка килеп сыенган, ә ерткыч арт аягына чүгенә төшеп, сикерергә әзерләнгән... Нәкъ шул мәлдә билгесез кеше кулына пычак тотып ерткычка ташланды, һәм ерткыч яңа дошманына таба борылды.

Көрәш озакка сузылмады. Билгесез кеше бик көчле һәм елгыр икән, бер кулы белән ягуарның бугазыннан тотып алды да тимер келәшчә белән кыскандай каты итеп кысты, ә икенчесе белән тегенең йөрәк турысына пычагын китереп кадады, ерткычның очлы тырнаклары үз тәненә батып кергәнгә дә игътибар итмәде.

Ягуар җиргә ауды. Билгесез кеше аны аягы белән читкә тибеп җибәргәч, качарга теләгән иде, шул чак башкалар да килеп җиттеләр. Герберт аның каршысына йөгереп килеп:

— Туктагыз әле, зинһар китмәгез! — дип кычкырды.

Сайрес Смит та билгесез кеше янына килеп җитте, тегесенең инженерны күргәч, чырае сүрәнләнеп китте. Аның кулбашы җәрәхәтләнгән, умырылган күлмәге кыпкызыл кан гына, ә үзе моны сизми дә иде бугай.

— Дустым, без хәзер сезгә мәңге бурычлы. Безнең улыбызны коткарам дип сез үзегезне харап итә яздыгыз,— диде Сайрес Смит.

— Үземне дисезме? Минем гомернең бер тиенлек бәясе бармы? Нигә кирәк миңа бу гомер!

— Сез җәрәхәтләнгәнсез бит.

— Зыян юк.

— Кулыгызны дусларча кысарга, рәхмәт әйтергә рөхсәт итегез!

Герберт рәхмәт әйтү өчен коткаручысы янына йөгереп килгәч, тегесе кулын күкрәгенә куйды. Ул әсәренеп еш-еш сулый, күзләре томанланган,— гүя тагын качып китәргә хәл иткән. Әмма үз-үзен көчләп бугай, кырыс кына сорады үзе:

— Сез кемнәр? Миннән сезгә ни кирәк?

Утрау кешеләренең тарихын беләсе киләдер, күрәсең, аның. Аларның башыннан кичкән хәлләрне белгәч, бәлкем, үз тормышын да сөйләп бирер.

Ричмондтан качып киткәннән бирле нинди хәлләргә таруларын Сайрес Смит берничә сүз белән генә сөйләп бирде; ничек котылып калуларын, утрауда нинди эшләр башкарганлыкларын санап чыкты.

Билгесез кеше дикъкать белән тыңлап торды.

Аннары инженер үзенең иптәшләре Гедеон Спилет, Герберт, Пенкроф, Наб турында сөйләде һәм Линкольн утравында тора башлаганнан бирле иң шатлыклы көнебез «Хәерле юл»ның сәяхәттән әйләнеп кайткан һәм яна иптәш табылганны белгән көн булды дип өстәде.

Бу сүзләрне ишеткәч, билгесез кеше кып-кызыл булды һәм башын аска иде: ул юашланып, каушап калган иде.

— Ә хәзер безнең кем икәнне белдегез инде, әйдәгез, кулыгызны бирегез, кысыйм! — диде Сайрес Смит.

— Юк, булдыра алмыйм. Сез намуслы кешеләр, мин исә...— диде дә тотлыгып калды, тавышы карлыкты.

Унҗиденче бүлек

Япа-ялгыз яшәү.— Билгесез кешенең үтенече.— Мал утарында йорт салу.— Уникеел гомер! — «Британия»нең боцманы.— Табор утравындагы тоткын.— Сайрес Смит кул кыса.— Серле язу.

Әлеге сүзләр утрау хуҗаларының алдан уйлаган уйлары дөрескә чыгуын раслый иде. Бу бәхетсез кеше кайчандыр элек ниндидер җинаять кылган булган; бәлкем, кешеләр алдында ул үзен аклагандыр да инде, әмма үз вөҗданы әле аны гафу итмәгән, күрәсең. Аны вөҗданы газаплый иде. Яңа танышлары рәхмәт йөзеннән аның кулын ихлас күңелдән кысарга теләсәләр дә, ул үзен намуслы кешеләргә кул бирергә лаеклы дип исәпләми иде! Хәер, ягуарны җиңгәннән соң ул урманга качмады-качуын, Күзәтү яссылыгында калды.

Аның тормышында нинди сер бар икән соң? Кайчан да булса, ул аны үзе ачармы? Бердәнбер чара — көтәргә генә кала. Һәрхәлдә, утрау хуҗалары аңардан сорашып күңелен җәрәхәтләргә теләмәделәр, берни булмагандай йөри бирделәр.

Соңгы көннәрдә утрауда тормыш үз эзенә төште. Сайрес Смит белән Гедеон Спилет бергәләп йә химия,

йә физика белән шөгыльләнәләр иде. Кайсы көннәрне генә Гедеон Спилет Герберт белән бергә ауга барып килә, чөнки хәзер егетнең ялгызын гына урманга җибәрергә шүрлиләр. Наб белән Пенкроф исә бер көнне утлауда һәм кош кетәгендә, ә икенче көнне мал утарында эшлиләр, шуның өстенә хуҗалыкта да эшләр җитәрлек иде.

Билгесез кешегә килгәндә исә, һаман элеккечә ялгызы гына йөри, табынга утырмый, агачлар ышыгында аерым йоклый, әңгәмәгә кушылмый иде. Әйтерсең лә үзен коткаручыларга карата ачу саклый иде.

Пенкроф бу хәлгә аптырады:

— Алайса, ни пычагыма кешеләрдән ярдәм сорап мөрәҗәгать иткән соң ул? Нигә диңгезгә язу язып ташлаган?

Сайрес Смит исә һаман үзенекен тәкрарлый:

— Ул моны үзе сөйләр әле.

— Кайчан соң?

— Бәлкем, сез уйлаганнан да элегрәктер, Пенкроф.

Чыннан да, элеге көннәр якынлашып килә иде.

Гранит сарайга кайтканына бер атна үткәч, унынчы декабрьдә билгесез кеше Сайрес Смит янына килде дә юаш кына итеп:

— Сэр, сезгә үтенечем бар иде,— диде.

— Рәхим итегез,— диде инженер.— Ләкин башта мине тыңлагыз әле.

Бу сүзләрне ишеткәч, билгесез кып-кызыл булды, йөгереп китәргә җыенды. Сайрес Смит аның үткәннәре хакында сораштыра башлар дип курыкты ахрысы ул. Инженер, шуны төшенгәч, аның кулыннан тотты:

— Карагыз әле, сез безне үзегез белән бер язмышка дучар булган очраклы кешеләр генә дип уйламагыз, без сезнең дусларыгыз бит. Мин бары шуны гына әйтмәкче идем. Хәзер инде сезне тыңлыйм! — диде.

Билгесез кеше күзләрен уып куйды. Аның куллары калтырый иде, берничә секунд сүзен әйтә алмыйча торды.

— Сэр, сезгә бер үтенечем бар,— диде ул янәдән.

— Нинди үтенеч?

— Моннан дүрт-биш миль җирдә, тау итәгендә, сезнең терлекләр асрый торган мал утарыгыз бар. Терлекләрне багарга да кирәк, миңа шунда яшәргә рөхсәт итмәссезме?

Сайрес Смит кызганып аңардан күзен ала алмыйча торды. Аннары:

— Дускай, анда торак юк бит, терлек абзарлары да әрле-бирле генә эшләнгән...— диде.

— Миңа шул да ярый, сэр.

— Дускай, сезнең теләкләрегезгә без һич тә каршы түгел. Утарда яшисегез килә икән, әйдә, яшәгез. Тик белегез, Гранит сарай ишеге сезгә һәрвакыт ачык, килсәгез, кадерле кунак булырсыз. Утарда яшәргә теләгәч, без анда сезгә уңайлы шартлар тудырырга тырышырбыз.

— Миңа ничек булса да ярый.

— Дускай,— диде Сайрес Смит, бу сүзгә ул аеруча басым ясады,— бу мәсьәләне үзебезчә хәл итәргә рөхсәт итегез.

— Рәхмәт, сэр,— диде билгесез кеше һәм шундук китеп барды.

Инженер аның үтенечен иптәшләренә дә сөйләп бирде. Һәм алар мал утарында агачтан өй салырга, аны мөмкин хәтле уңайлырак итеп җиһазларга булдылар.

Шул көнне үк кирәкле эш коралларын алып, утарга киттеләр; бер атна эчендә өй салынып та бетте, хуҗасын көтә иде инде.

Сиксән баштан артып киткән муфлон көтүен карарга уңайлы булсын өчен, өйне абзарлардан егерме фут читтә, кашлак җиргә салдылар. Өй җиһазларыннан: карават, өстәл, эскәмия, шкаф, сандык ясап куйдылар. Анда сугыш кораллары, дары-ядрәләр, эш кораллары да илттеләр.

Әйтергә кирәк, билгесез кеше салынып яткан торакны килеп карап йөдәтеп йөрмәде, төзүчеләргә игътибар итмичә, басудагы башлаган эшен дәвам итте. Җирне ул мамык кебек итеп эшкәртте, басу бодай чәчәргә әзер иде инде.

Егерменче декабрьгә өйнең бөтен эше беткәч, инженер билгесез кешегә торакның әзер икәнлеген хәбәр итте. Тегесе бүген үк анда китеп йоклаячагын әйтте.

Кич белән Гранит сарай хуҗалары гадәттәгечә зур залда җыелышып утыралар иде. Сәгать сигезләр булып килә,— билгесез кеше бүген яңа өенә китәргә тиеш. Иптәшләре, аны саубуллашырга мәҗбүр итеп уңайсыз хәлгә куймас өчен, үзләренең эше беткәч, Күзәтү яссылыгында ялгызын калдырганнар иде.

Зур залда гәпләшеп утырганда, кемдер әкрен генә

ишек шакыды. Ишектән ашыгып билгесез кеше килеп керде дә, тартып-сузып тормыйча:

— Әфәнделәр, сездән аерылганга чаклы, мин үзем турында дөресен сөйләп бирмәкче булам, менә тыңлагыз,— дип әйтте.

Шушы гап-гади сүзләр Сайрес Смитка һәм аның иптәшләренә бик көчле тәэсир итте. Сайрес Смит, урыныннан торып, билгесез кешегә:

— Без сездән берни сорашмыйбыз, дускай. Берни сөйләмәскә дә хакыгыз бар...— диде.

— Мин барысын сөйләргә тиешмен.

— Утырыгыз алайса.

— Юк, мин басып кына торам.

— Сезнең тормыш тарихын тыңларга без әзер,— диде Сайрес Смит.

Билгесез кеше залның карангырак почмагына барып басты. Ул яланбаш, кулларын күкрәгенә баглаган килеш басып тора; тавышы тонык иде. Мөгаен, аңа сөйләве җиңел түгелдер инде. Иптәшләре аның хикәясен тын да алмыйча тыңлап тордылар.

— Бер мең сигез йөз илле дүртенче елның егерменче декабрендә Шотландиянең эре җир биләүче лорды Гленарванның пар көче белән йөри торган яхтасы «Дункан» Австралиянең көнбатыш ярында утыз җиденче параллельгә урнашкан Бернуилли борынында якорь салды. Яхтага лорд Гленарван хатыны белән үзе, инглиз армиясе майоры, географ француз һәм капитан Грант балалары — яшь кыз белән бер малай утырганнар иде. Шуннан бер ел гына элек ул балаларның әтисе капитан Грантның корабы «Британия» баткан һәм бөтен экипажы һәлак булган иде.

«Дункан» яхтасы командасы составында унбишләп матрос булып, капитаннары Джон Манглс иде.

«Дункан»ның Австралиягә килеп чыгу сәбәпләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт иде. Моннан ярты ел элек кенә яхта экипажы Ирландия диңгезеннән өч телдә: инглизчә, немецчә, французча язулы бер шешә табып алган. Язуда кыскача гына итеп «Британия»нең һәлакәткә очравы һәм аннан өч кешенең — капитан Грант белән ике матросның исән калганлыгы, аларның кайсыдыр җиргә йөзеп чыкканлыгы хәбәр ителгән иде. Язуда ул җирнең географик координаты күрсәтелгән булса да, кайсыдыр цифрлары суда җебеп танымаслык хәлгә килгән иде.

Шулай итеп, язуда, исән калучыларның көньяк киң-

лекнең утыз җиденче градусы унберенче минутында икэнлеге әйтелгән иде. Ә озынлык билгесез иде. Димәк, капитан Грант белән аның юлдашларын утыз җиденче параллель кисеп үтә торган материклардан-океаннардан эзләп табарга мөмкин иде.

Англия адмиралтействосы капитан Грантны эзләргә экспедиция җибәрүдән баш тартты, әмма лорд Гленарван аны табарга карар бирде. Ул Мери һәм Роберт Грантлар белән танышты. Яхтаны ерак юлга чыгарга әзерләделәр. Лордның хатыны һәм капитан Грантның балалары да экспедициягә катнашырга теләк белдерделәр. Ниһаять, «Дункан» Глазгодан кузгалып китте һәм, Атлантик океанны кичеп, Магеллан бугазыннан Тын океанга чыкты һәм Патагониягә таба юнәлде. Язуны үзләренчә юрап, алар капитан Грант Патагониядә җирле кыргыйлар кулына әсир төшкән дип исәплиләр иде.

«Дункан»ның пассажирлары Патагониянең көнбатыш ярына төшеп калдылар, ә яхта диңгез буйлап йөзеп барып аларны Патагониянең көнчыгыш ярында, Корриентес борынында көтеп торырга тиеш иде.

Гленарван һәм аның юлдашлары утыз җиденче параллель буенча бөтен Патагонияне кичеп чыксалар да, капитан Грантны тапмадылар һәм, унөченче ноябрьдә яңадан яхтага утырып, диңгезгә чыктылар.

Алар юл өстендәге ике утраудан — Тристан-да Кунья һәм Амстердам утрауларыннан эзләргә керештеләр, ләкин тырышлыклары бушка китте. Алда әйтелгәнчә, бер мең сигез йөз илле дүртенче елның егерменче декабрендә алар Австралиянең Бернуилли борынына якынлашып киләләр иде.

Гленарван, утыз җиденче параллель буенча Австралия материгын кичеп чыгарга теләп, ярга аяк басты. Ярдан берничә миль җирдә бер ирландлының фермасы урнашкан иде, ул сәяхәтчеләрне киң күңел белән каршы алды. Лорд Гленарван ирландлыга бу якларга нинди максат белән килеп чыкканлыгын сөйләп бирде, һәм моннан ике ел элек Австралиянең көнбатыш яры тирәсендә Англиянең өч мачталы «Британия» судносы һәлак булуын ишетмәдегезме дип сорады.

Ферма хуҗасы баткан кораб турында берни ишетмәгән булган икән. Ләкин, барысының гаҗәпләнүенә каршы, шунда аның хезмәтчеләреннән берсе сүзгә катнашып китте:

— Милорд, ходайга шөкер диегез, әгәр капитан Грант әле дә исән булса, ул Австралиядә яшәргә тиеш,— диде.

— Сез кем буласыз? — дип сорады лорд Гленарван аңардан.

— Сезнең шикелле үк, мин дә шотландлы, милорд,— диде бу кеше,— капитан Грант белән бергә һәлакәткә очрап, исән калганнарның берсе.

Ул кешенең фамилиясе Айртон иде. Кулындагы документлары да аның «Британия»дә боцман булып хезмәт иткәнлеген расладылар. Аның сөйләвенчә, кораблары су асты кыясына бәрелеп ватылгач, ул капитанны күздән җуйган, экипаждан берүзем генә исән калдым дип уйлаган һәм капитан Грантны башкалар белән бергә һәлак булгандыр дип исәпләгән.

— Тик «Британия» Австралиянең көнбатыш яры буенда түгел, бәлки көнчыгыш яры буенда һәлак булды,— дип өстәде ул.— Язуда күрсәтелгәнчә, әгәр капитан Грант исән икән, аны көнчыгыш яр буеннан эзләргә кирәк, ул җирле халык кулына әсир төшкән булырга тиеш.

Айртон күзгә туры карап, ышандырырлык итеп ихластан сөйләгәч, ирландлы фермер да үзендә бер елдан артык хезмәт иткән бу кеше хакында әйбәт фикер әйткәч, аның сүзләреннән шикләнергә нигез калмый. Лорд Гленарван бу кешенең намуслы икәнлегенә ышана, аның киңәшен тотып, Австралияне утыз җиденче параллель буенча кичеп чыгарга була.

Гленарван, хатыны, капитан Грант балалары, майор, географ, капитан Манглс һәм берничә матростан торган кечкенә отряд Айртон җитәкчелегендә юлга чыкты, ә «Дункан», капитан ярдәмчесе Том Остин командалыгында Мельбурнга юнәлеп, анда лорд Гленарванның боерыгын көтеп торырга тиеш иде.

Бер мең сигез йөз илле дүртенче елның егерме өченче декабрендә отряд Австралиянең көнчыгыш ярына таба кузгалып китте.

Инде дөресен әйтергә кирәк, Айртон хыянәтче иде. Ул чыннан да «Британия»дә боцман булып хезмәт итте, ләкин капитан белән ызгышып, экипажны капитанга каршы баш күтәрергә котыртты һәм корабны үз кулына алырга теләде. Капитан Грант шуның өчен аны бер мең сигез йөз илле икенче елның сигезенче апрелендә Австралиянең көнбатыш ярында ташлап киткән иде.

Димәк, «Британия»нең һәлак булуын ул кабахәт ишетмәгән дә иде. Бу турыда Гленарван сөйләгәч кенә белде. Ярга ташлап калдырылгач, Бен Джойс дигән кушаматы белән Айртон качкын каторжаннар шайкасының башлыгына әверелде. Ә хәзер корабны көнчыгыш яр тирәсендә һәлак булды дип оятсыз рәвештә ышандырырга тели. Лорд Гленарванны ялгыш юл белән юри җибәреп, ул сәяхәт итеп йөргән арада, аның яхтасын кулга төшерергә һәм пиратлар судносына әверелдереп, диңгездә юлбасарлык итәргә өметләнде...

Билгесез кеше хикәясен сөйләүдән туктап калды. Аннары, калтыранган тавыш белән яңадан дәвам итте:

— Отряд Австралияне кичеп чыкмакчы булып юлга кузгалды. Гаҗәп тә түгел, алар адым саен бәлагә тарыдылар. Чөнки Айртон яки Бен Джойс шайкасы, экспедициянең әле алдына, әле артына төшеп, башлыклары өйрәткән явызлыкларны эшли килделәр.

Ә шул арада «Дункан» Мельбурнда ремонтта тора иде. Айртон лорд Гленарванга «Дункан»ны Мельбурннан көнчыгыш ярга җибәрергә кирәк дип киңәш итте,— чөнки анда бандитларга яхтаны кулга төшерүе асат иде. Айртон экспедицияне кеше кулы-аягы тимәгән кара урман эченә кертеп адаштырды, аларга анда адәм күрмәгән җәфалар чигәргә туры килде. Шунда ул Гленарванны яхта капитаны ярдәмчесенә хат язарга мәҗбүр итте, хатны илтеп бирергә үз өстенә алды. Ул хатта «Дункан»ны кичекмәстән көнчыгыш ярдагы Туфольд култыгына илтергә кушылган иде. Ә анда Айртонны шайкасы көтеп тора иде.

Хыянәтченең кулына хатны тапшырганда гына аның кем икәнлеге фаш булды, һәм ул качып китте. Әмма Айртон яхтаны үз кулына алырга мөмкинлек бирә торган хатны ничек тә кулына төшерде һәм ике көннән Мельбурнга барып та җитте.

Моңа кадәр хыянәтченең планнары гел тормышка аша килгән иде, моннан ары да шулай булыр дип уйлады: «Дункан»ны ул Туфольд култыгына җибәрер, анда бандитлар шайкасы, экипажны үтереп бетереп, судноны үз кулларына алырлар, һәм Бен Джойс тирә-яктагы диңгезләрдә юлбасарлык итәр. Ләкин ул явызга хыянәтчел теләкләрен тормышка ашырырга ходай кушмаган икән.

Мельбурнга килеп җиткәч, Айртон боерыкны капитан ярдәмчесе Том Остинга тапшырды, аның эчтәлеге белән

танышкач, тегесе шундук якорьне күтәрергә кушты. Ләкин, кузгалып киткәч, икенче көнне капитан ярдәмчесенең яхтаны Туфольд култыгына түгел, бәлки Яңа Зеландиягә таба алып баруы билгеле булды! Моны белгәч, Айртонның башта югалып калуын, аннары тиресеннән чыгарлык булып ярсуын күз алдына китерсәгез икән! Айртон тавыш күтәрде, әмма Остин аңа хатны китереп күрсәтте. Чыннан да, бәхетле очрак аркасында, ягъни француз географның язуда хата җибәрүе аркасында корабка Яңа Зеландиянең көнчыгыш ярына барып көтеп торырга кушылган иде.

Айртонның барлык планнары җимерелде. Ул баш күтәрде. Аны ябып куйдылар. Шулай итеп, ул, шайкасының һәм лорд Гленарван отрядының ни хәлдә икәнен белә алмыйча, Яңа Зеландиягә барырга мәҗбүр булды.

«Дункан» Яңа Зеландия ярлары тирәсендә өченче мартка хәтле йөзеп йөрде. Шул көнне Айртон туп аткан тавыш ишетте. «Дункан», барлык тупларыннан атып, Гленарван отрядын сәламли иде, һәм үзенең юлдашлары белән бергә яхтага лорд Гленарван килеп менде.

Ә моңа хәтле менә нәрсәләр булган иде.

Бик күп җәфалар чигеп, күп сынаулар аша узып, лорд Гленарван отрядын шулай да көнчыгыш ярга алып чыга алган һәм Туфольд бухтасына килгән. Ә яхта анда булмаган! Гленарван Мельбурнга телеграмма җибәргән. Аңа каршы: «Шушы айның унсигезендә «Дункан» билгесез юнәлештә юлга чыкты», дигән җавап килгән.

Гленарван судноның батыр экипажы Бен Джойс кулына төшкән, ә яхта пират судносына әверелгән дип уйлаган.

Шуңа карамастан Гленарван эзләүне дәвам иттергән. Ул батыр йөрәкле, мәрхәмәтле кеше иде. Бер сәүдә судносына утырып, Яңа Зеландиянең көнбатыш ярына хәтле барган һәм утрауны утыз җиденче параллель буенча кичеп чыккан, әмма капитан Грант табылмаган. Аның каравы, гаҗәбенә каршы, ходайның рәхмәте белән «Дункан»ны очраткан, яхта капитан ярдәмчесенә бирелгән боерык буенча инде биш атнадан бирле аларны көтеп тора икән!

Бу хәл бер мең сигез йөз илле бишенче елның өченче мартында булды. Шулай итеп Гленарван яңадан «Дункан»да,— Айртон да шунда ук иде. Аны Гленарванның каршысына китерделәр. Гленарван ул явыздан капитан Грант турында белгәннәрен кабат сөйләтергә теләде.

Айртон сөйләүдән баш тартты. Гленарван беренче портка туктау белән аны Англия властьлары кулына тапшырачагын әйтте. Әмма Айртон дәшмәде.

«Дункан» утыз җиденче параллель буенча юлын дәвам итте. Шул арада Гленарван ханым, бандитның каршылыгын сындырмакчы булып, аның белән әңгәмәгә кереште. Ниһаять, ул ниятенә иреште. Айртон Гленарванга белгәнен сөйләргә сүз бирде, тик үзен Англия властьлары кулына тапшырмауларын, Тын океандагы берәр утрауга төшереп кенә калдыруларын шарт итеп куйды. Гленарван вәгъдә бирде, чөнки капитан Грантның язмышын белү өчен ул барысына да күнәргә риза иде.

Айртон үзенең бөтен тарихын сөйләп бирде. Австралиягә төшереп калдырганнан соң капитан Грантның язмышын белмәвен дә яшермәде.

Шуңа карамастан Гленарван үз сүзендә торды. «Дункан» юлын дәвам итте. Көннәрдән бер көнне алар Табор утравына җиттеләр. Айртонны шунда төшереп калдырырга карар иттеләр. Утыз җиденче параллельгә урнашкан шушы кечкенә генә җир кисәгендә алар көтелмәгән могҗизага юлыктылар: капитан Грант һәм аның ике матросы шунда сыеныр почмак тапкан булып чыкты. Алар урынына кешесез утрауда җинаятьчене калдырып киттеләр. Гленарван аны яхтадан төшкән чагында үгет-нәсихәт белән озатып калды:

— Айртон, сез биредә бөтен дөньядан, кешеләрдән читтә япа-ялгыз яшәячәксез. Сез бередән беркая качып китә алмассыз! Сез ходай каршында каккан казык кебек япа-ялгыз булырсыз. Ходай сезнең күңелегезне үтәдән-үтә күреп торачак. Капитан Грант өчен без кайгырткан кебек сезнең хакта берәү дә кайгыртмас. Чөнки сез намуслы кешеләрнең игътибарына лаеклы кеше түгел, әмма сезне онытмаслар, Айртон! Мин бу утрауны беләм, сезне кайдан табарга икәне билгеле. Мин сезне онытмаячакмын!

Шуннан соң «Дункан» якорьне күтәрә дә офык артына китеп күздән югала. Бер мең сигез йөз илле бишенче елның унсигезенче мартында була бу хәл.

Айртон япа-ялгызы торып кала. Әмма аны кирәкле һәммә нәрсә белән: сугыш кораллары, эш кораллары, азык-төлек белән тәэмин итәләр. Капитан Грант салган өй аңа кала. Ул сөргенлектә ялгызы көн итәргә һәм җинаяте өчен җәзасын татырга тиеш иде.

Аны вөжданы газаплады, ул эшләгән җинаятеннән тәүбә итте, әфәнделәр! Әгәр көннәрдән бер көнне кешеләр аны алырга дип килсәләр, ул алар арасына бөтенләй бүтән кеше булып кайтырга ант итте! Ни газаплар чикмәде ул бичара! Хезмәт кешене төзәтә дип көне-төне эшләде! Күңелен пакьләндерергә теләп, көне-төне гыйбадәт кылды.

Айртон ике, өч ел шулай ялгызлыкта җәфа чикте, офыкта кораб күренмәсме дип карый-карый күзләрен талдырды. Гөнаһыннан арыныр өчен әле тагын күпме җәфа чигәргә кирәк икән дип изаланды. Аның кебек газапланган кеше тагын дөньяда берәр булды микән... Күңелендә вөждан газабы йөрткән кешегә ялгыз яшәүдән дә авыр җәза юктыр.

Ходай бу җәзаны гына азсынды, күрәсең. Айртон үзенең кыргыйлана баруын сизде. Әкренләп акылын җуя башлады. Ике ел үттеме, әллә дүрт елмы, анысын әйтүе кыен, тик сөргендә ул тора-бара кешелек сыйфатларын бөтенләй җуйды. Сез аны шул хәлдә килеп таптыгыз!

Айртонның, ягъни Бен Джойсның, үзем икәнлеген әйтеп тору кирәк микән, әфәнделәр.

Сайрес Смит һәм аның иптәшләре хикәянең азагын аягүрә баскан килеш тыңладылар. Бу гыйбрәтле хикәянең аларга ни дәрәҗәдә тәэсир итүен сөйләп аңлатуы да кыен. Алар чын ихластан тәүбәгә килгән кешенең күңел газабын, ачыргалануын үз күзләре белән күрделәр!

— Айртон, сез зур җинаять кылгансыз. Әмма ходай тәгалә сезнең гөнаһыгызны кичергәндер дип уйлыйм! Менә хәзер кешеләр арасында булуыгыз шуны исбатлый. Сезнең гаебегез кичерелде, Айртон! Безнең дустыбыз булырга телисезме? — диде Сайрес Смит.

Айртон артка чигенде.

— Әйдәгез, дусларча кул кысышабыз,— диде инженер.

Айртон Сайрес Смит янына атылды, каты итеп аның кулын кысты, үзенең күзеннән эре-эре яшь бөртекләре тәгәрәде.

— Хәзер безнең янда яшәргә каршы түгелме инде? — дип сорады Сайрес Смит.

— Мистер Сайрес, утарда тагын бераз ялгыз яшим инде.

— Ихтыярыгыз,— дип җавап бирде Сайрес Смит.

Айртон ишеккә юнәлгәч, инженер аны туктатты:

— Туктагыз әле, дускай, әйтегез әле. Ялгыз яшәргә теләгегез булгач, нигә диңгезгә язу язып ташладыгыз соң? Шул язу аркасында без сезне эзләп таптык бит.

— Нинди язу? — дип гаҗәпләнеп сорады Айртон. Ул нәрсә хакында сүз барганын да төшенмәде ахрысы.

— Шешә эчендәге язуны әйтәм: без аны диңгездән таптык, анда Табор утравының дөрес координатлары күрсәтелгән иде.

Айртон кулы белән маңгаен сыпырып куйды. Бераз уйланып торгач, әйтте:

— Минем андый язу язганым юктыр. Диңгезгә шешә ташламадым.

— Беркайчан дамы? — дип сорады Пенкроф.

— Беркайчан да! — дип җавап бирде Айртон, һәммәсенә карап башын иде дә чыгып китте.

Унсигезенче бүлек

Әңгәмә.— Сайрес Смит һәм Гедеон Спилет.— Инженерның идеясе.— Электр телеграфы.— Электр чыбыклары.— Батарея.— Алфавит.— Җәй.— Колония чәчәк ата.— Фотография.— Ялган кар.— Линкольн утравында ике ел.

— Бичара Айртон! — диде Герберт. Ул Айртонның артыннан йөгергән иде дә, тегесе бау белән аска шуып төшеп китте дә караңгыга кереп күздән югалды.

— Ул кайтачак әле,— диде Сайрес Смит.

— Бу ни хикмәт, мистер Сайрес! Язулы шешәне диңгезгә Айртон ташламаганмыни? Кем ташлаган соң алайса? — диде Пенкроф, исе китеп.

Мондый сорауны бирергә җирлек бар иде шул.

— Язуны Айртон ташлаган,— диде Наб.— Тик бу эш акылы авыша башлаганчы булганга, хәтереннән чыккан.

— Әйе шул. Ул аны аңсыз рәвештә эшләгәндер,— дип эләктереп алды Герберт.

— Бүтәнчә аңлатып булмый, дусларым,— диде инженер да.— Айртонның утрау координатларын дөрес күрсәтүенең сере дә аңлашылды, ул аны алдан ук, утрауга төшереп калдырганчы ук, белгән булган.

— Димәк, ул язуны акылын бөтенләй үк җуеп бетермәгән чагында язган булган,— диде Пенкроф.— Шешәне моннан җиде-сигез ел элек диңгезгә ташлаган булып чыга. Алайса, язу ничек әйбәт саклана алган соң?

— Бу факт Айртонның акылын үзе уйлаганнан шактый соң югалткан булуын исбатлый,— диде Сайрес Смит.

— Шулайдыр ахрысы. Югыйсә сәер бит.

Сайрес Смитның сүзне озынга сузасы килмәде:

— Әйе, сез хаклы,— дип кенә куйды.

— Айртон безгә дөресен сөйләде микән соң, ничек уйлыйсыз? — дип һаман төпченә бирде Пенкроф.

— Әйе. Ул сөйләгәннәр барысы да чын,— дип җавап бирде журналист.— Гленарванның экспедициясе турында газетада хәбәрләр чыкты; әле дә хәтеремдә: экспедиция уңышлы тәмамланды, дип яздылар.

— Шикләнмәгез, Пенкроф, Айртон дөресен сөйләде,— дип өстәде Сайрес Смит та.— Үзен аяп тормыйча, бар дөреслекне ачып салды. Кешеләр тәүбәгә килгәндә һәрвакыт дөресен сөйлиләр!

Иртәгесен, 21 нче декабрьдә, алар, яр буйлап барып, Күзәтү яссылыгына менделәр, әмма анда Айртонны тапмадылар. Ул төнлә үк мал утарына киткән, күрәсең; анда барып, аны борчып йөрмәскә булдылар. Аның күңел җәрәхәтен төзәтү аларның кулыннан килмәде, бәлки вакыт үзе төзәтер.

Герберт, Пенкроф һәм Наб көндәлек эшләренә чумдылар. Ә Сайрес Смит белән журналист Хәрабәдәге мастерскойга киттеләр.

— Карагыз әле, кадерле Сайрес, шешәдәге язуны кичәгечә аңлату ышандырырлык түгел бит,— дип сүз башлады Гедеон Спилет.— Айртонның үзе язган язуны шешәгә салып диңгезгә агызуын онытуы мөмкинме?

— Димәк, шешәне ул ташламаган.

— Сез бүтән берәү дип уйлыйсызмы?

— Мин әлегә берни белмим. Бу очракны да моңарчы чишә алмаган табышмаклар исәбенә кертәм.

— Сезнең исән калуыгыз, ярдан табылган әрҗә, Топның серле өрүләре һәм, ниһаять, бу шешә — һәммәсе акыл җитмәслек серле нәрсәләр... Аларның серен кайчандыр бер чишә алырбызмы-юкмы?

— Чишәрбез! — диде инженер, озак уйлап тормастан.— Утрауның төбенә хәтле казып төшсәм төшәрмен, әмма серен табармын.

— Бәлкем, берәр очраклы хәл безгә ярдәм итәр әле?..

— Очраклы хәл дисеңме! Юк, Спилет! Мин, могҗизаи көчләргә ышанмаган кебек, очраклы хәлләргә дә

ышанмыйм. Ул аңлашылмаган хәлләрнең сәбәбен барыбер табачакмын, чөнки дөньяда сәбәпсез берни булмый. Ә хәзергә үз эшебезне эшли торыйк һәм туктаусыз күзәтик.

1867 нче елның январе җитте. Һәрвакыттагыча, җәй көннәрендә эшләре күп була иде. Беркөнне Герберт белән Гедеон Спилет мал утарына барып чыктылар һәм Айртонның яңа салган өйдә торуын күрделәр. Терлекләрне хәзер ул бага, утрау хуҗаларын артык эштән — ике-өч көн саен утарга барып йөрү мәшәкатеннән коткарды. Әмма Айртонны япа-ялгызын озак калдыру ярамый, аның янына еш барып йөриләр иде.

Шуның өстенә инженер белән Гедеон Спилетка утрауның бу яклары шикле тоела иде, аны күзәтергә дә кеше кирәк иде. Әгәр Айртон берәр шикле нәрсә сизсә, Гранит сарайга хәбәр итәр итүен.

Әгәр дә аңа бик ашыгыч хәбәр итәргә кирәк булса, нишләргә? Линкольн утравындагы серләрне әйтмибез дә инде, әгәр офыкта берәр кораб күренсә, яисә берәр кораб һәлак булса, яки утрауга пиратлар килеп төшсә я утрау хуҗалары кичекмәстән хәл итәргә тиешле бүтән берәр сәбәп чыкса, нишләр ул?..

Шуңа күрә Сайрес Смит мал утары белән Гранит сарай арасында хәбәр алышу өчен элемтә булдырырга кирәк дигән фикергә килде.

Унынчы январьда ул үзенең ниятен иптәшләренә сөйләп бирде.

— Ә нәрсә эшләргә уйлыйсыз соң сез, мистер Сайрес? Телеграф үткәрергә ниятләмисездер бит? — дип сорады Пенкроф.

— Нәкъ үзен,— диде инженер.

— Электрлы телеграфмы?

— Әйе, электрлы,— дип җөпләде инженер.— Ток батареясы ясардай нәрсәләребез бар хәзер. Тимерчыбык әзерләве генә кыенрак булыр. Ләкин анысының да эмәлен табарбыз.

— Валлаһи, көннәрдән бер көнне утравыбызда поездга утырып йөри башласак, һич тә гаҗәпләнмәячәкмен! — диде дингезче, куанып.

Озакка сузмыйча эшкә дә тотындылар. Иң кыены — тимерчыбык ясау иде. Чөнки анысы барып чыкмаса, батарея һәм башкаларны ясап торуның кирәге калмый иде.

Үзегезгә мәгълүм, Линкольн утравында тимер бик яхшы сыйфатлы иде, димәк аннан тимерчыбык сузу, мөгаен, кыен булмастыр. Сайрес Смит башта төрле диаметрлы түгәрәк тишекләр тишелгән корыч сандал эшләде, тишекләр бер яктан зуррак башланып, икенче ягында кечерәя иде. Тимерчыбыкны әнә шул тишекләрнең зурысыннан кечесенә таба бер-бер артлы тартып чыгара-чыгара кирәкле нечкәлектә сузуга ирешәчәкләр иде. Корыч коючылар сүзе белән әйткәндә, корыч сандалны башта үзен «чыныктырып», олы шарлавык янында җиргә казып урнаштырылган зур станга кузгалмаслык итеп беркеттеләр; инженер яңадан шарлавыкның көчен файдаланырга исәпли иде.

Анда бит тула басу җайланмасы да урнашкан иде. Шуның су ярдәмендә хәрәкәткә килүче чарыгы әлегә эшсез тора, шуны тимерчыбык тарттыру һәм урау өчен файдаланырга булдылар.

Бу эш катлаулы һәм бик мәшәкатьле икән. Бер башы игәүләп очланган нәзек озын тимер таяклар башта, кыздырылып, корыч сандалның иң эре тишегенә куела, әйләнеп торган чарык ярдәмендә тарттырыла һәм урала бара. Егерме биш-утыз футка хәтле сузылган бу чыбыкны киредән сүтеп алалар, янадан мичтә кыздыралар, эретә төшәләр дә кечерәк тишектән үткәрәләр. Нәтиҗәдә кырык-илле фут озынлыгындагы тимерчыбык хасил була. Шуларны үзара ялгап, мал утары белән Гранит сарай арасына сузу өчен җитәрлек биш миль озынлыгындагы электр чыбыгы әзерләделәр.

Бу эш берничә-көнгә сузылды. Ә Сайрес Смит үзе ул арада батарея ясау белән мәшгуль булды.

Ул даими ток батареясы ясарга керешге. Үзегезгә мәгълүм, хәзерге батареяның элементлары ясалма графит, цинк һәм бакырдан тора. Инженерның бакыры юк иде,— нихәтле тырышып эзләсә дә, утрауда ул бакыр тапмады һәм бакырдан башка гына эшләргә ниятләде. Ясалма графит гадәттә газ заводларында ташкүмернең водородын аерып чыгару юлы белән табыла. Утраудагылар ясалма графитны шул юл белән таба алган да булырлар иде, ләкин аның өчен махсус приборлар кирәк. Һәм бу бик катлаулы эш бит.

Аның каравы аларның цинклары бар иде. Укучы хәтерләсә кирәк, диңгез буеннан табылган әрҗәнең эчке каты цинктан ясалган иде. Әлеге цинкның кирәге чыкты.

Ныклап уйлаганнан соң, Сайрес Смит 1820 нче елны Беккерель уйлап тапкан иң гади электр чыганагына охшаш батарея ясарга булды, чөнки аңа фәкать цинк кына кирәк иде. Ә нитрат кислотасы белән поташны теләгәнчә табарга мөмкин иде.

Нитрат кислотасы белән поташның үзара тәэсир итешү көченә нигезләнгән батареяның ничек ясалуын сөйләп бирик.

Инженер берничә пыяла савыт әзерләде, аларга нитрат кислотасы салды. Савытларның авызын уртасы тишекле бөкеләр белән япты. Тишекләргә аскы башы балчык бөке белән томаланган пыяла көпшәләр тыгып куйды һәм аларны тукыма кисәге белән чорнады. Көпшәнең өске ачык башыннан поташ эремәсе салды. Үсемлек көленнән табылган поташ эремәсе, пыяла көпшәнең балчык бөкесе аша әз-әзләп саркып, нитрат кислотасы белән реакциягә керәчәк иде.

Аннары Сайрес Смит ике цинк пластинка алды, аның берсен нитрат кислотасына, икенчесен поташ эремәсенә батырды. Шундук электр көчәнеше хасил булды һәм нитрат кислотасына батырылган пластинкадагы кире полюстан поташ эремәсенә батырылган пластинкадагы уңай полюска таба электр агымы уза башлады. Электр телеграфын хәрәкәткә китерерлек көчәнеш хасил итү өчен берничә пыяла банканың барысын бергә тоташтырып батарея булдырырга кирәк иде.

Оста уйлап табылган шушы гап-гади җайланма Гранит сарай белән мал утары арасында элемтә урнаштырырга ярдәм итте.

Алтынчы февральдә утрау хуҗалары мал утарына бара торган юлның буеннан-буена башына пыяла изоляторлар куелган баганалар утыртып чыктылар һәм чыбык суза башладылар. Берничә көннән линия әзер булды, батарея тоташтырасы гына калды. Ток чыбык буйлап секундына йөз мең километр тизлек белән узарга һәм әйбәт үткәргеч булган җир буйлап кире әйләнеп кайтырга тиеш иде.

Ике яклы телеграф элемтәсе өчен ике батарея ясадылар, аның берсен Гранит сарайга, икенчесен мал утарына урнаштырдылар.

Кабул итүче һәм тапшыручы аппаратлар да бик гади иде. Ике станциягә дә тимерчыбык чорналган электромагнит, ягъни йомшак тимер кисәге куела. Чыбык үзе токка тоташтырыла, электр тогы үткәндә тимер кисәге

электромагнитка әверелә. Ток бетүгә, әлеге тимер кисәгенең магнитлануы да бетә. Әнә шул электромагнит янына юка корыч кисәгеннән «тел» урнаштырыла һәм ул, электромагнит аша ток узганда, аңа таба тартылырга, ток өзелгәндә яңадан үз урынына кире кайтырга тиеш. Әнә шул корыч «тел»нең хәрәкәтен инженер алфавит хәрефләре язылган циферблат өстендәге укны селкетү өчен файдаланды, һәм ук кирәкле хәреф турысында туктап калырлык итеп көйләнде. Шул рәвешле инженер Гранит сарай белән утар арасында хәбәр алышу өчен телеграф булдырды.

Телеграф 12 нче февральгә өлгерде. Сайрес Смит шул көнне үк ике як батареяны да тоташтырды һәм Айртонның хәлен сорашып хәбәр җибәрде, ә берничә секундтан Айртоннан уңай җавап килеп тә җитте.

Пенкроф телеграфка бик куанды, һәр иртә-кич Айртонга телеграмма җибәрә башлады һәм җавапсыз калмый иде.

Телеграф элемтәсенең ике файдасы тиде: беренчедән, Айртонның өйдәме-түгелме икәнен һәрвакыт белеп торырга мөмкин иде; икенчедән, ул үзен хәзер элекке кебек ялгыз сизмәде. Хәер, Сайрес Смит сирәк дигәндә атнага бер тапкыр мал утарына бармыйча калмый, Айртон үзе дә Гранит сарайга кайтып киткәли, анда аны һәрвакыт шатланып каршы алалар иде.

Җәй эш белән үтеп китте. Азык-төлек запасы көннән-көн арта, яшелчә һәм иген бик мул уңа. Табор утравыннан алып кайткан үсемлекләр дә гөрләп үсеп китте. Күзәтү яссылыгы аларның мактанычына әверелде. Бодайның дүртенче уңышы да бик шәп булды. Дүрт йөз миллиард бөртек орлык булды микән дип исәпләп торырга берсенең дә башына килеп карамады. Хәер, Пенкроф санарга керешмәкче иде дә, Сайрес Смит аңа, әгәр минутына өч йөз, сәгатенә тугызар мең орлык санасаң да, барысының исәбенә чыгу өчен биш мең ярым ел кирәк булачагын әйткәч, ниятеннән ваз кичте.

Һавалар яхшы тора: көндез бик эссе, ә кичкә ул бераз сүрелә, чөнки диңгез ягыннан салкынча рәхәт җил исә; Гранит сарай кешеләре кичке җиләс һавада рәхәт сулап калалар. Берничә тапкыр кыска вакытлы көчле яшенле яңгырлар явып узды. Бөтен күк йөзен яктыртып ялт та йолт яшен яшьнәде, дөбердәү тавышы бер генә минутка да тынып тормады.

Кечкенә биләмәнең хуҗалыгы бу вакытта колак ишетмәгән, күз күрмәгән рәвештә алга китте. Алар хәзер йорт кошы ите генә ашыйлар. Йорт кошлары артык күп үрчегәнлектән, хәтта аларны чак кына киметергә дә туры килде. Дуңгызлар балалады, Наб белән Пенкрофка тагын да эш күбәйде. Онагрлар да колынлады, икесенең дә берәр колыны булды.

Гедеон Спилет белән Герберт хәзер онагрларга гына атланып йөриләр. Герберт та шәп җайдак булып җитте. Кайвакыт онагрларны җигеп, арба белән Гранит сарайга утын, ташкүмер, инженерга дип төрле кирәк-яракны ташыйлар иде.

Утрау хуҗалары көннәрнең баш пешәрлек кызулыгыннан куркып тормыйлар, еш кына Ерак Көнбатыш урманнарына сәяхәткә йөриләр. Яшел ботаклар гөмбәзе аларны көйдергеч кояш нурыннан саклый иде анда. Рәхмәт елгасының сул як яр буен Шарлавык елгасы тамагына хәтле йөреп-карап чыктылар.

Алар сәяхәткә мылтыксыз бармыйлар иде, чөнки юлда кабан дуңгызлары еш очрый, ә алар белән очрашу хәтәр иде.

Быел утрау хуҗалары ягуарларга каршы рәхимсез сугыш ачтылар. Гедеон Спилет аларны күралмый иде, аның нәфрәте Гербертка да йокты. Шәп коралланган сунарчылар аяусыз ерткычларны курыкмыйча аулыйлар. Иптәшләре Гербертның йөрәклелегенә, Гедеон Спилетның салкын канлылыгына сокланып бетә алмыйлар иде. Гранит сарайның зур залын хәзер егермеләп затлы ягуар тиресе бизи. Әгәр көннәр бозылмаса, аучылар ягуарларны бөтенләй кырып бетерергә сүз бирделәр.

Кайвакыт инженер утрауның моңарчы тикшерелмәгән якларына барып сагаеп тирә-якны күзәтеп йөри. Ерып чыккысыз урманнарда ул ниндидер эзләр табарга азаплана. Әмма никадәр йөрсә дә, шикләнерлек берни очрата алмады ул. Аңа ияреп йөргән Топ белән Юп та үзләрен тыныч тоталар иде. Югыйсә эт һаман әле инженер төшеп бик җентекләп тикшергән кое тирәсендә әйләнгәләп чабып йөри, кое авызына карап ачу белән өрүен дәвам иткәли.

Бу көннәрдә Гедеон Спилет белән Герберт әрҗәдән табылган һәм моңарчы тик яткан фотоаппаратны сынап карадылар. Утрауның иң гүзәл почмакларын рәсемгә төшереп алдылар.

Көчле объективлы фотоаппарат белән бергә, аларның фотограф өчен кирәкле барлык кирәк-яраклары да бар иде. Фотопластинканы эшкәртү өчен коллодий, кәмеш нитраты да, фиксаж өчен гипосульфит, рәсемне кәгазьгә төшерү өчен аммоний хлориды, аны «сеңдерү» өчен уксус кислотасының натрий тозы һәм алтын хлориды да бар иде. Әрҗәдә хлор сеңдерелгән фото кәгазе дә табылды, тик аны эшкәртер алдыннан берничә минут көмеш нитратына салып тотарга кирәк иде.

Тиздән журналист белән Герберт оста фотограф булып киттеләр. Төшерелгән табигать күренешләре: офык читендә Франклин тавы калкып күренгән утрау панорамасы; биек кыя ярлар эченнән аккан Рәхмәт елгасы тамагы; тау итәгенә, урман авызына урнашкан мал утары; Тырнак һәм Табылдык борыннарының кабатланмас күренеше рәсемдә бик матур чыкты. Фотографлар утрау хуҗаларын да рәсемгә төшерергә онытмадылар.

— Без күбәябез,— дип шаярта иде Пенкроф.

Гранит сарай стенасына тезеп куйган рәсемнәр күргәзмәсен ул Бродвейдагы бай кибет витринасын карагандай сокланып карап йөри иде. Рәсемнәр арасындагы үз портреты турысында аеруча масаеп басып тора ул. Дөресен әйткәндә, Юп рәсеме һәммәсенекеннән дә уңышлы чыкты. Аның фотограф алдында утыргандагы җитди кыяфәте көлеп үләрлек иде. Шуңа күрә рәсеме дә бик тере чыкты.

— Карагыз әле, карагыз, хәзер йөзен чытып җибәрә бу,— дип көлә диңгезче.

Маймыл кызу холыклы, әгәр портретын ошатмаса, күптән дулап киткән булыр иде инде; рәсемгә тел тидерерлек түгел иде шул, шуңа күрә ул да үз рәсеменнән күзен алмыйча сокланып тора.

Мартта җәйге кызулар кимеде. Яңгырлар чоры башланды. Ләкин һава һаман җылы иде әле. Быелгы март (ул Төньяк ярымшардагы сентябрьгә туры килә) шулай да үткәннән салкынрак, яңгырлырак булды. Мартта көннәр торышына карап, кыш иртә киләсен, кырыс буласын алдан ук сизәргә мөмкин иде.

21 нче мартта иртән хәтта кар төшкәндәй тоелды. Иртүк тәрәзә янына барган Герберт, кинәт:

— Карагыз әле, бөтен Котылу утравын кар каплаган! — дип сокланып кычкырып җибәрде.

Журналист та тәрәзәгә карады:

— Кар яварга иртәрәк әле,— диде ул.

Башкалар да тәрәзәгә килеп капландылар. Әйе, утрау гына түгел, Гранит сарай итәгендә бөтен яр буе җәймә япкан кебек ап-ак иде.

— Чып-чын кар бу! — диде Герберт.

— Валлаһи, карга охшаган! — дип аптырады Наб.

— Термометр илле сигез градус күрсәтә бит (Цельсий буенча 14° җылы)! — диде Гедеон Спилет.

Сайрес Смит ак җәймәгә сүзсез генә карап тора бирде, чөнки ул елның бу вакытында, бүгенгедәй җылы көнне, кар төшү сәбәбен аңлата алмады.

— Ах шайтан! Яшелчәләребезне харап итә инде! — диде Пенкроф, үрсәләнеп.

Диңгезче түбәнгә төшәргә җыенган иде, тиктормас Юп аны узып аска төшеп китте.

Орангутангның җиргә төшеп басуы булды, җир өстен каплаган ап-ак калын җәймә дәррәү өскә күтәрелде дә, кояш йөзен томалап, меңләгән вак кисәкләргә сибелде.

— Кошлар! — дип кычкырып җибәрде Герберт.

Чынлап та, болар — күзне чагылдырырлык ап-ак мамыклы диңгез кошлары иде. Йөз меңнәрчә кошлар көтүе, кечкенә утрауга һәм яр буена төшеп, җир өстен каплап алган булган, ә хәзер, һавага күтәрелеп, офыкка китеп күздән югалдылар. Театр сәхнәсендәге кебек, кышның кинәт җәй белән алмашынуын кешеләр шаккатып карап калдылар. Аянычка каршы, бу хәл шулхәтле көтелмәгәндә булды ки, Гедеон Спилет белән Герберт бер генә кошны да атып алырга өлгермәделәр. Бу кошларның кайсы токымнан икәнен дә, ничек аталганын да белмичә калдылар.

Берничә көннән соң, 26 нчы мартта, һәлакәткә очраган аэронавтларның Линкольн утравына килеп төшүенә ике ел тулды!

Унтугызынчы бүлек

Туган илләрен искә алу.— Өметләр, өметләр.— Яр буйларын тикшерү планы.— 16 нчы апрель — юлга чыгу көне.— Борылмалы ярымутрауның диңгездән күренеше.— Көнбатыш ярдагы базальт кыялар.— Көннәр бозыла.— Төн якынлаша.— Тагын бер сер.

Һәлакәткә очраган дусларыбызның кешесез җирдә яши башлауларына төгәл ике ел булды! Ике елдан бирле алар дөнья йөзендә ниләр барын белмәделәр, океан

уртасында югалып калган утрауда кояш системасының нәни астероидына эләккән кешеләр кебек яшәделәр.

Туган илләрендә хәзер нинди үзгәрешләр булды икән? Алар киткәндә илдә гражданнар сугышы туктамаган иде, көньяк кол биләүчеләр илне канга батырмадылар микән?

Алар шулай еш кына туган илләрен сагынып сөйләшеп алалар иде, тик Кушма Штатларда төньяклыларның хак эше җиңәчәгенә өмет өзмиләр иде.

Шушы ике ел эчендә утрау янына бер генә кораб та килеп чыкмады, офыкта бер генә җилкән дә күзгә чалынмады. Линкольн утравы диңгез юлларыннан читтә булганга, аны белүче юк иде, күрәсең. Картада күрсәтелмәгән булуы да шуны раслый иде. Гәрчә җайлы бухтасы булмаса да, эчәргә су алу өчен кораблар анда туктарга тиеш иде югыйсә.

Тирә-якта тик очсыз-кырыйсыз океан сулары,— аларга читтән килеп беркем ярдәм кулы сузмаячак,— димәк, илләренә ничек кайту турында үзләренә кайгыртырга кала. Котылуның бер генә чарасы бар. Апрель башларында Гранит сарайның зур залына җыелып әнә шул хакта бик озак сөйләштеләр.

Сөекле ватаннары Америка турында сүз чыккач, Гедеон Спилет:

— Линкольн утравыннан илебезгә кайтып китәргә теләсәк, бер генә чарабыз бар: ерак юлга чыдарлык зур кораб төзергә кирәк,— диде.— Кечкенәсен төзи алдык бит, океан гизәрдәен төзергә әллә кулыбыздан килмәсме!..

— Табор утравына барып җитә алганны, Туамоту утраулары тезмәсенә дә барып җитә алырбыз әле! — дип өстәде Герберт.

Диңгездә йөзү турында әңгәмә купса, Пенкрофның сүзе алдан йөри иде.

— Мин каршы түгел, мин риза,— диде ул.— Тик якын утрауга бару белән ерак юлга чыгу икесе ике нәрсә! Табор утравына гына барганда да җил судноны йомычка урынына чайкады, тик ул чакта без ярның янәшәдә генә икәнен белә идек. Ә кешеләр яши торган җирнең безгә иң якын дигәне дә — ике мең миль ераклыкта, бу — уен эш түгел! — диде.

— Пенкроф, сез әллә тәвәккәлләргә куркасызмы? — дип сорады журналист.

— Эш миңа терәлсә, мин теләсә кая барырга әзер, мистер Спилет. Үзегезгә мәгълүм, мин өркүчеләрдән түгел.

— Хәзер безнең икенче диңгезчебез дә бар, Пенкроф, шунысын да онытма син,— дип өстәде Наб.

Пенкроф, гаҗәпләнеп:

— Кем? — дип сорады.

— Айртон.

— Дөрес,— диде Герберт.

— Әгәр ул безнең белән китәргә риза булса!

— Нигә китмәсен икән ул, Пенкроф? Табор утравында яшәгәндә Гленарван яхтасы аны алырга дип килгән булса, әллә Айртон иленә кайтудан баш тартыр иде дисезме? — диде журналист.

— Айртон акылын соңгы елларда гына җуйган бит. Хәер, мәсьәлә анда түгел. Шотландия корабы Айртонны алып китәргә килерме, аңа өмегләнеп торыргамы-юкмы — шунысын хәл итәргә кирәк. Җәзасын җитәрлек татыды дип ышангач, Гленарван Табор утравыннан аны алып китәргә вәгъдә иткән бит. Ул вәгъдәсендә торыр дип уйлыйм мин.

— Ул тиздән килер, чөнки Айртонны калдырып киткәненә инде унике ел үткән! — диде журналист.

— Лорд Гленарван килми калмас, тиздән килергә тиеш,— диде Пенкроф та.— Аның яхтасы кая килер дисез соң? Линкольн утравына түгел бит инде, Табор утравына, әлбәттә.

— Әйе шул,— диде Герберт та.— Безнең Линкольн утравы хәтта картада да юк.

— Табор утравына килгән кешеләргә Айртонның һәм безнең Линкольн утравында икәнлекне белгертергә кирәк,— диде инженер.

— Капитан Грант төзегән, соңыннан Айртон яшәгән йортта Линкольн уравының координатларын күрсәтеп хат язып калдырырга кирәк. Хатны Гленарван һәм аның юлдашларының күзе төшәрлек җиргә куярбыз.

— Их, Табор утравында чагында нигә башыбызга килмәгән соң бу! — дип куйды диңгезче, үкенеп.

— Уебызга да кереп чыкмады ичмасам! — диде Герберт.— Чөнки ул чакта без Айртонның тарихын белми идек, аны алырга киләбез дип вәгъдә итүләрен дә белми идек; без боларны көз көне генә белә алдык, көннәр бо-

зылгач кына,— ул чакта Табор утравына барырлык түгел иде инде.

— Әйе шул, ул вакытта барырга соңга калган идек инде, хәзер яз җиткәнен көтәргә кала,— дип җөпләде Сайрес Смит.

Пенкроф шикләнә калды:

— Әгәр Шотландия яхтасы менә шушы көннәрдә килеп чыкса?

— Ай-һай, икеле. Гленарван кыш көне ерак юлга чыкмас,— диде инженер.— Килсә дә, Айртон монда яшәгән арада, соңгы биш ай эчендә, килеп киткәндер, әгәр килмәгән икән, ул чагында аны озак көтәргә туры килер; октябрьдә, көннәр әйбәтләнү белән, Табор утравына хат илтеп куярбыз.

— Әгәр «Дункан» килеп киткән икән, бик үкенечле була инде,— диде Наб.

— Килмәгәндер, ходай тәгалә безне илебезгә кайтудан мәхрүм итмәс! — диде Сайрес Смит.

— Килгәнен-килмәгәнен Табор утравына баргач белербез әле, аннары нишләргә икәнен хәл итәрбез,— диде журналист.

— Дөрес,— диде инженер.— Шуңа күрә сабыр булыйк, дусларым, һәм яхтага утырып Ватаныбызга кайтырбыз дип өмет итик; инде өметебез алдаса, тагын берәр нәрсә уйлап табарбыз.

— Әгәр без Линкольн утравыннан китәргә җыенабыз икән, утрау начар булган өчен китмибез, шулай бит, дусларым! — диде Пенкроф.

— Әлбәттә шулай, Пенкроф,— дип аның сүзен җөпләде Сайрес Смит.— Иң кадерле нәрсәләрдән: гаиләбездән, дусларыбыздан, Ватаныбыздан аерылып яшәргә кыен булганга китәбез!

Шундый карарга килгәч, алар зур кораб төзү, төньяктагы архипелагка яки көнбатыштагы Яңа Зеландиягә таба юлга чыгу хакында бүтән сүз кузгатмадылар. Көндәлек эшләренә чумдылар, һәм Гранит сарайда өченче кышларын чыгарга әзерләнделәр.

Көннәр бозылганчы корабка утырып утрауның яр буйларын әйләнеп чыгарга уйладылар. Әле һаман бөтен яр буйларын тикшереп бетергәннәре юк бит. Шарлавык елгасы тамагыннан алып Төньяк һәм Көньяк Казна борыннарына хәтле сузылган көнбатыш һәм төньяк ярларны, акула авызына охшаган тар култыкны юньләп белмиләр әлегә.

Бу сәяхәтне Пенкроф тәкъдим итте, һәм үз биләмәсен тулысынча өйрәнеп чыгарга теләгән Сайрес Смит моны хуплады.

Көннәр үзгәреп торса да, барометр әкрен төшә, яисә әкрен күтәрелә. Шуңа күрә һава шартлары йөзүгә комачауламас дип өмет итәләр. Апрель башында барометр теле аска төште, көнбатыштан биш-алты тәүлек көчле җил исеп торды, аннары барометр теле аязуга таба күтәрелә башлады. Аннары басым 759,45 миллиметрда туктап калды, һәм сәяхәтчеләр юлга чыгарга мөмкин дигән фикергә килделәр.

Кузгалып китү көнен 16 нчы апрель дип тәгаенләделәр. Һава шары портында якорьдә торган «Хәерле юл»ны юлга әзерләгәндә сәяхәтнең озакка сузылу мөмкинлеген истә тоттылар.

Сайрес Смит экспедициягә барырга җыенуларын Айртонга да җиткерде һәм аны да алып барырга теләүләрен әйтте, әмма Айртон моннан баш тартты. Ул чакта аңа үзләре кайтканчы Гранит сарайда торып торырга куштылар. Иптәшкә Юп абзыкайны калдырдылар.

16 нчы апрельдә иртән сәяхәтчеләр, Топны ияртеп, юлга кузгалдылар. Көньяк-көнбатыштан көчле җил исеп тора. «Хәерле юл», Һава шары портыннан чыккач, Елан борынына таба курс тотып, әле уң яны, әле сул яны белән борылып барырга мәҗбүр булды. Утрауның бөтен әйләнәсе туксан миль булып, гаваньнан алып Елан борынына хәтле көньяк яр егерме мильгә тиң иде. Шушы егерме миль араны сәяхәтчеләр җилгә каршы йөзеп бардылар.

Шул араны кораб көне буе узды, җитмәсә тиздән су күтәрелә башлады, һәм алты сәгать буена «Хәерле юл» дулкыннар белән көрәшеп барырга мәҗбүр булды. Төн җиткәндә генә ул Елан борынын урап уза алды.

Пенкроф җилкәннәрнең икесен җыярга һәм, тизлекне киметеп, юлны дәвам иттерергә тәкъдим кертте. Әмма Сайрес Смит ярга ике кабельтов җирдә якорь салып туктарга да шунда төн уздырырга, иртән яр буйларын әйбәтләп күзәтергә дигән фикерне артык күрде. Утрауның яр буйларын җентекләп тикшерү өчен, көндез генә йөзәргә, ә кичләрен, караңгы төшү белән, ярга якын килеп, якорь салып туктарга булдылар.

Кораб якорь салган көе төне буе шунда торды; җил

тынды, томан төште, су өсте тып-тын иде. Пенкрофтан кала, сәяхәтчеләр барысы да, өйдәге кебек үк булмаса да, төне буе рәхәтләнеп йокладылар.

Унҗиденче апрельдә кояш чыгу белән Пенкроф якорьне күтәрде дә көнбатыш яр буйлап сул галс белән йөзеп китте.

Яр читенә хәтле төшкән куе урманлы бу тирәләр сәяхәтчеләргә таныш иде инде, алар аннан бер тапкыр җәяүләп узганнар иде, бу юлы да гүзәл табигать манзарасыннан күзләрен ала алмыйча сокланып карап бардылар. Әйбәтрәк күрү өчен ярга якын йөзделәр, су өстендә чайкалган агач кәүсәләрен урап-урап уздылар. Берничә тапкыр якорь ташлап тордылар, туктаган араларда Гедеон Спилет гаҗәеп матур табигать күренешләрен рәсемгә төшереп алды.

Көн урталарына «Хәерле юл» Шарлавык елгасы тамагына якынлашты. Елгадан соң диңгез яры буйлап сузылып килгән урман сирәгәя, өч миль ераклыкта шәрә кыя ташлар башланып китә, алар арасында урыны-урыны белән генә яшеллек күренә.

Утрауның көньяк яры белән төньяк яры арасында аерма искитәрлек зур иде! Беренчесе ямь-яшел урман белән капланган булса, икенчесендә кыргый кыялар гына тырпаешып тора! Бу ярны «тимер яр» дип атарга да ярар иде,— чөнки күп якларда моныңише яр буйларын шулай атыйлар. Төрле рәвешләргә кереп тырпаешкан кыялар гүя биредә кайсыдыр геологик гасырларда кайнар лаваның кинәт кристаллашу процессының шаһиты булып торалар иде. Әгәр дә сәяхәтчеләр һава шары белән егылып төшкән вакытта шушы ярга туры килсәләр, бу шыксыз ташлар хәрабәсен күреп өметсезлеккә төшкән булырлар иде! Теге чакта, Франклин түбәсенә менеп биеклектән күзәткәндә, алар бу ярны мондый ук имәнеч һәм куркыныч дип күз алдына китермәгәннәр иде. Ә хәзер бу яр алар алдында кабатланмас рәвеше белән ярылып ята, җир йөзенең башка бер генә почмагында да мондый күренеш очратмассың!

«Хәерле юл» ярты миль эчкәре кереп диңгездән йөзеп бара. Яр буендагы төрле әкәмәт рәвешле, егерме футтан алып өчәр йөз фут озынлыктагы таш кантарлар шул ераклыктан да ап-ачык күренәләр. Өскә таба очлаеп менгән мәчет манараларын, гөмбәзсыман чиркәү башларын, дүрткырлы очлы һәйкәлләрне, нәзек озын

фабрика торбаларын хәтерләткән бу кантарлар өсте-өстенә өелешкән. Боз океанында бер-берсенә бәрелеп өелешкән боз таулары да бу хәтле үзенчәлекле дә һәм шул ук вакытта куркыныч та манзара тудыра алмас иде. Әнә тегендә гүя кыядан кыяга күпер сузылган, ә монда кыя очлары бер-берсенә аркалар белән тоташкан; арырак төпсез тирән тау мәгарәсе эче күренеп ята; янәшәсендә таш сөңгеләр, манаралар, таш уклар калкып чыккан, андыйны хәтта бер генә готик стиль соборында да күрмәссең. Иң бай фантазияле төзүченең дә кулыннан килмәслек бу могҗизаны табигать иҗат иткән, һәм ул сигез-тугыз мильгә сузылган яр буена үзенә бер мәһабәт төс биреп тора.

Сайрес Смит һәм иптәшләре шушы яр буена сулышларын да алмыйча карап тордылар. Ләкин Топ, никтер, бу тынычлыкны бозарга тартынмыйча, базальт кыяларда катлы-катлы яңгыраган кайтаваз уятып, каты итеп өрергә тотынды. Этнең болай өрүе дә инженерга бик сәер тоелды. Гранит сарай идәнендәге кое авызына карап та ул нәкъ шулай өрә торган иде бит.

— Тукталыйк шушында,— диде Сайрес Смит.

«Хәерле юл» кыялы ярга якын ук килде. Бәлкем, анда берәр мәгарә бардыр? Әмма Сайрес Смит анда тере җан иясе кереп ышыкланырлык тау куышы да, тишек-фәлән дә күрмәде; су күтәрелгән вакыт булганга, кыялар итәгенә үк менеп дулкын чайкала иде. Ниһаять, Топ та тынып калды. Аннары кораб, ярдан чак кына диңгезгә таба ераклашып, юлын дәвам итте.

Төньяк-көнбатыш яр буйлары комлы, сөзәк иде; хәер, сәяхәтчеләргә бу җирләр шактый таныш инде; сазламыклы үзәннәрдә анда-санда ялгыз агачлар үсеп утыра, артта калган кыргый шәрә яр буйларының киресе буларак, биредә оялаган су кошлары чыр-чулары белән тирә-юньне яңгыратып, ямьләндереп торалар иде.

Тиздән «Хәерле юл» утрауның төньяк очына урнашкан кечкенә генә, әмма тирән сулы бухтада ярга якын ук килеп туктады. Төн тыныч узды, чөнки җил шәфәкъ нуры белән бергә тынып, таң нуры белән бергә генә уянды.

Ярга төшүе кыен түгел иде. Утрауның оста аучылары Герберт белән Гедеон Спилет иртә таңнан урманга кереп киттеләр һәм ике сәгатьтән берәр бәйләм кыр үрдәкләре, шөлдиләр асып әйләнеп тә кайттылар. Топның,

яшен кебек атылып чабып йөреп, бер генә кошны да кулдан ычкындырмавын сокланып сөйләделәр.

Сәгать сигездә «Хәерле юл» якорен күтәрде дә уңай искән җил белән Төньяк Казна борынына таба кызу гына йөзеп китте. Көндез җил сизелерлек көчәйде.

— Көнбатыштан көчле җил исәргә уйлый,— диде Пенкроф.— Кичә кояш бурлаттай кызарып баеды, ә иртән күктә «мәче койрыклары» күренде, хәерлегә түгел бу.

«Мәче койрыклары» дип күк йөзендәге юка мамык очканын хәтерләткән озынча болытларны әйтәләр. Алар диңгез өстеннән биш мең фут биектә очалар һәм давыл буласын алдан хәбәр итәләр иде.

— Әйдәгез, алайса, барлык җилкәннәрне корыйк та тизрәк Акула култыгына барып җитик, шунда кереп сыенырбыз. Анда «Хәерле юл»га тыныч булыр,— диде Сайрес Смит.

— Дөрес әйтәсез,— диде Пенкроф та.— Төньяк яр буйларының карап сокланырлык нәрсәсе дә юк, гел ком көрте дә ком өеме, күңелсез тирәләр бу.

— Мин култыкта төн кунып кына калмаска, бәлки иртәгәсе көнне дә шунда уздырырга кирәктер дип киңәш итәм, аны бер әйбәтләп карап чыгасыбыз бар ич инде,— диде инженер.

— Теләсәк-теләмәсәк тә шулай эшләргә туры килер әле,— диде Пенкроф.— Әнә көнбатышка күз салыгыз, аннан нинди дәһшәтле кап-кара болыт килүе күренә!

— Һәрхәлдә, мондый уңай искән җилдә без Төньяк Казна борынына барып җитәргә өлгерәбез,— диде журналист.

— Әлегә җил уңай, арттан исә исүен, әмма култыкка кергән чакта ул безгә каршы әйләнәчәк: әле уң, әле сул ян белән борылгалап барсак кына инде. Җитмәсә без суның төбе нинди икәнен дә белмибез, шуңа күрә култыкка якты күздә керү хәерле булыр! — диде диңгезче.

— Көньяк өлешенә карап хөкем итсәк, Акула култыгының төбе рифлар белән капланган булырга тиеш,— дип искәртте Герберт.

— Пенкроф, үзегез ничек кирәк, шулай эшләгез. Без сезгә ышанабыз,— диде Сайрес Смит.

— Тыныч булыгыз, мистер Сайрес,— диде диңгезче,— бер дә юктан мин хәтәр җиргә барып кермәм! «Хә-

ерле юл»ның карынын төртеп тиштерүгә караганда, үземә пычак кадасалар, артыграк булыр.

Пенкроф корабның су астындагы өлешен «карыны» дип атый иде һәм аны үз гомеренә караганда кадерләбрәк саклый иде.

— Сәгать ничә? — дип сорады Пенкроф.

— Сәгать ун,— дип җавап бирде Гедеон Спилет.

— Төньяк Казна борынына хәтле ничә миль калды, мистер Сайрес?

— Чама белән унбиш миль,— диде инженер.

— Димәк, ике сәгать ярымнан, ягъни беренче яртыга Төньяк Казна борыны турысына җитәрбез,— диде диңгезче.— Үкенечкә каршы, су чигенә башлаган вакытка туры киләбез. Бухтага кергәндә җилгә һәм су агымына каршы баруы кыен булачак, мин шунысыннан шүрлим.

— Бүген ай тулган көн, апрель аенда бу көнне суның аеруча нык күтәрелүе һәм төшүе көтелә,— диде Герберт.

— Борын очына якорь салып туктап булмыймы соң, Пенкроф? — дип сорады Сайрес Смит.

— Ни сөйлисез, мистер Сайрес! Давыл чыгарга торганда яр буена барып якорь салырга ярыймыни! — дип кызып китте диңгезче.— Үз ирегегез белән диңгез төбенә китмәкче буласызмы?

— Нишләргә соң?

— Су яңадан күтәрелә башлаганчы, ягъни кичке җидегә хәтле ачык диңгездә торырбыз; караңгы төшеп өлгермәсә, шул чакны култыкка керергә тырышып карарбыз; барып чыкмаса — төнне диңгездә уздырабыз, таң ату белән корабны бухтага алып керермен.

— Үзең кара инде, Пенкроф, без сезгә ышанабыз,— дип кабатлады Сайрес Смит.

Пенкроф тирән итеп көрсенде:

— Эһ, шушында каршыда маяк торсын икән, безгә диңгездән узарга җиңел булыр иде.

Герберт та өстәп җибәрде:

— Яр буенда бу юлы безне булдыклы дустыбыз учак ягып көтеп тормый шул, бухтага керү юлын күрсәтүче юк!

— Карале, кадерле Сайрес, әле дә Герберт искә төшерде, без сезгә рәхмәт әйткәнебез юк бит әле. Дөресен әйткәндә, әгәр учак ягып юл күрсәтмәгән булсагыз,

без утрауга гомергә кайта алмаган була идек...— диде Гедеон Спилет инженерга.

Сайрес Смит, гаҗәпләнеп:

— Нинди учак? — дип сорады.

Журналист өчен Пенкроф җавап бирде:

— Сүз шул турыда бара, мистер Сайрес, утрауга әйләнеп кайтканда безгә бик кыенга туры килде. Әгәр дә унтугызынчы октябрьдән егерменче октябрьгә каршы төндә Гранит сарай янындагы мәйданда сез безне кайгыртып учак ягып куймаган булсагыз, без утрауны күрмичә яныннан узып китә идек.

— Әйе, әйе, бу чыннан да әйбәт фикер булган...— дип кенә мыгырданып куйды инженер.

— Ә хәзер безгә андый ярдәм күрсәтүче юк, әгәр Айртонның уена гына килмәсә...— дип өстәде диңгезче.

— Әйе шул, беркем юк! — дип раслады инженер.

Берничә минуттан, корабның борынында журналист белән икәү генә калгач, инженер аңа пышылдады:

— Сиңа шуны гына әйтә алам, Спилет, унтугызынчы октябрьдән егерменче октябрьгә каршы төндә Гранит сарай янындагы мәйданда да һәм башка бер генә җирдә дә минем учак якканым булмады!

Егерменче бүлек

Диңгездә төн.— Акула култыгы.— Кышка әзерләнү.— Иртә килгән кыш.— Салкыннар.— Йорт эчендәге эшләр.— Алты айдан соң.— Фоторәсем.— Көтелмәгән хәл.

Хәлләр нәкъ Пенкроф әйткәнчә булып чыкты,— аның алдан сизенүе тикмәгә булмаган. Җил көчәйгәннән-көчәйде, сәгатенә кырык-кырык биш миль[1] тизлек белән исә башлады, чын давылга әйләнде; җилкәнле кораблар ачык диңгездә мондый җилгә эләккәндә, гадәттә, рифләрне җыярга, брамсель җилкәнен төшерергә ашыгалар иде. Кичке сәгать алтыга «Хәерле юл» Акула култыгы турысына килеп җитсә дә, су кими башлаганлыктан, бухтага керә алмады. Капитан Пенкроф ачык диңгездә калырга мәҗбүр булды. Һәм мондый давылда, бик теләсә дә, Рәхмәт елгасы тамагына да кереп сыена алмас иде. Ул, грот җилкәнен җыеп, кливерны куйды һәм

[1] Ягъни сәгатенә 106 километр чамасы. *(Авт. искәрмәсе.)*

корабның борынын коры жиргә таба борды да күтәргә булды.

Җил нихәтле котырып иссә дә, бәхетләреннән, кыя яр ышыгында диңгез ул кадәр үк көчле давылламый иде. Кечкенә корабларны һәлак итә торган гаять зур дулкыннар монда килеп житмәделәр. Хәер, «Хәерле юл» үзе дә тиз генә йөзтүбән капланмас иде, чөнки аңа балласт дөрес төялгән иде. Әмма зур дулкыннарның палуба өстенә үк менеп корабны батыру ихтималын да онытмыйк. Тәҗрибәле диңгезче буларак, Пенкроф дулкын белән көрәшергә әзерләнде. Үз корабының бирешмәсенә инанса да, ул таң атуын зарыгып көтте.

Төн буена да Сайрес Смит белән Гедеон Спилетка икәү генә калу, серләшү җае чыкмады. Ә инженерның журналист колагына пышылдап әйткән сүзләренә карагандa, аларга Линкольн утравы белән идарә итүче яшерен көчнең яңа чыгышы турында фикер алышырга кирәк иде. Яр буенда янган әлеге учак сере Гедеон Спилетка һич тынгылык бирмәде. Учак төшкә генә кермәде бит инде! Аны Пенкроф белән Герберт та күрделәр! Күзгә төртсән күренмәслек караңгыда шул учак аларга утрауга юл күрсәтте; алар аны инженер якканлыгына шикләнмәделәр ич, ә хәзер менә, ишетмәсәң ишет, Сайрес Смит минем анда катнашым юк дип бара!

Өйгә әйләнеп кайткач та, журналист бу турыда инженер белән әйбәтләп сөйләшергә кирәк дип үзенә сүз бирде. Бу серне башкаларга да ачарга кирәк. Бүтәнчә булмый. Бәлкем, бергәләп Линкольн утравын тагын да тикшерерләр!

Ничек кенә булмасын, тикшерелмәгән култыкка керә торган яр буенда бу төнне учак янмады, «Хәерле юл» төне буе ачык диңгездә торды.

Көнчыгышта алсу таң нуры сызылуга, җил бераз басылды, юнәлешен чак кына үзгәртте, һәм корабны тар бугаз аша алып керүне җиңеләйтте. Иртән сәгать җидедә «Хәерле юл», Төньяк Казна борынын әйләнеп үтеп, тар бугаз аша бухтага килеп керде. Аның ярлары суынган лава кантарларыннан гыйбарәт иде.

— Бөтен бер флот сыярлык икән бу! — дип сокланып куйды Пенкроф.

— Иң кызыгы, култык ярлары вулкан атканда ике якка аерылып киткән агымнан хасил булган. Вулкан аткан саен ярлар биегәя барган. Шуңа күрә култык ике яктан да әйбәт ышыкланган: давыл вакытында да

монда диңгез суы күл өсте кебек тыныч булырга тиеш,— дип искәртте Сайрес Смит.

— Дөрес әйтәсез,— диде диңгезче.— Җил монда тар бугаз аша гына керә ала. Шуның өстенә тагын, төньяк борын көньяк борынны каплап, ышыклап тора, шунлыктан җил-давыллар бөтенләй дә үтә алмыйдыр. Валлаһи, безнең «Хәерле юл» монда ел буе якорьда тыныч тора алыр иде.

— Култык «Хәерле юл» өчен артык зур шул! — диде журналист.

— Дөрес әйтәсез, мистер Спилет,— диде диңгезче,— «Хәерле юл» өчен ул зур булыр, әгәр Кушма Штатлар флотына тыныч урын кирәк булса, моннан да әйбәтне табып булмаячак, минемчә!

Наб култыкның ярларына карап торды да:

— Акула авызына эләккән кебек,— дип пошынып куйды.

— Нәкъ акула авызы инде! — дип раслады Герберт та.— Курыкма, Наб, акула безне йотмас!

— Юк, Герберт, мин курыкмыйм анысы, шулай да култык миңа ошамый. Бигрәк шомлы тоела! — дип җавап бирде Наб.

Пенкроф:

— Син нишлисең, Наб, нигә минем култыкны хурлыйсың, мин аны Америкага бүләк итмәкче идем бит! — дип кычкырып җибәрде.

— Ничек соң, тирән микән монда? — дип кызыксынды инженер.— Безнең «Хәерле юл»га ярагач та, бронялы судноларга ярамас ул.

— Аны тикшерүе бик мөмкин, кыен түгел,— дип җавап бирде Пенкроф.

Диңгезче суга үзе ясаган лотны (бауга тагылган тимер кисәген) төшереп җибәрде. Илле сажинлы бау аска төшеп бетсә дә, тимер кисәге төпкә барып җитмәде.

— Безнең бронялы суднолар монда керә ала, комга утырмас,— диде Пенкроф.

— Чын упкын икән бу,— дип шаккатты Сайрес Смит та.— Утрау вулкан атудан барлыкка килгән. Диңгез төбендә чоңгыллар булуы бер дә гаҗәп түгел.

— Култыкның ярлары да текә, стена кебек тора,— диде Герберт.— Пенкрофның бавы, моннан биш-алты тапкыр озынрак булса да, төбенә җитмәс, шәт.

— Болары бар да әйбәт анысы, сүз юк. Тик синең

портының кайбер җитешмәгән яклары бар, минемчә, Пенкроф,— диде журналист.

— Нәрсә җитешми соң, мистер Спилет?

— Ярга менеп булмый, басып менәрдәй бер уентык та, чыгынтылар да юк. Стена кебек шоп-шома.

Чыннан да, култыкның каткан лавадан гыйбарәт текә шома ярына менү турында уйларлык та түгел иде. Крепость стеналары яки Норвегия фиордлары яры кебек текә иде алар, хәтта алардан да төксерәк иде. «Хәерле юл» стена буеннан ышкыла язып диярлек бара, әмма сәяхәтчеләр яр өстенә чыгарлык бер генә «баскыч» та очратмадылар.

Пенкроф, кирәк була калса, бу стенаны шартлатырга да мөмкин, дип үзен юатты. Инде монда күзәтер нәрсә калмавына ышангач, ул корабын чыгу юлына таба юнәлтте, һәм алар көндезге сәгать икеләр тирәсендә кабат ачык диңгезгә әйләнеп кайттылар.

Наб җиңел сулап җибәрде:

— Уф! Котылдык!

Алып акула авызында чакта аңа бик авыр булгандыр, күрәсең!

Казна борыныннан алып Рәхмәт елгасы тамагына хәтле күп дигәндә сигез миль ара булыр. «Хәерле юл», барлык җилкәннәрен киереп, ярдан бер миль чамасы читләтеп Гранит сарайга таба юнәлде. Суынган лава кантарларыннан гыйбарәт котсыз ярлар артта калды, күнегелгән ком көртләре башланды. Серле рәвештә исән калган инженерны теге чакта шушыннан тапканнар иде. Ком көртләре өстендә йөзәрләгән диңгез кошлары әйләнеп оча.

Төштән соң, сәгать дүртләр тирәсендә, кораб, Котылу утравын урап узгач, ике арадагы бугазга килеп керде, ә сәгать бишләр тирәсендә «Хәерле юл» якоре Рәхмәт елгасы тамагында су төбенә төшеп кадалды.

Сәяхәтчеләрнең өйдән чыгып китүенә өч тәүлек узды. Айртон аларны ярда көтеп тора иде, ә Юп абзыкай куанычыннан мышный-мышный каршыларына ук йөгереп килде.

Шулай итеп, сәяхәтчеләр утрауның бөтен яр буйларын тулаем тикшереп чыксалар да, шикләнерлек нәрсә тапмадылар. Әгәр утрауда нindidер серле зат яши икән, Борылмалы ярымутрауның кеше ерып чыккысыз куе урманнарында, әлегәчә тикшерелмәгән почмагында яшеренгәндер...

Гедеон Спилет белән инженер, үзара киңәшеп, әлеге серле хәлләр хакында, бигрәк тә иң аңлаешсыз соңгы вакыйга турында башка иптәшләренә дә әйтергә булдылар.

Яр буена яккан учак хакында сүз чыккач, Сайрес Смит түзмәде, журналисттан инде егерменче тапкырдыр:

— Ялгыш күрмәдегез микән сез? Вулкан авызыннан чыккан ут шәүләсе яисә атылган йолдызны учак ялкыны дип алданмадыгыз микән? — дип сорады.

— Юк, Сайрес,— дип җавап бирде журналист,— кеше яккан учак иде ул. Хәер, әнә Пенкроф белән Герберттан сорагыз. Утны алар да күрде, минем сүзне алар да расларлар.

Бу сөйләшүдән соң берничә көн үткәч, 25 нче апрельнең кичендә алар һәммәсе бергә Күзәтү яссылыгына барырга дип җыенгач, Сайрес Смит иптәшләренә мөрәҗәгать итте:

— Дусларым! Мин сезнең белән кайбер серле нәрсәләр хакында сөйләшергә телим, сезнең фикерне беләсем килә. Бу гайре табигый, могҗизалы хәлләр...

Төрепкәсен пыскытып торган җиреннән Пенкроф:

— Гайре табигый дисезме! — дип кычкырып җибәрде.— Алай булгач, безнең утрауны *гайре табигый* дип атарга мөмкинмени?

— Юк, Пенкроф. Әмма *серле* дип атарга мөмкин. Хәер, Спилет белән без аңламаган нәрсәләрне, бәлкем, сез аңлатып бирерсез.

— Сөйләгез соң, нәрсә бар, мистер Сайрес,— дип үтенде диңгезче.

— Тыңлагыз алайса! — дип сүзен дәвам иттерде Сайрес.— Мин диңгезгә батканнан соң ярдан чирек миль җирдә исән килеш табылдым һәм үзем мәгарәгә ничек килеп ятканлыгымны белмим. Сез шуны аңлатып бирә аласызмы?

— Исегезне җуйган булгансыздыр...— диде Пенкроф.

— Юк, алай булуы мөмкин түгел. Аннары, Топның мин яткан мәгарәдән биш миль ераклыктагы сезнең торакны ничек тапканлыгын аңлатып бирә аласызмы?

— Сизгерлеге аркасындадыр...— диде Герберт.

— Ничек сизгерлеге аркасында булсын,— дип бүлдерде аны журналист.— Ул төнне давыл котыра, яңгыр коеп ява иде, ә Топ Хәрабәгә пычракка-нигә буялмыйча, коп-коры килеш килеп керде.

— Дәвам итик,— диде инженер.— Дюгон белән көрәшкәндә баш җитмәслек нинди көч этне судан атып бәрде?

— Юк, аңлатып бирә алмыйм,— дип танырга мәҗбүр булды Пенкроф.— Дюгонның корсагын кем ярганын да аңлата алмыйм, ул пычак эзе иде бит...

— Дәвам итик,— диде инженер.— Теге дуңгыз баласы тәнендәге ядрәнең каян эләккәнен дә, һәлакәткә очраган берәр кораб эзләрен дә таба алмадык. Шулай ук безгә иң кирәкле әйберләр салынган әрҗәнең яр буена ничек килеп чыкканын да, беренче тапкыр диңгезгә сәяхәт вакытында эченә язу салынган шешәнең ничек итеп безнең кулга килеп эләккәнен дә, ниһаять, көймәбезнең ничек бавы өзелеп, нәкъ кирәк чакта гына аның Рәхмәт елгасы буйлап агып төшүен дә аңлату кыен; Гранит сарайны маймыллар яулап алганнан соң баскычны аска кем ташлаганын, һәм, ниһаять, Айртон мин язмадым дип баш тарткан язуны кем язганын аңлата аласызмы?

Сайрес Смит утрауда моңарчы кичергән серле вакыйгаларне, берсен дә онытмыйча, берәм-берәм санап чыкты. Герберт, Пенкроф һәм Наб, ни дип җавап бирергә дә белмичә, бер-берсенә аптырашып карап тора бирделәр. Әлеге серле вакыйгаләр, беренче тапкыр буларак, күз алдында үзара бер чылбырга тезелгән килеш килеп бастылар, һәм алар телсез калдылар.

Ниһаять, Пенкроф телгә килде:

— Валлаһи, сез дөрес әйтәсез, мистер Сайрес, боларны аңлатып бирүе читен!

— Менә тыңлагыз, әлеге санаганнарга тагын мин шундый ук гаҗәп һәм аңлаешсыз бер фактны өстим, дусларым.

— Нинди факт, мистер Сайрес? — дип кызыксынды Герберт.

— Пенкроф, сез Табор утравыннан кайтканда Линкольн утравында ялкынланып учак янганын күрдек дигән идегез, шулаймы?

— Әйе, шулай.

— Ут идеме соң ул, тәгаен әйтә аласызмы?

— Әлбәттә.

— Ә син, Герберт?

— Әйе, мистер Сайрес, ут беренчел зурлыктагы йолдыз кебек якты яна иде! — диде Герберт.

— Бәлкем, ул йолдыз булгандыр? — дип төпченә бирде инженер.

— Юк инде,— дип каршы төште Пенкроф.— Күк йөзен кап-кара болыт каплаган иде, аннары офык өстендә шундый түбәндә йолдыз буламы? Учакны мистер Спилет та күрде бит, безнең сүзнең дөреслеген ул да раслар!

— Шунысын да өстим, учак электр уты кебек бик якты яна иде,— диде журналист.

— Бик дөрес...— дип җөпләде Герберт.— Гранит сарай янындагы мәйданда яна иде.

— Алай булгач, тыңлагыз инде, дусларым, унтугызынчы октябрьдән егерменче октябрьгә каршы төнне ни мин, ни Наб яр буенда учак якмадык.

— Ничек инде!..— дип кычкырып җибәрде Пенкроф; гаҗәпләнүдән хәтта башлаган сүзен дә әйтеп бетерә алмады.

— Без Гранит сарайдан чыкмадык та,— дип җавап бирде Сайрес Смит.— Әгәр ул төнне яр буенда учак янган булса, аңа безнең катнашыбыз юк.

Пенкроф белән Герберт гаҗәпләнүдән тынсыз-авазсыз калдылар. Юк ла, ялгыш булуы мөмкин түгел. 19 нчы октябрьдән 20 нче октябрьгә каршы төнне алар яр өстендә учак янганын үз күзләре белән күрделәр бит.

Ярабби! Ышанмас җирдән ышанырсың: аларны ниндидер серләр чолгап алган лабаса! Линкольн утравы белән яшерен рәвештә идарә итүче ниндидер акыл ирешмәслек серле бер көч аларга мәрхәмәт күрсәтә һәм иң кирәк чагында ярдәм кулы суза. Ничек ачасы соң ул серне? Күңелләренең тынычлыгын алды бит бу! Ул серле зат утрауның кул тимәгән берәр почмагында яшеренмәде микән? Ничек кенә белергә соң моны!

Сайрес Смит Топ белән Юпның коридор түрендәге кое авызы тирәсендә үзләрен сәер тотуларын да хәтергә төшерде. Үзенең диңгезгә тоташкан коены тикшергәнлеген, ләкин шикләнердәй нәрсә тапмавын да яшермәде. Алар яз җитү белән бөтен утрауны актарып чыгарга карар иттеләр, сүзне шунда туктаттылар.

Шул көннән бирле Пенкроф уйчанланып китте, сагаюлы булып калды. Моңарчы ул утрауны үзләренең шәхси милке исәпли иде, ә хәзер аның тагын бер хуҗасы барлыгы беленде, алар, телиме-теләмиме, аңа буйсынырга мәҗбүрләр. Инде алар Наб белән еш кына икәүдән-икәү шул серләр хакында сөйләшәләр иде. Һәм, икесе дә диндар булганлыктан, утрауда илаһи көч барлыгына тәмам ышана яздылар.

Май ае җитте. Ул Төньяк ярымшарда ноябрь аена туры килә. Көннәр бозылды. Кышның рәхимсез суык булачагын сиздерде. Шуңа күрә аларга, кичекмәстән, кышка тырышыбрак әзерләнергә туры килде.

Хәер, аларның чатлама суык кышны чыгарлыклары бар иде. Җылы кием-салымнары җитәрлек. Муфлон көтүе хәзер ишәйде, тупас булса да, җылы тула басарга йоннары күп.

Айртонга да кышкы кием киерттеләр. Сайрес Смит аңа салкыннар башлангач та Гранит сарайга күчәргә киңәш итте. Гранит сарайда утарга караганда җылы да, уңайлы да иде. Айртон көзге эшләр бетү белән кайтырга вәгъдә бирде. Ул сүзендә торды: апрель уртасында ук күченеп кайтты. Шуннан бирле һәммәсе белән бергә яши башлады. Ул иптәшләренә ярдәмчел, үзен бик тыйнак тота, тик нигәдер һаман да бик басынкы, сагышлы йөри, иптәшләре шаярган-көлгәндә дә катнашмый иде.

Линкольн утравындагы өченче кышны алар өйдән чыкмый үткәрделәр диярлек. Тышта давыл, өермә котырына; көчле җил хәтта таш кыяны дер селкетә сыман иде. Тау-тау дулкыннар бөтен утрауны күмеп, басып китәрдәй булып тәгәрәп киләләр: әгәр ялгыш берәр кораб килеп чыгып, яр буена туктарга уйласа, һичшиксез, ул су асты кыяларына бәрелеп челпәрәм килер иде. Давыл вакытында Рәхмәт елгасы ике мәртәбә ярыннан ташып чыкты, бар күперләрне агызып китә язды. Ике тапкырында да су астында калган күперләрне соңыннан төзәтергә, ныгытырга туры килде.

Кар катыш яңгыр өермәләре Күзәтү яссылыгына да күп зыян китерде. Бигрәк тә җил тегермәне һәм кош кетәге зарарланды. Утрау хуҗалары аларны берничә тапкыр төзәтергә мәҗбүр булдылар.

Көчле давыллы көннәрдә азык эзләп яссытаулыкка ягуарлар һәм көтүе белән маймыллар килеп чыккалады. Елганы урыны белән боз тоткан, аны кичүе кыен түгел иде. Ерткычлар яшелчәлекне, иген басуларын, кош кетәген харап итмәгәйләре дип утрау хуҗалары курка калдылар, чакырылмаган кунакларны еш кына мылтыктан атып куып җибәрергә туры килгәләде. Әлбәттә, кешеләрнең моннан тыш мәшәкатьләре дә җитәрлек иде.

Кайвакыт, хәтта салкын көннәрдә дә, Үрдәк сазлыгына ауга баргаладылар. Топ белән Юп кошларны пырылдатып куып һавага күтәрәләр, Гедеон Спилет белән Герберт исә кыр үрдәкләрен, шөлдиләрне, чүрәкәйләрне,

тәкәрлекләрне, безкойрыкларны атып кына торалар, бер генә ядрә дә әрәм китми. Кош-корт ауларга бу тирәгә килеп йөрүе әллә ни кыен түгел, аучылар, Рәхмәт елгасы аша чыгып, Һава шары порты юлыннан яисә Табылдык борыны аша яр буеннан әйләнеп баралар; кыскасы, кайдан барсалар да, юл ике-өч мильдән дә артмый иде.

Кышның иң салкын дүрт ае — июнь, июль, август, сентябрь айлары — әнә шул мәшәкатьләр белән бер көе узып китте. Гомумән, Гранит сарай хуҗалары салкын кыштан әллә ни җәфа чикмәделәр. Һәртөрле давыл һәм өермәләрдән бер яктан Франклин тавы, икенче яктан урман белән капланган биек кыя яр ышыклап торган мал утарына зыян-җәбер бөтенләй дә тимәде. Эшсез тора алмаган Айртон, октябрьнең икенче яртысында берничә көн утарда торып, ватык-җимерекләрне берүзе генә төзәтеп кайтты.

Кыш буена да теге серле көч үзен сиздермәде. Гәрчә Пенкроф белән Герберт һәр вак-төякне серле нәрсәгә юрарга тырышсалар да, көчәнүләре бушка китә иде. Топ белән Юп та үзләрен тыныч тоталар, хәзер кое авызы тирәсендә бөтерелмиләр иде. Гайре табигый вакыйгаләр чылбыры гүя өзелде. Гранит сарай хуҗалары исә бу турыда кичләрен еш кына сүз кузгаталар һәм киләчәктә утрауның әле аяк басылмаган иң хәтәр почмакларын да актарып, йөреп чыгарга ниятлиләр иде. Әмма көтелмәгән бер вакыйга аркасында аларның бөтен планнары җимерелде.

Бу хәл октябрьдә булды. Яз житкән иде инде. Кояшның җылы нурлары табигатьне тергезеп җибәрде, урман авызында ылыслы агачлар куенындагы кычыткан, банксия, деодар куакларында яшел бәреләр ачылды.

Укучы хәтерлидер, Гедеон Спилет белән Герберт Линкольн утравын кат-кат фотога төшерергә яраталар иде.

17 нче октябрьдә, көн аяз булудан файдаланып, Герберт төштән соң сәгать өчләр тирәсендә Гранит сарай тәрәзәсеннән Казна борыныннан алып Тырнак борынына хәтле җәелеп яткан Берләшү бухтасын рәсемгә төшерергә булды.

Офык сызыгы ап-ачык беленеп ята. Талгын җилдән шадраланган диңгез өсте ерактан тымызык күл суы кебек кояш нурларында җем-җем итеп уйнаклый иде.

Герберт фотоаппаратын Гранит сарайның зур залы тәрәзәсе төбенә җайлап куйды. Биредән култыкның яр буйлары киң булып күренеп ята. Бөтен рәвешен китереп рәсемгә төшереп алгач, егет караңгы чоланга негативын эшләргә кереп китте.

Эшләп чыккач, негативны яктыга куеп карады һәм офык читендә бер кара нокта күреп алды.

«Бозылган пластинка туры килгән икән»,— дип уйлап куйды Герберт.

Күзәтү трубасының зурайткыч пыяласын алып, рәсем өстенә иелде.

Рәсемгә текәлеп карагач, «аһ!» дип куйды ул,— пыяланы кулыннан чак төшереп җибәрмәде.

Сайрес Смит эшләгән бүлмәгә йөгереп кереп, рәсем белән зурайткыч пыяланы аңа сузды да ноктага төртеп күрсәтте.

Сайрес Смит, рәсемдә каралып торган ноктаны күргәч, кулына күзәтү трубасы тотып, тәрәзә янына йөгереп килде.

Трубаны шикле нокта күренгән турыга юнәлтте. Текәлеп карап торгач, кулын аска төшерде дә:

— Кораб! — дип бер генә сүз әйтте.

Чыннан да, офыкта кораб күренә иде.

ӨЧЕНЧЕ КИСӘК

УТРАУНЫҢ СЕРЕ

Беренче бүлек

Офыкта кораб.— Айртонны чакырып кайтару.— Мөһим бәхәс.— «Дункан» түгел бу.— Шикле кораб.— Чарасын күрергә кирәк.— Кораб якынлаша.— Туптан ату.— Бриг якорь салып туктады.— Төн.

Һава шары егылып төшкәннән бирле ике ел ярым вакыт узды, ә Линкольн утравында яшәүче сәяхәтчеләрнең әле һаман кешеләр гомер иткән җирләр белән элемтәгә керә алганы юк иде. Бервакыт журналист үзләренең язмышын, хатка язып, канатлы хәбәрче артыннан җибәреп карады, әмма ул хат кешеләргә барып ирештемикән? Бик икеле. Шушы ике-өч ел эчендә аларның кечкенә биләмәсенә Айртон гына өстәлде.

Менә, көтмәгәндә-уйламаганда, 17 нче ноябрьдә мәңге буш диңгез киңлегендә кораб күренде!

Әйе, һич шик юк, офык читендә шәйләнгән кара нокта, әлбәттә, кораб иде. Утрау яныннан узып кына китәрме ул, әллә ярга якынлашырмы? Моны ике-өч сәгатьсез белеп булмый иде.

Сайрес Смит белән Герберт тиз генә Спилетны, Пенкроф белән Набны Гранит сарайның зур залына чакырып керттеләр. Әлеге яңалыкны аларга да җиткерделәр. Пенкроф күзәтү трубасын тартып алды да кабаланып офыкны күзәтә башлады һәм фотопластинкада беленер-беленмәс кенә тап күренгән турыда кара нокта барлыгына ышанды.

— Аһ, иблис кавеме! Кара син, кораб бит бу! — диде ул әллә ни шатланмыйча гына.

— Кая бара ул? Безгә таба киләме? — дип сорады Гедеон Спилет.

— Әйтүе кыен,— диде Пенкроф.— Офыкта әлегә мачта очлары гына күренә, гәүдәсе күмелгән.

— Нишлибез инде? — диде үсмер Герберт дулкынланып.

— Көтәбез,— диде Сайрес Смит.

Линкольн утравына килеп төшкәннән бирле аларның тормышында мондый да мөһим вакыйганең булганы юк иде әле; күңелләрендә купкан тойгылар давылына, курку катыш өмет ташкынына күмелеп, алар сәгать буе ләм-мим дәшмичә, тын гына басып тордылар.

Безнең дусларны кораблары баткач кешесез шәрә утрауга дулкын чыгарып ташлаган бәхетсез корбаннарга тиңләп булмый иде. Мескен корбаннар аяусыз табигать көчләренә каршы алны-ялны белмичә көрәшеп кенә үзләренә яшәү хокукы яулый алалар, шуңа күрә көнетөне илләренә кайту хыялында яналар. Ә безнең дусларга Линкольн утравын ташлап китәргә туры килсә, иң башта Наб кайгырыр иде; үзен монда иң бай, иң бәхетле кеше итеп сизгән Пенкроф та хәсрәтләнер иде. Алар икесе дә утраудагы яңача яшәү шартларына күнектеләр инде; үзләренең акыл көчен җигеп мәдәни дөньяга әверелдергән биләмәләрендә чын хуҗа булып яшиләр. Ә кораб — материктан хәбәр дигән сүз бит; ул, бәлкем, аларның туган илләреннән үк киләдер әле... Әнә ул һәр минут саен утрауга якынлаша бара. Кешеләр килә бит анда, кешеләр! Шулай булгач, корабтан күзен алмыйча карап торган безнең дусларның ничек йөрәкләре тетрәнмәсен!

Пенкроф, күзәтү трубасын кулына алып, әледән-әле тәрәзә янына бара, озаклап-озаклап корабны күзәтә, корабның хәзер утраудан егерме миль чамасы көнчыгыштанрак килүен шәйләргә мөмкин иде. Димәк, әле сигнал бирсәң дә күрмәячәк ул. Бәлкем, флаг күтәрергәдер? Тик барыбер флагны да күрә алмаслар; мылтыктан атсаң да ишетмәсләр; учак ягып карасаң да төтенен шәйләмәсләр...

Мәгәр күккә ашып торган Франклин тавы кораб мачтасыннан әйләнә-тирәне күзәтеп баручы сигналчы күзенә чалынмый калмаска тиеш иде. Әмма, күргән очракта да, кешесез буш утрауга кораб нигә дип туктасын икән? Тын океанның бу читенә ул очраклы рәвештә генә килеп чыкмагандыр дисеңме? Чөнки географик карталарда океанның бу тирәләрендә Табор утравыннан

кала бүтән җир юк; ул утрау да Яңа Зеландия һәм Америкага, Полинезия утрауларына йөрүче суднолар юлыннан шактый читтә урнашкан.

Утрау хуҗаларының күңелен әнә шундый сораулар борчый иде. Әмма беркем көтмәгәндә бу сорауларга Герберт җавап бирде дә куйды:

— Әгәр ул «Дункан» булса? — диде егет ашкынып.

Укучылар хәтерләсә кирәк: Айртонны Табор утравына төшереп калдырган лорд Гленарван яхтасы «Дункан» исемле иде, һәм ул, иртәме-соңмы, Айртонны алып китәргә тиеш иде. Ә Табор утравы Линкольн утравыннан ерак түгел; димәк, аңа юнәлгән кораб алаймы-булаймы Линкольн утравына күренми калмаска тиеш. Чөнки ике утрау арасы меридиан буенча фәкать йөз илле миль, ә параллель буенча җитмеш биш кенә миль.

— Моны бик тиз Айртонга хәбәр итәргә кирәк, аны җәһәт кенә Гранит сарайга кайтарырга кирәк,— диде Гедеон Спилет.— Корабның «Дункан»мы-түгелме икәнен ул гына әйтә алыр.

Журналистның киңәшен иптәшләре дә хуп күрде. Ул, Гранит сарай белән утар арасында хәбәрләшү өчен куелган телеграф аппараты янына килеп, Айртонга:

«Бик тиз кайтып җит», дип телеграм сукты.

Айртоннан шундук:

«Кайтам», дигән җавап алынды.

Утрау хуҗалары яңадан корабка текәлделәр.

— «Дункан» булса, Айртон аны шундук таный инде, үзе дә шушы яхтада йөзгән бит ул,— диде Герберт.

— Таныса, куанычыннан нишләргә дә белмәс инде бичара,— дип куйды Пенкроф.

Моны Сайрес Смит та җөпләде:

— Әйе шул. Айртон хәзер «Дункан»га бер дә тартынмыйча горур рәвештә аяк баса ала. Лорд Гленарван яхтасы гына булып чыксын иде, чын күңелдән шуны телим. Чөнки башка кораб бирегә изге ният белән килмәстер! Бу тирәләрнең яманаты тикмәгә таралмаган; мин боларны Малайя пиратлары булмагае дип шикләнәм.

— Юк, утравыбызга аларны аяк та бастырмыйбыз, сугышабыз! — диде Герберт.

Инженер, елмаеп:

— Әлбәттә, дускаем! Тик сугышырга туры килмәсен иде,— дип куйды.

Гедеон Спилет та кинәт:

— Карагыз әле,— диде.— Линкольн утравы иң соңгы географик карталарда да юк бит, аны диңгезчеләр белми. Әгәр кораб, билгесез яңа җир очратса, яныннан узып кына китмәс, аны карап-күреп чыгарга теләр. Шулай түгелме, Сайрес?

— Бик тә акыллы фикер,— диде Пенкроф.

— Мин дә килешәм,— диде инженер.— Хәтта ант итәргә була: кайсы гына капитан да, картада юк җир очратса, аны картага теркәп куярга, димәк, тикшереп чыгарга теләр. Безнең утрау исә — географларга билгесез җир. Менә шул.

— Ярый, шулай да булсын,— диде Пенкроф.— Судно бирегә килде ди. Утраудан берничә кабельтов җирдә якорь салып туктады ди. Шунда без нишлибез инде?

Маңгайга терәп бирелгән сорауга җавап ишетелмәде, барысы да тынып калдылар. Бераз уйланып торганнан соң, Сайрес Смит гадәттәгечә тыныч кына әйтеп куйды:

— Менә болай итик, дусларым: тотабыз да кораб белән элемтәгә керәбез. Һәм, утрауга Кушма Штатлар флагын кадап калдырып, Ватаныбызга кайтып китәбез. Ә аннары, бирегә күчеп утырырга теләүчеләрне алып килеп, утрауны колониягә әверелдерәбез. Тын океан уртасындагы бу яңа, игелекле җир кисәген Америка республикасына бүләк итәрбез.

Пенкроф «ура!» кычкырды.

— Ватаныбызга бездән менә дигән бүләк булачак бу. Утрауның барлык җирләрен диярлек үзләштердек инде, һәммә урыннарына исемнәр кушып чыктык, табигый гаване бар, эчә торган суы бар; бер дигән юллары, телеграфы, кораблар төзү урыны, хәтта тула басу фабрикасы да бар. Димәк, Линкольн утравын картага төшерергә генә кала!

Гедеон Спилет шикләнә куйды:

— Әгәр без кайтып киткән арада берәрсе безнең утрауга хуҗа булып алса?

— Булмый торсын! — дип янады Пенкроф.— Үзем монда калам да саклап торам. Пенкрофка ышана аласыз! Ачык авызлар кесәләреннән сәгать урлатса урлатыр; әмма миннән алай асат кына утрауны урлый алмаслар!

Тагын бер сәгать үтте. Тик судноның Линкольн утравына якынлашамы-юкмы, якынлашса, нинди тизлек белән якынлашканын һаман белерлек түгел иде әле.

Моны хәтта Пенкроф та әйтә алмады. Мәгәр, төньяк җиле искәнлектән, корабның уң галс белән килүен чамаларга була иде. Җил аны утрауга таба куалый; картада суның бу тирәләрдәге тирәнлеге күрсәтелмәсә дә, дулкынсыз, тыныч көнне яр буена курыкмыйча килергә мөмкин бит.

Төштән соң, сәгать дүртләрдә, чакыргач бер сәгатьтән соң, Айртон да Гранит сарайга кайтып житте.

Залга килеп кергәч:

— Ни бар, әфәнделәр? Мин әмерегезне үтәргә әзер,— диде.

Сайрес Смит аның белән гадәтенчә кул кысышып күреште дә:

— Айртон, көтелмәгән хәл килеп чыкты, шуңа күрә сезне чакырып кайтардык. Диңгездә кораб күренә! — диде.

Айртон агарынып китте, күзендә курку галәмәте чагылды. Ул ялт итеп тәрәзәгә борылды һәм офыкка төбәлде. Әмма берни күрмәде.

— Күзәтү трубасын алыгыз! — диде Гедеон Спилет.— Әйбәтләп карагыз әле, Айртон: ул, бәлкем, «Дункан»дыр, сезне илегезгә алып китәргә килгәндер?

— «Дункан»! — дип куйды Айртон үзалдына.— Шулай тизме!

Бу сүзләр аның авызыннан ихтыярсыздан ычкынды һәм ул, куллары белән башын тотып, тынып калды.

Кешесез утрауда унике ел буе япа-ялгызы яшәп тә, ул әле һаман гаебе акланган дип исәпләми микәнни? Гөнаһларыннан тәүбә иткәннән соң да, үзен кичермәде микәнни? Кешеләрнең аны гафу иткәнлекләренә ышанмый микәнни?

— Юк, юк, «Дункан» булмас,— дип мыгырдады ул.

— Әйбәтләбрәк карагыз әле, Айртон. Аларның кем икәнлеген алдан белеп тору безгә бик кирәк,— диде инженер.

Айртон, күзәтү трубасын алып, ул күрсәткән турыга юнәлтте. Беравык тын гына офыкны күзәтте.

— Әйе, сез хаклы: анда кораб күренә; тик «Дункан» түгелдер дип уйлыйм,— диде.

— Нигә «Дункан» булмасын? — дип сорады Гедеон Спилет.

— Чөнки «Дункан» — парга көйләнгән яхта, нихәтле карасам да, ни кораб өстендә, ни кораб артында төтен тасмасын күрә алмадым.

— Бәлки, ул җилкән белән киләдер? — диде Пенкроф.— Җил уңай искәндә нигә ташкүмер әрәм итсеннәр икән. Тирә-якта коры җир булмагач, ягулыкны кайдан алсыннар соң?

— Әйе шул, дөрес әйтәсездер, Пенкроф. Судноның учаклары сүнгән,— диде Айртон.— Ярга якыная төшсен әле, шунда тәгаен күрербез.

Айртон шулай диде дә залның аргы почмагына барып утырды һәм тынып калды. Хәтта серле кораб хакында иптәшләренең кайнар бәхәсенә дә катнашмады.

Бу вакыйга һәммәсенең күңелен кузгатканлыктан, берсе дә бүленгән эшен дәвам иттерә алмады. Гедеон Спилет белән Пенкроф, үзләренә урын таба алмыйча, гасабиланып, залда ишекле-түрле зур-зур атлап йөри бирделәр. Герберт исә ни булыр икән дип түземсезләнеп көтә. Бер Наб кына үзен гадәтенчә тыныч тота. Чөнки хуҗасы Сайрес Смит кайда, аның өчен туган иле дә шунда иде. Инженер тирән уйга чумган; дөресен әйткәндә, ул, корабның ярга туктавын теләүдән бигрәк, аның туктавыннан курка бугай.

Ә кораб ул арада утрауга тагын да якыная төште. Күзәтү трубасыннан карагач, аның гадәттә Тын океан пиратлары утырып йөри торган Малайя «прао»сы түгеллеген, бәлки ерак юлга йөрүче кораб икәнлеген аерырга мөмкин иде инде. Инженерның шомлы сизенүләре дөрескә чыкмастыр ахрысы: бу корабның Линкольн утравы тирәсенә килеп чыгуы яманга булмастыр, күрәсең. Пенкроф, билгесез корабны тагын бик дикъкатьләп күзәткәч, җиһазларына караганда, ул бриг булырга тиеш, марсель һәм брамсель җилкәннәрен кабартып, уң галс белән утрауга таба кыеклап якынлаша, диде. Айртон да диңгезченең сүзен җөпләде.

Әгәр кораб йөрешен әкренәйтмәсә, тиздән Тырнак борыны артына кереп күмеләчәк, чөнки ул көньяк-көнбатышка таба бара. Ул чагында Һава шары порты янындагы биек яр өстенә менеп кенә күзәтергә туры киләчәк. Ни үкенеч! Сәгать биш якынлашып килә, караңгы төшкәч, күзәтүе кыен булачак.

— Төнлә нишләрбез икән? — диде Гедеон Спилет.— Әллә учак ягып, корабтагыларга утрауда кеше барлыгын белгертик микән?

Журналистның соравына асат кына җавап биреп булмый иде. Сайрес Смитның шик-шөбһәләре һаман бетмәгән әле. Шулай да учак ягарга карар иттеләр. Югыйсә

корабның төнлә утрау яныннан узып китүе, бөтенләйгә күздән югалуы мөмкин иде. Линкольн утравы тирәсенә моннан соң бүтән кораб кайчан килеп чыга әле, һәм киләме-юкмы, әйтүе кыен. Кем белә, язмыш аларга тагын нинди көтелмәгән сынаулар әзерләгәндер?..

— Суднода кемнәр булуына карамастан, без утрауда кеше барлыгын аларга белгертергә тиешбез,— дип кабатлады журналист,— әгәр шушы бердәнбер форсатны да кулдан ычкындырсак, соңыннан гомергә үкенәчәкбез.

Болай хәл иттеләр: Наб белән Пенкроф, Һава шары портына барып, караңгы төшүгә, зур итеп учак ягалар, аның уты бриг экипажының игътибарын тартмыйча калмаячак, әлбәттә.

Наб белән Пенкроф Гранит сарайдан чыгарга җыенганнар гына иде, кинәт кораб юнәлешен үзгәртте дә туптуры утрауга, Берләшү бухтасына таба килә башлады. Бриг тиз йөрешле судно булса кирәк, чөнки тиз якынлаша иде.

Наб белән Пенкроф Гранит сарайда калдылар, ә Айртонга күзәтү трубасы биреп, корабның «Дункан»мы, түгелме икәнен тиз үк белергә куштылар, чөнки Шотландия яхтасы да бриг кебек җиһазландырылган иде. Кораб хәзер ярдан күп булса ун миль ераклыкта, димәк, Айртон аның ике мачтасы арасында трубасы бармы-юкмы — шуны әйтергә тиеш.

Әле караңгы төшеп җитмәгән, күзәтүе кыен түгел. Айртон күзәтү трубасын күзеннән читкә алды да кырт кистереп:

— Юк, «Дункан» түгел! «Дункан» булуы мөмкин түгел! — дип кабатлады.

Инде хәзер Пенкроф күзәтү трубасы белән корабны эзләп тапты һәм иптәшләренә бригның өч йөздән алып дүрт йөз тоннага хәтле су сыешлы, бик яхшы җиһазланган бер дигән шәп судно икәнлеген,— кыскасы, океаннарда йөзүче кораблар арасында иң кызу йөрешле судноларның берсе булуын әйтте. Ә кайсы милләтнеке икәнен әлегә тануы читен, диде.

— Флагштогында әләме җилферди, тик төсен аерып булмый,— дип өстәде.

— Хәер, тагын ярты сәгатьтән барысын да белербез,— диде журналист.— Кораб капитаны ярга туктарга ниятли. Димәк, бүгенме-иртәгәме без аның белән танышырбыз.

— Анысы шулаен шулай, сүз дә юк,— диде Пен-

крэф.— Тик кемнәр икән соң алар, алдан белеп торасы иде бит. Дөресен әйткәндә, флагын хәзер үк күрергә иде.

Журналист белән сөйләшкәндә дә Пенкроф күзен күзәтү трубасыннан алмады.

Көн сүрелеп бара, кояшның соңгы нурлары сүнү белән бергә җил дә тынды. Флагштокка эленгән әләм чүпрәк кисәге кебек салынып төште, фалга уралды, аның төсен аеру тагын да кыенлашты.

— Юк, бу Америка флагы түгел,— диде Пенкроф.— Англиянеке дә түгел. Англия флагының кызыл төсе ерактан ук күзгә ташланыр иде; Франция һәм Германия флагларына да охшамаган; русларның ак диңгез флагы да, Испаниянең сары флагы да түгел... Ул бер генә төсле... Океанның бу тирәләренә тагын кайсы ил флаглары килеп чыгуы мөмкин соң?.. Чилинекеме?.. Юк, ул өч төстән тора... Бразилиянекеме? Бразилиянеке — яшел... Әллә Япониянекеме? Ул сарылы-каралы... ә бу...

Шул вакыт кинәт җил исеп куйды һәм серле флагны җилфердәтеп җибәрде. Пенкроф шул мәлдә генә күзәтү трубасын күзеннән алып түбән төшергән иде, Айртон тиз генә аны диңгезче кулыннан тартып алды да күзенә китерде һәм, текәлеп карагач, дулкынланудан карлыгып киткән тавыш белән:

— Кара флаг! — дип кычкырып җибәрде.

Әйе, чыннан да корабның флагштогында кара әләм җилферди иде. Килмешәк корабтан шикләнергә тулы нигез бар икән шул!

Инженер дөрес сизенгән булып чыга! Димәк, бу пиратлар корабы! Димәк, ул Тын океанның көньягында, бу тирәләрдә юлбасарлык итә; бу киңлекләрдә талау белән аты чыккан Малайя «прао»ларының көндәше. Линкольн утравына ул нинди максат белән туктарга ниятли икән соң? Бәлкем, ул кешеләр игътибарыннан читтәге, беркем белмәгән җир кисәгенә таланган хәзинәсен яшерергә уйлыйдыр? Әллә кышкы давылларда кереп ышыкланырга тын гавань эзлиме? Дусларыбызның изге биләмәсе Тын океан пиратларының бозыклык оясына әверелер микәнни?

Һәркемнең күңеленә ихтыярсыздан әнә шундый уйлар килде. Кара флаг белән очрашуның хәерлегә түгеллеге көн кебек ачык иде. Кара флаг — пиратлар флагы! Теге чакта каторжаннарның явыз нияте гамәлгә ашса, «Дункан» мачтасына да шундый кара флаг менеп кунаклаган буласы иде!

Хәзер бер генә минутны да әрәм уздырырга ярамый иде.

— Дусларым, корабның утрауны ерактан гына карап узуы да ихтимал. Бәлкем, экипаж ярга төшмәс тә әле. Шулай дип өметләник булмаса. Әмма без утрауда үзебезнең барлыкны күрсәтергә тиеш түгелбез. Күзәтү яссылыгындагы җил тегермәне ерактан ук күзгә ташлана. Айртон белән Наб, хәзер үк анда барып, тегермән канатын алып куйсыннар, Гранит сарай тәрәзәләрен агач ботаклары белән томалыйк. Утларны сүндерик. Утрауда кеше барлыгын сиздерерлек бер генә эз дә калмасын! — диде инженер.

— Ә корабыбыз? — дип сорады Герберт.

— Зыян юк, ул күренми, Һава шары портында эчкәре яшеренгән. Башкисәрләр аны тапмас! — диде Пенкроф.

Вакытны сузмастан, һәммәсе инженерның боерыкларын үтәргә юнәлделәр. Наб белән Айртон яссытаулыкка киттеләр, кеше барлыгын сиздерерлек нәрсәләрне яшерергә керештеләр. Ул арада башкалар, Җакамар урманына барып, кочагы белән агач ботаклары, лианалар күтәреп кайттылар һәм Гранит сарайның ишек-тәрәзә уемнарын тыштан күренмәслек итеп капладылар, алар ерактан караганда үсеп утырган куакларга охшап калды. Көтмәгәндә һөҗүм булса дип, сугыш коралларын, дарыядрәләрне кул астына тезеп куйдылар.

Әзерлек эшләре беткәч, Сайрес Смит иптәшләренә мөрәҗәгать итте. Дулкынланудан аның тавышы калтырап чыкты:

— Дусларым! Әгәр дә ул кабахәт җаннар Линкольн утравына аяк басарга батырчылык итсәләр, без аларны лаеклы рәвештә каршыларбыз дип ышанырга кирәк, шулай бит?

Һәммәсе өчен журналист җавап бирде:

— Әйе, Сайрес! Утравыбыз өчен без аяусыз сугышачакбыз! Кирәк икән, башыбызны да шунда салырга әзербез!

Инженер иптәшләренә кулын сузды, барысы да аны кайнарланып кыстылар.

Фәкать Айртон гына бер почмакта дәшмичә басып тора бирде, иптәшләренә кушылмады. Бәлкем, ул, элек җинаятьче булганга, аның кулын кысарга үзен лаеклы түгел дип исәпләгәндер.

Сайрес Смит Айртонның күңел кичерешләрен аңлады, аның янына килде дә:

— Айртон, ә сез ни эшләргә уйлыйсыз? — дип сорады.

— Үз бурычымны үтәргә телим,— дип җавап бирде Айртон.

Шуннан соң ул тәрәзә янына, күзәтү урынына, барып басты да тәрәзәне каплаган ботаклар арасыннан диңгезгә текәлде.

Сәгать сигезенче ярты иде, егерме минутлап элек кенә кояш Гранит сарай артында офыкка төшеп күмелде, көнчыгыш якта күк йөзенә әкренләп караңгылык инде. Бриг һаман Берләшү бухтасына таба килә. Ара инде сигез мильдән дә ким калган иде. Ул хәзер нәкъ Күзәтү яссылыгы турысында, чөнки Тырнак борыны янында борылгач, су күтәрелеше агымына эләгеп, төньякка таба авышты. Дөресен әйткәндә, ул хәзер бухтада иде инде,— әгәр дә Тырнак борыныннан алып Казна борынына таба күзләмә генә туры сызык үткәрсәң, кораб эчтә, утрау ягында калачак.

Бриг бухта түренә керерме? Бухтага кергәч, якорь салып туктармы? Утраудагыларны әнә шулар борчый иде. Бәлкем, ул яр буйларын гына карап узар; кешесен ярга төшереп тормастан, үз юлы белән китеп барыр? Бу сорауга җавапны бер сәгатьтән соң гына белеп булачак. Әлегә сабыр гына көтәргә туры килә.

Мачтасында кара әләм җилфердәгән шомлы бригтан шикләнүен инженер яшерми дә. Үз көчләре белән ирешкән бөтен шушы тормышларына, гомуми эшкә, газиз биләмәләренә афәт алып килде микәнни бу бриг? Пиратлар (бригта диңгез юлбасарлары икәнлеген хәзер алар тәгаен беләләр иде инде) элек тә бу утрауга килеп йөрделәр микән әллә? Югыйсә, утрауга якынлашкач, алар нигә флаг күтәрерләр иде... Элек ярга төшкәннәр иде микәнни соң алар? Әгәр төшкән булсалар, кайбер серле хәлләрнең сәбәбе ачыклана ачыклануын. Утрауның тикшерелмәгән якларында аларның юлдашлары яшәми микән? Дусларына кушылу өчен аларның ярга төшүен генә көтеп торалармы әллә?

Сайрес Смит күңелен борчыган бу сорауларның берсенә дә җавап таба алмады; ул пират бригының биргә килүе хәерлегә түгеллеген, үзләренә хәвеф-хәтәр янавын гына чамалады.

Шуңа күрә ул үзе дә, иптәшләре дә соңгы сулышла-

рынача каршылык күрсәтергә ант иттеләр. Пиратларның саны ишлеме икән, утраудагыларның санынннан күпмегә артык икән, килмешәкләр әйбәт коралланганмы — беренче чиратта шуларны белергә кирәк иде! Әмма бригка ничек үтеп керергә соң?

Төн җитте. Яңа туган ай, кичке шәфәкъ белән бергә сүнеп, күк йөзеннән югалды. Утрау һәм диңгез деге кебек караңгылыкка чумды. Офыкны каплап алган капкара болыт аша бер генә яктылык нуры да үтеп чыга алмады. Җил тынды. Хәтта агач яфраклары да кыштырдамый иде. Ярга, иренеп кенә, тавышсыз-тынсыз дулкын кага. Караңгыда кораб күренми, анда ут кабызмадылар, утрауга якын килсә дә, аның кайда икәнен шәйләрлек түгел иде.

— Һәй, белмәссең дә әле, бәлкем, ул төнлә китеп тә барыр. Иртән каһәр төшкән бригның эзе дә калмас,— дип куйды Пенкроф.

Диңгезчегә җавап биргәндәй, диңгез өстендә кинәт гөлт итеп ялкын кабынды, артыннан ук дөп итеп туп аткан тавыш ишетелде.

Бриг якында гына икән, палубасында артиллериясе дә бар икән.

Ялкын кабынуы белән тавыш яңгыравы арасында алты секунд вакыт узды.

Димәк, бриг белән яр арасы ике чакрымнан узмый.

Шул мәлдә чылбыр шалтыраганы, дөбер-дөбер итеп кораб бортына бәрелә-сугыла суга шуып төшкәне ишетелде.

Кораб Гранит сарай каршысында гына якорь салып туктады.

Икенче бүлек

Киңәшмә.— Алдан сизену.— Айртонның тәкъдиме.— Тәкъдим кабул ителде.— Айртон белән Пенкроф Котылу утравында.— Норфолк каторжаннары.— Пиратларның планы.— Айртонның батырлыгы.— Кире кайту.— Илле кешегә каршы алтау.

Пиратларның максаты хакында хәзер инә очы хәтле дә шик калмады: алар утрау янында якорь салып туктадылар, иртәгә көймәгә утырып ярга чыгачаклар.

Сайрес Смит һәм аның иптәшләре сугышырга әзер иделәр; тик үз көчләренә нихәтле ышансалар да, саклану чараларын да онытмадылар.

Пиратлар, ярга чыккач, әгәр яр буйларын карау белән генә чикләнсәләр, эчкәре керүне кирәк тапмасалар, утрауда кеше яшәгәнлеген бәлки сизмәсләр дә. Кем белә, алар, бәлкем, Рәхмәт елгасыннан эчәргә су алу белән канәгатьләнерләр; елга тамагыннан бер миль ярым өстәрәк салынган күперне һәм Хәрабәдәге хуҗалык әйберләрен күрмәсләр дә.

Тик алар яхта мачтасына ни өчен кара флаг күтәрделәр икән соң? Нигә туптан аттылар? Масаю галәмәте генәдер бу, бүтән түгел. Әгәр дә үзләрен бүгенге көнпәи алып утрауның хуҗасы дип искәртүләре булмаса? Сайрес Смит хәзер бригның баштанаяк коралланган икәнен төшенде. Пиратларның тубына каршы Линкольн утравы хуҗалары нинди сугыш коралларыннан ата алалар соң? Бары тик мылтыклардан гына шул.

— Шулай да безнең янга үтеп керү асат булмаячак,— дип әйтте кисәтүле тавыш белән Сайрес Смит.— Элекке су юлын камышлар, үләннәр үсеп каплап китте, аны дошман таба алмаячак; димәк, Гранит сарайга керә алмаячаклар.

— Ә яшелчәлегебез, ашлык басуларыбыз, кош кетәге, утар, мастерскойларыбыз, бөтен байлыгыбыз нишләр? — дип кычкырып җибәрде Пенкроф. Хәтта ул аягы белән идәнгә тибеп куйды.— Алар ике-өч сәгать эчендә барысын таптап, изеп китәчәкләр бит.

— Изеп тә китәрләр, Пенкроф, бернишләр хәл юк, аларга комачауларга кулыбыздан килмәячәк,— дип җавап бирде Сайрес Смит.

— Алар күпме икән соң? Хикмәт шунда,— диде журналист.— Әгәр дистәдән артмасалар, без аларны җиңә алыр идек, әгәр кырыклап, иллеләп булсалар, аннан да артып китсәләр, ул чагында...

Кинәт шунда, инженер янына Айртон килеп сүз кушты:

— Мистер Смит, зинһар, миңа рөхсәт итегез әле...

— Нәрсәне, дускай?

— Бригка барып, экипажның күпме икәнен белеп килим.

Инженер кыюсыз гына каршы төште:

— Айртон, әҗәл белән уйнау бит бу,

— Ә нигә, булса ни, мистер Смит.

— Юк, монысы артык!

— Мин үз бурычымны гына үтәп калмаска, тиешеннән артыгын да эшләргә тиеш,— диде Айртон.

— Көймә белән бармакчы буласызмы? — дип кызыксынды Гедеон Спилет.

— Юк, мин йөзеп кенә барам. Көймә уза алмаган җирдән ялгыз кешегә үтүе җиңелрәк.

— Бригка хәтле бер мильдән дә артык икәнен беләсезме? — дип сорады Герберт.

— Мин әйбәт йөзәм, мистер Герберт.

— Тагын бер тапкыр кисәтәм, Айртон, әҗәл белән уйныйсыз бит,— диде инженер.

— Булса соң,— дип үз сүзеннән кайтмады Айртон.— Зинһар рөхсәт итегез, үтенеп сорыйм, мистер Смит. Кешелек абруемны аклар өчен, бәлкем, бердәнбер очрактыр бу.

Әгәр аның үтенечен кире какса, тәүбәгә килгән җинаятьченең хәтере калачагын аңлады инженер.

— Ярый, барыгыз, Айртон,— дип ризалык бирде.

— Мин сезнең белән барам,— дип тәкъдим итте кинәт Пенкроф.

— Әллә миңа ышанмыйсызмы? — диде Айртон һәм юаш кына өстәп куйды:— Ышанмассыз шул, үзем гаепле.

— Юк, юк, алай түгел,— дип ашыгып кире какты Сайрес Смит.— Юк, Айртон! Сез аны дөрес аңламадыгыз. Пенкроф сездән һич шикләнми.

— Әйе шул,— дип раслады Пенкроф.— Айртонны мин кечкенә утрауга хәтле озатып куймакчы идем. Кем белә, бәлкем, башкисәрләрнең берәрсе ярга чыккандыр инде; бер кеше барганчы, ике кеше әйбәтрәк бит, шау-шу куптарырга ирек бирмәбез. Мин, утрауда калып, Айртонны көтеп торырмын, ул бригка ялгызы барыр, чөнки үзе шулай тели бит.

Айртонга бригка барырга рөхсәт бирделәр, һәм ул юлга әзерләнә башлады. Аның нияте баш китәрлек кыю тоелса да, караңгы төн канатына сыенып уңышлы үтәп чыгачагын өмет итәргә мөмкин иде, Айртон судно янына йөзеп барырга, аның ватерштагына яки вант-путингына тотынып өскә менеп, экипажның ничә кешедән торуын, пиратларның максатын белергә тели иде.

Иптәшләре Айртонны һәм Пенкрофны ярга хәтле озатып куйдылар. Айртон, чишенеп, тәнен туң май белән ышкыды; үзегезгә мәгълүм, май тәнне салкыннан саклый. Кем белә, әллә салкын суда аңа сәгатьләр буе торырга туры килер.

Ә ул арада Пенкроф белән Наб көймәне алып килергә дип киттеләр. Көймә Рәхмәт елгасында йөз адымлап

өстәрәк бәйләп куелган бит; алар әйләнеп кайтканда, Айртон юлга чыгарга әзер иде инде.

Кемдер Айртонның җилкәсенә җылы одеал китереп япты, һәм иптәшләре чиратлашып аның кулын кысып хушлаштылар.

Пенкроф белән Айртон утырган көймә ярдан кузгалып китте.

Ике юлчыны тиздән караңгылык йотты — сәгать унберенче ярты иде инде. Иптәшләре батыр йөрәкле юлчыларны көтеп тору өчен Хәрабәгә таба киттеләр.

Көймә тиз генә бугаз суын йөзеп үтте дә кечкенә утрау янына килеп туктады. Айртон белән Пенкроф пиратларга тап була күрмәгәек дип бик сак кыландылар. Әмма утрауны бик игътибар белән күздән кичергәч, анда беркем юклыгына ышандылар. Кыя ярыкларына төнгә кунаклаган кошларны куркыта-куркыта, Айртон, Пенкроф белән бергә, кызу-кызу атлап утрауны кичеп чыкты да кисәк суга ташланды һәм корабка таба тавышсыз-тынсыз гына йөзеп китте: корабта яңарак кына ут кабыздылар, аның кайда икәнлеге күренеп тора иде.

Ә Пенкроф, яр буенда кыяга ышыкланып, иптәшенең кайтуын көтеп калды.

Айртон киң-киң селтәнеп колач сала-сала суны ярып бригка таба йөзә, су ике яктан аның гәүдәсе буйлап шуып уза да артта тын гына бергә килеп кушыла. Йөзүченең башы су өстеннән чак кына калкып күренә. Ул диңгездә уты чагылган корабның кара шәүләсеннән күзен алмый, күңелендә фәкать бер гамь: ни генә булмасын, иптәшләренә биргән сүзендә торырга — үз бурычын үтәргә тиеш ул! Корабта аны хәвеф-хәтәр сагалавы да, утрау тирәсенә акула килеп чыгу ихтималы да бик борчымый иде. Су агымы аны алга таба этәрде, яр шактый еракта калды инде.

Ярты сәгатьтән Айртон сиздерми генә корабка килеп тотынды. Бераз хәл җыйгач, якорь чылбырына ябышып өскә үрмәләде һәм судноның борынына исән-имин менеп җитте, анда матросларның берничә пар чалбары кибәргә эленгән иде. Айртон тиз генә шуларның берсен киеп алды да, җайлабрак урнашып, тирә-якка колак салды.

Бригтагылар йокламый иде әле. Кая ул йокы! Һәрьяктан сөйләшкән, җырлаган, көлешкән тавышлар ишетелеп тора. Кинәт Айртон әшәке сүгенү белән аралашкан өзек-төтек җөмләләргә игътибар итте.

— Шәп нәрсә кулга төшердек без, бриг наять булып чыкты!

— Әйбәт йөзә, «Житез» дип тикмәгә кушмаганнар!

— Бөтен Норфолк флоты арттан куса да житә алмаячак! Тотсыннар койрыкны!

— Яшәсен капитаныбыз!

— Яшәсен Боб Гарвей!

Әлеге сүзләрне ишеткәч Айртонның нинди хисләр кичергәнен күз алдына китерүе кыен булмастыр, чөнки Боб Гарвей Айртонның Австралиядәге элекке танышы, жинаятьче дусты, башкисәр моряк иде! Димәк, Боб Гарвей аларның бергәләп корган жинаятьчел уен тормышка ашырган! Норфолк утравы янында ул Сандвич утрауларының берсенә баручы, сугыш кирәк-яраклары, кораллар, инструментлар, жиһазлар төялгән бригны кулга төшергән икән. Аның элекке каторжаннардан, башкисәрләрдән, адәм актыкларыннан торган, хәзер пиратларга әверелгән бөтен шайкасы бригны яулап алып, Тын океан суларын айкап йөри башлаган. Корабларга һөжүм итә, кораб командасын кырып сала, явызлыкта хәтта Малайя пиратларын да уздырып жибәрә икән.

Лаякыл исерек каторжаннар кызып-кызып сөйләшәләр, берсен-берсе бүлдереп батырлыклары, егетлекләре белән мактанышалар иде. Аларның өзек-төтек сүзләреннән Айртон әнә шуларны аңлап алды:

«Житез»нең хәзерге экипажы тулысы белән Норфолктан качкан инглиз каторжаннардан тора икән.

Норфолкның нәрсә икәнен кыскача гына сезгә дә сөйләп бирик.

Австралиянең көнчыгышында көньяк киңлекнең 29°2′, көнчыгыш озынлыкның 165°42′ урнашкан, әйләнәсе егерме дүрт километрга тиң кечкенә генә утрау бар, шунда диңгез тигезлегеннән мең дә бер йөз фут биеклеге Питти тавы калкып тора. Әнә шул Норфолк утравы инде. Ул — Англия суды тарафыннан хөкемгә тартылган төзәлмәс жинаятьчеләрнең сөрген урыны. Утрауда жинаятьчеләрнең саны биш йөзгә житә, анда каты тәртип куелган, шуны бозучыга иң авыр жәза кулланыла, утрауны йөз илле солдат һәм губернатор карамагындагы йөз илле надзиратель саклый. Жир шарында бу хәтле түбәнлеккә төшкән кабахәт жаннар өере тупланган тагын берәр почмак бар микән?.. Кайвакыт каторжаннарның берәрсе, үтә сизгер каравылчыларны алдап (хәер, мондый очрак сирәк була), искәрмәстән берәр корабны яулап алалар да

Полинезия утрауларында талау белән шөгыльләнә башлыйлар.

Атаклы Боб Гарвей да үз шайкасы белән әнә шул кәсепкә керешкән. Заманында Айртон да юлбасарлык итәргә хыяллана иде Боб Гарвей Норфолк утравы янында якорьда торган «Җитез» бригын яулап алган; бандитлар кораб командасын кырып бетергәннәр; ул хәзер пиратлар корабына әверелгән. Кайчандыр ерак юлларга йөрүче кораб капитаны булган, ә хәзер яманаты чыккан пират Гарвей командалыгында каторжаннар инде бер елдан бирле Тын океан суларын айкап йөриләр, юлбасарлык итәләр икән!

Җинаятьчеләрнең күбесе корабның койрык өлешенә — ютка җыелганнар, ә берничәсе палубага таралган, гәп сугалар.

Исерекләрнең кычкырып-кычкырып бәхәсләшкәне, стакан чәкәшкәне ишетелә. Ул сөйләшүләрдән Айртон шуны төшенде: «Җитез» Линкольн утравы янына очраклы рәвештә генә килеп чыккан. Пиратларның утрауга аяк басканнары юк икән. Сайрес Смит алдан сизенгәнчә, капитан, картада булмаган билгесез җир кисәген күргәч, анда төшәргә, әгәр уңайлы бухта табылса, утрауда бриг өчен тукталу урыны ясарга ниятләгән.

Мачтага флаг күтәрү һәм туптан ату мактану галәмәте икән; хәрби корабларның әләм күтәреп, туптан залп бирүләренә охшатырга тырышалар, янәсе. Димәк, туптан ату сигнал түгел, һәм Линкольн утравы белән Норфолк качкыннары арасында бертөрле бәйләнеш тә юк икән.

Колониягә һәм аның кешеләренә хәвефле көннәр килде. Шик юк, Линкольн утравы бандитлар күңеленә хуш киләчәк,— чөнки анда эчәргә яраклы су, кораблар торырлык уңайлы бухта бар; утрауның табигый хәзинәләре өстенә колонистларның хезмәте белән булдырылган байлыклар һәм табигать тарафыннан барлыкка китерелгән ышанычлы крепость — Гранит сарай бар. Пиратлар бу тыныч почмакны бозыклык оясына әвереледерәчәкләр. Утрауда кешеләр яшәмәве, аның дингезчеләргә билгесез булуы юлбасарларга кулай гына. Алар берничә еллар буе биредә гамьсез-имин яши алачак. Шунысы да бәхәссез: Боб Гарвей шайкасы шаһитлар булуны өнәмәячәк, утрау хуҗаларын аяусыз кырып бетерәчәкләр. Сайрес Смит һәм аның иптәшләренә качып котылу, утрауның берәр почмагында яшеренеп тору өмете дә юк, чөнки пиратлар монда озакка төпләнергә уйлыйлар, хәтта

«Җитез» юлбасарлыкка чыгып киткәндә дә, берничә кешесен, мөгаен, утрауда калдырып торыр. Димәк, бер генә юл кала — сугышырга, башкисәрләрнең берсен дә аяп тормыйча кырып бетерергә, моның өчен бер генә чарадан да тартынмаска кирәк, чөнки бу адәм актыкларын юк итәргә теләсә нинди чара кулланса да гөнаһ түгел.

Айртонның башында әнә шундый уйлар кайнады, һәм Сайрес Смитның да шулай дип уйлавына шикләнмәде ул.

Ләкин пиратларга каршы көрәшкәндә уңышка ирешү һәм җиңү бригның ничек коралланган булуына һәм анда ничә кеше барлыгына бәйләнгән иде.

Айртон ничек булса да шушы мәгълүматларны белергә тели иде. Берәр сәгатьтән, палубада акыру-бакырулар, сүгенүләр тынгач, чамасыз эчелгән исерткечтән пиратларның яртысыннан артыгы аяктан егылып йоклап киткәч, ул һич икеләнмичә палубага аяк басты. Анда утлар сүнгән, караңгылык хөкем сөрә иде.

Ул ватерштаг буйлап алгы мачтага үрмәләде, аннан бакка керде. Тегендә дә монда аунап яткан каторжаннар арасыннан сак кына атлап бөтен корабны йөреп чыкты, «Җитез»нең сигез һәм ун кадаклы дүрт тубы барлыгын белде. Капмалап карагач, аларның казенник ярдәмендә корыла торган икәнлеген чамалады. Димәк, дошманның гаять зур җимергеч көчкә ия иң яңа төр туплары бар.

Айртон палубада йоклап яткан ун пират санады, кубрикларда йоклаучылар да шул чамадыр, әле артыграк та булмаса. Бая ишетеп калган сүзләрдән ул экипажның илле кешедән торганлыгын белгән иде. Линкольн утравының алты кешесенә каршы илле пират — бик күп бит бу! Әмма аның каравы Сайрес Смит Айртонның фидакярлеге аркасында дошманның көче күпме икәнен алдан белеп торачак һәм уйлап, сак хәрәкәт итәчәк.

Хәзер үк яр буена кире кайтып китәргә, иптәшләренә күргәннәрен сөйләп бирергә мөмкин иде инде, чөнки хәтәр разведканың максаты үтәлде, һәм Айртон «Җитез»дән төшеп китәргә дә җыенган иде.

Кинәт аның башына бер кыю фикер килде. Айртонның үз бурычымны үтәргә телим, дөресе, бурычым таләп иткәннән дә күбрәкне эшләргә телим дип әйтүе тикмәгә түгел иде. Ул үзен корбан итсә итәр, аның каравы утрауны һәм иптәшләрен коткарыр. Югыйсә, күреп тора: Сайрес Смит һәм аның иптәшләре яхшы коралланган илле

пиратны җиңә алмаячак, дошман барыбер өстенлекне алачак, алар Гранит сарайга бәреп керәчәкләр, яисә камап торып утраудагыларны ачтан кырып бетерәчәкләр. Айртон үзен тоткынлыктан коткарган иптәшләрен берәмберәм күңел күзе аша кичереп чыкты, алар аңа кешелек абруен кире кайтарырга, намуслы кеше булырга ярдәм иттеләр, шуңа күрә ул үзен иптәшләренә бар яктан да бурычлы саный иде. Ә пиратлар аларның һәммәсен аяусыз рәвештә кырып бетерәчәкләр, хезмәт җимешләрен юкка чыгарачаклар, утрауны юлбасарлар оясына әверелдерәчәкләр! Бу афәтнең төп гаеплесе кем дисезме? Айртон! Чөнки аның җинаятьче дусты, элекке фикердәше Боб Гарвей Айртонның теге чактагы ниятен тормышка ашырган бит. Күңеленә шушы фикер килгәч, Айртонның чәче үрә торды. Ул ничек тә бригны бөтен экипажы белән бергә шартлатырга ниятләде. Айртон үзе дә шунда шартласа шартлар, аның караве үз бурычын намуслы рәвештә үтәп һәлак булыр.

Айртон икеләнми иде инде. Корабның гадәттә койрык ягында дары саклана торган крюйт-камера урнашкан була, анда барып җитүе әллә ни кыен түгел. Пират судносында дары запасы күп булырга тиеш, аны күз ачып йомганчы шартлату өчен бер очкын җитә.

Айртон әкрен генә аскы палубага төште, анда кайсы кайда пиратлар аунап ята, аларны йокыдан бигрәк исерткеч егып салган. Грот-мачтада фонарь янып тора, аның әйләнәсенә сугыш кораллары тезеп куяр өчен тирәк корылган.

Айртон шуннан үзенә револьвер сайлап алды, аның корулы икәнен абайлады. Хәзер ул бригның көлен күккә очырачак. Ул тавыш-тынсыз гына корабның койрыгына таба елышты, анда ют астында крюйт-камера урнашкан булырга тиеш бит.

Әмма караңгылы-яктылы корабта алга баруы кыен иде, юл өстендә аркылы да торкылы пират гәүдәләре ауный; әледән-әле Айртон йоклап яткан бандитларга абына, тегеләре күзләрен ачып тормыйча гына сүгенеп җибәрәләр, хәтта төрткәләп алалар; Айртон, тынын кысып, урынында катып кала. Шулай да ул «Җитез»нең койрык өлешен аерып торган бүлемгә хәтле килеп җитә алды, кулы белән кармалап ишекне эзләп тапты, бу — крюйт-камера ишеге булырга тиеш иде.

Ишекне ватып керергә кирәк икән. Айртон, тавыш чыгармаска тырышып, эшкә кереште. Әмма асылма йозак-

ны каеруы асат булмады. Айртонның келәшчәдәй көчле кулларына йозак, ниһаять, биреште, ишек ачылып китте.

Нәкъ шул мәлдә кемнеңдер авыр кулы Айртонның иңбашына килеп ятты. Колак төбендә:

— Нәрсә кирәк сиңа монда, дускай? — дигән дорфа тавыш ишетелде. Әзмәвердәй бер кеше аның битен фонарь белән яктыртты.

Айртон ирексездән артка чигенде. Күзне камаштыргыч ут яктысында элеккe дусты Боб Гарвей чалынып китте, әмма Гарвей Айртонны танымады, чөнки аны күптән үлгәнгә саный иде.

Боб Гарвей Айртонның чалбар якасыннан эләктереп алды:

— Нәрсә кирәк сиңа монда? — дип кабатлады. Айртон, җавапсыз-нисез, пиратлар башлыгын читкә селтәп атты да крюйт-камерага ташланды. Дарылы мичкәгә револьвердан бер ядрә җибәрсә, барысы күккә очачак!..

— Егетләр, килегез! — дип акырып җибәрде Боб Гарвей.

Тавышка уянган ике-өч пират, сикереп торып, Айртонга ташландылар, аны аяктан егарга маташтылар. Әмма көчле Айртон алар кулыннан ычкына алды. Бер-бер артлы ике тапкыр револьвердан атты, ике җинаятьче идәнгә капланды; әмма Айртон үзе читкә тайпылырга өлгерә алмыйча калды, кемнеңдер пычагы кулбашын ярып җибәрде.

Айртон ниятен гамәлгә ашыра алмаячагын төшенде. Боб Гарвей крюйт-камера ишеген шапылдатып япты, пиратларның инде күбесе уянды, корабта ыгы-зыгы купты. Утрауга әйләнеп кайтыр, иптәшләре белән бер сафта торып сугышыр өчен Айртонга исән калырга кирәк иде. Тизрәк качарга!

Тик соң түгелме икән инде? Котылып булырына өмет аз иде. Әмма Айртон иптәшләре янына ничек тә кайтып җитәргә карар итте.

Револьверда дүрт патрон калды. Айртон тагын ике тапкыр атып җибәрде, әмма Боб Гарвейга дип төзәп атканы тимәде; яралаca да, җиңелчә яралагандыр. Айртон, бер мәлгә пиратларның артка чигенүләреннән файдаланып, палубага менә торган трапка ташланды. Фонарь яныннан йөгереп узышлый, револьвер сабы белән аны бәреп ватты, әйләнә-тирә караңгылыкка чумды, качарга җайлы булды.

Тавышка уянган пиратлар траптан төшә башладылар. Бишенче тапкыр атуында Айртон берсен баскычтан сгып төшерде, калганнары, корабта нинди хәл булганлыгын төшенмичә, як-якка сибелделәр. Бер-ике сикерүдә Айртон палубага менеп җитте, шунда якасыннан эләктергән бер пиратның битенә атып җибәрде, бу аның алтынчы, соңгы пулясы иде. Аннары фальшборт аша диңгезгә сикерде.

Алты-җиде сажин да йөзеп китәргә өлгермәгәндер, әйләнә-тирәсендә яңгыр кебек яуган ядрәләрдән су кайнап тора башлады.

Утрауда кыяга ышыкланып, Айртонның әйләнеп кайтуын көтеп торган Пенкроф, Хәрабәдә яшеренгән Сайрес Смит, журналист, Герберт, Наб, атышу тавышларын ишеткәч, ниләр генә кичермәделәр. Кулларына мылтык алып, яр буена таба йөгерделәр, дошманның һөҗүменә каршы торырга әзерләнделәр.

Алар яхшыны өмет тә итмәделәр; Айртон, пиратлар кулына төшеп, һәлак булгандыр; диңгез юлбасарлары төннән файдаланып яр буена чыгарга җыеналардыр дип уйладылар.

Ярты сәгать чамасы вакыт үтте. Ату тавышлары тынды, әмма ни Айртон, ни Пенкроф күренмәде. Пиратлар кечкенә утрауны яулап алдылар микәнни? Бәлкем, Айртон белән Пенкрофка хәзер үк ярдәм кирәктер? Ә ничек итеп ярдәм итәргә соң? Су күтәрелгән вакыт булганга, бугаз аша чыгарлык түгел. Көймә теге якта. Үзегез уйлап карагыз инде, Сайрес Смит белән аның иптәшләре ни газаплар кичермәделәр!

Ниһаять, төнге сәгать беренче яртыда ярга көймә килеп туктады, анда ике кеше утыра иде. Сайрес Смит һәм аның иптәшләре кулбашы җиңелчә яраланган Айртонны һәм сау-сәламәт Пенкрофны кочаклап алдылар. Анда калмыйча, шундук Хәрабәгә киттеләр. Айртон бригта ниләр булганын сөйләп бирде; бригны шартлатырга ниятләп тә, уңышсызлыкка таруын да яшереп тормады.

Иптәшләренең кулын кыса-кыса, ул сөйләвен дәвам иттерде. Хәлнең аеруча хәвефле икәнен әйтте. Пиратлар хәзер сагайдылар. Алар Линкольн утравында кеше барлыгын беләләр, шуңа күрә ярга яхшы коралланган, күп санлы отряд җибәрәчәкләр, беркемгә рәхим-шәфкать күрсәтмәячәкләр. Әгәр утраулылардан берәрсе пиратлар кулына төшә калса, бетте дигән сүз.

— Без үзебезне корбан итәргә әзер,— диде журналист.

— Әйдәгез, өйгә кайтыйк, дошманны уяу күзәтик,— диде инженер.

— Мистер Смит, без бу бәладән котыла алырбызмы, юкмы, ничек дип уйлыйсыз? — дип сорады диңгезче.

— Әлбәттә котылабыз, Пенкроф.

— Белмим шул! Иллегә каршы без алтау гына бит.

— Дөрес әйтәсез, без алтау... Әгәр дә тагын...

— Тагын дип кемне әйтәсез? — дип сорады Пенкроф.

Сайрес Смит сүзсез генә бармагы белән күккә ишарәләде.

Өченче бүлек

Томан тарала.— Инженерның әмере.— Өч җиргә сак куелды.— Айртон һәм Пенкроф.— Беренче шлюпка.— Тагын икәү — Кечкенә утрауда.— Алты пират ярга чыкты.— Бриг якорен күтәрә.— «Җитез»нең батареясы.— Өмет юк.— Көтелмәгән чишелеш.

Төнлә ул-бу сизелмәде. Әмма утрау хуҗалары ни булыр дип сагаеп көттеләр, күзәтү урыннннан, ягъни Хәрабәдән китмәделәр. Пиратлар да ярга чыгарга омтылмадылар бугай. Айртон артыннан атып калганнан соң, бүтән ату тавышы, шау-шу ишетелмәде; Линкольн утравы янында кораб торганлыгын хәтта сизәрлек тә түгел иде. Утраудагыларның көчле каршылык күрсәтүеннән шүрләп, бриг якорен күтәргәндер, китү ягын хәерлерәк санагандыр дип шикләнергә мөмкин иде.

Ә хәл бөтенләй бүтәнчә иде. Таңның беренче нурлары сызылуга, иртәнге томанга төренгән кораб шәүләсе күзгә чалынды. Бу «Җитез» иде.

— Дусларым, томан таралганчы, минемчә, менә мондый чаралар күрергә кирәк. Әлегә томан безне яшерә, пиратларның шиген кузгатмыйча, без хәрәкәт итә алабыз. Беренчедән, утрауда кеше күп яши, аның халкы дошманга каршы каты көрәшәчәк дигән фикер тудырырга кирәк. Шуңа күрә өч төркемгә бүленергә тәкъдим итәм: беренчесе Хәрабәдә калыр, икенчесе Рәхмәт елгасы тамагына юнәлер. Өченчесе, минемчә, кечкенә утрауда яшеренеп, пиратларга ярга чыгарга ирек бирмәсә, һич югында бераз тоткарласа шәп булыр. Безнең карамакта ике карабин, дүрт мылтык бар. Димәк, корал җитәрлек. Дары, ядрәләр артыгы белән. Дошманга каршы рәхимсез сугышачакбыз. Пиратларның мылтыгын-

нан, тупларыннан курыкмаска кирәк. Алар бу кыялар алдында көчсез. Без Гранит сарай тәрәзәсеннән атмагач, бригтагыларның аңа атарга башына килмәс, югыйсә торагыбызны җимереп ташларлар иде. Безгә бердәнбер нәрсәдән — кул сугышыннан сакланырга кирәк, чөнки бригның экипажы сан ягыннан күпкә өстен. Шуңа күрә, дошманның күзенә күренмәгән хәлдә, аларга ярга төшәргә ирек бирмәскә кирәк. Патроннарны җәлләмәскә! Бертуктаусыз атарга, төз атарга! Һәрберебез сигезәр, хәтта унар дошманны юк итәргә тиеш, һәм без моңа ирешербез!

Сайрес Смит ничек хәрәкәт итәргә икәнен тәфсилләп аңлатып бирде. Гүя сүз кан кою турында түгел, көндәлек эшләр хакында баргандай бик тыныч кына сөйләде. Иптәшләре аны бүлдермичә тыңлап тордылар. Дәшмәүләре — берсүзсез ризалык билгесе иде. Томан таралганчы, һәркем үзенә билгеләнгән сак урынына китәргә тиеш булды.

Наб белән Пенкроф, тиз генә Гранит сарайга кайтып, аннан җитәрлек кадәр дары, патроннар алып килделәр. Гедеон Спилет белән Айртон беренче дәрәҗә оста атучылар иде, алар бер мильгә хәтле ата торган карабин белән коралландылар. Калган дүрт мылтык Сайрес Смит, Наб, Пенкроф һәм Гербертка булды.

Хәзер сакларның ничек урнашуын карыйк.

Сайрес Смит белән Герберт Хәрабәдә калдылар. Яшеренгән җирдән алар Гранит сарай итәгендәге яр буеның байтак өлешен ут астында тота алалар иде.

Гедеон Спилет белән Наб Рәхмәт елгасының тамагында кыялар арасына яшеренделәр. Зур күперне һәм барлык кечкенә күперләрне күтәртеп куйдылар. Бу төркем дошманның бер генә шлюпкасын да ярга якын китермәскә һәм, булдыра алган хәтле, елганың каршы ярына чыгуына комачауларга тиеш иде.

Ә Пенкроф белән Айртон шул арада көймәне суга төшерделәр, бугаз суын кичеп чыгып, кечкенә утрауның икесе ике урында урнашырга тиеш булдылар. Утраудагыларның дүрт урыннан атуын күргәч, пиратлар утрауда кеше күплеген, аларның үз азатлыгын арзан сатмаячагын төшенерләр.

Әгәр пиратлар шулай да ярга чыга калсалар, яки тылдан урап артларына төшү куркынычы туса, Айртон белән Пенкроф шундук утрауга кире кайтырга һәм көрәшнең иң кискен җиренә барырга тиеш булдылар.

Сугышчан сак урыннарына таралыр алдыннан дуслар бер-берсенең кулын кысып ирләрчә хушлаштылар. Пенкроф Герберт улын кысып кочаклады, йөрәген телгәләгән кайгысын сиздермәскә тырышты.

Дуслар аерылышып киттеләр.

Сайрес Смит белән Герберт, журналист белән Наб тиздән кыя артына кереп күмелделәр. Айртон белән Пенкроф исә, биш минут эчендә бугаз суын көймә белән исән-сау ишеп чыгып, кечкенә утрауга төштеләр һәм аның көнчыгыш ягында кыялар артына кереп яшеренделәр.

Бригтагылар аларны күрмәде, хәер, сакчылар үзләре дә куе томан аша корабны чак шәйлиләр иде.

Иртәнге сәгать җиденче ярты иде.

Тиздән томан пәрдәсен ертып, корабның мачта башлары төртеп чыкты. Бераздан томан диңгез өстенә иңеп төште, һәм, җил чыгып, томанны кисәкләргә таркатып, еракка куып алып китте.

Аяз һавада аермачык күренгән «Җитез», борыны белән төньякка таба төбәлеп, сул янын утрауга каратып, ике якорь салган килеш тын гына тора иде. Сайрес Смит алдан исәпләгәнчә, бриг утраудан бер миль тирәсе ераклыкта иде.

Мачтасында дәһшәтле кара әләм җилферди.

Инженер, күзәтү трубасыннан карап, бриг батареясының дүрт тубын да күрде. Туп көпшәләре утрауга төбәлгән, гүя атарга боерык көтәләр.

«Җитез» әлегә тын тора. Палубасында егермеләп, әллә утызлап пират йөренә. Берничәсе ютта тора, икесе урта мачтаның салингына менеп атланганнар, күзәтү трубасы белән утрауны күзәтәләр.

Боб Гарвей һәм аның командасы кичә төнлә булган хәлне томанлы гына хәтерлиләр булса кирәк. Ниндидер ярым ялангач кеше крюйт-камера ишеген ватты; пиратлар аңа ташлангач, алты тапкыр атып, берсен үтерде, икесен җәрәхәтләде. Ул кешенең үзенә ни булды икән? Мылтыктан диңгезгә аткан ядрәләр аңа тигәнме? Әллә утрауга йөзеп чыга алганмы ул? Кайдан килеп чыккан булды икән ул? Корабта нәрсә эшләргә ниятләде икән? Боб Гарвей уйлаганча, чыннан да бригны шартлатмакчы булды микәнни? Кыскасы, бу хәлгә баш җитәрлек түгел иде. Качкын каторжаннар тик шунысын тәгаен төшенделәр: «Җитез» туктаган билгесез утрауда кешеләр яши, һәм аның азатлыгы өчен көрәшкә барлык халкы күтәреләчәк. Тик нигәдер яр буенда да, яссытау-

лыкта да беркем күренми әлегә. Бер җирдә дә кеше яши торган торак-фәлән күзгә чалынмый. Утрауның халкы утрау түренә качып китәргә өлгерде микәнни?

Пиратлар башлыгы Боб Гарвейның башына әнә шундый сораулар тулган. Сак кеше буларак, ул шайкасын төшерүдән алда, утрауны бик ныклап тикшерергә тели иде.

Сәгать ярым вакыт узды. Бригтагы пиратларның һөҗүм итәргә, яисә ярга кеше төшерергә исәпләре күренмәде. Боб Гарвей икеләнә бугай. Иң көчле зурайткыч трубадан караса да, ул кыя арасына яшеренгән сакчыларны күрә алмаячак, билгеле. Ә Гранит сарайның ишек-тәрәзәләрен каплаган яшел үсемлекләргә аның игътибар итүе дә икеле иде. Тоташ гранит стена эчендә, шундый биеклектә кеше торак коргандыр дип аның башына ничек килсен ди? Тырнак борыныннан алып Казна борынына хәтле сузылган Берләшү бухтасы ярының буеннан буена кеше яшәгәнлеген искәртердәй бер генә эз дә күренмәде.

Иртәнге сәгать сигезләр тирәсендә «Җитез»дә ниндидер хәрәкәт башланды. Матрослар бау ярдәмендә суга шлюпка төшерделәр. Җиде кеше шлюпкага кереп утырды. Җидесенең дә кулында мылтык. Берсе рульне тотты, дүртесе ишкәккә ябыштылар, икесе шлюпканың борынына утырды; мылтыкларын атарга әзер тоткан хәлдә, алга таба иелә төшеп, һәммәсе дикъкать белән утрауның яр буйларын күзәтергә керештеләр. Алар утрауны читтән генә күзәтергә ниятлиләр, ахрысы, әгәр ярга чыгарга исәпләсәләр, капитан күбрәк кеше җибәрер иде.

Салингка атланып, зурайткыч трубадан күзәткән пиратлар монда кечкенә утраучык барлыгын да, ике утрау арасын ярты миль чамасы бугаз аерып торганын да күргәннәрдер, әлбәттә. Шлюпканы күзәтеп торган Сайрес Смит шуны искәреп алды: пиратлар, саклану йөзеннән, бугазга керергә уйламыйлар, башта кечкенә утрауга туктамакчы булалар иде, күрәсең.

Пенкроф белән Айртон, һәркайсы үз сагында кыя артына яшеренгән җирдән, шлюпканың туп-туры аларга таба килүен күреп алдылар, аның мылтык төзәрлек җиргә якынлашуын көтеп тора башладылар.

Ишкәкчеләр, шлюпкага игътибар юнәлттермәс өчен, бик сак ишәләр, ишкәкләрен сирәк селтиләр. Шлюпка борынында утырган пиратларның берсе кулына лот тоткан. Рәхмәт елгасы агымының дәвамы булган фарватер-

ны белмәкче буладыр. Димәк, Боб Гарвей бригын ярга якын ук китерергә тели. Вантларга үрмәләгән утызлап пират шлюпканы күзәтәләр, ярга якынаер өчен су юлын хәтердә калдырырга тырышалар.

Кечкенә утрауга җитәргә ике кабельтов кала шлюпка туктады. Рульне тоткан пират, аягүрә басып, туктарга җайлы урын эзләргә кереште.

Кинәт ике тапкыр мылтык шартлады. Кыя ташлар өстендә ике төштә ак төтен таралды. Рульдәге пират белән кулына лот тоткан пират шлюпка төбенә капланып төштеләр. Айртон белән Пенкрофның пулялары берьюлы ике юлбасарның башына җитте.

Шулчак колак тондыргыч дөпелдәү тавышы ишетелде, бриг өстенә төтен баганасы чөелде, һәм Айртон белән Пенкроф яшеренгән кыя башына туп ядрәсе килеп тиде, тирә-якка таш ватыклары чәчелде, бәхетләре, сакчыларга ул тимәде.

Шлюпкадан ләгънәт яудырган, сүгенгән тавышлар ишетелде, әмма шлюпка юлын дәвам иттерде. Рульгә бүтән матрос килеп утырды, ишкәкчеләр ачу белән селтәнеп-селтәнеп ишәргә керештеләр.

Көткәннең киресе буларак, бригка таба йөзү урынына, шлюпка яр кырыйлап китте, ул кечкенә утрауның көньяк очыннан урап узарга ниятли бугай. Пиратлар, пулядан качып, кызу-кызу ишәләр.

Алар, ярга биш кабельтов каларак, ярым түгәрәк ясап борылдылар да елга тамагына таба юнәлделәр.

Ниятләре аңлашылды: утрау белән кечкенә утрау арасындагы бугаз суына кереп, кечкенә утраудагы засаданың артына төшмәкчеләр икән; кечкенә утраунын сакчылары ни хәтле күп булмасын, ике ут арасында — шлюпкадан яудырган пуля яңгыры белән бригтан очкан туп ядрәсе астында калачаклар. Хәлләре аяныч иде.

Шлюпка унбиш минутлап шул юнәлештә йөзеп барды. Су өстендә дә, һавада да тынлык хөкем сөрде, беркем аны бозарга ниятләми иде.

Гәрчә Айртон белән Пенкроф дошманның артка төшү ниятен аңласалар да, сак урыныннан китәргә җыенмадылар, моның сәбәпләре күп иде: беренчедән, һөҗүм итүчеләргә үзләрен сиздерүнең хаҗәте юк, чөнки «Җитез»дән күреп алып, аларны шундук бетерәчәкләр; икенчедән, алар елга тамагын саклаучы Наб белән Гедеон Спилетның һәм Хәрабәдә яшеренгән Сайрес Смит белән Гербертның шлюпканы уздырмавына ышаналар иде.

Беренче атышудан соң егерме минутлап узгач, шлюпка елга тамагына килеп җитәргә ике кабельтов чамасы калды. Гадәттәгечә, бу сәгатьтә су күтәрелә башлады, тар бугазда агым көчәйде. Агым шлюпканы елгага таба агызып алып китте, бик каты ишкәнгә күрә генә алар бугазның урталыгыннан бара алдылар. Шлюпка елга тамагына пуля барып җитәрлек якынлашкач, кинәт каршыдан җибәрелгән ике пуля ике пиратны егып салды: Наб белән Спилет төз атучылар шул.

Шундук бригтан ике ядрә очып чыкты, хыянәтчел төтен күренгән кыяга китереп бәрде, әмма кешеләргә тидерә алмады, кыя башларын гына кыеп китте.

Хәзер шлюпкада сугышырдай өч кеше калды. Шлюпканы көчле агым Сайрес Смит белән Герберт турысыннан атылган ук тизлеге белән агызып алып китте. Сакта торучылар, барыбер тидереп булмас дип, атудан тыелып калдылар: шлюпка бугаз суын узып чыккач, кечкенә утрауның төньяк очыннан борылды да фәкать ике ишкәк ярдәмендә бригка таба китеп барды.

Утрау сакчыларына әлегә зарланырлык сәбәп юк иде. Дошманның беренче адымы уңышсызлыкка очрады. Дүрт пират авыр яраланды, бәлкем үлүчеләре дә бардыр, ә утраунықыларның тырналган җире дә юк иде, аларның бер генә пулясы да әрәм китмәде. Әгәр дошман үз тактикасын үзгәртмәсә, яңадан ярга шлюпка җибәрсә, аларны берәм-берәм кырып бетерүе кыен булмаячак.

Инженер тәкъдим иткән маневр уңышлы булып чыкты. Пиратлар үзләре алдында яхшы коралланган күп санлы дошман икәнен һәм аны җиңүе ансат түгеллеген уйларга мәҗбүр булганнардыр.

Пират шлюпкасы, дулкын белән көрәшә-көрәшә, тик ярты сәгатьтән соң гына «Җитез»гә кайтып җитә алды. Ишкәкчеләр шлюпкадан яралы иптәшләрен күтәреп чыгаргач, бригтагылар акыра-бакыра сүгенделәр, ачудан өч-дүрт тапкыр туптан аттылар, тик утраудагыларга тидерә алмадылар.

Менә ярсып котырынган, кичәге әчүдән айнып та җитмәгән бер дистә пират, кабат шлюпкага утырып, ярга таба юнәлде. Аның артыннан суга икенче шлюпканы төшерделәр, анысына сигез кеше утырды. Беренчесе, кечкенә утраудагы дошманнарын бәреп чыгарырга ниятләп, шунда таба йөзгән арада, икенчесе Рәхмәт елгасы тамагына таба юнәлде.

Пенкроф белән Айртонның хәле мөшкел иде. Алар утрауга кире кайтырга кирәклеген төшенделәр.

Ләкин беренче көймәнең якынаюын көтеп тордылар да, икесе берьюлы төз атып, ишкәкчеләр арасында тагын чуалыш тудырдылар, аннары качкан җирдән чыгып, пулялар яңгыры астында утрауны җилдәй кичеп чыктылар да көймәгә атылып керделәр һәм, икенче шлюпка утрауның көньяк очына килеп җиткәнче, бугаз суы аша чыгып, Хәрабәгә кереп яшеренделәр.

Алар Сайрес Смит белән Герберт янына килеп җитүгә, пиратларның беренче шлюпкасы кечкенә утрауга туктады, пиратлар, сикерешеп төшеп, утрауның астынөскә китереп актарырга тотындылар.

Нәкъ шул вакытта икенче шлюпка Рәхмәт елгасы тамагына килеп җитте, һәм аларга ике мылтык берьюлы атып җибәрде. Гедеон Спилет белән Наб сигез пираттан икесенең башына җиттеләр; шлюпканы көчле агым агызып алып китеп, су асты кыясына китереп бәрде. Исән калган алты пират, мылтыкларын суга тидермәс өчен баш очына күтәреп, елганың уң як ярына чыктылар һәм, сакчылар күзеннән качып, тизрәк Табылдык борынына таба чаптылар, анда аларны пуля куып җитәрлек түгел иде инде.

Шулай итеп, кечкенә утрауда унике пират ярга чыкты, дөресе, икесе яралы иде, аның каравы, аларның көймәсе бар; ә утрауның үзендә алты пират, әмма алар Гранит сарай ягына чыга алмаячаклар, чөнки юлларында елга бар, күперләре күтәртеп куелган.

Пенкроф Хәрабәгә йөгереп кергән уңайга:

— Әлегә нык торабыз,— диде.— Мистер Сайрес, дөрес бит, нык торабыз бит? Әйеме?

— Минемчә, сугышның яңа фазасы башлана. Пиратларны ахмакка санау, күрәләтә җайсыз шартларда ярга яңа команда җибәрерләр дип уйлау акылсызлык булыр иде!

— Алар бугаз суын аркылы чыга алмаячак,— диде диңгезче.— Айртон белән Гедеон Спилетның кулында карабин, курыкмагыз, бер генә башкисәрне дә уздырмаслар. Карабинның бер мильдән дә еракка атканын беләбез бит!

— Анысы дөрес,— диде Герберт.— Тик ике карабин белән судноның батареясына каршы торып буламы соң?

— Бриг бугаз суына кермәде бит әле,— диде Пенкроф.

— Әгәр керә калса? — дип сорады Сайрес.

— Кермәс! Анда комга утыра ла ул, аннары беттеләр дигән сүз!

— Керер дә,— дип сүзгә кушылды Айртон.— Пиратлар су күтәрелгән вакытта кереп калырга тырышырлар, су кимегәндә комга утыруларына да исләре китмәс. Ул чагында аларның тупларына каршы тора алмаячакбыз.

— Аһ, иблис кавеме! — диде Пенкроф.— Карагыз әле, ул кабахәтләр якорь күтәрергә маташалар бугай!

— Гранит сарайга кереп яшереник мәллә? — диде Герберт.

— Бераз көтик әле,— диде Сайрес Смит.

— Ә Наб белән мистер Спилет нишләрләр? — дип куйды Пенкроф.

— Вакыты җиткәч, безнең янга килерләр. Әзер торыгыз, Айртон. Хәзер өмет сезнең карабинда һәм Спилетнекында.

Пенкроф дөрес искәргән! «Җитез» якорьда килеш борылып азаплана иде, ул утрауга якын килергә ниятли бугай. Су әле тагын сәгать ярым буе артачак, хәзер агымның көче кимеде, бригка маневр ясарга комачауламаячак. Әмма Пенкроф Айртонның бриг бугаз суына керергә курыкмас дигән сүзенә ышанып бетмәде.

Кечкенә утраудагы пиратлар исә ул арада бугаз читенә килеп җиттеләр. Алар мылтыклар белән генә коралланган, Хәрабәгә һәм елга тамагына яшеренгән колонистларга теләсәләр дә зыян китерә алмыйлар иде. Килмешәкләр дошманнарының еракка ата торган карабиннары барлыгын белмиләр әле, шуңа күрә курыкмыйча иркенләп утрауны карап йөриләр, яр буеннан батырланып, хәтта яшеренмичә дә, узып баралар.

Әмма аларның кикриге тиз шиңде. Кинәт Айртон белән Спилетның карабиннары берьюлы телгә килде: ике каторжан шундук җиргә капланды.

Кечкенә утраудагы дошман язып та аңлатып булмаслык көчле куркуга төште. Исән калган ун пират, әллә яраланган, әллә үлгән ике иптәшен дә алмыйча, кечкенә утрауның каршы ярына ташландылар, шлюпкага сикереп менделәр дә, кызу-кызу ишеп, бригка таба йөзеп киттеләр.

— Әһә, сигез кеше сафтан чыкты! — дип мактанып куйды Пенкроф.— Мистер Спилет белән Айртон оста аталар, каһәр, берсеннән-берсе һич калышырлык түгел.

— Әфәнделәр, хәл катлаулана: бриг якорен күтәрә,— диде Айртон, карабинын яңадан корып.

— Карагыз әле, чынлап та якорь күтәрәләр бит тегеләр!..— диде пошынып Пенкроф.

— Кузгалды!

Пиратларның бриг штурвалын чыкырдатып борганнары ишетелде. Беренче мәлдә «Җитез» якорьга таба тартылып куйды, аннары якорь урыныннан купкач, ярга таба килә башлады. Җил диңгез ягыннан исә иде. Судно стаксель һәм формарсель җилкәннәрен корды.

Елга тамагында һәм Хәрабәдә сакта торучылар, үзләренең барлыгын сиздермичә, бригның маневрын дулкынланып күзәттеләр. Хәл кыенлашты: дошман батареясы утрауга терәп диярлек атачак, ә утрау сакчылары аларга бер зыян да китерә алмаячак. Пиратларны утрауга якын китермәскә иде бит, нишләргә соң?

Сайрес Смит кыен хәлдән чыгу юлын эзләп баш ватса да, бер төрле дә чара уйлап таба алмады. Гранит сарайга кереп бикләнергә туры килер микәнни? Пиратлар аны камап алгач, атналар буена, айлар буена шунда түзеп тора алырлармы соң? Ризыклары шактый вакытка җитәр җитүен. Ярый, әйтик, бу план барып та чыксын, ди. Ә аннары нишләргә? Пиратлар барыбер утрауга хуҗа булачак бит, бөтен дөньяны астын-өскә китерәчәкләр, рәхәтләнеп хәкарәт итәчәкләр, ахырда барыбер Гранит сарайдагы әсирләрне җиңәчәкләр.

Хәер, Боб Гарвей бригны бугазга кертергә куркыр, утрауга туктатмас дигән бер өмет бар иде әле. Ул чакта судно утраудан ярты миль еракта булачак, аннан туп ядрәсе утрауга, аның кешеләренә әллә ни зур зыян китерә алмаячак.

Пенкроф һаман үз сүзен тукыды:

— Әгәр Боб Гарвей чын диңгезче булса, гомергә дә бригын хәтәр җиргә алып кермәс. Көн бозылса, дулкын купса, корабка ни буласын күз алдына китерәсезме соң, ә?

Ул арада бриг кечкенә утрауга якынлашты: пиратлар аның көньяк очына таба киләләр. Җил әкрен исә, су агымы күзгә күренеп азайды. Боб Гарвей корабын теләгән җиренә тоткарлыксыз илтә ала иде.

Бая разведкага җибәрелгән пиратлар шлюпкасы су юлын тапты, хәзер бриг кыю рәвештә алга бара. Аның ниятен төшенүе кыен түгел иде инде. Ул Хәрабә каршысында якорь салып туктаячак та шуннан торып утрауга туптан ата башлаячак.

Тиздән «Җитез» кечкенә утрауның көньяк очына җитте, бер мәшәкатьсез борылды да, кыек грот җилкәнен күтәреп, җилгә каршы китте һәм Рәхмәт елгасы турысына якынлашты.

— Аһ, юлбасарлар, тәки киләләр бит! — диде ачынып Пенкроф.

Журналист белән Наб елга тамагы янында яшеренгән урыннан китәргә вакыт җиткәнлеген төшенделәр, чөнки аннан корабка ату мәгънәсезлек кенә иде. Аяусыз көрәш башланган кыен мәлдә барысының бергә булуы хәерле иде. Гедеон Спилет белән Наб кыя артына кача-поса Хәрабәгә таба йөгерделәр, яңгыр урынына яуган пулялар аларга зарар китерә алмады, алар Сайрес Смит, Айртон, Пенкроф һәм Герберт янына килеп кушылдылар.

— Спилет! Наб! Яраланмадыгызмы? — дип сорады инженер.

— Юк, яраланмадык,— дип җавап бирде журналист.— Бераз сыдырып кына китте! Карагыз әле боларны, бәдбәхет бриг бугазга кереп маташа бит!

— Ул ун минуттан Гранит сарай каршысына килеп туктаячак! — диде Пенкроф.

— Хәзер нишлибез соң инде, Сайрес? — дип сорады Гедеон Спилет инженердан.

— Әле вакыт барында, пиратлар күргәнче, тизрәк Гранит сарайга кереп яшеренергә кирәк.

— Дөрес әйтәсез. Тик анда ябылып, без...

— Нишләргә икәнен анда күрербез,— диде инженер.

— Әйдәгез алайса, тизрәк!

— Мистер Сайрес, әгәр без Айртон белән монда калсак? — дип үтенде диңгезче.

— Нишләмәкче буласыз, Пенкроф? Безгә хәзер аерылырга ярамый,— дип риза булмады Сайрес Смит.

Вакытны әрәм итмәстән, барысы бергә Хәрабәдән чыктылар. Гранит стенаның маңгай кебек чыгып торган кәрнизе аларны «Җитез»нең палубасына җыелган пиратлар күзеннән яшерә иде. Кыя башларын җимереп, дөп тә дөп туп ата, бриг ярга якын ук килгән, ахрысы.

Күтәрткеч кәрзин янына йөгереп килеп, Гранит сарайга менү өчен берничә минут җитте. Анда, зур залда, кичәдән бирле Топ белән Юп ябылуда утыралар иде.

Ярый әле, вакытында килеп өлгерделәр! Яшел яфракларга күмелгән тәрәзәдән алар «Җитез»нең төтенгә уралган хәлдә бугазга кереп килүен күрделәр. Хәтта үзләре дә сизмәстән читкә тайчанып куйдылар, чөнки суд-

ноның дүрт тубы бертуктаусыз атып тора, Хәрабә белән Рәхмәт елгасы тамагына, бая сакчылар торган урыннарга, ядрә ява гына. Кыя башлары чәлпәрәмә килеп як-якка оча, залп биргән саен пиратлар «урра!» кычкыралар.

Шулай да утраудагылар Гранит сарай исән калыр дип өметләнәләр иде әле, чөнки Сайрес Смит киңәше белән, саклык йөзеннән, бая тәрәзәләрне яшеллек белән каплап өлгерделәр. Әмма кинәт ишекне җимереп коридорга ядрә очып керде.

— Ләгънәт яусын! — дип кычкырып җибәрде Пенкроф.— Кабахәт юлбасарлар безне күреп калдылар микәнни?

Бәлкем, пиратлар аларны күрмәгәндер дә, Боб Гарвей шоп-шома гранит стенада аерылып торган яшелләккә ул-бу булса дип кенә залп бирергә кирәк тапкандыр. Гранит сарайны икеләтә ярсып утка тоту башланды; тагын бер ядрә тиеп, тәрәзәдәге яшел ботакларны читкә алып очырды, һәм тәрәзә уемы ыржаеп ачылып калды.

Утрау хуҗаларының хәле өметсез иде инде. Аларның торагын дошман белеп алды. Утрау хуҗаларының исә дошман ядрәсенә каршы торырлык көчләре юк иде, тирә-якка бертуктаусыз сибелеп торган гранит кыйпылчыклардан яшеренерлек урын да калмады. Гранит сарайны ташлап чыгып, өстәге коридорга яшеренми чара юк иде инде. Кинәт шулчак көчле гөрселдәү тавышы тирә-якны дер селкетте, ачыргаланып кычкырган, акырган, бакырган авазлар ишетелде.

Сайрес Смит һәм аның иптәшләре тәрәзәгә ташландылар...

Моңарчы колак ишетмәгән, күз күрмәгән ниндидер көч су баганасы белән бергә бригны күккә чөйде дә, бриг шартлап урталай сынды һәм бата башлады, ун секундтан дулкын корабны бөтен юлбасарлары-ние белән бергә күмеп китте!

Дүртенче бүлек

Колонистлар яр буенда.— Айртон белән Пенкроф судагы әйберләрне коткаралар.— Иртән табын янында әңгәмә.— Пенкрофның фикере.— Бригны тикшерү.—Крюйт-камера исән.— Яңа хәзинәләр.— Соңгы калдыклар.— Тимер торба кисәге.

— Бриг шартлады! — дип кычкырып җибәрде Герберт.

— Күккә очтылар! Гүя Айртон крюйт-камерадагы

дарыга ут төрткән! — диде Пенкроф һәм Герберт белән Наб артыннан ишеккә ташланды.

Көтелмәгән тамашадан әле һаман аңына килә алмыйча басып торган Гедеон Спилет:

— Нәрсә булды соң бу? — дип сорады.

— Бу юлы инде барсын да белербез!..— диде инженер ашыгып.

— Нәрсәне белербез дисез?

— Анысы соңыннан, Спилет, соңыннан; әйдәгез тизрәк барып карыйк! Пиратларның көле күккә очты, шуңа сөеник.

Сайрес Смит, журналист белән Айртонны ияртеп, ярга ашыкты, анда аларны Пенкроф, Наб, Герберт көтеп торалар иде.

Диңгез бригны мачтасы-ние белән бергә йотты. Су баганасы аны өскә чөйгәннән соң янга аударды, кораб шул хәлендә төпкә китте,— күрәсең, аның ярылган төшеннән эченә су кереп тулгандыр. Бугазның бу тирәсендә суның тирәнлеге егерме футтан артмый, димәк, су кайтканда бриг судан калкып чыгарга тиеш иде.

Су өстендә кораб калдыклары йөзеп йөри — запас мачталар, рейлар, читлеге-ние белән тавыклар (бичара канатлы мәхлуклар тере иде әле), әрҗәләр, мичкәләр су басымы белән люктан өскә калыккандыр, күрәсең. Әмма палуба такталары, тышлык калайлары нишләптер күренми, шуңа күрә «Җитез»нең көтелмәгән һәлакәте тагын да серлерәк тоела иде.

Бриг ауган вакытта ике мачтасы палубадан берничә фут өстәнрәк сынган: штагларын, вантларын өзеп, җилкәннәре белән бергә су өстенә калкып чыкты; җилкәннәрнең кайберсе таралган, кайберләре агачларга уралган иде. Барлык шушы байлыкны су агымы диңгезгә агызып алып китсенме, безнең дуслар авыз ачып шуны карап торсыннармы?.. Юк, әлбәттә. Айртон белән Пенкроф, мачта сыныкларын яр буена яисә Котылу утравы кырыена тартып чыгарырга теләп, көймәгә таба йөгерделәр.

Ишкәкләргә тотынгач, Гедеон Спилет аларга:

— Елганың уң ярындагы алты пиратны оныттыгызмыни? — дип кычкырды.

Әйе шул, шлюпкалары су астындагы кыяга бәрелеп тишелгәч, Табылдык борынына таба йөгергән башкисәрләрне ул бик вакытында искә төшерде.

Һәммәсе Табылдык борынына таба борылып карадылар, ләкин анда качаклар күренмәде. Бригның һәлакә-

тенә шаһит булгач, алар утрауның эченә үк кереп качканнардыр, мөгаен.

— Алар белән соңыннан исәпләшербез әле, хәзер алардан мөһимрәк эшебез бар,— диде Сайрес Смит.— Дөрес, алар кораллы, ә кораллы бандитлардан бәла-каза гына көт. Тик алтыга каршы алты әллә ни куркыныч түгел, көчләр тигез дигән сүз.

Айртон белән Пенкроф көймәне ярдан этеп җибәрделәр, каерып-каерып ишкәнгә, көймә һәлакәт урынына таба кызу йөзеп китте.

Диңгез өсте тыныч, суның хәзер иң кубәйгән чагы, чөнки ике көн элек кенә яңа ай туды. Баткан бриг әле берәр сәгатьтән соң гына күренә башлаячак иде.

Пенкроф белән Айртон мачта һәм агач кисәкләрен аркан белән бәйләделәр дә, бер очын Гранит сарай итәгенә ярга ташладылар. Андагылар бергәләшеп аларны ярга тартып чыгардылар. Аннары су өстендә йөзеп йөргән башка әйберләрне: читлекләре белән тавыкларны, ниндидер мичкә, әрҗәләрне тотып алып, көймәгә төяп, ярга чыгара башладылар, әйберләрне мондагылар шундук Хәрабәгә ташый тордылар.

Корабл ватыклары белән бергә өскә берничә мәет калыкты. Айртон шулар арасыннан Боб Гарвейны таныды. Мәеткә төртеп күрсәтте дә, дулкынланып, Пенкрофка:

— Менә мин дә шуның ише идем, Пенкроф! — диде.

Аңа каршы Пенкроф ихтирам белән:

— Юк, хәзер сез бөтенләй башка кеше инде, безнең хөрмәтле Айртоныбыз! — диде.

Шунысы гаҗәп, мәетләр, нигәдер, аз иде. Барлыгы биш-алты мәет санадылар. Пиратлар мөгаен һәлакәтне сизмичә калганнардыр, корабтан сикерергә өлгермәгәннәрдер. Кораб янтавына ауганлыктан, күбесе борт җәтмәсенә уралып үлгәндер. Әйе, су агымы берничә мәетне диңгезгә агызып алып китте, утрау хуҗаларын күңелсез мәшәкатьтән коткарды, югыйсә аларны Линкольн утравының ерак почмагында җир куенына салырга туры килер иде.

Сайрес Смит һәм аның иптәшләре ике сәгать буе кораб калдыкларын ярга ташыдылар, мачталардан җилкәннәрне чишеп алдылар; бәхетләре, алар ертылмаган иде, җилкәннәрне ком өстенә киптерергә җәеп куйдылар. Эш белән мавыгып, сөйләшергә дә вакытлары булмады. Ә башларында очсыз-кырыйсыз уйлар кайный иде! Барлык җиһазлары, барлык әйберләре белән бергә

бриг — олы бер хәзинә иде. Һәр кораб, үзенә күрә, йөзеп йөрүче бөтен бер дөнья бит ул. Андагы күпләгән кирәкле әйберләр хисабына хәзер утрау хуҗаларының малмөлкәте тагын да ишәячәк. Кыскасы, диңгез яры буеннан табылган әрҗә вакыйгасе кебек хәл кабатланды, тик бу юлы аның күләме чагыштырмаслык зур иде.

Пенкроф әле хәтта үзалдына болай дип уйлап куйды: «Ә нигә баткан корабны өскә күтәрмәскә безгә? Әгәр бер генә урыннан ярылган булса, аны төзәтүе кыен булмас. Өч йөз-дүрт йөз тонна су сыешлы кораб — безнең «Хәерле юл» белән чагыштырганда чын гигант ул! Аңа утырып хет мең миль ераклыкка чыгып кит! Кая телисең, шунда бар! Сайрес, Айртон белән бергә безгә бу эшкә тотынырга кирәк булыр! Тырышлыгыбыз бушка китмәс дип уйлыйм!» Әгәр дә бригны йөзәрлек итеп төзәтә алсалар, туган илләренә кайту хыялы да чынга аша бит. Суның кимүен көтәргә кирәк. Судно корпусы өскә чыккач, әйбәтләп карарлар, төзәтеп булубулмавы шунда күренер.

Баткан кораб калдыкларын тотып бетереп, яр буена ышанычлы җиргә чыгарып куйгач, утрау хуҗалары туктап хәл җыярга, ашап алырга булдылар. Ачыгудан аяктан егылыр чиккә җиткәннәр иде инде. Бәхетләре, азык-төлек чоланы монда якында гына иде, Наб оста пешекче икәнлеген тагын бер тапкыр исбатлады. Табынны Хәрабә янында ачык һавада гына әзерләделәр. Укучылар үзләре дә сизәләрдер, ашаганда сүз фәкать әлеге көтелмәгән вакыйга хакында, утрау хуҗаларын котылгысыз үлемнән коткарган могҗиза турында барды.

— Чын могҗиза булды бу, валлаһи. Әйтерең бармы! — диде Пенкроф исе китеп.— Гранит сарайда безнең хәл харап иде бит инде. Нәкъ кирәк чагында башкисәрләрнең көле күккә очты!

— Карагыз әле, Пенкроф, ничек булды соң бу? Нәрсәдән шартлады икән ул? Сәбәбен күз алдына китерә аласызмы? — дип сорады журналист.

— Нишләп китермәскә! Юлбасарлар бригында хәрби корабтагы кебек тәртип бар дисезме! Пиратлар чын диңгезчемени алар. Крюйт-камера ишеген ачык калдырганнардыр... Бандитлар утрауга бертуктаусыз атып тордылар бит, берәр диванасы яисә ачык авызы аркасында күккә очуы озак дисезме?!

— Мистер Сайрес, карагыз әле, корабның җимерекләре бик аз бит, гаҗәп тоелмыймы сезгә? Корпусы гына

зарарланган, ахрысы. Шартлау тавышы да тоныкиде. Кораб шартламагандыр, нәрсәгәдер бәрелеп, баткан гынадыр, миңа шулай тоела,— диде Герберт.

— Син шуңа гаҗәпләнденме, дускаем? — дип сорады инженер.

— Бик, мистер Сайрес.

— Мин дә гаҗәпләнәм шул, Герберт. Бик гаҗәп. Бераз сабыр итик инде, дустым: су астыннан чыккач, күрербез, нинди хикмәт бар икән анда.

Пенкроф сүрән генә сорап куйды:

— Әллә сез «Җитез»не су асты кыясына бәрелеп баткан димәкче буласызмы, мистер Сайрес?

— Ә нигә батмасын? Су астында рифлар күп бит,— диде Наб.

— Ай-һай, Наб! Син, дустым, иң кирәген күрмәгәнсең. Мин бригны батарга бер минут кала күрдем: ул бик зур дулкын белән бергә өскә чөелде дә сул янтавына авып төште. Әгәр ул кыяга бәрелсә, юньле суднолар кебек, тыныч кына төпкә киткән булыр иде,— диде Пенкроф.

— «Җитез»не юньле судно димәкче буласызмы әллә, юньсез судно бит ул! — дип төрттереп куйды Наб.

— Күрербез, Пенкроф, күрербез, сабыр ит,— диде инженер.

— Күрербез анысы, сүзем юк. Тик башымны кисмәгә бирәм, бугазда су төбендә судно бәрелерлек кыя юк! Мистер Сайрес, кулыгызны күкрәгегезгә куеп әйтегез әле, бу вакыйгане бая нигә могҗиза дидегез?

Сайрес гүя бу сорауны ишетмәде.

— Батканмы, әллә шартлаганмы,— барыбер түгелме. Һәрхәлдә, бик вакытында төпкә китте, шунысына ризадыр бит сез, Пенкроф? — диде Гедеон Спилет.

— Риза булмаска ни. Хикмәт андамыни. Бу эшкә илаһи көчнең катнашы бармы-юкмы, шуны сорыйм бит мин мистер Смиттан.

— Әлегә үз фикеремне әйтмичә торам, ярыймы, Пенкроф,— диде инженер.

Пенкроф бу җаваптан канәгать түгел иде, әлбәттә. Ул бриг шартлаган дигән фикерендә калды, үз сүзеннән ваз кичәргә теләмәде. Су кимегән чакта ничәмә-ничә тапкыр аркылы чыгып йөргән, төбен вак ком каплаган бугазда беркем белмәгән су асты кыясы бар дип аны кем ышандыра алсын, гомергә дә ышандыра алмаячак. Җитмәсә кораб баткан чакта суның иң биек күтәрелгән

вакыты иде, төптә су азайгач та күренмәстәй риф булса да, судно аңа тимичә иркенләп уза алыр иде. Димәк, кораб рифка бәрелеп ватылмаган. Димәк, ул шартлап күккә очкан.

Дөресен әйткәндә, диңгезченең фикере ышандырырлык иде.

Сәгать икенче яртыларда утраудагылар, көймәгә утырып, кораб баткан җиргә киттеләр. Шунысы аяныч, корабның ике шлюпкасын да коткарып булмады; берсе, белгәнегезчә, Рәхмәт елгасы тамагында су асты кыясына бәрелеп тишелде, аны төзәтерлек түгел иде. Ә икенчесен бриг белән бергә упкын йотты. Ул бриг астында калып сытылгандыр, шуңа күрә өскә калыкмады, ахрысы.

Ул арада «Җитез»нең гәүдәсе судан күренә башлады. Баксаң, бриг янга авып кына калмаган, мачталар сынган, балластлары урыннан күчкән дә йөзтүбән әйләнгән. Күккә коточкыч зур су баганасы чөеп, судноны аударган көчле шартлауның нәтиҗәсе әнә шундый иде.

Утрау хуҗалары бриг корпусы тирәли йөреп карап чыктылар. Су киму дәвам итә иде әле, алар көтелмәгән һәлакәтнең сәбәбен белә алмасалар да, нәтиҗәсен үз күзләре белән күрделәр.

Корабның алгы өлешендә, төбенең ике ягында да коточкыч зур тишек иде, аның озынлыгы егерме фут чамасы булыр. Һәм аны мөгаен ямарлык та түгелдер. Бу урында кораб тышының агачы гына түгел, җиз тышлыгы да юкка чыккан икән; хәтта ник бер кадак, ник бер шөреп калсын. Әйе, «Җитез»нең борынынннан алып койрыгына хәтле бөтен тышлыгы буйдан-буйга купкан, яраксыз хәлгә килгән иде. Коточкыч зур көч фальшкильне алып аткан, киль үзе берничә җирдә кильсоннан ычкынган, буйдан-буйга ярылган.

— Аһ, иблис кавеме! Бу корабны төзәтүе асат булмас,— диде Пенкроф исе китеп.

— Дөресе, төзәтүе дә шикле әле! — диде Айртон.

— Әгәр ул шартлаган икән, шартлауның нәтиҗәсе нигә бик сәер соң? Карагыз әле, корабның өске ягына, палубасына бер зыян да килмәгән. Шартлаган булса, ул да күккә очарга тиеш иде бит! Тишелгән җирләренә күз салыгыз әле: тишегенең зурлыгына караганда, бриг су асты кыясына бәрелгән булырга тиеш; юк, шартламаган бу! — диде Гедеон Спилет.

— Бугазның төбендә рифлар юк дим бит! Бригны

теләсә нинди сәбәптән һәлак булды дисәгез диярсез, мин анысына риза, тик риф түгел! — диде Пенкроф.

— Әйдәгез әле, судно эченә кереп карыйк,— диде инженер.— Һәлакәтнең сәбәбен, бәлкем, шунда белербез.

Бу акыллы тәкъдимгә һәммәсе риза булды, аннары корабтагы әйберләрне дә барларга, коткарырдаен коткарырга кирәк иде.

Бригның эченә керүе әллә ни кыен булмады. Су әкренләп кими-кими бөтенләй чигенде, кораб эченә түбәнге палубадан керүе җайлырак иде, чөнки судно йөзтүбән капланган, ул өстә калган. Чуен балластлар төрле җирдән палубаны төртеп тишкән. Бриг корпусын чуарлаган ярык-тишекләрдән су агып ята иде.

Сайрес Смит һәм аның иптәшләре, кулларына балта алып, вата-җимерә юл ачып, палубага менделәр. Анда зурысыннан-кечесеннән әрҗәләр өелешкән. Су астында озак ятмагач, бәлкем әле эчендәге әйберләре дә бозылмагандыр?

Безнең дуслар башлап корабның йөген ышанычлы урынга ташырга булдылар. Су әле бернічә сәгатьтән соң гына күтәрелә башлаячак. Берсе дә вакытны әрәм итмәде. Айртон белән Пенкроф корпусның тишелгән җиренә әрҗәләрне, мичкәләрне төшерү өчен бау астылар. Әйберләрне көймәгә төяп шундук ярга чыгара бардылар. Кул астына ни эләксә, шуны рәттән чыгардылар, буш вакытта карарбыз әле, диделәр.

Инде хәзер үк бригның трюмындагы төрле-төрле кыйммәтле малны күргәч, куанырлык иде: хуҗалык кирәк-ярагы, өй җиһазлары, савыт-саба, төргәк-төргәк тукыма, эш кораллары, кыскасы, Полинезия утраулары белән сәүдә итә торган суднода гадәттә ниләр була, монда шулар иде. Әйберләрнең саны күп булмаса да, ишләре байтак иде.

Корабның эче дә, бигрәк тә алгы ягы коточкыч нык зарарланган иде: бүлемнәр, терәкләр бар да җимерелгән, гүя бриг эчендә гаять зур снаряд шартлаган. Утрау хуҗалары корабның борыныннан алып койрык өлешенә хәтле әрҗә һәм мичкәләр арасыннан тоткарлыксыз үтә алдылар. Әрҗә һәм мичкәләрне берәм-берәм чыгара бардылар. Әйберләр авыр булмаса да, теләсә ничек аунап яталар иде.

Дуслар корабның койрык өлешенә дә барып җиттеләр. Айртонның әйтүенә караганда, дары сакланган крюйт-камера шунда урнашкан булырга тиеш. Сайрес Смит

фикеренчә, алар шартламагандыр мөгаен, дары мичкәләре исән булырга тиеш иде. Ә суга ул тиз чыланмый, чөнки тимер мичкәдә саклана. Инженер дөрес уйлаган икән. Ядрә өемнәре арасында егермеләп тулы мичкә таптылар. Дары мичкәләре гадәттә эчтән бакыр белән каплатылган була. Аларны сак кына тотып крюйт-камерадан чыгардылар. Пенкроф «Җитез»нең дары шартлаудан һәлак булмавын үз күзе белән күрде. Корабның крюйт-камера урнашкан өлеше гомумән аз зарарланган иде.

— Нишлисең, андый хәлнең дә булуы мөмкин,— диде диңгезче, әмма шундук үҗәтләнеп өстәп куйды:— Ләкин безнең бугаз суы астында кыялар юк!

— Ул чагында сәбәбе нәрсә соң? — дип сорады Герберт.

— Белмим,— дип кырт кисте Пенкроф.— Мистер Сайрес та белми, беркем белми, һәм беркайчан беләчәк түгел.

Кораб эчен карау белән мавыгып, утрау хуҗалары берничә сәгать узып киткәнен, инде су күтәрелә башлаганын сизмичә дә калганнар иде. Эшне туктатырга туры килде. Хәер, бригны дулкын урыныннан кузгатып агызып китәр дип куркырга урын юк иде, ул комга тирән баткан, теләсә нинди якорьдан ныграк утыра.

Бриг эчендәге мал-мөлкәтне ташып бетерү өчен иконче тапкыр су кимегәнен тынычлап көтәргә мөмкин иде. Ә кораб үзе тәмам эштән чыккан, аны мөгаен төзәтеп булмаячактыр. Ком аска суырганчы, ичмасам тышлыгының кирәкле өлешләрен ашыгыч коткарып калырга кирәктер.

Кичке сәгать бишләр тирәсе иде. Утрау хуҗаларына бүген бик авырга туры килде. Көндезгене бик әйбәтләп ашагач, ару-талчыгудан көчкә аякта басып торуга карамастан, «Җитез»нең трюмыннан чыгарган әрҗәләрдәниләр барын белергә теләү вәсвәсәсен җиңә алмадылар.

Әрҗәләрнең күбесендә төрле кием-салым икән. Үзегез дә беләсез инде, аларны күргәч безнең дуслар куанычтан «ура!» кычкырдылар. Кием-салым дисеңме, төрле аяк киеме дисеңме, шул хәтле күп, бөтен утрау халкын ун кат киендерерлек иде.

— Һи-и, карагыз әле бу хәзинәне! Өстебезгә олавы белән ишелде бит. Кая куеп бетерербез инде бу хәтле байлыкны?— дип сөйләнде Пенкроф.

Яңа әйбер табылган саен диңгезче дәртләнеп «ура» кычкыра, ә табыш мул: шикәр камышыннан ясалган аракылы мичкә дисеңме, тәмәке каплары, төрле-төрле сугыш кораллары, мамык төргәкләре, авыл хуҗалыгы кораллары, капчык-капчык төрле үсемлек орлыклары, балта остасы, тимерче өчен кораллар, дисеңме — ниләр генә юк. Суда әз торганга берсе дә бозылмаган. Эх, моннан ике ел элек табылган булса бу байлык! Нишлисең, әле хәзер дә артык түгел! Уйлап табуга һәвәс, булдыклы дусларыбыз барлык әйберләрне үз кул көче белән булдырсалар да, бу хәзинәләргә урын табылачак, билгеле.

Гранит сарайның чоланнары иркен! Тик шул көнне үк әйберләрне анда ташып бетерә алмадылар. Утрауда «Җитез»нең алты пираты яши бит, аларны да истән чыгарырга ярамый иде. Ул явыз җаннардан сакланасы бар. Рәхмәт елгасының күперләре күтәрелгән күтәрелүен, әмма ул җинаятьчеләр елга-инешләрдән куркып торыр дисеңме? Алар хәзер соңгы чиккә җиткән, икеләтә явызланган бит.

Әлегә килмешәкләргә каршы чара күрүнең хаҗәтен тапмадылар. Нишләргә икәнен киләчәк күрсәтер тагын. Бүгенгә Хәрабә янына өеп куелган әрҗәләрне, капларны гына каравылларга кирәк дигән фикергә килделәр, төне буе алмашлап кизү торып чыктылар.

Төн тыныч узды. Пиратларның утрау кешеләренә һөҗүм итәргә батырлыгы җитмәде.

Гранит сарайны сакларга калган Юп абзый белән Топ та, ул-бу туса, шундук тавыш куптарган булырлар иде.

Соңгы өч көндә — унтугызынчы, егерменче, егерме беренче октябрьләрдә — утрау хуҗалары баш күтәрми эшләделәр, эшкә ярардай барлык нәрсәләрне — «Җитез»гә төялгән йөкне дә, аның үз җиһазларын да — барысын коткарып калырга тырыштылар. Су кимегән арада алар трюмны бушаттылар, ә су арта башлагач, шул йөкне ярга ташыдылар. Корабны ком көннән-көн аскарак суыра барса да, тышлыкның җиз табакларын кубарып бетерделәр диярлек. Айртон белән Пенкроф, су төбенә чумып, комга күмелгәнче дип, чылбыр, чуен кисәкләре ише авыр әйберләрне, хәтта дүрт тупны өскә менгерделәр һәм аларны, буш мичкәләргә бәйләп, яр читенә тарттырдылар.

Күргәнебезчә, дусларыбызның чоланнары, складлары гына түгел, арсеналы да баеды. Яңа хыяллар белән рух-

анган Пенкроф бугаз суына һәм елга тамагына керү юлын саклау өчен ярга туп куярга ниятли иде. Аларның хәзер дүрт тубы бар. Киләчәктә ул туплар Линкольн утравы тирәсенә килергә батырчылык иткән теләсә кайсы флотилияне, диңгезченең үз сүзләре белән әйткәндә, «Иң дәһшәтле флотилияне дә» качарга мәҗбүр итәчәк!

Ул арада бригның беригә яраксыз кабыргалары гына тырпаеп калды. Кинәт көннәр бозылды һәм бу эшне үзенчә тогәллләп тә куйды: Сайрес Смит бригны шартлатып, кисәкләрен ярга чыгарырга исәпләп торганда гына төньяк җиле исә башлады, диңгездә купкан дулкыннар инженерны кирәкмәгәнгә дары әрәм итүдән коткардылар.

Егерме өченче октябрьдән егерме дүртенче октябрьгә каршы төнне давыл бригның каркасын җимереп, кисәкләрен ярга чыгарып ташлады.

Сөйләп торуның кирәге булыр микән,— Сайрес Смит корабның кәгазьләрен эзләп, барлык шкафларны, әрҗәләрне берәмтекләп актарып чыкса да, бер генә документ та табылмады. Бригның элекке хуҗасы яки капитанның шәхесен таныклый торган барлык кәгазьләрне пиратлар юк иткәннәрдер күрәсең. «Җитез»нең тышында да кайсы порттан чыкканлыгын күрсәтүче язу калмаган, аның кайсы илнеке икәнен белүе читен иде. Аның алгы өлешенең төзелешенә карап, Айртон белән Пенкроф Англия верфендә эшләнгән икәнен генә исбатладылар.

Бригның һәлакәтеннән соң, дөресрәге, колонистларны үлемнән коткарган серле шартлаудан соң бер атна үткәч, хәтта суның иң кимегән чагында да, «Җитез»нең эзен табарлык түгел иде инде. Аның соңгы калдыкларын диңгез дулкыннары агызып алып китте. Бригның барлык йөге Гранит сарайның чоланнарына кереп урнашты.

Утызынчы октябрьдә диңгез яры буйлап барганда әгәр дә Наб шартлаудан калган калын гына түгәрәк торба ише тимер кисәге тапмаган булса, бригның көтелмәгән серле һәлакәте табышмакка әвереләсе иде. Бу тимер торба кәкрәеп киләгән, кырыйлары чәрдәкләнеп беткән иде.

Наб бу табылдыкны Хәрабәдәге мастерскойда иптәшләре белән бергә нидер эшләп азапланган инженерга алып кайтып күрсәтте.

Сайрес Смит, тимер кисәген төрлечә әйләндереп карагач, Пенкрофка борылды да:

— Дустым, «Җитез»не су асты кыясына бәрелмәде дигән фикердән кире кайтмадыгызмы әле? — дип сорады.

— Юк, кайтмадым,— дип җавап бирде диңгезче.— Үзегез дә беләсез лә, безнең бугазның суы астында кыялар юк.

Инженер Пенкрофка тимер торба кисәген сузды:

— Әгәр дә шушы тимер кисәгенә бәрелгән булса, ни диярсез?

Диңгезче гаҗәпләнеп:

— Шушы торбагамы? — дип ышанмыйча сорап куйды.

Сайрес Смит дусларына карады:

— Дусларым, исегездәме, батардан алда, бригны гаять зур су баганасы күккә чөйде?

— Исебездә, исебездә, мистер Сайрес! — дип ашыгып җавап бирде Герберт.

— Суның нигә күккә чөелгәнен беләсегез киләме? Менә карагыз, шушының аркасында ул,— дип инженер кулындагы тимер торба калдыгын сузды.

— Шушымы? — дип сорады Пенкроф.

— Әйе. Су асты минасының калдыгы бу.

Иптәшләре шаккатып, беравыздан:

— Мина калдыгы! — дип кычкырып җибәрделәр.

Пенкроф бирешергә теләмәде:

— Ул минаны кем куйган соң анда?

— Мин түгел! Әлегә шунысын гына әйтә алам,— дип җавап бирде Сайрес Смит.— Тик дәлиле күз алдыгызда: кемдер мина куйган. Аның коточкыч каты шартлавын үз күзегез белән күрдегез.

Бишенче бүлек

Инженерның фикере.— Пенкроф зур планнар кора.— Утрауны туплар саклый.— Туптан дүрт тапкыр аттылар.— Исән калган пиратлар турында әңгәмә.— Айртон икеләнә.— Сайрес Смит кешелекле карар кабул итә.— Пенкроф теләмичә генә сүзеннән чигенә.

Димәк, һәлакәтнең сәбәбе аңлашылды: су астында мина шартлаган. Сайрес Смит белеп әйтә иде, әлбәттә,— АКШның гражданнар сугышы вакытында аңа бу көчле коралны кулланырга туры килгәне бар иде. Эченә нитроглицерин, пикрин кислотасы тозлары һәм башка шартлагыч матдәләр тутырылган мина шартлаганда күккә гаять зур су баганасы чөелде һәм бриг ярылып, су төбе-

нә китте. Бригның корпусы бөтенләй яраксызга чыккан, аны су астыннан менгезеп, төзәтерлек түгел иде. Су асты минасы фрегат бронясын да балыкчы көймәсен тишкән кебек асат тишкәнне, кая инде бриг исән калсын!

Шартлауның сәбәбе мәгълүм булды... Тик бугаз суына мина каян килгән соң? Шунысы табышмак иде.

Сайрес Смит болай дип сүз башлады:

— Дусларым, утрауда ниндидер серле зат яшәвенә хәзер шик калмады. Ул, бәлкем, безнең кебек үк һәлакәткә очраган берәр бәхетсез корбандыр. Моны искә төшерүемнең сәбәбе шул: Айртонны соңгы ике ел эчендә утраудагы табышмаклы хәлләр белән таныштырмакчы булам. Безгә ничәмә-ничә тапкыр ярдәм кулы сузган ул күзгә күренмәс шәфкатьле кеше кемдер,— анысын әйтә алмыйм. Ул нинди максаттан чыгып безгә игелек күрсәтәдер һәм шәфкать иткән кешеләренә нигә күренәсе килмидер, анысын әлегә төшенеп җитмим, әмма тегеләйме-болаймы, ул безгә иң кирәк чагында ярдәм күрсәтте һәм ул ярдәм гаҗәеп кодрәткә ия кешенең генә кулыннан килерлек ярдәм иде. Без генә түгел, үз чиратында аңа Айртон да бурычлы. Чөнки ул күзгә күренмәс яклаучыбыз мине генә диңгез упкыныннан коткарып калмады, әнә бит Айртон хакында язулы шешәне бугаз суына китереп ташлаган, иптәшебезнең аянычлы язмышын безгә ирештергән дә иде. Шунысын да әйтик, бик мохтаҗ чакта иң кирәкле әйберләр салынган әрҗәне Табылдык борынына мөгаен ул ташлагандыр, аннары утрауны тапсыннар дип төнлә кыя башына учакны ул яккандыр, күрәсең. Дуңгыз баласы итеннән табылган ядрәне дә мылтыктан ул аткандыр мөгаен. Инде әнә юлбасарлар бригын юк иткән минаны да ул куйгандыр,— кыскасы, барлык аңлаешсыз, серле изгелекләре өчен без шушы яшерен шәфкать иясенә мәңге бурычлыбыз. Һәлакәткә очраган берәр бичарамы ул, яки бу утрауга сөргенгә сөрелгән берәр откынмы — кем генә булмасын, әгәр дә без аның изгелекләрен онытсак, яхшылык кадерен белмәүче адәм актыклары булыр идек. Без аңа мәңге бурычлы һәм иртәме-соңмы аның изгелегенә каршы изгелек эшләрбез дип өметләнәм.

— Әйе шул, дөрес әйтәсез, кадерле Сайрес,— диде Гедеон Спилет,— кайдадыр биредә утрауда гади кешегә хас булмаган кодрәткә ия серле зат яши һәм моңарчы шушы кодрәте белән безгә файда итә килде. Әгәр дә без илаһи көчнең барлыгына һәм безнең көндәлек тормы-

шыбызга катнашу мөмкинлегенә ышана торган булсак, бу билгесез затны илаһи көч дияр идек. Ул мөгаен Гранит сарайдагы кое аша яшерен рәвештә безнең барлык ният-максатларыбызны белеп торадыр. Беренче тапкыр корабыбызга утырып диңгезгә чыккан көнне теге серле шешәне диңгезгә ул ташлагандыр. Топны күл төбеннән өскә атып бәрүче дә, дюгонны пычак белән суючы да ул булгандыр. Сайрес, сезне диңгез упкыныннан коткаручы да улдыр һәм шунысын искәрдегезме, болар һәммәсе дә — гади кешенең кулыннан килерлек эш түгел. Әгәр чыннан да боларны ул эшләгән икән,— димәк ул ничектер табигатьнең сукыр көчләрен дә буйсындыра ала дигән сүз.

Журналистны тыңлап торган иптәшләре аның дәлилле фикер сөрешенә таң калдылар.

— Дөрес,— дип дәвам итте Сайрес Смит,— утрауда серле зат яшәгәнлегенә хәзер беребез дә шикләнми. Ул әлегә хәтле кешеләр ирешмәгән гаҗәеп кодрәткә ия. Анысы әлегә безгә табышмак... Әмма билгесез затның үзен тапкач, без анысының серенә дә төшенербез. Димәк, безгә бер мәсьәләне хәл итәргә кирәк: без ул мәрхәмәт иясенең киләчәктә дә яшерен калуына риза булабызмы, әллә аны ничек тә табарга тырышабызмы. Минем бу хакта сезнең фикерне беләсем килә, дусларым.

Башта Пенкроф җавап бирде:

— Минемчә, ул кем генә булмасын, шәп егет, мин аны җаным-тәнем белән ихтирам итәм.

— Анысы әйбәт,— диде Сайрес Смит,— тик сез минем соравыма җавап бирмәдегез, Пенкроф, мин әйткәнгә ризамы сез, юкмы?

Наб та сүзгә кушылды:

— Минемчә, без эзләсәк тә, эзләмәсәк тә — барыбер, үзе күренергә теләмәсә, без аны гомергә таба алмаячакбыз, хуҗам.

Пенкроф аның сүзен күтәреп алды:

— Әй акыллы әйттең, Наб, бик шәп әйттең,— диде.

— Мин дә Набның фикерен яклыйм, әмма аны эзләмәскә дигән сүз түгел бит әле бу. Ул серле шәхесне табабызмы, юкмы,— һәрхәлдә, аның алдында үз бурычыбыз үтәлгән булыр,— диде Гедеон Спилет.

Инженер Гербертка карады:

— Ә син ни дисең, дустым?

Герберт күзендә очкын кабынды:

— Аһ! Мин аңа башта сезне, аннары безнең һәммә-

безне коткарган өчен бик зур рәхмәт әйтер идем, мистер Сайрес!

— Әйбәт уйлагансың, улым! — дип хуплады егетне Пенкроф.— Мин дә, башкаларыбыз да сиңа кушылырга каршы түгел. Минем төпчену гадәтем юк-югын, үзегезгә мәгълүм, әмма ул баһадирны күрер өчен мин уң күземне бирергә дә әзер. Мин аны күз алдына болай китерәм: ул зур гәүдәле, көч-гайрәтле, мәһабәт чибәр кешедер; озын бөдрә сакалы күкрәгенә салынып тора, чәчләре җем-җем килә, үзе ак болыт өстенә менеп утырган да кулына зур гына шар тоткан.

Гедеон Спилет елмаеп дингезченең сүзен бүлдерде:

— Сез безгә аллаһе тәгаләнең үзен сурәтлидегез ләбаса.

— Бәхәсләшмим,— диде Пенкроф.— Нишлим соң, ул серле затның сурәте минем күз алдына әнә шундый кыяфәттә килә.

— Ә сезнең фикерегез ничек, Айртон? — дип сорады инженер.

— Мин ни диярга дә белмим, мистер Смит. Сез ничек дип хәл итсәгез дә дөрес, әйбәт булачак. Әгәр аны эзләргә мин дә катнашсын дисәгез, мин ике дә уйлап тормыйча сезгә кушылам.

— Бик зур рәхмәт, Айртон,— диде Сайрес Смит.— Әмма мин сездән туры җавап көтәм. Сез безнең кебек үк тулы хокуклы кеше; безгә тугрылыклы икәнегезне ничәмә-ничә тапкыр эш белән исбатладыгыз. Бүген мөһим карар кабул иткәндә сезнең фикерне дә беләсебез килә. Бу хәлләр турында нәрсә дип уйлыйсыз?

— Мистер Смит, без серле химаячебезне ничек тә табарга тиеш,— дип җавап бирде Айртон.— Бәлкем, ул ялгызлыктан газап чигәдер. Бәлкем, зур хәсрәте бардыр. Бәлкем, ул безнең ярдәм белән яңача яши башлар. Үзегез әйттегез бит әнә, мин аңа бурычлы дидегез. Табор утравына ул килгән, әлбәттә, бүтән беркем дә түгел; ул; анда газап чигүче мин бичараны ул тапкан, мине коткарырга кирәклеген сезгә ул хәбәр иткән. Димәк, аның аркасында мин намуслы кешегә әверелдем. Моны гомергә онытасым юк.

— Ярый, шулай итәрбез: эзләргә керешәбез. Тик моңа тиз тотынырга кирәк. Бөтен утрауны йөреп чыгарбыз, бер генә тишек-тошыгын да калдырмабыз. Әрсезлегебезне билгесез дустыбыз гафу итсен, без аны изге нияттән эзлибез.

Шуннан соңгы көннәрдә утрау хуҗалары тырышып кышка әзерләнделәр — терлекләргә печән чаптылар, иген уңышын җыеп алдылар. Кичектермәслек эшләрне бетергәч, эзләү сәяхәтенә чыгарга булдылар. Табор утравыннан алып кайтып утырткан яшелчәләр дә ул арада өлгереп җитте. Күп көч кергән яшелчә уңышын җыеп, чоланнарга ташып урнаштырырга туры килде. Бәхетләре, Гранит сарайда утрауның барлык байлыгын кертеп тутырырга урын җитәрлек иде. Табигать үзе төзегән ышанычлы чоланнарда утрау хуҗаларының барлык азыктөлеге әйбәт саклана иде, анда дүрт аяклы дошманнар да, ике аяклы дошманнар да керерлек түгел. Калын гранит стена аша дым да үтми. Гранит сарайның иң өстәге табигый мәгарәләрен дары белән шартлатып, кәйләләр белән чокып зурайткач, иркен келәт барлыкка килде. Азык-төлек, сугыш кирәк-яраклары, эш кораллары, савыт-сабалар, кыскасы, утрау хуҗаларының барлык мөл-мөлкәте шунда саклана хәзер.

Пират бригыннан алынган туплар саф корычтан коелган, бер дигәннәр. Пенкроф киңәше белән аларны, чыгырлар ярдәмендә Гранит сарайга менгезделәр; тәрәзә араларына тишекләр уйдылар, шул тишекләрдән ялтырап торган озын туп көпшәләре диңгезгә төбәлде. Кош очар биеклектән туплар Берләшү бухтасы сагына бастылар. Бу — Гибралтар бугазындагы сак кебек булды.

Линкольн утравына килеп чыгарга батырчылык иткән теләсә кем корабы хәзер шул туплар утына эләгәчәк иде.

Көннәрдән бер көнне Пенкроф:

— Мистер Сайрес, туплар урнаштыргач инде хәзер аларның ничек атуын да сынап карасак зарар итмәс иде, еракка аталар микән? — диде.

Бу — сигезенче ноябрь көне иде.

— Ни мәгънәсе булыр икән соң аның? — дип сорады инженер.

— Нигә булмасын, сынарга кирәк, әлбәттә! Югыйсә бу сөйкемле ядрәләрнең кая хәтле очуын без каян белик. Аллага шөкер, ядрә шактый күп җыелды.

— Сынап карыйк алайса,— диде инженер.— Тик сынау өчен генә дарыны әрәм итмик, пироксилин кулланыйк, пироксилиныбыз күп.

Журналистның да, Пенкроф кебек үк, Гранит сарай тупларының ничек атуын сынап карыйсы килә иде.

— Безнең туплар пироксилин шартлауга чыдармы соң? — дип сорады ул.

— Чыдар дип уйлыйм. Тик саграк эш итәргә туры килер,— дип өстәде инженер.

Сайрес Смит артиллерия остасы да иде. Тупларның яхшы икәнен ул бер карауда күрде. Туплар иң яхшы сыйфатлы корычтан коелган, бик тиз корыла ала, эре ядрә белән ата. Димәк, шактый еракка атарга тиеш. Үзегезгә мәгълүм, тупның ату ераклыгы ядрә траекториясенең озынлыгына бәйле, ә траекториянең озынлыгы исә снарядны атып җибәрү тизлегенә бәйле.

— Атып җибәрү тизлеге исә дарының күләменә бәйле,— дип аңлатты Сайрес Смит иптәшләренә.— Тупны койганда иң мөһиме — металлның сыйфаты, ягъни металл иң югары каршылык көченә ия булырга тиеш. Ә җир йөзендәге барлык металлар арасында иң ныгы — корыч. Шуңа күрә мин пироксилин газы киңәюенә генә безнең туплар чыдарга тиеш дип уйлыйм.

— Атып карагач, күренер! — диде Пенкроф.

Әйтеп торуның хаҗәте бар микән, дүрт туп та яхшы каралган, әйбәтләп чистартылган, ялтырап тора иде. Тупларны су астыннан күтәреп, ярга чыгарып бастыргач, Пенкроф вакытын да, көч-егәрен дә кызганмыйча, аларны сөртеп, майлап, ялтыратып куйды. Затворларын, йозакларын, зажимнарын чистартты. Хәзер алар кояшта ялык-йолык килеп тора иде. Американың хәрби фрегатына куелган орудиеләрмени!

Ул көнне утраудагылар барысы бергә җыелдылар (хәтта Топ белән Юп та читтә калмады). Бер-бер артлы атып карап, тупның дүртесен дә сынарга булдылар. Хәтерегездәдер, алда бер тапкыр искәрткән идек инде, пироксилинның шартлау көче гади дарыга караганда дүрт тапкыр артыграк дип. Тупларны пироксилин белән корганда шуны да истә тоттылар.

Пенкроф кабызгыч филтәнен шнурын кулына тотты, атарга әзерләнде.

Менә Сайрес Смит кулы белән ишарәләүгә, туп дөп итеп атып җибәрде. Диңгезгә төбәлгән ядрә Котылу утравы өстеннән очып узды да каядыр еракка китеп югалды. Аның нинди ераклыкка төшүен хәтта чамалап та өлгерә алмадылар.

Икенче тупны Табылдык борынының иң очына төзәделәр. Гранит сарайдан өч миль ераклыктагы кыя башы чәчрәп тирә-якка сибелде.

Бу юлы тупны Герберт төзәгән иде. Орудиедән беренче тапкыр атуында ук төз тидерүенә аның күңеле канат-

ланып китте. Аңардан да бигрәк, Пенкрофның башы күккә тиде. Тимәскә, аның улы бит ул! Кара, ничек төз ата, чын тупчымыни!

Берләшү бухтасының яры буйлап сузылган ком көртләренә төзәлгән өченче ядрә Гранит сарайдан дүрт миль ераклыкка очып барып төште дә рикошет ясап диңгезгә сикереп чумды, як-якка су көлтәләре чәелде.

Дүртенче тапкыр атарга әзерләнгәч, Сайрес Смит орудиенең күпме ераклыкка хәтле ата алу мөмкинлеген белергә теләп, пироксилинны артыграк салды. Туп шартласа-нитсә дип, иптәшләре читкәрәк китеп бастылар, филтәне озын шнур ярдәмендә кабыздылар.

Колак тондыргыч шартлау тавышы дөньяны дер селкетте, әмма туп бирешмәде, чыдады. Утрау хуҗалары тәрәзәгә килеп капландылар һәм ядрәнең Гранит сарайдан биш миль чамасы ераклыкта Казна борынындагы кыя очын кыеп китеп, Акула култыгы суына барып төшүен күрделәр.

Диңгезченең чиктән ашкан шатлык авазлары шартлау тавышын күмеп китә язды.

— Йә, мистер Сайрес, безнең батареяны ничек дисез соң? — диде ул.— Гранит сарайга хәзер Тын океанның хет барлык пиратлары җыелып килсен! Рәхим итсеннәр! Безнең рөхсәттән башка берәрсе ярга аяк басып карасын хәзер!

— Андый тәҗрибә ясарга туры килмәсен диген инде, Пенкроф,— диде инженер.

— Пиратлар дигәннән, утрауда качып йөргән теге алты башкисәрне нишләтәбез соң? Безнең урманнарда, кыр-болыннарда рәхәт чигеп йөрсеннәрмени? Ул пиратлар ягуар белән бер бит. Ягуарларга кулланган җәза хөкемен аларга да кулланырга кирәк,— диде Пенкроф һәм дустына карады:— Сез ничек дисез, Айртон?

Айртон җавап бирмәде. Сайрес Смит диңгезчене мондый саксыз сорау биргән өчен күңеленнән битәрләп куйды. Шулай да җавапны ул да түземсезләнеп көтте.

— Мин үзем дә шуларише ягуар идем, Пенкроф. Үз фикеремне әйтергә бу очракта хакым юк,— диде Айртон уңайсызланып һәм әкрен генә атлап бүлмәдән чыгып китте.

— Ах, ахмак, туң күчән түгел диген инде мине! — диде диңгезче ачынып.— Бичара Айртон! Фикерен генә беләсем килгән иде. Безнең кебек үк, ул да үз фикерен әйтергә хаклы бит.

— Дөрес әйтәсең, әлбәттә,— дип Гедеон Спилет та аны җөпләде.— Әмма Айртонны тыйнаклыгы өчен ихтирам итәргә кирәк. Ул әле һаман элекке хәлен онытып бетерә алмый.

— Ярый, мистер Спилет, моннан соң андый хата ясамам! Айртонны кыерсытканчы, телемне тешләп өзәрмен! Пиратлар хакындагы сүзгә кайтыйк. Минемчә, аларның бездән шәфкать көтәргә хаклары юк. Утрауны алардан тизрәк тазартырга кирәк.

— Сез чыннан да шулай уйлыйсызмы, Пенкроф? — дип сорады инженер.

— Әйе, шулай уйлыйм.

— Алай рәхимсез кылану кирәкмәстер, көтәргә кирәк. Алар моннан соң дошманлык кылырга батырчылык итмәсләр инде.

Пенкроф моның ише икеле-микеле кылануны белми иде:

— Моңарчы эшләгән дошманлыклары җитмәгәнмени сезгә?

— Кем белә, алар, бәлкем, үткән эшләренә үкенәләрдер инде, яхшы якка үзгәрергә телиләрдер...— диде Сайрес Смит.

Диңгезче җилкәсен сикертеп куйды.

— Алар үкенәдер дисезме? — диде ул шаккатып.

Герберт диңгезченең кулына кагылды.

— Пенкроф, Айртонны искә төшер! Ул намуслы кешегә әверелде бит.

Пенкроф берәм-берәм иптәшләренә күз йөртеп чыкты. Үзенең тәкъдиме мондый каршылыкка очрар дип ул гомергә дә уйламаган иде. Туры сүзле, кырыс кеше буларак, ул утрауга аяк баскан пиратлар белән кәнфитләнеп маташырга, Боб Гарвей койрыклары, «Җитез»нең юлбасар командасы белән килешү төзергә кирәк дигән фикерне кемдер алга сөрер дип үлгәндә дә уйламас иде. Башкисәр пиратларны ерткыч хайваннар дип саный иде ул; һич тә икеләнмичә, вөҗдан газабы кичермичә аларны кырып бетерергә кирәк дип ихлас күңелдән ышана иде.

— Карагыз әле боларны! Барысы да миңа каршы! Ул зимагурлар алдында кин күңелләләнеп маташкан буласызмы! Әйдә, сезнеңчә булсын. Тик карагыз аны, соңыннан үкенергә туры килмәсен.

— Безгә һөҗүм итәргә җыенганнары сизелми бит әле. Сак булырбыз,— диде Герберт.

Журналист моңа хәтле озак дәшми торган җиреннән

— Алай димә! Алар алтау бит, яхшы коралланган үзләре. Утрауның төрле төшендә аулак почмакларда сагалап торырлар да һәммәбезне берәм-берәм үтерсп бетерерләр һәм утрауны яулап алырлар,— диде.

— Нигә моңа хәтле алай эшләмәделәр соң? — дип сорады Герберт.— Чөнки андый максатлары юк. Аннары без дә алтау бит.

Иптәшләре нинди генә дәлил китерсә дә, Пенкрофны ышандыра алмадылар.

— Ярар, ярар! — диде ул.— Әйдә, ул әүлия nяләре үз дигәнчә йөри бирсеннәр, алар аркасында баш авырттырмыйк әле.

Наб та сүзгә кушылды:

— Юк ла инде, Пенкроф. Син андый ук явыз түгел бит, шулай күренергә генә тырышасың! Әгәр дә ул бәхетсез башларның берәрсе алдыңа килеп чыкса, атып үтерергә кулың күтәрелмәс иде әле...

— Ике дә уйлап тормыйча, котырган эт урынына атып үтерер идем,— дип Пенкроф кырт кисте.

— Пенкроф, моңарчы гел минем сүзгә күнә торган идегез бит. Бу юлы да миңа ышана аласызмы? — диде инженер.

Пенкроф барыбер үз фикереннән кайтмады.

— Ярый, бу юлы да мин сезгә буйсынам, мистер Смит.

— Бик шәп. Алайса көтәбез. Әгәр үзләре башлап һөҗүм итсә, тиешле җавабын бирербез.

Гәрчә Пенкроф мондый тактиканы хупламаса да, юньлегә илтмәячәге хакында кисәтсә дә, инженерның тәкъдименә барысы да күнделәр. Һәр секунд, һәр минут уяу булган хәлдә, хәзергә бер төрле чара кылмаска, көтәргә кирәк дип уйлаштылар. Линкольн утравы иркен, җире уңдырышлы. Әгәр дә теге килмешәкләрнең күңелендә инә очы хәтле изге иман калган икән, бәлкем, тәүбәгә килерләр. Гадел тормышка аяк басарлар, чөнки хәзерге шартларда аларга бердәнбер дөрес юл — намуслы көн итү иде. Һәрхәлдә, кешелеклелек саклау йөзеннән генә булса да, хәзергә көтәргә кирәк. Дөрес, утрау хуҗалары моннан соң үз белемнәрендә элекке кебек иркенләп йөри алмаслар инде. Моңарчы алар ерткыч җанварлардан гына сагаялар иде, хәзер ерткыч хайваннардан да явызрак үчле алты җинаятьче якынтирәдә генә йөриләрдер. Утрауда хәлләр хәтәргә әйләнде. Әгәр дә безнең батыр йөрәкле дуслар урынында

бүтән ихтыярсызрак кешеләр булса, күптән күңел тынычлыгын җуярлар иде. Гәрчә Пенкроф белән бәхәстә бүтәннәр үзләрен хаклы санасалар да, чынлыкта аларның хаклымы-түгелме икәнен киләчәк кенә хәл итә ала иде.

Алтынчы бүлек

Экспедиция планы.— Айртон утарда.— Һава шары портына бару.— Пенкроф икеләнә.— Утарга ашыгыч хәбәр җибәрәләр.— Айртоннан җавап юк.— Иртәгесен юлга чыгу.— Телеграф нигә тын тора.— Ату.

Безнең дуслар ул арада утрауны тулысынча йөреп чыгарга ниятләп, сәяхәткә әзерләнә башладылар. Алар уенча, бу беренче дәрәҗә мөһим эш иде, чөнки алар хәзер ике максатны күздә тоталар: беренчедән, серле һәм изге җан иясен табарга телиләр, аның утрауда яшәвенә хәзер берсе дә шикләнми иде инде; икенчедән, пиратларның язмышын беләселәре килә иде: алар кайда яшиләр икән, ни белән шөгыльләнәләр, алардан нинди явызлыклар көтәргә мөмкин?

Сайрес Смит озакламыйча юлга кузгалырга әмер биргән дә булыр иде, әмма сәяхәтнең берничә көнгә сузыласын истә тотып, төн кунарга тукталганда кирәкле әйберләрне төяр өчен арба җигеп чыгарга булдылар. Бәхетсезгә вакытсыз дигәндәй, онагрларның берсе бу арада аягын бирттергән, арбага җигәрлек түгел иде. Аны берничә көн ял иттерергә туры киләчәк. Шуңа күрә сәяхәтне ун көнгә, ягъни егерменче ноябрьгә хәтле кичектерергә булдылар. Бу географик киңлектәге ноябрь ае Төньяк ярымшардагы май аена туры килә иде. Табигатьтә яз тантана иткән чак. Кояш Козерог тропигы турысына менеп җитә, елның иң озын көннәре башлана. Кыскасы, экспедиция бик уңайлы вакытка туры килә. Хәтта теләгән максатларына ирешмәсәләр дә, табигатьнең күпме байлыкларын очратырлар, күпме яңалыклар күрерләр. Чөнки Сайрес Смитның уйлавынча, алар Ерак Көнбатыш урманнарын Борылмалы ярымутрау очына хәтле кичеп чыгарга җыеналар иде.

Экспедициягә хәтле соңгы ун көн эчендә утрау хуҗалары Күзәтү яссылыгындагы эшләрен бетерергә булдылар.

Айртон утарга китәргә җыенды, чөнки терлекләрне карарга кирәк иде. Ул анда ике көн торырга, терлекләр-

гә күбрәк итеп азык салып, Гранит сарайга әйләнеп кайтырга тиеш иде.

Юлга кузгалыр алдыннан Айртоннан Сайрес Смит, иптәшкә бирәрсен алмыйсызмы, хәзер утрауда ялгыз йөрүе хәтәр, дигәч, Айртон, мәшәкатьләнмәгез, эшләрне ялгызым да бетерә алырмын, пиратлар очраса да, курыкмыйм, дип кенә җавап бирде. Әгәр дә утарда һәм шул тирәләрдә бер-бер хәл сизсә, шундук Гранит сарайга телеграм җибәрәчәген әйтте.

Шулай итеп, Айртон 9 нчы ноябрьдә иртән, арбага онагр җигеп, утарга юнәлде, ике сәгатьтән: утарда ул-бу юк, иминлек дип телеграм сукты.

Шушы ике көн эчендә Сайрес Смит күптәнге хыялын тормышка ашырырга булды: ул Гранит сарайны һөҗүм итүдән саклау чарасын төгәлләп куярга тели иде. Моның өчен Грант күленең көньяк очындагы элекке су юлын кеше күзеннән яшерергә кирәк иде. Аны элек таш белән томалап, үләннәр, яфраклар белән каплаганнар иде инде. Хәзер инженер күл суын ике-өч сажень өскә күтәрергә, тишекне су астында калдырырга җыена иде.

Моның өчен күлдә: берсен Глицерин инеше тамагында, икенчесен Шарлавык тамагында — ике буа төзергә кирәк иде. Утрау хуҗалары кызып эшкә тотындылар: кыя җимерекләрен сылап ныгыттылар һәм тиздән киңлеге җиде-сигез фут, биеклеге өч фут чамасы ике буа әзер булды.

Эш бетүгә, күл суы артып, элекке су юлы аска күмелде, монда кайчандыр җир астына төшеп китә торган тишек булгандыр дип беркемнең дә башына килмәс иде.

Гранит сарайны су белән тәэмин итүче, күтәрткеч кәрзинне хәрәкәткә китерүче каналга кагылмадылар, әлбәттә; монысын әйтеп тормаска да була.

Хәзер, күтәрткеч кәрзинне өскә менгезеп куйгач, утрау хуҗалары крепость кебек нык, җайлы-рәхәт торакларында бер төрле һөҗүмнән дә курыкмыйча тыныч күңел белән иркенләп яши алалар иде.

Эшләрен тиз бетергәч, Пенкроф, Гедеон Спилет, Герберт Һава шары портына барып килергә булдылар, чөнки сәяхәткә чыгу көненә хәтле буш вакытлары калды. Диңгезчене «Хәерле юл»ны барып карыйсы килә иде, бухтаны пиратлар тапмадылар микән дип борчыла иде ул.

— Безнең теге әфәнделәр Берләшү бухтасының көньяк башында ярга чыкканнар иде бит, әгәр яр буйлап

китсәләр, портка чыкмадылармы икән дип куркам. Әгәр тапсалар, «Хәерле юл»ның бәясе сукыр бер тиенлек калмагандыр.

Пенкрофның шөбһәләнүе юкка түгел иде, аның һава шары портына барып килергә кирәк дигән теләгенә беркем дә каршы төшмәде.

Диңгезче һәм аның иптәшләре, кулларына мылтыклар тотып, 10 нчы ноябрь көнне төштән соң юлга кузгалдылар. Пенкроф, гамьсез күренергә тырышып, мылтыгының һәр көпшәсен икешәр патрон белән корды да әчке мәгънә белән башын кагып куйды. Аның бу ишарәсе юлыма берәрсе чыгып карасын, «ерткычмы ул, кешеме»— барыбер, минннән юньлелек көтмәсен дигәнне аңлата иде. Гедеон Спилет белән Герберт та кулларына мылтык алдылар, төштән соң сәгать өчләрдә алар Гранит сарайдан чыгып киттеләр.

Наб иптәшләрен Рәхмәт елгасы тугаена хәтле озата барды, алар елганың аргы ягына чыккач, күперне күтәртеп куйды. Сәяхәтчеләр әйләнеп кайткач, берәрсе мылтыктан атып хәбәр итәр, шунда Наб күперне төшерер, диештеләр.

Кечкенә отряд портка таба, ягъни утрауның көньяк яр буеннан китте. Өч ярым миль араны ике сәгать эчендә уздылар. Юлның урманлы ягын да, Үрдәк сазлыгы ягын да игътибар белән карый-карый бардылар, ләкин качкыннарның барлыгын искәртердәй бер төрле эз дә очратмадылар; утрау халкының күпме икәнлеген, ничек коралланганлыгын белмәгән пиратлар утрауның кеше ерып чыкмаслык берәр аулак почмагына кереп качканнардыр ахрысы.

Һава шары портына барып җиткәч, тар бухта суында якорь салган җирдә корабның тыныч кына торганын күреп, Пенкроф шатлыгыннан кычкырып җибәргәнен сизмичә дә калды. Хәер, табигать үзе бухтаны кеше күзеннән яшерү өчен бар тырышлыгын салган: тирәли биекбиек таш кыялар өеп куйган; ул диңгез ягыннан булсын, коры җирдән булсын, күренерлек түгел иде; анда ялгыш кына барып чыксаң яки яр буендагы кыялар башына үрмәләп менсәң генә бу табигый гаваньне табарга мөмкин иде.

Пенкроф җиңел сулап куйды:

— Теге караклар, димәк, монда килеп чыкмаганнар әле. Хәер, җирдән сөйрәлүче аның нише хәшәрәтләрнең башына тауга менәргә кирәк дигән уй киләме соң, биек

үлән арасына үрмәләп кереп посканнардыр әле. Ерак Көнбатыш урманына баргач, очратырбыз без аларны.

— Аллага шөкер, монда килмәгәннәр. Югыйсә безнең корабны тапсалар, аңа утырып сызган булырлар иде. Аннары Табор утравына ничек барыр идек? — диде Герберт.

— Әйе шул, безгә Айртонның кайда яшәгәнен әйтеп, Линкольн утравы координатларын күрсәтеп, хат язарга да Табор утравына илтеп кайтырга кирәк, әгәр Шотландия яхтасы килсә, табып укыр,— дип аның сүзенә кушылды журналист.

— Бәхетебез бар икән әле, кораб исән, әмер булуга юлга чыгарга әзер тора,— диде диңгезче.

— Сәяхәттән әйләнеп кайткач, Табор утравына барып килербез, Пенкроф. Хәер, әгәр дә серле затны тапсак, бәлкем, ул безгә Линкольн утравы хакында да, Табор утравы хакында да яңа хәбәрләр сөйли алыр. Онытмагансыздыр, шешәдәге язуны ул язган бит, яхтаның кайчан килергә тиешлеген дә беләдер әле, бәлкем.

— Аһ шайтан! Кем икән соң ул? Менә бит, ул безне белә, ә без аны белмибез! Әгәр дә ул һәлакәткә тарыган кеше икән, нигә бездән качып йөри соң? Без намуслы, гадел кешеләр ләбаса, безнең белән аралашу хурлыкмыни! Монда ул үз ирөге белән килгән микән соң? Теләгән чагында моннан китә ала микән? Әле дә утрауда микән ул? Бәлкем, монда юктыр да инде?

Серле зат турында сөйләшә-сөйләшә алар корабка менделәр һәм палубаны әйләнеп чыктылар. Кинәт диңгезче якорь арканы чорналган төпсәгә күзе төшкәч, аһ итеп куйды.

— Менә сиңа кирәк булса! Карагыз әле бу тамашаны!

— Нәрсә булган, Пенкроф? — дип сорады журналист.

— Мин бәйләгән төен түгел бу!

Пенкроф якорьның чорнап куелган арканы сүтелмәсен дип бәйләнгән төенгә төртеп күрсәтте.

Гедеон Спилет үз чиратында:

— Нишләп сезнеке булмасын? — дип сорады.

— Шулай инде, башымны кисмәгә бирәм, минеке түгел! Карагыз, кара, менә бит: бу яссы төен, ә мин гадәттә икеле төен ясыйм.

— Ялгыш әйтмисезме, Пенкроф?

— Нишләп ялгышыйм,— диде диңгезче.— Кул үзен-

нән-үзе төйни ул төенне, аңа кешенең катышуы кирәк тә түгел. Ә кул ялгышмый ул!

— Алайса, монда пиратлар менгәнмени? — дип сорады Герберт.

— Анысын белмим инде,— диде Пенкроф.— Мин якорьның күтәрелгән икәнен һәм соңыннан янәдән төшерелгән булуын гына әйтәм. Менә-менә, карагыз әле, тагын бер дәлил. Якорь арканын бушайтканнар, ә чорнаган чакта клюзына җиткермәгәннәр. Әйтәм бит инде, безнең суднога кемнәрдер утырып йөргән.

— Әгәр пиратлар булса, алар корабны талап чыккан булырлар иде, яисә аңа утырып качарлар иде...

— Кая качсыннар алар? Табор утравынамы? — диде диңгезче.— Мондый кечкенә суднога утырып, ерак юлга чыгарга аларның йөрәге җитә дисеңме?

— Аннары Табор утравын алар беләме әле, юкмы,— диде журналист та.

— Ни дисәгез дә диярсез, безнең кораб бездән башка диңгезгә чыккан. Мине Вайнъярдта туган Бонадвентур Пенкроф дип белсәгез, корабны да диңгезгә чыккан дип белегез.

Диңгезченең сүзенә Гедеон Спилет та, Герберт та каршы килә алмады. Пенкроф корабны Һава шары портына китереп куйганнан соң кемдер аңа утырып йөргән булса кирәк.

Диңгезче якорьны кемдер күтәргән һәм янәдән төшергән, ди. Диңгезгә чыгасы булмаса, якорьны нигә күтәрсеннәр дә, нигә төшерсеннәр икән?

Шулай да журналист бирешергә теләмәде, диңгезченең шиген кире кагу өчен соңгы дәлилне китерергә маташты:

— Утрау яныннан узганда «Хәерле юл»ны без ничек күрми калдык соң?

— Их, мистер Спилет, җил арттан искәндә, төн караңгы булганда, ике сәгатьтән соң теләсә кайсы утраудан күзәтсәң дә күреп булмый аны!

— Ярый, шулай дип фараз итик. Тик каторжаннар нигә диңгезгә чыктылар икән; диңгезгә бер чыккач, нигә бухтага кире кайтарып куйганнар, шунысын белер идем.

— Их, мистер Спилет, әйдә, бусы да сер булып калсын инде... Безнең әйләнә-тирәдә сер-табышмаклар болай да җитәрлек, монысы өчен дә баш ватмыйк. «Хәерле юл» исән килеш үз урынында торамы, тора, шунысы җит-

кән. Әгәр пиратлар аны тагын бер тапкыр алсалар, вәссәлам диген! Бүтән койрыгын да күрмәбез!

— Пенкроф, әгәр «Хәерле юл»ны Гранит сарай каршысына илтеп куйсак, яхшырак булмасмы? — диде Герберт.

— Яхшы булыр,— диде Пенкроф.— Хәер, юк, Рәхмәт елгасы тамагы судно торыр өчен җайсыз, анда диңгез тыныч түгел, дулкынлы.

— Әгәр анда ком өстенә чыгарсак, Хәрабә янына ук тартып китерсәк?..

— Анысы ярар иде,— диде Пенкроф.— Тик без озакка китәбез бит, Гранит сарайга тиз генә әйләнеп кайта алмыйбыз. Без сәяхәттә вакытта «Хәерле юл» монда торса, ышанычлырак. Утравыбызны явыз башкисәрләрдән азат иткәнче, шушында Һава шары портында гына торсын.

— Мин дә сезнең фикерне хуплыйм. Көннәр бозыла калса, Рәхмәт елгасы тамагына караганда ул монда әйбәтрәк сакланыр,— диде журналист.

— Әгәр пиратлар яңадан килеп чыкса? — дип куйды Герберт.

— Килсә килә инде, дустым, бернишләр хәл юк,— диде Пенкроф.— Күз алдына китер: юлбасарлар монда килде ди, судноны тапмагач, шундук эзләргә керешәчәкләр, аны Гранит сарай яныннан табып, без югында барыбер басып алачаклар. Мистер Спилет дөрес әйтә, «Хәерле юл» үз урынында калсын, монда хәвефсезрәк аңа. Сәяхәттән әйләнеп кайткач, судноны Гранит сарай янына китереп куярбыз. Анда уңайлырак булыр; яңадан берәрсе һөҗүм иткәнче тора бирсен шунда. Әгәр андый кыю йөрәклеләр табылса...

— Ярый, хәл иттек! Әйдәгез кайтыр юлга! — диде журналист.

Гранит сарайга кайтып кергәч, юлчылар ниләр күргәнен инженерга сөйләп бирделәр. Корабны хәзергә анда калдыруны, киләчәктә Гранит сарайга күчерүне ул да хуплады. Хәтта ул Котылу утравы белән Гранит сарай каршысындагы бугаз суына, буа буып, гавань ясап булмас микән дигән фикер әйтте. Әгәр бу хыял гамәлгә ашса, «Хәерле юл» һәрвакыт кул астында, аларның күз алдында торачак; кирәк дисәләр, йозаклап та куярга мөмкин.

Шул кичне Айртонга телеграм суктылар, утардан ике кәҗә алып кайтырга куштылар. Кәҗәләрне Наб яссы-

таудагы болынга ияләштерергә уйлый иде. Тик, гаҗәпкә каршы, нишләптер Айртон җавап бирмәде. Инженер аптырап калды. Хәер, Айртонның бу чакта утарда булмавы да мөмкин иде, бәлкем, ул Гранит сарайга кайтырга чыккандыр инде. Киткәненә ике көн тулды; алдан сөйләшенгәнчә, ул унысында, иң соңы унберендә иртән кайтып җитәргә тиеш иде.

Иптәшләре Айртонны менә кайтып керер дип көттеләр. Наб белән Герберт күпер төбенә барып, ул күренүгә, күперне төшерергә әзер тордылар.

Кичке сәгать уннар җитте, тик Айртон күренмәде. Икенче тапкыр телеграм җибәрергә кирәк дигән фикергә килделәр, бик тиз җавап бирергә куштылар.

Әмма Гранит сарайдагы телеграф аппараты тыптын тора бирде.

Иптәшләре ни булды икән дип борчылып бер-берсенә караштылар. Димәк, Айртон утарда түгел, яисә анда булса да, нилектәндер телеграм суга алмыйдыр. Караңгы төн булуга карамыйча, әллә аңа ярдәмгә чыгып китәргә микән?

Тавышлар икегә бүленде: берәүләр хәзер үк чыгып китү ягында, ә икенчеләр исә иртәгә таң атуын көтү ягында иде.

— Телеграф аппараты ватылмады микән? — дип искә төшерде Герберт.

— Бик мөмкин,— диде журналист.

— Иртәгә хәтле көтәргә кирәк,— диде Сайрес Смит.— Айртон, бәлкем, безнең хәбәрне алмагандыр яисә без аның җавабын ала алмыйбыздыр.

Иртәгә таң атуын көтәргә булсалар да, күңелләрендә борчу, шик-шөбһә арта барды.

Унберенче ноябрьдә таң нуры сызылуга, Сайрес Смит янә телеграф янына килде, телеграм сукты, әмма җавап килмәде.

Тагын бер тапкыр хәбәр җибәреп караса да, һаман тынлык хөкем сөрде.

— Әйдәгез, тизрәк утарга киттек! — диде ул.

— Мылтыкларны алыйк! — дип искәртте Пенкроф.

Гранит сарайны караусыз калдырмас өчен, Набны алмадылар. Наб аларны Глицерин инешенә хәтле озатып куйгач, күперне күтәртеп, агач артына посып, иптәшләренең һәм Айртонның кайтканын көтеп торырга тиеш булды.

Әгәр пиратлар килеп чыкса һәм Күзәтү яссылыгы-

на бәреп керергә маташсалар, мылтыктан ут ачып аларны тоткарларга тырышыр ул. Инде хәл кыенлашса, Гранит сарайга менеп, күтәрткеч кәрзинне алып куяр да беркем бәреп керә алмаслык крепостьта аңа тыныч булыр.

Сайрес Смит, Гедеон Спилет, Герберт һәм Пенкроф исә туры юлдан утарга барып, анда Айртонны тапмасалар, тирә-юньдәге урман эчләрен актарып чыгарбыз дип уйлаштылар.

Иртәнге сәгать алтыда инженер өч юлдашы белән Глицерин инешеннән чыгып китте. Наб инешнең сул ярындагы калкулык артына, биек агачлар ышыгына кереп посты.

Күзәтү яссылыгыннан төшеп, юлчылар утарга юнәлделәр. Чак кына шикле кыштырдау ишетелүгә, атарга әзер булып, корулы мылтыкларын кулларына тоттылар. Кораллары ике карабиннан, ике мылтыктан гыйбарәт булып, пуля белән корылган иде.

Юлның ике ягында да тоташ ешлык, анда явыз ниятле кешегә качып торырга уңайлы, ә пиратлар җитмәсә яхшы коралланган да, алар белән биредә очрашсаң, әҗәлеңне көт тә тор.

Юлчылар сөйләшми-нитми кызу-кызу атлап баралар. Топ алдан йөгерә, әле юл буйлап еракка ук чабып китә, әле урман эченә кереп югала; өрмичә, гамьсез генә җирне иснәп бара. Әгәр хәвеф-хәтәр барлыгын сизсә, тугрылыклы эт ерактан ук хәбәр бирер иде, берәр дошман каршыга килеп чыкса, абалап өрә башлар иде.

Алар бара торган юл читенә телеграф баганалары тезелеп киткән. Инде ике миль юл узсалар да, чыбыкның өзелгән җире күренмәде. Баганалар үз урынында басып тора, тимер чыбык әйбәт тарттырылган көе сузылып бара. Ләкин күп тә китмәделәр, инженер чыбыкның салыныбрак торганын шәйләп алды; җитмеш дүртенче багана турысына җиткәч, алдан барган Герберт кинәт туктап калды да:

— Чыбык өзелгән! — дип кычкырып җибәрде.

Арттанрак килгән иптәшләре адымнарын кызулатып Герберт янына килеп җиттеләр. Юл аркылы багана авып ятуын, тимер чыбыкның өзелгәнлеген күрделәр. Гранит сарайдан утарга җибәрелгән хәбәрнең, утардан Гранит сарайга киләсе җавапның ни өчен килеп җитмәвен төшенделәр.

— Багананы җил аудармаган,— диде Пенкроф.

— Әйе шул,— диде Гедеон Спилет.— Күрәсез ич, әнә, багана төбе казылган, баганаы кеше аударган.

— Тимер чыбыкны тартып өзгәннәр,— диде Герберт.

Чыннан да, чыбыкны көч белән тартып өзгәннәр, чыбыкның ике очы да җирдә аунап ята иде.

— Күптән өзелгәнме? — дип сорады Сайрес Смит.

— Юк, яңарак кына өзгәннәр ахрысы,— диде Герберт.

— Әйдәгез! Утарга тизрәк барып җитик! — диде диңгезче.

Юлчылар инде юлның урталыгында иделәр. Тагын ике миль ярым барасы калган иде. Алар ләм-мим сөйләшмичә тагын да кызурак бара башладылар.

Утарда нидер булганлыгына хәзер шик калмады. Айртон Гранит сарайга хәбәр җибәрсә дә, килеп ирешмәгән. Әмма юлчыларны анысы әллә ни борчымады. Ә менә Айртонның кичә кич кайтырга тиеш булып та, кайтмавы юньлегә түгел, ниндидер хәвефле хәл булганын искәртә иде. Гранит сарай белән утар арасындагы телеграф чыбыгын юкка өзмәгәннәр бит инде. Бу пиратлар эше. Качкын каторжаннардан башка телеграф чыбыгын кем өзсен икән?

Борчылудан үз-үзләрен белешмичә, юлчылар йөгерә үк башладылар. Алар барысы да Айртонны яратып өлгергәннәр иде инде. Кайчандыр үзенә буйсынган башкисәрләр аны үтереп ташладылар микәнни?

Озакламый тар гына инешкә җиттеләр. Утар тирәсендәге болын уртасыннан аккан инеш Кызыл инешнең кушылдыгы иде. Анда җиткәч, әкренрәк бара башладылар. Сугышырга туры килсә дип бераз хәл җыярга булдылар. Мылтыкларның чакмасына баскан хәлдә, һәркайсы урманның бер өлешен күзәтеп бара иде. Топ ырылдап-ырылдап куя, бусы да юньлегә түгел иде.

Ниһаять, агачлар сирәгәеп, алда утар коймасы күренде. Карап торуга ул төзек кебек иде. Капкасының, гадәттәгечә, келәсе төшерелгән. Эчтә тып-тын, муфлоннарның бәэлдәгәне дә, Айртонның тавышы да ишетелми.

— Әйдәгез, эчкә керик! — диде Сайрес Смит.

Инженер коймага якынайды, иптәшләр, ут ачарга әзер хәлдә, егерме адымлап читтә торалар иде.

Сайрес Смит эчтәге келәне күтәрде дә капканың бер як яртысын ачарга үрелгән иде, Топ ярсып өрергә ябышты. Койманың эчке ягыннан кинәт атып җибәрде-

ләр, аңа җавап иткәндәй бу яктан ачыргаланып кычкырган тавыш ишетелде.

Ядрә тиеп җәрәхәтләнгән Герберт җиргә ауды!

Җиденче бүлек

Журналист белән Пенкроф утарда.— Гербертны өйгә алып керәләр.— Диңгезче кайгыга батты.— Инженер белән журналист.— Дәвалау.— Яралы савыга башлады.— Набны ничек кисәтергә.— Тугрылыклы хәбәрче.— Набның җавабы.

Герберт тавышын ишеткәч, Пенкроф, мылтыгын атып бәреп, аның янына ташланды.

— Аһ, үтерделәр! Улымны үтерделәр! Үтерделәр! Үтерделәр! — дип үрсәләнеп кычкырды ул.

Сайрес Смит белән Гедеон Спилет та егет янына атылдылар. Журналист колагын егетнең күкрәгенә куйды, шатланып:

— Тере! — диде.— Аны өйгә кертергә кирәк...

— Гранит сарайгамы? Анда алып кайтып булмас,— диде инженер.

— Утарга алайса! — диде Пенкроф.

— Хәзер, көтегез,— диде Сайрес Смит.

Ул койманы әйләнеп узарга теләп, сулга ташланган иде, шунда пират белән йөзгә-йөз килеп бәрелә язды; тегесе мылтыктан атып җибәрде, пуля инженерның эшләпә читен тишеп узды. Юлбасар икенче тапкыр атарга өлгерә алмыйча калды, Сайрес Смит хәнҗәре белән аның йөрәгенә кадады, бандит гөрселдәп җиргә ауды. Сайрес Смит хәнҗәр белән мылтыкка караганда остарак сугыша иде.

Ә ул арада Гедеон Спилет белән Пенкроф койма башына үрмәләп менделәр дә эчке якка сикереп төштеләр һәм, капканың бастырыгын алып, ачып җибәрделәр. Аннары өйгә чабып керделәр, өй эче буш, анда беркем дә юк иде. Тиздән Гербертны Айртонның ятагына китереп салдылар.

Бераздан Сайрес Смит та килеп керде.

Исен җуйган Герберт янында диңгезче олы хәсрәткә төшеп басып тора, үксеп елый, кайгысыннан башын стенага бәреп ватар чиккә җиткән. Инженер белән журналист аны юатырлык сүз таба алмадылар. Кайгыдан үзләренең дә тамагына төер утырган, сүз әйтерлек хәлдә түгел иделәр.

Алар Гербертны әҗәл тырнагыннан коткарыр өчен әллә ниләр эшләргә әзер иделәр. Дөньяны күп күргән, башыннан төрле хәлләр кичкән Гедеон Спилетның медицинадан да бераз мәгълүматы бар иде. Әллә ни күп белмәсә дә, аңа мылтыктан, кылыч-хәнҗәрдән җәрәхәтләнгән яралыларны байтак дәваларга туры килде. Сайрес Смит белән бергә алар яралының җәрәхәтен карап, беренче ярдәм күрсәтергә әзерләнделәр.

Гедеон Спилет Гербертның бөтенләй аңсыз ятуына аптырады. Бу халәт каны күп агудан яки шоктан — тетрәнүдән булырга мөмкин иде. Ядрә бик каты көч белән сөягенә бәрелеп, егетнең яшь организмын тетрәткән булса кирәк.

Гербертның чырае кәгазь кебек ап-ак иде. Йөрәге бик әкрен тибә, вакыт-вакыт бөтенләй туктап калган кебек була. Гедеон Спилет андый чакта йөрәк тибешен эзләп тә таба алмагач, йөрәге бөтенләй туктаган дип куркып китә. Егет һаман аңына килә алмый. Кыскасы, хәле бик начар иде.

Журналист сак кына Гербертның изүен ачты, кулъяулыгы белән җәрәхәтенең канын сөртте, салкын су белән юды.

Хәзер җәрәхәт урыны ачык күренеп тора иде. Өченче белән дүртенче кабыргасы арасында озынча түгәрәк тишек бар. Бу ядрә эзе иде.

Сайрес Смит белән Гедеон Спилет егетне янына борып яткырдылар, шунда яралы ишетелер-ишетелмәс кенә ыңгырашып куйды. Бу — ыңгырашудан бигрәк, җан биргәндә алган соңгы сулышны хәтерләтте.

Егетнең аркасында да канлы җәрәхәт бар икән, ядрә шуннан чыгып киткән.

— Аллага шөкер! Җәрәхәте үтәли чыккан, пуляны алып азапланырга кирәкми,— дип җиңел сулап куйды журналист.

— Ә йөрәге? — дип сорады Сайрес Смит.

— Йөрәгенә тимәгән, югыйсә Герберт шундук үлгән булыр иде.

— Үлгән! — дип кычкырды, дөресрәге акырып елап җибәрде Пенкроф.

Дингезче журналистның «үлгән» дигән сүзен генә ишетеп калган икән.

— Юк, үлмәгән,— диде Сайрес Смит.— Юк дим бит, үлмәгән! Йөрәк тибеше сизелә! Ыңгырашканын ишеттегез бит. Зинһар, тыелыгыз, Пенкроф! Улыгыз ха-

кына сабыр итегез! Без үзебезне тыныч тотарга тиешбез. Зинһар безне каушатмагыз, дустым.

Пенкроф тынып калды, әмма кайгысы басылмады, аның ирләрчә кырыс йөзен бертуктаусыз күз яше юды.

Гедеон Спилет исә җәрәхәтне дәвалау өченниләр кирәк соң әле, дип элекке белгәннәрен исенә төшерергә тырышты. Яралыны әйбәтләп карагач, пуляның үтәли чыкканына тәгаен ышанды. Тик нинди әгъзалары зарарланган, кай төшләренә зыян тигән икәнен иң тәҗрибәле хирург та хәзер генә әйтә алмас иде, журналист әлбәттә аларын белми иде.

Әмма Гедеон Спилет шунысын тәгаен белә иде: аңа зарарланган тукымаларны ялкынсынудан сакларга кирәк; аннары бу авыр ярадан, үлем ярасыннан, эчке әгъзалары да ялкынсынуы, бизгәк башлануы мөмкин. Шуларны булдырмаска кирәк. Ялкынсынуга каршы нинди чаралар бар соң әле, нинди дарулар кулланырга? Яралыны өзлегүдән ничек сакларга соң?

Һәрхәлдә, хәзер үк ике җәрәхәтне дә әйбәтләп бәйләргә кирәк иде. Җәрәхәтне җылы су белән юарга, чәрдәкләнгән тукымаларны тарттырырга ярамый, кан китүе мөмкин. Гербертның болай да каны күп аккан, хәлсезләнгән.

Журналист ике җәрәхәтне дә салкын су белән юарга булды.

Яралыны сул ягына яткыздылар.

— Аңа селкенергә ярамый. Шушылай ятуы уңайлырак булыр, күкрәгендәге һәм аркасындагы ике җәрәхәте ачык, үлеге тышка чыксын өчен җайлы. Герберткә тынычлык бик кирәк хәзер,— диде Гедеон Спилет.

— Гранит сарайга алып кайтыйк алайса,— диде Пенкроф.

— Юк, ярамый,— диде журналист.

Диңгезче йодрыгы белән күккә янады:

— Ләгънәт яусын!

— Пенкроф, җитәр! — диде Сайрес Смит.

Гедеон Спилет яралы өстенә иелгәч, аның чыраена игътибар итте, Гербертның чырае баягыча кәгазь кебек ап-ак иде. Журналистның күңеленә шом керде.

— Сайрес, мин врач түгел бит... Синнән яшерә алмыйм, мин нишләргә белмим... Зинһар ярдәм итегез, берәр киңәш бирегез!..— диде.

Инженер аның кулын каты итеп кысты да:

— Зинһар тынычланыгыз, дустым. Үзегезне кулга

алыгыз... Гербертны ничек тә коткарырга кирәк, шуны истән чыгармагыз!

Бу сүзләрдән соң Гедеон Спилет үзен кулга алды, кинәт үзенең бик җаваплы икәнен тойды. Ул авыру янына килеп утырды, ә Сайрес Смит аның янәшәсендә басып тора иде. Пенкроф күлмәгеннән чүпрәк ертып алды да җебен суырып чүпли башлады.

Гедеон Спилет Сайрес Смитка беренче чиратта кан агуын туктатырга кирәклеген әйтте. Әмма җәрәхәтне бөтенләй томаларга ярамый, тиз җөйләнергә ирек бирмәскә кирәк, чөнки эчке әгъзалар зарарланган булса, күкрәк эчендә үлек җыелуы мөмкин, диде.

Сайрес Смит журналистның фикеренә кушылды. Иртә җөйләнергә ирек бирмичә, җәрәхәтне дәваларга булдылар. Бәхетләре, пычак кулланырга кирәкмәде.

Ялкынсынуга каршы берәр әйбәт дару бар идеме соң аларда?

Кул астында гына табигатьнең үзендә бер чара бар иде барын. Янәшәдән генә салкын чишмә суы ага иде, салкын суны халыкта ялкынсынган җирләрнең сызлавын басу өчен, җәрәхәтле авыруларны дәвалау өчен кулланалар. Хәзерге вакытта бу чараны күп кенә врачлар да таный. Салкын суның тагын бер өстенлеге бар: беренче көннәрдә ачык җәрәхәткә һаваның тәэсире бик куркыныч, бәйләмәгән очракта салкын су җәрәхәтне әнә шул куркынычтан саклый.

Гедеон Спилет белән Сайрес Смит, булган мөмкинлектән чыгып, дәвалый башладылар. Гербертның ике җәрәхәтен дә киндер тукыма белән ябып, аны әледәнәле салкын су белән чылатып тордылар.

Диңгезче исә учакка ут тергезеп җибәрде. Айртонның өендәге әйберләрне барлап чыккач, кайчандыр Гербертның Грант күле буеннан җыйган дару үләннәрен табып алды. Аларны кайнаттылар, аңа бераз шикәр дә куштылар. Егетнең авызына шушы хәл керткеч эчемлекне берничә кашык салып карадылар, ләкин яралы үзе моны сизмәде дә. Тәне бик кызу иде, көне буе аңына килә алмады. Егетнең гомере кыл өстендә иде, һәм кыл өзелеп китәм, өзелеп китәм дип кенә торды.

Иртәгесен, 12 нче ноябрьдә, дәвалаучыларның күңелендә инә очы хәтле генә өмет уянды: Герберт аңына килде. Ул күзен ачты, өстенә иелгән Сайрес Смитны, Гедеон Спилетны, Пенкрофны таныды. Хәтта берничә сүз дә әйтте. Әмманиләр булганын хәтерләмәде.

Гедеон Спилет аңа хәлне кыскача гына сөйләп бирде. Егеткә кузгалмыйча, тыныч кына ятарга кушты, төп куркыныч узган булса да, ярасы тиз төзәлсен өчен борчылмаска кирәк диде. Хәер, Герберт авыртуны сизми дә диярлек иде, чөнки берөзлексез салкын су белән чылатып торуның файдасы тиде, җәрәхәт ялкынсынмады. Тәненең кызышуы да бөтән артмады. Җәрәхәттән үлеге әкренләп килеп тора. Авыр яра зыянсыз гына төзәлер дигән өмет уянды. Пенкроф беренче тапкыр җиңел сулап куйды. Ул авыру яныннан бер генә минутка да китмәде, үзенең йөрәк пәрасен әнисе ничек караса, диңгезче дә яралы улын шулай карады.

Герберт яңадан йокыга талды, тик бу юлы ул тигез тын алып тыныч йоклады.

— Мистер Спилет, зинһар дөресен әйтегез, савыгыр микән ул? Сез Гербертны коткара алырсызмы? — дип инәлде Пенкроф.

— Пенкроф, сабыр бул, без аны коткарырбыз. Яшермим, җәрәхәте бик авыр; ядрә бәлкем үпкәсенә тиеп киткәндер, ләкин үпкә җәрәхәтеннән кеше үлми,— дип җавап бирде журналист.

— Ярабби, бу сүзләрегез ходай тәгаләгә барып ирешсен иде! — диде Пенкроф.

Соңгы бер тәүлек эчендә юлчылар Герберт яныннан бер генә минутка да китмәделәр, бар гамьнәре Гербертка юнәлгән иде. Пиратларның бирегә әйләнеп килеп, үзләренә һөҗүм итүе мөмкин, утарны сакларга кирәк дигән уй башларына да кереп чыкмады.

Ә 12 нче ноябрьдә Пенкроф авыру янында утырган арада, Сайрес Смит белән Гедеон Спилет үз хәлләре турында икәүләп киңәшеп, нинди чара күрергә икәнен уйлаштылар.

Беренче эш итеп алар бөтен утарны карап чыктылар, ләкин Айртонны бер генә җирдә дә тапмадылар. Бичараны элекке юлбасар танышлары алып китте микәнни? Аңа көтмәгәндә һөҗүм иткәннәрдер, күрәсең. Алар белән көрәшә алды микән ул, әллә шундук һәлак булды микән? Соңгысы дөрестер күрәсең. Кичә койма өстеннән төшкәндә Гедеон Спилет бер юлбасарның Франклин тавы сыртына таба йөгерүен күреп калды. Топ аның артыннан чапты. Рәхмәт елгасы тамагында көймәләре кыяга бәрелеп ватылган килмешәкләрнең берсе иде ул. Койма буенда Сайрес Смит хәнҗәр белән кадап үтергән кеше дә шул ук Боб Гарвей шайкасыннан иде.

Әмма ләкин утарда ватык-җимерекләр юк иде, әйберләр урыннан кузгалмаган. Муфланнар, кәҗәләр дә урманга качышып бетмәгән, абзар ишекләре бикле. Койма да аумаган, өй эче дә тузмаган, көрәшкән чакта була торган эзләр, ватык-җимерекләр күренми. Тик Айртонның мондагы патроннары, дарысы гына үзе белән бергә юкка чыккан.

— Бичара Айртонга көтмәгәндә һөҗүм иткәннәрдер. Югыйсә бер генә тапкыр да мылтыктан атмыйча, көрәшмичә бирелә торган кеше түгел иде ул,— диде Сайрес Смит.

— Шулайдыр дип куркам шул мин дә! — диде журналист.— Каторжаннар аны үтереп, утарны яулап алганнардыр, чөнки монда иркенләп яшәр өчен һәммә нәрсә бар, ризык мул. Ә безне күргәч, качып киткәннәрдер. Айртон үле булса да, тере булса да, хәзер кайдадыр еракта инде.

— Бөтен урманны актарып чыгып, ул кабахәтләрне кырып бетерергә кирәк,— диде инженер.— Пенкрофның алдан сизенүе тикмәгә булмаган. Пиратларны ерткыч хайван кебек атып бетерик дигән иде бит ул, дөрес әйткән икән. Әгәр аны тыңлаган булсак, бу бәхетсезлекләргә тарымыйдыр идек!

— Әйе шул,— диде журналист.— Аның каравы хәзер аларны рәхимсез рәвештә кырып бетерергә хакыбыз бар.

— Гербертны Гранит сарайга алып кайтырлык булганчы безгә монда утарда торырга туры килә.

— Наб ялгызы нишләр?

— Набка анда тыныч бит әле.

— Без озак кайтмагач, борчылып монда килергә чыкса?

— Аңа Гранит сарайдан беркая чыгарга ярамый! Юлда атып үтерерләр! — диде инженер ашыгып.

— Әгәр юлга чыкса!

— Их, телеграф эшләсә, урыннан кузгалмаска кушар идек! Хәбәр итеп тә булмый бит! Пенкроф белән Гербертның икесен генә монда калдыра да алмыйбыз... Гранит сарайга минем үземә китәргә туры килә.

— Юк, юк, моннан чыгарга ярамый, Сайрес! — дип кычкырып җибәрде журналист.— Әҗәл белән уйнарга хакыгыз юк. Бу очракта гайрәтләнү ярдәм итми. Бандитлар кайдадыр якын-тирәдә генә посып торалар, бертуктаусыз безне күзәтәләрдер. Әгәр Гранит сарайга

китсәгез, ике корбан булырсыз, икегез өчен дә кайгырырга туры килер аннары.

Инженер бирешмәде:

— Ә Набны нишләтәбез соң? Бер тәүлектән бирле бездән хәбәр булмагач, ул юлга чыгар бит!

— Ул пиратларның монда икәнен белми шул, сакланырга кирәген дә уйламаячак, бандитлар аны харап итәчәк!..

— Аны кисәтергә берәр чара юкмыни соң?

Кинәт инженерның күзе Топка төште. Әңгәмә вакытында эт бүлмә буйлап әрле-бирле йөренеп торды, гүя ул аларга: «Ә мин ярамыйммыни?» — дип әйтергә тели иде.

— Топ! — дип дәште Сайрес Смит.

Тугрылыклы эт хуҗасы янына чабып килде.

Журналист та инженерның ниятен төшенде:

— Дөрес уйлагансың, Смит, Топны җибәрергә кирәк. Без үтә алмаган җирдә ул асат үтә алыр. Эт Гранит сарайга хатны илтеп бирер. Җавабын да алып кайтыр.

— Вакытны әрәм итмик! Тизрәк! — диде инженер.

Гедеон Спилет тиз генә куен дәфтәреннән бер бит кәгазь ертып алды да:

«Герберт яраланды. Без әлегә утарда калабыз. Сак бул, Гранит сарайдан чыкма. Ул тирәдә пиратлар күренмәдеме? Топ артыннан хәбәр җибәр»,— дип берничә юл хат язды.

Набка кирәкле хәбәр дә, үзләре белергә теләгән сораулар да шушы берничә юл язуда әйтелде. Журналист, кәгазьне бөкләп, Топның муенсасына кыстырды, бер почмагын күрсәтеп калдырды.

Инженер Топны сөеп:

— Топ! Акыллы этем Топ! Наб! Набны төшендеңме, Топ! Бар! Бар! Наб янына бар!

Шушы сүзләрдән соң Топ шундук ишеккә ыргылды. Ул хуҗасының ни әйтергә теләгәнен, үзенең нишләргә тиешлеген шундук төшенде. Утардан өйгә кайту юлын ул әйбәт белә иде. Күп булса ярты сәгатьтән ул анда кайтып җитәчәк. Куе үлән арасыннан, урман эченнән күренмичә уза ала эт. Ә кешене пиратлар капкадан чыгуга күреп алачаклар, шундук ата башлаячаклар.

Инженер капка янына килеп аны чак кына кысып ачты да Гранит сарай ягына таба ишарәләп, этенә:

— Наб! Топ, аңладыңмы, Наб! — дип кабатлады.

Топ, койма буеннан узып, тиздән юкка чыкты.

— Ул кайтып җитәчәк! — диде журналист.

— Кайтып җитеп, әйләнеп тә киләчәк әле ул, минем булдыклы, тугры этем Топ!

— Сәгать ничә? — дип сорады Гедеон Спилет.

— Ун тулды.

— Бер сәгатьтән ул монда булачак. Көтик.

Капканы бикләп куйдылар. Һәм инженер белән журналист өйгә керделәр. Герберт әле уянмаган, каты йоклап ята. Пенкроф салкын сулы чүпрәкне гел алыштырып тора. Гедеон Спилет дәвалау эшеннән арынып, җиңелчә генә ашарга әзерләргә кереште. Ул тау итәгенә терәлгән коймага әледән-әле карап ала иде, бандитлар шул яктан һөҗүм итмәгәйләре дип шикләнә иде.

Алар Топның кайтуын борчылып көттеләр. Сәгать унбер туларак Сайрес Смит белән журналист, кулларына карабин алып, капка төбенә барып бастылар. Ерактан эт өргәнен ишетүгә, капканы ачарга әзер тордылар. Топ исән-имин Гранит сарайга кайтып җитсә, Набның аны шундук кире җибәрәчәгенә шикләнмәделәр.

Бер ун минутлар чамасы тордылар микән, кинәт кайдадыр мылтык шартлады, һәм шундук этнең ярсып-ярсып өргәне ишетелде.

Инженер капканы ачты да, бер йөз адымлап алдадары төтене күреп, шунда таба төзәп атып җибәрде.

Шул секундта капкадан Топ чабып керде, аның артыннан ук капканы шартлатып бикләп куйдылар.

Инженер акыллы этнең башын ике куллап кочып:

— Топ! Топ! — дип куанып тәкрарлады.

Топның муенсасына язу кыстырылган иде. Сайрес Смит аны алып, Набның эре-эре хәрефләр белән язган хатын укыды:

«Гранит сарай тирәсендә пиратлар күренми. Мин урынымнан кузгалмыйм. Бичара Герберт!»

Сигезенче бүлек

Пиратлар утар тирәсендә кайнашалар.— Вакытлы торак.— Гербертны дәвалау.— Пенкрофның эченә җылы керде.— Элекке тормышларын искә төшерү.— Киләчәк нәрсә вәгъдә итә? — Сайрес Смит шул хакта уйлана.

Димәк, качкын каторжаннар һаман бу тирәдә кайнашалар, сагалап торып, утрау хуҗаларын берәм-берәм үтереп бетерергә чамалыйлар күрәсең. Килмешәкләр

чыннан да ерткыч хайванга тиң икән, аларны башта ук кызганмаска кирәк булган. Хәзер сакланырга туры килә, чөнки өстенлек бандитлар ягында,— алар үзләре качып йөриләр, ә мондагыларны уч төбендәгедәй күреп торалар, сиздермәстән берәр почмактан килеп чыгып һөҗүм итүләре дә ихтимал, ә үзләренә искәрмәстән һөҗүм итәргә мөмкин түгел.

Шуңа күрә Сайрес Смит утардан беркая чыкмаска, әлегә шушында яшәп торырга кирәк диде. Бәхетләренә азык-төлек монда берничә атнага җитәрлек иде. Айртонның өендә көн итү өчен кирәкле һәммә нәрсә бар иде; утрау хуҗалары искәрмәстән килеп чыкканлыктан, пиратлар утардагы әйберләрне талап чыгарга өлгермәгәннәр.

Мондагы хәлләр Сайрес Смит фараз иткәнгә туры килә иде: Линкольн утравына аяк баскан алты пират утрауның көньяк яры буйлап китеп, Борылмалы ярымутрауны әйләнеп узганнардыр, әмма Ерак Көнбатыш урманнары эченә керергә шүрләп, диңгез яры буйлап юнәлгәннәрдер. Шарлавык елгасы тамагына җиткәч, аның уң як яры буеннан Франклин тавы итәгенә җиткәннәрдер. Тау тирәсендә кереп сыеныр куыш табуы ансат булыр дип эзли киткәннәрдер һәм юл өстендәге утарга тап булганнардыр. Утарда ул вакытта беркем юк иде. Шунда төпләнеп алгач, үзләренең явыз ниятләрен тормышка ашырырга форсат көтеп торганнардыр. Уйламаганда Айртон килеп чыгып, аларның планын бозгандыр, алар бичара Айртонны искәрмәстән тотып алганнардыр... Юлбасарларның аны ничек җәзалаганын күз алдына китерүе кыен түгел иде.

Хәзер пиратлар шушы тирәдә генә айкалалар,— алар бишәү генә калды калуын, әмма бишесе дә яхшы коралланган. Гранит сарайга кайту өчен урман аша исән-сау узып китү турында сүз дә булуы мөмкин түгел, һәр куак төбе саен дошман ядрәсе сагалап тора, ә утрау хуҗаларының дошман һөҗүменнән котылу өчен әлегә бер генә чаралары да юк.

— Көтәргә кирәк, фәкать көтәргә! — дип кабатлады Сайрес Смит.— Бүтән чарабыз юк. Герберт савыккач, бандитларны ауларга чыгарбыз, шунда алардан арынырбыз. Сәяхәтебезнең бер максаты шул иде бит.

— Серле химаячебезне эзләүдән кала,— дип куйды Гедеон Спилет.— Тик бу юлы ул нигәдер безгә иң кирәк чакта ярдәм итмәде.

— Алай димә! — диде инженер.

— Нигә? — дип сорады журналист аптырап.

— Әле безнең күрәчәгебез бетмәгән, илаһи химаячебезнең безгә ярдәм итәргә сылтавы күп табылыр әле. Хәзер хикмәт анда түгел. Герберт кына исән калсын.

Чынлап да аларның хәзер бөтен хәсрәт-борчуы, барлык мәшәкате Гербертның авыруы белән бәйле иде. Берничә көн узды, бәхеткә, егетнең хәле начарланмады. Каты авырганда берничә көнне тыныч уздырып җибәрү — хәлнең уңайга китүе дигән сүз иде. Салкын компрессны бертуктаусыз алыштырып торганга, җәрәхәт ялкынсынмады. Вулкан якын булганлыктан, су составындагы күкерт җәрәхәтне төзәтергә ярдәм итә, диде журналист. Җәрәхәтнең үлекләве нык кимеде. Гербертның хәле көннән-көн уңайлана, тәненең кызуы сүрелә бара. Тик ашавы кысылганга, ул бик хәлсезләнде; шулай да дару үләне төнәтмәләре эчертүнең, тынычлыкның шифасы тиде.

Сайрес Смит, Гедеон Спилет, Пенкроф җәрәхәт бәйләргә тәмам остарып җиттеләр. Айртон өендәге барлык эчке күлмәкләр яра бәйләүгә китеп бетте. Гербертның җәрәхәтенә компресс ябып, өстенә мамык урынына тукымадан йолкынган җепләрне куялар да чүпрәк белән әйбәтләп бәйлиләр; аны артык кысмаска, буш та итмәскә тырышалар иде. Журналист җәрәхәтне бәйләүгә аеруча игътибар итә; врачлар, операцияне ясаудан да бигрәк әйбәт итеп бәйләү әһәмиятле дип, юкка әйтми инде.

Ун көннән соң, 22 нче ноябрьдә, Гербертның хәле җиңеләйде. Берничә кашык шулпа ашый башлады. Бит урталары алсуланып чыкты, күзләре нурланды, үзен баккан иптәшләренә елмаеп карап ята иде. Пенкроф авыруны сөйләштермәс өчен иртәдән алып кичкә хәтле бертуктаусыз үзе сөйләнә, ул Гербертка җыен юк-барны сөйләп бетерде. Герберт, үзе тирәсеннән көне-төне бер генә минутка да китмәгән иптәшләре арасында Айртон күренмәгәч, гаҗәпләнеп, аның кайдалыгын сорады, диңгезче авыруны борчымас өчен кыска гына итеп: Айртон Гранит сарайга кайтып китте, Наб белән икәүләп Гранит сарайны пиратлар һөҗүменнән саклыйлар, диде.

— У-у, бәдбәхет пиратлар! Ул кабахәт җаннар яхшылыкның кадерен беләме? Мистер Смит яхшылык бе-

лән аларны иманга китермәкче булды. Ул әфәнделәрне эре калибрлы пуля гына акылга утыртса утыртыр.

— Алар яңадан бу тирәдә күренмәделәрме? — дип сорады Герберт.

— Юк, улым,— диде диңгезче.— Борчылма бер дә, без аларны табарбыз; менә савыгып кына җит, аннары күрербез әле: почмактан атарга остарган ул куян җаннар йөзгә-йөз очрашкач нишләрләр икән!

— Бик хәлсез шул әле мин, Пенкроф!

— Һи, исең киткән икән! Харап булган! Янәсе ядрә күкрәген тишеп чыккан! Мин аннан бигрәк җәрәхәтләр күргәнем бар әле, менә бит, әле дә исән-сау!

Авыру савыга башлады, әгәр өзлекмәсә, иң хәтәр вакытлары узып китте инде. Әгәр ядрә сөяккә кереп утырган булса, Гербертның аягын яки кулын кисәргә туры килсә, ни хәл итәрләр иде!

— Шуларны күз алдына китерсәм, йөрәгем жу итеп китә,— диде Гедеон Спилет.

Инженер аның маңгаена терәп сорады:

— Алай да, әгәр алдыңа шундый сынау килеп басса, икеләнеп калыр идеңме?

— Юк, икеләнмәс идем,— дип җавап бирде Гедеон Спилет,— аллага шөкер, башыбызга ул хәсрәт төшмәде.

Алда күргәнебезчә, алар бу юлы да, авыр хәлгә төшкәч, үз көчләренә таяндылар, үз булдыклыгы, үз белемнәре аркасында яңа җиңүгә ирештеләр! Әмма килер бер көн: аларның бөтен белеме, барлык акыл-тәҗрибәсенең көче җитмәслек хәл килеп туар бит; ул чагында нишләрләр? Алар утрауда ялгыз бит! Җәмгыятьтә кешеләр бер-берсенә таяналар, бер-берсенә булыша, кеше кешесез яши алмый. Сайрес Смит моны төшенә, һәм еш кына күңеленә кайчан да булса чарасыз калуыбыз мөмкин бит дигән уй килә дә шомланып китә иде.

Аңа хәтта алар моңа хәтле бәхетле яшәп тә, хәзер һәлакәт чигенә килеп басканнардыр кебек тоела башлады. Ричмондтан качып киткән көннән алып, ике ел ярым вакыт дәвамында, аларга гел уңай килеп торды. Утрау минералларга, төрле металларга бай, урманнарда, болын-тугайларда үсемлекләр мул үсә, кош-кортлар, җәнлекләр күп. Табигать үз хәзинәсен өеп бирә; үзләре дә, белем-тәҗрибәләрен җигеп, табигатьнең юмартлыгыннан файдалана беләләр. Аларның матди хәле бик тә канәгатьләнерлек иде. Иң кыен чакта ниндидер

аңлаешсыз көч ярдәмгә килеп тора! Болар мәңге дәвам итмәс бит!

Кыскасы, Сайрес Смит язмышның аларга арты белән борылганын тойды.

Әнә бит, утрау янына уйламаганда юлбасарлар корабы килеп чыкты; гәрчә ниндидер серле көч ярдәмендә пиратлар һәлак булса да, алтысы исән калды. Ярга чыккан, исән калган бишесен әнә хәзер әзәрлекләрлек тә түгел. Баштанаяк коралланган кабахәт җаннар мөгаен Айртонның башына җиткәннәрдер. Гербертны да яраладылар. Бичара бала үлемнән чак исән калды. Киләчәктә язмыш тагын да рәхимсезрәк сынаулар әзерләмәгәндер дисеңме? Сайрес Смитның күңелен әнә шундый шомлы уйлар биләгән. Ничә тапкыр алар бу турыда журналист белән дә сөйләштеләр. Әлеге кодрәтле яклаучы аларны әллә хәзер ташлап китте микән? Бәлкем, ул серле кеше утраудан ук китеп баргандыр? Әллә юлбасарларның ядрәсе аны да харап иттеме?

Бу сораулар җавапсыз калды. Бу турыда еш сөйләшсәләр дә, Сайрес Смит белән Гедеон Спилетны өметсезлеккә төшкән, рухлары сынган дип уйлау дөрес булмас. Кешеләре ул түгел. Алар теләсә нинди язмыш сынавына каршы кыю атларга, теләсә нинди кыен хәлдән исән чыгу юлын табарга сәләтле. Язмыш нинди генә көтелмәгән хәлгә куйса да, югалып кала торган түгел алар. Киләчәккә каршы кыю атлап баралар. Яңадан берәр афәткә тарысалар да, батырларча көрәшәчәкләр.

Тугызынчы бүлек

Набтан хәбәр юк.— Журналист белән Пенкрофның тәкъдиме кире кагылды.— Гедеон Спилет икенче тапкыр утардан чыкты.— Тукыма кисәге.— Хәбәр.— Ашыгыч күчену.— Күзәтү яссылыгында.

Гербертның хәле көн саен яхшыра барды. Иптәшләре хәзер аның бераз ныгуын гына көтәләр, шундук Гранит сарайга кайтып китәселәр. Утардагы йортта көн итәр өчен кирәкле һәммә нәрсә булса да, ни әйтсәң дә, төп тораклары түгел шул, андагы уңайлыклар җитми.

Аннары монда җан тынычлыгы да юк. Нихәтле сак йөрсәң дә, теләсә кайсы секундта пиратлар пулясына азык булуың бар. Ә тегендә, ышанычлы гранит стена куенында, аларга тыныч булыр иде. Пиратлар анда һөҗүм итәргә маташсалар да, үз башларына гына бу-

лачак. Шуңа күрә алар Гербертны өйгә алып кайтыр көнне түземсезләнеп көтәләр. Гәрчә Җакамар урманыннан үтүе хәтәр икәнен белсәләр дә, барыбер үз ниятләреннән ваз кичмәячәкләр.

Набтан нигәдер хәбәр юк. Әмма аның өчен әллә ни борчылмадылар. Гранит ныгытма эчендә батыр негр дошманга тиз генә бирешмәячәк. Шуңа күрә Топны икенче тапкыр хәбәр илтергә җибәреп, үз куллары белән әҗәл авызына ташлыйсылары килмәде. Кечкенә колониянең тугрылыклы, акыллы, алыштыргысыз әгъзасы бит ул, аннан да язсалар нишләрләр!

Гәрчә Гранит сарайда һәммәсе бергә җыелырга атлыксалар да, түзем рәвештә көтәргә туры килә иде. Сайрес Смит көчләре таркалганын күреп тора, шуның өчен бик пошына иде, чөнки аларның таркаулыгы дошман файдасына бит. Айртон булмагач, алар биш дошманга каршы дүртәү генә калдылар. Герберт та исәпкә керми әле. Сизгер күңелле егет кыен чакта монда тоткарлануга үзе сәбәпче икәнен тоя, моны авыр кичерә иде.

29 нчы ноябрь көнне төш вакытында, Гербертның йоклавыннан һәм ишетмәвеннән файдаланып, Сайрес Смит, Гедеон Спилет белән Пенкроф пиратларга каршы көрәшне нидән башлау хакында киңәшеп алдылар.

Набтан хәбәр булмавы, аның белән ара өзеклеге турында сүз чыккач, журналист:

— Дусларым, утар коймасының теге ягына чыгу — үз ирегебез белән дошман авызына керү дигән сүз, үзебез атарга да өлгерми калырбыз, дошман пулясы башыбызга җитәр. Шулай булгач хәзер үк теге кабахәт җаннарга каршы ауга чыгарга вакыт җитмәде микән,— диде.

— Дөрес әйтәсез,— диде Пенкроф.— Нигә ядрәдән куркып торырга. Әгәр мистер Сайрес рөхсәт итсә, мин хәзер үк урманга китәм. Харап икән! Бер кеше бер кешене җиңмәскә!

— Ә биш кешене? — дип сорады инженер.

— Мин дә Пенкроф белән барам,— дип аны бүлдерде журналист.— Топны да алабыз. Әйбәт коралланып, икебез дә...

— Кадерлем Спилет һәм Пенкроф, тыныч кына сөйләшик әле. Әгәр дә пиратлар бер урынга төпләнгән булсалар, без ул урынны белсәк, аларны ул позициядән бәреп чыгару турында сүз барса, мин бер каршылыксыз риза булыр идем, без аларга маңгайдан һөҗүм итәр

идек. Лэкин пиратларның беренче булып һөжүм итүе дә мөмкин бит.

— Һәй, мистер Сайрес, һәр ядрә төзәгән җиренә тиямени ул,— диде Пенкроф.

— Гербертны яралаган ядрә тиде бит,— диде инженер.— Әгәр сез икәүләп утардан китсәгез, мин ялгыз калам, пиратларга каршы берүземә сугышырга туры килә. Пиратлар сезне алдап урман эченә алып керерләр дә, утарда яралы малай белән бер кеше генә калганын белгәч, һөжүм итәрләр.

Пенкроф йөрәге ярсуга түзә алмаса да:

— Сез хаклы, мистер Сайрес, әйе шул, хак әйтәсез,— дип ризалашты.— Алар утарны басып алырга тырышачаклар. Монда байлыкның мул икәнен беләләр! Ә сез бер ялгыз аларга каршы тора алмассыз! Их, әгәр Гранит сарайда булсак без!

— Гранит сарайда булсак, ярар иде ул! — диде инженер.— Анда мин Герберт янында теләсә кайсыгызны калдырыр идем дә, өчебез урманга тегеләрне эзли китәр идек. Ни үкенеч! Без утарда шул, моннан барыбыз да берьюлы гына чыга алабыз.

Иптәшләре Сайрес Смитның төпле дәлиленә каршы килә алмадылар.

Гедеон Спилет тирән көрсенеп куйды:

— Их, Айртон да безнең янда булса! Аһ, мескен, мескен! Намуслы яши башлагач кына, бик тиз үлеп китте шул!

— Әгәр үлгән булса...— дип сәер генә әйтеп куйды Пенкроф.

— Әллә аны исәндер дип уйлыйсызмы, Пенкроф? Юлбасарлар рәхим-шәфкать күрсәткәннәрдер дисезме? — дип сорады Гедеон Спилет.

— Әлбәттә, алар файдасына ла ул!

— Ничек инде! Айртон, үзенең элекке юлбасар иптәшләре арасына эләккәч, барысын оныткандыр дисезме, безгә бурычлы икәне дә исеннән чыккандырмы...

Гүя бу коточкыч шикне уена да китермәгәндәй, Пенкроф көттереп кенә:

— Белмәссең,— дип куйды.

Сайрес Смит диңгезченең кулыннан тотты:

— Пенкроф, андый әшәке фикер каян башыгызга килде? Моннан соң сездән андый яман сүз ишетмим! Зинһар мине үпкәләтмәгез! Айртонның хыянәт итмәячәгенә үзем ант итәм!

— Мин дә,— диде журналист ашыгып.

— Шулай анысы, мистер Сайрес... мин хаклы түгелдер...— диде Пенкроф.— Дөрес әйттегез, бик әшәке фикер бу, алай уйларга нигез дә юк! Нишлим соң? Зиһенем чуалып бетте бит инде. Ябылуда утырып акылым ычкынды бугай инде. Үз гомеремдә болай явызланганым юк иде.

— Сабыр итәргә кирәк, Пенкроф,— диде инженер.— Кадерлем Спилет, Гербертны Гранит сарайга кайчан күчерергә ярар икән?

Журналист уйланып торгач:

— Әйтүе кыен, Сайрес. Ашыгырга ярамас. Харап итеп ташлавыбыз бар. Әлегә эшләр уңайга бара, бер атнадан Гербертка көч керер дип уйлыйм, шунда карарбыз!

Бер атна! Димәк, Гранит сарайга кайту декабрьнең беренче числосына хәтле кичектерелә.

Инде язның ике ае узды. Көннәр аяз, матур тора, кызулар җитте. Урман саф яшеллеккә күмелеп купшыланып утыра. Уныш өлгереп килә. Гранит сарайга кайту белән кыр эшләре башлана дигән сүз, экспедиция тагын кичектерелә.

Укучылар күреп тора, утрау хуҗаларының ирексездән монда ябырылып ятуы бик зур зыян иде. Алар үз хәлләренә сүзсез генә буйсынырга мәҗбүр булсалар да, эчләре поша иде.

Журналист бер-ике тапкыр капкадан чыгып, коймә тирәли әйләнеп керде. Топ та аңа иярде. Берәрсе кинәт каршыга чыкса дип, Гедеон Спилет карабинын сузган килеш алга иелә төшеп атлады.

Әмма юлында аңа беркем очрамады, шикле эз-фәлән дә күренмәде. Сизгер эт, әгәр хәтәр барлыгын тойса, өреп хәбәр итәр иде, әмма Топ тыныч кына йөгереп бара, күрәсең бу мәлдә тирә-юньдә беркем юктыр; бәлкем, пиратлар утрауның бүтән ягына киткәннәрдер.

Әмма 27 нче ноябрь көнне, икенче тапкыр чыкканында Гедеон Спилет тауның көньяк битләвендә урман эченә чирек миль чамасы эчкәре кергәч, Топның тынычсызлана башлавын искәрде. Ул элекке кебек алдан гамьсез генә юрттырып бармый, әсәренеп бер алга таба чаба, тагын кире атылып килә, үләннәрне-куакларны шикләнеп-шикләнеп исни.

Гедеон Спилет этне алга өстерде дә үзе артыннан иярде, карабинын атарга әзер тоткан килеш, агач арт-

ларына ышыклана-ышыклана як-ягына сагаеп карыйкарый барды. Топ кеше барлыгын сизгәндер дип булмый; андый очракта ул, гүя күренмәгән дошманына үчегеп, буылып-буылып өрә торган иде. Ә хәзер хәтта ырылдамый да,— димәк, куркыныч кайдадыр еракта.

Топ биш минут чамасы урманда эзләнеп йөргәч, кинәт куе куаклыкка ташланды да, аннан чүпрәк кисәге табып алып чыкты.

Ауналып-пычранып беткән ниндидер кием ертыгы иде бу. Гедеон Спилет аны тиз генә утарга алып кайтты.

Иптәшләре чүпрәкне әйбәтләп карагач, Айртон курткасының кисәге икәнен таныдылар. Чөнки аның курткасы Гранит сарай мастерскоенда басылган туладан тегелгән иде.

— Менә күрдегезме инде, Пенкроф, бичара Айртон дошманнарга каршы аяусыз көрәшкән. Димәк, пиратлар аны ирексезләп алып киткәннәр! Йә, хәзер дә аны хыянәт иткәндер дип шикләнәсеңме? — диде Сайрес Смит.

— Юк, юк, мистер Сайрес, мин күптән шикләнмим инде. Бая әллә каян гына башыма кергән шик булды ул. Минемчә, хәзер безгә бер фикер аңлашылды!

— Нинди? — дип кызыксынды журналист.

— Айртонны утарда үтермәгәннәр! Аны моннан исән килеш алып чыгып киткәннәр! Әнә бит дошманнарына урманда каршылык күрсәткән!

— Бәлкем, шулайдыр,— диде инженер уйчан гына.

Утрау хуҗаларының күңелендә Айртон исән дигән өмет терелде. Моңарчы алар Айртонны пиратлар көтмәгәндә атып үтергәндер дип уйлаганнар иде. Әнә Гербертны искәрмәстән яраладылар бит. Әгәр каторжаннар аны башта ук үтермәгәннәр икән, үзләре белән кайдыр утрау эченәрәк алып кереп киткәннәр икән, ул хәзер дә исәндер, бәлкем, тоткынлыкта җәфа чигәдер? Пиратларның берсе Австралиядәге элекке дустын,— качкын каторжаннар башлыгы Бен Джойсны,— таныгандыр. Кем белә, алар Айртонны пиратлар шайкасы ягына аударырга ниятләгәннәрдер? Әгәр дә аны хыянәткә үгетли алсалар, аларның зур отышы була бит бу.

Кыскасы, чүпрәк кисәге алар күңелендә Айртонны исән килеш табарбыз дигән өметне терелтте. Әгәр Айртон исән булып, пиратлар кулында тоткынлыкта икән, ул ничек тә котылырга тырышачак, булдыра алганын

да, булдыра алмаганын да эшләячәк һәм иптәшләре янына кайтачак!

— Әгәр дә, безнең бәхеттән, Айртон кача алса, туры Гранит сарайга кайтачак, чөнки ул бандитларның Гербертны үтерә язганын белми, безнең монда ябылуда утырганны башына да китерми!

— Их, Гранит сарайга кайткан булсын иде,— диде Пенкроф ашкынып,— без дә өйдә булса идек! Ул кабахәт җаннарны өйгә якын китермәсләр китерүен, тик аларның яссытаулыкны пыран-зыран китерүе, яшелчәлекне, иген басуларын таптап-изеп чыгулары, кош кетәген талаулары мөмкин.

Пенкроф Линкольн утравында яшәү дәверендә атаклы фермерга әверелде, яшелчәлеккә, иген басуларына күңеле белән беректе.

Герберт та Гранит сарайга кайтырга ашкына иде, барлык иптәшләренең бу моментта бергә тупланырга тиешлеген ул да төшенә. Утарда аның аркасында гына яталар бит! Тизрәк китәргә кирәк моннан, ничек тә китәргә иде! Ул Гранит сарайга кайтканда юлда кыенлыкка түзә алырмын дип уйлый иде. Өйгә кайткач, диңгез һавасында, саф җилдә тизрәк терелер идем, ди.

Ул ничәмә-ничә тапкыр Гедеон Спилетка ялынып караса да, табип Гербертның җөйләнеп бетмәгән ярасы юлда ачылмагае дип шикләнә, юлга чыгарга рөхсәт бирми, һәм дөрес итә иде.

Әмма тиздән алар бер көтелмәгән хәл аркасында егетнең үтенечен үтәргә мәҗбүр булдылар, соңыннан шушы саксыз адым аркасында нинди тәмуг газабына дучар булуларын бер ходай үзе генә белә иде.

Бу хәл 29 нчы ноябрь көнне иртәнге сәгать җидедә булды. Сайрес Смит, Гедеон Спилет һәм Пенкроф Гербертның ятагы янына җыелып сөйләшеп торалар иде. Кинәт этнең чиный-чиный өргәнен ишеттеләр.

Өчесе дә карабиннарын кулга алып өйдән йөгерешеп чыктылар, атарга әзерләнделәр.

Эт койма буенда чабулап йөри, өскә таба ыргылаыргыла өрә, тик ачу белән түгел, шатлыктан өргән кебек тоела иде.

— Кемдер килә!

— Әйе шул!

— Дошман түгел!

— Бәлкем Набтыр!

— Әллә Айртонмы?

Шулай дип сөйләнергә өлгермәделәр, кемдер койма өстенә менеп, эчке якка сикереп тә төште.

Бу Юп, Юп абзыкай үзе иде. Топның шатлыгыннан өрә-өрә аны каршылавы икән.

— Юп! — диде куанып Пенкроф.

— Аны Наб җибәргән,— диде журналист.

— Алайса язуы бардыр,— диде инженер.

Пенкроф орангутанг каршысына йөгерде. Чыннан да хуҗасына хәбәр җибәрү өчен Наб Юптан да ышанычлы, Юптан да җитез хәбәрчене кайдан тапсын! Бер генә кеше дә, хәтта Топ та үтә алмас җирдән фәкать Юп кына үтә ала бит.

Сайрес Смит хаклы булып чыкты. Юпның муенына нәни генә янчык асылган иде, янчыктан Набның хаты чыкты.

«Җомга көн, иртәнге сәгать алты.
Яссытаулыкны пиратлар басып алды.
Наб.»

Хатны укыгач, барысы да сүзсез калдылар, кара кайгыга батып, дәшмичә генә бер-берсенә караштылар, аннары башларын түбән иеп, өйгә кереп киттеләр. Пиратлар Күзәтү яссылыгын басып алган,— бу һәлакәт, афәт, бөлгенлек иде!

Ишектән керүчеләрнең боек чыраена карагач та Герберт күңелсез хәл барлыгын төшенде, ә Юпны да күргәч, Гранит сарайга куркыныч янавына шиге калмады.

— Мистер Сайрес, минем өйгә кайтасым килә! Юлда түзә алам мин! Хәзер үк юлга чыгасым килә! — дип инәлде ул.

Гедеон Спилет Герберт янына килде. Егетнең чыраена озак кына карап торгач:

— Ярый, әйдәгез кайтабыз! — дип ризалыгын бирде.

Иптәшләре Гербертны носилка беләнме, әллә Айртон утырып килгән арбага яткырып алып кайтыйкмы дип тиз генә киңәшеп алдылар. Носилкага салсалар, арба кебек селкетмәс иде селкетүен, аның каравы носилканы ике кеше күтәрергә тиеш була; юлда искәрмәстән дошман һөҗүм итсә, ике кешенең кулы бәйле дигән сүз.

Ә арбага салсалар, өчесенең дә кулы бушый. Арба төбенә матрасны кат-кат түшәргә дә, онагрларны йөгәненнән тотып, бәрдермичә, җай белән генә алып кайтырга да мөмкин бит.

Арбаны ишек төбенә тартып китерделәр, Пенкроф онагрны арбага җикте.

Сайрес Смит белән журналист, Герберт яткан матрасларны алып чыгып, арба төбенә түшәделәр.

Көн гаҗәеп матур иде. Агачларның җете яшел яфраклары арасыннан шаян кояш нурлары төшеп уйнаклый.

— Мылтыклар әзерме? — дип сорады Сайрес Смит.

Бар да әзер иде. Инженер белән Пенкроф куш көпшәле мылтыклар, ә Гедеон Спилет карабин алды. Юлга кузгалыр алдыннан Сайрес Смит:

— Герберт, урының җайлымы? — дип сорады.

— Җайлы, мистер Сайрес, зинһар борчылмагыз. Юлда үлмим мин,— дип җавап кайтарды Герберт.

Егет сер сынатмаска маташса да, актык көчен җыеп түзәргә тырышуы, хәлсезлеген, күңеле буталуын көчкә генә җиңүе күренеп тора иде.

Сайрес Смитның йөрәге авыртып куйды. Юлга кузгалырга әмер бирә алмыйча, байтак каушап торды. Әмма кире уйласа, егетнең өметен өзү, хәтта үтерү икәнен төшенеп, ниһаять:

— Кузгалдык! — дип әмер бирде.

Мал утарының капкасын ачып җибәрделәр. Юп белән Топ тавыш-тынсыз гына беренче булып иреккә атылдылар,— кирәк чагында алар да тынлык саклый белә иде. Арба койманың тышкы ягына чыгуга, капкалар ябылды; Пенкроф онагрны әкрен генә әйдәп кузгатып алып китте.

Аларга утар юлыннан кайтмаска кирәк иде, әмма урман эчләп китсәләр, тигезле-тигезсез юлдан барганда арба селкетер дип, теләсә-теләмәсәләр дә, пиратлар белгән юлдан кайтырга мәҗбүр булдылар.

Сайрес Смит белән Гедеон Спилет, дошман һөҗүм итсә, сугышырга әзер хәлдә, арбаның икесе ике ягыннан атлыйлар. Хәер, пиратлар Күзәтү яссылыгыннан нигә алай тиз китсеннәр икән. Наб дошманнар анда күренүгә үк хәбәр җибәргән булса кирәк. Хәтта «иртәнге сәгать алты» дип вакыты да күрсәтелгән иде. Мал утарында ничәмә-ничә тапкыр кунак булган елгыр маймылга Гранит сарай белән утар арасындагы биш мильне узу өчен кырык биш минут җиткән. Юл болай тыныч күрснә; атышырга туры килсә дә, Гранит сарай тирәсенәрәк барып җиткәч булыр.

Әмма юлчылар әйләнә-тирәне сагаеп күзәтеп баралар. Кулына чукмар тоткан Юп һәм Топ әле юл буйлап алга таба чабалар, әле урман эченә кереп китәләр. Һәрхәлдә, әлегә үзләрен тыныч тоталар.

Пенкроф арбаны җай гына алып бара. Алар утардан сигезенче яртыда чыгып киткәннәр иде, бер сәгать эчендә исән-имин генә дүрт миль юл уздылар.

Юл буш, Рәхмәт елгасыннан алып күл янына хәтле сузылган Җакамар урманының бу тирәләре тып-тын. Тирә-юньдә шылт иткән тавыш та ишетелми. Беренче тапкыр килеп төшкәндәге кебек, бүген дә гүя урманда бер генә адәм заты да юктыр кебек тоела.

Минут үткән саен яссытаулыкка якынлаша баралар. Тагын бер миль узуга Глицерин инеше аркылы салынган күпер күренәчәк. Сайрес Смит аны төшерелгән дип уйлый; пиратлар аның аркылы узганнардыр, яисә су аша чыксалар да, чигенергә туры килсә дип, күперне алдан ук төшереп куйганнардыр.

Ниһаять, агач яфраклары арасыннан ялтырап диңгез күренде. Арба салмак кына бара бирде, юлчылар исә адымнарын тыя төштеләр.

Кинәт Пенкроф онагрны тыеп туктатты да:

— Ах явызлар! — дип ачынып кычкырып җибәрде.

Калтыранган кулы белән алга таба ишарәләде. Анда җил тегермәне, терлек абзарлары, кош кетәге өстеннән һавага кап-кара төтен баганалары үрли иде.

Кемдер куе төтен арасында чабып йөри: бер күренеп кала, бер кереп югала.

Бу Наб икән.

Юлчылар аңа кычкырдылар. Наб, иптәшләре дәшкән тавышны ишеткәч, каршыларына йөгереп килде.

Каторжаннар Күзәтү яссылыгындагы бөтен нәрсәнең астын-өскә китереп, кырып-җимереп, ут төртеп, ярты сәгать элек кенә китеп барганнар.

— Мистер Гербертның хәле ничек? — дип сорады Наб.

Гедеон Спилет арба янына килде.

Герберт һушсыз ята иде.

Унынчы бүлек

Герберт Гранит сарайда.— Набның хикәясе.— Сайрес Смит Күзәтү яссылыгына бара.— Андагы афәт.— Гербертның авыруы көчәйде.— Өянке кайрысы.— Үлем бизгәге.— Топ янә өрә.

Пиратларның явыз эшләре, Күзәтү яссылыгындагы җимерү-талаулары, Гранит сарайга куркыныч янавы хакында сөйләшүләр тынды. Барысының да игътибары Гербертка юнәлде, ул гына исән калсын иде! Арбада селкенеп кайту ярамады, күрәсең; бичара бала өзлекте микәнни? Гедеон Спилет каушап калды, авыруның савыгуына өметен җуя башлады. Һәммәсен кара кайгы басты.

Арба елга тугаена килеп туктагач, аңын җуйган Гербертны агач ботакларыннан тиз генә әмәлләгән носилкага матраслары-ние белән күтәреп салдылар. Ун минуттан Сайрес Смит, Гедеон Спилет һәм Пенкроф гранит стена итәгенә килеп җиттеләр. Набка арбаны Күзәтү яссылыгына илтеп туарырга куштылар.

Күтәрткеч кәрзин белән өскә менгезгәч, Гербертны Гранит сарайдагы үз ятагына илтеп салдылар.

Бик азаплана торгач, авыруны көч-хәл белән аңына китерә алдылар. Ул, үз бүлмәсендә ятканын күреп, куанычтан елмаеп куйды, әмма сүз әйтерлек хәле юк иде.

Гедеон Спилет авыруны хәсиятләп карарга тотынды. Ул егетнең төзәлеп бетмәгән ярасы ачылгандыр дип шикләнгән иде. Ләкин ярасы ачылмаган булып чыкты. Аңын нигә җуйды икән соң ул? Нигә хәле начарланып китте икән?

Герберт яңадан авыраеп китте, исен җуйды. Журналист белән Пенкроф аның яныннан бер генә секундка да китмәделәр.

Ә ул арада Сайрес Смит Набка утардагы хәлләрне кыскача гына сөйләп бирде, ә Наб Күзәтү яссылыгындагы афәтне тасвирлады.

Кичә төнлә пиратлар Глицерин инеше ярына урман авызына килеп чыкканнар. Кош кетәге янында сакта торган Наб инеш аркылы чыга башлаган пиратларның берсенә ике дә уйлап тормыйча атып җибәргән. Тик, караңгы булганга, пуляның тигәнме-юкмы икәнен белми. Һәрхәлдә, бер ядрә белән ул дошман бандасын куып җибәрә алмаган, үзе көчкә Гранит сарайга менеп өлгергән.

Шунда Наб, пиратларның яссытаулыктагы барлык хуҗалыкны харап итәчәген күз алдына китереп, нишләргә икән дип хәсрәткә төшкән. Бу кабахәтләрне аннан ничек куып җибәрергә соң? Хуҗасы Смитка бу хәлләрне ничек хәбәр итәргә? Ә мал утарындагыларның үз хәлләре ничек икән соң? Әнә шундый борчулы сорауларга җавап эзләп, Набның тәмам башы каткан.

Сайрес Смит һәм аның иптәшләре утарга 11 нче ноябрьдә чыгып киткәннәр иде, ә хәзер 29 нчы ноябрь. Унтугыз көн эчендә Наб бары бер хәбәр алды. Топ аша җибәргән хаттан ул утардагыларның хәле яман икәнен аңлап калды: Айртон югалган, Герберт каты яраланган, авыр хәлдә ята; инженер, журналист һәм диңгезче ирексездән мал утарында ябылуда утыралар.

Бичара Наб, нишләргә дә белмичә, тәмам хәсрәткә баткан; үзе өчен борчылмаган ул, пиратлар гомергә дә Гранит сарайга менә алмаячак. Әмма Күзәтү яссылыгындагы каралтыларны, сарайларны, яшелчәлекне, иген басуларын пиратлар харап итә бит инде. Алардан котылу чарасын, бәлки, хуҗасы Сайрес Смит үзе уйлап табар дип яссытаулыкка афәт килүен аңа хәбәр итәргә булган.

Хәбәр илтергә Юпны җибәрергә уйлаган. Маймылның гаять акыллы, үтә сизгер икәнлеген белә иде ул, моны ничәмә-ничә тапкыр сынаганы бар иде. Юп «утар» дигән сүзне аңлый, чөнки ул сүзне күп ишеткәне бар. Укучылар хәтерлидер әле: маймыл еш кына Пенкроф белән бергә арбага утырып мал утарына йөри иде. Әле төн караңгы, таң яктысы иңмәгән. Елгыр маймыл сиздермичә генә урман аша узып китә алыр; әгәр пиратлар аны күрә калсалар да, урман ешлыкларында яшәүче маймылларның берсе дип уйларлар.

Наб, күп икеләнеп тормыйча, Юпның муенына хат салган янчык аскан да аны Гранит сарай ишеге төбенә алып килгән. Ишектән җиргә хәтле озын бау төшереп җибәргән һәм:

— Юп! Юп! Утар! Утар! — дип берничә тапкыр кабатлаган.

Маймыл аның ни әйтергә теләгәнен шундук аңлаган, арканга тотынып, аска шуып төшеп киткән һәм караңгыга кереп тә югалган, пиратлар аны сизмичә дә калганнар.

— Син әйбәт уйлагансың, тик безгә пиратлар ха-

кында кисәтмәгән булсаң да ярыйсы икән...— диде Сайрес Смит.

Сайрес Смит бу сүзләре белән Гербертның хәленә ишарәләде: егет савыгып килә иде бит, юлда өзлегеп кенә хәле авыраеп китте.

Наб хикәясенең азагын сөйләп бетерде. Пиратлар яр буена бүтән килеп чыкмаганнар. Алар утрау халкының күпме икәнен белмиләр, Гранит сарайны яхшы коралланган отряд саклый дип уйлыйлар, күрәсең. Бригның һөҗүменә каршы утрауның аскы һәм өске кыяларыннан көчле ут белән җавап бирүләрен хәтергә төшергәннәрдер, тагын ут эченә барып керәселәре килмәгәндер. Ә Күзәтү яссылыгына юл ачык, анда аларга Гранит сарайдан атсалар да тидерә алмаячаклар. Һәм җинаятьчеләр яссытаулыктагы хуҗалыкны ерткычларча ярсый-ярсый җимерергә-кырырга, таларга-яндырырга керешкәннәр. Явызлана-явызлана үч алганнар. Утрау хуҗалары кайтып җитәргә ярты сәгать кала гына урман эченә чигенгәннәр, алар юлчыларны һаман мал утарында ябылып утыра дип уйлаганнар, күрәсең.

Наб, алар китүгә, торактан чыгып, дошман пулясыннан да курыкмыйча, тизрәк яссытаулыкка чапкан. Ул терлек абзарларының янгынын сүндерергә азапланган. Урман авызында арба күренгәнче ут белән көрәшкән.

Утрауда әнә шундый аянычлы хәлләр булып алды! Линкольн утравы хуҗаларына хәзер адым саен пиратлар һөҗүменнән сакланырга кирәк иде. Моңа хәтле алар бик бәхетле яшәгәннәр икән! Ә хәзер алар адым саен афәткә, адым саен хәвеф-хәтәргә юлыга башладылар.

Гедеон Спилет белән Пенкроф Гранит сарайда Герберт янында калдылар. Ә Сайрес Смит, Набны алып, яссытаулыкка китте, юлбасарларның кылган явызлыкларын үз күзе белән күрергә теләгән иде ул.

Бәхетләре, талаучылар Гранит сарай итәгенә үк килеп җитмәгәннәр, югыйсә Хәрабәдәге мастерскойны тармар китергән булырлар иде. Хәер, анысы ярты бәла булыр иде ичмасам. Ә Күзәтү яссылыгында әнә кара күмер белән җимерекләр өеме генә калган!

Сайрес Смит белән Наб Рәхмәт елгасына җиттеләр, күпер аша елганың сул як ярына чыктылар, ә пиратлар елга аша узмаганнар, күрәсең; ул-бу сизелмәде. Теге як ярдагы урман эчендә дә шикле нәрсәләр күренмәде.

Алар соңыннан булган хәлләрне болайрак күз алдына китерделәр: пиратлар утрау хуҗаларының мал утарыннан кайтуын күреп калып, хәзер Гранит сарайда икәнлекләренә ышангач, кире утарга киткәннәрдер, чөнки анда мал-мөлкәтнең күплеген беләләр. Яисә Рәхмәт елгасы буйлап түбән таба төшеп, Җакамар урманына кереп киткәнлектән, юлчыларның кайтуын күрми калганнардыр. Ул очракта үз лагерьларына кайтып, яңадан һөҗүм башларга җай чыкканны көтеп торалардыр.

Хәзер аларның үзләренә искәрмәстән һөҗүм итәргә кирәк иде, әмма Герберт савыкмыйча, утрау хуҗалары аны ташлап чыга алмыйлар. Сайрес Смит барысының бергә булуын тели, шуңа күрә берәүгә дә Гранит сарайдан чыгып йөрергә рөхсәт итмәде.

Инженер белән Наб Күзәтү яссылыгына менеп җиткәч, андагы афәтне күреп, тынсыз калдылар! Иген басуы тапталып беткән, өлгергән ашлык җиргә егылып коелган. Бөтен яшелчәлекне аркылыга-буйга казып-актарып чыкканнар. Әле дә, бәхетләренннән, Гранит сарайда кара көнгә дип салып куйган орлыклары саклана иде.

Ә җил тегермәне, кош кетәге, онагр абзарлары урынында кара кисәүләр генә көйрәп ята. Исән калган терлекләр Күзәтү яссылыгының төрле ягына таралышып беткәннәр. Янгын вакытында күлнең аргы башына очып киткән кош-кортлар, кире кайтып, яр буенда чырчу килеп каңгырышып йөриләр. Кыскасы, мондагы хуҗалыкны яңадан юктан бар итәргә кирәк иде.

Сайрес Смит ап-ак агарынып, ачуын көчкә тыеп, озак басып торды. Тапталып-изелеп беткән басу-кырларга, пыскып яткан күмер өемнәренә соңгы тапкыр күз салды да, ләм-мим дәшмичә борылып, Гранит сарайга кайтып китте.

Линкольн утравы хуҗаларына кайгылы, авыр көннәр килде. Утрауда яши башлаганнан бирле аларның башына мондый да ачы хәсрәт төшкәне юк иде әле. Герберт күз алдында сызып бара. Каты ярадан сәламәтлеге тәмам какшаган егетнең хәле, өзлегүдән соң, тагын да начарайды. Гедеон Спилет авыруның хәле өметсез икәнен күреп тора, әмма бу каты чиргә каршы көрәшергә бер чара да таба алмый аптырады.

Герберт ярым хушсыз ята. Хәзер саташа да башлады. Аларның хәл керткеч төнәтмәдән башка дарулары юк иде. Егетне бизгәк калтыратырга тотынды.

Гедеон Спилет бу яңа чирне 6 нчы декабрьдә сизеп алды. Егетнең бармаклары, борыны, колак яфраклары балавыздай саргаеп китте, бөтен тәнен калтырату алды, теше тешкә бәрелеп шык-шык килде. Йөрәге әле котырып тибә, әле сүлпәнәя иде. Тәне корышты, тамагы чатнап кипте. Тәне каты кызыша иде, күзләре сәер ялтырый, бит урталары кызарып чыкты, йөрәге дөп-дөп кага башлады, бөтен тәне манма тир булды һәм шуннан соң тәненең кызуы сүрелә төште, калтыратуы басылды. Бизгәк өянәге биш сәгатькә сузылды.

Гедеон Спилет Герберт яныннан бер генә секундка да китмәде. Ул егетне өянәкле бизгәк тотуын аңлады. Бизгәкне ничек тә туктатырга кирәк иде, югыйсә аның ахыры яман булачак иде.

Гедеон Спилет Сайрес Смитка:

— Бизгәкне туктату өчен дару табарга кирәк,— диде.

— Дару!.. Каян табабыз аны? Бездә хин агачы каерысы юк бит, хинин даруы да юк!

— Хинин юк, дөрес анысы. Әмма күл буенда тал агачы үсә, тал каерысы хининны алыштыра ала.

— Әйдәгез, тизрәк сынап карыйк, вакытны әрәм итмик! — диде Сайрес Смит.

Чыннан да, тал каерысы әзме-күпме хин агачы каерысын алыштыра ала иде. Һиндстан кәстәнәсе каерысы, энә агачы яфрагы, «аждаһа тамыры» һәм башка кайбер үсемлекләр дә хинны алыштыра ала икән. Һәрхәлдә, күл астында булган чараны сынап карарга кирәк иде. Хин агачыннан калышса да, тал каерысын табигый хәлендә кулланырга булдылар, чөнки тал каерысындагы алколоидны — ягъни салицинны саф хәлендә аерып алу мондагы шартларда мөмкин түгел иде.

Сайрес Смит, күлгә барып, «кара тал» каерысын каезлап алып кайтты; аны төеп, төнәтмә ясап шул кичтә Гербертка эчерделәр.

Төн тыныч узды. Герберт саташып ятса да, бизгәк өянәге төнлә дә, иртәгесен дә кабатланмады.

Пенкрофның рухы күтәрелеп китте, әмма Гедеон Спилет бөтенләй үк өметләнерлек сүз әйтә алмады әле. Бизгәкнең өянәге көн саен булмыйча, көн аралаш кабатланадыр, хикмәт шундадыр дип уйлады. Һәрхәлдә, монысы иртәгә генә мәгълүм булачак. Гранит сарай хуҗалары иртәгесе көннең җитүен котлары очып көттеләр!

Өянәк узганнан соң Гербертның бөтен гәүдәсе вагылып-хәлсезләнеп калды, башы томанлы, күз аллары караңгы иде. Гедеон Спилет бизгәкнең тагын бер нәтиҗәсен күреп куркуга төште: Гербертның бавыры бик зурайган, шешкән иде; тиздән аның саташуы да көчәйде, авыру мигә үк бәргәндер ахрысы.

Гедеон Спилет бу хәлне күреп бөтенләй үк каушап калды. Инженерны читкә чакырып алды да:

— Бу — яман бизгәк! — диде.

Сайрес Смит, коты чыгып:

— Яман бизгәк? — дип кабатлады.— Ялгышмыйсызмы, Спилет. Яман бизгәк кинәттән башланмый бит ул. Электән үк үзен сиздерергә тиеш иде.

— Юк, ялгышмыйм,— диде журналист.— Герберт аны мондагы сазлыктан эләктергәндер. Беренче өянәге узып китте, үзегез күрдегез. Тиздән икенчесе килергә тиеш. Әгәр өченче өянәгенә хәтле авыруны туктата алмасак... Герберт һәлак булачак.

— Ә тал каерысы ярдәм итмәсме?..

— Ярдәм итмәс,— диде Гедеон Спилет.— Яман бизгәкнең өченче өянәгенә кеше түзә алмый, үлә.

Бәхеткә каршы, бу сүзләрне Пенкроф ишетмәде. Кайгысыннан акылын җуяр иде бичара.

7 нче декабрьдә көне буе һәм төне буе Сайрес Смит белән Гедеон Спилет кичергән газапларны сөйләп аңлатырлык түгел иде.

Иртәгесен төш вакытында икенче өянәк башланды. Авыру үз-үзен белешмичә үлем белән көрәшеп ята иде. Үләсе килмичә, инәлеп кулларын Сайрес Смитка таба, Гедеон Спилет белән Пенкрофка таба суза. Бу газапны йөрәк күтәрерлек түгел иде. Пенкрофны бүлмәдән алып чыгып китәргә туры килде.

Икенче өянәк тә биш сәгатькә сузылды. Авыруның өченче өянәккә түзә алмаячагы көн кебек ачык иде.

Төн коточкыч авыр узды. Герберт төне буе саташып чыкты. Аның үз-үзен белешмичә сөйләнгән сүзләреннән йөрәкләр телгәләнеп бетте. Ул ятагында бәргәләнә, бертуктаусыз ниләрдер кычкыра; имеш, ул пиратлар белән сугыша, Айртонны үз янына дәшә. Каядыр юкка чыккан шәфкать иясен чакыра, аннан ярдәм сорап инәлә. Бәргәләнүдән туктагач, хәлсезләнеп, изелеп кала, аңсыз ята... Гедеон Спилет берничә тапкыр аны үлгән дип коты очты...

Иртәгесен, 8 нче декабрьдә, Гербертның хәле тагын да авырайды. Ябыгып калган хәлсез бармаклары одеял читен капшады. Аңа төелгән тал каерысын яңадан эчертеп карадылар, әмма Гедеон Спилет аның шифасы тияр дип өметләнми дә иде инде.

— Әгәр иртәгә хәтле без Гербертка бизгәкне баса торган көчле дару табып эчермәсәк, ул түзә алмас! — диде.

Төн житте. Гербертның соңгы төне иде бу! Үз яшенә караганда күп акыллы, түзем, мәрхәмәтле малай соңгы сулышларын сулый иде. Аны барысы да үз улыдай яраталар иде, әмма коткарырга берсенең дә хәленнән килми! Яман бизгәк чирен җиңә торган бердәнбер дару Линкольн утравында табылмады!

Сигезенче декабрьдән тугызынчы декабрьгә каршы төнне авыру бертуктаусыз саташты. Бавыры кабарып шеште. Зиһене томаланды. Герберт беркемне танымый башлады.

Таң атканчы түзә алырмы-юкмы? Өченче өянәген ул күтәрә алмаячак. Гербертның соңгы көче сызып бетеп бара. Саташуларыннан арынган арада ул үле кебек ята башлады.

Иртәгесен сәгать өчләр тирәсендә Герберт кинәт ачыргаланып бер сулкылдап куйды да үлем әчесе белән тартыша башлады. Аны саклап утырган Наб коты очып күрше бүлмәгә ярдәм сорап йөгереп чыкты, анда бүтән иптәшләре йокламыйча утыра иде.

Шул чакны Топ сәер итеп өрә башлады.

Һәммәсе Гербертның бүлмәсенә атылып керделәр, үлем исереклеге белән ятагыннан идәнгә сикереп төшәргә азапланган егетне көчкә тотып калдылар. Гедеон Спилет Гербертның кулыннан тамыр тибешен эзләп тапты, егетнең йөрәге болай тигез тибә иде.

Сәгать бишләр тирәсе иде. Яңа чыгып килгән кояшның нурлары Гранит сарай тәрәзәсеннән үтеп керде. Аяз, матур көн туып килә, бичара малайның гомерендәге соңгы көн.

Карават янындагы кечкенә өстәлгә кояш яктысы төшүгә, Пенкроф кинәт «аһ!» итеп куйды, өстәлдә кай арададыр пәйда булган озынча тартмага төртеп күрсәтте.

Тартма капкачына «хинин» дип язылган иде.

Унберенче бүлек

Аңлаешсыз сер.— Герберт савыга.— Экспедициягә әзерлек.— Беренче көн.— Төн.— Икенче көн.— Каури.— Кавуарлар.— Урманда кеше эзләре.— Елан борыны.

Гедеон Спилет тиз генә тартманы кулына алды да ачып карады. Аның эчендә ике йөз гран[1] чамасы ак төстәге порошок бар иде. Журналист порошокны чеметеп авызына капты. Әрем әчесеннән дә зәһәррәк әче тәм авызын өтеп алды, бу — хин агачы каерысыннан табыла торган кыйммәтле алколоид, бизгәккә каршы көчле дару — хинин иде.

Тартма монда каян килгән соң, дип озак баш ватып тормыйча, Гербертка хинин порошогын тизрәк эчерергә кирәк иде. Анысын соңыннан да тикшерергә өлгерерләр.

— Кофе! — дип сорады Гедеон Спилет.

Наб күз ачып йомганчы бер чокыр җылы кофе китерде. Гедеон Спилет, чокырга унсигез гран чамасы хинин салып, Гербертка эчерде.

Әле соң түгел, яман бизгәкнең өченче өянәге башланмаган!

Шәт, бизгәкнең өченче өянәге килмәс тә инде!

Һәммәсенең күңеле күтәрелеп китте. Серле илаһи көчтән инде беркем мәрхәмәт көтмәгән чакта, аңардан бөтенләй дә өмет өзелгән чакта, ул тагын ярдәм кулын сузды.

Бер сәгатьтән Герберт тыныч йокыга талды. Хәзер дуслар бу хәлләр турында иркенләп фикер алыша алалар иде. Серле затның ярдәме бу юлы бигрәк тә ачыктан-ачык булды инде. Гранит сарайга, җитмәсә төн уртасында ничек керә алган соң ул? Моны күз алдына да китерерлек түгел иде. Утраудагы бөек серле затның бөтен гамәлләре, үзе кебек үк, аңлашылмаслык табышмак булып кала бирде.

Гербертка өч сәгатьтән өч сәгатькә хинин эчертеп тордылар.

Икенче тәүлектә аның хәле уңайга китте. Әле савыгып җитте дип әйтергә иртәрәк иде, бизгәк чиренең каткат кире кайтарып алу гадәте бар аның. Әмма егетнең иптәшләре аны шифалы дару белән тырышып дәвалыйлар; дару табып китерүче кеше үзе дә кайдадыр шушы

[1] **Гран** — аптека үлчәве, 0,0622 граммга тигез.

тирәдә генә яши, күрәсең. Кыскасы, һәркайсының күңелендә якты өметләр терелде.

Өметләре алдамады. Ун көннән, 20 нче декабрьдә, Герберт савыга башлады. Әлегә бик хәлсез иде ул, әмма бизгәк өянәге бүтән кабатланмады. Акыллы егет врач кушканнарны төгәл үтәп бара, чөнки аның бик тә савыгасы килә иде!

Пенкроф үзе дә үлем хастасыннан терелгәндәй булды. Өченче өянәк килергә тиешле вакыт имин генә узып киткәч, шатлыгыннан шашар чиккә җиткән диңгезче Гедеон Спилетны кысып кочаклады, чак буып үтермәде. Моннан соң ул журналистка ихтирам белән *доктор* дип дәшә башлады. Мәгәр һәммәсенең дә теге чын дәвалаучыны күрәселәре килә иде.

— Сабыр итегез, күрербез әле, күрербез,— дип үзенекен сөйләде Пенкроф.

Декабрь ае узып китте. 1867 нче ел бетте. Иске елда Линкольн утравы хуҗаларының башыннан авыр сынаулар узды.

1868 нче Яңа ел кояшлы аяз көннәре белән килде. Зәп-зәңгәр күк йөзендә ялт итеп кояш көлеп тора. Көн түзеп булмаслык эссе. Бәхеткә каршы, диңгез ягыннан искән талгын җил кызуны бераз сүрелдерә төшә.

Гербертка әкренләп тереклек көче керә бара. Аның ятагын Гранит сарай тәрәзәсе янына ук китереп куйдылар. Тәрәзәдән кергән терелткеч диңгез һавасын егет күкрәгеп тутырып сулый, тозлы диңгез җиле аңа шифалы сулышын өрә. Аның хәзер ашыйсы гына килеп тора. Наб моңа куанып бетә алмый. Ул яшь дустына тәмле-тәмле туклыклы җиңел ризыклар пешерә. Бу хәлгә хәтта Пенкроф та, көнләшкәндәй:

— Валлаһи, үземнең дә каты авырыйсым килә башлады,— дип шаярта иде.

Бу вакыт эчендә пиратлар Гранит сарай тирәсендә бер генә тапкыр да күренмәделәр. Айртоннан да хәбәр юк иде. Сайрес Смит белән Герберт аны тере килеш табарбыз дип өметләнәләр, ә калганнар исә Айртон һәлак булгандыр дип уйлыйлар. Шулай да бу билгесезлек артык озакка сузылды, шуңа күрә дуслар Герберт терелү белән сәяхәткә чыгарга сүз бирделәр, чөнки бу сәяхәтнең максаты алар өчен бик тә мөһим иде. Мәгәр юлбасарларны җиңү өчен барысы да походка катнашырга тиеш булганга, тагын бер айсыз да юлга чыгып китә алмаслар әле.

Ә Гербертның хәле көннән-көн яхшырды. Бавырының шеше бетте, җәрәхәтләре төзәлде.

Январь аеның буеннан-буена алар Күзәтү яссылыгында эшләделәр. Исән калган игенне, яшелчәләрне җыеп алдылар. Яңа чәчү өчен орлыклар әзерләделәр, яшелчә үсентеләре утырттылар. Тегермәнне, ат абзарларын, кош кетәгендәге каралтыларны Сайрес Смит яңадан төзергә ашыкмады. Чөнки алар юлбасарларны эзләп чыгып киткән арада, теге кабахәтләр үзләре яңадан монда килеп чыкмагае. Ул эт җаннарга яңадан бар нәрсәне талап, яндырып хәкарәтләргә ирек бирсеннәрме? Утрауны ул хәшәрәтләрдән әрчегәч барысын да яңадан төзергә мөмкин бит.

Январь уртасы узгач, авыруга урыныннан торырга рөхсәт иттеләр, башта көнгә бер сәгать, аннары ике, аннары өч сәгать йөрергә куштылар. Егетнең электән нигезе нык булганлыктан, көч тиз керде. Бу арада аңа унсигез яшь тулып китте. Буйга да тартылып үсеп бара, чибәр, сөйкемле егет булып җитеп килә иде. Кырыс «доктор» Спилет авыруны әле тәмам сәламәтләнеп житкән исәпләми, дәвалауны үз җае белән алып бара иде.

Ай ахырында Герберт Күзәтү яссылыгына, яр буйларына чыгып йөри башлады. Пенкроф белән Набка ияреп берничә тапкыр диңгездә су коенды, диңгез суы аңа шифалы иде. Сайрес Смит сәяхәткә чыгу көнен 15 нче февральгә билгеләде. Елның бу вакытында төннәр якты була, утраудагы эзләнүләр вакытында бу файдага гына иде.

Походка әзерлек башланды. Алар ике максатны күздә тоталар: беренчедән, пиратларны юк итү һәм, әгәр исән булса, Айртонны табу; икенчедән, үзләренә зур булышлык күрсәткән шәфкать иясен белергә тырышу — шунсыз Гранит сарайга кайтмаска исәпләре. Шуңа күрә юлга җитди әзерләнергә уйлыйлар.

Линкольн утравының кайбер урыннарын алар һәр карышына хәтле беләләр; мәсәлән, Тырнак борыныннан алып Көньяк һәм Төньяк Казна борынына хәтле булган яр буйларын, Үрдәк сазлыгын, Грант күленең көньяк очын, Жакамар урманының Рәхмәт елгасы белән утар юлы арасындагы өлешләрен, Рәхмәт елгасы һәм Кызыл инеш яры буйларын, Франклин тавының мал утары урнашкан тирәләрен.

Алар Тырнак борыныннан алып Елан борынына хәтле Вашингтон бухтасының тирә-ягын, утрауның көн-

батыш яры буйларындагы урман һәм сазлыкларны, акула авызын хәтерләткән култыкка хәтле сузылган ком көртләрен дә өстән-өстән булса да тикшергәннәр иде инде.

Әмма алар Борылмалы ярымутрауны тоташ каплап алган кара урманнарны, Рәхмәт елгасының уң як яр буйларын, Шарлавык елгасының сул як ярын, Франклин тавының көнбатыш, төньяк һәм көнчыгыш сыртларын, тарлавыкларын, үзәнлекләрен бөтенләй дә белмиләр иде, анда тирән-тирән тау куышлары булуы да ихтимал бит.

Башта мал утарына тиеп китсәләр начар булмас иде булуын, чөнки пиратлар анда барып чыгып, төпләнеп калулары мөмкин. Әгәр пиратлар, аулак урын санап, анда урнашып калган булсалар, талыйсын талаганнардыр инде, аны кайтара алмаслар. Димәк, анда бүтән вакытта да барырга өлгерерләр.

Үзара киңәшкәч, алар теге чакта уйлашкан вариантка тукталдылар — урман аша Елан борынына таба юнәлергә хәл иттеләр. Уналты-унҗиде миль араны алар агачларын кисеп, куакларны балта белән чабып, юл салып барырга тиеш иде. Киләчәктә ул Борылмалы ярымутрауны Гранит сарай белән тоташтыра торган юлга әвереләчәк.

Арба төзек, онагрлар яхшы ял иткән, ерак юлга чыгарга әзер иделәр. Арбага азык-төлек, юлга кирәкле әйбер-сәйбер, поход кухнясы, савыт-саба, Гранит сарайның бай арсеналыннан сайлап алынган сугыш кораллары, сугыш кирәк-яраклары төялде. Пиратлар, бәлкем, урманда качып йөриләрдер. Агач арасыннан посып торып, ут ачарга да күп сорамаслар. Шуңа күрә сәяхәтчеләргә вак төркемнәргә бүгәләнергә, таркалырга ярамый. Гранит сарайда беркемне дә калдырмаска, хәтта Топ белән Юпны да сәяхәткә алырга туры киләчәк. Үтеп керә алмаслык ныгытмадай тораклары вакытлыча саксыз да кала ала.

Иртәгә юлга чыгасы дигән көн, 14 нче февраль, якшәмбегә туры килде. Көне буе ял иттеләр, аллага гыйбадәт кылдылар. Авырудан яңа савыккан, хәлсезрәк Гербертка арбага утырып барырга киңәш иттеләр.

Иртәгесен таң атуга Сайрес Смит үзләре юкта берәрсе Гранит сарайга бәреп кермәсен дип, саклык чаралары күрергә кереште. Үзләре элек файдаланган бау баскычны Хәрабәгә илтеп, тирән чокыр казып, комга

күмделәр; кайткач казып алып, Гранит сарайга шуның белән менәрбез дип уйладылар; күтәрткеч кәрзинне, чыгырларны сүтеп, эчкә кертеп куйдылар. Анысын Пенкроф башкарды; эше беткәч, кыя киртләченә эләктергән аркан буйлап җиргә шуып төште дә, арканны аска тартып алдылар. Гранит сарайга менәрлек җай калмады.

Һава әйбәт иде.

— Бүген көн бик кызу булачак! — диде журналист куанып.

— Зыян юк, доктор Спилет. Без урман эченнән агачлар ышыгыннан барачакбыз, кояшны сизмәбез дә әле,— диде Пенкроф.

— Кузгалдык! — диде инженер.

Арба аларны Хәрабә янында, яр буенда көтә иде; журналист Гербертка башта гына булса да утырып барырга кушты. Егет врач киңәшенә буйсынырга мәҗбүр булды.

Наб онагрларны йөгәненнән тотып алды. Сайрес Смит, журналист һәм диңгезче алдан җәяү атладылар. Топ аларга иярүенә бик тә шатланып яннарыннан сикергәләп бара. Герберт маймылны үз янына арбага чакырган иде, тегесе ялындырып тормыйча шундук менеп тә утырды.

Кечкенә төркем сәяхәткә кузгалды.

Арба гранит стенаның чатына җитеп борылды да Рәхмәт елгасының сул як яры буйлап өскә таба менеп китте, бер миль узгач, күпер аша теге якка чыкты; аннан Һава шары портына бара торган юл башлана иде. Юлны сул якта калдырып, алар Ерак Көнбатыш урманының биек агачлары ышыгына эчкә кереп киттеләр.

Агач аралары иркен, арба узарлык иде; кайчакларны гына юлчыларга чәбәләнеп беткән лианаларны, куе куакларны балта белән чабып, юл салырга туры килә. Ике миль арада әллә ни искә алырлык тоткарлык очрамады.

Киң ябалдашлы агачлар ышыгында күләгә, салкынча рәхәт иде. Әйләнә-тирәдә очсыз-кырыйсыз урман патшалыгы хөкем сөрә; биек-биек деодар, дуглас, казуарин, банксия, драцена һәм башка төрле агачлар күккә үк үрләп үсеп утыралар.

Биредә утрауның барлык төр кошлары: көртлекләр, жакамарлар, фазаннар, чыр-чулы какадулар, аллыгөлле тутыйлар очрый. Куак араларыннан агутлар,

көңгерәләр, су дуңгызлары чабышып уза. Болар барысы да утраудагы беренче сәяхәтне хәтерләтә.

— Шулай да ниндидер үзгәреш барлыгы сизелә. Җәнлекләр дә, кошлар да элеккегә караганда куркаграк. Бандитлар бу тирәдән узган булса кирәк, аларның эзләре очрар әле, менә күрерсез,— диде Сайрес Смит.

Чыннан да, бара торгач, аның сүзен раслый торган әле теге, әле бу билгеләр очрый башлады: аларга карагач, күптән түгел генә биредән бер төркем кеше узганлыгын сизәргә мөмкин иде: әнә агачның ботагын сындырып киткәннәр, кире кайтканда юлны табу өчендер, күрәсең, менә монда учак көле өелеп калган, кызыл балчыклы җирләрдә аяк эзләре ярылып ята. Әмма озакка тукталып яшәгән урыннары очрамады.

Инженер иптәшләренә киек ауларга рөхсәт итмәде. Пиратлар, бәлкем, әле дә урманда йөриләрдер, мылтык тавышын ишетеп калырлар. Җитмәсә, киек аулар өчен, телиләрме-юкмы урман эченәрәк керергә туры килер иде, ә Сайрес Смит аерылып йөрергә катгый каршы килде.

Гранит сарайдан алты миль чамасы киткәч, төштән соң баруы кыенлашты. Урыны-урыны белән урман ерып керә алмаслык куерып үскән; балта белән агачларны чабып аударып кына сукмак салырга мөмкин иде. Ешлыкка керердән элек Сайрес Смит Топ белән Юпны әйләнә-тирәне күзәтергә алга таба җибәрә иде; алар үз вазифаларын намуслы рәвештә үтәргә атлыгып торалар. Күзәтчеләр хуҗалары янына тыныч кына әйләнеп кайтса, димәк, урманда шикле нәрсә юк: ерткычлар да, пиратлар да сагаламый дигән сүз иде.

Сәяхәтчеләр Гранит сарайдан тугыз миль чамасы киткәч, кичкә Рәхмәт елгасына коючы, монарчы мәгълүм булмаган кечкенә генә инешкә юлыктылар, шунда тукталыш ясарга булдылар. Утрау туфрагының гаять уңдырышлы булуының сәбәпләреннән берсе шушындый инешләрнең күп булуы, җирне мул сугаруы иде.

Юлда килгәндә һәммәсе бик тә ачыкканнар иде, кич әйбәтләп ашагач, йокларга яттылар. Төнлә хәвеф-хәтәрдән саклану чаралары күрергә туры килде. Ерткыч җанварлардан, ягуарлардан саклану өчен, Сайрес Смит тирә-якка берничә учак ягарга кушу белән чикләнер иде,— чөнки андый очракта иң ышанычлысы ут булыр иде; әмма бүген учак ялкыны пиратларның игътибарын

гына тартуы мөмкин. Шуңа күрә учак якмаулары хәерлерәк, төннең карангылыгы алар файдасына гына.

Алар төнгә сак куйдылар: икешәр кеше ике сәгать саен алмашлап каравылда торырга тиеш булды. Ни карышса да, Гербертны кизүдән азат итәргә туры килде. Пенкроф белән Гедеон Спилет һәм Сайрес Смит белән Наб — ике пар — йоклаучылар тирәсендә йөренеп тордылар.

Хәер, төн кыска булды. Биредә тирә-якның карангылыгы, кояш юклыктан бигрәк, күк йөзен каплаган агач ябалдашларының куе күләгәсеннән иде. Тынлыкны ара-тирә ягуарларның карлыккан тавыш белән үкерүе, маймылларның каһкаһәләп көлүе боза иде.

Төн имин генә узды. Иртәгесен, 16 нчы февральдә, сәяхәтчеләр урман аша юлларын дәвам иттерделәр. Юл авыр иде, бик әкрен барырга туры килде.

Әледән-әле тукталып, балта белән агачларны чабып аударып юл салып барырга туры килгәнлектән, көне буена фәкать алты миль уздылар. Үзләрен табигатьнең чын хуҗасы итеп санаганлыктан, зур-зур матур агачларга кул салырга кызганалар алар. Аннары теләсәләр дә мәһабәт агачларны егуы ансат булмас иде. Шуңа күрә кечерәк агачларны, куакларны чабарга тырышалар. Шунлыктан юл турыдан салынмый, борыла-сырыла барырга туры килә, нәтиҗәдә ул озыная.

Бүген Герберт утрауда моңарчы очрамаган яңа төр агачлар күрде. Әнә агач сыман абаганың каурыйдай яфраклары югарыдан агып төшкән фонтан суларын хәтерләтә; мөгез агачының озын, татлы кузакларын ашарга ябышкан онагрларны һич тә аерып алып булмый. Таң калырлык матур, гигант каури агачлары монда да очрады аларга. Тезелеп торган колонналарны хәтерләтеп, икешәр йөз фут биеккә менеп киткән төз кәүсәләр очындагы яшел ябалдашлар бөтен күк йөзен каплаган. Яңа Зеландия урманнарының патшасы саналган бу пәһлеван агачлар Ливан эрбетләре кебек бөтен дөньяга танылган.

Бу урманнарда моңарчы утрауда очраган җанварлар гына яши икән. Дөрес, аучылар Австралиядә яши торган бер пар бик зур кош күреп калдылар: бу — казуарларның бер төре — эму иде; метр ярым биеклеге бу көрән каурыйлы кошлар чеүән аяклылар отрядына керәләр. Топ җан-фәрман алар артыннан куып караган

иде дә, кая ул, эмулар тоттырамы соң, алар яшен уты кебек ялт итеп шундук юкка чыктылар.

Сәяхәтчеләр бандитларга юлыкмадылар юлыгуын, тик эзләре тагын да очраштыргалады. Күптән түгел сүнгән учак көле, учак тирәсен чуарлаган кеше аягы эзләре күренде. Табан эзләрен бик җентекләп тикшергәч, озынлыгын-киңлеген үлчәгәч, монда биш кеше булып киткәнлеген ачыкладылар. Биредә алар тукталыш ясаган булса кирәк; ләкин ни тырышсалар да алтынчы кешенең, Айртонның, аяк эзен тапмадылар. Димәк, Айртон пиратлар белән бергә түгел.

— Айртон алар белән түгел! — диде Герберт.

Пенкроф та аның сүзен раслады:

— Алар белән түгел шул,— диде.— Айртон алар белән булмагач, димәк, ул кабахәт җаннар аны үтергәннәрдер. Бу явыз ерткычларның кереп ышыкланыр өннәре дә юк ахрысы. Өннәре булмагач, аларны юлбарыс аулаган кебек аулап та булмаячак.

— Күренеп тора шул, аларның өннәре юк. Шуңа күрә урман арасында теләсә кайда искәнеп йөриләрдер. Алай кулайрак аларга. Утрауның хуҗасы булыр сәгать сукканын көтәләр,— диде журналист.

— Утрауның хуҗасы дисеңме? — дип үртәлеп кычкырып җибәрде диңгезче. Кемдер тимер кулы белән бугазына ябышкандай тавышы гырылдап чыкты: — Утрауның хуҗасымы! — дип кабатлады. Аннары тынычланып әйтеп куйды: — Минем мылтык нинди ядрә белән корылган, беләсезме сез, мистер Сайрес?

— Юк, Пенкроф, белмим!

— Гербертның күкрәген үтәли тишеп чыккан ядрә белән. Тыныч булыгыз, ул инде төзәгән җиренә тими калмаячак!

Әмма аның үче нихәтле гадел булмасын, барыбер Айртонны үлемнән терелтә алмас иде. Юеш җирдә аермачык күренеп яткан аяк эзләренә караганда, Айртонны тере килеш табудан өмет өзәргә кирәген төшенделәр алар.

Гранит сарайдан ундүрт миль киткәч, кич белән төн кунарга туктадылар; Сайрес Смит, Елан борынына биш мильдән дә ары калмады, диде.

Чыннан да, иртәгесен борынга тиз барып җиттеләр. Урманны үтәдән-үтә кичеп чыксалар да, пиратларның яшеренгән урынын белә алмадылар, шулай ук серле шәфкать иясенең дә торган җире табылмады.

Уникенче бүлек

Борылмалы ярымутрауны тикшерү.— Шарлавык елгасы тамагында тукталыш.— Мал утарына йөз адымлап калды.— Гедеон Спилет белән Пенкроф күзәтергә киттеләр.— Алар әйләнеп кайтты.— Алга! — Ишек ачык.— Тәрәзәдә ут елтырый.— Ай яктысында.

Иртәгесен, 18 нче февраль көнне, алар Елан борын備ннан алып Шарлавык елгасына хәтле диңгез яры буйларын тикшерүгә багышладылар. Ярымутрауның яры буйлап өч-дүрт миль киңлектә сузылган тоташ урманның һәр карыш җирен бик җентекләп карап чыктылар. Ботакларын киң җәеп үскән агачларга карагач, монда туфракның гаять уңдырышлы икәненә куанып бетәрлек түгел иде. Утрауның иң уңдырышлы җирләре шушындадыр, күрәсең. Гүя бирегә, уртача климатлы төбәккә, Америка һәм Үзәк Африканың кеше кулы-аягы тимәгән тропик урманнарыннан бер кисәген китереп урнаштырганнар. Өстә дым мул булганга, астан вулкан уты җылытканга, үсемлекләр биредә уртача климатлы җирләргә хас булмаганча, котырып үскәннәр. Күбесенчә пәһлеван каурилар, эвкалиптлар гөрләп үсеп утыра.

Әмма сәяхәтчеләр бирегә табигать күренешләренә хозурланып йөрү өчен килмәделәр. Алар Линкольн утравының бу мәсьәләдә Бәхетле утраулар дип аталган Канар утраулары белән ярышуын беләләр иде. Ни аяныч! Хәзер Линкольн утравы аларныкы гына түгел шул,— кансыз ерткычлар бәреп керде; аларның берсен дә калдырмыйча кырып бетерергә кирәк.

Көнбатыш ярдан ни тырышып эзләсәләр дә, пиратлар табылмады: аяк эзләре дә, сынган ботаклар да, учак көлләре дә, тукталыш урыннары да очрамады.

Сайрес Смит иптәшләренә:

— Мин гаҗәпләнмим,— диде.— Бандитлар Табылдык борыны янында ярга чыгу белән Үрдәк сазлыгы аша Ерак Көнбатыш урманы эченә кереп киткәннәрдер. Алар без узган юлдан барганнар булса кирәк. Шуңа күрә без адым саен алар эзенә юлыктык. Көнбатыш ярга килеп чыккач, биредә кереп сыеныр почмак тапмасларына ышанып, төньякка борылганнардыр һәм безнең мал утарына килеп чыкканнардыр...

— Хәзер дә шунда кереп урнашканнардыр әле алар,— диде Пенкроф.

— Юктыр...— дип кире какты аның сүзен инженер.— Безнең шул тирәдән эзләгәнне төшенергә тиеш алар. Мал утары аларга азык-төлек, кирәк-ярак талау чыганагы гына. Анда төпләнеп калмаслар.

— Мин дә Сайресның фикеренә кушылам,— диде журналист.— Минемчә, пиратлар Франклин тавы арасына кереп ояларга тырышачаклар.

— Алай булгач, нигә уйлап торабыз соң, мистер Смит. Әйдәгез, утарга киттек! Алар белән эшне бетерергә кирәк. Нигә вакытны әрәм итәбез!

— Ашыкмыйк, дустым. Ерак Көнбатыш урманы эчендә әлеге тылсым иясенең торагы юк микән, шуны да белергә кирәк әле. Оныттыгызмыни, Пенкроф, безнең сәяхәтнең икенче максаты шул бит. Җинаятьчеләрне җәзаларга, ә мәрхәмәт иясенең изгелегенә изгелек белән җавап бирергә хәл иткән идек бит.

— Әйе шул, мистер Сайрес,— диде диңгезче.— Минем уемча, әгәр үзе күренергә теләмәсә, без серле әфәндене барыбер тапмаячакбыз.

Асылда Пенкроф һәммә иптәшләре уйлаганны әйтте. Билгесез шәфкать иясенең торагы да, үзе кебек үк, серле, яшерендер, әлбәттә.

Кич белән арба Шарлавык елгасы тамагына җитеп туктады. Гадәттәгечә, барлык саклык чараларын күреп, шунда төн кунарга әзерләнделәр. Иркен һавадагы тормышның, диңгез ягыннан искән җилләрнең, терелткеч урман һавасының шифасы тиде,— Герберт авырганга хәтле нинди көчле, таза булса, шул хәленә кайтты. Хәзер арбага утырып бармый, кәрванның алдыннан атлый иде.

Иртәгесен, 19 нчы февральдә, алар диңгез яры белән саубуллашып, елганың сул як яры буйлап агымга каршы менеп киттеләр. Ә елганың теге ягында күккә үрләгән әкәмәт рәвешле базальт кыялар торып калды. Елганың сул яры буйлап элекке сәяхәт вакытларында ук көнбатыш ярдан мал утарына сукмак салынган иде. Сәяхәтчеләрнең Франклин тавына хәтле алты миль чамасы барасылары бар.

Сайрес Смит иптәшләренә: елга үзәнен җентекләп күзәтә-күзәтә барып, сиздермичә генә мал утарына килеп җитәргә дә, әгәр анда пиратлар басып кергән булса,— аны сугышып алырга, әгәр буш булса,— шунда урнашып Франклин тавын тикшерергә кирәк дигән план тәкъдим итте.

Бу план бер тавыштан кабул ителде, чөнки аларның үз утрауларында чын хуҗа булып каласылары килә иде!

Юлчылар Франклин тавының иң зур ике сырты арасыннан кысылып диярлек барган үзән буйлап киттеләр. Агачлар елга яры буенда куе үскән, ә тау битләвенә менгән саен сирәгәяләр. Тирә-якта тау сыртларын тарлавыклар, чокырлар кискәләп уза, анда дошманга качып торырга уңай, шуңа күрә сакланып барырга туры килә. Топ белән Юпны алдан җибәрәләр: алар әле уң якка, әле сул якка куе агачлык арасына кереп китәләр. Бер-берсе белән җитезлектә, сизгерлектә ярышалар, күзәтче вазифасын намуслы рәвештә башкаралар. Әмма тау башыннан агып төшә торган бу елга буенда кемдер йөргәнлеген расларлык эзләр табылмады, якынтирәдә пиратларның барлыгы сизелмәде.

Кичке сәгать биштә арба мал утарының утыртма коймасы буена алты йөз адымнар кала туктады. Койма тирәли үскән биек агачларның ябалдашлары утарны каплап диярлек киткән иде.

Мал утарын дошман басып алмаганмы — иң элек шуны белергә кирәк иде. Әгәр анда бандитлар кереп оялаган булса, көн яктысында койма янына барырга куркыныч, Герберт язмышына тарулары мөмкин, шуңа күрә караңгы төшүен көтәргә булдылар.

Әмма Гедеон Спилет белән түземсез Пенкроф хәзер үк койма янына барырга атлыгалар иде.

— Юк инде, дусларым, караңгы төшкәнен көтегез. Нигә үлемгә ашкынасыз. Минем рөхсәтем юк,— диде инженер.

Диңгезче, буйсынырга теләмичә, сукранып алды:

— Йә инде, нигә тотасыз безне, мистер Сайрес!..

— Тынычланыгыз, зинһар, үтенәм, Пенкроф! — диде инженер.

Диңгезче, кыска гына итеп:

— Тынычланырга әзер! — диде дә матросларча иң ачы сүзләр белән сүгенеп җибәрде: дошманга булган бөтен зәһәрен шулай итеп тышка чыгарды.

Алар арба тирәсенә җыелыштылар. Сагаеп урманны күзәтеп басып тордылар.

Өч сәгатьләп вакыт узды. Җил тынды. Биек агачлар ышыгында тирән тынлык хөкем сөрә иде; шылт иткән тавыш чыкса да ишетелерлек иде. Нәзек ботакларның чыртлап сынуы да, аяк табаны астында кипкән яфрак-

лар кыштырдавы да, урмәләгәндә аста калып сытылган үләннәрнең чыштырдавы да,— кыскасы, берсе дә сизелми калмаска тиеш иде. Әмма әйләнә-тирәдә тынлык. Топ алгы аякларын сузып яткан да башын аякларына салган, тыныч кына карап ята.

Кичке сигезгә караңгы төште, күзәтчеләргә кузгалырга форсат туды. Гедеон Спилет белән Пенкроф икәүләп барырга теләк белдерделәр. Сайрес Смит аларга кузгалырга рөхсәт бирде. Топ белән Юпны арба янында калдырырга туры килде, югыйсә эт өреп, маймыл кычкырып тикмәгә дошманны сагайтулары мөмкин иде.

— Кирәкмәгән җирдә гайрәтләнмәгез. Сезнең бурыч — мал утарын сугышып алу түгел, бәлки дошманны күзәтү. Бандитлар анда оялаганмы-юкмы — шунысын гына белеп килегез,— диде.

— Ярый,— диде Пенкроф күндәм генә.

Ике күзәтче юлга кузгалып киттеләр.

Урманда, агачлар ышыгында, дөм караңгы, утызкырык адымнан берни күренми иде. Журналист белән Пенкроф бик сакланып атлыйлар, чак кына шикле аваз ишетелгән кебек тоелуга, туктап катып калалар. Чөнки һәр минут дошман мылтыгы шартлавы мөмкин дип уйлыйлар. Икесе берьюлы дошман пулясына азык булмас өчен бер-берсеннән шактый ара калдырып атлыйлар иде.

Биш минуттан Гедеон Спилет белән Пенкроф урман авызына килеп чыктылар; алда — алан, шуның аргы читендә мал утарының утыртма коймасы.

Алан әле караңгыланып җитмәгән, тонык кына яктырып тора. Утыз адымлап яндарак мал утарының капкасы күренә. Ул бикле бугай. Урман авызыннан коймага хәтле утыз адым узасы бар. Сугышчылар арасында бу «куркыныч ара» дип йөртелә. Шул куркыныч арага аяк атларга батырчылык иткән кешене дошман ядрәсе аяп тормаячак.

Гедеон Спилет белән диңгезче, гомумән, куркып каушап калучылардан түгел иде. Әмма бу мәлдә аз гына саксызлык та үзләренең генә түгел, бөтен иптәшләренең язмышын хәл итүе мөмкин бит. Әгәр күзәтчеләрнең икесен дә үтерсәләр, Сайрес Смит, Наб һәм Герберт ни хәлдә калачак?

Пенкроф, дошман якын булган ачудан йөрәге түзмичә, (ул юлбасарларны мал утарында дип белә иде),

алга атлаган иде, журналист аның кулбашыннан кысып тотты.

— Караңгылансын, аннары барырбыз,— дип пышылдады ул Пенкрофның колагына.

Мылтыгын кысып тоткан килеш, Пенкроф туктап калды, эченнән бандитларны эт итеп сүгеп, түземсезләнеп караңгы төшүен көтә башлады.

Тиздән соңгы яктылык чаткыларын да караңгылык йотты. Гүя урман арасыннан агып чыккан дегет кебек куе караңгылык аланны күмеп китте. Шәфәкъны күккә хәтле үрләп менгән Франклин тавы каплап тора иде. Бу төбәкләрдә караңгылык бик тиз төшүчән. Кузгалырга вакыт җитте.

Журналист белән Пенкроф урман авызында туктап калганнан бирле мал утары коймасын бер секундка да күздән ычкындырмадылар. Эчтә беркем дә юк кебек иде. Койма сызыгы караңгы күк йөзендә тип-тигез булып шәүләләнеп тора. Әгәр пиратлар мал утарында булса, төрле көтелмәгән хәлләрдән саклану өчен, мөгаен, күзәтчеләр куйган булырлар иде.

Гедеон Спилет иптәшенең кулын кысты, аннары икәүләп, мылтыкларын атарга әзер тоткан хәлдә, коймага таба шуышып киттеләр.

Капка янына килеп җиттеләр; караңгыда инә очы хәтле дә ут чаткысы җемелдәми иде.

Пенкроф капканы ачарга үрелде, тик алдан уйлаганча, капка эчке яктан бикле иде. Диңгезче тышкы бикнең эленмәгән икәнен дә шәйләде. Димәк, бандитлар эчтә; беркем керә алмасын өчен, капка биген ныгытып бикләгәннәр.

Гедеон Спилет белән Пенкроф эчкә колак салдылар. Койма эчендә үле тынлык хөкем сөрә иде. Абзардан муфлоннар, кәҗәләр бәэлдәгәне дә ишетелми, алар йоклый иде, күрәсең.

Журналист белән Пенкроф бер тавыш та ишетмәгәч, әллә койма өстеннән төшеп карыйк микән дип уйлашканнар иде дә, әмма бу Сайрес Смитның әмеренә каршы килә дип, тыелып калдылар.

Пиратлар аларның һөҗүм итәргә җыенуын белми, шулай булгач аларны искәрмәстән кырып салырга мөмкин. Әмма алдыңны-артыңны уйламыйча койма өстеннән төшеп бар эшне харап итәргә дә мөмкин.

Журналист уйламый кыланудан тыелып калды. Сабыр итәргә, һәммәсе бергә җыелгач кына керергә кирәк,

дип уйлады. Һәрхәлдә, хәзер алар койма янына сиздермичә килергә мөмкин икәнен, анда дошман сагы юклыгын белделәр. Шуны ачыклагач, иптәшләре янына әйләнеп кайтырга һәм нишләргә икәнен бергәләп киңәшергә булдылар.

Пенкроф та бу фикергә күнде бугай, журналист урманга таба борылып киткәч, сукранмыйча гына аның артыннан иярде.

Инженерга хәлне сөйләп бирделәр. Бераз уйланып торганнан соң ул:

— Бик шәп. Минемчә, мал утарында бандитлар юк,— диде.

— Тиздән койма өстеннән төшәрбез дә анысын тәгаен белербез,— диде Пенкроф.

— Әйдәгез, киттек, дусларым! — диде Сайрес Смит.

— Арбаны урманда калдырабызмы? — дип сорады Наб.

— Калдырмыйбыз. Анда безнең сугыш кирәк-яраклары, азык-төлек төялгән бит. Кирәк чакта артына ышыкланырга да була.

— Әйдәгез, кузгалдык! — диде Гедеон Спилет.

Арба, урманнан чыгып, әкрен генә мал утарына таба юнәлде. Бая Гедеон Спилет белән Пенкроф аланнан шуышып үткәндәге кебек, әйләнә-тирә дөм караңгы иде. Аяк астындагы куе йомшак үлән тавыш-мазарны йота.

Сәяхәтчеләр ут ачарга әзерләнделәр. Юпны артка чыгардылар. Наб, алга ташланмасын дип, Топны муенчагыннан тотты.

Аланга җиттеләр. Анда беркем күренмәде. Сәяхәтчеләр төркеме коймага таба юнәлде. «Куркыныч ара»ны ашыгып кичтеләр. Ату тавышы ишетелмәде. Арба утыртма койма янына килеп туктады. Наб онагрлар янында калды. Инженер, журналист, Герберт һәм Пенкроф капкага таба киттеләр. Бандитлар эчтән капканы әйберләр белән терәтеп куймаганнар микән?

Капканың бер ягы ачык иде!

Инженер, диңгезче һәм журналистка борылып:

— Ә сез бикле дигән идегез түгелме? — дип сорады.

Тегеләр икесе дә телсез калдылар.

— Валлаһи дим, капка әле генә бикле иде! — дип, Пенкроф исе китте.

Сәяхәтчеләр тәмам аптырадылар. Пенкроф белән Гедеон Спилет бая монда килеп карап киткәндә, пиратлар мал утарында булганнар. Анысында шик юк.

Чөнки эчтән бикле капканы юлбасарлардан башка тагын кем ачсын ди? Алар әле дә эчтә микән соң? Әллә берәрсе аннан чыккан булды микән?

Һәммәсенең күңелен әнә шундый сораулар борчыды.

Ишегалдына кереп барган җирдән Герберт кинәт кире артка чигенде дә Сайрес Смитның кулына ябышты.

— Нәрсә күрдегез анда? — дип сорады инженер.

— Ут бар.

— Өйдәме?

— Өйдә.

Бишесе дә капкага килделәр. Нәкъ каршыда тәрәзәдә сыек кына ут шәүләсе бар иде.

Сайрес Смит тиз генә бер карарга килде:

— Безнең файдага бу! Бандитлар өйдә бикләнгәннәр, без һөҗүм итәр дип башларына да килмидер, мөгаен. Алар хәзер безнең кулда! Әйдәгез, алга!

Сәяхәтчеләр, мылтыкларын алга сузып, ишегалдына керделәр. Арбаны койма тышында калдырдылар. Топ белән Юпны, арбага бәйләп, сакка куйдылар.

Сайрес Смит, Пенкроф, Гедеон Спилет бер яктан, Герберт белән Наб икенче яктан койма кырыйлап өйгә таба киттеләр. Ишегалды дөм караңгы, беркем юк иде.

Берничә минуттан өйгә килеп тә җиттеләр, ишек эчтән бикле иде.

Сайрес Смит иптәшләренә селкенмәскә дә кушып ымлады да яктылык төшкән тәрәзәдән эчке якка карады.

Бүлмә эченә күз йөртеп чыкты.

Өстәлдә фонарь янып тора. Өстәл янында Айртонның ятагы күренә.

Анда кемдер йоклап ята.

Кинәт Сайрес Смит тәрәзәдән артка чигенде һәм, пышылдап:

— Айртон! — диде.

Тиз генә ишекне ачып, ягъни каерып керделәр дә бүлмә эченә ташландылар.

Айртон йоклый иде. Йөзе бик йончыган, күп газаплар кичергәнлеге сизелеп тора. Беләкләрендә һәм тубыкларында канлы җәрәхәтләр бар.

Менә нинди сәер шартларда очрашырга язган икән аларга!

Сайрес Смит Айртон өстенә иелде, кулыннан тотып:

— Айртон! — дип дәште.

Айртон күзен ачты, Сайрес Смитка карады, аннары тирә-яктагыларга берәм-берәм күз йөртеп чыкты.

Үз күзенә үзе ышанмыйча:

— Сезме бу? Чыннан да сезме соң бу? — дип кычкырып җибәрде.

— Айртон! Айртон! — дип кабатлады Сайрес Смит.

— Мин кайда?

— Мал утарындагы үз өеңдә.

— Ялгызыммы?

— Әйе.

— Алар хәзер әйләнеп кайтачак. Сакланыгыз! Зинһар сакланыгыз! — дип кычкырды Айртон. Аннары хәлсезләнеп ятагына ауды.

— Спилет, пиратлар, әйләнеп килеп, менә-менә һөҗүм итүләре мөмкин. Арбаны ишегалдына кертегез. Капканы әйбәтләп бикләгез дә, барыгыз да монда керегез,— диде инженер.

Пенкроф, Наб һәм журналист инженерның әмерен үтәргә ашыгып чыгып киттеләр. Бер генә секундны да әрәм итәргә ярамый иде. Бәлкем, арба пиратлар кулына төшкәндер дә инде.

Журналист һәм иптәшләре атылып ишегалдына чыктылар һәм Топның ырылдаганын ишеттеләр.

Айртонны ялгыз калдырып, Сайрес Смит та ишек төбенә чыкты. Мылтыгын алга төбәде, Герберт анын янәшәсенә басты. Сагаеп, икесе дә койма өстендә калкып торган тау сыртына карадылар. Әгәр бандитлар анда яшеренгән булсалар, утрау хуҗаларын берәм-берәм атып үтерүләре бик тә мөмкин иде.

Шул чак кап-кара урман өстенә ай калыкты. Әйләнә-тирә көндезге кебек яктырып китте. Ай яктысы бөтен ишегалдын, тегендә дә, монда да үсеп утырган агачларны, урталыктан аккан инешне, ямь-яшел чирәмне яктыртты. Франклин тавы янәшәсендә өй һәм койма сөт кебек ак булып күренә иде, ә каршы яктагы койма күләгәдә кап-кара стена кебек тора.

Тиздән урталыктагы яктыга гаять зур кара шәүлә килеп керде,— бу арба иде. Сайрес Смит капканың ябылуын, келәсе шалтырап бикләнгәнен ишетте.

Шул чак кинәт Топ, бәен өзеп, абалап өрә-өрә ишегалды түренә, өйнең уң ягына ыргылды.

— Сак булыгыз, дусларым! Мылтыкларыгызны төзәгез! — дип боерды Сайрес Смит.

Утрау хуҗалары, мылтыкларын күз турысына күтәреп, атарга әзерләнделәр. Топ тыела алмыйча ярсыпярсып өрә иде, Юп та аның янына барып тыела алмыйча ачы итеп чыелдап җибәрде.

Утрау хуҗалары алар артыннан йөгерделәр һәм биек агачлар арасыннан агып ятучы инеш янына килеп җиттеләр.

Сөт кебек ай яктысында инеш ярында ни күрсеннәр: үлән өстендә биш үле гәүдә ята иде.

Болар — моннан дүрт ай элек Линкольн утравына аяк баскан юлбасар пиратлар иде.

Унөченче бүлек

Айртонның хикәясе.— Элекке җинаятьче дусларының нияте.— Мал утарын яулап алу.— Линкольн утравының гадел хөкемдарлы.— «Хәерле юл» — Франклин тавы тирәсендә әйләнүләр.— Тау өстендәге үзәнлекләр.— Җир астыннан гөрелте ишетелә.— Пенкрофның җавабы.— Кратер төбендә.— Кайту.

Бу ни хәл? Пиратларны кем кырып салган? Әллә Айртонмы? Юк, ул булмас! Бер минут кына элек ул юлбасарларны монда әйләнеп кайтыр дип курыккан иде бит!

Ә Айртон тирән йокыга талган, аны уятып алырлык та түгел иде. Бая көч-хәл белән берничә сүз әйткәч, ул ятагына авып төште дә исеннән тайгандай тынып калды.

Ниләр булды икән соң монда дип тәмам аптырашкан утрау хуҗалары төне буе керфек тә какмадылар, берсе бер ишегалдына чыгып карамады, пиратларның мәете яткан урынга аяк атларга күңелләре тартмады. Тегеләр ничек әҗәлләрен таптылар икән соң? Моны хәтта Айртон да әйтә алмастыр, мөгаен, чөнки ул бичара үзенең мал утарындагы өендә ятканын да белмәде бит. Әмма ул юлбасарларның коточкыч үлем җәзасын татыганчы ниләр булганын белергә тиеш.

Иртәгесен Айртон йокысыннан уянды. Йөз дә дүрт көн югалып торганнан соң аны тере килеш, сау-сәламәт килеш күргәч, сәяхәтчеләр бик куандылар.

Айртон шул көннәр эчендә ниләр кичергәнен, һәрхәлдә, үзе белгән кадәресен кыскача сөйләп бирде.

Мал утарына килеп җиткәч, унынчы ноябрьдә, караңгы төшү белән пиратлар койма өстеннән төшеп,

Айртонны тотып алганнар. Аяк-кулларын бәйләп, авызына чүпрәк тутырып, Франклин тавы арасына алып киткәннәр, анда үзләре яшәгән караңгы мәгарәгә кертеп ташлаганнар.

Алар аны үлем җәзасына хөкем иткәннәр, иртәгә үтерербез дип калдырганнар. Шунда кинәт пиратларның берсе аны таныган, Австралиядәге исемен хәтергә төшергән. Айртонны җәзаларга ниятләгән пиратлар Бен Джойска кул күтәрергә батырчылык итмәгәннәр.

Айртон элекке җинаятьче дусларының таләбенә буйсынырга теләмәгән. Юлбасарлар аны үз якларына аударырга тырышканнар, Гранит сарайны яулап алырга булышыр дип өметләнгәннәр; якын да килеп булмаслык ул ныгытмага үтеп керергә, андагы кешеләрне үтереп бетереп, утрауга хуҗа булырга ниятләгәннәр!

Айртон үгеткә бирелмәгән. Гөнаһларыннан тәүбә иткән, кешелек абруен аклый алган элекке җинаятьче үз иптәшләренә хыянәт итүгә караганда үлемне артык санаган.

Аның аяк-кулларын яңадан бәйләп, авызына чүпрәк тутырып, дүрт айга якын мәгарәгә ябып тотканнар, гел күзәтеп торганнар.

Пиратлар утрауга төшү белән үк мал утарына юлыкканнар, әмма анда урнашып калырга шикләнгәннәр, аннан азык-төлек кенә ташыганнар. Бандитларның икесе 11 нче ноябрьдә сәяхәтчеләргә юлыкканнар, сәяхәтчеләргә атканнар. Иптәшләре янына әйләнеп кайткан ялгыз бандит утрау кешеләренең берсен «дөмектердем» дип мактанган; әмма җинаятьче үзе дә иптәшсез генә кайткан, анысын Сайрес Смит хәнҗәре кадап үтергәнен үзегез дә беләсез инде.

Җинаятьче авызыннан Гербертның һәлак булганын ишеткәч, Айртон бик кайгырган. Иптәшләренең дүртәү генә калганын белгәч, пиратларга ничек каршы торырлар инде дип борчылган.

Сәяхәтчеләр Гербертның авыруы аркасында мал утарындагы өйдә торырга мәҗбүр булган көннәрдә пиратлар мәгарәдә яшеренеп ятканнар. Күзәтү яссытаулыгына һөҗүм итеп, анда кырып-җимереп кайтканнан соң да мәгарәдән чыкмаганнар.

Айртонга рәхим-шәфкать күрсәтмәгәннәр. Аны бәйләгән баулар аяк-кул итен кисеп кергән, ул җәрәхәт әрнеп торган. Ул көн дә үлем көткән, котылырмын дип һич кенә дә өметләнмәгән.

Бу хәл февраль уртасына хәтле дәвам иткән. Юлбасарлар утрау хуҗаларына һөҗүм итәргә һаман җай көткәннәр, ояларыннан сирәк чыкканнар. Берничә тапкыр утрауның көньяк ярына хәтле барып, киек аулап кайтканнар. Айртон дусларының хәбәр-хәтерен белмәгән, аларны исән күрүдән инде өметен өзгән!

Ахырда бичара бу газапларга түзә алмый һушыннан тайган. Ике көн буе иссез яткан, шул вакыт эчендә ниләр булганын ишетмәгән дә, күрмәгән дә.

— Мистер Сайрес, мин аягым-кулым бәйләнгән килеш мәгарәдә яткан җиремнән ничек монда эләккәнмен соң, һич белмим,— диде Айртон.

— Ә пиратлар абзар коймасы буенда ничек үлеп яталар соң?

— Үлеп яталар?! — дип кычкырып җибәрде Айртон шаккатып. Хәлсез булуына карамастан, ул хәтта ятагыннан калкынды.

Иптәшләре аңа урыныннан торырга ярдәм иттеләр. Ул аягына баскач, бергәләп инеш буена киттеләр.

Көн яктырган иде инде.

Инеш буенда төрлесе төрле кыяфәттә пиратларның җансыз гәүдәләре ауный. Алар көтмәгәндә үлемгә дучар булганнар, күрәсең, үзләре моны сизмичә дә калганнардыр ахрысы.

Айртон бу хәлгә шаккатып, телсез калып карап торды. Сайрес Смит һәм аның иптәшләре дә ләм-мим дәшмичә көттеләр.

Инженерның кушуы буенча, Наб белән Пенкроф салкында катып өлгергән мәетләрне карарга керештеләр.

Аларның гәүдәсендә бер генә җәрәхәт тә күренмәде. Бик җентекләп карый торгач кына Пенкроф һәркайсында кечкенә генә кызыл тап барлыгын белде: тик берсенең табы — маңгаенда, икенчесенеке — күкрәк турысында, өченчесенеке — аркасында, дүртенчесенеке иңбашында иде. Боларның нәрсәдән калган тап икәнен әлегә һичкем белә алмады.

— Аларның үлеменә шул таплар сәбәпче! — диде Сайрес Смит.

Аптырап калган журналист:

— Нинди корал эзе соң ул? — дип сорады.

— Аларны кем үтергән соң? — диде Пенкроф.

— Безнең утрауның гадел хөкемдары,— диде Сайрес Смит.— Сезне, Айртон, монда китерүче дә — ничә-

мә-ничә тапкыр безне авыр хәлдән коткарган мәрхәмәт иясе, безнең көчтән килмәгән эшләрне эшләп тә, бездән яшеренеп калучы кеше.

— Тизрәк эзлик инде аны! — диде Пенкроф.

— Без аны эзләвен эзләрбез. Тик шул хәтле могҗизалар эшләгән ул илаһи затны без таба алмабыз. Әгәр ул үз янына безне чакырырга кирәк тапса гына күрә алырбыз без аны.

Серле шәфкать иясенең яшерен рәвештә күрсәткән мәрхәмәтләре аркасында үзләре булдыксызга чыккан кебек тоелып, Сайрес Смитның хәтере кала иде, шул ук вакытта ул аңа бик рәхмәтле дә иде. Тик серле зат алар эшенә катнашкан саен Сайрес Смитның көчсезлеген искәртә, моңа инженерның горур җаны үртәлә башлаган иде. Яшерен рәвештә мәрхәмәт күрсәтеп, рәхмәттән качкач, димәк, күпмедер дәрәҗәдә һавалану булып чыга түгелме соң бу; Сайрес Смитның фикеренчә, бу хәл аның иткән яхшылыкларының бәясен киметә иде.

— Без аны эзләрбез,— дип кабатлады инженер.— Ходай кушса, кайчан да булса бер, ул һавалы затка үзебезнең яхшылык кадерен белүче кешеләр икәнебезне исбатларбыз! Аның изгелегенә изгелек белән кайтару өчен ниләр генә эшләмәс идем, хәтта үз-үземне корбан итеп булса да, аңа яхшылыгын кайтарыр идем.

Шул көннән башлап билгесез шәфкать иясен эзләү, гайре табигый кодрәткә ия ул кешенең исемен белү, бу сернең ачкычын ничек тә табу Линкольн утравы кешеләренең бердәнбер максатына әверелде.

Алар хәзер өйгә кайтырга ашыктылар. Иптәшләренең зур тырышлыгы нәтиҗәсендә Айртонның рухы күтәрелде, тәненә көч керде.

Наб белән Пенкроф пиратларның мәетләрен мал утарыннан еракка алып китеп күмделәр.

Аннары Айртонга ул югында үзләренең башыннан кичкән хәлләрне сөйләделәр. Айртон Гербертның яралануын, иптәшләренең нинди авыр сынауларга дучар ителүен ишетте. Иптәшләре аны тере хәлендә күрүдән өмет өзгәнлекләрен, рәхимсез җинаятьчеләр аны ерткычларча үтергәннәрдер дип уйлаганлыкларын да яшермәделәр.

Сайрес Смит сүзен түбәндәгечә тәмамлады:

— Ә хәзер безнең алда зур бурыч тора. Безнең бер максатыбыз үтәлде: пиратлардан арындык, үз утра-

выбызга тулы хуҗа булып калдык, тик моның өчен без *аңа* бурычлы.

— Бик шәп! — диде Гедеон Спилет.— Франклин тавы арасындагы барлык тарлавыкларны актарып чыгарбыз, бер тау куышын да, бер чоңгылны да карамыйча калмабыз! Һәй, дөньяда әле бер генә журналистка да мондый маҗаралы серне чишүгә катнашырга туры килмәгәндер!

— Шәфкатьле ярдәмчебезне тапмыйча, Гранит сарайга кайтмабыз,— диде Герберт.

— Әйе, кулыбыздан килгәнне барысын эшләрбез... тик, әйтәм бит, ул үзе безгә күренергә теләсә генә без аны таба алырбыз!

— Алайса монда калабыз,— дип тәкъдим итте Пенкроф.

— Калабыз,— дип риза булды Сайрес Смит.— Азыктөлек җитәрлек. Эзләнүләр алып барасы җирләр моннан якын. Кирәк чагында арба җигеп тиз генә Гранит сарайга да кайтып килергә мөмкин.

— Дөрес,— диде диңгезче.— Тик бер нәрсәне онытмыйк.

— Нәрсәне?

— Җәй уртасы җитеп килә, сәяхәткә чыгасыбыз бар бит.

— Нинди сәяхәт? Кая? — дип сорады Гедеон Спилет.

— Табор утравына,— диде Пенкроф,— Айртонны алып китәргә Шотландия яхтасы килсә, аның кайда икәнен белмәсләр бит. Анда утравыбызның координатларын әйтеп хат язып калдырырга кирәк. Хәер, бәлкем соңга да калганбыздыр инде.

— Тукта әле, Пенкроф,— диде Айртон.— Табор утравына нәрсәгә утырып бармакчы буласыз?

— Үзебезнең корабка!

— Үзебезнең корабка? — диде Айртон.— Юк бит инде ул.

— Нәрсә юк, кораб юкмы? — дип кычкырып җибәрде Пенкроф, хәтта урыныннан сикереп торды.

— Кораб юк, Пенкроф,— диде Айртон.— Бер атна элек пиратлар корабны бухтадан табып алганнар, аңа утырып диңгезгә чыкканнар һәм...

Пенкрофның хәтта йөрәге ярыла язды.

— Йә, шуннан?

— Аларның Боб Гарвейлары юк бит хәзер, кораб-

ны йөртә белүче юк... Шуннан алар су асты кыясына килеп бәрелгәннәр. Кораб тишелгән.

— Аһ, явыз җаннар! Аһ, башкисәрләр! Ләгънәт төшкере бәдбәхетләр! — диде диңгезче.

Герберт аның кулыннан тотты.

— Пенкроф! Борчылма, зинһар, без бүтән кораб төзербез, моннан яхшыракны, зурракны. Бездә хәзер пиратлар бригының кайбер тимерле өлешләре, бау-арканнары, җилкәннәре бар!

— Утыз-кырык тонна су сыешлы кораб төзү өчен күпме вакыт кирәген беләсезме сез? — диде үрсәләнеп Пенкроф.— Аңа биш ай кирәк, ярты елга сузылмаса әле.

— Күпме кирәк булса да булыр, яңа кораб төзергә туры килә. Табор утравына быел бармабыз,— диде журналист.

Инженер да диңгезчене юатырга кереште:

— Бернишләр хәл юк, Пенкроф...

— Нишлисең, бу бәхетсезлеккә дә түзәрбез инде. Тик Табор утравына барырга кичекмәсәк ярый.

Пенкроф яраткан корабын югалту кайгысын авыр кичерде.

— Аһ, «Хәерле юл»! Аһ, кадерле корабым! — дип үрсәләнде ул.

Кораблары һәлак булганга башкалар да борчылды, әлбәттә. Тиз көндә яңа кораб төзергә кирәк дигән фикергә килделәр. Әмма әлегә аларның төп максаты утрауның барлык яшерен почмакларын тикшереп чыгу иде.

Шул көнне үк, ягъни 19 нчы февральдә, алар серле затны эзләү сәяхәтен башладылар һәм бөтен атнаны шуңа багышладылар. Франклин тавы итәгендә, аның күпләгән сыртлары арасында очына чыккысыз борылмалы-сырылмалы үзәннәр, төпсез чокырлар бар иде. Серне, мөгаен, менә шул тарлавыклардан, хәтта тауның карынынан ук эзләргә кирәктер. Бер кемгә дә күренергә теләмәгән кешегә яшерен торагын шунда төзү кулай иде. Тау аралары шул хәтле буталчык, Сайрес Смитка бик озаклап эзләнергә туры килде.

Башта тауның көньяк итәген, Шарлавык елгасының су башы тирәсен йөреп чыктылар. Айртон теге юлбасарлар яшеренгән куышны күрсәтте. Куыш Айртон ябылып ятканда ничек булса, әле дә шул хәлендә икән, бандитларның мал утарыннан талап алып кайткан

сугыш кораллары, ядрә, дары, азык-төлекләр тегендә дә монда аунап ята.

Сәяхәтчеләр куышның әйләнә-тирәсендәге биек-биек ылыслы агачлар үскән үзәнлекне дә бик җентекләп карап чыктылар. Аннары көньяк-көнбатыш тау сыртын урап уздылар, кысан тарлавык буйлап диңгез ярындагы әкияти базальт кыяларга хәтле барып җиттеләр.

Базальт кыяларда агачлар да, үләннәр дә үсми иде. Тегендә карасаң да таш, монда карасаң да таш... Кыя араларында таштан ташка сикереп тау кәҗәләре, муфлоннар гына йөри. Бу тирәләрдән утрауның уңдырышсыз җирләре башлана. Франклин тавы итәгендәге күплəгән үзәнлекләрнең фәкать өчесе урманга, көтүлекләргә бай. Мәсәлән, мал утары урнашкан үзәнлек, аның көнбатышында Шарлавык елгасы үзәне, ә көнчыгышында Кызыл инеш үзәне. Әлеге елгалар икесе дә кайдандыр тау түбәсеннән башлана да түбәнгә омтылып, юлында кушылдыкларын ияртеп, мул сулы елгага әверелә һәм утрауның көньяк очын сугара. Рәхмәт елгасын исә, башлыча, Җакамар урманы эченнән агып чыккан күпләгән чишмәләр туендыра. Борылмалы ярымутрауны әнә шушы исәпсез-хисапсыз җир асты сулары, бай чишмә-кизләүләр сугарганга үсемлекләр гөрләп үсә.

Югарыда искә алынган, эчә торган суы мул үзәнлекләрнең өчесе дә кешедән качып яшәргә теләүче өчен бик җайлы иде, анда тереклек итәр өчен кирәкле һәммә нәрсә бар иде. Шуңа күрә сәяхәтчеләр шушы өч үзәнлекнең һәр карышын игътибар белән карап чыктылар, әмма кеше яшәгәнен расларлык эзләр очратмадылар.

Кайда яши икән соң ул серле зат? Әллә төньяк тау битендәге кыргый тарлавыклар, җимерек кыялар арасында, үсемлек заты үсмәгән шәрә упкыннарда, катып калган лава кантарлары арасында микән?

Франклин тавының төньяк тау битендә киң генә ике сай үзәнлек бар иде; анда үсемлекнең әсәре дә юк, эре шома ташлар, зур-зур кантарлар гына чәчелеп ята, буразна-буразна булып каткан лава ташкыны арасында вулкан чыгарып аткан тау токымнары, вак-вак обсидиан, лабрадорит кантарлары өелеп тора. Утрауның бу почмагында эзләнүләр озакка сузылачак. Тау эченә уелып кергән тирән-тирән тау куышлары, мәгарәләр бар. Тереклек итәр өчен яраксыз булса да, кешедән качып яшәргә теләүчегә алар уңайлы, әлбәттә, чөнки ке-

ше күзеннән читтә урнашканнар. Сумалаланган агач ботакларына ут кабызып, сәяхәтчеләр утрау барлыкка килгәндә үк хасил булган бу тау тишекләренең, караңгы мәгарәләрнең түренә үк узып һәр борылмасын карап йөрделәр. Бар җирдә дә караңгылык һәм тынлык хөкем сөрә. Җир карынындагы бу борынгы юлларга гомергә дә кеше аягы басмагандыр, бу ташларны беркем урыныннан кузгатмагандыр ахрысы. Әүвәл-әүвәл заманнарда җир астыннан бәреп чыккан ут ташкыны, диңгез төбеннән таш кантарларын өсте-өстенә өеп менгезеп, утрау хасил иткән, һәм шул гомердән бирле һәр нәрсә монда шул хәлендә кала биргәндер мөгаен.

Гәрчә җир карынындагы бу юллар, бу тармаклар мәңге караңгы, мәңге буш булса да, Сайрес Смит анда мәңге тынлык хөкем сөрә дия алмас иде.

Тау карынына берничә фут эчкә кергән караңгы мәгарәләрнең берсеннән узышлый ул кайдандыр еraktан ишетелгән гөрелтегә игътибар итте, гөрелте тау куышының таш гөмбәзләренә бәрелеп кире кайта-кайта яңгырады.

Аның янәшәсеннән атлаган Гедеон Спилет та ерактан килгән бу гөрелтене ишетте. Әллә сүнгән вулкан карынындагы ут терелеп килә микән? Икесе дә туктап тыңлап тордылар — тонык гөрелте кат-кат ишетелде; чыннан да, җир астында ниндидер геологик процесс бара ахрысы.

— Димәк, вулкан сүнеп бетмәгән булып чыга? — диде журналист.

— Шулайдыр, күрәсең. Без теге вакытта кратерга төшеп караганнан соң, тауның түбәнге катламнарында ниндидер үзгәреш башланган ахрысы. Сүнгән дип исәпләнгән вулканның шулай күбесе күпмедер вакыттан соң яңадан уянучан,— диде Сайрес Смит.

— Әгәр Франклин тавы уянса, вулкан ата башласа, Линкольн утравын һәлак итмәсме соң? — дип сорады Гедеон Спилет.

— Итмәстер,— диде инженер.— Вулканның кратеры саклаячак, артык парлар, лава ташкыны шуннан агып чыгачак.

— Әгәр лава утрауның уңдырышлы ягына таба яңа юл ярып чыкмаса...

— Ә нигә алай дип уйлыйсыз, кадерле Спилет? Лава табигатьнең үзе тарафыннан әзерләнгән юлдан акмыйча, нигә башка юл ачсын икән?

— Вулканнар бик холыксыз бит,— диде журналист.

— Франклин тавы менә хәзер без тикшерә торган шәрә үзәнлекләр ягына таба авыш, лавага шунда таба агарга җайлы. Бүтән якка аксын өчен авырлык үзәге күчәргә тиеш, ә анысы җир тетрәгәндә генә мөмкин.

— Минем белүемчә, вулкан атканда җир дә тетрәүчән.

— Мөмкин хәл, әлбәттә! — дип килеште инженер.— Әгәр вулкан озак атмый торган булса, авызына тау токымнары бөялсә, җир тетрәве мөмкин. Сезнең пошыну тикмәгә түгел, кадерле Спилет, вулканның атуы күп очракта коточкыч бәлаләр китереп чыгара. Аның тыныч кына йоклавы хәерлерәк булыр иде, гомергә дә уянмасын иде ул. Әмма анысы безнең көчтән килә торган нәрсә түгел. Ни генә булмасын, Күзәтү яссытаулыгындагы безнең иген басуларына, яшелчәлеккә әллә ни зыян тимәс дип уйлыйм. Яссытаулык белән вулкан арасында тирән иңкүлек ята. Әгәр дә лава күл ягына таба агарга керешсә, иңкүлек буйлап ком көртләренә, Акула култыгына таба юнәләчәк.

— Гадәттә, вулкан уянганда тау түбәсеннән төтен чыга. Ә без төтен күрмәдек бугай,— диде Гедеон Спилет.

— Әйе шул, күрмәдек. Мин кичә генә тау түбәсен озаклап күзәткән идем, вулкан авызында бүрек хәтле дә төтен күренмәде. Ничәмә-ничә гасырлар дәвамында вулкан авызына таш кантарлары, вулкан көле, каткан лава тыгылгандыр... Ул бөке беренче тапкыр җир тетрәүдән үк күккә очачак. Пар казанын хәтерләткән утрау, аның учагына охшаган вулкан газ басымыннан шартламаячак. Анысыннан шикләнмәгез, кадерле Спилет. Һәрхәлдә, әйтәм ич, безнең өчен вулканның йоклавы хәерлерәк.

— Юк, ялгыш түгел, әнә гөрелте аермачык ишетелә. Чыннан да, вулкан карынында нindidер үзгәрешләр бара шул!..

Инженер, сагаеп тыңлана-тыңлана:

— Әйе шул, дөрес әйтәсез,— диде.— Без ялгышмыйбыз... Анда нindidер процесс бара. Нинди процесс икәнен, нәтиҗәсен генә алдан күрүе кыен.

Тау куышыннан чыккач, Сайрес Смит белән Гедеон Спилет иптәшләрен эзләп таптылар да күзәтүләрен аларга да сөйләделәр.

— Кара син! Вулкан хикмәтләрен яңадан күрсәтергә җыена диген. Күрсәтеп карасын. Аңа да йөгән табылыр!..

— Ә кем йөгәнләр икән соң аны? — дип сорады Наб.

— Безнең изге даһиебыз, шәфкатьле ярдәмчебез! Әгәр вулкан тамагын киерергә керешсә, аның авызын томалау чарасын табар ул!

Укучылар шаһит, Пенкроф утрауда хакимлек итүче яңа аллага какшамас ышаныч баглый иде. Әйтергә кирәк, моңа кадәр ничәмә-ничә тапкыр үзенең ярдәмен күрсәткән серле зат чыннан да илаһи көчкә ия сыман иде. Әмма ул тылсымчыны нихәтле тырышып эзләсәләр дә, әлегә хәтле таба алганнары юк бит. Нихәтле бирелеп, дәртләнеп, үҗәтләнеп эзләүгә карамастан, аның торагы әлегә яшерен килеш кала бирә.

19нчы ноябрьдән 25нче февральгә хәтле эзләүләрнең даирәсе киңәйде, утрауның бөтен төньягына җәелде; утрауның барлык аулак почмакларына хәтле актарып чыктылар инде. Хәтта шуңа хәтле барып җиттеләр ки, шикле өйне тентегән чакта стеналарын шакып-шакып караган кебек, сәяхәтчеләр дә кыя итәкләрен шакып-шакып карадылар. Инженер тау сыртларының төгәл картасын сызды, сәяхәтчеләр тауның иң ерак итәкләренә хәтле барып карап килделәр. Алар хәтта тауның урталыгындагы мәйданчыгына, аннан өстә калкып торган ак кар кунган очлы түбәсенә дә менделәр.

Ул гына җитмәсә дигәндәй, кратер авызына ук төштеләр. Анда әлегә ут-фәлән күренмәсә дә, чоңгыл төбеннән дәһшәтле гөрелте аермачык ишетелә иде. Кратердан әлегә сызылып төтен чыкмый, пар болыты да күтәрелми, стеналары да кайнар түгел иде,— кыскасы, тиздән вулкан атачагын искәртердәй билгеләр юк, югыйсә.

Тауның түбәсендә дә, тау битләрендә дә үзләре эзләгән шәфкать иясенең яшәгән җирен очратмадылар.

Шуннан соң алар ком көртләренә таба киттеләр, ул тирәләрне аркылыга-буйга йөреп чыктылар. Акула култыгының стена кебек текә биек ярларына хәтле барып җитеп, аларны җентекләп тикшерделәр. Каткан лавадан гыйбарәт текә ярдан аска төшүе бик кыен булса да, диңгезгә хәтле төшеп карадылар. Беркайда беркем эзе дә юк иде! Үҗәтләнеп, тырышып эзләүләренең аянычлы нәтиҗәсе шул булды: уңышсызлыклардан соң Сайрес Смитның да, башкаларның да күңеле сүрелде.

Эзләнүләрне туктатырга, өйгә кайтырга, шәт, вакыт җиткәндер дип уйлаштылар. Серле затның торагы утрауда түгел дип әйтергә аларның хәзер тулы хакы бар иде. Һәм алар йөгәнсез хыяллар, шашкын фаразлар иркенә бирелделәр. Пенкроф белән Наб исә хыялда теге билгесез затның сурәтен тудырып кына калмадылар, тылсымлы әкият дөньясына ук кереп чумдылар.

Егерме бишенче февральдә сәяхәтчеләр Гранит сарайга әйләнеп кайттылар. Ук койрыгына ике катлы нечкә бау тагып урталыктагы мәйданчыкка атып җибәрделәр һәм торакка менәргә бау баскычны җайладылар.

Бер ай үткәч, 24 нче мартта, алар Линкольн утравында яши башлауларына өч ел тулган көнне бәйрәм иттеләр.

Ундүртенче бүлек

Өч ел узды.— Яңа кораб төзү хакында киңәш.— Утрауда тормыш гөрләп бара.— Кораб төзү.— Көньяк ярымшарда салкыннар.— Пенкроф буйсына.— Кием-салым юу.— Франклин тавы.

Ричмонд әсирләренең тоткынлыктан качуларына өч ел тулды. Газиз ватаннарын бер генә минутка да хәтердән чыгармадылар алар, әледән-әле искә ала тордылар. Гражданнар сугышы беткәндер, инде төньяклыларның гадел эше тантана итәдер дип уйлыйлар иде. Коточкыч бу сугышның нәтиҗәләре ничек булды икән соң? Күпме кан коелгандыр инде... Дусларыннан, таныш-белешләреннән кемнәр исән, кемнәр корбан булды икән? Алар күбесенчә әнә шуларны сөйләшәләр иде. Их, бер генә көнгә туган илләренә кайтып килерләр иде! Кеше яши торган берәр җир белән бәйләнешкә керәсе, туган илләре белән утрау арасында даими элемтә булдырасы иде,— аннан соң биредә байтак еллар яшәсәләр дә, үкенмәсләр иде. Бәлкем, әле монда яшәгән еллары үз гомерләрендә иң бәхетле чор булып күңелләрендә сакланыр иде. Бу хыяллар тормышка ашмаслык түгел лабаса!

Аларның хыялы гамәлгә ашсын өчен ике юл бар иде: яки Линкольн утравы янына берәр кораб килеп чыга да шуңа утырып илләренә кайтып китәләр, яисә үзләре океан гизәрдәй зур кораб төзиләр.

Беркөнне Пенкроф:

— Бәлкем, безнең даһиебыз илебезгә кайтырга ярдәм итәр! — дип куйды.

Чынлап та, Пенкроф белән Набка әгәр Акула култыгында яисә Һава шары портында өч йөз тонна су сыешлы кораб көтеп тора дисәләр, һич тә шаккатмаслар иде, чөнки алар билгесез заттан теләсә нинди могжиза көтәргә мөмкин дип исәплиләр иде.

Әмма Сайрес Смит, аек кеше буларак, чынбарлыкка күзне ачыбрак карарга кушты һәм корабны үзләренә төзергә кирәклекне әйтте. Һәм инде мәсьәләне һич тә кичектерергә ярамый иде; Айртонның кайда икәнлеген әйтеп хат язарга да, аны тиз көндә Табор утравына илтеп куярга кирәк ич.

«Хәерле юл» хәзер юк; яңа кораб төзер өчен иң кимендә ярты ел вакыт кирәк. Инде кыш айлары якынлаша. Кыскасы, киләсе язсыз сәяхәткә чыгу хакында уйларлык түгел иде.

Бу турыда сүз чыккач, инженер Пенкрофка:

— Ярый, дустым, әле вакыт күп, көннәр җылынганчы бик әйбәтләп әзерләнеп куярбыз,— диде.— Инде яңа кораб төзергә уйлыйбыз икән, аны зуррак итәргә кирәк. Шотландия яхтасы Табор утравына киләме-юкмы — тәгаен белмибез. Бәлкем, ул моннан берничә ай элек килгәндер, Айртонны озак эзләп тә тапмагач, кире кайтып киткәндер. Безгә үзебезгә Полинезия яки Яңа Зеландия утрауларына барып җитәрлек кораб төзергә кирәк. Сез шуңа ризамы?

— Мистер Сайрес, сезнең кулыгыздан теләсә нинди эш килә, бергәләп андый зур корабны да ясый алырбыз, шәт,— диде Пенкроф.— Агач җитәрлек, корал-мазар бар. Вакыт кына кирәк. Хикмәт шунда.

— Ике йөз илле-өч йөз тонна су сыешлы кораб төзү өчен ничә ай кирәк булыр икән? — дип сорады Сайрес Смит.

— Кимендә җиде-сигез ай,— дип җавап бирде Пенкроф.— Тик кыш борын төбендә, бик салкында агачны эшкәртүе кыен. Берничә атнага эшне туктатып торырга туры киләчәк. Ходай кушып, корабны ноябрь аенда суга төшерә алсак, шәп инде.

— Бик әйбәт! Табор утравына һәм аннан ерагракка сәяхәткә чыгу өчен иң җайлы вакыт,— диде Сайрес Смит.

— Сызымын сызып бирсәгез, эшче куллар әзер. Бу юлы Айртон да булышыр,— диде диңгезче.

Башкалар белән дә киңәшкәч, алар да инженерның фикерен хупладылар. Дөрес, ике йөз илле-өч йөз тонна су сыешлы корабны төзү асат эш түгел, әмма утрау кешеләре үз көчләренә ышаналар, моңарчы тотынган эшләрен башкарып чыкмыйча калганнары юк иде әле.

Тиздән Сайрес Смит корабның сызымын сызды. Ә ул арада башкалар корабка дип агач кистеләр. Ерак Көнбатыш урманнарында кораб төзү өчен яраклы менә дигән имәннәр, карама агачлары үсә. Соңгы сәяхәт вакытында кисеп узган сукмакны киңәйтеп юл ясадылар, аңа *Ерак Көнбатыш юлы* дип исем куштылар. Шул юлдан агачларны Хәрабә янына ташыдылар,— корабны шунда төзергә исәплиләр иде. Киселәсе агачлар төрлесе төрле җирдә үсеп утырганлыктан, юлны да төрлечә салырга туры килде, нәтиҗәдә Борылмалы ярымутрауның байтак өлешенә үтеп керергә мөмкинлек туды.

Алар тизрәк агачларны кисеп, кабыгын каезлап куярга ашыктылар, чөнки кораб төзү өчен чи агач ярамый, ул кибеп өлгерергә тиеш иде. Кораб төзүчеләр апрель аеның буеннан-буена тырышып эшләделәр: көн белән төн тигезләшкән чордагы көчле давылларны исәпкә алмаганда, бу айда күңелсез вакыйгаләр булмады. Юп урман кисүчеләргә ярдәм итте — агачны аудару өчен иң очына менеп аркан бәйләп төшү дисеңме, кабыгы каезланган бүрәнәләрне җилкәсенә күтәреп ташуны —ниләр генә эшләмәде маймыл.

Хәрабә янына иркен генә агач әвеслек кордылар, бүрәнәләрне шуның астына әрдәнәләп өеп куйдылар, эшне башлаганчы алар анда кибеп торырга тиеш иде.

Апрельдә, Төньяк ярымшардагы октябрь аендагыча, көннәр аяз торды. Кораб эшеннән башка, утрау хуҗалары Күзәтү яссылыгында да хезмәт иттеләр, җирне әйбәтләп эшкәрттеләр. Юлбасарлардан калган җимешлекләрне бетерергә керештеләр. Яңа тегермән салдылар, кошларга яңа кетәк кордылар. Кош-корт саны ишәйгәнлектән, кетәкләрне элеккесенә караганда киңрәк итеп төзергә туры килде. Ат абзарында хәзер биш онагр яши — дүртесе көчле, таза, җигәргә өйрәтелгән онагрлар: аларны арбага да җигәләр, атланып та йөриләр. Ә күптән түгел тагын бер колын туган иде. Утрауда җир эшкәртү кораллары да артты — сука ясадылар. Онагрларны сукага җигеп җир сукаладылар. Быел утрау кешеләренең һәрберсе эшли, берәү дә кул кушырып утырмый иде,— эш кешеләренә хас булганча, алар һәм-

мәсе таза-сау, сәламәтлекләренә теләсә кем кызыгырлык; эштән кайткач, Гранит сарайда кичләрне күңелле уздыралар, киләчәккә матур-матур хыяллар коралар!

Айртон хәзер дуслык җәмгыятенең тулы хокуклы әгъзасы, мал утарында аерым яшәргә теләми иде. Әмма ул күбесенчә моңлы-уйчан була, аз сөйләшә, иптәшләре белән күңел ачуга әллә ни катнашмый, баш күтәрми эшли дә эшли. Үзе ул көчле, җитез, зиһенле, булдыклы эшче, аны яраталар, ихтирам итәләр, ул моны сизми түгел, сизәдер.

Мал утарын да ташлап бетермиләр. Көн аралаш берәрсе арба җигеп яисә онагрга атланып терлек-туарга азык салырга бара, кәҗәләрне савып, сөтен алып кайта да Наб карамагына тапшыра.

Барган юлы шунда киекләр дә аулыйлар. Шуңа күрә мал утарына күбесенчә Герберт белән Гедеон Спилет йөри. Алар Топны да ияртәләр. Сунарчылар киек ауларга хәзер тәмам остарып җиттеләр, киек җәнлекләр: су дуңгызлары, агутлар, көңгерәләр, кабаннар чоланда өсте-өстенә өстәлеп тора. Киек кош итеннән дә өзелмиләр: кыр үрдәкләре, көртлек, суер, жакамар, чуллыкларны атып кына торалар. Табигатьнең хәзинәләре мул: куяннар бакчасында — куяннар, сайлыкларда — кабырчыклар, яр буенда ташбакалар, Рәхмәт елгасында уйнаклаган балык көтүе дисеңме — барысы да бар. Күзәтү яссылыгында исә яшелчәләр, урманнарда — кыргый җимешләр: ниләр генә юк хәзер утрауда! Баш пешекче Наб аларны чоланга ташып өлгертә алмый.

Шунысын да әйтергә кирәк, Гранит сарай белән мал утары арасындагы телеграф чыбыкларын яңадан тоташтырдылар. Мал утарына киткән берәрсе төн кунарга калса, шундук хәбәр җибәрә. Утрауда хәзер яңадан тынычлык урнашты, һәрхәлдә, усал ниятле кешеләр һөҗүме көтелми иде.

Хәер, утрауга тагын качкын каторжаннар килеп чыкмас, бәла кабатланмас дип кем әйтә ала. Белмәссең, Боб Гарвейның Норфолк утравында тоткынлыкта калган җинаятьче иптәшләре, аның үрнәгенә таянып, явыз ниятләрен кабатларга уйласалар нишләрсең... Шуңа күрә утрау хуҗалары кораб туктардай урыннарны һәрвакыт күзәтә торалар. Берләшү бухтасыннан алып Вашингтон бухтасына хәтле киң офык сызыгын зурайткыч труба белән өзлексез күзәтәләр. Мал утарына барган саен көнбатыш юнәлештәге диңгезне дә бик жен-

теклэп карыйлар иде, Франклин тавы сыртларыннан диңгез бик еракка хэтле күренэ.

Әлегэ хэтле шикле нэрсэ күзгэ чалынмаса да, һәрвакыт сак, уяу булырга туры килэ.

Көннәрдән беркөнне кич белән Сайрес Смит иптәшләренә мал утарын ныгытырга кирәклеген әйтте. Койманы биегәйтергә, дошманнан кереп яшеренү һәм һөҗүмне кайтару өчен ныгытма корырга киңәш итте... Гранит сарай табигать тарафыннан болай да үтеп керэ алмаслык итеп эшләнгән, ә мал абзарындагы каралтылар, андагы азык-төлек, арандагы терлек-туар ят күзләрнең игътибарын тартып торачак, шуңа күрә аны саклау чараларын күрергә кирәк иде.

Мал утарын ныгыту хакында әле әйбәтләп уйларга, бу эшне телиләрме-теләмиләрме язга хәтле кичектерергә туры килде.

15 нче майга Хәрабә янында яңа корабның борын һәм койрык өлешләренә терәк куелган «умрау сырты» әзер булды. Таза имәннән ясалган бу сыртның озынлыгы йөз дә ун фут иде; аңа егерме биш футлы палуба өрлеге куярга мөмкин иде. Кораб төзүчеләр салкыннар башланганчы шуларны гына ясап өлгерделәр. Икенче атнада корабның койрык өлешенә беренче кабыргаларын беркеттеләр, шуннан соң эшне туктатырга туры килде.

Ай ахырында көннәр тәмам бозылды. Көнчыгыштан каты җилләр исте, әледән-әле давыл чыкты. Сайрес Смит төзелә башлаган кораб өчен борчыла иде. Аның урынын дөрес сайлаганнар сайлавын, ул Гранит сарай янында гына иде, ә бит давыл вакытында Котылу утравы ышанычлы түгел иде, өермәле җил куып китергән тау-тау дулкыннар аның өстеннән узып Гранит сарай итәгенә хәтле тәгәрәп киләләр дә гранит стенага китереп бәрәләр иде.

Инженер юкка хафаланган икән, җил әлегә күп вакыт көньяк-көнчыгыштан исә, шул сәбәпле Гранит сарайны Табылдык борыны кыялары әйбәт ышыклый иде.

Пенкроф белән Айртон кораб төзүгә ихластан тотынганнар иде, аны быел күбрәк эшләп калырга тырыштылар; үзәкләренә үтеп әче җил искәндә дә, җеп бөртекләренә хәтле яңгыр чылатканда да эшне ташламадылар; кулдагы чүкеч кадакны көннең нинди булуына карамастан яхшы кага дип юандылар. Әмма яңгыр-

лардан соң көн суытып җибәрде, салкында агач тимер кебек катып китте, балта осталарына аны эшкәртүе кыенлашты, һәм 10 нчы июньдә кораб төзүне тәмам туктатып торырга туры килде.

Сайрес Смит һәм аның иптәшләре Линкольн утравында кышның аеруча салкын икәнлегенә күптән игътибар иткәннәр иде инде. Мондый каты салкыннар экватордан Линкольн утравы белән бердәй ераклыкта урнашкан Яңа Англия штатларында гына була торган иде. Төньяк ярымшардагы Яңа Англиядә һәм Кушма Штатларның төньяк өлкәләрендә мондый каты салкыннарның сәбәбе җир өстенең сөзәклегеннән, Котып белән чиктәш булуыннан дип аңлатыла: анда төньяк җилләреннән ышыкларлык таулар, калкулыклар юк. Әмма Линкольн утравындагы кышның салкынлыгын бу сәбәп белән аңлатып булмый иде.

Беркөнне бу турыда сүз чыккач, инженер иптәшләренә:

— Күзәтүләрдән күренгәнчә, бер үк географик киңлектә урнашсалар да, утраулар, диңгез яр буйлары континентларның үзәк өлкәләренә караганда җылырак була. Мәсәлән, мин Ломбардиядә кышның Шотландиягә караганда кырысрак икәнлеген ишеткәнем бар. Моның сәбәбен болай аңлаталар: диңгез җәй көне җылынып кала да кыш көне шул җылысын кайтара, имеш. Димәк, утрауда, гомумән, кыш йомшаграк булырга тиеш,— диде.

— Мистер Смит, алайса нигә Линкольн утравы әлеге кагыйдәгә туры килми соң? — дип сорады Герберт.

— Моны аңлату кыен,— диде инженер.— Мондагы климатның үзенчәлекле булуы утравыбызның Көньяк ярымшарга урнашуы аркасындадыр. Ә Көньяк ярымшарда кыш Төньяк ярымшардагыга караганда кырысрак була, аныСын син беләсең, балакаем.

— Әйе шул, дөрес,— дип аның сүзенә кушылды Герберт.— Тын океанның көньягында котыптан шактый еракта йөзеп йөрүче бозларны очратырга мөмкин.

Аның сүзенә Пенкроф та өстәп җибәрде:

— Мин кит аулаучы суднода йөзгәндә Горн борыны турысында да айсберглар очрый иде.

— Алайса Линкольн утравыннан ерак түгел айсберглар йөзеп йөргәнгә яисә боз кыры барлыкка килгәнгә күрә кыш үзәккә үтәрлек салкындыр,— диде Гедеон Спилет.

— Сезнең фикерегезнең дөреслеккә туры килүе мөмкин, кадерле Спилет,— диде Сайрес Смит.— Боз таулары якын булганга монда кышлар кырысрактыр. Анныры Көньяк ярымшарның Төньяк ярымшарга караганда салкынрак булуының физикага нигезләнгән сәбәбе дә бар: җәй көне бу ярымшарга кояш якынрак тора, димәк, кышын ул аннан һичшиксез ераграк булырга тиеш. Кыш белән җәйнең уртача температурасы арасындагы зур аерма шуның белән аңлатыла. Линкольн утравында кыш аеруча салкын, ә җәй бик кызу була.

Пенкроф кашын җыерды.

— Мистер Смит, безнең Көньяк ярымшарда нигә шулай җайсыз соң? Бу гаделлек түгел инде!

Инженер көлеп куйды:

— Дустым Пенкроф, гаделлекме, түгелме, әмма моның белән исәпләшмичә хәл юк, бу — факт. Җирнең Кояш тирәли хәрәкәт итә торган юлы түп-түгәрәк түгел, бәлки озынчарак, бу — механика законына нигезләнгән. Шуңа күрә Җир билгеле бер вакытта афелиягә, ягъни юлының Кояштан иң ерак ноктасына җитә; ә икенче вакытта — перигелиядә, димәк, юлының Кояшка иң якын ноктасында була. Җирнең Кояштан иң ерак ноктасы Көньяк ярымшарда урнашкан илләрнең кыш көненә туры килә; димәк, бу өлкәләрдә кышның салкынлыгы шуңа бәйләнгән. Моны бернишләтер хәл юк, Пенкроф. Галәмнең төзелешен иң бөек галимнәр дә үзгәртә алмый.

Пенкроф бу котылгысыз хакыйкатькә көчкә генә күнде бугай.

— Шулай да гаҗәп хәл! Дөнья бик катлаулы төзелгән! Кешеләрнең барлык белгәннәрен язсаң, калын-калын китаплар туар иде,— дип өстәде Пенкроф.

— Әгәр дә кешеләрнең белмәгәннәрен язсаң, аннан да калынрак китаплар килеп чыгар иде әле,— диде Сайрес Смит.

Ни генә дисәң дә, июньдә утрауда гадәтләнгән кырыс кыш башланды, алар күп вакыт Гранит сарайдан чыга алмыйча утырдылар.

Болай ябылып утыру һәммәсен ялыктырып бетерде, бигрәк тә Гедеон Спилет тоткынлыкка түзә алмый иде.

Бервакыт ул Набка болай диде:

— Әгәр дә, сүз тыңлап, газета-журналлар яздыра торган җиргә барып, миңа иң начар дигән газета гына булса да яздырып килсәң, мин бөтен шартың китереп

нотариустан расланган кәгазь язар идем дә барлык мөлкәтемне сиңа мирас итәр идем! Валлаһи, бәхетем түгәрәкләнсен өчен миңа бары газета җитми. Их, дустым, һәр көн туган саен кичә бөтен дөньяда ниләр булганын белеп торуы рәхәт икән ул!

Наб көлеп җибәрде.

— Кара син, дөнья хәбәрләрен белеп торасы килә икән! Ә мин эш арасында барысын онытам тагын. Һәр көн эш муеннан бит!

Чынлап та, өй эчендә дә, тышта да эшнең кыш көне бетәсе юк.

. Линкольн утравы хуҗаларының өч еллык тырышлыгы нәтиҗәсендә биләмә быел чын мәгънәсендә чәчәк атты. Баткан бриг аларның тагын бер хәзинә чыганагына әверелде. Төзелә торган корабка җитәрлек җиһазлар, кирәк-яраклар булу өстенә, Гранит сарай чоланнары савыт-саба, эш кораллары, сугыш кирәк-яраклары, кием-салымга баеды. Алар моннан соң тула басып азапланмадылар. Беренче кышны чыкканда бик туңганнар иде, хәзер алар иң каты суыклардан да курыкмыйлар. Эчке киемнәре дә күбәйде, аларны чиста, пөхтә тоталар. Диңгез тозындагы натрий хлоридыннан Сайрес Смит асат кына натрий һәм хлор аерып алды. Натрийны — сода ясаганда, ә хлорны хлорлы известь булдыру өчен файдаланалар; әйе тегесе дә, монысы да кер юганда кулланыла иде. Хәер, алар кием-салымны берьюлы күп итеп, борынгы заманнарның ишле гаиләләрендәгечә, елга дүрт тапкыр гына юалар, һәм, әйтергә кирәк, көн саен газета уку турында хыялланган Гедеон Спилет белән Пенкроф керне бик агартып юалар иде.

Кышның июнь, июль, август айлары тыныч кына узып китте. Көннең салкынлыгы Фаренгейт буенча уртача сигез градустан (Цельсий буенча минус 13,33° тан) артмады. Кыш, гомумән, узган елга караганда кырысрак булды булуын. Гранит сарайда мичләрне кызу итеп яктылар. Каминнарда ялкын көне-төне сүнмәде, стеналарга буй-буй сөрем утырды. Утынны кызганмадылар,— урман якын. Кораб өчен әзерләгән бүрәнәләрнең яраксызын да утынга турадылар, ташкүмерне ташуы кыен булганга, аны саклап тоттылар.

Кешеләр генә түгел, терлекләр дә әйбәт кышладылар. Юп абзый гына кышлыксыз икән,— хәер, туңу аның бердәнбер кимчелеге иде. Маймылга эченә мамык

салып халат сырып киерттеләр. Әйбәт хезмәтче булып чыкты ул; бик җитез, булдыклы, тырыш үзе, теленә салынмый. Иске һәм Яңа Дөньядагы барлык хезмәтчеләргә үрнәк була алырлык иде.

— Нигә гаҗәпләнәсез аңа? Дүрт куллы бит ул, шулай булгач аннан таләп тә зуррак, исемен акларга тиешлә ул! — диде Пенкроф.

Акыллы хайван шул хәтле дә тырыша инде мәхлук!

Франклин тавы тирәсеннән серле затның торагын эзләү сәяхәтеннән соң җиде ай узды, шул вакыт эчендә дә, сентябрь аенда көннәр җылына башлагач та, утраудагы мәрхәмәтле даһи үзен сиздермәде. Хәер, дөресен әйткәндә, аның ярдәменә мохтаҗлык та төшмәде,— бу вакыт эчендә безнең дусларга бәхетсез хәлләргә, язмышның авыр сынауларына тарырга туры килмәде.

Билгесез зат Гранит сарай кешеләре белән калын гранит идән аша яшерен элемтәгә керергә дә тырышмады кебек, югыйсә Топ шундук сизгән булыр иде. Этнең хәзер ырылдаганы, Юпның тынгысызланып мыгырдаганы тоелмый. Топ белән Юп бик тату яшиләр, күптән инде бу ике дусның чоландагы өсте ябулы кое тирәсендә буталганнары, үрсәләнеп өргән, шыңшыганнары юк. Элек инженер аларның мондый кыланышына тиз игътибар итә торган иде. Дөрес, Сайрес Смитның бу табышмакны чишәргә теләве әле дә сүнмәгән. Мөгаен, билгесез шәфкать иясенә дә яңадан үзен сиздерердәй көтелмәгән хәлләр килеп чыкмый калмастыр, шәт. Киләчәктә тагын ниләр күрергә язгандыр, белмәссең. Кышны исән-сау чыктылар, әмма язның беренче көннәрендә үк көтелмәгән хәл килеп туды һәм аның ахыры начар буласы ачык иде.

Җиденче октябрьдә Сайрес Смит, Франклин тавын күзәткәндә, сүнгән вулкан авызыннан һавага нечкә генә төтен баганасы белән ап-ак пар болыты чыгуын күреп алды.

Унбишенче бүлек

Вулкан уяна.— Җәй.— Эшне башлап җибәрделәр.— 15 нче октябрь киче.— Телеграм.— Үтенеч.— Җавап.— Тизрәк мал утарына барырга!— Язу.— Яңа телеграф чыбыгы.— Базальт кыялар.— Суның күтәрелгән вакыты.— Суның кимүе.— Мәгарә.— Күз камаштыргыч яктылык.

Инженердан хәвефле хәбәр ишетүгә, иптәшләре, эшләрен ташлап, дәшмичә генә Франклин тавына төбәлделәр.

Вулкан йокыдан уяна ахры: аның карыныннан күтәрелгән газлар һәм пар болыты кратер авызына бөялгән каты токымнар аша саркып торалар иде. Җир астында дөрләгән ут өскә үк бәреп чыгармы, вулкан котырып ата башлармы — анысын әлегә әйтүе кыен иде, һәм афәтне булдырмыйча калу да кешеләр кулыннан килә торган эш түгел иде.

Вулкан ата калса да, аның зыян-җәбере бөтен утрауга ук тимәс, бәлкем. Вулкан авызыннан ташып чыккан эрегән тау токымнары һәрвакытта хәвефле булмый бит. Утрау мондый сынауны уздырган инде,— әнә, тауның төньяк битеннән агып төшеп, катып калган лава ташкыны моңа шаһит. Өстәвенә, кратер төньякка авыш һәм аның өске ягындагы тирән ярык лаваны кабат утрауның уңдырышсыз ягына таба юнәлдерергә тиеш сыман.

Элек шулай булгач та, киләчәктә дә шулай булыр микән соң? Вулканнарның иске авызы бик каты томалангач, уты яңа урыннан бәреп чыккан очраклар да еш була ич. Әнә бит Этнада, Попокатепетлада, Орисабта шундый хәл булды. Вулкан атар алдыннан еш кына көтелмәгән хәлләр килеп чыга. Вулкан атканда җир дә тетри, ә җир тетрәгәндә янартауның эчке төзелеше үзгәрә, эрегән лава үзенә яңа юл яра ала.

Сайрес Смит иптәшләренә әнә шуларны сөйләде һәм, артык куәртмыйча гына, хәлнең хәвефле икәнен исбатлый торган дәлилләр китерде.

Әмма аларның бу хәлне үзгәртергә кулларыннан килми иде инде. Гранит сарайга әлегә хәвеф-хәтәр янамый, тик җир тетрәсә генә куркыныч. Әгәр дә Франклин тавының көньяк битендә яңа кратер ачылса, мал утарына да зыян итәчәк.

Шул көннән алып тау түбәсендә ап-ак пар болыты

күренеп тора башлады, ул көннән-көн күперә, җәелә бара иде. Әмма әлегә сөттәй куе пар эчендә ут чаткылары җемелдәми. Кайдадыр түбәндә тау эчендә генә күзгә күренмәс учак дөрли иде, күрәсең.

Ни генә булмасын, утрау хуҗалары көннәр җылынуга эшне башлап җибәрделәр. Кораб төзүне ашыктырырга кирәк иде. Диңгез яры буендагы шарлавыкны Сайрес Смит такта яруга көйләде. Хәзер балта осталары тактаны бик тиз, ансат яралар. Бу гади җайланманы инженер Норвегия авылларындагыңа охшатып ясады. Җайланма ике юнәлештә берьюлы хәрәкәт итүгә көйләнгән: бүрәнә яткан хәлендә шуып бара, ә пычкы өстән аска кисә, хикмәт шунда.

Ай ахырына Хәрабә янында кораб гәүдәсенең төп өлешләре җыелып бетте. Корабның нинди буласын аермачык күз алдына китерергә мөмкин иде инде. Аның борын өлешен тар, ә койрык ягын киң иттеләр, ерак юлга йөзә торган шхуна иде бу. Әле тышкы һәм эчке тышлыкларын кагасы, палубасын җәясе бар. Аңа вакыт күп китәчәк. Шартлаган пират бригының тимерле өлешләрен коткарып калулары файдага булды. Бриг тышлыгының калдҗаеп беткән табакларыннан, агач тирәкләреннән Пенкроф белән Айртон шөрепләрен, бакыр кадакларын суырдылар. Шулай итеп, тимерчеләргә эш кими төште, ә балта осталарының эше очсыз-кырыйсыз иде әле.

Өстәвенә, кораб төзүне бер атнага бүлеп торырга туры килде, чөнки печән чабу, уңыш җыю вакыты җиткән иде. Күзәтү яссылыгыннан җыелган ашлыкны, яшелчәләрне келәтләргә ташып куярга кирәк иде. Бу эшләрне төгәлләгәч, янә кораб төзергә тотындылар, һәм инде аннан бер генә секундка да бүленмәделәр.

Кичләрен төзүчеләр бик арыйлар, көчкә аякларында басып торалар иде. Вакытны әрәм итмәс өчен ашауның вакытын да авыштырдылар: көндезге ашны төш вакытында, ә кичкесен кояш баегач, тәмам караңгы төшкәч кенә ашыйлар. Гранит сарайга кайтып керүгә йокыга авалар иде.

Хәер, кайчакларны кызыклы әңгәмә башланып китә дә соң ятарга туры килә. Шхуна төзелеп бетүгә, кешеләр яши торган җирләргә сәяхәткә чыгабыз дип куаналар, ул сәяхәт аларның язмышын бәхетле якка үзгәртергә тиеш. Әмма алар барыбер озакламый Линкольн утравына кире әйләнеп кайтырга уйлыйлар! Кайтмас-

ка соң! Үзләре нигез салган, нихәтле көч-хезмәтләре кергән, авыр сынаулар кичергән, зур җиңүләргә ирешкән биләмәне нигә бөтенләйгә ташласыннар алар! Америка белән элемтә урнаштыргач, биләмәдәге тормыш тагын да тизрәк алга китәчәк әле.

Пенкроф белән Наб хәтта утрауда калып гомер кичерергә хыялланалар иде.

— Герберт, син утравыбызны ташлап китмәссең бит? — диде беркөн Пенкроф.

— Юк, Пенкроф, әгәр син монда каласың икән, мин дә китмим!

— Әйе, мин монда калырга булдым, сөеклем,— диде Пенкроф.— Мин сине монда көтәрмен. Ә син хатының, балаларың белән әйләнеп килерсең. Мин синең балаларыңны багармын, алар батыр булып үсәрләр, исең китәр!

Герберт кызарып чыкты, көлә-көлә әйтте:

— Ярый, хәл иттек!

Аннары Пенкроф кычкырып хыялланырга кереште:

— Ә сез, мистер Сайрес, утрауның даими губернаторы булырсыз. Шунысын сорыйм дигән идем: утравыбыз күпме халыкны туендыра алыр икән? Минемчә, ун меңнән дә ким булмас.

Дуслар әнә шулай еш кына кичләрен гәпләшәләр. Пенкрофның сүзләреннән берсе дә көлми, киресенчә, ул һәммәсен үзенең хыяллары артыннан ияртә, ә журналист утрауда «Нью-Линкольн геральд» газетасы чыгарырга уйлый иде.

Әйе, адәм баласы иҗат итәргә, җир йөзендә үз эзен калдырырга, бөтен күңелен үзеннән соң да яшәячәк зур эшкә багышларга омтыла. Кешене җир шарында яшәгән хайваннардан өстен иткән сыйфатлар да әнә шулар. Кешеләрнең хайваннар дөньясына хакимлеге шуның белән акланадыр да.

Хәер, белмәссең, Топ белән Юп та киләчәк турында хыялланалардыр, бәлкем.

Бер Айртон гына хыялын эчендә саклый: гаебе акланган килеш лорд Гленарван белән очрашу, яңа кеше булып һәммәсе алдына килеп басу аның өчен олы бәхет булыр иде.

15 октябрьдә күңелле әңгәмә гадәттәгедән озаккарак сузылды. Йокларга вакыт җиткәнен искәрткәндәй, күбесенең авызы зур-зур итеп ачыла башлады. Пенкроф

ятагына таба кузгалган да иде инде, кинәт шул чак залда электр кыңгыравы чыңлады.

Дуслар барысы монда җыелган: Сайрес Смит, Гедеон Спилет, Герберт, Айртон, Наб һәм Пенкроф — һәммәсе дә өйдә, мал утарында беркем юк чак иде.

Сайрес Смит урыныннан торды. Бүтәннәр, ялгыш ишеттек мәллә дигәндәй, бер-берсенә аптырашып карашып алдылар.

— Нәрсә икән бу? Әллә берәр җен шалтыратамы? — дип куйды Наб.

Бу шаяртуга берәү дә җавап бирмәде.

Герберт:

— Бу арада яшеннәр яшьни. Бәлкем, электр корылмаларының гәэсиредер әле,— дип әйтә башлаган иде, бөтенесенең сораулы карашы төбәлгән инженер башын чайкады.

— Көтик әле,— диде Гедеон Спилет.— Әгәр берәрсе сигнал бирергә тели икән, кабат шалтыратырга тиеш.

— Кем сигнал бирсен икән соң? — диде Наб.

— Әллә оныттыңмы? — диде Пенкроф.— Теге...

Аның сүзен каты чылтыраган кыңгырау тавышы бүлде.

Сайрес Смит аппарат янына килде, токны тоташтырып, утарга телеграм сукты:

«Ни кирәк?»

Беравыктан алфавитлы түгәрәк өстендәге ук йөреп китте һәм Гранит сарай кешеләре түбәндәге сүзләрне укыдылар:

«Тиз генә утарга килегез!»

— Ниһаять! — дип җиңел сулап куйды Сайрес Смит.

Ниһаять, сер ачылачак! Һичкем арымаган диярсең, күзләреннән йокы качты — һәммәсе тизрәк утарга барырга атлыга иде. Ләм-мим сөйләшмичә тиз генә юлга әзерләнделәр, берничә секундтан алар диңгез ярында иделәр инде. Гранит сарайда Топ белән Юп кына калды. Бу сәяхәткә аларны алуның кирәге шул хәтле генә иде.

Тирә-як дөм караңгы. Бүген туган яңа ай кояш баеганда ук күк йөзеннән югалды. Герберт искәрткәнчә, яшенле яңгыр җыена иде. Күк йөзен кап-кара болытлар каплап алды. Авыр болытлар өскә үк салынып төште. Офыкта әледән-әле аҗаган кабынып ала иде.

Берәр сәгатьтән утрауга көчле яңгыр коячак. Төн бик хәвефле, тәшвишле иде.

Безнең дусларны күзгә төртсәң күренмәслек караңгылык та токкарлый алмады. Утар юлыннан алар күз йомып та бара алалар иде. Менә алар Рәхмәт елгасының сул яры буйлап барып, Күзәтү яссылыгына менделәр, Глицерин инеше күпереннән чыктылар һәм урманга кереп киттеләр.

Юлчылар, кызыксынудан дулкынланып, ашыга-ашыга атлыйлар. Кайчаннан бирле эзләп тә таба алмаган сернең ачкычы хәзер алар кулына төшәчәк. Утрау тормышы белән тыгыз бәйләнгән яшерен шәфкать иясенең, киң күңелле, кодрәтле билгесез затның исеме тиздән мәгълүм булачак. Ул, һичшиксез, аларның тормышын илтифат белән күзәтәдер, һәрбер вак-төяк мәшәкатьләренә хәтле белеп торадыр, Гранит сарайда сөйләшкән һәр сүзне ишетәдер, югыйсә иң кирәк чакта ярдәм итәргә өлгермәс иде.

Һәркем үзалдына уйга баткан, кызу-кызу атлый. Агач ябалдашлары астында кап-караңгы, хәтта юл читләре дә күренми. Урманда кабер тынлыгы хөкем сөрә. Яшенле яңгыр алдыннан була торган шомлы бөркүлек изә, кошлар, җәнлекләр тынып посканнар. Хәтта агач яфраклары да лепердәми. Караңгыда юлчыларның таш кебек каты җиргә дөп-дөп баскан аяк тавышлары гына ишетелә.

Юлга чыкканнан бирле чирек сәгать эчендә тынлыкны фәкать Пенкрофның бер соравы һәм инженерның аңа җавабы бозды.

— Фонарь аласы калган,— диде диңгезче.

— Фонарьны утарда табарбыз,— диде инженер.

Сайрес Смит һәм аның юлдашлары Гранит сарайдан унынчы унике минутта юлга чыкканнар иде. Унынчы кырык җиде минутта алар биш миль юлның өч милен уздылар да инде.

Күк йөзен бөтен иңенә ялт та йолт яшен утлары яктырта, яшен яктысында тирә-яктагы агач яфраклары кап-кара челтәр булып аермачык күренә башлады. Көчле яктыдан күзләр камаша. Менә-менә яңгыр коярга тотыначак. Әнә бит яшен камчылары күк йөзен тагын да ешрак телгәлиләр, дәһшәтле-куркыныч булып ялтырыйлар иде. Күкрәү тавышы якынайды. Һава түзеп булмаслык бөркүләнде.

Ниндидер тыелгысыз көч тартып алып баргандай, юлчылар кызулаганнан-кызуладылар.

Унберенче унбиш минутта яшен яктысы ялтырап

киткән арада алда утар коймасы күренде. Капкадан эчкә керүгә, күк шартлап ярылгандай булды.

Юлчылар ишегалдын күз ачып йомганчы йөгереп уздылар да өй ишеге төбенә атылып менделәр.

Билгесез кеше өйдә булса кирәк,— телеграмны ул аннан суккан бит. Әмма бер генә тәрәзәдә дә ут яктысы күренмәде.

Инженер ишек шакыды.

Җавап ишетелмәде.

Сайрес Смит ишекне ачты, һәммәсе кап-караңгы өй эченә атладылар.

Наб, чакма чагып, фонарьга ут кабызды һәм өй эченең һәммә почмагын яктыртып карап чыкты...

Өйдә беркем юк иде. Бер генә әйбер дә урыныннан кузгалмаган, үзләре ничек калдырып киткән булсалар, шул хәлендә иде.

Сайрес Смит, аптырап:

— Әллә ялгыш булдымы бу? — дип пышылдады.

Ялгышмадылар бит инде югыйсә, телеграмда ап-ачык итеп:

«Тиз генә утарга килегез!» диелгән иде.

Юлчылар телеграф торган өстәл янына килделәр. Монда да һәр нәрсә үз урынында иде — батареяларга, аларның әрҗәсенә, кабул итүче һәм тапшыручы аппаратларга беркем кагылмаган.

— Иң соңыннан монда кайсыгыз булган иде? — дип сорады инженер.

— Мин, мистер Сайрес,— диде Айртон.

— Кайчан?

— Дүрт көн элек.

Герберт өстәлгә таба ишарәләде:

— Карагыз әле, язу!

Өстәл өстендә ак кәгазь ята иде, аңа инглизчә:

«Яңа телеграф чыбыгы буйлап барыгыз», дип язылган иде.

— Юлга! — дип боерды Сайрес Смит.

Ул телеграмның утардан түгел, ә билгесез кешенең яшерен торагыннан җибәрелгән икәненә төшенде. Иске чыбыкка ялганган яңа телеграф чыбыгы аның торагын Гранит сарай белән тоташтыра, күрәсең.

Наб кулына фонарь алды, һәм алар утардан чыгып киттеләр.

Тышта яшен котырына. Яшен ялтырауга ук колак ярып күк күкрәп җибәрә. Яшеннең Франклин тавы өс-

тенә, утрау турысына ук килеп җиткәнлеге сизелә. Яшен яктысында вулкан түбәсендәге пар болыты күренеп-күренеп китә иде.

Утар ишегалдында яңа чыбык күренмәде. Капкадан чыгуга, Сайрес Смит беренче телеграф баганасы янына йөгереп барды, яшен яктырткан арада ул багана башындагы изолятордан җиргә чыбык сузылып төшкәнен күреп өлгерде.

— Менә ул! — диде.

Тимер чыбык җирдән сузылып бара иде, ул су астындагы кабель кебек яхшы тышча эчендә иде. Чыбык урман аша тауның көньяк итәгенә таба, аннан утрауның көнбатыш ярына таба сузылган.

— Чыбык буенча барыгыз! — диде Сайрес Смит.

Әле тонык фонарь уты яктысында, әле күз камаштыргыч яшен яктысында сәяхәтчеләр телеграф чыбыгын күрә-күрә алга атладылар.

Баш түбәсендә дөбер-дөбер күк күкрәгәнлектән сөйләшергә мөмкин түгел иде. Хәер, сүзнең хәзер кирәге дә юк иде, бердәнбер максат — тизрәк алга бару иде.

Сайрес Смит һәм аның иптәшләре утар урнашкан үзәнлек белән Шарлавык елгасы үзәнлеген аерып торган тау сыртын иң тар җиреннән кичтеләр; әле агач ботакларына эленгән, әле җирдән сузылган чыбык аларга юл күрсәтә иде.

Инженер чыбыкны үзәнлек түрендә бетәр,— билгесез кешенең яшерен торагы шунда урнашкандыр дип өметләнгән иде. Өмете акланмады. Аларга әле көньяк-көнбатыш тау сыртына да менәргә һәм әкияти базальт кыяларга хәтле сузылган яссытаулык өстенә дә төшәргә туры килде. Дөрес барабыз микән дип, әледән-әле я берсе, я икенчесе җиргә иелеп чыбыкны капшый. Инде күренеп тора ки, чыбык туп-туры диңгезгә таба сузылган. Бик озак эзләп тә таба алмаган яшерен торак шундагы билгесез кыялар арасында тирән мәгарәгә урнашкандыр, күрәсең.

Хәзер гүя бөтен күк йөзен тоташ ут чолгап алды: яшен бертуктаусыз яшьни иде. Яшен камчысы күктән сузылып төшә дә вулкан түбәсенә китереп бәрә һәм куе төтен белән тулган кратерга кереп юкка чыга. Гүя тау үзе утлы яшен атып утыргандай тоела иде.

Унбер туларга берничә минут кала юлчылар утрауның көнбатыш ярына, диңгез өстендә калкып торган биек гранит стенаның читенә үк килеп җиттеләр. Биш

йөз фут аста диңгез дулкыннары үкерә-үкерә таш ярны кыйный иде.

Сайрес Смитның исәпләвенчә, алар утардан бер миль ярым ара килделәр. Телеграф чыбыгы хәзер кыялар арасындагы тар гына тирән чокырның текә ярыннан аска таба юнәлгән иде.

Юлчылар аска төшә башладылар. Һәр атлаган адым бик хәтәр монда: тотрыксыз таш кантарлары урыныннан кубар да аларны диңгезгә сыдырып төшерер кебек иде. Әмма алар курку дигәнне уйга да кертеп чыгармадылар,— үз ихтыярларына үзләре хуҗа түгел иде инде алар. Тимер валчыкларын магнит үзенә тарткан кебек, билгесез кешенең серле торагы да аларны ирексездән үзенә тарта иде.

Хәтта көндез карарга да коточкыч тоелган чокыр битеннән алар ничек төшкәннәрен дә сизмәделәр. Аяк асларыннан ташлар тәгәрәп-тәгәрәп китә, яшен яктысында алар утлы метеор кебек ялтырап калалар. Сайрес Смит алдан бара. Иң арттан Айртон килә. Алар аякларын кыя таш читләренә тери-тери атлап төшәләр, ара-тирә юри шомарткандай тип-тигез җирләрдән кинәт таеп китәләр дә әллә нихәтле шуып баралар, янадан торып басып, аска төшүне дәвам иттерәләр иде.

Ниһаять, телефон чыбыгы кырт кына борылды да яр буендагы кыялар арасыннан узып, караләҗым ташлар тезмәсенә таба сузылды. Диңгез суы аеруча югары күтәрелгән көннәрдә дулкын бу кара ташларга җитеп бәргәләнәдер, мөгаен. Юлчылар базальт стенаның аскы киртләченә үк төшеп җиттеләр. Аста, диңгез чите белән янәшә, тар гына озын таш нигез сузыла, чыбык шуның буйлап китә икән. Юлчылар шул юнәлештә йөз адымлап баргач, сөзәк ярдан диңгезгә үк төшеп җиттеләр.

Инженер чыбыкны тотып карагач, аның су астына ук төшеп китүен белде.

Юлчылар Сайрес Смит янына җыелдылар, бу хәлгә шаккатып туктап калдылар.

Гаҗизлектән, өметсезлектән аһ итеп куйдылар. Диңгезгә ташланып, су астындагы мәгарәне эзләргә туры килер микәнни? Хисләре кузгалган, әсәренгән юлчылар ике дә уйлап тормастан хәтта суга ташланырга да әзер иделәр. Тик Сайрес Смит кына иптәшләрен тыеп калды.

Таш кыяның батынкы урынына кереп сыенырга өндәде.

— Шушында көтик. Хәзер суның күтәрелгән чагы. Су чигенгәч керү юлы ачылырга тиештер, мөгаен,— диде.

— Нигә алай дип уйлыйсыз? — дип сорады аңардан Пенкроф.

— Әгәр янына керер юлы булмаса, ул безне чакырмас иде.

Сайрес Смитның ышанып әйткән бу сүзенә каршы килүче табылмады. Дөрес әйтә, базальт стенаның су астындагы өлешендә күмелеп калган мәгарә булуы бик ихтимал иде.

Ике-өч сәгать көтәргә туры килде аларга. Юлчылар базальт стена куенына сыенган килеш яңгырдан ышыкланып басып тордылар. Яшен камчылары туктаусыз телгәләгән кап-кара болыттан инде яңгыр тоташ ташкын булып агыла башлады. Күкрәү авазлары, базальт кыяларга бәрелә-бәрелә, дөбердәп катлы-катлы булып ишетелә иде.

Юлчылар, гаять дулкынланып, ни буласын түземсезләнеп көтәләр, күңелләренә сәер уйлар килә. Нинди могҗиза булыр соң анда? Каршыларына илаһи бер зат, пәһлеван буйлы тылсымчы килеп басармы? Әйе, бу серле кодрәт иясен алар әкияттәге баһадир сурәтендә дип беләләр иде.

Төн уртасы авышкач, Сайрес Смит, кулына фонарь тотып, диңгез читендәге кыяларны күзәтергә төште. Инде ике сәгать чамасы су әкренләп чигенә иде.

Инженер ялгышмаган икән: су эченнән әнә киң генә тау куышы авызы күренә башлаган, әлеге телефон чыбыгы бөгелеп шуның эченә кереп югала икән.

Сайрес Смит иптәшләре янына әйләнеп кайткач:

— Берәр сәгатьтән мәгарә эченә керерлек булачак,— диде.

— Мәгарә чыннан да бармыни? — дип сорады Пенкроф.

Сайрес Смит сорауга каршы сорау бирде:

— Сез шикләнгән идегезме?

— Мәгарәдән су бөтенләй үк чыгып бетмәсә, әгәр төбе тирән булса, ничек анда керербез соң? — дип сорады Герберт.

— Мәгарәдән су чыгып бетәдер, әгәр су кала торган булса, утырып керергә берәр нәрсә тәкъдим итәрләр.

Тагын бер сәгатьтән һәммәсе дә коеп яуган яңгыр астында диңгез ярына ук төштеләр. Өч сәгать эчендә

су унбиш футка кимегән иде. Мәгарә авызы әкренләп судан калкып чыкты, аның түшәменә кимендә сигез футлап бардыр, күрәсең.

Гүя күпер астыннан агып чыккандай, аның эченнән әле су күбекләнеп кайнап агуын дәвам итә иде.

Инженер иелеп карагач, су өстендә ниндидер озынча карамчык чайкалып торганын күреп алды һәм аны үзенә таба тартып китерде. Бу — мәгарә эчендәге очлаеп торган бер ташка бәйләп куелган көймә иде. Көймә табаклы калайлардан эшләнгән икән. Аның төбендә, утыргыч астында, ике ишкәк күренде.

— Көймәгә! — дип әмер бирде Сайрес Смит.

Һәммәсе җәһәт кенә көймәгә керделәр. Наб белән Айртон ишәргә утырдылар, Пенкроф койрыкны тотты. Сайрес Смит юлны яктыртсын өчен көймә борынына фонарь элеп куйды.

Тау куышының тәбәнәк авызыннан эчкә кергәч, кинәт куыш киңәеп, түшәме биегәеп китте; әмма эчтә дөм караңгы булганга, фонарьның тоныҡ яктысында мәгарәнең бөтен зурлыгын күреп булмый иде; аның киңлеген дә, биеклеген дә, тирәнлеген дә чамаларлык түгел иде. Су астындагы базальт мәгарә эчендә илаһи бер тынлык хөкем сөрә иде. Бирегә тыштан бер генә аваз да ишетелми, калын стеналар аша яшен яктысы да күренә алмый.

Җир шарының кайсыдыр почмакларында, табигый төрбәләрне хәтерләтеп, ерак гасырларда барлыкка килгән бихисап зур җир асты мәгарәләре бар. Кайберләре исә диңгез астында күмелеп калган, икенчеләренең эчендә зур-зур күлләр барлыкка килгән. Мәсәлән, Гебрид утрауларының берсе Стаффада — Фингал мәгарәсе, Британьның Дуарнене бухтасында — Морг тау куышы, Корсикада — Бонифачо тау куышы, Норвегиядә Лиз-Фиорд мәгарәсе, Кентуккидагы биеклеге биш йөз фут, озынлыгы егерме мильдән дә ашып киткән Мамонт мәгарәсе әнә шундыйлар. Җир шарының төрле почмакларында табигать төзегән шушындый зур-зур төрбәләр әле дә сакланалар һәм күңелдә соклану уяталар.

Сәяхәтчеләр тап булган әлеге мәгарә дә коточкыч зур иде ахрысы. Әллә инде утрауның уртасына хәтле үк барып җитә микән дигән сорау да туды. Көймә инде чирек сәгатьтән бирле йөзә, инженерның боерыгына буйсынып Пенкроф аны әле уңга, әле сулгарак борып алып бара иде. Кинәт инженер:

— Уңгарак! — дип әмер бирде.

Көймә, юнәлешен үзгәртеп, мәгарәнең уң як стенасы буеннан бара башлады. Инженер бу мәлдә тимер чыбыкның әле дә стена буйлап барамы-юкмы икәнен белергә тели иде.

Стенадагы киртләчләргә эленгән кабельне күргәч тә:

— Алга! — дип боерды инженер.

Ике ишкәк берьюлы кара суга төшеп чумды, тукталып та өлгермәгән көймә кузгалып китте.

Тагын чирек сәгатьләп йөзделәр. Мәгарә авызыннан бирле ярты миль чамасы килгәннәрдер мөгаен. Яңадан Сайресның боерыгы яңгырады:

— Тукта!

Көймә туктады. Утрауның карынына бик тирәнгә уелып кергән бихисап зур әлеге мәгарә эчен көчле ут көлтәсе яктыртканын күреп юлчылар таң калдылар.

Моңарчы беркемгә мәгълүм булмаган бу яшерен тау куышын хәзер иркенләп карарга мөмкинлек туды.

Гүя барысы бер биеклектә, бер юанлыкта торгызылган базальт баганаларга таянып йөз футлап өскә түшәм гөмбәзе күтәрелгән. Җир кабыгы барлыкка килгән беренче дәверләрдә үк хасил булган әлеге баганаларның берсеннән берсенә челтәрле кәрнизләр, кашагалар сузылган. Берсе өстенә берсе менеп баскан базальт түмәрләрнең биеклеге кырыгар-иллешәр футка җитә; ә багана төпләрендә тыныч кына су чайпала. Утрау өстендә давыл котырынганы исә биредә сизелми дә иде. Билгесез ут чыганагыннан таралган нурлар базальт кристалларының һәр кырында чагылалар, тирә-якка аллы-гөлле чаткылар чәчеп җемелдиләр, гүя нурлар үтә күренмәле стенаның үзеннән чыга; стенадагы һәр киртләч асылташ булып елык-елык килә иде. Әйләнә-тирәдә җемелдәгән нурлар суда да чагыла, су өстендә белбелдәп ялкын уйный, гүя көймә утлы агым өстеннән йөзеп бара диярсең.

Суда уйнаклаган, базальт стеналарны, баганаларны, гөмбәзләрне нурына коендырган ут көлтәсенең чыганагы турында шик булуы мөмкин түгел,— бу электр яктысы, әлбәттә; нурының аксыл төстә булуы да шуңа ишарәли. Мәгарә эчен электр уты кояш кебек балкыткан иде.

Сайрес Смит боерыгына буйсынып, ишкәкләр янәдән суга чумды, тирә-якка чәчрәгән су тамчыларында алмаз чаткылар җемелдәде, көймә әлеге ут чыганагына

таба йөзеп китте, тиздән аның янына килеп житәрәк туктады.

Суның киңлеге бу урында өч йөз илле фут чамасы бардыр. Ут чыганагының артында базальт стена күренә. Мәгарә киңәеп, биредә күл хасил булган. Мәгарәнең биек гөмбәзе, як-яктагы диварлар, алардагы кырлы-кырлы ташлар — барысы тирә-якка нур чәчә; көчле яктылык гүя шушы ташларның үзеннән чыга, гүя ташлар затлы бриллиант кебек шомартылган да аларның һәр кыры утлы чаткылар чәчеп нурлана иде.

Тып-тын күл уртасында су өстендә орчык сыман озын нәрсә калкып тора. Аның ике башыннан, гүя кызган мич авызыннан бөркелгәндәй, ут көлтәләре бәреп чыккан. Кит сыман диңгез хайванына охшаган бу нәрсәнен озынлыгы ике йөз илле футлар чамасы, ул су өстеннән ун-унике фут өскә калкып тора.

Көймә әкрен генә аңа якынлашты. Көймә борынында утырган Сайрес Смит аягүрә басты да алга таба төбәлде һәм каушап журналистның кулына тотынды:

— Бу ул бит! Ул бит, ул! Ул!..— дип кычкырып жибәрде.

Эскәмиягә кире утырды да пышылдап тегенен исемен әйтте, аны тик Гедеон Спилет кына ишетте.

Журналист та бу исемне белә иде ахрысы, чөнки аңа инженерның сүзе бик каты тәэсир итте. Карлыгып киткән тавыш белән:

— Ул дисезме? Законнан тыш дип игълан ителгән кешеме?

— Ул! — дип кабатлады Сайрес Смит.

Инженер ишкәкчеләргә боерды, һәм көймә әлеге сәер әйбергә якынлашты. Көймәне аның сул башындагы түгәрәк стенасы янына китереп туктаттылар, стенадагы калын пыяла аша күз камаштыргыч яктылык бөркелә иде.

Сайрес Смит һәм аның иптәшләре өстәге мәйданчыкка менделәр. Ачык люк авызыннан аска төшеп киттеләр.

Аста электр уты яктырткан коридор башланды. Аның бер башында ишек күренде. Инженер ишекне ачты.

Алар музейны хәтерләткән иркен бүлмәгә керделәр. Анда минераллар патшалыгының хәзинәләре, сәнгать әсәрләре, промышленность әйберләре үрнәкләре жыелган иде. Сәяхәтчеләр гүя әкият дөньясына килеп эләктеләр.

Затлы диванда бер кеше ята иде, ул гүя бүлмәгә кешеләр кергәнен сизмәде дә, селкенмичә ята бирде.

Сайрес Смит алга атлады һәм иптәшләрен таң калдырып:

— Капитан Немо, сез чакырдыгызмы безне? Менә килдек! — диде.

Уналтынчы бүлек

Капитан Немо.— Аның беренче сүзләре.— Ил азатлыгы өчен көрәшченең гомер тарихы.—Илбасарларга нәфрәт.— Капитан Немоның юлдашлары.— Су астындагы тормыш.— Ялгызлык.— Линкольн утравы.— «Наутилус»ның соңгы торагы.— Утрауның серле даһие.

Диванда яткан кеше, бу сүзләрне ишеткәч, башын күтәрде; йөзенә ут яктысы төште; артка таралган күпереп торган чәчле, киң маңгайлы, чал сакаллы, горур карашлы бу кешенең башын тотышы сокланырлык матур иде.

Ул урыныннан торып басты, кулы белән диван аркасына таянды. Күз карашы гаять тыныч иде. Озак авырудан сәламәтлеге какшаган икәнлеге сизелеп торса да, тавышы яңгыравыклы иде: ул артык дәрәҗәдә гаҗәпләнеп, инглизчә:

— Минем исемем юк бит, хөрмәтле әфәндем,— диде.

— Мин сезнең исемегезне беләм,— диде Сайрес Смит.

Капитан Немо инженерны юк итәргә теләгәндәй утлы карашын аңа төбәде. Аннары диванга утырды да:

— Хәер, барыбер түгелме. Тиздән үләм бит,— дип пышылдады.

Сайрес Смит капитан Немо янына килде дә аның кулын тотты. Тегенең кулы кызу иде. Айртон, Пенкроф, Герберт һәм Наб читтәрәк, зиннәтле залның бер почмагында басып торалар иде. Мондагы һава электр ионнарына туенган иде.

Капитан Немо әкрен генә кулын тартып алды, инженер белән журналистка утырырга урын күрсәтте.

Һәммәсе, таң калып, сүзсез генә аңа карап торалар. «Утрауның даһие» менә кем икән; ничәмә-ничә тапкыр аларны коткарып калган кодрәт иясе, аларга нихәтле изгелекләр кылган шәфкатьле зат менә кем икән! — дип шаккаттылар. Алар алдында хәлсезләнгән, әҗәлен

күтеп яткан кеше утыра иде. Ә Пенкроф белән Наб ярым алла күрербез дип өметләнделәр бит.

Сайрес Смит капитан Немоны кайдан белә икән соң? Үз исемен беркем белми дип уйлаган капитан Немо, исемен ишеткәч, нигә сикереп торды?..

Капитан янә диванга ятты, терсәкләренә таянып күтәрелде дә янында утырган Сайрес Смитка дикъкать белән карады:

— Сез, әфәндем, минем исемне беләсезмени? — дип сорады.

— Беләм,— дип җавап бирде Сайрес Смит.— Атаклы су асты көймәсенең исемен дә беләм...

Капитан, көлемсерәп:

— «Наутилус»,— диде.

— Әйе, «Наутилус».

— Ә минем кем икәнне беләсезме? Мин кем соң, анысын беләсезме?..

— Беләм.

— Утыз елдан бирле минем кешелек дөньясы белән бертөрле элемтәм юк бит, утыз ел буе мин диңгез тирәнлегендә яшим, чөнки мин азатлыкны бары шушында таптым! Минем серне кем ачкан соң?

— Ул кеше сезгә сер сакларга ант итмәгән. Шулай булгач, аны хыянәтче дип гаепләргә сезнең хакыгыз юк.

— Моннан уналты ел элек очраклы рәвештә минем судного эләккән француз мәллә?

— Шул үзе.

— «Наутилус» Мальстримга эләккәч, ул ике юлдашы белән һәлак булмаганмыни?

— Юк, һәлак булмаган. Ул сезнең гомер тарихын сурәтләгән «Сиксән мең километр су астында» исемле китап бастырып чыгарган.

— Минем гомернең берничә аен гына диегез, әфәндем! — дип ашыгып төзәтте капитан.

— Әйе, сез хаклы, әлбәттә. Тик сезнең хакта тулы фикер тусын өчен сезнең янда берничә ай яшәү дә житкән...

— Олы җинаятьче дипме, шулаймы? — дип куйды Немо, һавалы елмайган хәлдә.— Фетнәче, мөртәт дипме?

Инженер җавап бирмәде.

— Нигә дәшмисез, әфәндем?

— Минем капитан Немоны гаепләргә, һәрхәлдә, узган эшләре өчен гаепләргә хакым юк. Беркем, шул исәптән мин дә, аның ни өчен шундый сөер тормыш бе-

лән яшәргә мәҗбүр булуын белмибез; сәбәбен белмәгәч, нәтиҗәсе өчен гаепләргә ярамый. Тик мин шунысын яхшы беләм: Линкольн утравына килеп төшкән көннән бирле сезнең шәфкатьле ярдәмегез безне даими саклый килде. Һәм без аңлыйбыз: мәрхәмәтле, киң күңелле, кодрәтле ярдәмчебезгә без мәңге бурычлы; ә ул мәрхәмәтле, кодрәтле көчкә ия ярдәмчебез сез икән, капитан Немо.

— Әйе, мин сезгә ярдәм иттем,— дип гади генә әйтеп куйды капитан Немо.

Инженер белән журналист аягүрә бастылар. Немога ихлас күңелдән рәхмәт әйтергә теләп, иптәшләре дә алар янына килделәр.

Капитан аларның рәхмәт әйтергә җыенуын кул ишарәсе белән тыйды да, дулкынланганын яшерә алмыйча:

— Туктагыз, башта мине тыңлагыз,— диде.

Һәм капитан Немо берничә сүз белән генә, әмма берни яшермичә, кыскача үз тормышын сөйләп бирде.

Хикәясе кыска булса да, сүзен сөйләп бетерер өчен аңа сүнеп барган барлык көчен тупларга туры килде. Аның хәле бетеп баруын күреп, Сайрес Смит аңа берничә тапкыр ял итәргә киңәш бирсә дә, капитан Немо баш кына чайкады. Ул иртәгә хәтле түзә алмаячагын сизә иде. Журналист, врач буларак, аны карарга теләгән белдергәч тә ул:

— Кирәкмәс, әфәндем, файдасы юк инде. Бер-ике сәгатьлек гомерем калган,— диде.

Капитан Немо Һиндстанда туып үскән; кайчандыр ирекле кнәзлек булган Бундельханд белән идарә итүче раджа улы икән; Һиндстанның атаклы диңгезчесе Типпо-Сәиб та алар нәселеннән чыккан. Ун яшьлек чагында Немоны әтисе Европага укырга җибәрә, кайчан да булса улының туган илен изүче европалыларга каршы бер дәрәҗәдә торып көрәшерлек булып җитешүен тели.

Искиткеч сәләтле, намуслы, тирән акыллы егет — принц Даккар ун яшеннән алып утыз яшенә хәтле тырышып укый, төрле фәннәрне үзләштерә, табигать белеме, математика һәм әдәбият буенча зур белем туплый.

Аннары принц Даккар бөтен Европа буйлап сәяхәт итә. Затлы нәселдән чыкканлыгы, байлыгы аркасында һәр җирдә аны зурлап каршы алалар, әмма ул югары җәмгыятьнең уен-көлкеләренә кызыкмый. Чибәр һинд егете һәрвакыт җитди, хәтта караңгы чырайлы булып кала, фәкать гыйлем үзләштерү белән мавыга. Ә кү-

келендә исә илен басып алучыларга карата сүнмәс нәфрәт уты яна. Принц Даккар бары әнә шул илгә генә нәфрәт саклый, нихәтле якты йөз күрсәтсәләр дә, аның җиренә аяк басарга теләми; ул — Англия; егет бу илнең күп якларына сокланган саен нәфрәте генә арта бара.

Бу — җиңелүченең җиңүчегә карата ачы нәфрәте! Буйсындыручы көч беркайчан да буйсынучыдан рәхим-шәфкать көтмәсен! Азатлык өчен көрәш, изүчеләргә үч рухында тәрбияләнгән һәм инглизләр тарафыннан богауланган туган илен, шигъри ватанын өзелеп яраткан һинд егете, Берләшкән Корольлеккә сүздә генә буйсынган кнәз улы, Типпо-Сәиб нәселеннән чыккан принц Һиндстанны коллыкка төшергән, ләгънәт тамгасы йөрткән хаким илнең җиренә мәңге аяк басмаска ант итә.

Принц Даккар — сәнгать могҗизаларына гашыйк рәссам да, фән өлкәсендәге һәр нәрсә белән кызыксынучы галим дә, Европаның король сарайларында дипломатиянең нечкәлекләренә өйрәнүче дәүләт эшлеклесе дә була. Читтән белгән кешегә ул һәр нәрсә белән кызыксынучан, ләкин чын эш майтарырга сәләтсез космополит; бөтен дөнья буйлап гизүче, ләкин бер илне дә үз итмәүче бай сәяхәтче, тәкәббер кысыр чәчәк булып күренүе ихтимал иде.

Ә асылда ул андый булмый. Бу рәссам, бу галим, бу талант иясе, Һиндстанның чын улы күңелендә илбасарларга үч кайный; килер бер көн, аның ватандашлары үз илләренең хокукын даулап баш күтәрерләр, чит ил баскыннарын куып чыгарып, азатлык яулап алырлар дип өметләнә иде ул.

Менә 1849 нчы елны принц Даккар Бундельхандка кайта. Аксөяк нәселдән бер кызга өйләнә. Туган иленең коллыкта газап чигүен күреп йөрәге әрнегән кыз принцның фикердәше була. Ул хатыннан ике бала туа, принц балаларын бик ярата. Гаилә бәхетенә ләззәтләнеп яшәсә дә, ул Һиндстанның коллыкта газап чигүен онытмый, форсат чыгуын көтә.

Англия хакимлеге нәтиҗәсендә Һиндстан халкы исә бөлгенлеккә төшә бара. Принц Даккар изелүчеләрне яклап чыга, чит ил басып алучыларга халык күңелендә нәфрәт кабыза. Ул бөтен ил буйлап йөреп чыга: инглизләр кул астындагы өлкәләрнең дә, әлегә азат кнәзлекләрнең дә халкын Типпо-Сәибның азатлык өчен

көрәшеп Серингапатам янында һәлак булган героик көннәрен искә төшерергә чакыра.

Һәм 1857 нче елда сипайлар баш күтәрәләр. Аларны көрәшкә рухландыручы принц Даккар була. Ул бик күп халыкны оештыра. Гадел эш өчен сәләтен дә, бар мөлкәтен дә кызганмый. Ул беренчеләр сафында курыкмыйча сугыша; туган илләрен азат итү өчен көрәшкә күтәрелгән иң гади кешеләр белән бергә гомерен дә кызганмыйча сугыша. Егерме тапкыр яу кырында була ул, ун тапкыр яралана. Һиндстанны азат итү өчен көрәшкә күтәрелгән соңгы сугышчылар дошман пулясыннан һәлак булгач, үзе дә үлем эзли, ләкин исән кала.

Һиндстанда хакимлек иткән Бөек Британиягә беркайчан да мондый зур куркыныч янаганы булмаган, әгәр дә баш күтәрүчеләргә читтән ярдәм килсә, Берләшкән Корольлекнең Азиядәге хакимлеге бәреп төшерелгән булыр иде.

Принц Даккарның исеме бу көннәрдә бөтен илгә таныла. Ул яшеренми, ачыктан-ачык көрәшә. Аны тотып бирүчегә зур акча вәгъдә итәләр, тик Даккарны тотып бирердәй бер генә хыянәтче дә табылмый. Әмма әтисе, әнисе, хатыны һәм балалары аның өчен һәлак булалар. Ул исә үзе өчен аларга куркыныч янаганын белеп өлгергәнче, аларны инде үтерәләр.

Хаклык тагын бер тапкыр көч тарафыннан җиңелә. Әмма алдынгы кешелек беркайчан чигенми, ул гүя үзенең хакын дауларга котылгысызлыктан фатиха алган.

Сипайлар җиңелә. Раджаларның борынгы кнәзлеге кабат Англиянең каты изүенә дучар ителә.

Исән калган принц Даккар Бундельханд тауларына кайта. «Кеше» затына бетмәс нәфрәт саклаган, цивилизацияне куралмаска әйләнгән, аннан мәңгегә качарга хәл иткән ялгыз Даккар, калган мөлкәтен акчага әйләндереп, иң тугрылыклы көрәштәшләрен алып, көннәрдән беркөнне каядыр китеп юкка чыга.

Принц Даккар кая китә соң? Кешеләр яшәгән җир йөзендә таба алмаган ирекне кайдан эзли соң ул? Ирекне фәкать су астында, диңгез тирәнлегендә таба! Чөнки анда инде аны беркем дә эзәрлекләми.

Сугыштан ваз кичеп, ул галимгә әверелә. Тын океанның кешесез бер утравына китеп кораб төзергә ниятли. Аның сызымы буенча шунда су асты көймәсе төзелә. Бетмәс-төкәнмәс чыганаклардан электр егәрен табуга ирешеп, ул аның очсыз-кырыйсыз механик көчен кулә-

чәктә кайчан да бер вакыт бөтен дөньяга мәгълүм булачак ысуллар белән үзе өчен файдалануга ирешә,— ул көчне су асты көймәсендә куллана: ул көч көймәне йөртә дә, җылыта да башлый. Принц Даккар һәм аның юлдашлары диңгезне һәм аның бетмәс-төкәнмәс хәзинәләрен, исәпсез күп балыкларын, имезүче хайваннарын, су асты басуларында үскән мул сүүсемнәрен — кыскасы, табигать үзенең диңгез чоңгылларында яшереп асраганны һәм кешеләр югалткан табышларны файдаланып көн итәләр болар. Һәм иң мөһиме шул: ниһаять, аның иң зур теләге тормышка аша: бар дөнья белән алыш-биреше өзелә. Ул көймәсенә «Наутилус» дип исем куша, үзен капитан Немо дип атый да диңгез тирәнлегендә юкка чыга.

Күп еллардан бирле капитан Немо Җир шарының бер котыбыннан икенче котыбынача барлык океан тирәнлекләрендә йөзеп йөри. Кешеләр яшәгән дөньяда хокуксыз кеше — пария — җир йөзенең билгесез су асты дөньясыннан күз күрмәгән, колак ишетмәгән гаҗәеп хәзинәләр туплый. Виго бухтасында 1702 нче елны баткан испан корабларындагы миллионлаган алтын аның бетмәс-төкәнмәс байлык чыганагына әверелә; үзен беркемгә белгертмәгән хәлдә, әлеге алтыннарны ул үз ватаннарының бәйсезлеге өчен көрәшүчеләргә ярдәмгә тота [1].

Озак еллар буе кешеләр белән бертөрле элемтәгә керми. Менә көтмәгәндә 1866 нчы елның 6 нчы ноябрендә аның корабына өч кеше: француз профессор, аның хезмәтчесе белән Канада балыкчысы килеп эләгә. Аларны капитан Немо «Наутилус» артыннан куганы өчен, Американың «Авраам Линкольн» фрегатын батыргач, диңгездән коткара.

Профессор аңа «Наутилус»ны кешеләр әле китсыман гигант су хайваны дип, әле пиратларның су асты көймәсе дип уйлауларын һәм барлык диңгезләрдә аны аулау оештырылганлыгын әйтә.

Үзенең серле дөньясына очраклы рәвештә эләккән бу чит кешеләрне капитан Немо океанга да ташлаган булыр иде. Әмма ул андый явызлыкны эшләми, аларны күпмедер вакыт әсирлектә тота. Җиде ай буе су асты көймәсендә яшәп, әсирләр, капитан Немо корабы-

---

[1] Сүз греклар восстаниесе турында бара, капитан Немо аларга ярдәм итә. (*Автор искәрмәсе.*)

ның су астында сиксән мең километр юл узган арада гаҗәеп маҗаралар кичерүенә шаһит булалар.

Капитан Немоның элекке тормышын бөтенләй белмәгән бу өч әсир 1867 нче елның егерме икенче июнендә «Наутилус»ның кече көймәсен урлап качалар. Нәкъ шул вакытта «Наутилус»ны көчле Мальстрим агымы Норвегия ярларына таба агызып алып китә. Капитан качкыннарны чоңгылдан чыга алмаганнардыр, аларны диңгез упкыны йоткандыр дип уйлый. Ул французның ике юлдашы белән бергә могҗизалы рәвештә исән калуын, диңгез дулкыннары аларны ярга чыгарып ташлагач, Лофотен утравы балыкчылары табып алуын, Франциягә кайткач та, профессорның җиде ай буе «Наутилус»та йөзүен тасвирлаган китап язып чыгаруын, бу гаҗәеп кызыклы сәяхәт вакытында күргән искиткеч маҗараларны укучыларның гаять кызыксынып укуларын белми иде.

Капитан Немо әле тагын шактый вакыт шулай яши бирә, барлык диңгезләрдә йөзә. Менә бер-бер артлы аның юлдашлары үлеп бетә, ул аларны Тын океан төбендәге мәрҗәннәр зиратына күмә. «Наутилус» бушап кала,— кешеләрдән качып су астында яшәүчеләр арасыннан хәзер фәкать капитан Немо гына кала.

Аңа инде алтмыш яшь тула. Ялгыз карт «Наутилус»ны су астындагы гаваньнарның берсенә алып керә, элек тә аның корабы озак йөзеп кайтканнан соң анда кереп ял итә торган була.

Ул гавань — Линкольн утравы астындагы мәгарәдә була, «Наутилус» әле хәзер дә шунда тора.

Алты ел буе беркая чыкмыйча, капитан Немо шушында яши, ул әҗәлен көтә. Көтмәгәндә ул Ричмонд әсирләре утырып качкан һава шарының кешесез утрауга егылып төшүенә шаһит була. Скафандр кигән килеш утраудан берничә кабельтов су астында йөргән вакытында диңгезгә баткан инженер Сайрес Смитка тап була. Капитан Немоның күңелендә мәрхәмәт уяна, ул Сайрес Смитны коткара.

Һәлакәткә очраган бу биш кешедән башта ул качмакчы була, әмма гаваньнан чыгу юлы бикләнә: вулкан көче тәэсирендә базальт мәгарәнең түбе өскә күтәрелә, һәм «Наутилус» җир астындагы гаваньда бикләнеп кала. Хәзер инде «Наутилус» җиңел көймә генә йөзеп чыгып йөргән җирдән диңгезгә уза алмый.

Капитан Немо шунда яшәп кала. Кешесез утрауга

килеп төшкән, тормыш итәр өчен кирәкле бар әйберләрдән дә мәхрүм булган күршеләренең ничек яшәвен күзәтә башлый. Әмма үзенең аларга күренәсе килми. Тора-бара бу кешеләрнең намуслы, булдыклы, үзара туганнарча тату-дус икәнлекләрен күрә, аларның табигать белән көрәшүләрен кызыксынып искәрә башлый. Теләсә-теләмәсә дә аларның тормыш серләренә катнаша. Водолаз костюмы кигән килеш ул Гранит сарай астындагы кое авызына асат үтеп керә. Кое стенасындагы киртләчләргә тотынып өскә хәтле менә, утраудагы кешеләрнең элекке тормышларын сагынып искә төшерүләрен, хәзерге хәлләрен, киләчәккә корган планнарын барысын ишетеп тора. Америкадагы кан коюлы сугыш турында, негрларны коллыктан азат итү өчен илнең бер өлкәләре икенче өлкәләренә каршы көрәшкә күтәрелгәнлеген дә алардан ишетә. Әйе, утрауга ихтыярсыздан килеп эләккән бу кешеләрнең зур ихтирамга лаек икәненә төшенә. Кешелекнең намуслы вәкилләре буларак, алар капитан Немоны кешеләр дөньясы белән татулаштыра алган да булырлар иде.

Капитан Немо әүвәл Сайрес Смитны коткара. Аның этен Хәрабәгә илтә, Топны күл төбендәге дюгоньнан аралый. Утрау кешеләре өчен бик кирәкле күп кенә әйберләр салынган әрҗәне Табылдык борынына чыгарып ташлый; әйе, көймәне дә ул чишә, һәм көймә Рәхмәт елгасыннан аска агып төшә. Гранит сарайны маймыллар яулап алгач, бау баскычны аска ул ташлый. Диңгезгә язулы шешә агызып, Айртонның Табор утравында ялгыз яшәвен ул хәбәр итә; һәм бугаз төбенә су асты минасы куеп, юлбасарлар бригын да ул шартлата. Хинин китереп куеп, Гербертны үлемнән ул коткара; ниһаять, электр пулясы белән атып, биш бандитны ул кырып сала. Су астында ау вакытында да ул үзе уйлап тапкан әнә шул коралны куллана икән. Илаһи көч тарафыннан эшләнгән кебек тоелган әлеге изгелекләрне менә кем эшләгән икән! Бу изгелекләр капитанның кодрәтле һәм мәрхәмәтле кеше булуынраслыйлар иде. Кеше сөймәгән бу галим яхшылык эшләргә ярата иде. Ничәмә-ничә тапкыр үзе иң кыен хәлләрдән коткарып калган кешеләргә ул тагын бер тапкыр ярдәм итәргә уйлый: әҗәле җиткәнен сизеп, аларга берничә файдалы киңәш бирмәкче була. Шушы дәһшәтле сәгатьтә ул, йөрәк кушуына буйсынып, утрау кешеләрен үз янына чакырган; моның өчен «Наутилус» белән утар арасында

үзе уздырган телеграфтан файдаланган. Әгәр дә үзенең тормыш тарихы күпмедер дәрәҗәдә Сайрес Смитка билгеле булуын, инженерның аңа капитан Немо дип дәшәчәген алдан белгән булса, бәлкем, ул аларны үз янына чакырмаган да булыр иде.

Капитан Немо үз тарихын сөйләп бетерде. Шуннан соң Сайрес Смит сүз алды; билгесез кешенең утраудагы биләмәгә ярдәм иткән һәрбер очрагын санап чыкканнан соң, ул эшләгән барлык изгелекләре өчен аңа үз исеменнән дә, иптәшләре исеменнән дә капитанга рәхмәт әйтте.

Капитан Немо үз хезмәте өчен рәхмәт әйтүләренә каршы иде. Аны үз тормышындагы соңгы бер вакыйга аеруча дулкынландырган иде, ул инженерның үзенә сузган кулын кысып:

— Ә хәзер минем тормыш тарихын беләсез инде, әфәндем. Мине хөкемгә тарта аласыз,— диде.

Бу сүзе белән капитан тормышындагы соңгы бер күңелсез вакыйгагә ишарәләде. «Наутилус»ка эләккән өч чит ил кешесенең күз алдында булды бу хәл. Француз профессоры бу вакыйга турында китабында язмыйча калмагандыр, бу күңелсез хәбәр бар халыкка таралгандыр дип уйлый иде ул.

Ул хәл түбәндәгедән гыйбарәт иде: профессор белән ике юлдашының «Наутилус»тан качарына берничә көн кала, Атлантик океанның төньяк киңлекләрендә йөзгәндә, су асты көймәсен бер фрегат эзәрлекләргә керешә. «Наутилус» исә, аңа ташланып, корпусы белән фрегатның төбен тишә һәм рәхим-шәфкатьсез батыра.

Сайрес Смит, капитанның нәрсәгә ишарә итүен төшенсә дә, дәшмәде.

— Ул Англия фрегаты иде! — дип кычкырып җибәрде капитан Немо, аның күңелендә бу мизгелдә принц Даккар хисләре уянган иде.— Англия фрегаты иде ул! Белдегезме? Ул миңа һөҗүм итте. Тар гына сай бухтада мине ябып калдырды. Миңа аннан бәреп чыгарга кирәк иде... Мин бәреп чыктым! — диде. Шуннан соң тынычрак тавыш белән дәвам итте: — Хаклык һәм гаделлек минем якта иде. Һәр җирдә мин, булдыра алганча, кешеләргә яхшылык кылдым. Кайвакыт явызлык итәргә дә туры килгәләде. Кичерү һәр очракта да гаделлек дигән сүз түгел! — Кыска гына паузадан соң капитан Немо: — Минем хакта хәзер ни дип уйлыйсыз, әфәнделәр? — дип кабатлады.

Сайрес Смит капитанга дусларча кул сузды һәм җитди рәвештә:

— Капитан Немо, сез борынгыны кире кайтарырга тырышасыз, котылгысызлыкка, прогресска каршы көрәшәсез, сезнең гаеп әнә шул. Моның үзе ялгыш адымга берәүләр соклана, икенчеләр нәфрәтләнә, кешелеклелек ягын уйлап фикер йөрткәндә бу адымны акларга мөмкин, һәм моны бер алла гына хөкем итә ала. Сез изге максатыгызны тормышка ашыру өчен ялгыш юлдан киткәнсез. Әмма андый кешегә ихтирам кимеми. Сезнең ялгышларыгыз намуслы исемегезгә тап төшерми, тарих хөкеменнән куркырга сезнең сәбәбегез юк. Тарих геройларча башсызлыкларны гафу итә, гәрчә бу адымның нәтиҗәләре хөкем ителергә лаек булса да.

Капитан Немо тирән көрсенеп куйды да кулын күккә таба сузып әкрен генә:

— Мин хаклымы, юкмы? — дип сорады.

Сайрес Смит аның артыннан кабатлады:

— Бөек эшләр ходай тәгалә иркендә, ул үзе хөкем итсен! Капитан Немо, сезнең каршыгызда басып торучы намуслы кешеләр, сездән күпме изгелек күргән кешеләр, сезне мәңге сагынып искә алырлар.

Герберт капитан Немо каршысына килеп тезләнде дә кулын тотып үпте.

Үлеп баручының күзеннән яшьләре тәгәрәп чыкты.

— Балакаем, миннән фатиха!..— дип пышылдады ул.

Унҗиденче бүлек

Капитан Немоның соңгы сулышлары.— Васыяте.— Бер генә көн белгән дусларына бүләге.— Капитан Немоның табуты.— Калучыларга киңәше.— Соңгы минутлары.— Диңгез упкынында.

Таң атты, әмма дөм-караңгы мәгарә эченә кояш нурлары үтеп керә алмады. Су күтәрелгәч, мәгарәгә керү юлы күмелеп калды, тик «Наутилус»ның борын һәм койрык ягындагы калын пыяла аша көлтә кебек бәреп чыккан ясалма ут яктысы сүнмәде, сүрелмәде, гаҗәеп кораб тирәсендәге су өстенә энҗе нурлар чәчеп җемелдә бирде.

Капитан Немо тәмам арды, хәлсезләнеп яңадан диванга ауды. Аны Гранит сарайга алып кайту турында сүз дә кузгатырлык түгел иде,— ул үзенең «Наутилус»ында миллионнар түләп тә сатып ала алмаслык

кыйммәтле хәзинәләре арасында калырга теләк белдерде; шунда үлем сәгатен көтәргә булды.

Ул селкенмичә дә ярым һушсыз ята, Сайрес Смит белән Гедеон Спилет аның хәлен дикъкать белән күзәтеп торалар. Әйе, күз алдында әкрен генә сүнеп бара ул. Кайчандыр куәтле гәүдәсе менә-менә өзелергә торган җанын сыйдырган зәгыйфь кабык кебек кенә калган. Бөтен тереклеге йөрәге белән миенә тупланган.

Инженер белән журналист пышылдап кына киңәшеп алдылар. Нинди дәва кулланып карарга соң? Үлемнән алып кала алмасалар да, бәлкем берничә көнгә генә гомерен озайтып булмасмы? Ул үзе бер төрле дәва да ярдәм итмәячәк ди, үлемнән курыкмый, тыныч кына әҗәлен көтә иде.

— Без ярдәм итә алмабыз инде,— диде Гедеон Спилет.

— Аның үлеме нидән соң? — дип сорады Пенкроф.

— Көче-егәре беткән,— диде журналист.

— Саф һавага, кояшка алып чыгып карарга иде, тернәкләнеп китмәс иде микән.

— Юк, Пенкроф,— диде инженер,— файда юк! Капитан Немо үзе дә көймәсеннән китәргә теләмәс. Ул утыз ел «Наутилус»та яшәгән, «Наутилус»та үләргә тели.

Капитан Немо Сайрес Смитның сүзләрен ишеткәндер ахрысы,— чак кына күтәрелеп, хәлсез тавыш белән аңлаешлы итеп әйтте:

— Сез дөрес әйтәсез, әфәндем. Мин монда үләргә тиеш, үзем дә шуны телим. Минем сезгә үтенечем бар.

Сайрес Смит белән иптәшләре диван янына килделәр, ятарга җайлы булсын дип авыруның мендәрләрен рәтләп куйдылар.

Капитан Немо бизәкле түшәмнән сирпелгән йомшак электр нурларына коенган бүлмә эченә, андагы могҗизаларга күз йөртеп чыкты: соклангыч гобеленнар тарттырылган стеналарда картиналар — итальян, фламанд, француз, испан рәссамнарының гүзәл әсәрләре эленеп тора; төрле почмаклардан атаклы сынчыларның әсәрләренең кечерәйтелгән бронза, мәрмәр күчермәләре күренә, түр стена буенда шәп музыка коралы — орга́н тора; киштә-шүрлекләргә сирәк очрый торган әйбер үрнәкләре тезелгән; зал уртасындагы бассейнда диңгез фаунасы һәм флорасы үрнәкләре: суүсемнәре, диңгез үләннәре, үсемлексыман диңгез хайваннары, хайван-

сыман диңгез үсемлекләре, энҗе үскән кабырчыклар, бик кыйммәтле энҗе бәйләмнәре шәйләнә — әнә шуларның барчасын берәм-берәм күздән кичерде Немо. Ниһаять, күз карашы зал-музей ишеге өстенә язып элενгән:

MOBILIS IN MOBILI [1]

дигән сүзләргә — «Наутилус»ның девизына тукталды.

Гүя аның сәнгать осталары һәм табигать иҗат иткән бу гүзәл әсәрләргә соңгы кабат карап ләззәтләнүе, гомеренең озак елларын диңгез төбендә, шушы әйберләр арасында чикләвен уйлавы иде.

Сайрес Смит капитан Немоны бүлдерергә батырчылык итмәде, аның сүз башлавын көтте. Тынлык берничә минутка сузылды; шушы кыска мизгелдә капитан Немо бөтен гомерен күз алдыннан үткәргәндер, күрәсең. Ниһаять, ул үзен сәяхәтчеләргә таба борды:

— Димәк, мине күпмедер дәрәҗәдә сездән рәхмәт ишетергә лаек дип исәплисез, әфәнделәр?

— Капитан, сезнең көннәрне озынайту өчен без гомеребезне дә кызганмас идек!

— Бик шәп! Бик шәп! — дип дәвам иттерде капитан Немо.— Минем соңгы васыятемне үтәргә ант итсәгез, сезгә эшләгән барлык яхшылыгым өчен рәхмәтегез шул булыр.

— Ант итәбез,— диде Сайрес Смит үзе исеменнән дә, иптәшләре исеменнән дә.

— Әфәнделәр, мин иртәгә үләм,— дип башлады сүзен капитан. Каршы нидер әйтергә җыенган Гербертны ул кул ишарәсе белән тыйды.— Иртәгә үләм,— дип кабатлады.— «Наутилус»ның табутым булуын телим. Миңа бүтән табут кирәкми. Минем барлык дусларым диңгез төбенә күмелгән. Мин дә алар янәшәсендә ятарга телим.

Капитан Немоның сүзләре тирән тынлык эчендә ишетелде, аңа дәшүче булмады.

— Тыңлагыз, әфәнделәрем. «Наутилус» бу мәгарә эчендә әсир калды, чөнки мәгарә авызы турысында диңгез төбе өскә күтәрелде, юлны бикләде. Әгәр дә аңа бу төрмәдән качарга җай юк икән, соңгы чиктә ул упкын төбенә төшеп ята ала, минем каберем була ала.

Утрау кешеләре аны ихтирам белән тыңлап тордылар.

---

[1] Хәрәкәттә бәрәкәт.

— Иртәгә мин үлгәч, сез, мистер Смит, иптәшләрегез белән «Наутилус»тан чыгып китәрсез. Монда тупланган барлык хәзинә үзем белән бергә юкка чыгарга тиеш. Сезгә принц Даккардан ядкарь итеп бер әйбер: менә бу тартманы калдырам. Монда берничә миллионлык бриллиант җыелган; алар минем җир йөзендә бәхет барлыгына ышанган, гаилә башы, әти кеше вакытымнан калган хатирәләр. Аннары монда диңгез төбеннән мин һәм минем иптәшләрем тапкан иң шәп энҗеләр җыелган. Бу хәзинәне сез кайчан да булса изге эш өчен файдаланырсыз, мин анысына ышанам. Мистер Смит, сезнең һәм иптәшләрегезнең кулында бу мөлкәт явызлык өчен хезмәт итмәс, шәт. Сезнең киләчәк изге эшләрегездә минем дә жаным катнашыр дип уйлыйм,— мин моңа ышанам һәм курыкмыйм.

Капитан Немо тынып калды, сөйләр көче бетте. Бераз ял иткәч, тагын сөйләп китте:

— Иртәгә сез бу тартманы алып, бу бүлмәдән чыгарсыз да ишекне бикләрсез. Аннары «Наутилус»ның өске мәйданчыгына менгәч, люк капкачын ябып, бигеп эләрсез.

— Барысын эшләрбез, капитан,— диде Сайрес Смит.

— Ярый. Аннары монда килгән көймәгезгә утырырсыз. «Наутилус» яныннан китәрдән алда, аның койрык өлешенә барып, ватерлиниясендәге ике кранны ачарсыз. Камераларга су тулар да «Наутилус» әкренләп су астына китәр. Упкын төбендә кабергә ятар.

Сайрес Смитның ихтыярсыз хәрәкәтен тоеп калгач, ул:

— Курыкмагыз, сез минем мәетне күмәсез,— диде.

Сайрес Смит та, иптәшләре дә капитан Немога каршы төшәргә үзләрен хаклы дип санамадылар. Ул соңгы васыятен әйтте, васыять үтәлергә тиеш иде.

— Сез ант итегез, әфәнделәр,— диде капитан әкрен генә.

— Без аны үтәрбез! — диде инженер.

Капитан рәхмәтен ишарә белән генә белдерде, үзен берничә сәгатькә ялгызын калдырырга кушты. Гедеон Спилет врач ярдәме кирәк булса дип, янында калырга теләгән иде, капитан:

— Курыкмагыз, мин иртәгә хәтле түзәм әле,— диде.

Һәммәсе бүлмәдән чыгып киттеләр, китапханә һәм ашханә аша узып, судноның алгы өлешенә килделәр, машина бүлегенә җиттеләр. Анда «Наутилус»ны вёрту-

че, яктылык һәм җылылык бирүче электр аппаратлары тора иде.

«Наутилус» техника өлкәсендә бер могҗиза иде; анда башка төрле могҗизалар да тулы икән, инженер бу хәлгә сокланып бетә алмады.

Утрау кешеләре судан җиде-сигез фут өстә калкып торган мәйданчыкка менделәр. Караңгылыкка электр уты бөркеп торган кабарынкы түгәрәк тәрәзә янына килделәр. Тәрәзәдән корабны идарә итүче руль куелган буш кабина күренде. Кайчандыр анда «Наутилус»ны диңгездән алга алып барган рулевой басып торгандыр, ә электр уты еракка хәтле юлны яктырта торган булгандыр.

Әле генә күргән, ишеткәннәреннән таң калган сәяхәтчеләр бик озак сүзсез басып тордылар; ничәмә-ничә тапкыр аларга яшерен рәвештә ярдәм кулы сузган кеше, берничә сәгать элек кенә үзе дә аларга күренгән шәфкать иясе үлеп бара, бу хәсрәттән һәркайсының йөрәк бәгырьләре өзгәләнә иде.

Кешелек җәмгыятеннән читтә диярлек маҗаралы гомер кичергән кешенең эшләренә, гамәлләренә киләчәк буыннар нинди хөкем чыгармасын, мәгәр принц Даккар онытылмаслык хатирә калдыра торган гаҗәеп җан ияләренең берсе иде.

— Нинди гаҗәеп кеше бу валлаһи! — диде Пенкроф, ниһаять,— уйлап карагыз, ничәмә-ничә еллар буе океан төбендә яшәгән! Баксаң, бахыр, монда да тынычлык тапмаган лабаса!

— «Наутилус» безгә дә ярап куяр иде. Аңа утырып без Линкольн утравын ташлап китә алыр, кешеләр яшәгән берәр җиргә барып җитәр идек әле,— диде Айртон.

— Аһ иблис кавеме! — дип кычкырып җибәрде Пенкроф.— Мондый корабны идарә итәргә минем йөрәк җитәме соң! Диңгездә йөзәргә дисәң була, рәхим ит! Әмма диңгез астыннан йөзү мәңге булмый миннән!

Ә журналист аңа каршы төште:

— Пенкроф, минемчә, «Наутилус» кебек су асты көймәсен идарә итү асат булырга тиеш, без аны тиз үзләштерер идек. Өермә-фәләннән дә, пиратлардан да куркасы юк. Берничә фут аста, диңгез тирәнлегендә, тын күл өстендәге кебек, мәңге тынычлык хөкем сөрәдер, мөгаен,— диде ул.

— Бәлкем, шулайдыр,— дип ризалашты диңгезче.— Яхшы җиһазланган шхуна эчендә көчле давылга эләгү-

eң мондый тынлыктан хәерлерәк. Кораблар су астында түгел, су өстендә йөзәргә тиеш.

— Дусларым, су асты көймәләре хакында, һәрхәлдә, «Наутилус» хакында бәхәсләшү мәгънәсез. «Наутилус»ка без хуҗа түгел, аңа баш булырга хакыбыз юк. Ул безгә хезмәт итә алмый. «Наутилус» мәгарә эченә бикләнгән, моннан чыга алмый, хикмәт анда гына да түгел. Онытмагыз, капитан Немо корабының үзе белән бергә диңгез төбенә төшеп ятуын тели. Ул васыятен безгә ачык әйтте, без аны җиренә җиткереп үтәргә тиешбез.

Тагын бераз сөйләшеп торгач, Сайрес Смит белән иптәшләре «Наутилус» каютасына төшеп киттеләр. Тамак туйдыргач, алар капитан Немо яткан залга керделәр.

Ул бөтен гәүдәсен богаулаган хәлсезлекне инде сизми бугай, күзләре бизгәк тоткан кешенекедәй ялтырый, иреннәре хәлсез елмая.

Сәяхәтчеләр аның янына килделәр.

— Әфәнделәр, батыр, гадел, яхшы ниятле кешеләр сез. Гомуми эшегезгә тугрылыклы кешеләр. Мин сезне күп күзәттем. Мин сезне яраттым, яратам мин сезне!.. Мистер Смит, бирегез кулыгызны.

Сайрес Смит кулын сузды, капитан Немо аны дусларча каты итеп кысты.

— Менә әйбәт булды! — дип пышылдады ул. Аннары тавышын күтәрә төшеп:— Минем хакта җитәр. Сезнең турыда, Линкольн утравы турында сөйләшик... Сез утраудан китәргә исәплисезме?

— Китсәк тә без монда тагын әйләнеп киләчәкбез! — диде Пенкроф ашкынып.

— Әйләнеп килерсезме?.. Ярый, бик әйбәт, Пенкроф. Утрауны яратканыгызны беләм,— диде капитан елмаеп.— Сезнең тырышлык белән монда күп үзгәрешләр барлыкка килде,— бу утрауның чын хуҗалары — сез.

Шунда Сайрес Смит та сүзгә кушылды:

— Без утрауны Кушма Штатларга бүләк итмәкче булабыз, ул безнең диңгез флоты өчен Тын океанның бу ерак почмагында бик уңайлы порт булачак.

— Сез туган илегезне кайгыртасыз, әфәнделәр,— диде капитан.— Сез туган илегез чәчәк атсын, даны артсын дип хезмәт иттегез. Сез хаклы. Ватаныгызга кайтырга кирәк, әлбәттә. Үз туган туфрагыгызда үләргә кирәк!.. Ә мин менә иң газиз нәрсәләремнән читтә үләм!

— Бәлкем, берәр кешегә васыятегез бардыр? — дип сорады инженер.— Бәлкем, иптәшләрегезгә берәр ядкарь

калдырырга телисездер? Һиндстан тауларында сезнең дусларыгыз калгандыр бит?

— Юк, мистер Смит. Минем дусларым юк инде! Мин нәселебезнең соңгы кешесе... Белгән кешеләрем мине күптән үлгәнгә саныйлар... Сезнең язмышны сөйләшик. Кешеләрдән аерылу, ялгызлык түзеп булмаслык авыр хәсрәт ул... Менә мин ялгыз яши алам дип ялгыштым, шуңа күрә үләм!.. Сез моннан ничек тә китәргә тырышыгыз, туган илегезгә кайтыгыз. Теге кабахәт җаннар сезнең корабны батырды...

— Без инде яңа кораб төзибез,— диде Гедеон Спилет.— Кешеләр яши торган җирләргә барып җитә алырлык зур итеп ясыйбыз. Әгәр без Линкольн утравыннан китә алсак, иртәме-соңмы барыбер монда әйләнеп киләбез. Бу утрау белән бик күп хатирәләребез бәйләнгән, без аны оныта алмаячакбыз!

— Биредә язмыш безне капитан Немо белән очраштырды,— диде Сайрес Смит.

— Без биредә сезне бик еш искә алырбыз,— дип өстәде Герберт.

— Мин монда мәңге йокыга талып, тынычлык табармын, тик...— диде дә капитан Немо тотлыгып калды, әйтәсе сүзен өзеп:— Мистер Смит, сезнең белән ялгыз гына сөйләшәсе сүзем бар иде...— диде.

Инженерның иптәшләре, үлеп барган кешенең теләгенә буйсынып, бүлмәдән чыктылар.

Берничә минут капитан Немо Сайрес Смит белән ни турындадыр сөйләште. Аннары инженер иптәшләрен чакырды, әмма капитанның ни әйткәнен иптәшләренә белдермәде.

Гедеон Спилет капитан Немоның чыраена игътибар итте. Авыру соңгы ихтыярын җыеп кына түзеп тора, тәнен богаулый барган хәлсезлеккә тиздән бирешәчәк ул.

Кичкә хәтле авыруның хәле үзгәрмәде. Утрау кешеләре бер генә минутка да «Наутилус»тан чыкмадылар. Төн җитте, хәер аны бу караңгы төрбәдә сизәрлек түгел иде.

Капитан Немоның үлем ачысы белән газапланганы тоелмый, әмма егәре бетә бара. Затлы нәфислеген җуймаган йөзе суырыла бара, аңа үлек төсе керә. Иреннәре вакыт-вакыт ишетелер-ишетелмәс ниләрдер пышылдый. Гаҗәеп кызыклы тормышның әле теге, әле бу вакыйгасе хәтерендә яңарадыр, күрәсең. Ә тәненнән әкренләп тереклек китә бара иде. Аяк-куллары да суына башлады.

Янында басып торган сәяхәтчеләргә ул бер-ике җылы сүз әйтте, йөзенә үлгән кеше чыраенда мәңге кала торган мөлаем елмаю чыкты.

Төн уртасыннан соң, актык көчен җыеп, капитан Немо кулын күкрәгенә кушырып куйды, шул хәлендә үләргә җыенуы булды ахрысы.

Төнге сәгать берләрдә фәкать күзендә генә тереклек әсәре калды. Кайчандыр ут уйнаткан күзләрендә соңгы нур чагылып китте: «Алла, Ватан!» — дип пышылдаган соңгы сүзе ишетелде һәм ул тын гына җан бирде.

Сайрес Смит иелеп аның күзен йомдырды. Кайчандыр принц Даккар булган капитан Немо дөньядан китте.

Герберт белән Пенкроф елап җибәрделәр. Айртон күз яшьләрен сөртеп алды. Наб идәнгә тезләнде, ә журналист каушап катып калды.

Сайрес Смит мәрхүмнең баш өстенә кулын күтәрде:

— Урының оҗмахта булсын! — диде, аннары иптәшләренә таба борылды:— Мәрхүмне яхшылык белән искә алыйк!

Берничә сәгатьтән алар мәрхүмнең васыятен җиренә җиткерделәр.

Сайрес Смит һәм аның иптәшләре шәфкать иясе бүләк иткән бердәнбер ядкарьне — зур хәзинә салынган тартманы алып, «Наутилус»тан чыктылар.

Яп-якты ут янып торган зиннәтле залның ишеген бикләделәр. Люкның корыч капкачын, «Наутилус»ка бер тамчы су үтмәслек итеп, тыгызлап яптылар.

«Наутилус»ка бәйләп куелган көймәгә төшеп утырдылар.

Көймәне корабның койрык ягына алып киттеләр. Анда ватерлиниядә ике кран күренә иде. Краннар кораб диңгез төбенә чумганда су тутыра торган бүлемнәргә тоташкан иде.

Ике кранны да ачтылар, бүлемнәргә әкренләп су тула башлады, «Наутилус» аска күмелә барды һәм мәңгегә тын диңгез төбенә китте.

Ә сәяхәтчеләр диңгез суы үтәли аны әле бик озак күреп тордылар. Дөм-караңгы мәгарәдә төпкә төшеп барган корабның көчле электр уты су аша күренә; су, зәңгәрләнеп, үтә күренеп ялтырый иде. Ниһаять, корабның нурланып торган түгәрәк яктысы әкренләп тоныкланды, капитан Немоның табутына әверелгән «Наутилус» диңгез төбенә төшеп ятты.

Унсигезенче бүлек

Утрау хуҗалары фикер алыша.— Кораб төзү.— 1869 нчы елның беренче январе.— Вулкан өстендә төтен баганасы.— Айртон белән Сайрес Смит мал утарына китәләр.— Даккар мәгарәсен тикшерү.— Капитан Немо Сайрес Смитка нәрсә әйткән?

Утрау хуҗалары таң сызылганда тирән тынлыкта мәгарә авызына көймә белән йөзеп килеп җиттеләр. Мәрхүм капитан Немо хөрмәтенә тау куышын *«Даккар мәгарәсе»* дип атадылар. Су чигенгән вакыт булганга, базальт стена итәгендә дулкыннар уйнаклавына игътибар итмәстән, тау куышыннан мәшәкатьсез-нисез килеп чыктылар.

Көймәне дулкын килеп җитә алмаслык аулак почмакка бәйләп куйдылар. Наб белән Айртон хәтта аны мәгарә стенасы буендагы комлыкка тартып чыгардылар.

Яшенле яңгыр туктаган икән. Тик көнбатыш якта әле һаман еракта-еракта күк күкрәгәне ишетелә. Яңгыр туктаса да, күк йөзе болытлардан арынмаган. Кыскасы, Көньяк ярымшардагы язның беренче ае — октябрь матур башланмады. Юнәлешен гел үзгәртеп искән көчле җил көннәрнең тотрыксыз булачагын искәртә иде.

Сайрес Смит белән аның дуслары Даккар мәгарәсеннән чыккач, утарга киттеләр. Юлда Наб белән Герберт капитанның утардан мәгарәгә үткәргән телеграф чыбыгын, киләчәктә кирәге чыгар дип, җыя бардылар.

Сәяхәтчеләр сирәк-мирәк кенә бер-ике авыз сүз алышалар. Алар әле һаман 15 нче октябрьдән 16 нчы октябрьгә каршы төнге вакыйга тәэсиреннән айнымаганнар. Тормышларының иң авыр минутларында ярдәмгә килүче шәфкать иясе, утрауның мәрхәмәтле даһие капитан Немо хәзер юк инде. «Наутилус» үзенең хуҗасы белән бергә океан төбенә төшеп ятты. Һәрберсе үзенең дөньядан аерылганлыгын хәзер тагын да ачыграк тойды. Кодрәт иясенең ярдәменә күнеккәннәр иде шул инде. Ни аяныч! Хәзер аннан да мәхрүм калдылар. Һәммәсе, хәтта Гедеон Спилет белән Сайрес Смит та сагышка баттылар. Утарга барганда юлда үзара ләм-мим сөйләшмәделәр.

Иртәнге сәгать тугызларда утрау хуҗалары Гранит сарайга әйләнеп кайттылар.

Кораб төзүне ашыктырырга кирәк дигән фикергә килделәр. Сайрес Смит вакытын да, сәләтен дә кызганмады. Киләчәктә нинди авыр хәлләргә калмаслар. Ерак юлга

сәяхәткә чыгарлык, давылга бирешмәслек зур кораблары булса, моннан котылуга ышаныч артыр иде.

Корабны төзеп бетергәч, әгәр Линкольн утравын шундук ташлап китәргә, Полинезия яки Яңа Зеландиягә барырга теләмәсәләр дә, һәрхәлдә, Табор утравына барып килерләр, Айртонның кайда икәнен әйтеп хат язып калдырырлар. Моны һичшиксез эшләргә кирәк, чөнки Шотландия яхтасының бирегә килеп чыгуы ихтимал. Бу форсатны һич тә кулдан ычкындырырга ярамас!

Тукталган эшне яңадан кузгатып җибәрделәр. Сайрес Смит, Пенкроф, Айртон, Наб, Гедеон Спилет белән Герберт көне-төне, алны-ялны белмичә диярлек эшләделәр. Алар кичектерергә ярамаслык берәр эш чыкса гына бүленделәр. Кораб биш айдан, ягъни март башына әзер булырга тиеш иде. Шуңа өлгертсәләр генә Табор утравына барып килә алалар. Югыйсә көн белән төн тигезләшкән чорда көчле җил кубучан, диңгезгә чыгуы хәтәр булачак. Шуңа күрә балта осталары бер минутларын бушка уздырмадылар. Хәер, судноның җиһазлары әзер диярлек иде, чөнки, «Җитез»нең җиһазларын тулысынча коткара алдылар. Корабның корпусын гына төзеп бетерергә кирәк.

1868 нче елның ахыры шушы мөһим эш белән узды, бүтән мәшәкатьләр онытылды. Ике ай ярымнан корабның барлык кабыргалары урынына беркетелде, тышлыкның беренче такталары кагылды. Инде хәзер үк корабның шәп чыгасын, теләсә нинди сынауга да бирешмәячәген чамаларга мөмкин иде. Пенкроф үз-үзен аямыйча эшләде, әгәр иптәшләренең берәрсе кулыннан балтасын куеп, мылтык алып ауга барырга җыенса, түзмичә, ул гамьсезне битәрләргә керешә иде. Ә бит кыш якынлаша, Гранит сарай чоланнарын азык-төлек белән тутырырга вакыт иде. Пенкрофның исә анда кайгысы юк! Күзенә корабтан башкасы күренми, берәрсе эштә күренмәсә, ул чыгырдан чыга. Андый чакларда, сукрана-сукрана, берүзе алты кешелек эшли иде.

Быел җәй айларында көннәрнең рәте булмады. Берничә көн тоташтан кояш кыздырды-кыздырды да, һава бик көчле электрлашты, яшеннәр китте, көчле яңгырлар койды. Тәүлекләр буе күк күкрәде. Күк йөзе бертуктаусыз тоныкы кына гөлдерәп торды — экватор тирәләрендә мондый хәл гадәти иде.

1869 нчы, яңа елның беренче көнендә, яшеннәр аеруча азынды, утрауның берничә төшенә яшен сукты. Зур-

зур агачларны яшен атып сындырды. Кош кетәгеи көньяктан, күл ягыннан ышыклап үскән биек, мәһабәт кычыткан агачын да яндырды. Җир карынындагы үзгәрешләр белән әллә бу дәһшәтле яшеннәр арасында бәйләнеш бар микән? Җир шарының тирән катламнарындагы көчеш, кузгалышларның тәэсире түгел микән бу яшеннәр? Сайрес Смитның күңеленә әнә шундый фикер килде, чөнки каты яшеннәр башлангач, вулканның эшчәнлеге дә көчәйде.

Өченче январьда Герберт таң ату белән онагрларны җигәргә дип Күзәтү яссылыгына киткән иде. Яссытаулыкка менгәч, вулкан ягына күз салса, кратер авызыннан биек булып төтен баганасы күтәрелүен күрде.

Герберт бу хәбәрне иптәшләренә кайтып әйтергә ашыкты. Утрау хуҗалары шундук яссытаулыкка менеп, вулканны күзәтә башладылар.

— Ай-һай, бу юлы пар гына түгел бу! Безнең Алып батыр сулап кына ятмый, челем дә тарта икән! — диде диңгезче.

Гәрчә ул киная белән әйтсә дә, вулкан тирәсендәге күренешне төгәл сурәтләп бирде. Моңарчы өч айдан бирле вулкан авызыннан куе пар гына чыгып ята иде, бу хәл вулкан карынында эрегән токымнарның кайнавын аңлата иде. Ә хәзер вулкан авызыннан пар йомгаклары түгел, куе төтен чыга. Нигез әйләнәсе өч йөз фут, биеклеге җиде-сигез йөз фут чамасы куе соргылт төтен баганасы күк йөзенә үк үрләгән. Ә биектә ул, җәелә төшеп, гөмбә рәвешенә кергән.

— Морҗага ут капкан,— диде Гедеон Спилет.

— Без аны сүндерә алмыйбыз шул,— дип авыр сулап әйтте Герберт.

— Морҗа чистартучылар вулканнарны әледән-әле әрчи торсалар начар булмас иде ул,— дип куйды Наб җитди тавыш белән.

— Хуплыйм, Наб, молодец,— дип кычкырды Пенкроф.— Вулкан чистартучы кәсебенә керешергә ниятең юктыр ич? — Диңгезче шаркылдап көлеп җибәрде.

Сайрес Смит Франклин тавы бугазыннан бөркелгән куе төтенне бик озак күзәтте, ул иптәшләреннән читтәрәк тора иде, муенын сузып, сагаеп, ерак гөрселдәү авазына колак салды. Аннары иптәшләре янына килде дә:

— Дусларым, вулкан эчендә зур үзгәрешләр бара. Бу хәлне үз-үзебездән яшерүнең мәгънәсе юк. Вулкан

эчендәге токымнар кайнау гына түгел, инде ялкын кабынган, тиздән вулкан ата башлаячак!..

— Атмагае, атсын! — дип җибәрде Пенкроф.— Әгәр шәп ата икән, без аны алкышларбыз гына! Безнең вулканнан да мөһимрәк эшебез бар әле, шулай бит, мистер Сайрес!

— Юк, Пенкроф,— дип каршы төште Сайрес Смит.— Лава төньякка авыш кратердан иске юлыннан агарга тиеш тиешен, шулай да...

— Шулай да вулкан атуның безгә файдасы юк, атуыннан атмавы хәерле,— дип аның сүзенә өстәде Гедеон Спилет.

— Каян беләсең бит! — дип үзенекен тукыды диңгезче.— Вулкан тотар да безгә бик кирәкле, сирәк очрый торган берәр файдалы токымны чыгарып атар. Аның бүләген файдалана белер идек белүен.

Әмма Сайрес Смит аның шаяртуын өнәмичә башын чайкап торды. Вулкандагы бу үзгәрешнең хәерлегә түгеллеген сизенә иде ул. Бу хәлне Пенкроф кебек гамьсез кабул итә алмый иде. Төньякка авыш кратердан лава ташкыны утрауның урманлы ягына, эшкәртелгән җирләргә агарга тиеш түгел түгелен, анысына шикләнмәсәләр дә, бүтән төрле хәтәр хәлләр килеп чыгуы ихтимал иде. Вулкан атканда еш кына җир тетри. Әгәр җир тетрәсә, Линкольн утравының җимерелеп һәлак булу куркынычы зур иде, чөнки ул төрле токымнардан тора: төньякта — каткан лава, базальт, гранит, ә көньякта — көпшәк җир; бу токымнар үзара нык берекмәгән. Лава ташкыны зыянлы булмаса да, җир тетрәүдән утрау үзе юкка чыгуы ихтимал иде.

Айртон җиргә ятып, колагын куеп тыңлап торды да кинәт әйтте:

— Минемчә, минемчә, ерактан дөбердәү тавышы ишетелгән кебек, гүя тимер кисәкләре төялгән арба дыңгырдап киләмени.

Башкалар да сагаеп тыңларга керештеләр, Айртон әйткән дөбердәүне алар да ишетте. Дөбердәү авазы тынуга, җир астында озак кына гүләү ишетелеп торды; ул әле көчәя, әле әкренәя — әйтерсең, җир карыннан көчле өермә гүләп узып бара иде. Әмма вулкан атканда ишетелә торган, мылтык шартлавын хәтерләткән тавышлар әлегә юк иде. Димәк, пар белән төтен үзәк кратердан тоткарлыксыз чыгып тора, әгәр кратер авызы

җитәрлек киң булса, ул чагында шартлаудан, Җир кабыгының кискен тетрәвеннән курыкмаска да мөмкин.

— Куегыз! Әйдәгез эшкә тотыныйк,— диде бераздан Пенкроф.— Франклин тавы җаны теләгәнчә челемен төтәтсен, ажгырсын, үкерсен, ут-ялкын бөркесен, шуның аркасында без кул кушырып утырыйкмы! Әйдәгез, Айртон, Наб, Герберт, киттек эшкә. Әйдәгез сез дә, мистер Сайрес, мистер Спилет! Безгә бүген батырып эшләсәк тә гөнаһ түгел! Хәзер иң зур бурычыбыз шул, корабның буй кыршавын урнаштырасы бар, аңа ун пар кул да аз әле. Минем теләкне беләсегез киләме? Безнең яңа «Хәерле юл» (сез корабны алай атауга каршы түгелдер бит) иң күбе ике айдан Һава шары портында күз явын алып торырга тиеш! Юкка вакыт әрәм итмик!

Утрау хуҗалары, буйсынып, Пенкроф артыннан ияр-деләр. Кораб төзелеп яткан җиргә килгәч, корабның барлык терәкләрен, кабыргаларын бергә тоташтыручы кыршауны ныгытырга тотындылар. Бу бик кыен эш иде, Пенкрофның һәммәсен җыеп китерү тикмәгә түгел икән.

3 нче ноябрьдә алар, вулканны онытып, көне буе кораб эшендә булдылар. Хәер, вулкан Гранит сарай итәгеннән, яр буеннан күренми дә иде. Әмма аяз күк йөзеннән һәр көнлек юлыннан тәгәрәгән кояшны ике-өч тапкыр куе кара күләгә каплап узды,— куе төтен болыты шулай утрау өстенә күтәрелеп агыла иде. Диңгез ягыннан искән җил төтен белән парны каядыр көнбатыш тарафка куалый. Сайрес Смит белән Гедеон Спилет бу хәлне игътибарсыз калдырмадылар. Вулканның ашыгу-кабалануын, тиздән атарга җыенуын искәреп, сөйләшеп алдылар, әмма эштән бүленмәделәр. Корабны тизрәк төзеп бетерү үзләре өчен кирәгрәк икәнен төшенделәр. Нык кораб булса, бер төрле көтелмәгән хәл дә куркыныч түгел. Кем белә, көннәрдән бер көнне бу кораб аларның бердәнбер сыеныр почмагы булып калмасмы әле...

Кич белән, ашап алганнан соң, Сайрес Смит, Гедеон Спилет, Герберт бергәләп Күзәтү яссытаулыгына киттеләр. Җир өсте инде караңгыланып килә, әмма бу хәл алар файдасына иде: вулкан авызыннан бөркелгән пар белән төтен арасында ялкын телләре күренмиме, ут булып кызган ташлар атылмыймы — шуны беләселәре килә иде.

Иптәшләреннән алда Күзәтү яссылыгына йөгереп менгән Герберт:

— Кратердан ялкын бәрә! — дип кычкырып җибәрде.

Күзәтү яссытаулыгыннан алты миль ераклыктагы Франклин тавы кызыл ялкын бөркелеп торган гигант учакны хәтерләтә иде. Әмма төн караңгы булса да, аның уты тоныкланыбрак күренә — төтен, шлак, көл белән аралаш булгангадыр инде, утрау турысында күк йөзенә кызгылт-сары шәфәкъ иңгән, аның яктысында каралҗым урманны шәйләрлек иде. Һавага төтен йомгаклары таралган, алар арасыннан берәм-сәрәм йолдызлар җемелди.

— Кара син, бик кызу китте бит эшләр! — дип куйды инженер.

— Гаҗәп түгел, вулкан күптән уянды,— диде Гедеон Спилет.— Хәтерегезгә төшерегез, Сайрес, капитан Немоның яшерен торагын табарга өметләнеп, тау араларында эзләнеп йөргәндә үк пар чыгуын күргән идек. Әгәр ялгышмасам, октябрь урталары иде бугай ул...

— Әйе! Ике ай ярым вакыт үткән инде! — диде Герберт.

— Димәк, җир астындагы ут ун атна буе кызып яткан. Ул вакыт эчендә көч җыеп өлгергән, әлбәттә! — диде Гедеон Спилет.

— Сез җирнең тирбәлгәнен сизмисезме әллә? — дип сорады Сайрес Смит.

Гедеон Спилет:

— Сизәм, тик чынлап торып җир тетрәгәнче әле...— дип башлаган иде, Сайрес Смит аңа:

— Мин җир тетрәр димим, аллам сакласын! — дип тиз генә каршы төште.— Юк. Әлеге тирбәлү җир астындагы утның тәэсиреннән ул. Җир кабыгы пар казанының стенасына охшаган, ә газ басымы аркасында казанның стеналары дерелдәгәнен үзегез дә беләсез. Менә хәзер дә нәкъ шундый хәлне тоябыз.

— Карагыз инде, ут көлтәсе бигрәк матур чөелә! — дип сокланып куйды Герберт.

Нәкъ шул мәлдә кратердан көлтә-көлтә утлы чаткылар очып чыкты, аларны хәтта куе пар йомгагы да каплый алмый иде. Меңләгән утлы вак таш кисәкләре, очкыннар вулкан тирәсенә сибелеп тора башладылар. Утлы ташлар төтен бүрегә өстенә үк очып менәләр дә чаткы булып чәчеләләр. Якында гына берничә туптан картечь белән аткан сыман тавышлар ишетелә.

Сайрес Смит, Гедеон Спилет, Герберт Күзәтү яссылыгында бер сәгать буе вулкан атуын карап тордылар,

аннары түбәнгә төшеп, Гранит сарайга кайтып киттеләр. Инженер уйга батты, дөресрәге ниндидер исәпкә калган кебек тоела иде. Гедеон Спилет түзмәде:

— Вулкан атуына бәйле берәр хәвеф-хәтәр барлыгын сиздегез мәллә? — дип сорады.

— Әйе дә, юк та! — диде Сайрес Смит.

— Җир тетрәүдән утравыбыз һәлак булуы мөмкин бит, иң зур бәхетсезлек түгелмени шул? Дөресен әйткәндә, пар белән лава үзенә ачык юл тапты табуын, мин хәзер курыкмыйм инде,— диде журналист.

— Мин дә җир тетрәүдән курыкмыйм хәзер. Җир астындагы газлар киңәюдән җир кабыгы үзгәрсә дә, ул хәтле хәтәр түгел,— диде Сайрес Смит.— Әмма һәлакәтнең башка сәбәпләре дә бар...

— Нинди, кадерле Сайрес?

— Үзем дә әлегә яхшылап белеп бетермим... Тауга менеп карарга кирәк иде... Бу хәл берничә көннән ачыкланырга тиеш дип уйлыйм.

Гедеон Спилет бүтән сорашып маташмады. Җир астындагы гөрелтенен көчәя баруына карамастан, Гранит сарай кешеләре тирән йокыга талдылар.

Тагын өч көн үтте. Кораб төзүне дәвам иттерделәр. Инженер телдән әйтмәсә дә, эшне мөмкин хәтле тизләтергә тырышты. Франклин тавының өске өлешен капкара дәһшәтле болыт төреп тора хәзер. Кратердан ялкын белән бергә кыя кыйпылчыклары очып чыга да киредән аска төшеп югала. Пенкроф вулкан атуының мәзәк ягын табып, әледән-әле тыела алмыйча кычкырып җибәрә:

— Карагыз әле! Безнең баһадир туп уйный! Күрегез, күр, ташларны ничек биеккә чөя!

Чыннан да, вулкан авызыннан чөелгән ташлар кире упкынга төшеп юкка чыга иде. Күрәсең, әле эчке басым нәтиҗәсендә өскә күпереп менгән лава кратер авызына ук килеп җитмәгән. Һәрхәлдә, тауның Күзәтү яссылыгыннан әйбәт күренгән төньяк-көнчыгыш бите буйлап дәһшәтле ут ташкыны акканы чамаланмый иде.

Яңа корабны төзеп бетерергә нихәтле ашыкмасыннар, башка төрле мөһим эшләр дә килеп чыга иде шул. Беренчедән, утарга йөрергә, андагы муфлон, кәҗә көтүләрен карарга, аларга азык әзерләргә кирәк булды. Иртәгесен, 7 нче ноябрьдә, Айртон утарга китәргә тиеш иде. Ул андагы эшләрне үзе генә дә башкарып чыга ала иде алуын, әмма инженер:

— Айртон, иртәгә утарга китсәгез, мин дә сезнең бе-

ләп бергә барам,— дигәч, башкалар аптырабрак калдылар.

Диңгезче тыела алмыйча кычкырып ук җибәрде:

— Юк инде, мистер Сайрес. Һәр көнебез исәптә, әгәр икәүләп китсәгез, ике эшче кул кими, әллә уен эшме!

— Без берсекөнгә кайтабыз,— диде Сайрес Смит.— Миңа утарда булырга кирәк... Вулканның кайчан тулы көченә ата башлавын беләсем килә.

— Вулкан! Вулкан! — дип сукранды Пенкроф.— Дөньяда аннан да кирәгрәк эшләр бар. Күреп торасыз, ул хәлләр минем исемә дә кереп чыкмый хәзер!

Диңгезченең ризасызлыгына карамастан, инженер иртәгесен утарга барырга булды. Гербертның да Сайрес Смитка иярәсе килгән иде дә, Пенкрофның кәефе кырылудан курыкты.

Иртәгесен таң атуга Сайрес Смит белән Айртон, пар онагр җигелгән арбага утырып, мал утарына таба юрттырып киттеләр.

Кратер авызыннан чыккан авыр кара болыт урман өстенә үк салынып төшкән иде. Күк йөзен томалап алган бу болытка төрле химик элементлар да катнашкандыр инде. Кара төтен белән тузанга әйләнгән минераль матдәләр, он кебек соры көл аралашканнан болыт шулай куергандыр. Вулкан көле бик җиңел, кайбер очракларда ул айлар буе һавада йөзеп йөри, җиргә төшми икән.

1783 нче елда Исландиядә вулкан атканнан соң һавада ел буе диярлек вулкан көле йөзеп йөргән, аның аша кояш нурлары чак-чак кына үтеп чыга алган.

Әмма күбесенчә мондый вак кисәкчәләр шундук җиргә утыра. Утрауда да шушы хәл кабатланды. Сайрес Смит белән Айртон утар коймасы янына килеп җитүләре булды, күктән кара карсыман яисә вак дарысыман нәрсә ява башлады һәм әйләнә-тирә әкияттәге кебек күзгә күренеп үзгәрде. Урман, болын, кыялар өстен берничә бармак иңле кара тузан каплады. Бәхеткә, төньяк-көнчыгыштан җил исә башлап, кара болытны тиздән диңгез ягына таба куып алып китте.

— Менә гаҗәеп тамаша! — диде Айртон.

— Нинди дәһшәт диген. Вак пемза, минераль тузан ул; вулкан эчендә тирәндә дәһшәтле хәлләр барлыгын исбатлый.

— Без моңа каршы бер чара таба алмыйбызмы соң, мистер Смит?

— Юк шул. Вулкан атуын күзәтеп кенә тора алабыз. Сез хәзергә мондагы эшләрне карагыз, Айртон. Мин ул арада Кызыл инеш янына барып, төньяк тау битен карап төшим. Аннары...

— Ә аннары... нәрсә, мистер Смит?

— Аннары Даккар мәгарәсенә барып килербез... Минем аны да күрәсем килә, Кыскасы, ике сәгатьтән әйләнеп кайтырмын.

Инженерны көткән арада Айртон муфлоннарны, кәҗәләрне карады. Алар тыныч түгел, әсәренешкәннәр, вулкан атачагын сизенәләр иде ахрысы.

Ә Сайрес Смит көнбатыш тау сыртына менеп җитте, Кызыл инешне әйләнеп узды. Беренче сәяхәт вакытында күкертле чишмә тапкан җиргә җитте.

Ул гомердән бирле монда таң калырлык үзгәрешләр булган! Һавага хәзер бер генә төтен баганасы түгел, унөч төтен баганасы үрләп менә икән. Көчле насос белән аткандай, төтен баганалары биеккә үк чөелә. Димәк, җир кабыгын эчтән бик көчле басым этеп тора. Әйләнәтирәгә су парлары белән кушылган күкерт газы, водород, углекислый газ таралган. Сайрес Смит монда җирнең дер селкенүен тойды. Ә аяк астында әлегә элекке вулкан эзләре генә, вакытлар узу белән тыгызланып туфракка әверелгән иске көл генә ята. Яңа лава эзләре күренми иде.

Франклин тавының төньяк битләвендә инженер Кызыл инеш тирәсендәге кебек үк хәлне күрде, тик монда үзгәрешләр тагын да күбрәк иде. Кратердан төтен болыты белән бергә ялкын телләре атыла, вак ташлар яңгыр кебек ява, әмма әлегә лава акмый иде. Димәк, эрегән токымнар төп кратер авызына хәтле менеп җитмәгән әле.

— Тизрәк булсын иде инде булса! — дип мыгырданды Сайрес Смит.— Ичмасам лаваның элекке юлдан агамы-юкмы икәнлеген белер идем. Югыйсә, башка яктан ага башламас дип кем кистереп әйтә ала. Тик әле куркынычның иң хәтәре ул түгел! Капитан Немо моны алдан дөрес сизенгән! Юк, төп куркыныч ул түгел!

Сайрес Смит Акула култыгының икегә аерылып киткән урынына, иске лава ташкыны янына килеп җитте. Элекке ташкынны бик игътибар белән күзәткәч, аның соңгы катлавының да бик-бик борынгы икәнлегенә төшенде.

Аннары ул утарга кире борылды. Күк күкрәүгә охшап җир астыннан ишетелгән ерак гөрелтегә, сирәк-мирәк каты шартлау тавышларына колак сала-сала атлады ул. Сәгать тугызларга утарга кайтып керде.

Айртон аны көтеп тора иде инде.

— Терлекләргә азык тараттым, мистер Смит,— диде Айртон.

— Бик шәп.

— Алар нигәдер бик тынычсызланалар әле.

— Буласы хәвефне сизенәләрдер, эчке сизем алдамый ул.

— Ә хәзер нишлибез?

— Фонарь белән чакма алыгыз да, әйдәгез, юлга кузгалабыз, Айртон,— диде инженер.

Айртон онагрларны бая ук туарган иде инде, алар хәзер утарда йөриләр. Капканы тышкы яктан бикләделәр дә тар сукмактан көнбатыш ярга таба киттеләр: Сайрес Смит алдан, Айртон арттан атлады.

Алар мамык өстеннән атлап баргандай баралар: аяк астына һавадан яуган көл, эре корым түшәлгән иде. Урманда бер җан иясе калмаган. Кошларга хәтле юкка чыкканнар. Кайчак җил генә исеп, җирдәге көл катлавын тузгыта, сәяхәтчеләр кара болыт эченә күмелеп калалар, бер-берсен күздән җуялар.

Куе тузан болытында тончыкмас, һәм күзләрен саклар өчен кулъяулыклары белән әле авызларын, әле күзләрен каплыйлар.

Әлбәттә бу хәлдә Сайрес Смит белән Айртон тиз бара алмадылар. Сулыш алырга да авыр иде, гүя һаваның кислороды янып кимегән. Тиздән тын җитми башлады. Йөз адымлап киткән саен, туктап тын алырга туры килде. Утрауның көнбатыш яры буеннан сузылган базальт, порфир кыялар тезмәсенә җиткәндә сәгать ун тулды.

Айртон белән Сайрес Смит текә ярдан аска төшә башладылар, теге чакта яшенле яңгыр койган төндә Даккар мәгарәсенә илткән кеше йөри алмаслык сукмактан читкә авышмаска тырыштылар. Хәер, көн яктысында сукмактан төшүе ул хәтле үк хәтәр булмады, өстәвенә шома, тайгак яр битенә көл катлавы утырган, атлавы асат, аяк шумый иде.

Тиздән юлчылар, диңгезгә җитәргә кырык фут чамасы кала, ярның сөзәкләнгән турысында иделәр инде. Су чигенә башлаган булса да, комлы яр ачылмаган иде

әле, вулкан тузаны утырган, көрән төскә кергән дулкын базальт кыя итәгенә җай гына бәргәләнә.

Сайрес Смит белән Айртон Даккар мәгарәсе авызын тиз таптылар, ярның иң түбән җирендә мәйданчык кебек торган кыя өстенә төштеләр.

— Көймә урынындамы? — дип сорады инженер.

— Әйе,— диде Айртон, Пенкроф белән бергә базальт мәгарә ышыгына куеп калдырган җиңел көймәне тартып чыгарды.

— Ярый алайса, юлга кузгалдык!

Икесе дә көймәгә кереп утырдылар. Көймә дулкын өстеннән шуып кына диярлек мәгарәнең тәбәнәк авызыннан эчкә кереп китте; Айртон чакма чагып фонарь кабызды, аны алдан юлны яктыртып барырлык итеп көймә борынына урнаштырды, аннары кулына ишкәк алды; Сайрес Смит койрыкка утырды, көймәне мәгарә эченә юнәлтте.

«Наутилус» биредә юк иде инде; тау куышындагы мәңгелек төн карасын җиңгән якты ут күренмәде. Көчле энергия чыганагына көйләнгән электр уты, бәлкем, су астында тирәндә әле һаман яктыртып торадыр, әмма упкыннан, капитан Немо кабере яныннан, монда өскә бер генә нур да менеп җитә алмый иде.

Фонарь яктысы Сайрес Смитка көймәне мәгарәнең уң як стенасы буеннан кыю рәвештә алып барырга юл күрсәтә. Базальт гөмбәз астында кабер тынлыгы хөкем сөрә. Һәрхәлдә, мәгарәнең алгы ягында тын иде, ә бераздан инженер җир астыннан килгән гүләү тавышын аермачык ишетте.

— Бу — вулкан,— диде ул.

Тиздән гүләү тавышына зәһәр ис тә килеп кушылды, Сайрес Смит белән Айртон күкерт газы исенә тончыга яздылар.

Сайрес Смитның чырае агарып китте.

— Капитан әнә шуны кисәтте дә инде! — дип мыгырдап куйды ул.— Шулай да без үз максатыбызга ирешергә тиешбез.

— Ярый, ирешербез,— диде Айртон, ишкәкләрен батыра-батыра ишеп, көймәне мәгарә түренә таба алып китте.

Егерме биш минуттан көймә мәгарәнең түр стенасы янына җитеп туктады.

Сайрес Смит, утыргычка аягүрә басып, фонарен югары күтәрде дә вулканның төп кратеры белән мәгарәне

аерып торган стенаны әкренләп, өлешләп карый башлады. Стенаның калынлыгы ни чама икән? Йөз футмы, әллә ун гынамы? Бу сорауга берәү дә җавап бирә алмаячак. Стенаның калын булуы бик шикле, чөнки биредә җир астыннан гүелдәү бик ачык ишетелә.

Стена буйлый карап чыккач, фонарьне ишкәк башына эләктерде дә янәдән каршы як базальт стенадан йөртә башлады,— стенаның өске өлешен карарга тырышты.

Шунда таш стенаның күренер-күренмәс ярыкларыннан ачы төтен бөркелүен күрде: мәгарә һавасын шул агулый икән. Шома базальт стенаны пәрәвез кебек ярыклар чуарлаган, ярыкларның кайберсе су өстенә кадәр төшеп җиткән икән.

Сайрес Смит берара уйга чумып басып торды. Аннары чак ишетелерлек итеп:

— Әйе, капитан хаклы! Хәтәр урын менә шушында, бу чыннан да коточкыч хәл! — дип пышылдады.

Айртон берни сорашмады. Сайрес Смит кулы белән ишарәләүгә ишкәген суга батырды. Ярты сәгатьтән соң юлчылар Даккар мәгарәсеннән чыгып киттеләр.

Унтугызынчы бүлек

Сайрес Смит күргәннәрен хикәя итә.— Кораб төзүне тизләтәләр.— Соңгы тапкыр утарга бару.— Ут белән су көрәше.— Утрауда нәрсә калды.— Корабны суга төшерү.— 8 нче марттан 9 нчы мартка каршы төн.

Утарда көне буе торып хуҗалыкны барлагач, Сайрес Смит белән Айртон анда төн кундылар да 8 нче январьда иртән Гранит сарайга кайтып киттеләр.

Инженер иптәшләрен янына җыйды, утрауның язмышы кыл өстендә торуын, аны һәлакәттән коткару мөмкин түгеллеген әйтте.

Гаять дулкынланып, ул:

— Дусларым! Үзенең табигый ясалышы аркасында Линкольн утравы озак яшәргә сәләтле түгел. Азмыдыр-күпмедер вакыттан соң ул барыбер җимереләчәк. Аны һәлакәткә китерүче сәбәп үзендә үк тупланган һәм берни коткара алмаячак,— диде.

Дуслар бер-берсенә караштылар, аннары аптырашып Сайрес Смитка төбәлделәр,— алар бу сүзләрнең мәгънәсен төшенеп бетмәделәр.

Гедеон Спилет:

— Аңлатыбрак сөйләгез әле, Сайрес,— диде.

— Хәзер аңлатам,— дип җавап бирде Смит.— Мин сезгә капитан Немоның ялгызыма гына нәрсәләр әйткәнен сөйләп бирәм.

— Капитан Немо? — дип аптыраштылар башкалар.

— Әйе. Үләр алдыннан ул безгә соңгы ярдәмен, соңгы киңәшен әйтте.

— Соңгы? — дип кабатлады Пенкроф.— Соңгы ярдәм дисезме? Менә күрерсез, үлгәннән соң да аның безгә ярдәме бер генә тапкыр тимәс әле.

— Капитан Немо сезгә нәрсә дигән иде соң? — дип сорады журналист.

— Менә нәрсә, дусларым,— Линкольн утравының төзелеше Тын океандагы башка утраулардан аерыла, иртәме-соңмы аның су астындагы нигезе җимерелергә тиеш.

— Җимерелергә? Линкольн утравы җимереләме? Куегыз! — диде Пенкроф ышанмыйча. Сайрес Смитка ихтирамы нихәтле зур булмасын, ул иңнәрен сикертеп куйды.

— Игътибар белән тыңлагыз, Пенкроф,— дип сүзен дәвам иттерде инженер.— Капитан Немо алдан ук менә нәрсәне сизенгән: кичә, Даккар мәгарәсенең стенасын карап чыккач, үзем дә күрдем: мәгарәнең түр стенасы вулкан белән тоташ; вулкан үзәгеннән, ягъни аның учагыннан түрдәге стена гына аерып тора. Ул стенаны иңеннән буена бик күп ярыклар чуарлаган, ярыклардан хәзер вулкан «миче»нең газы чыгып тора.

— Йә, шуннан? — дип сорады Пенкроф төксе генә.

— Шуннан шул, газ басымыннан ул ярыклар киңәячәк. Базальт стена җимереләчәк һәм тиздән мәгарәдәге су вулкан эченә бәреп керәчәк.

— Бик шәп,— диде Пенкроф, гадәтенчә шаяртырга тырышып.— Су вулкан утын сүндерәчәк һәм вәссәлам!

— Әйе, вәссәлам шул! — диде Сайрес Смит.— Стена җимерелеп, диңгез суы вулкан эченә бәреп кергән көнне, Пенкроф, Линкольн утравы шартлап күккә очачак! Әгәр Урта диңгез суы Этна эченә бәреп керсә, Сицилия утравы да күптән очкан булыр иде инде.

Иптәшләре инженерның катгый фикеренә каршы берни дә әйтә алмадылар. Утрауның коточкыч язмышка дучар икәнлегенә төшенделәр.

Сайрес Смит арттырып сөйләми иде. Моңарчы да бик күп кешеләрнең күңеленә вулканнарның кызган карынын

су тутырып сүндереп булмас микән дигән уй килгәне бар иде. Чөнки күп вулканнар диңгез яки күл буена урнашкан. Әмма ул хыялыйлар шунысын белмиләр, артык күп ягудан пар басымы кинәт артып, пар казаны шартлаган кебек үк, вулкан тирәсендәге җирләр дә шартлап күккә очачак. Ничәмә-ничә мең градуска кызган ябык урынга бәреп кергән су шул мизгелдә парга әйләнеп, коточкыч көч белән тышка омтыла һәм теләсә нинди кабыкны җимереп чыга.

Шик калмады, утрауның язмышы хәвефле; дәһшәтле сәгать якынлаша. Бу сәгатьнең кайчан сугуы Даккар мәгарәсендәге базальт стенаның күпмегә чыдавына бәйләнгән икән. Сүз хәзер айлар, атналар хакында бармый,— бәлкем көннәр, сәгатьләр хакында барадыр.

Утрау хуҗаларының хәсрәтен сөйләп аңлатырлык түгел иде. Алар үзебез харап булабыз дип борчылмадылар, авыр чакта аларны куенына сыендырган утрауның, чәчәк атучы өлкәгә, җир өстендәге оҗмахка әверелдерергә хыялланган җир кисәгенең җимереләчәген уйлап кайгыга баттылар. Нихәтле көч әрәмгә китә! Нихәтле хезмәт җилгә оча бит!

Пенкроф түзә алмады, елап ук җибәрде: эре-эре яшь бөртекләре яңагы буйлап тәгәрәде, елавын яшерергә дә теләмәде ул.

Әңгәмә әле тагын бераз дәвам итте, Линкольн утравы хуҗалары берәр котылу юлы юкмы дип киңәштеләр. Нәтиҗәдә, бер минутны әрәм итмәстән, корабны тизрәк төзеп бетерергә, ашыгыч кына җиһазларга кирәк дигән бердәм карарга килделәр, чөнки котылу өчен бердәнбер юл фәкать шул иде.

Һәммәсе дә корабны төзү эшендә катнашырга тиеш булды. Игеннәрне җыеп, ауга йөреп, Гранит сарай чоланнарындагы азык-төлекне арттырып азапланмаска... Чоланнардагы азыкның булган хәтлесе дә ерак юлга артыгы белән җитәрлек иде. Хәзер аларның бердәнбер максаты: коточкыч һәлакәткә хәтле корабны төзеп җиткерү иде.

Ярсып эшкә тотындылар һәм алны-ялны белми эшләделәр. 23 нче январьга кораб тышлыгының яртысын кагып бетерделәр. Вулкан түбәсендәге хәлләр әлегә үзгәрешсез кебек иде. Кратердан һаман да пар болыты, төтен, ялкын телләре, кызган ташлар атыла. Ә 23 нче январь төнендә исә кратер бугазына тыгылган лава басымыннан кинәт вулканның бүреккә охшаш түбәсе шарт-

лады. Колак яргыч шартлау тавышына, утрау җимерелә дип уйлап, барысы да Гранит сарайдан атылып чыктылар.

Төнге сәгать ике иде.

Бөтен күк йөзен ялкын чолгап алды. Мең фут биеклегендәге, миллионнарча пот авырлыктагы конуссыман түбә очып утрау өстенә килеп төшүгә җир дер селкенде. Бәхетләре бар икән, кратер авызы төньякка авыш булганга, ул тау белән диңгез арасындагы комлы, туфлы тигезлеккә барып төште. Киңәеп калган кратердан хәзер күккә кып-кызыл ялкын бөркелә, бөтен күк йөзен гүя янгын шәүләсе чолгап алган иде. Күпереп менгән лава ташкыны тиздән вулканның яңа авызыннан ташып чыкты да тау бите буйлап ага башлады, гүя меңләгән утлы еланнар шуыша иде.

Айртон ачыргаланып:

— Ах, мал утарын харап итә! Мал утарын! — дип кычкырып җибәрде.

Чыннан да, яңа кратер хәзер башка якка авыш иде, лава утар ягына таба ага, димәк утрауның уңдырышлы өлешләре, Кызыл инеш чыганагы, Җакамар урманы харап булачак.

Айртонның тавышын ишетүгә, һәммәсе онагрлар абзарына ташландылар. Аларның күңеленә, утарга чабып барып, анда ябылган терлекләрне чыгарырга кирәк дигән уй килде. Күз ачып йомганчы онагрларны арбага җиктеләр.

Утарга барып җиткәндә иртәнге өч тулмаган иде әле. Терлекләр абзарда ду киләләр, кәҗәләр акырыша, муфлоннар бакырыша. Янындагы тау сыртыннан утлы ташкын төшеп килә, ул инде болынга җитеп, утар коймасына якынлаша иде. Айртон капканы ачып җибәрүгә, шашынган терлекләр атылып чыгып, күзләренә ак-кара күренмичә, төрле якка чабып качып беттеләр.

Бер сәгатьтән кайнар лава ташкыны бөтен утарга җәелде, юлында очраган инеш суын парга әйләндереп күмеп китте, өй-каралтылар, коры саламга ут капкандай, гөлт итеп кабынып киттеләр дә, минут эчендә юкка чыктылар, бөтен койма-кура секунд эчендә янып бетте. Утарның бер шырпысы да калмады!

Утрау хуҗалары лава ташкыны белән көрәшеп карасалар да, бу акылсыз, мәгънәсез омтылыш кына иде, чөнки кеше мондый коточкыч һәлакәт алдында әлегә көчсез.

24 нче январь көне туды. Гранит сарайга әйләнеп кайтканчы Сайрес Смит белән иптәшләре лава ташкынының төгәл юнәлешен беләселәре килде. Франклин тавыннан алып утрау өсте көнбатыш ярга таба сөзәк иде, юлында Җакамар урманы саклагыч киртә кебек торса да, лава ташкынының Күзәтү яссылыгына килеп җитәсе ачыкланды.

— Бер юаныч,— күл саклаячак безне,— диде Гедеон Спилет.

Сайрес Смит:

— Шулай дип өметләник,— диде дә бүтән сүз әйтмәде.

Алар вулканның бүреге очып төшкән тигезлеккә барып карамакчылар иде, утлы ташкын аларның юлын бүлде. Ул ике иңкүлек буйлап — Кызыл инеш үзәнлеге белән Шарлавык елгасы үзәнлегеннән агып төшә башлады, елга суы шундук парга әверелә барды. Лава ташкынын кичеп чыгарга мөмкин түгел иде, киресенчә, аның алдында чигенергә туры килде.

Вулкан танымаслык булып котырына. Кратеры упкын авызы кебек киңәйгән, көнчыгыш һәм көньяктан ярылып киткән, шул ярыклардан бертуктаусыз лава ага, ике ташкын булып йөгерә. Яңа кратер өстендә төтен, көл йомгаклары ургыла, алар күкне каплап алган кара болыт белән кушылалар. Вулкан аткан авазлар, гөрселдәүшартлаулар көчле күк күкрәү белән аралаша. Вулкан авызыннан атылып чыккан утлы кантарлар өчәр йөз метр биеккә чөелеп, болыт эчендә шартлыйлар да меңәрләгән вак кисәкләргә таркалып тирә-якка чәчеләләр. Вулкан гөрселдәвенә күктән яшен яшьнәп, күк гөлдерәп җавап бирә.

Җакамар урманы авызында ышыкланган килеш, утрау хуҗалары бу дәһшәтне шаккатып карап тора бирделәр. Әмма иртәнге җиделәрдә түзәр әмәл калмады. Әйләнә-тирәдә таш яңгыры ява, өстәвенә лава ташкыны Кызыл инеш үзәнен күмеп китте, бу хәл аларны яр буеннан бүлеп калдыруы мөмкин иде. Тиздән урман авызындагы агачларга да ут кабынды, яшел агач эчендәге дым шундук парга әйләнде дә, юан-юан кәүсәләр шарт та шорт ярылырга керешәләр иде. Тик бик яшь, юешрәк агачлар гына әлегә моңа бирешми утыралар.

Утрау хуҗалары утар юлына чыктылар. Әледән-әле артларына борылып карый-карый әкрен генә Гранит сарайга таба кайтып киттеләр. Әмма үзәнлек сөзәк булганлыктан, ташкын көнчыгыш ярга таба тиз ага иде,

аскы каты аз-маз катуга, өстеннән, кайный-кайный яңа дулкын килә башлый иде.

Кызыл инеш үзәненнән юнәлгән төп ташкын бик куркыныч күренә. Урманның ташкынга якын ягы тоташ яна, ябалдашлар өстендә төтен ургыла, агач кәүсәләре кабынып китә дә шарт-шорт ярыла-ярыла яналар.

Юлчылар Кызыл инеш тамагына ярты миль чамасы читтә күл ярында тукталдылар. Аларның үлем яки яшәвев хәл иткән минут якынлашып килә иде.

Сайрес Смит иң куркыныч хәлләрдә дә каушап калмый торган нык ихтыярга ия кеше, ул иптәшләренең инде иң ачы хакыйкатьне дә тыңлый алачакларына ышана иде.

— Бәлкем, күл лава ташкынын туктатыр, шул хәл утрауны коткарып калыр. Тик лаваның Ерак Көнбатыш урманнарына ук җәелеп, бөтен нәрсәне харап итүе, утрауда бер үсемлек заты калмавы ихтимал. Ул чакта шәрә кыялар өстендә әҗәл көтәргә туры киләчәк. Хәер, озак көтмәбез дә, утрау шартлап күккә очар.

Пенкроф, кулын күкрәгенә кушырып, җиргә тибеп куйды:

— Ничек инде? Корабны төзеп азапланмыйкмыни?

— Пенкроф, үз бурычыңны ахырга хәтле үтәргә кирәк,— диде Сайрес Смит.

Эрегән лава елгасы бу мәлдә, гүзәл агачлар арасына ташланып, аларны ялмый-ялмый, күлгә дә килеп житте. Шунда аның юлын калкулык бүлде. Әгәр ул биегрәк булса, ташкынны туктата да алыр иде.

— Эшкә! — дип кычкырды Сайрес Смит.

Инженерның ниятен тиз төшенеп алдылар. Ул, буа төзеп, лава ташкынын күлгә таба юнәлтергә исәпли иде.

Иптәшләре, Хәрабәгә йөгереп барып, көрәкләр, кәйләләр, балталар алып килделәр. Агач егып, җир өеп, берничә сәгать эчендә билдән биек итеп берничә адым озынлыгындагы буа төзеп өлгерттеләр. Эшне бетергәндә аларга берничә минут узган кебек кенә тоелды.

Вакытында өлгерделәр. Эрегән лава буага килеп житте. Яз көне ярларыннан ташып чыгарга омтылган елга кебек, күзгә күренеп күперде, буаны ерыр да, менә-менә Ерак Көнбатыш урманын басып китәр кебек тоелды. Әмма буа бирешмәде. Бик хәвефле бер мизгел булып алды: гүя утлы елга нишләргә белмичә туктап калды һәм кинәт Грант күленә таба егерме фут биеклегендәге текә ярдан аска омтылды.

Тынсыз-өнсез калган сәяхәтчеләр ике табигать көченең дәһшәтле көрәшен шаккатып карап тордылар.

Ут белән су көрәшә! Таң калырлык тамаша иде бу! Бу соклангыч та, куркыныч та көрәшне сурәтләп бирергә кайсы язучы каләменең көче җитәр иде икән? Кайсы рәссам моның рәсемен ясый алыр иде икән? Күл ярыннан кайнап-ургылып утлы ташкын килеп төшүгә, су чыжылдап парга әйләнә дә ак пар болыты өерелә-өерелә күккә чөелә, гүя кинәт кемдер гигант пар казанының капкачын ачып җибәргәндәй тоела башлый. Күлнең суы никадәрле күп булмасын, ут аны ахырда барыбер җиңәр, чөнки су күлгә өстәлми, ә бетмәс-төкәнмәс чыганактан агып чыккан дәһшәтле ут елгасы армый-талмый дулкын арты дулкынын тәгәрәтә генә.

Күлгә төшү белән үк лава үзе дә катып кала, таш кантарлары хасил була; өсте-өстенә өстәлә барган кантарлар тиздән кыя булып та чыктылар. Кыя өстеннән яңадан-яңа лава ташкыны уза торды, алар суга төшә барды, ката барды, кыя күл эченә таба сузыла барды. Бер-бер артлы таш кыялар рәте тезелеп китте. Тиздән бу ташкын бөтен күлне тутырачак, күл суы ташып чыга алмый, чөнки шундук парга әйләнеп оча бара иде. Күл өстендә колакны кисәрлек чыжылдаган, чытырдаган тавышлар ишетелеп тора, жил пар болытын диңгез ягына таба очыра, салкын һавада ул пар куерып, яңгыр булып яварга керешә иде. Каткан лава кантарлары өсте-өстенә өелүдән таш дамба озыная барды. Әле кайчан гына тып-тын су өсте ялтырап яткан урында, җир тетрәүдән калган таш өемнәре кебек, парланып утырган кыялар тезелеп китте. Күз алдына китерә аласыз: давыл кубарган тау чаклы дулкыннар егерме градус салкында бер мизгелдә бозга әверелде, ди. Юлында очраган һәр нәрсәне кырып-җимереп килгән утлы ташкынның ярдан ташлануына өч сәгать узды дигәндә күлдә әнә шундый күренеш хасил булды.

Бу юлы суны ут җиңде.

Әмма утрау кешеләре өчен лаваның күл ягына таба борылуы зур бәхет иде. Бу хәл һәлакәтне берничә көнгә артка чигерде. Күзәтү яссылыгы, Гранит сарай, тезелеп яткан кораб әлегә исән калды. Шул берничә көн эчендә корабның тышлыгын кагып бетереп, әйбәтләп мүкләргә дә тизрәк суга төшерергә кирәк иде. Җиһазларын диңгезгә төшергәч тә урнаштырып булыр. Ярда калу хәзер иң хәтәре, утрау менә-менә шартлап күккә

очарга тора. Моңа хәтле ышанычлы торак булган Гранит сарай да тиздән җимерелеп төшәчәк.

25 нче январьдан 30 нчы январьга хәтле алты көн эчендә утрау хуҗалары ярсып-ярсып эшләделәр, егерме балта остасы да алар хәтле эшли алмас иде. Бер минут ял итмәделәр, йокламадылар, тәүлек буе бертуктамый корабта булдылар. Вулкан авызыннан бөркелгән ялкын яктысында төнлә дә көндезге кебек яп-якты иде. Кратердан лава һаман ага, тик күләме бераз кими төште. Моңа шатландылар гына, чөнки Грант күле инде тулды диярлек. Әгәр ташкын тагын да көчәйсә, лава, күлдән артып чыгып, Күзәтү яссылыгына агачак, ә аннан океан ярына таба юнәләчәк.

Утрауның көнчыгыш яры әле азмы-күпме сакланган булса да, көнбатыш өлеше бөтенләй инде такыраеп калган иде.

Чыннан да, икенче ташкын Шарлавык елгасы буйлап ага, инде елга ярыннан да артып чыкты, үзәнлектә тоткарлыкка очрамыйча, һаман саен як-якка киңрәк җәелә барды. Утлы ташкын Ерак Көнбатыш урманына һәлакәт илтә иде. Елның кызу чоры бит, агачларның дымы эсседән кибеп беткән диярлек, алар гөлт итеп кабыналар да, ялкын тиз арада куе ботаклар буйлап өскә үрли. Урманның асты да, өсте дә яна. Агачлар арасыннан җирдән үрмәләгән ташкынга караганда, янгын агач ботакларыннан тизрәк йөгерә иде.

Куркудан шашкан җанварлар — ягуарлар, кабан, көнгерә, аюлар — гомумән һәммә киек һәм кошлар, котылу юлын эзләп, Рәхмәт елгасына, Үрдәк сазлыгына һәм, юл аша чыгып, Һава шары портына таба ташландылар. Эш белән мәшгуль балта осталарының иң явыз ерткычларга да игътибар итәргә вакыты юк иде... Алар Гранит сарайны бөтенләй ташлап чыктылар. Хәрабәгә кереп сыенырга батырчылык итмичә, Рәхмәт елгасы тамагына чатыр корып, шунда яши башладылар.

Сайрес Смит белән Гедеон Спилет һәр көн Күзәтү яссылыгына менеп төшәләр. Кайсы көнне аларга Герберт та иярә. Әмма Пенкроф анда менми, элек сокланып туя алмаган утрауның фаҗигасен күрәсе килми.

Утрау күренеше чыннан да бик аяныч иде. Урман үскән яклар шәрәләнеп калган. Борылмалы ярымутрауның иң очында гына яшеллек күренә. Тегендә дә монда агачларның кап-кара иләмсез кәүсәләре генә тырпаешып утыралар. Элекке урманлы яклар хәзер Үрдәк

сазлыгына караганда да шыксызрак, бушрак. Кайнар ташкын барысын харап иткән. Кайчандыр күккә үрләп үсеп утырган гүзәл агачлар урынында вулкан туфы кантарлары ята. Шарлавык елгасы белән Рәхмәт елгаларында хәзер бер тамчы су юк, әгәр Грант күле дә парга әйләнеп бетсә, колонистларга эчәр су да калмас иде. Әле дә, бәхеттән, күлнең көньяк читендә бер кечерәк кенә почмак исән калды,—анда буа сымак нәрсә хасил булды, күлнең калган барлык суы шунда җыелды. Еракта, төньяк-көнбатышта, гигант тырнакларын җиргә батырган аждаһадай, вулкан ыржаеп күренә. Үзләренең тырыш хезмәте нәтиҗәсендә бай өлкәгә әверелгән, күкрәп үскән урманнар белән капланган, җирне сугарып, саф сулы чишмә-кизләүләр, елга-инешләр аккан, басуларында мул иген үскән утрауның аянычлы күренешен, дәһшәтле манзарасын күреп, аларның йөрәкләре телгәләнеп бетте. Бер мизгелдә бар гүзәллек юкка чыкты, әйләнә-тирәдә шәрә ташлар гына тырпаешып калды. Әгәр аларның электән туплаган азык-төлеге булмаса, ачтан үләрләр иде.

— Йөрәгең ярылырлык хәлләр бит,— диде Гедеон Спилет.

— Әйе, Спилет. Тизрәк корабны төзеп бетерик, бар өмет шунда! — диде инженер.

— Сайрес, вулкан бераз тынычланган кебек тоелмыймы? Лавасы һаман ташыса да, элекке кебек күп түгел бугай!

— Аның инде мәгънәсе юк,— диде Сайрес Смит.— Вулкан карынында барыбер ут дөрли, менә-менә анда диңгез суы бәреп керәчәк. Диңгездә йөзеп барган чакта корабта янгын чыгып, аны сүндерә алмауларын, иртәме-соңмы утның дарылы мичкәләр төялгән трюмга барып җитәчәген белгән пассажирлардан безнең хәл бер дә артык түгел. Әйдәгез, Спилет, китик, эшлик! Вакытны әрәм итмик!

Тагын бер атна буе, 7 нче февральгә хәтле, кратердан эрегән токымнар ташыды, ләкин вулкан ату көчәймәде. Сайрес Смит эрегән токымнар елгасы диңгез ярына агып төшмәгәе дип борчыла башлады, ул чакта төзелеп бетмәгән кораб харап булачак бит. Берничә көннән утрау хуҗалары аяк астында җирнең бик тирәндә тетрәнүен тойдылар, бу хәлгә котлары очты.

20 нче февраль җитте. Корабны тәмам төзеп бетереп, суга төшерер өчен тагын бер айлап вакыт кирәк

иде. Утрау аңа хәтле түзә алырмы-юкмы? Пенкроф белән Сайрес Смит, корпусына су үтмәслек булуга, корабны суга төшерергә исәплиләр. Палубасын җәюне, өске өлешләрен төзеп бетерүне, җиһазландыруны диңгездә чакта да эшләргә мөмкин,— утраудан еракта кереп сыеныр почмак кына булсын. Корабны Һава шары портына, янартаудан ераккарак илтмәскә микән дип уйлый башладылар. Чөнки ул хәзер гранит стена белән Котылу утравы арасында елга тамагында тора, алай-болай Линкольн утравы шартлый калса, аста калып изелүе мөмкин иде. Шуңа күрә төзүчеләр ничек тә кораб корпусын ясап бетерергә ашыктылар.

Шулай итеп, 3 нче мартны да җиткерделәр, ун көннән корабны суга төшерәбез дип өметләнәләр иде инде.

Линкольн утравында дүрт ел буе яшәү дәверендә күпме бәла-каза кичергән кешеләрнең күңелендә өмет чаткысы терелде. Газиз биләмәләренең харап булуын үз күзе белән күргәннән бирле эченә йомылган төксе чырайлы Пенкрофның да күңеле күтәрелеп китте. Дөрес, хәзер ул бары кораб турында гына уйлый, фәкать аңа гына өметләнә.

— Без аны төзеп бетерәбез, мистер Смит. Менә күрерсез, төзеп бетерәбез,— диде ул инженерга.— Тик көн үтә тора, көн белән төн тигезләшкәнче өлгерергә иде. Хәер, бер дә булмаса Табор утравына китеп, анда кыш чыгарбыз. Линкольн утравыннан соң Табор утравы кызык түгел инде түгелен! Кая инде аңа безнең утрауга җитү! Их, бәхетсез баш! Мондый хәлгә каласым төшемә дә кермәгән иде!

— Ашыгырга кирәк! — дип кенә әйтте инженер һәрвакыттагыча.

Бер генә минутны да әрәм итмичә, һәммәсе ашыга-ашыга бирелеп эшләделәр.

Көннәрдән бер көнне Наб:

— Мистер Смит, әгәр капитан Немо исән булса, утрау бу хәлгә тарыр иде микән, ничек уйлыйсыз?

— Әйе, Наб,— диде Сайрес Смит.

— Минемчә, бу хәл булмас иде,— дип пышылдады Пенкроф Набның колагына.

— Мин дә шулай дип уйлыйм,— диде Наб ышаныч белән.

Мартның беренче атнасында Франклин тавы яңадан кодрәтен күрсәтә башлады. Эрегән лава чәчрәгәннән хасил булган меңләгән пыяла кисәкләре яңгыр булып

җиргә яуды. Кратер янәдән тулып ташып чыкты да, лава барлык тау сыртлары буйлап ага башлады. Утлы ташкын катып өлгергән туф өстеннән йөгерде, беренче ташкыннан соң шыксыз кәүсәләре тырпаеп калган, күмерләнгән агачларны ялмап йотты. Бу юлы ташкын Грант күленең көньяк-көнбатыш яры буйлап китте, Глицерин елгасы аша чыгып, Күзәтү яссытаулыгына кадәр җәелде. Бу аның утрау хуҗаларына соңгы үтергеч һөҗүме иде. Тегермән, кош кетәге, ат абзарлары, сарайлар күз ачып йомганчы күмергә әйләнде. Куркышкан кошлар пырылдап төрле якка тузгыдылар. Топ белән Юп та, һәлакәт якынлашуын сизенеп, тынычлыкларын җуйдылар. Вулкан атудан күпме җанвар һәлак булды инде. Исән калган җәнлекләр исә Үрдәк сазлыгына кереп тулдылар. Ә Күзәтү яссылыгындагылары соңгы сыеныр җирләреннән дә яздылар. Утлы ташкын, ялкын бөрки-бөрки, шарлавык булып гранит стена читеннән диңгез ярына ыргылды. Сурәтләп бирергә сүз җитмәслек дәһшәтле бер галибанә күренеш туды! Чәчләрне үрә торгызырлык куркыныч Ниагара төне буена ташыды; өскә пар болытлары чөеп, үтәли кыпкызыл яктырып, эрегән чуен ташкыны кебек акты да акты, тирә-якка кайнап торган авыр лава тамчылары чәчрәп торды.

Ташкын утрау хуҗаларының соңгы торакларына килеп җитә язды. Кораб корпусының өске җөйләрен мүкләргә өлгерә алмасалар да, төзүчеләр шхунаны суга төшерергә карар иттеләр.

Пенкроф белән Айртон корабны иртәгесен, 9 нчы мартта, суга төшерер өчен хәзерлек эшләрен башладылар.

8 нче марттан 9 нчы мартка каршы төнне кинәт кратер авызыннан яшен аткандагы кебек шартлап гигант пар болыты бәреп чыкты да өч мең фут биеккә очып менде. Газ басымына түзмичә Даккар мәгарәсенең стенасы җимерелеп, диңгез вулкан учагына бәреп керде, күрәсең. Дөньяда булмаганча коточкыч каты шартлау тавышы йөзләрчә миль ераклыкларга хәтле таралды. Кыя җимерекләре күккә очты, тау диңгезгә ишелеп төште. Әле хәзер генә Линкольн утравы торган җирне берничә минут эчендә су күмеп китте.

Егерменче бүлек

Океан уртасында ялгыз кыя.— Соңгы сыеныр почмак.— Алда — үлем.— Көтелмәгән ярдәм.— Ярдәм кайдан, ничек килде соң?— Соңгы шәфкать.— Коры җир эчендә — утрау.— Капитан Немо кабере.

Су өстендә биеклеге өч метр чамасы, озынлыгы утыз, киңлеге унбиш футлы ялгыз кыя калкып тора. Океан сулары йоткан утраудан бары Гранит сарай урнашкан таш стенаның бер кисәге генә исән калды. Гранит стена үзе ярылып, җимерелеп төште, таш кантарлар өсте-өстенә өелешеп, океан эченнән шушы сырт калкып чыкты. Утрауның башка барлык өлешләрен: шартлап тирә-якка очкан Франклин тавын, кайчандыр каткан лавадан хасил булган Төньяк һәм Көньяк Казна борыннарын, Күзәтү яссытаулыгын, Котылу утравын, Һава шары портының таш кыяларын, Даккар төрбәсенә әверелгән базальт кыяларны, янартаудан ерактагы Борылмалы ярымутрауны — һәммәсен упкын йотты. Линкольн утравыннан калган тар гына кыя өстенә алты кеше һәм Топ менеп сыендылар.

Утрау фаунасының барча вәкилләре: җәнлекләр дә, кошлар да һәлак булдылар,— кайсы таш астында калып сытылды, кайсы диңгезгә батты. Ни аяныч! Бичара маймыл Юп та һәлак булды, җир ярыгына төшеп киткәндер, күрәсең.

Сайрес Смит, Гедеон Спилет, Герберт, Пенкроф, Наб һәм Айртон чатырда иделәр, утрау шартлагач, төрле яктан коелган ташлар белән бергә шартлау дулкыны аларны диңгезгә атып бәрде, шуның аркасында гына исән калдылар алар.

Ярдан берәр чакрым ераклыкта судан калкып чыккач, алар тирә-якка күз салдылар һәм, гранит кантарлар өелешкәннән хасил булган сыртны күреп, шунда йөзеп бардылар да үрмәләп өскә менделәр.

Шәп-шәрә бу кыя башында алар инде тугыз көн яшәделәр! Гранит сарайдан алып чыккан аз-маз азыктөлек, таш арасындагы чокырларга җыелып калган яңгыр суы белән җан асрадылар. Соңгы өметләре булган кораб юкка чыккан иде. Бу кыядан алар хәзер беркая китә алмыйлар. Салкын төндә туңсалар да җылынырга утлары юк. Язмыш аларны шулай үлемгә дучар итте.

Көндәлек ашауны бик кысып тотсалар да, тугызынчы көнне, 18 нче мартта, аларның ике көнлек азыгы

калды. Мондый аяныч шартларда аларның белеме дә, зиһене дә ярдәм итә алмый иде инде. Алдагысы алла кулында иде.

Сайрес Смит үзен тыныч тота, Гедеон Спилетның бераз дулкынлануы сизелә, ә Пенкроф, эченнән ярсып, ташлар өстендә бертуктаусыз йөренеп тора. Герберт инженер яныннан китми, кулыннан килмәслек ярдәм өмет иткәндәй, күзен аңардан алмый. Наб белән Айртон сыкранмыйча язмыш ихтыярына буйсындылар.

— Афәткә тарыдык! Афәткә! — дип кабатлады Пенкроф.— Әгәр каегыбыз гына булса да, ичмасам чикләвек кабыгы гына булса да, Табор утравына барып җитә алыр идек, мөгаен. Бер генә нәрсәбез дә юк бит!

— Капитан Немо вакытлы үлеп котылды! — диде Наб.

Тагын биш көн узды. Сайрес Смит һәм аның бәхетсез иптәшләре үләр чиккә җиттеләр, чөнки алар җан асрарлык кына ашыйлар иде. Көчләре бетте. Герберт белән Наб саташа башладылар.

Аларның ичмасам инә очы хәтле дә өмете калмады. Нәрсәгә өмет итсен соң алар? Ялгыз кыя янына берәр кораб килеп чыгар дипме? Тәҗрибәдән беләләр бит инде, Тын океанның бу тирәсенә кораблар килеп чыкмый. Нәкъ шушы көннәрдә Шотландия яхтасы Табор утравына Айртонны эзләп килер дип ничек өмет итмәк кирәк?.. Буш хыял! Хәер, яхта килсә дә, Айртонның кайдалыгын белмәс, язу калдырып кайта алмадылар бит; капитан яхтасы эзләр-эзләр дә, тапмагач, үз юлына китеп барыр.

Котылырбыз дигән бер генә дә өмет юк иде. Бу кыяда аларны үлем сагалый, ач үлем сагалый!

Алар инде басып та тора алмыйлар, селкенмичә яталар. Тирә-якта ниләр барлыгын да сизәр хәлдә түгел иделәр.

Айртон гына әледән-әле, башын көчкә күтәреп, бупбуш диңгез өстенә тилмереп күз сала!

24 нче мартта иртә белән кинәт Айртон кулын күтәрде, очсыз-кырыйсыз су киңлегендә ниндидер ноктага ишарәләде. Башта тезләнде, аннары көч-хәл белән торып, аягүрә басты. Ул, сигнал бирергә теләгәндәй, кулларын болгады...

Анда кораб йөзеп килә иде. Ул очраклы килеп чыкмаган, кыяга таба туп-туры кызу килә иде. Әгәр басып торырлык егәре булып, офык читенә күз салсалар, кыя

башындагы бичара тоткыннар бу корабны берничә сәгать элек күреп алган булырлар иде инде!

Айртон чак ишетелерлек итеп:

— «Дункан»! — диде дә исеннән таеп егылды.

Сайрес Смит белән аның иптәшләре кораб каютасында аңнарына килделәр. Ничек исән калуларына төшенә алмыйча, аптырадылар.

— «Дункан»! — диде ул әкрен генә.

— «Дункан»! — дип кабатлады Сайрес Смит. Ике кулын күккә сузып:— Йа кадир, йа рахман! Рәхмәтеңнән ташламадын! Без котылдык!

Чыннан да, аларны лорд Гленарван яхтасы «Дункан» коткарды; аны хәзер капитан Грант улы Роберт йөртә икән; корабны кешесез Табор утравында унике ел буе ялгызы яшәп, гаебе акланган Айртонны туган иленә алып кайту өчен җибәргәннәр!..

Шулай итеп, утрау хуҗалары исән калды, кораб аларны туган илләренә алып кайтырга әзерләнде.

— Капитан Роберт, Айртонны тапмыйча Табор утравыннан кузгалып киткәннән соң төньяк-көнчыгышка таба тагын йөз миль йөзәргә дип сезгә кем киңәш итте? — дип сорады Сайрес Смит.

— Мистер Смит, без бирегә Айртонны гына түгел, бәлки сезне дә алып китәргә дип килдек,— диде Роберт Грант.

— Мине һәм минем иптәшләрне дә?

— Әлбәттә! Без Линкольн утравына таба юлга чыктык.

Гедеон Спилет, Герберт, Наб, Пенкроф бертавыштан:

— Линкольн утравына? — дип шаккатып кычкырып җибәрделәр.

— Линкольн утравын кайдан белдегез сез? — дип сорады Сайрес Смит.— Утрау карталарда да юк бит.

— Мин аны Табор утравында калдырган сезнең хатыгыздан белдем.

— Хаттан? — дип кайтарып сорады тәмам аптыраган Гедеон Спилет.

— Әйе, хаттан. Менә ул,— дип Роберт Грант бер бит кәгазь сузды. Анда: «Хәзерге көндә Айртон һәм Американың биш кешесе Линкольн утравында»,— дип язылган иде, утрауның координатлары күрсәтелгән иде.

Сайрес Смит хатны укыганда утардагы язуны язган кулны таныды.

— Бу — капитан Немо эше!..— дип куйды.

— Аһ, менә кем икән! — дип кычкырып җибәрде Пенкроф.— Теге чакта безнең корабны ул алган булып чыга. Япа-ялгызы Табор утравына барып килергә батырлыгы җиткән бит!..

— Ул анда хат язып калдырыр өчен барган! — дип өстәде Герберт.

— Капитан Немо үлгәннән соң да ярдәм итәр әле безгә дип әйтмәдемме мин сезгә, менә дөрес булып чыкты! — диде Пенкроф.

Сайрес Смит үтә тәэсирләнеп:

— Дусларым! Капитан Немо безнең чын коткаручыбыз. Ходай тәгалә урынын оҗмахта итсен! — диде.

Сайрес Смит сүзеннән соң һәммәсе, баш киемен салып, капитанның исемен пышылдадылар.

Шул мәлдә Айртон инженер янына килде:

— Тартманы кая куйыйм? — дип сорады.

Һәлакәт вакытында, үзе турында онытып, Айртон тартманы саклап калган иде, менә ул аны Сайрес Смитка китереп бирде.

Куанычтан югалып калган Сайрес Смит:

— Айртон! Айртон! — дип дулкынланып кабатлады. Аннары Роберт Грантка борылды:— Әфәндем! Сез Табор утравында җинаятьчене ташлап калдырган булсагыз, ә хәзер сезнең алда намуслы кеше басып тора, мин аның кулын дусларча горурланып кысам! — дип өстәде.

Шуннан соң Роберт Грант капитан Немо белән Линкольн утравында яшәүчеләрнең гаҗәеп дуслыгы турындагы хикәяне ишетте. Аннары капитан яңа рифның координатларын ачыклап язып алды. Моннан соң бу риф Тын океан картасында күрсәтеләчәк. Һәм менә алар кайту юлына борылдылар.

Ике атнадан утрау кешеләре Америкага кайтып җиткәч, туган илләрендә коточкыч сугыштан соң тынычлык урнашканлыгын, хак эш җиңгәнлеген күрделәр.

Капитан Немо бүләк иткән тартмадагы байлыкның бер өлешенә Линкольн утравы кешеләре Айова штатында зур гына җир сатып алдылар. Хәзинәләр арасыннан иң матур энҗене леди Гленарванга «Дункан» тарафыннан коткарылган, туган илләренә кайткан кешеләр исеменнән бүләк итеп җибәрделәр.

Бу яңа җиргә алар кайчандыр Линкольн утравына алып китәргә теләгән кешеләрен чакырдылар, хезмәт итәргә, иркендә, муллыкта яшәргә мөмкинлек тудырдылар. Шулай итеп монда зур гына биләмәләре булды, аңа Тын океан суында юкка чыккан утрауның исемен куштылар. Аларның монда да Рәхмәт елгасы, Франклин тавы, кечкенә генә Грант күле, Ерак Көнбатыш урманы дип аталган урманнары бар иде. Кыскасы, аларның биләмәсе гүя утрау иде — коры җир уртасындагы утрау иде ул.

Инженерның һәм аның иптәшләренең булдыклы җитәкчелегендә биләмә чәчәк атты. Элекке Линкольн утравы кешеләре бер-берсеннән аерылмадылар,— алар мәңге бергә яшәргә ант иттеләр. Наб болай да гомергә хуҗасы янында иде, Айртон иптәшләре өчен һәрвакыт үзен корбан итәргә әзер, кайчандыр атаклы диңгезче булган Пенкроф атаклы фермерга әйләнде; Герберт Сайрес Смит кул астында укуын тәмамлады, Гедеон Спилет исә дөньяда иң күп хәбәр бастыручы «Нью-Линкольн геральд» газетасын чыгара башлады.

Сайрес Смит һәм аның дуслары янына биләмәгә кадерле кунаклар: лорд һәм леди Гленарваннар, капитан Джон Манглс һәм аның хатыны — Роберт Грантның апасы — Мери, Роберт Грант үзе, майор Мак-Набс һәм шулай ук капитан Грант, капитан Немо маҗараларына катнашкан башка кешеләр еш кына кунакка киләләр иде.

Һәммәсе элекке кебек бик дус, бәхетле яшиләр. Кайчандыр ач, ялангач килеш килеп төшкән, дүрт ел буе бер мохтаҗлык күрмичә яшәгән ерактагы утрауны, Тын океан дулкыннары уртасында торып калган ялгыз таш кыя астындагы капитан Немо дигән шәфкать иясенең табутын да гомергә онытмадылар алар.

1875

ЭЧТӘЛЕК

ИКЕНЧЕ КИСӘК

Тоткын

Беренче бүлек. Ядрә хакында бәхәс.— Көймә ясау.— Ауда.— Герберт агач башына менә.— Утрауда кеше яшәгәнлеге сизелми.— Чалкан әйләндерелгән ташбака.— Ташбака югалган.— Сайрес Смитның аңлатмасы . . . 3

Икенче бүлек. Көймәне беренче тапкыр сынау.— Диңгез ярыннан табылган әйберләр.— Табылдык борыны.— Әрҗә эчендә нәрсәләр бар? — Эш кораллары, сугыш кораллары, приборлар, кием-салым, китаплар, йорт кирәкяраглы.— Пенкрофка нәрсә җитми? — Инҗил.— Изге китапның бер аяте 11

Өченче бүлек. Көймәдә сәяхәт.— Су күтәрелә.— Карама агачы, кычыткан агачы.— Төрле үсемлекләр.— Җакамар.— Урман күренеше.— Гигант эвкалиптлар.— Бизгәктән саклаучы агачлар.— Маймыллар көтүе.— Шарлавык.— Төн куну 21

Дүртенче бүлек. Диңгез ярына габа юл.— Маймыллар.— Яңа елга.— Нигә су күтәрелгәне сизелми? — Яр урынына — урман.— Елан борыны.— Герберт Гедеон Спилеттан көнләшә.— Бамбук ничек яна? 30

Бишенче бүлек. Көньяк яр буйлап кайту.— Яр буе сызыгы.— Баткан кораб калдыкларын эзләү.— Һава шары калдыгы.— Табигый гавань.— Төн уртасында Рәхмәт елгасыннан көймә агып килә 38

Алтынчы бүлек. Пенкроф аваз сала.— Хәрабәдә төн куну.— Герберт ук ата.— Сайрес Смитның тәкъдиме.— Көтелмәгәндә чарасы табылды.— Гранит сарайда нилар булган? — Яна хезмәтче 47

Җиденче бүлек. Кичектергесез эшләр.— Рәхмәт елгасы аркылы күпер.— Күзәтү яссылыгы утрауга әвереләчәк.— Күтәрелмә күпер.— Уңышны урып-җыю.— Чишмә.— Кечкенә күперләр.— Кош-корт кетәге.— Күгәрчен оясы.— Онагрлар.— Ат җигү.— Һава шары портына бару . 57

Сигезенче бүлек. Эчке кием-салым.— Тюлень тиресеннән тегелгән аяк киемнәре.— Пироксилин ясау.— Яшелчә утырту.— Балык тоту.— Ташбака йомыркалары.— Юп абзыйның уңышлары.— Мал утары.— Муфлоннар аулау.— Үсемлек һәм хайваннар дөньясының яңа байлыклары.— Еракта калган илләрен сагынып искә алу. 66

Тугызынчы бүлек. Көннәр бозылды.— Су көче ярдәм итә.— Тәрәзә пыяласы һәм пыяла савыт-саба ясау.— Саго пальмасы.— Мал утарына барып йөрүләр.— Терлекләр үрчи.— Журналистның соравы.— Линкольн утравының төгәл координатлары.— Пенкрофның тәкъдиме . .

Унынчы бүлек. Кораб ясау.— Икенче уңышны урып җыю.— Сумкалы аю аулау.— Файдасына караганда матурлыгы сокландырырлык үсемлек.— Диңгездә — кит.— Вайнъярдта ясалган гарпун.— Кит түшкәсен эшкәртү.— Кит мыегын файдалану.— Май азагы.— Пенкрофның дөньясы түгәрәкләнде 84

Унберенче бүлек. Кыш.— Йон әзерләү.— Тула басу.— Пенкрофның бәйләнчек фикере.— Кит мыегыннан алдавыч әзерләү.— Альбатросның ярдәме.— Киләчәк гасырлар ягулыгы.— Топ белән Юп.— Өермә.— Кош кетәгендә җимерекләр.— Сазлыкка сәяхәт.— Сайрес Смит өйдә кала.— Коены тикшерү 93

Уникенче бүлек. Корабны җиһазлау.— Кыргый этләр һөҗүме.— Юп җәрәхәтләнде.— Юпны дәвалау.— Кораб ясалып бетте.— Пенкроф тантана итә.— «Хәерле юл».— Утрауның көньяк очына диңгез буйлап беренче сәяхәт.— Диңгездән табылган шешә 103

Унөченче бүлек. Утрауга бару хәл ителде.— Төрле фаразлар.— Юлга җыену.— Өч сәяхәтче.— Беренче төн.— Икенче төн.— Табор утравы.— Комлы яр буеннан эзләнүләр.— Урманда эзләнүләр.— Утрауда беркем юк.— Хайваннар.— Үсемлекләр.— Йорт.— Өй эче буш . . . 115

Ундүртенче бүлек. Әйбер-сәйберләрнең исәбен алу.— Төн.— Берничә хәреф.— Эзләнүләрне дәвам иттерү.— Үсемлекләр һәм хайваннар.— Герберт чак исән калды.— Корабта.— Утраудан китү.— Көн бозыла.— Гадәт онытылмаган.— Диңгездә адашу.— Коткаручы ут 123

Унбишенче бүлек. Утрауга кайту.— Бәхәс.— Сайрес Смит һәм билгесез кеше.— Һава шары порты.— Өченче уңыш.— Җил тегермәне.— Он тарту, икмәк пешерү.— Инженерның фидакярлеге.— Сынау.— Күз яшьләре . . 133

Уналтынчы бүлек. Әйтелмәгән сер.— Билгесез кешенең беренче сүзләре.— Утрауда унике ел.— Гаебен тану.— Югалып тору.— Сайрес Смит өметен өзми.— Җил тегермәне салу.— Икмәк пешерү.— Тугрылык.— Гадел кешеләрнең сәламләве 141

Унҗиденче бүлек. Япа-ялгыз яшәү.— Билгесез кешенең үтенече.— Мал утарында йорт салу.— Унике ел гомер! — «Британия»нең боцманы.— Табор утравындагы тоткын.— Сайрес Смит кул кыса.— Серле язу . . . 150

Унсигезенче бүлек. Әңгәмә.— Сайрес Смит һәм Гедеон Спилет.— Инженерның идеясе.— Электр телеграфы.— Электр чыбыклары.— Батарея.— Алфавит.— Җәй.— Колония чәчәк ата.— Фотография.— Ялган кар.— Линкольн утравында ике ел 160

Унтугызынчы бүлек. Туган илләрен искә алу.— Өметләр, өметләр.— Яр буйларын тикшерү планы.— 16 нчы апрель — юлга чыгу көне.— Борылмалы ярымутрауның диңгездән күренеше.— Көнбатыш ярдагы базальт кыялар.— Көннәр бозыла.— Төн якынлаша.— Тагын бер сер 168

Егерменче бүлек. Диңгездә төн.— Акула култыгы.— Кышка әзерләнү.— Иртә килгән кыш.— Салкыннар.— Йорт эчендәге эшләр.— Алты айдан соң.— Фоторәсем.— Көтелмәгән хәл 177

ӨЧЕНЧЕ КИСӘК

Утрауның сере

Беренче бүлек. Офыкта кораб.— Айртонны чакырып кайтару.— Мөһим бәхәс.— «Дункан» түгел бу.— Шикле кораб.— Чарасын күрергә кирәк.— Кораб якынлаша.— Туптан ату.— Бриг якорь салып туктады.— Төн . . 187

Икенче бүлек. Киңәшмә.— Алдан сизенү.— Айртонның тәкъдиме.— Тәкъдим кабул ителде.— Айртон белән Пенкроф Котылу утравында.— Норфолк каторжаннары.— Пиратларның планы.— Айртонның батырлыгы.— Кире кайту.— Илле кешегә каршы алтау 197

Өченче бүлек. Томан тарала.— Инженерның әмере.— Өч җиргә сак куелды.— Айртон һәм Пенкроф.— Беренче шлюпка.— Тагын икәү.— Кечкенә утрауда.— Алты пират ярга чыкты.— Бриг якорен күтәрә.— «Җитезнең батареясы.— Өмет юк.— Көтелмәгән чишелеш . . 207

Дүртенче бүлек. Колонистлар яр буенда.— Айртон белән Пенкроф судагы әйберләрне коткаралар.— Иртән табын янында әңгәмә.— Пенкрофның фикере.— Бригны тикшерү.— Крюйт-камера исән.— Яңа хәзинәләр.— Соңгы калдыклар.— Тимер торба кисәге 217

Бишенче бүлек. Инженерның фикере.— Пенкроф зур планнар кора.— Утрауны туплар саклый.— Туптан дүрт тапкыр аттылар.— Исән калган пиратлар турында әңгәмә.— Айртон икеләнә.— Сайрес Смит кешелекле карар кабул итә.— Пенкроф теләмичә генә сүзеннән чигенә . 227

Алтынчы бүлек. Экспедиция планы.— Айртон утарда.— Һава шары портына бару.— Пенкроф икеләнә.— Утарга ашыгыч хәбәр җибәрәләр.—Айртоннан җавап юк.— Иртәгесен юлга чыгу.— Телеграф нигә тын тора.— Ату . 236

Җиденче бүлек. Журналист белән Пенкроф утарда.— Гербертны өйгә алып керәләр.— Дингезче кайгыга батты.— Инженер белән журналист.— Дәвалау.— Яралы савыга башлады.— Набны ничек кисәтергә.— Тугрылыклы хәбәрче.— Набның җавабы 245

Сигезенче бүлек. Пиратлар утар тирәсендә кайнашалар.— Вакытлы торак.— Гербертны дәвалау.— Пенкрофның эченә җылы керде — Элекке тормышларын искә төшерү.— Киләчәк нәрсә вәгъдә итә? — Сайрес Смит шул хакта уйлана 252

Тугызынчы бүлек. Набтан хәбәр юк.— Журналист белән Пенкрофның тәкъдиме кире кагылды.— Гедеон Спилет икенче тапкыр утардан чыкты.— Тукыма кисәге.— Хәбәр.— Ашыгыч күчену.— Күзәтү яссылыгында . . . 256

Унынчы бүлек. Герберт Гранит сарайда.— Набның хикәясе.— Сайрес Смит Күзәтү яссылыгына бара.— Андагы афәт.— Гербертның авыруы көчәйде.— Өянке кайрысы.— Үлем бизгәге.— Топ янә өрә 265

Унберенче бүлек. Аңлаешсыз сер.— Герберт савыга.— Экспедициягә әзерлек.— Беренче көн.— Төн.— Икенче көн.— Каури.— Казуарлар.— Урманда кеше эзләре.— Елан борыны 272

Уникенче бүлек. Борылмалы ярымутрауны тикшерү.— Шарлавык елгасы тамагында тукталыш.— Мал утарына йөз адымлап калды.— Гедеон Спилет белән Пенкроф күзәтергә киттеләр.— Алар әйләнеп кайтты.— Алга! — Ишек ачык.— Тәрәзәдә ут елтырый.— Ай яктысында . . 280

Унөченче бүлек. Айртонның хикәясе.— Элекке җинаятьче дусларының нияте.— Мал утарын яулап алу.— Линкольн утравының гадел хөкемдары.— «Хәерле юл».— Франклин тавы тирәсендә эзләнүләр.— Тау өстендәге үзәнлекләр.— Җир астыннан гөрелте ишетелә.— Пенкрофның җавабы.— Кратер төбендә.— Кайту . . . 288

Ундүртенче бүлек. Өч ел узды.— Яңа кораб төзү хакында киңәш.— Утрауда тормыш гөрләп бара.— Кораб төзү.— Көньяк ярымшарда салкыннар.— Пенкроф буйсына.— Кием-салым юу.— Франклин тавы 298

Унбишенче бүлек. Вулкан уяна.— Җәй.— Эшне башлап җибәрделәр.— 15 нче октябрь киче.— Телеграм.— Үтенеч.— Җавап.— Тизрәк мал утарына барырга! — Язу.— Яңа телеграф чыбыгы.— Базальт кыялар.— Суның күтәрелгән вакыты.— Суның кимүе.— Мәгарә.— Күз камаштыргыч яктылык 307

Уналтынчы бүлек. Капитан Немо.— Аның беренче сүзләре.— Ил азатлыгы өчен көрәшченең гомер тарихы.— Илбасарларга нәфрәт.— Капитан Немоның юлдашлары.— Су астындагы тормыш.— Ялгызлык.— Линкольн утравы.— «Наутилус»ның соңгы торагы.— Утрауның серле даһие 319

Унҗиденче бүлек. Капитан Немоның соңгы сулышлары.— Васыяте.— Бер генә көн белгән дусларына бүләге.— Капитан Немоның табуты.— Калучыларга киңәше.— Соңгы минутлары.— Диңгез упкынында 328

Унсигезенче бүлек.— Утрау хуҗалары фикер алыша.— Кораб төзү.— 1869 нчы елның беренче январе.— Вулкан өстендә

төтен баганасы.— Айртон белән Сайрес Смит мал утарына китәләр.— Даккар мәгарәсен тикшерү.— Капитан Немо Сайрес Смитка нәрсә әйткән? 336

Унтугызынчы бүлек. Сайрес Смит күргәннәрен хикәя итә.— Кораб төзүне тизләтәләр.— Соңгы тапкыр утарга бару. Ут белән су көрәше.— Утрауда нәрсә калды.— Корабны суга төшерү.— 8 нче марттан 9 нчы мартка каршы төн 346

Егерменче бүлек. Океан уртасында ялгыз кыя.— Соңгы сыеныр почмак.— Алда — үлем.— Көтелмәгән ярдәм.— Ярдәм кайдан, ничек килде соң? — Соңгы шәфкать.— Коры җир эчендә — утрау.— Капитан Немо кабере . 358

ӨЛКӘН ЯШЬТӘГЕ БАЛАЛАР ӨЧЕН

Жюль Верн

ТАИНСТВЕННЫЙ ОСТРОВ

(На татарском языке)

Редакторы *С. Сибгатуллина.* Художнигы *Г. Трифонов.* Художество редакторы *Ю. Пахомов.* Техник редакторы *Л. Тилк.* Корректорлары *М. Хәйруллина, Р. Раскулова*

ИБ № 3429

Наборга бирелде 24.04.84. Басарга кул куелды 28.08.84. Формат 84×108 1/32. Типография кәгазе № 1. Гарнитура литературная. Печать высокая. Якынча басма табагы 19,3+форз. 0,2. Усл. кр. отт. 19,9. Учетн.-изд. табагы 20,6+форз. 0,3. Тираж 28 000. Заказ Б-268. Бәясе 85 тиен.

Татарстан китап нәшрияты. 420084. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420084. Казань, ул. Баумана, 19.

Татарстан АССР Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре дәүләт комитетының Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты. 420084. Казан, Бауман ур., 19.

85 тиен